
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2002





**Кичке моң**

*Шагыйрь Гакыйл Сәгыйров рәсеме*

Казан утлары

Qazan utları

2002

7

(957)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## *Бу санда*

### ШИГЪРИ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Һәрнәрсәгә—акчалата. *Роман* ........ 5
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Туйкә буйларыннан кояш калка. *Шигырьләр* ........ 61
Госман САДӘ. Каридел аръягында. *Шигырьләр* ........ 89
Резеда ВӘЛИЕВА. Бәхетле булыгыз, дусларым!.. *Шигырьләр* ........ 93
Әмир МӘХМҮДОВ. Ак төшләр. *Шигырьләр* ........ 114
Сәйдә ЗЫЯЛЫ. Сөю дәвамы. *Шигырьләр* ........ 117

### ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Нурихан ФӘТТАХ. Сармат кызы Сәринә. *Тарихи драма* ........ 64

### ПУБЛИЦИСТИКА

Рафаиль ХӘКИМ. Кем син, татар? ........ 97
Нурулла ГАРИФ. Син яшәсәң, без дә яшәрбез ........ 120
Хәлең ничек, татар китабы? *(Түгәрәк өстәл янында әңгәмә)* ........ 139

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Очмыйча син түзеп кара... ........ 133

### ТАРИХ

Гомәр САБИРҖАНОВ. Әхмәтһади Максудиның иҗади мирасы сәхифәләреннән ........ 144
Фатих УРМАНЧЕ. Мең ярым ел элек ........ 149

### КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

27—Нәмел (Кырмыска) сүрәсе ........ 158

### ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Гомәр САТТАРОВ. И газиз телем! ........ 163

### МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Рифә РАХМАН. Төрек-татар әдәби бәйләнешләренең кайбер сәхифәләре .. 172

### ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Тәлгат НӘҖМИЕВ. Хикмәтле хәлләр ........ 182
Рафаэль МОСТАФИН. Бер рәсем тарихы ........ 188
Укучы сүзе ........ 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Р. МИР-ХАЙДАРОВ. Роман «За все—наличными» *(начало);* стихи И. ГИЛЯЗОВА, Г. САДЭ, Р. ВАЛИЕВОЙ, А. МАХМУДОВА, С. ЗЫЯЛЫ.
«Драматургия»: Н. ФАТТАХ. Историческая драма «Дочь Сармата Сарина».
«Публицистика»: Р. ХАКИМ. «Кто ты, татарин?» *(начало);* Н. ГАРИФ. «Ты будешь жить—мы будем живы»; «Рухият» и татарская книга» (беседа за круглым столом о книгах из серии «Наши знаменитости» изданных издательством «Рухият»).
«Литературная критика»: статья С. ХАФИЗОВА «Попробуй жить без полета».
«История»: статьи Г. САБИРЗЯНОВА «Страницы из литературного наследия Ахмедхади Максуди», Ф. УРМАНЧЕ «Полторы тысячи лет тому назад».
Коран на татарском языке.
«Актуальная проблема»: статья Г. САТТАРОВА «О мой родной язык!»
«К истории культуры»: Р. РАХМАН. «Некоторые страницы турецко-татарских литературных связей».
«Юмор-сатира»: Т. НАЗМИЕВ. Забавные истории.
Р. МУСТАФИН. История одной фотографии.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Лето»—фотоэтюд А. Бикмухаметовой; поэтесса Ф. Зиятдинова.

## IN OUR ISSUE:

"Prose and poetry": R. MIRKHAIDAROV'S novel «Cash for anything» (beginning); the verses I. GILIAZOV, G. SADA, R. VALIEVA, A. MAKHMUDOV, S. ZYALI.
"Dramatics": N. FATTAKH. Historic drama "Sarmat Sarin's daughter".
"Journalism": R. KHAKIM "Who is you, Tatar" (beginning), N. GARIF "You'll live - we'll live"; "Rukhiat" and Tatar book (round-table talk)
"Literary criticism": S KHAFIZOV'S article "Try live without flight".
"History": G. SABIRZANOV'S article "The pages from Akhmedkhadi Maksudi's literary legacy. F URMANCHE'S article "One thouand and half years ago".
Koran in Tatar language.
"Actual problem": G. SATTAROV'S article "Oh, my native language".
"History of culture": R. RAKHMAN "Tatar and Turkish literary bounds".
"Humor and satira": T. NAZMIEV "Amusindly stories".
R. MUSTAFIN "The story of one picture".
Reader words.
The diary of social and cultural life.
In our covers: "Summer" - photostudy of A. Bikmukhamedova; poet F. Ziatdinova.

*The magazin edits monthly*

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 24.06.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—329
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.



## Рауль Мирхәйдәров

# ҺӘРНӘРСӘГӘ—АКЧАЛАТА

РОМАН

*Ренарга багышлана.*

*Үләт килә—типтерел кал.*
*Әйтем.*

### Тәрҗемәчедән

*Рауль Мирхәйдәровның әти-әниләре Оренбург татарларыннан булган. Үзе саф татар телендә сөйләшә белсә дә, Казакъстанда яшәп, рус мәктәбендә укыган, урысча югары белем алган төзүче-инженер ул—шуңа күрә әсәрләрен урыс телендә яза. Әмма барыбер үзен татар әдибе дип саный.*

*Ләкин, ни кызганыч, рус телендә дүрт дистәдән артык китабы миллионлаган тиражлар белән нәшер ителсә дә, Рауль Мирхәйдәров иҗаты татар укучысына бик аз таныш әле. Аның татарча басылып чыккан әсәрләре— «Безне онытмагыз...» повесте (Хәйдәр Гайнетдинов тәрҗемәсе. «Казан утлары» журналы, №4—1982 ел), «Игълан буенча танышу» повесте (Вакыйф Зыятдинов тәрҗемәсе. «Казан утлары» журналы, № 4—1998 ел), «Ирталәгән сагыш» романы (Марс Шабаев тәрҗемәсе. «Казан утлары», №№ 8, 9, 10—2000 ел), «Аккош» хикәясе (Марс Шабаев тәрҗемәсе. «Идел» журналы, №№ 2-3—2001 ел). Нибары менә шулар әлегә. Рауль Мирхәйдәровның катлаулы тормышы һәм иҗаты турында Флүс Латыйфи «Үзебезнеке» («Казан утлары», № 4—1998 ел), Равил Фәйзуллин «Замана язучысы» («Казан утлары», № 8—2000 ел), Рафаэль Сибат «Хәтер һәм мәхәббәт» («Казан утлары», № 8—2001 ел) исемле мәкаләләр белән чыкты. «Ирталәгән сагыш» романының аерым өзекләре «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталарында да басылды. «Татарстан» журналының 2001 елгы 4 нче санында Р. Мирхәйдәров белән «Читкә тибәрмә безне, Казан» дигән бик әтрафлы әңгәмә дөнья күрде.*

*Әле телгә алынган әсәрләренең төп каһарманнары—татарлар. Иҗатының беренче чорында, нигездә, үзе күргән-кичергәннәрен әдәби әсәрләренә салган Р. Мирхәйдәров*

*Кыскартылган журнал варианты.*

*соңгы ун-унбиш ел эчендә элекке совет мафиясе һәм хәзерге рус мафиясе, «яңа руслар» тормышына багышланган бик кискен-үткен сәяси-социаль детектив романнары белән танылды.*

*Журналыбыз укучыларына Рауль Мирхәйдәровның «Һәрнәрсәгә—акчалата» дигән детектив романын тәкъдим итәбез. Романның төп каһарманы—1923 елда Америкага күчеп киткән атаклы Казан рәссамы Николай Фешинның оныгы Константин Фешин (кушаматы—Тоглар). Ул—ялган акчалар, Америка долларлары ясаучы. Хәер, әсәрнең эчтәлеген сөйләп тору кирәкмидер, укучылар үзләре укып рәхәтләнсен.*

*Тәрҗемәчедән бер искәрмә: романдагы җинаятьчеләр телендә «төрмә жаргоны» булган сүзләрнең күбесе тәрҗемә ителмәде. Җинаятьчелекнең милләте юк бит. Россия киңлекләрендә яшәүче җинаятьчеләр, кайсы гына милләттән булсалар да, аларның гомуми уртак жаргоны бер. Шундый жаргон сүзләрнең кайберләрен китереп узабыз. Менә алар: к а т а л а —кәрт уенында бик оста хәрәмләшүче; к а т р а н —качып кәрт уйный торган яшерен урын; б р а т а н , б р а т в а —җинаятьчеләрнең бер-берсенә эндәшү сүзләре; л о х, ч ә й н е к —аңгыра, томана, мокыт; к с и в а —паспорт, документ-фәлән; х а з а —йорт; м е н т —милиционер; а в т о р и т е т , п а х а н —өер, төркем башлыгы; л и м о н —миллион; б а к с — яшел—доллар акча; з а п а д л о —иң кабахәт түбәнлек эшләгән җинаятьче; к о р е ш —тамырдаш, дус; ф о м к а —хәнҗәр; ф а р ц о в щ и к —төрле чит ил акчаларын, бигрәк тә АКШ долларларын сатып йөрүче; х а л д е й —ялагай хезмәтче; ф а р т —бәхет, уңыш; р э к е т —куркытып-талап алу; к и л л е р —акчага ялланып кеше үтерүче. Янә башка сүзләр дә очраргa мөмкин, алары текст эчендә аңлашыла булыр.*

*Тагын шунысын да әйтеп узыйк: Р. Мирхәйдәровның татар телендәге беренче китабын—«Иргәләгән сагыш»ны Татарстан китап нәшрияты быел нәшер итә.*

*Ә хәзер—әдипнең «Һәрнәрсәгә—акчалата» романы сезнең хөкемгә, хөрмәтле укучылар!*

Марс ШАБАЕВ.

## Качу

### I

Карангы август төне.

Бик затлы ак костюм кигән ике егет Күктүбәдәге казино ишегеннән атлап кергән бер вакытта, Кырымнан мең чакрымнар ераклыктагы бакчаларга күмелеп утырган чечен авылы Али-Йорт башындагы юл читендә ялгыз бер ир, Грозныйга бара торган машиналарның берәрсен туктатырга теләп, кул күтәреп тора иде. Аның өстендә—кыйммәтле «Найк» спорт костюмы, кулында—зур теннис сумкасы. Биредән Ичкерия башкаласына кадәр кырык чакрымлап ара. Әллә тулып киләләр, әллә зиннәтле «мерседес», «феррари», «вольво» һәм «мазерати» ише машиналарның хуҗалары чит кешене утыртасылары килми—ажгыртып гамьсез генә узалар да китәләр, узалар да китәләр. Чеченнәр тыз-быз килеп, бәрелеп-сугылып йөрүчеләрне яратмый, төгәлрәк әйткәндә—куралмый, түбәнсетеп карый, шуңа күрә юл читендәге ир кеше күзне сукырайтып үткән фаралар яктысында үз дәрәҗәсен белеп кенә, тыныч басып тора, әйтерсең, ул беркая да ашыкмый иде.

Әмма Грозныйга юл тотучы бу сәер төнге адәм, чынлыкта, ашыкканнан да артык ашыга—тагын ярты сәгатьләп торса, аның янә ireген югалтуы бар. Чираттагы машина үзе яныннан выжылдап узып киткәндә, ул Швейцариядә эшләнгән, бик сирәк очрый торган «Юлисс Нордан» сәгатенең карангыда яктырып күренүче телләренә гасабиланып карап ала һәм үзенең котылу мөмкинлеге кимегәннән-кими барганын искәрә иде. Ерактагы машина фараларының утларын күреп, ул янадан

үзен кулга ала, янадан кулын күтәрә, юкса килеп туктаган лимузинда үзен эзәрлекләүчеләр булырын да чамалый.

Чираттагы машина иске генә, кыршылып беткән «жигуленок» иде, ул узып китте дә кинәт туктап, артка чигенде. Тәнге сәер адәм машина кабинасының ачыла төшкән тәрәзәсенә иелеп чечен телендә сорады:

—Сез мине Грозныйга илтеп ташлый алмассызмы икән? Бик кирәк иде,—дип, учында яшереп тоткан йөзәр долларлык ике акча күрсәтте.

—О, югары тариф!—дип сызгырып куйды рульдәге яшь егет һәм, янәшәсендәге хатынга карап алып, русчалап дәвам итте:—Менә, хатынымны өйгә кертеп чыгыйк та—бирелә якын гына—аннары ыжгыртырбыз. Мондый төшемле эштән баш тартсаң, гөнаһ булыр, юкса, дөресен әйткәндә, эт булып арыган идем инде.

—Юлда рульгә мин утыра алам,—диде сәер пассажир.

Иске «жиделек»нең хуҗасы, күрәсең, шаян шат күңелле кеше иде:

—Юк, юк, мондый акчага комфорт һәм музыка белән генә,—дип, магнитофонын бар көченә ачып җибәрде.

Әйтерсең лә, машинаны алмаштырып куйдылар, ул урыныннан ыргылып кузгалды, беркавым әрсезләнеп, үзе яныннан выжылдап узып киткән галәмәт зур «калиллак»ны куып җитәргә дә маташып карады. Арттагы утыргычка кереп сеңгән пассажир, күзләрен йомып, черем иткәнгә салышты—аның сүз куертасы килми иде.

Бер ун минуттан ул сиздермичә генә артка борылып карады: куып килүче лимузиннар да, тиз йөрешле джиплар да күренми иде. Үзен тулы ышанычлы итеп тоймаса да: «Ычкындым бугай»,—дип уйлап алды качак. Хәер, тормышы өчен курку хисе дә юк иде аның. Әгәр тота-нитә калсалар да, аны кыйнамаслар иде, мөгаен. Анардан битәр, аны саклап торган кешеләрне үтерерләр иде. Ул, ихтимал, җир йөзендәге иң кирәкле, иң кыйммәтле тоткын булгандыр. Юк, ул үзен начар саклаганлыктан гына түгел, ә тоткынлыкта булган өч елы буена качарга бик җентекләп әзерләнгәнлектән генә качып китә алды. Елдан-ел ул үз тирәсендәгеләрнең сизгерлеген йомшартырга тырышты, сакчыларны үзенә күнектерделәштерде, үз сәгатен көтте—ул үзен алтын читлектән беркайчан да тере килеш чыгармаячакларын белә, чөнки ул аларга гомерлеккә, гүргә кергәнче кирәкле кеше иде.

Аның сакчылары аптырый: бу тоткынга башка тормышка омтылу нигә кирәк? Аның һәр теләге, һәр капризы берсүзсез үтәлә, аның тирәсендә йөгерешеп кенә йөриләр—эшләсен генә! Шуна күрә аның беләгендәге «Юлисс Нордан» сәгате дә элеккеге советлар илендәге бердәнбер сәгать булгандыр, мөгаен. Яшереп торасы юк, ул үз эшеннән тәм таба, зур рәхәтлек кичерә—моны аның хуҗалары да белә, аның таланты-осталыгы һәм алтын кулларына сокланмаган кеше юк иде. Шулай булса да, тоткын үзенең качачагына нык ышана—аның тормыш сөючән холык-табигатен ирексезләп, буйсындырып тотарлык көч дөньяда юк. Мондый очракларда сакчылар белән тоткын арасында күзгә күренмәс астыртын көрәш бара. Акыл көрәше. Тоткынның бернәрсә белән дә чагыштыргысыз максаты—тормыш, ирек, ә тегеләрнең исә—бары тик үз мәнфәгате, файда. Ләкин аларны, һичшиксез, җинәргә—качып китәргә катгый карар кылынган иде инде. Тигезсез көрәш тойгысы, еллар буена «мәче-тычкан» уены күңелне гел тырнап тора иде. Һәм шулай килеп чыкты да: бу «уен» өч елга сузылды.

Машина, көтмәгәндә олы юлдан авыл юлына борылып керде дә, еракта утлары җемелдәшкән авылга таба чаба башлады. Алар нык-таза бер таш йорт янына барып туктадылар. Йорт янәшәсендә алсу әрмән ташы—туфтан салынган җыйнак кына мәчет тә бар иде. Шоферның хатыны, машинадан төшә-төшешли, ихтирам белән генә чечен телендә берәр чынаяк чәй эчеп чыгарга йортка чакырды. Качкын, рәхмәт хисе белән, үзенең арыганлыгын, машинада гына утырып көтәчәген әйтте.

Машина хуҗасы озак көттермәде—бераздан ул канистр күтәреп

килеп тә чыкты һәм үзенең калтырчасына тутырып бензин салды. Аңа ияреп машина янына туганнарыннан тагын кемдер—әллә әтисе, әллә энесе, бәлки, өлкән абыйсыдыр,—чыкты. Ул «Жигули»ның ишеген ача төште, качкын белән кул биреп күрешкәннән соң, юлда, бигрәк тә Грозныйда саграк булырга киңәш итте.

—Явыз заман, явыз кешеләр,—диде ул хушлашканда һәм кулын мөселманча күтәреп амин итте.

Ни әйтсәң дә, носари рус бит, күңеле карышса да, «амин» хәрәкәтен качкынга да ирексездән кабатларга туры килде. Нишлисең, кайвакыт хәл-вакыйгалар бездән көчлерәк була шул.

«Жиделек», чечен музыкасын яңгыратып, аңарга тыңгы белмәс хуҗасы да ярымтавыш белән кушылып җырлый-җырлый, Грозныйга таба җилдертте. Юл буена алар бары тик әһәмияте аз булган берничә генә сүз алыштылар—үзенең яшьлегенә һәм башсызлыгына карамастан, шофер бу юлчының, никадәр яшерергә тырышса да, нәрсәгәдер бик нык борчылганын аңлап алган иде. Шуңа күрә ул да артык сүз куертырга базмады. Юкса аның бик тә сөйләшәсе килә—төнге пассажиры аның үзенә дә, хатынына да ошап калган иде. Йокылы шәһәр башына барып кергәч кенә, ул сорап куйды:

—Сезне кая илтү яхшырак булыр?

Юл буе шул хакта уйланып килгән качак кистереп кенә әйтте:

—Рәхим итеп, автовокзалга,—диде.

Аэропортка бару үзеннән-үзе кире кагылган иде—качакның бер документ-фәләне дә юк бит. Дөрес, хәзер поездларда да паспорт сорыйлар, дип сөйлиләр. Бигрәк тә каһәрле Чечня халкын тинтерәтәләр икән. Димәк, качак өчен иң яхшы транспорт булып бары тик автомобиль генә кала.

Көтмәгәнчә җанлылык хөкем сөргән төнге автовокзалга килеп житкәч, пассажир килешенгән ике йөз долларын биргәндә, кесәсеннән тагын бер йөзлек доллар чыгарып, аптырабрак калган шоферга сузды:

—Синең йортың янәшәсендә мәчет бар, иртән шунда кереп, Аллаһы Тәгаләгә дога кыл, минем бик зур борчуларым бар,—диде.

—Мин ничек ярдәм итә алам?—дип кабынып китте шофер егет.

—Юк, рәхмәт, син мөмкин булганын эшләдең инде. Сау бул.

Аның бу гамәле бер мизгелгә күңеле йомшап китүдән яисә хискә бирелеп әсәрләнүдән түгел—ул моны алай-болай берәр хәл килеп чыгудан саклану чарасы итеп һәм ышанычлы итеп эшләде: үзенең бәласен әйткән яки ярдәм сораган кешене чечен бервакытта да сатмаячак.

Төн уртасы булуга карамастан, автовокзал гөрли-кайный: шәхси машиналар берсе артыннан берсе килеп-китеп тора, зур мәйданда качак бер генә автобус та яки күз ияләшкән сары шакмаклы бер генә такси да шәйләмәде. Күбрәк «Жигули»лар, төрле төстәге «Волга»лар һәм, әлбәттә, чит ил маркалы машиналар... Алар Кавказ, Ставрополь, Кубань, Ростов-Дон тирәләренә башка якларга караганда алданрак килеп тулган һәм теркәлгән иде.

Качак, машина номерларына илтифатсыз гына карый-карый, ашыкмый гына бөтен мәйданны йөреп чыкты һәм пассажирларны шәхси машиналарда ташуның ни өчен шулай җанлануын тиздән аңлап алды. Самолетлар очса оча—очмаса юк, поездлар йөрүне бер ярты еллап элек туктатканнар—ул бу хакта газетлардан да укыган, үзара сөйләшүләрдән дә ишеткән иде инде. «Бер яманның—бер яхшысы» дигән мәкальне исенә төшерде ул, димәк, бу хәлләрнең барысы да аңа кулай гына. Машина номерларына һәм аларның хуҗаларының кычкырып чакырып торуларына караганда, ул хәзер теләсә кай якка—Нальчигына, Владикавказына, Сухумиенә, Ставрополенә китеп бара ала, әмма аңа исә бары тик Ростовка гына барырга кирәк иде. Ләкин Кубань ягына машиналар күренмәде...

Автовокзал биләмәләрен карап йөри торгач, арт якта ул шашлычныйга барып төртелде, шунда ук кулдан гына хинкали да сата иделәр, анысын, мөгаен, якындагы йортларда пешерәләрдер инде. Качак, озын

юл алдыннан капкалап алу зарар итмәс, дип уйлап алды. Нервылары гел киеренкелектә булгангадыр, күрәсең, аның кинәт үлеп ашыйсы килә башлады. Кыршылып беткән пластик өстәлләрнең рәтлерәк күренгән берсен сайлап, ул сарык итеннән әзерләнгән биш-алты шашлык белән бер тәлинкә грузин хинкалие китерүләрен сорады—бу елларда ул шул тәмле азыкка һәвәсләнеп киткән иде. Парда пешерелгән шундый ук бер тәлинкә пилмән күтәреп, аның янына елгыр гына бер егет тә килеп утырды, ләкин аңа тыныч кына ашарга биш минут та бирмәделәр, әледән-әле шоферлар йөгереп килә торды—алар бәяләрне һәм барасы юлларын килештерә, бер-берсеннән зарлана иделәр. Әйе, бу бәхет иде—качак каршындагы егет, автовокзал хуҗасы ук булмаса да, аның төп ярдәмчеседер, хуҗасы бу минутларда берәр җирдә күңел ачадыр. Бер җай табып, кавказ әсире егеткә чечен телендә эндәште:

—Энекәш, мине бик тиз генә Ростовка утыртып җибәрә алмассыңмы икән? Судка барырга соңга калам, өлгермәсәм, гөнаһ булыр...

Егет өстәлдәшенә игътибар белән карап алды, аның яхшы түләячәген чамалады бугай, дустанә елмаеп җавап бирде:

—Изге эш, Аллыйм. Ләкин, бик кызганыч, бүген Ростов машиналары күренми. Әмма хәл итеп булмастай хәлләр юк, дөресме? Ростовтан әйләнеп кайтырга теләүчеләрне эзләп карарга мөмкин... Үзләре теләп барырга теләүчене тапмасак, берәрсен мәҗбүр итәрбез, әмма бу гамәл...—ул бераз уйланып торды да,—сигез йөз бакс булыр,—диде.

—Сигез йөз минем өчен күбрәк, энекәш. Телеграмманы бер сәгать элек кенә алдык, туган-тумачаны йөреп чыгарга вакыт җитмәде, биш йөзгә килешергә тырышып кара әле.—Үзенең акчалы булуын бу елгыр егетләрнең сизеп алуын теләми иде ул. Сүзен дәвам итеп, өстәп куйды:—Тик машинасы калтырча булмасын, яна булсын иде, шоферының да ялгызы гына булуы шарт. Кирәге чыкса, юлда аны үзем алыштыра алам.

—Яхшы, яхшы. Җитди кешеләрне яратам мин. Болгавыр заман, юл озын... Төн... Әмма сиңа фарт килде, машиналарны мин үзем җибәрәм бит. Исемем Абдулла, кушаматым—Зуко,—дип, егет соңлабрак булса да, үзе белән таныштырды һәм өстәл аша төсле татуировкалы нык-таза кулын сузды.

Латинамерикан кушаматлы бу яңа танышы бик озак—сәгатьтән артык югалып торды, качак ул арада ике чәйнек чәй эчеп бетерде. Шуннан соң гына тирә-яктагы барлык тыюлы билгеләргә дә карамастан, өстәл янына ук кинәт кенә аксыл-көрән төстәге «Волга» килеп туктады, аның номерлары Ставропольнеке иде.

—Менә сиңа шәп чабышкы, туган, менә җайдагы—ышанычлы егет. Әгәр ул-бу килеп чыкса, мин аны җир астыннан да табачакмын,—дип еш-еш тезеп китте машинаның арткы ишегеннән ишелеп килеп чыккан Абдулла.—Аванс итеп йөз долларыңны төрт тә, калган дүрт йөзен барып җиткәч Андрюхага бирерсең. Бәхетле юл!

Качак Зукога йөзлек доллар тоттырды. Машина Кавказда мәңге онытылмас «Сулико» көеннән озын итеп аккорд бирде дә урыныннан җегәрле генә кузгалып китте.

«Хуш, Чечня! Хуш, Грозный! Хуш, Кавказдагы әсирлек!»—дип кычкырасы килде качакның. Әмма ул, йөрәге шатлыктан менә-менә сикереп чыгардай булса да, үзен тыеп кала алды.

Ставрополь Андреенең «Волга»сы, күрәсең, Төньяк Кавказда арыбире даими йөреп торадыр, ГАИ постлары янында егет каушамый гына машинасыннан чыга, юл хәрәкәте хезмәткәрләре белән кул биреп, салкын гына исәнләшә һәм, тартынып-нитеп тормыйча, агай-энеләрчә генә сөйләшә—боларның берсе дә күзәтүчән пассажирның игътибарыннан читтә калмады. Моңысы да бәхет иде—димәк, аның документларын тикшереп, сумкасында казынып тормаячаклар: боларның берсе дә кирәкмәс иде. Машинаның магнитофонлы радиоалгычы булса да, Андрюханың язмалары гел төрмә җырларыннан гына тора икән, шуңа күрә качак

әледән-әле радионы тоташтырырга сорап барды. Мәскәүдән соңгы хәбәрләрне тыңлаганда, ул ирексездән елмаеп уйлап куйды: тапшыру менәменә өзелер дә чечен радиосы бик каты саклап тотылган әсирнең качуы, аның төсе-кыяфәте, аерым билгеләре, чама белән яше һәм нинди киемнән булуы турында хәбәр итәр шикелле тоелды. Бары тик Андрейның машинасында барганда гына ул соңгы өч елында—ә бу шашкан Россиядә аз вакыт түгел—үзенең ниндидер чын булмаган кинолардагыча тормыш белән яшәгәнлеген аңлап алды. Шулай булгач, чираттагы бирәр ямьсез хәлгә тармас өчен аңа кискен рәвештә хәзерге кырыс, шәфкатьсез дөньяга кайтырга кирәк иде. Машина Ростов ягына таба зур тизлек белән җилдерсә дә, ул әле бик озак үзенә иркенәеп, бушанып калырга ирек бирмәде.

Бу яңа тормышны тизрәк аңларга-төшенергә тырышып, ул шофердан сорады:

—Номерыгызга караганда, сез Ставропольныкы... Анда гади кешеләр, зыялылар үзләренең атаклы якташларына ничегрәк карыйлар соң?

—Горбачевка, дисезме?—егет ачыкларга теләп, кайтарып сорады.

—Әйе, әлбәттә, шуңа. Ул бит сезнең яклардан шулай югарыга кунаклаган берәү генә...

—Һәм Аллага шөкер. Андый залимның берсе дә бик житкән.—Егет усал итеп аты-юлы белән сүгенеп куйды.

—Ни өчен алай бик сүгәсез аны? Ул бит сезгә ирек бирде, кәсәбәчелекне рөхсәт итте. Элек, мөгаен, болай ачыктан-ачык акча суга алмас идегез әле...

—Ә элек аның артык кирәге дә юк иде,—дип җавап кайтарды Андрюха.—Ростовка Грозныйдан көненә ике мәртәбә йомшак урынлы автобус йөреп тора, билеты да унсигез сум гына иде. Ә Абдулла сездән күпме каерды? Менә шул шул—кешеләрнең акылын томалый алмассың, халыкның күзе ачыла башлады.

—Күрәм, сез сәясәтче, менә дигән трибун икәнсез,—дип тагын да дәртләндерде аны качак, егетнең ярты сүздән үк кабынып киткәненә ишарәләп.

Тегесе кинәт көлеп җибәрде:

—Ә сез, әйтерсең, айдан төшкәнсез, өч ел мич башында утырган әкияти Иванушка шикелле, Горбачев турында сорашасыз. Башка берәү булса, моның өчен авызына менеп төшәргә дә күп сорамас... Әлегә ул Россия-анакайга хәерчелек белән ызгыш-талаш кына китерде, ә тиздән, ах, сизәм—бик тиздән рус каны коелачак. Мин гади эш аты гына, сезнең Чечнягызда һәр атнада булып торам, сугышның котылгысыз икәнен дә күрәм. Сездә ярты миллион халык коралллы хәзер, закон буенча һәр чечен корал йөртергә хокуклы, автоматларны базарда карбызлар белән янәшә саталар, патроннарны бәрәңге алган шикелле чиләкләп алалар. Шундый ризасыз-канәгатьсез һәм сугышчан халыкка тау-тау корал, авыр артиллерия, минометлар, «Град» ракеталары, самолетлар калдырырга ярый идеме соң? Анда хәзер һәркайдан малларны куып алып китәләр, машиналарны урлыйлар, поездларны кычкыртып талыйлар. Ә Мәскәүдәге ахмаклар байлык төяп состав арты состав җибәрә тора, нефтьүткәргечләр тәүлегенә егерме дүрт сәгать буена Грозныйга эшкәртү өчен нефть куа, үз заводлары исә нефтьсез, эшсез тора. Рус акчасына Дудаев армия төзи, «Борз» автоматлары эшләп чыгаруны агымга куйган. Мөгаен, Мәскәүдә Ак йортта да, Думада да йөк төялгән составлар, нефть һәм кораллар өчен байтак кешенең кесәсенә акча явадыр. Халык барын да күрә, барысын да аңлый... Бу җепнең очы безнең залимнан башланганын—аны якташ дип әйтергә тел әйләнми—халык бик яхшы белә: бу ботканы ул пешерде бит. Элек Русьта Иван Сусаниннар булган, ә хәзер Мишка Горбачевлар заманы...—дип әрнеп сүзен тәмамлады егет һәм озакка тынып калды.

«Менә, чын тормышка беренче сәяхәт тә ясалды. Мондый сорауларын өчен, чынлап та, берне менеп тә төшүләре ихтимал»,—дип күңелсез йомгак ясады пассажир. Чечняда сугышка әзерләнгәннәрен ул беркем

белмәгәннән дә артык белә, һәм, рус буларак, бу бәланен киләсен тиешле урынга хәбәр итә алмавына изалана иде, ә баксан, моны инде гади шофер да белә икән. Бөек Ватан сугышы алдыннан да шулай булган бит, немецлар, кем әйтмешли, инде ишек төбендә, ә без аларга һаман состав арты состав: икмәген, күмерен, корычын жибәрүне дәвам иткәнбез... Янадан шул ук тырмага басабыз, әле тагын да яманрак итеп—үзебезне киләчәктә үтерүчеләрне үзебез үк коралландырабыз һәм туендырабыз.

Ләкин хәзер сәясәт турында уйлыйсы килми, ниндидер эчке тавыш пышылдап тора: «Син ин элек үзен турында уйла, исемсез, фамилиясез, паспортсыз-нисез син кем хәзер?»

Хәзер документларсыз бер адым да атлый алмыйсын, һәркайда чикләр, шлагбаумнар, һәр жирдә «аусвайс» таләп итәләр.

Урлап алып китүчеләре анын гомерлеккә үз кулларында калачагына шул кадәр ышанганнар иде ки, беренче уңышларыннан канатланып китеп һәм күнелләре йомшарып, берсе шунда аны урлап кына калмаганлыкларын, янәсе автокатастрофада һәлак булганлыгын да оештырганлыкларын әйтеп ташлаган иде. Куып алып киткән машинаны да кызганып тормаганнар, ә ана охшаш кеше мәетен танылмаган һәм сорап алынмаган мәетләр арасыннан атна буе сайлаганнар. Урланган тоткынны эзләү беркемнең дә башына килмәсен өчен бик нык тырышканнар инде—анын бит теләсә кемне жир астыннан да эзләп таба ала торган адәмнәргә дә кирәге чыгуы бар иде. Хәтерендә әле, урлаучыларына ул шундый сорау биргән иде: «Ә сез минем үлгәнлегемне искә алу мәҗлесе үткәрдегезме сон?» Тегеләр шаркылдап көлеп жибәрделәр. Берсе: «Юк, башыбыз житмәде,—диде һәм өстәп куйды:—Ләкин сине еш искә алганлыкларын, менә ул чын оста, алтын куллы иде, дигәнлекләрен яхшы беләбез»,—диде.

«Өч ел элек минем паспортым һәм машина йөртү таныклыгым кем исеменә иде сон әле?!»—анын башына ирексездән шундый сәер уй килде һәм үзенен ул вакытта Игорь Трофимович Селезнев булып йөргәнлеген хәтеренә төшерде. Әмма урлаучыларына анын фамилиясе әһәмиятле түгел, аларга атаклы Тогларнын катастрофада янып үлүе турында хәбәр тарату мөһим иде—аны шулай Тоглар итеп күмеп тә куйдылар.

Качак үзе дә һәр эш-гамәлен озаклап, жентекләп әзерләргә ярата иде, шуна күрә ул чеченнәрнен зирәклеген бәяләми булдыра алмады: нигә аларга Мәскәүдәге жинаятьчел төркемнәр белән болай да киеренке булган мөнәсәбәтләрен кирәкмәгәнгә тагын да кискенләштереп торырга, ди? Әгәр дә анын урланганын элекке мәктәпне үткән караклар—үз даирәсендәге Япончик, Захар, Сильвестер, Карт Шакро, Сво кебекләр белеп алса, алар шундук лаеклы «бартер» оештырыр иделәр, монын өчен башкала-ташкалада исемле вә бай чеченнәр житәрлек бит. Әмма булган—беткән, үткән эшкә салават. Хәзер ул янадан туган шикелле булып чыга. Бу уйдан качак бераз күнелләнеп тә китте, хәтта елмаеп куйды, тик бу елмаю бер мизгел булып алды да сүнде...

«Иртәгәдән минем исемем ничек булачак сон әле?»—дип янә уйга чумды ул, ләкин, күпме генә тырышмасын, үзенен «яна исемен» хәтеренә төшерә алмады. Анын мондый хәлгә таруы беренче тапкыр: хәтере искиткеч яхшы, мөгаен, ул, берәр бит текстны бер укуда хәтерләрендә калдырып, сәхнәдән сөйләп бирүчеләр белән дә ярышыр, яна гына укылган берәр поэманы шундук үзе дә сөйләп бирә алыр иде. Халык теленә монарчы таныш булмаган «компьютер» сүзе килеп кергәч, ничектер бер кәеф-сафа корып утырганда ул вакытта әле «карт» тагылмасыз гына Шакро, кемгәдер анын ни-нәрсә икәнен үтемле итеп анлатырга тырышып, болай дигән иде: «Ну, ул Тоглар кебек инде... Тик компьютерлар күп, ә Тоглар бердәнбер». Шуннан сон теге томана да компьютернын ин элек искиткеч хәтерле, барысын да гомерлеккә хәтерендә саклый торган нәрсә икәнен анлап алган иде. Менә хәзер Тогларнын хәтере сынатты...» Мөгаен, картаямдыр, әллә арыганлыктан, артык әсәренүдәнме?»—дип күнелсез генә елмайды ул.

Ростовка да ул кемгә булса да мәхәббәт тотып яки гадәттән тыш хискә бирелеп ашкынмый—анда аның ни тугрылыклы дуслары, ни күңелендә йөрткән кешесе, ни туганнары юк. Андагы «Ростсельмаш» заводы тирәсендә аның яшерен бер урыны бар, ул шунда тизрәк барып җитәргә алгысый иде. Андый яшерен урыннары бер дистәләп булып, Советлар Союзы таркалгач, аларның күпчелеге якын чит ил җирләрендә калды. Хәзер аның төрле исемгә язылган паспортлары да, яшерен урыннар үзләре дә бөтенләйгә югалды инде. Менә әле дә ул үзенең Ташкенттагы исем-фамилиясен хәтерли—Сөләйманов Рефат Шакирович, 1947 елгы, кырым татары. Әмма Ростовтагы яшерен урын Чечнядән иң якындагысы иде...

## 2

Бер унайга җилдергән машина эчендә искитмәле әйбәт, әмма ачы караклык тормышы турында инерәп-ыңгырашып торган җыр тавышыннан оеп барган пассажир тагын әле бик күптәнге хәлен—төрмәгә беренче утыруын һәм беренче Остазын исенә төшерде. Шул Остазы бит инде аңа гел тукып торды: иректә чакта тормышның караңгы-кара мизгелләрен истә тотарга, аңа һәрвакыт әзер булырга, шуның өчен илнең һәр мөмкин булган төбәгендә җилпәздәй таратып, яшерен урыннар эшләргә кирәк, диде. Әгәр запасыңда паспорт-фәләнише биш-алты документың бар икән—мондый зур илдә шайтанның үзеннән дә куркасы түгел, һәркем торган җирендә теркәлергә тиеш булса да, анысы аның йолкышлар өчен генә. Егетнең сирәк очрый торган талантын беренче шәйләп алган Остазы әнә шулай сөйли иде. Ләкин егетне бервакытта да йолкышка санамадылар, төрмәдәге беренче көннәреннән үк аны Оста дип йөрттеләр, бары тик соңыннан җитди кушамат алыр вакыт җиткәч кенә Тоглар исеме пәйда булды—бу кушамат җинаятьчел түгел, аны әле мединститутның беренче курсында укыганда ук студентлар шулай атый башладылар.

Машина тәрәзәсеннән саф рус авыллары күренеп кала—үзе тоткынлыкта тилмергән, ирек сөючән Ичкерия җирләре артта калган иде. Кассетадагы бер караклар җырын икенчесе алыштыра тора, шофер да озакка тынды, ул сугыш чыга-нитә калса, үзен тагын солдатка алачаклары турында күңелсезләнеп уйлана—әле хәрби хезмәттән кайтканына да дүрт кенә ел, аның хәрби һөнәре сирәк һөнәр—сапер... берничек ычкына алмассың...

Ә Тоглар исә юл буендагы авылларны күзәтеп барган уңайга илленче елларда үзе яшәгән караңгы, салкын, шөкәтсез авылны хәтерләде. Бередә дә шуңа охшаш күренешләр чалынып-чалынып кала иде, ул кинәт кенә балачагына кайтып китте, анда әле дә әтисе дә исән, ул үзе Костик, Костя Фешин иде. Ул Оренбург белән Актүбә арасындагы казакъ даласында утырган Мартук дигән кечкенә генә авылда туган иде—хәзер инде чит илдә булып чыга. Бик вакытсыз чакта, сугыш чорында 1943 елның аяусыз салкын декабрендә туган. Аның әтисе, тумышы белән Казанныкы булган Фешин Николай Николаевич, кырык икенче елда Смоленск тирәләрендә каты яраланып, тылдагы госпитальгә—Оренбургка эләгә. Шунда ул Костикның булачак әнисе, госпитальдә шәфкать туташы булып эшләүче Зоя Григорьевна Валянская белән таныша. Әтисенең сул кулын терсәгеннән кисеп ташлыйлар, тәненең бик күп җирләрен тегеп-ямап, армия хезмәтенә яраксыз дип табалар. Бер кулсыз орденлы фронтовик ирен ияртеп, көмәнле әнисе туган нигезенә—Россия белән Казакъстан чигендә утырган әлеге поселокка кайтып егыла, чик дигәне дә географик карталарда гына була инде аның.

Үзенең дә чәчләренә чал керә башлаган ир, төн караңгылыгында җилдерүче «Волга»ның арткы утыргычында утырган килеш, күңеленнән генә: «Әти...»—дип уйлап куйды. Әле алты яше дә тулмаган елгыр Костик мәктәпкә укырга киткән иде, димәк, 1949 елның көзе була инде бу. Шул заманнардан бирле, бәлки әле аннан да элегерәктер, ул үзенең даладагы

тимер юл буена сырышкан поселоктагы тормышын һаман да хәтерендә саклый...

Сугыштан соңгы беренче еллар... Һәркайда җимереклек, хәрабәләр, ачлык, эшсезлек... Бигрәк тә алар поселогында эшсезлек көчле иде: ни завод-фабрикалар, ни шахталар юк, күршедә хәерчелеккә калган «Өченче Интернационал» колхозы гына бар иде, аны соңрак «Победа» дип, исемен алмаштырып та маташтылар әле, әмма ул барыбер хәзерге үзгәртеп кору елларында мәңгегә юкка чыкты шикелле. Тагын әле ярымкустарьчылык артеле «Промкомбинат» булган икән. Анда ни-нәрсәләр белән генә шөгыльләнмиләр иде: бүрекләр тегәләр, итек басалар, күнитек әмәллиләр, атлар өчен иярләргә кадәр ясыйлар—ул елларда атлар төп транспорт чарасы иде бит. Әле шуның өстенә сабын да кайнаталар, конфет та пешерәләр иде. Аккургаш, кара кургашлар эретмәсе белән эретеп самавыр, кәстрүл, керосинка ишелэрне ямап бирәләр... Кыскасы, җаннарын саклап калыр өчен аның мартуклы якташлары ни-нәрсәләр генә эшләмиләр иде икән?! Сау-таза кешеләргә дә поселокта эш җитми, ә аның әтисе шикелле яраланган-ямалган, җитмәсә бер куллы авыру кешегә нишләргә кирәк иде? Поселок шул ук авыл җире бит ул, бөтен тормышың кул хезмәтенә бәйләнгән: бакча казып, бәрәңгесен, яшелчәсен-мазарын утыртасыңмы, мал асрыйсыңмы, йорт-куранны төзәткәлисеңме—һәркайда кул кирәк.

Беренче елларда һәр эштә әнисе бер үзе изалана, хәтта иренә тәмәкене дә үзе төреп бирә иде, аннары анысын әтисе үзе мәтәштерә башлады. Әмма кинәт кенә әтисенең тормышы үзгәрде дә куйды. Бер базар көнне булды бу. Ул заманнарда әле потребкооперация дигәннәре үз көченә кермәгән, кибетләрдә чын-чынлап сәүдә-сату юк дәрәҗәсендә, барысы да базарда гына, шунлыктан базар поселокта иң кирәкле урыннарның берсе иде. Анда эш-йомыш төшеп кенә түгел, үзен күрсәтеп, кешеләрне күреп-аралашып алу өчен дә йөри иделәр. Һәрхәлдә ул елларда бу шулай иде.

Шул истәлекле бер язгы көндә кесәсенә күпмедер акча кергән әтисе белән әнисе, нәрсәдер алырга теләпме, әллә караштырып кайтырга дип кенәме, базарга китеп барганнар. Шунда базарның бер почмагындагы чиркәү янында авылдашларының кызыксынуын кузгаткан, Мартук өчен бер дә көтелмәгән товарга барып юлыгалар болар. Берсе бер кулсыз, икенчесе агач аяклы ике гарип кычкырып-кычкырып рәсемнәр сата, «күңелсез тормышны сәнгать әсәрләре белән бизәргә» өнди, имеш. Аларның саткан товарлары зәңгәр күлдәге пар аккошлар, үбешеп торган күгәрченнәр, зарыгулы-иркә карашлы гүзәлләр, хатын-кызлар егылып китәрдәй чем-кара чәчле чибәр егетләр, күкрәп утырган роза чәчәкләре, матурлап курчак итеп киендерелгән балалар, әкият баһадирлары һәм су кызлары—барысы да соңрак «лубок» дип аталасы тупас, зәвыксыз рәсемнәр икән. Ләкин ул заманнарда базардагы сәләмә киемле ярым ач халык өчен бу рәсемнәр ниндидер башка, бай һәм тук тормыш хәбәрчеләре булып тоелганнардыр, күрәсең, шуңа да халык ул рәсемнәргә сокланып карап, яннарыннан китә алмый торгандыр. Рәсемнәр арзан, бер чиләк бәрәңге яки кило ярым дуңгыз мае бәясе тора икән, шуңа күрә бик теләп алалар яки шул ук дуңгыз маена яки самосад тәмәкегә алмашалар, ә бер тере казга хәтта сайлап-сатулашып икешәр рәсем дә алып була, имеш. Костикның әнисе дә, астына кан төсле кызыл хәрефләр белән «мин сине яраткан кебек ярат мине!» дигән язулы гашыйк парлар төшерелгән рәсемгә кызыгып, шуны сатып алмакчы булган. Ләкин әтисе аны тыеп калган: «Кирәкми, мин әйбәтрәк ясап бирермен»,—дигән.

Әтисе базардан бик дулкынланып-әсәрләнеп кайткан, шундук кайнанасы—Костикның әбисе була инде—Мария Ивановнадан күптән алыштырылырга тиешле иске өстәл клеенкасын сорап алган. Инде яңа клеенка да бар, әмма аны якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә генә өстәлгә яба торган булганнар икән. Ни булса, шул булган—әтисе күршесе ярдәме белән клеенканы тар такталарга тарттырып кадаклап та куйган, аннары

янә шул кайнанасыннан инде, ике уч он, бер-ике йомырка сорап алган, итекче Петерстан жилем келәе юнәткән һәм төнгә әлеге иске клеенканы грунтлап, беренче кат буяп та куйган.

Аннары ул, кайдан мөмкин, шуннан буяулар, пумалалар эзләп, ике көн поселок буенча чабып йөргән. Монда да аның бәхете баскан. Сугышка кадәр Мартукның район Пионерлар йортында изостудия эшләгән булган икән. Шул Пионерлар йортының хәзерге директоры, үзе дә фронтовик, тәвәккәлләп, Николайга сугышка кадәр булган яшь рәссамнар түгәрәгеннән калган барлык ни-нәрсәләр тутырылган ташландык чоланда казынырга рөхсәт биргән. Шунда төрле-төрле пумалалары да, рәссамнарга кирәкле картон да һәм хәтта бер төргәк менә дигән киндер тукыма да, аннан да кирәге—биш ел эчендә кибеп, яраксызга әйләнгән диярлек булса да, шактый күп буяулар да табылган. Әмма бу эшнең рәтен белгән Николай кибеп каткан буяуларны сыңар кулы белән уып, аларны скипидар, олифа, көнбагыш һәм житен майлары белән катыштырган да яраклы хәлгә китергән. Костик исә бу эштә аңа тырышып ярдәм итә иде. Ниһаять, шундый көн килеп житте: әтисе, барысын да йокларга яткырып, үзенең рәсем ясарга тотыначагын әйтте. Ә иртәсен, улы шау-гөр килеп зур бүлмәгә барып керсә—Украина урамына караган ике тәрәзә арасында, лак һәм буяу исләре анкытып, зур бер рәсем балкып тора иде инде.

Яшеллекләргә күмелгән әкияти бер сарай—замок күренә, ак төнбоеклар үскән зур гына күл аша сузылган күпер өстендә Костикның әнисенә искиткеч охшаган гүзәл бер хатын-кыз басып тора, үзе аяк өсләренә кадәр төшкән челтәрле ак күлмәктән, башында чәчәкләр белән бизәлгән купшы-матур эшләпә, кулында тавис кошы канатларыннан эшләнгән, күз явыңны алырлык жилпәзә.

Малай, бу матурлыктан күзен ала алмыйча, соклануыннан телсез калды. Аның «Моны минем әтием ясады!»—дип кычкырасы килде, әмма тавышы чыкмады, ул бары тик әтисе өчен горурланудан елап кына жибәрде. Әнисе белән әбисе дә еладылар, алары инде, ниһаять, әтисенең үзенә яраклы-тиң эш таба алу шатлыгыннан елау иде.

Шул көннән әтисенең тормышы кискен үзгәрде. Үз рәсемнәрен күтәреп, базарга ул берничә рәт кенә чыгып керде, аның рәсемнәрен күргән теге кырык тартмачылар Мартукка килми-күренми башладылар—бер кулсыз рәссамның рәсемнәре белән ярышырлык куәтләре юклыгын аңладылар булса кирәк. Әтисе, заказлар алып, күбрәк өйдә эшләде... Сугышта үлеп калган бик күп авылдашларын да фоторәсемнәреннән күчереп ясап бирә иде...

Ә теге «Замок янында» дигән рәсемен «Промкомбинат»ның хәйләкәр фотографы, авылда иң бай кеше, зур гына акча түләп сатып алган иде. Соңыннан, шул рәсем алдына бастырып, ул мартуклыларның берничә буынын фоторәсемгә төшереп торды, акча сукты. Костикның әтисенең даны кайсыдыр елларда шулкадәр ерак таралган иде ки, өчәр ат жигелгән кашавой чаналарда аның янына әллә кайдагы Полтавка, Белая хатка, Нагорный, Хлебодаровка дигән ерак рус авылларыннан килә иделәр, ул атналар буена өйдә булмый—әнә шул бай хужаларга рәсемнәр ясый иде.

Ә Сталинның үлеменә бер ел кала Пионерлар йортында яңадан изостудия ачылды. Балалар белән эшләргә Николай Николаевичны чакырдылар, шунда ул гомерендә беренче мәртәбә һәр ай саен хезмәт хакы ала башлады. Шул студиягә Костик та йөри һәм сәләтле рәссам булырга өметләр баглый иде. Әйе, күптән булган хәлләр инде бу... Ә бит барысы да вак-төякләренә кадәр күнелдә сакланып калган...

Ростовка бара торган юл Россиядә иң яхшыларыннан берсе, галоген фаралары белән төн караңгылыгын ярып жилдерүче машинаның тизлеге спидометрда 120 километрдан төшми иде. Әллә шул гел бер уңайга тирбәлеп барудан, әллә нервылары бушанып калудан—Тоглар үзе дә сизмәстән йокыга талды. Йокылы төшендә дә өзек-төтек булып балачагы бимазалады. Ничәмә-ничә еллардан соң беренче мәртәбә төшенә мәктәбе

керде, еракта калган 1953 ел, имеш, бөек Юлбашчының үлгән көне...

Ул көнне тын гына яшәп яткан поселок өстендә, бөтен ил өстендәге кебек үк, туктаусыз улау тавышлары ишетелеп торды, базар янындагы чиркәү чаңнарына да шулай ук бертуктаусыз кага-суга тордылар. Мәктәптә өч сәгатькә сузылган митинг булды—елап шешенеп беткән бер ораторны икенчесе алыштыра, тынлаучыларның кечесеннән олысына кадәр күзләреннән яшь кипмәде. Костик та елады. Хәтта өйгә кайткач та әтиәниләре аны берничек тә тынычландыра алмады. Шуннан соң әтисе аны үзенең остаханәсенә алып керде дә ишекне ныклап ябып әйтте:

—Елама, улым, ул синең күз яшьләреңә дә тормый. Үсеп житеп, акыл кергәч, мин сиңа ни өчен икәнен сөйләрмен әле,—диде.

Әмма Иосиф Виссарионовичны яратканнан булмаса да, улы һаман елавында булды. Ә ни өчен? Анысын кем белә?.. Үлем-китем һәрвакыт авыр кичерелә.

1955 елның 5 октябрендә Американың Лос-Анджелес шәһәрендә үзенең вилласында Костикның әтисе ягыннан житмеш дүрт яшьлек бабасы вафат булыр. Америка Көнбатышта өф итеп иркәләп йөрткән танылган рәссам Николай Иванович Фешинны тиешле дәрәжәдә хөрмәтләп жирләр. Ул инде патша заманыннан ук сынлы сәнгать академигы, 1923 елда Россиядән чит илгә чыгып китәргә аңа нарком Луначарский ярдәм иткән. Соңыннан—1976 елда рәссамның кызы Ия Николаевна Фешина—Бренхам әтисенең васыятен үтәп, җәсәден тавыш-тынсыз гына Казанга кайтарып яңадан жирләгән.

Кандагы нәсел геннары яши, алар көчле булса, иртәме-соңмы барыбер бәреп чыга икән. Шул ук сәләт, башка төрлерәк юнәлеш алып, бабасы Николай Иванович вә әтисе Николай Николаевич Фешиннар аша Костикка—бүгенге Тоглларга да күчкән.

Ул йокысыннан айнып киткәндә, тәрәзә артында кояшлы аяз көн тора иде инде. Тирә-якта әле төрле үләннәр чәчәк атып, хуш ис таратып утыра, әле бернәрсә дә көзнең якынлашуын сиздерми төсле—бары тик юл читендәге карбыз-кавыннарның тау-тау өемнәре, шул ук юл буйлап бер авылдан икенчесенә кадәр тезелешеп баскан кешеләрнең бәрәңге, слива, помидор ише нигъмәтләрне сатып торулары гына көзгә кереп баруларын искәртә иде. Үз гомерендә илне аркылы-торкылы йөреп чыкса да, Тогларның мондый галәмәт сәүдәне бервакытта да күргәне булмады. Бөтен Россия зур бер базарга әйләнгән, халык берьюлы сатучыларга әверелеп беткән икән. Кайчандыр ул бер акыллы кешедән шундый сүз ишеткән иде: үз жырларын жырламаган халык—куркыныч авыру. Халык ул, теге кеше хәзер үз ватандашларының жырламауларын гына түгел, жир сөрми-чәчми дә яшәгәннәрен күрсә, нәрсә әйтер иде икән?

Ниндидер райүзәкне узып киткәч, машина сизелерлек итеп кинәт кенә бер якка янтая башлады. Шофер моны бик тиз абайлап алды: «Ахрысы, кадакка туры килдек бугай, янә шушы авыл янында!»—дип, усал итеп сүгенеп куйды. Пассажирының бернәрсә дә аңламавын күргәч, Андрей аңлатып бирде: көпчәк ямау-ябыштыру остаханәләренең кайберләре эш булсын өчен юлга кадак, төрле пыяла ватыклары, махсус чәнечкеле тимер-томыр чәчәләр икән.

Инде һич исе китмәскә өйрәнгән Константин Николаевич:

—Базары нинди—хезмәте шундый,—дип кенә куйды. Ул Кавказ әсире булып өч ел гомерен тоткынлыкта уздырганда, тормыш та, кешеләр аңы да бик нык үзгәргән иде.

Алар яңадан кузгалып киттеләр. Ямау-ябыштыру остаханәсенә якынлашкач, качак ул хәйләкәрләр ягына кәжә тоягы ясап күрсәтте: янәсе бер койрыгыгызга басар әле ул!

Шофер озак югалып торды һәм Тоглар үзе дә остаханәгә сугылып чыгарга булды. Ямалган камераны көпчәк эченә тыгып маташалар иде, ул, борылып чыгып китәргә жыенгач кына, киштәләргә пөхтәләп тезеп куелган төрле эш коралларын күреп алды, Ростовта шуларсыз эш майтара

алмаячагын исенә төшерде. Ул киштәләр янына килеп, озын саплы бер зур кувалда, киң һәм куәтле зубило-кискеч, тимер сапка эретеп ябыштырылган таза гына чүкеч сайлап алды. Хуҗаны чакырып, аңа йөз долларлык акча суздьі—Тогларның башка төрле акчасы юк иде. Остаһын кул селтәп карышып торуына карамастан:

—Берәр иске-москыга төреп бир инде,—диде.

Андрей, бернәрсә дә аңламыйча, бу галәмәтне гаҗәпләнеп күзәтеп торды да, ишек алдына чыккач:

—Йөз долларга мин дә кискеч-тишкеч белән чүкечемне сатар идем, үз янымда кувалда гына йөртмим, чечен автоматы «борз»ны кулай күрәм...—диде.

—Ә миңа кувалда бик кирәк иде,—дип пассажиры җавап кайтаргач, шофер сүзен шунда ук өзде.

Запас көпчәкне һәм чүпрәк-чапракка төрелгән эш коралларын багажникка урнаштырып, алар янә юлга кузгалдылар. Дәшми-тынмый, һәркайсысы үз уйларында булды. Андрей: «Бу сәер пассажирга йөз долларлык кувалда нигә кирәк булды икән?»—дип баш ватса, Тоглар яшереп куйган җирендә үзен кем исем-фамилиясе язылган нинди документлар көткәнен уйланып бара иде. Аларның берсе дә күршесенең ни-нәрсәләр турында уйланганын белә алмады.

Фешин яңадан ирексездән Остазын, аның ил буйлап төрле төбәкләрдә яшерен урыннар булдырырга өйрәткәнен исенә төшерде. Мөгаен, кайчан да булса үз кесәләреннән акча һәм документларын урлаткан яки аларны кесәләре-ниләре белән кисеп алганнарын хәтерләүче өлкәнрәк яшьтәге кешеләрнең исендәдер: гадәттә, аларның документларын почта тартмаларына яисә чүп савытларына ташлап китә иделәр, кесә каракларының шундый романтик чаклары да булды, дөресрәге, бер традиция иде бу: акча акча инде, ә документлар (ул караклар телендә «ксива» дип йөртелә)—бөтенләй башка нәрсә. Хәер, йорт басучыларның да үз законы бар иде: өйдә хуҗасы булганда,—ул йөз яшьлек карчыкмы яки бер бала гынамы,—алар ул йортка басып керми һәм бервакытта да корал йөртми—монысы инде әтрәк-әләм кешенең эше булыр (анысы караклар телендә—«западло»),—караклар законы шуны таләп итә иде. Бәлки, шуңадыр да, элек фатир басулар һичкайчан да көч куллану һәм үтерүләргә барып житми, ул җинаятьләр өчен җәзалар да каты булмый һәм хәзер дә шулай кала бирә. Лабухларны, ягъни музыкантларны да таламыйлар, анысы да әтрәк-әләм эше—«западло» санала, ә караклар законын бозган өчен җавап бирергә, аларның сиңа җирәнеп каравын күтәрергә кирәк була иде. Әмма заманнар үзгәрә, заманнар белән бергә җинаятьчелек тә үзгәрә бара.

«Ак якалы» меңләгән, дистә меңләгән дәүләт хезмәткәрләре ялган документлар белән банклардан кредитлар ала да гомерлеккә юкка чыга, алар, кагыйдә буларак, Мәскәүдә качып яталар. Икенче дистә меңләгәннәре ялган паспортлар белән хосусый туристик фирма һәм агентлыклардан чит ил паспортлары юллый да, чит илгә сыпырта—анда исә бай-купшы йорт-виллалар сатып ала, акчасын шундагы банкларга урнаштыра. Яшерен яки ачыктан-ачык җинаятьчел дөньяныкы булган йөзләрчә хосусый банклар казнадан урланган яки хакимиятнең ирек куюыннан файдаланган һәртөрле жуликларның вәгъдәләренә ышанып, Көнбатыштагыча акыл ирешмәслек зур процентлар алып яшәргә хыялланган гражданнардан җыйган миллионнарча долларларны һәркөнне иркенләп чит илгә күчерә торалар. Шулай итеп, җинаятьчел дөнья КГБ сын да, прокуратура белән МВД сын да, академик-генераллар, профессорларны да җиңде дигән сүз... Кайчандыр Тогларны урлап алып китүчеләрнең берсе авызга суккандай әйтеп куйган иде: безнең илдә бандитлар белән фахишәләр генә чын, алар хәтта башка илләрдәге үз ишеләрен дә чәйнәп төкерделәр; ә калганнар—бигрәк тә депутат, эксперт, министр, сәясәтчеләр, хәтта президент үзе дә—гади курчаклар гына, дигән иде. Әйтүе юкка булмаган икән. Ул белгән дә белгән инде, илне ялган чечен авизо кәгазьләре

белән төп башына утыртып калдыру һәм алты триллион сумны сыптыру фикерен дә шул адәм әйткән бит!

Әлбәттә, Тогларнын Остазы бер өч дистә елдан сон җинаятьчел дөнья өчен нинди мөмкинлекләр ачылачагынын йөздән бер өлешен дә алдан күрә алмаган. Ләкин ул ин кирәген эшләде—Тогларнын сирәк талант икәнлегенә һәммәсен дә ышандырды, аны кирәкле кешеләр—заказ бирүчеләр һәм үз канатлары астына алучылар белән таныштырды. Дөрес, Константин күп нәрсәгә үз акылы белән иреште: ул, мәсәлән, ялган документларнын туксан тугыз проценты яшертен әзерләнгәнен белсә дә, үзе андый паспорт, диплом, хәрби билет, хезмәт кенәгәсе ишеләр белән эш итүне яратмый иде. Ул үз юлын сайлады: урланган «ксиваларны» кесә каракларыннан сатып ала, еш кына аларга үзе заказ бирә, бигрәк тә Мәскәү, Ленинград һәм паспортны теркәү каты куелган союздаш республикаларда яшәүчеләрнен документларын сорый иде. Кайвакытларда ул мондый бурычны үз заказчыларына куша, тегеләре исә кирәкле документларны туганнары, дуслары, таныш-белешләре, хезмәттәшләреннән чәлдерә. Андыйлар бигрәк тә ышанычлы, ул кәгазьләргә аз-маз гына төзәтүләр кертәсен дә—эшен бетте, кодагый! Ә тәртипле гражданнар урлаткан-югалткан документлары урынына һәрвакыт яналарын ала ала. Шул рәвешле, еллар, төбәкләр буенча тәртипләп салып куелган документларнын зур коллекциясе тупланган иде. Шуна да Тогларны чиста эшләүче, алтын куллы дип йөртәләр иде. Чөнки ул, әйтик, илленче елларда туган кешегә аннан алданрак яки сонрак туганнардан урланган документларны әзерләп-әмәлләп бирмәс. Һәр республикада, һәр төбәктә,—әле тагын аерым режимлы махсус шәһәрләр дә бар бит!—документлар бирелгән елындагы үз сериясе һәм номеры белән теркәлә. Моны паспорт режимын Ригада яки Ржевта булсын тикшереп торучылар бик яхшы белә. Паспорт янына хезмәт кенәгәсен, хәрби билетны, ә кайчакта партбилетны да әзерләргә кирәк бит әле. Монысы инде тулы бер фән! Һәм Тоглар аны бик яхшы үзләштерде, ул, мөгаен, теләсә кайсы режимлы оешманын махсус бүлеген җитәкли алыр иде. Һәм барысы өчен дә Остазына рәхмәтле ул: анысынын әмере буенча барлык зона һәм этаплардан элек кадрлар бүлекләрендә, милициянен паспорт бүлекләрендә, ЖЭКларда гади паспортискалар булып эшләгән кешеләрне эзләп табалар, алар исә «Аеруча яшерен» һәм «Дәүләт сере» дигән һәртөрле күрсәтмәләрнен серләрен Тогларга ачып сала иделәр. Шуна да ул әзерләгән документлар ин ышанычлы санала. Ә инде мөһер-имза ишеләрне, хәтта автор үзе дә аермаслык итеп тулы бит текстларны язу, тушь һәм язу караларынын төсләрен туры китерү, фоторәсемнәрне гаять зур осталык белән алыштырып ябыштыру, паспортка чип-чиста фамилия язып кую, хезмәт кенәгәсенен битләрен янага алыштыру кебек эшләр Тогларга берни дә тормый иде. Ихтимал, алты яшеннән үк әтисе янында кайнашып, ана теләсә нинди төстәге майлы буяулар ясарга ярдәм итеп йөрүләре дә булышкандыр, ул буяулар бит сыйфатлары белән атаклы Подольск һәм Ленинград буяуларыннан да өстен була иде. Алар кулында һәрнәрсә гамәлгә ярый: корым, йомырка, бал, суган кабыгы, кипкән гөлҗимеш, чәчәкләр-үләннәр, акбур, он, керосин, куян каны һәм әле тагын дистәләрчә башка нәрсәләр—шуларсыз теләгән буяунын төсен табып булмый иде. Әтисе шикелле, ул да химияне куллары белән капшап кына сиземләми, эзли торган буявынын төсе килеп чыгарга тиешле әйберләрне башыннан үткәрә-барлый иде. Ул вакытта әле, әлбәттә, Тоглар талантынын кайчандыр аерым бер даирә кешеләр арасында үзен алыштыргысыз шәхес итеп танытачагын, оста буларак, исемен һәрвакыт хөрмәт белән телгә алачакларын уена да кертеп карамады. Менә шулай итеп, әтисендәге шикелле үк, анарда да атаклы бабасынын каны, анын геннары уйный башлады, әмма аларга, ни кызганыч, җинаятьчел күләгә төште.

## 4

Академик Фешинның оныгы белән язмыш дигәнең аның тормыш юлы башында ук усал шаярды. Мәктәпне ул алтын медальгә тәмамлады һәм, көчәнми-нитми генә, Актүбә медицина институтына укырга керде. Юкса, күпләр Костяның рәсем сәнгатенә булган сәләтен камилләштерү өчен Строгановка училищесына китүен көткән иде, әмма аның үзен табиб һөнәре кызыктырды, өйдәгеләр дә рәссам булу яхшы-рактыр дип ышанып җитмәделәр. Егет институт янәшәсендәге тулай торакта яшәде, башкалардан да әлләни артык аерылып тормады, ләкин ничектер кинәт кенә аның теләсә нинди белешмә кәгазен төп нөсхәсенә охшатып язып бирә алуы фаш булды. Ул заманнарда лекцияләрне калдыр-ган өчен бик каты сорыйлар, хәтта стипендиядән мәхрүм итүләре дә мөмкин иде. Ә ул чор студентларының күпчелеге стипендия акчасына гына яши, ихтимал, шунлыктандыр, Костя Фешин яна дусларына булы-шудан баш тарта алмады, студент халкы да житез-елгыр бит—кайберләре белешмә кәгазьләренең чиста бланкларын китерә башлады. Икенче курста укыганда Костя Фешинны армиягә алдылар. Озын, төз егет бер ел буе бик тырышып бокс белән шөгыльләнгән иде, аны флотка юлладылар— ул чорда дингезчеләрне беренче чиратта жыя иделәр. Алтмышынчы еллар башында дингездә тулы дүрт ел, коры жирдә өч ел хезмәт итәләр иде. Шунлыктан, егет институтына егерме өч яшендә генә әйләнеп кайтты, кайчандыр аның белән беренче курска укырга кергән кызлар инде институтны тәмамлап килә иделәр.

Костя Фешинга Тын океанда, Владивостоктагы «Дерзкий» эсмине-цында хезмәт итәргә туры килде. Хезмәтенең беренче елында—1963 елда әтисе вафат булды. Әтисенә әле нибары кырык кына яшь иде, яралары хәтсез булган солдатны үлем ничә елдан соң килеп тапты. Әтисенең үләренә өч ел калганда, Костяның Казанда яшәүче әбисе, кайчандыр бик оста пианистка Елизавета Матвеевна да бу фани дөнья белән тын гына хушлашкан иде. Ул яшьлегендә атаклы рәссамга гашыйк булган, анардан авырлы калып, рәссам Америкага мөһаҗирлеккә киткәч, тупылдап торган бер малай тапкан. Лос-Анджелеста яшәүче академик Фешин, мөгаен, Татарстанда үзенең улы үсеп килгәнен белмәгәндер дә—аларның мәхәббәтләре берничә ел дәвам итсә дә, Елизавета Матвеевна үзенең сөйгәненнән кош теледәй бер генә хат-хәбәр дә алмаган бит. Хәер, ул заманнарда чит илдән хат-хәбәр алулар бик куркыныч булган: ОГПУ йоклап ятмаган, шуңа күрә дә Николай Николаевич үзе балигъ булганчы әнисе фамилиясен йөрткән—Соколов. Бары тик паспорт алганда гына әнисе аңа әтисенең фамилиясен бирергә карар кылган һәм бу хакта берничек тә аңлатып тормаган. Моның ничек шулай килеп чыкканын беркем дә белми калган, әмма улы Фешин булып киткән. Бу турыда улы Костяга Николай Николаевич үзе сөйләп биргән иде, ләкин үз фамилияләренең чын сере Тогларга шактый соңлап кына ачылачак әле.

Армиядән Костя ныгып-тазарып, тәмам буйга житкән егет булып кайтты, киемнәре дә илле икенче үлчәмнең бишенче буйлысы булды, армиягә чаклы кигән әйберләренең берсе дә ярамый иде инде.

Әнисенең матди мөмкинлекләренә исәп тоту турында сүз була да алмый: шәфкать туташы ул елларда аена житмеш-сиксән сум гына ала, ярый әле, кечкенәрәк бакча кисәге, аннары бер дуңгыз баласы белән берничә тавыклары бар иде. Элек хәрби дингезчеләрнең киемнәре, юка булса да, чын тукымадан нык-таза итеп тегелә иде, Костя лекцияләренә дә шул флот киемнәрен киеп йөрде: шулай киенеп йөрүче алар бөтен институтка икәү генә булып, икенчесе дә дингезче, анысы Кара дингездә хезмәт иткән икән. Ярлылык һәм казна киеменнән тизрәк котылырга теләү китереп тыкты да инде төрмәгә атаклы Фешин оныгын. Билгеле, армиядән кайткач та, Костя студент дус-ишләренә

ялган белешмәләр әмәлләп бирүдән туктамады—аның сәләте турындагы сүзләр ул юк чакта да үлмәгән иде.

Ләкин ничектер бервакыт, Яна ел алдыннан, күрше бүлмәдә яшәүче егет аның янына урта яшьләрдәге билгесез бер ир кешене алып килде. Ул адәм яхшы—бай киемле, алтын тешле, имән бармагында да авыр алтын йөзеге бар иде. Ул үзен Чимкенттан килгән бер хуҗалыкчы дип таныштырды, үзе белән алып кергән шешәне ачып, сыйланып утырганда, ул, менә дигән белгеч булса да, тулы бәхет өчен дипломы гына җитмәвеннән зарланып утырды. Тулай торакта салып утырганнан соң, Фешинны ресторанга чакырды, шунда күзгә-күз калгач, диплом ясап ярдәм итүен үтенде, буш диплом катыргыларының өендә өч ел инде аунап ятканлыгын әйтте. Бәлки, шул җинеллек дингезче егетне әлеге эшкә алынырга этәргәндер дә, юкса, бу юлы ул үзенен гамәле саф җинаятьчелеккә тартканын да белә иде. Әмма төп сәбәп башка: аның туйдырып бетергән дингезче киемнәреннән тизрәк котыласы килә. Үзенең күпчелек яшьтәшләре кебек, ул да Тимерьюлчылар сараена биюләргә яңа габардин кытай костюмы, ефәк күлмәк, очлы башлы лакланган штиблетлар, каракүл шәл якалы төксел йон тукыма—ратин пәлтә киеп килү турында хыяллана, андый пәлтәне исә заказ буенча «Люкс» ательесында гына тегәләр иде. Тагын бер пар җылы свитер, мамык пуловер һәм мех пирчәткәләр дә булдырасы килде аның. Ул кышта бигрәк тә нык туңа иде шул, аның бит хәтта бүреге дә юк иде. Ә кызыктырып юлдан яздыручы алтын тешле адәм тәкъдим иткән акчага әле болардан тыш әллә нәрсәләр, хәтта җәйге каникулларда Илек елгасына су коеныргa йөрү өчен велосипед та алырга булыр иде. Инде бу вакытта Тоглар кушаматы алып өлгергән студент егет ризалашты. Экраннарда ниндидер бер кинофильм барган чак иде, фильмның баш герое Тоглар да Фешинныкы кебек сәләткә ия икән, студент егетләр, сөйләшеп тә тормыйча, шул исемне Костя Фешинга сыладылар да куйдылар, бу кушаматның аңа гомерлеккә ябышып калачагына исәп тә тотмаганнардыр, мөгаен. Әлеге кинофильмда Венадамы, Будапешттамы ялган акча ясаучы ул геройны хәзерге Тогларның бер төкереп, аннары киптереп эләрлек осталыкка ирешәчәген күз алдына да китермәгәннәрдер.

Хәтта үзенең әлеге беренче эшен дә Тоглар осталарча чиста итеп эшләп бирде, ялган диплом Алма-Ата төзүчеләр институты инженерларының чын дипломнарыннан берничек тә аерылып тормый иде. Каһәр суккыры теге «алтын теш» үзе ышанычсыз булып чыкты: бер әрләшкән-талашканнан соң аны хатыны барып чаккан, ә ул, үз тиресен саклап калу нияте белән, Костя Фешинны саткан.

Икенче елның сентябрендә, өченче курста укый башлагач кына, аны туп-туры дәрестән алып чыгып киттеләр. Әмма, дөресен генә әйткәндә, ертык күнитекнең резин табанынннан кисеп әмәлләгән ялган мөһер өчен алган акча аның җинел яраланучан күнеленә күп шатлыклар һәм канәгатьлек хисе китергән иде. Ул кышта ул, әй, көязләнеп, фырт киенеп тә карады соң ұнде! Һәр язу машинкасы органнарның тиешле рәсми махсус исәбендә, ә бәйрәм көннәрендә барлык оешмаларда да аеруча нык саклана торган бүлмәләргә бикләнгән ул елларда элекке Тын Океан дингезчесенең җинаяте җитди санала иде. Шуңа күрә, яшьлегенә, беренче хөкемгә тартылуына, армиядән һәм институтыннан менә дигән характеристика-бәяләмәләренә дә карамастан, аңа биш елны чәпәп тә куйдылар.

Төрмә аның университеты булды, Остазы әйтмешли, аның Оксфорды. Төрмәдән Тоглар, ихтимал, югары партия мәктәбен тәмамлаучылар да көнләшерлек бәйләнеш-бәйләнешләр урнаштырып чыкты. Остазы лагерь башлыклары белән үзен бик иркен тота иде, шуңа аркаланып, ул ярты ел утырдым дигәндә колония башлыгының бер якын туганына урман техникасы институты—янә дә Алма-Атаныкын!—дипломын әтмәлләп бирде. Яңа пешеп чыккан дипломны әйләндергәләп карагач, полковник хисләнеп, яшь тоткынның исендә калырлык сүзләр әйтте: «Их, егет,

миндә синен талантың булсамы, минме...»—дип тукталып калды.

Шәхси баюы өчен тоткыннарны соң тамчысына кадәр сыга торган бу кызыл танаулы әзмәвер (тоткыннар телендә «вертухай»), үзендә шундый талант булса, ни-нәрсәләр майтарыр иде икән—кызганыч, анысын Фешин белә алмый калды. Кыйммәтле мебель ясаучы столярлар бригадасы әзмәвернең мәһабәт йорты өчен сирәк очрый торган агачлардан уепсырлап, бизәкли-бизәкли мебель ясаганын, тимерчеләр Ленинградтагы Җәйге бакча коймаларына бик тә охшатып аңа челтәр койма коюларын Костя, әлбәттә, белә иде.

Тоглар дәрәҗәләре түбәнрәк булган башлыкларга да күп төрле документлар «пешереп» бирде, әмма иң күп заказлар ирректән килә иде һәм шулар Фешинның киләчәк тормышын хәл итте дә. Иректәгеләрнең тырышлыгы, төрмә түрәләренең аңа әйбәт карашы аркасында ул вакытыннан элек, өч ел гына утырып чыкты...

## 5

Ростовка, нәкъ Фешин исәпләгәнчә, караңгы төшеп, урамда утлар кабынгач кына килеп керделәр. Константин Николаевич шәһәрне яхшы белә, бирсдә еш була һәм, кирәге чыкса, шактый гына хатын-кызларның телефоннарын да хәтерендә янарта алыр иде. Ләкин ул багланышлар хәзер өзелгәндер инде, үткәннәрдә актарынуның мәгънәсе юк, аннары күптәнге ул чибәркәйләр дә картаеп беткәннәрдер инде мөгаен. Юлда ул Ростовка җитәрәк Андрейны җибәрергә, икенче берәр машинага күчеп утырырга теләгән иде, әмма максатына якынлашкач, кире уйлады. Егет ышанычлы күренә, иң мөһиме—пассажирның җитдие туры килгәнен, үзен шаяртуларсыз-нисез тотарга һәм кирәкмәс ахмак сораулар бирмәскә тиешлеген аңлый иде. Шунлыктан, шәһәр чите якынлашуга, Тоглар шоферга «Ростсельмаш» районына барырга кирәклеген әйтте.

Ростовтагы әлеге яшерен урынны ул әле үзгәртеп корулар башланганчы ук, Сочига китеп барышлый, сиксәненче еллар башында ясап калдырган иде. Хәтерендә, шәһәрдәге дус-ишләре белән бик шәп кенә типтереп йөргәч, ул, алдан уйланган уеннан кайтып, бу яшерен урын әмәлләүне икенче килүенә дә калдырмакчы булган иде, ләкин соңгы мизгелдә, чираттагы чибәркәй белән очрашуын кичектереп, эшкә тотынды—димәк, язмыш шулай кушкан...

«Ростсельмаш»ның өр-яңа комбайннары рәт-рәт тезелеп торган зур мәйданны уратып алган кызыл кирпеч койма күренгәч, ул Андрейга юлдан төшеп, астарак юл читендәге агачлар ышыгына туктарга кушты. Багажниктан чүпрәк-чапракка төрелгән эш коралларын алгач, шоферга үзен көтеп торырга әйтте дә койма буйлап китеп барды, аннары тиздән тимер юл ягына таба борылып кереп китте.

Яшерен урыннар өчен ышанычлы, караңгырак, кешесез җирләрне сайлыйлар—бу шпионнарга билгеле кагыйдә. Шәһәрдә иң яхшы урыннар сәнәгать заводлары, әле аларның да иң күрексезләре тирәсендә була. Андый җирләрдә гашыйклар да йөрми, тикмәгә кызыксынучы ачык авызлар да юк, болардан нәрсә дә булса сыпыртырлык әйбер дә күренми, ул сиңа конфет яки тәмәке фабрикасы түгел инде, андыйлар тирәсендә тормыш көндезен дә, төнен дә кайнап тора: фабрика эшчеләре дә, читятлар да тәүлекләп, айлап-еллап, хәтта дистә еллап урлашалар анда.

Койма буеннан, аңа терәлеп үк диярлек, урман полосасы сузыла, ул, ихтимал, атаклы завод төзелгән чагында ук утыртылган булгандыр. Фешинны заводка керү-чыгу юллары ягыннан күрергә мөмкин түгел, әгәр дә берәрсе очраклы килеп чыкса да аны-моны сизенми үтеп китәр иде. Почмактан унбишләп метр киткәч, ул иң өске рәттә тамга салынган ике кирпечне күреп алды—димәк, исән! Якындагы тимер юлдан чираттагы

йөк поезды дангыр-донгыр дөбердәп уза башлаганны күтеп алгач, ул жәһәт кенә койма өстенә күтәрелде, авыр кувалда белән берничә сугуда кирпечләрне урман полосасы ягына ишеп төшерде, әле кискеч һәм чүкечнен кирәге юк иде. Жиргә сикереп төшкәч, аунап яткан кирпечләргә чүкече белән бер бәрүдә үзенә кирәклеләрен аерып алды. Кирпечләрнен берсенен эче куыш, анын эчендә өстенә тузан сибелгән балавызланган калын гына кәгазь төргәк бар иде.

Фешин кирпеч ватыкларын урман полосасы эченә томырды, эш коралларын пөхтәләп төреп арырак жыеп куйды, бары тик шуннан сон гына төргәкне сүтеп жибәрде: анда паспорт, хәрби билет һәм Брежнев заманындагы йөз сумлыклар белән биш мен акча саклана иде. Ул чорда аз акча түгел иде бу, «Жигули» машинасынын ярты бәясе иде. Профессорнын еллык хезмәт хакы, дигән сүз, әмма әрәм югалган акчаларын кызганып тормады ул. Хезмәт иямре һәм крестьяннар дәүләте шаккаткыч тотрыклылыкка ия иде, акчасын еллар, дистә елларга яшереп саклаучылар ул акчаларнын бәясе төшәчәк яки аларны менә инде житмеш ел дәвамында беркемгә билгесез инфляция дигән нәрсә ашаячак дип уйлап та карамый иделәр шул. Тоглар күнелсез генә көлемсерәп куйды: «Гиннес китабына кем күп ашаган, кем күп йоклаган, кем төкерү яки кычкыру ярышында жинеп чыкканнарны түгел, менә шушындый рекордларны теркәп барасы иде»...

Акчаларын ул янадан үз кәгазенә төрде дә шунда ук үсеп утырган карт тупыл ярыгына кыстырды, ә документларына күз дә салып тормады: аларнын Ленинградта туган Фешин Константин Николаевич исеменә иканлеген хәтеренә төшергән иде инде. Сәгатенә карап алгач, Тоглар бөтен эшен ун минутта төгәлләгәненә игътибар итте дә машина янына ашыкты. Моторы эшләп торган «Волга» пассажирны көтеп тора иде, күнеле күтәрелеп киткән Фешин кузгалырга кушты. Шофернын:

—Кая таба?—дип соравына каршы ул:

—Ростовнын ин яхшы кунакханәсенә,—дип, кулын изәп куйды.

—Димәк, «Интурист»ка,—дип ачыклады Андрей.

Ул пассажирынын эш коралларысыз буш кул белән әйләнеп килгәнен күреп бик гажәпләнгән иде, ләкин сорау-фәлән бирергә базмады—исәп-хисап ясар вакыт килеп житә иде.

Машина оста гына борылып, шәһәр үзәгенә таба элдерде, борылышта ул бераз салулап алды, шунда Константин Николаевичнын аягына идәндә яткан авыр сумка килеп төртелде. Ул аны бөтенләй оныткан, Грозныйдан чыкканнан бирле хәтеренә дә китермәгән иде. Тәненә кинәт салкын тир бәрде: бер генә секундка үзенен яшерен урынынннан документларын алып килгәндә машинадан жилләр искән итеп күзаллады. Шул тәэсирдән тыны кысылып, Фешин, утыргыч артына сөялеп, күзләрен йомды, аннары, анына килгәч, кыйммәтле спорт сумкасынын «молниясен» тавышсызнисез жинел генә ачты да кулын сумка эченә тыкты—бухгалтер исәп-хисаплары бланкысыннан ясалган биш авыр төргәк үз урынында иде.

Бланкларга яшерелгән һәр төргәктә 1990 ел үрнәгендәге икешәр миллион доллар ята иде—монда дулкынлану гына түгел, йөрәген ярылып, инфаркт сугарга да күп сорамас.

Машина жилдереп килеп кергән шәһәр үзәге, элекке матур заманнардагы кебек, гөлт итеп балкып тора, Константин Николаевич монысын ук көтмәгән иде. Ул, тәрәзәгә сыланып, таныш та, шул ук вакытта таныш та түгел шәһәр манзарасын күзәтеп бара башлады—анын Ростовта сонгы мәртәбә кунак булганыннан сон сигез ел үтеп киткән иде инде. Машина түгәрәк ясап, кунакханә алдындагы мәйданга килеп туктагач, Тоглар дулкынланып көткән шоферга килешенгән бәяне тоттырды да, тагын шул кадәр үк өстәп, әйтте:

—Рәхмәт, туган, коткардын,—диде.—Юлын жинел булды, шухыр-мохырсыз, фартлы егет син. Ә бу биш йөз доллар сина Грозныйга бер ике-өч ай барып йөрмәс өчен булыр, саклангынны саклармын, дигән

Ходай. Ә Чечня мәсьәләсендә син хаклы, сугыш, һичшиксез, булачак һәм озак көттермәс, үзеңә башка маршрут сайла...—дип, егеткә саубуллашып кул бирде.

Үзе берничә мәртәбә яшәп киткән кунакханәнең холлын Тоглар танымады, хәер, кунакханә хәзер үзе дә башка исем белән аталып йөртелә икән—«Редиссон-Ростов». Хуҗасы дингез артыннан, чит илдән килгән кеше булганга күрә, мөгаен, шулай танымаслык булып үзгәргәндер дә ул. Идән һәм диварлары күзге кебек елык-елык килеп торырлык итеп шомартылган аксыл-алтынсу итальян мәрмәре белән капланган, тирә-яктагы җиһазлар һәммәсе кыйммәтле кызыл агачтан, күз явынны алырлык бакырдыр-бәллүрдер, үсеп утыручы кәрлә агачлар һәм тере чәчәкләр, бизәкле авыр рамнарга куелган рәсем-картиналар һәм хәтта купшы-зиннәтле люстра турысында кечкенә фонтаны да атып утыра. Тоглар әле машинада килгәндә үк моннан ары бернәрсәгә дә гаҗәпләнмәскә карар кылган иде, шунлыктан ул кызыл агачтан ясалган һәм гөлт итеп балкып торган конторка ягына таба ышанычлы адымнар белән атлады. Конторканың мангаена инглизчә «Ресеншин» дип язып куелган, гадәттәгечә «урыннар юк» дигән язу күренми иде. «Буш номерлар бармы?»—дип соравына мөлаем гына җавап бирделәр: «Бар, кесә ягыңа карап, хәтта сайлап алырга була: 150 доллардан 370 долларга кадәр»,—диделәр. Яшерелгән урынында ун еллап яткан паспортын сузып, Фешин икенче каттан өч көнгә бер кешелек люкс бирүләрен үтенде—ул лифтта йөрергә яратмый иде. Келәм җәелгән киң мәрмәр баскычтан үз номерына күтәрелгәндә, елмаеп уйлап алды: бирегә урнашыр өчен дә яшерелгән урыныннан документларын алган кадәр вакыт җитте—ун минут. Элек, «Интурист»тан номер алу өчен аңа берәр атна алдан мәш килә башларга, дәрәҗәле-абруйлы берничә кешегә мөрәҗәгать итәргә, кунакханә дирекциясенә рәсми хат оештырырга һәм, әлбәттә инде, яшәр өчен түлисе суммадан биш мәртәбә артык ришвәт бирергә туры килә иде. Билгеле, хәзер андый гамәлләр ямьсез бер саташу шикелле кабул ителәдер. Икенче катта гадәттәге кизү торучы хатын да юк икән, Тогларга номер ачкычын аста ук кулына тоттырдылар.

Номерын ачып кергәч, ул, сумкасын алдагы бүлмәдә, ишек төбендә калдырып, люксның киң холлына үтте, күн диванга зур канәгатьлек белән җәелеп утырды, каршындагы көзгедән үзен күреп алгач, бәхетле тавыш белән кинәт кычкырып җибәрде:

—Ура-а! Мин иректә!

Ул, йомшап-тугарылып китеп, шулай ярты сәгатьләп утырды, аннары, журналлар өстәлчегендә кунакханәнең проспектын күреп, аны игътибар белән өйрәнергә кереште. Ашарга номерга ук китертергә була икән, Фешин телефонга үрелде, ресторанга шылтыратты да бик җентекләп, метрдотельнең түземлеген сыный-сыный, үзенә кичке аш әзерләп менгезүләрен үтенде, ә эчәргә—куе карангы әрмән коньягы «Ахтамар»ны сайлады. Нәкъ ярты сәгатьтән кертергә вәгъдә иттеләр, Тоглар ваннада юынып алырга ашыкты—аның өчен күнегелгән тормыш янадан башланды.

## 6

Иртән душта коенып-юынып чыккач, ул, иң беренче эше итеп, сумкасыннан биш яшерен төргәкнең берсен алды. Акыллы адәмнәр мондый яшерен төргәкләрне уйлап табу өчен дә бер генә ел баш ватмаганнар. Тоглар төргәкнең бер ян капкачын оста гына ачты да ике кисәк акча суырып алды, аларның һәр кисәгендә унар мең доллар иде. Аннары ян капкачын кире урынына куйды, капкач черт итте: эчтә бик хәйләкәр итеп беркетелгән кечкенә пружин капкачның эшермәсен этеп бикләде.

Ресторан буфетында капкалап алгач, Константин Николаевич анык бер максат белән шәһәргә чыгып китте—аның яхшы итеп киенәсе килде,

чөнки ул хәзерге «яңа руслар»ның киенүен кабул итә алмый, алар шикелле көндез дә, төнлә дә, теләсә кайда йә спорт костюмы, йә кызыл пинжәктән йөрергә теләми иде. Билгеле, өч ел буе чечен тоткынлыгында ятканда аның газетлар укырга, телевизор карарга да мөмкинлеге булды, аның хәтта бик сизгер спутник антеннасы да бар иде, шуңа күрә ул илдәге хәл-әхвәлләрне, бигрәк тә Мәскәү хәлләрен белеп торды: Европаның Карденнан алып Труссардига чаклы барлык мода йортлары анда үз кибетләрен ачканнар, аны тоткынлыкта тотучы чеченнәр шул кибетләрнең каталог исемлекләреннән ул үзе сайлаган кием-салымны алып кайтып бирә тордылар. Әйе, Тоглар кыйммәтле-зиннәтле әйберләрне ярата һәм, иң мөһиме, аларны алырга мөмкинлеге дә бар иде.

Утырып чыкканнан соң, Остазының ярдәме белән бер мәшәкатьсез генә ташкала-башкалага килеп урнашты ул, шунда аны Мәскәүдәге дистәләрчә валюта кибетләрендә йөртеп, беренче мәртәбә кәттә-кәяз итеп киендерделәр. Шул көннән башлап ул, «Березка» кибетләре ябылып беткәнче, кирәк-ярагын гел шулардан гына сатып ала торган булды. Ростовның төп сәүдә үзәге булган урамда Армани, Версаче, Луи Ферро, Лагерфельд кибетләренә килеп төртелгәч, Тогларның тан калуын күрсәгез икән! «Әйе, капиталист йоклап ятмый»,—дип көлемсерәп куйды ул һәм моның шулай булуына шатланды да әле.

Ул итальян кибете «Фантони»ны да абайлап алды, әлек, җае туры килгәндә, бу атаклы фирманың портмоне, кейс, чалбар каешы ише вак-төякләрен алгалый иде, ә бирегә кинәт—галәмәт зур бинаның тулы бер каты шул фирма кибете! Иске дустын очраткандай, ул биредә озаккарак тукталды: бозау тиресеннән эшләнгән, ефәк эчлекле, алтын йөгертелгән бронза каешлы-йозаклы, фирма эмблемалары төшерелгән бик зиннәтле чемодан сатып алды. Шуның янына ана әле яңарак кына модага кергән тагын бер әйбер—шулай ук күннән эшләнгән юл саквояжы тәкъдим иттеләр, ул Һолливуд кинофильмнарындагы бай сәяхәтчеләрнең берничә бүлемле сандык-кофрларын хәтерләтә иде, тагын кайбер вак-төяк—элеккеләре истәлеге итеп портмоне, каешлар да алды ул.

Аннары Константин Николаевич аяк киемнәре кибетенә керде, анда да итальяннарның барысын да уздырып җибәргәннәре күзгә ташланып тора иде, юкса инглиз, испан, португал аяк киемнәре, һәркемгә таныш «Саламандер» да бар, ләкин, билгеле инде, алар башка төрлерәк иде. Ул Ростовта ике костюм да алырга ниятләде, берсе ачык төстә булсын—чөнки әле бик матур көз тора, икенчесе—кичкелеккә, житди булырга тиеш, шуңа күрә ул аяк киемен дә шул алынасы костюмнарга чамалап сайлады. «Буццати» фирмасының елан тиресеннән тегелгән чия төсендәге туфлиен һәм «Серджио Росси» фирмасының бәрән тиресеннән бик пөхтә итеп тегелгән тоныкпкара төстәге, җинел юка табанлы бик матур штиблетын алды. Унайлы, матур аяк киемнәренең муллыгына соклана-соклана, ул, әлбәттә, бераз моңаеп та куйды—яшьлегендә күпме матурлыклардан мәхрүм булынган бит.

Ләкин Фешин аяк киеме, төрле аксессуарлар һәм парфюмерия кирәк-яраклары гына алып йөрмәде, ул үз кулы белән ясалган акчаларның сыйфатын да тикшерә иде шикелле, чөнки күреп торды: һәр кибеттә йөз долларлык акчаларны һәртөрле детекторлар аша үткәрәләр, төсле карангы- индикатор белән тикшерәләр, капшап-сыпырып та карыйлар—һәркайсының үз тикшерү алымы,—бары тик тешләп-ашап кына карамый иделәр. Әмма ул бу тырышу-көчәнүләргә игътибар да итмәде, дулкынламады да: аның хезмәт җимешләре булган ул акчалар Ростовның гади кибетләреннән күп тапкырлар җентеклерәк тикшерү үткән иде инде. Шулай булса да, моның чын тормышның төп тикшерүе иде һәм, ничек сәер тоелмасын, ул монардан рәхәт бер канәгатьләнү хисе кичерде: аның ялган долларлары тикшереп торучыларның һәммәсен дә бер-бер артлы җинә барды.

Киемнәр кибетендә, аяк киеме кибетендәге шикелле үк, итальян

товарлары өстенлек итә, аларны таләбрәк тә алалар икән. Элек Тоглар француз яки инглиз костюмнарын хуп күрә иде, ләкин хәзер итальян модельчеләре консерватив инглизләр яки немецләргә караганда сайланырга гаять күп төрле үрнәкләр тәкъдим итә икән. Сайлана торгач, ул үзенә житен дә, йон да, кытай ефәге дә кушып эшләнгән катлаулы юка тукымадан тегелгән ачык төстәге Версаче костюмы сатып алды. Ике капламалы, артыннан ике жирдән ярып жибәрелгән костюм ана үлчәп тегелгән кебек иде, хәтта чалбарын да ни кыскартып, ни озынайтып төзәтеп торасы юк. Шулай да кичләрен кияр өчен ул «Хуго Босс» фирмасы теккән немец костюмы алды—хәер, тукымасы барыбер итальяннарның атаклы «черрути» йонынннан иде: аны күп кенә танылган кутюрье—модельерлар, шул исәптән, безнең Греков та өстен күрә, чөнки ул аз гына майлы-дымлы шикелле ялтырап тора, йомшак һәм нәфис күренсә дә, бөтенләй бөгәрләнмитаушалмый. Караңгы соры төс өстеннән беленер-беленмәс кенә бормаборма булып кара сызыклар төшә, ул гәүдәне тагын да төз-зифа итеп күрсәтә. Костюм шулай ук ике капламалы, әмма арттан ерыксыз, классик инглиз өлгесе белән тегелгән, заманчалыгы жилкә тирәләрендә, таррак жиңнәрендә булып, биле дә, егерменче еллар гангстерлары модасын кабатламыйча, чама белеп кенә тарайтыла төшкән иде.

Кием-салым сайлап һәм кассадан кассага йөреп, Фешин әбәт вакыты житкәнне дә сизми калды. Дингез якоре төшерелгән «Юлис Нордан» сәгатенә күз төшереп алгач, ул үзенең инде дүрт сәгать сайланып йөргәнен абайлады, элек болай озак юанмый торган иде, хәер, элек, әлбәттә, болай сайланырлык та булмый иде шул. Хәзер инде күлмәкләр белән галстуклар гына аласы калды, әмма ни «Версаче», ни «Кендзо» кибетендә игътибарын жәлеп итәрлекләрен тапмады, шулай да «Хуго Босс»тан, куртка эченнән кияр өчен, калын тукымадан тегелгән бер күлмәк алды—ул, гомумән, спорт стилен ярата төшә иде. Аңа каршыдагы «Астория» кибетенә керергә киңәш иттеләр, анысы хатын-кызлар кибете булса да, ирләр күлмәкләре сатыла торган махсус бүлеге бар, шунда атаклы Ван Хейзен күлмәкләре—күбәләк галстук белән кичләрен кия торган ефәкләреннән алып әле яңарак кына модага кереп барган спорт стилендәге тыгыз тукыма күлмәкләргә кадәр сатыла икән.

Фешин «Астория» янына килеп житкәндә, ябык кына жилкәләренә аксыл-сары матур чәчләрен тузгытып салган зифа сылу гәүдәле, гәүдәсенә килешле сыланып торган зәңгәрсу-шәмәхә велюр күлмәк кигән бер кыз кибет ишеген бикләп тора иде. Ничек итсә итте, Константин Николаевич аны берничә минутка гына үзен кибеткә кертергә ризалаштырды.

Зәвык белән жиһазландырылган сәүдә залына килеп кергәч, Тоглар, хәзерге заман гадәтләреннән чыгып караганда, кызның зур тәвәккәллеккә барганын аңлап алды—башка сатучылар инде әбәткә чыгып очкан, күзгә кереп тора торган купшы, зиннәтле-бай хатын-кыз кием-салымнары арасында кызый бер ялгызы гына калган иде. «Мин шулай ук бик ышанычлы күренәмме икәнни?—дип кинәт кенә уйлап куйды Тоглар һәм үзенә үзе үк жавап та бирде:—Бик яшь, тәжрибәсез, ипле-тәртипле һәм, бәхеткә, әле тормышта кыйналмаган...» Ни өчендер, шунда ук күңелен кызны кызгану катыш ярату хисе биләп алды, ләкин сиздермәскә тырышты, кыздан үзенә күлмәкләр сайларга ярдәм итүен үтенде. Кыз нindирәк костюмнар өчен икәнлеген сорагач, ана чемоданын ачып, костюмнарын күрсәтергә туры килде.

—Әйбәт костюмнар, заманча, Версаченың да, Босснын да эшләрен яратам,—диде кыз.—Аларга, чынлап та, Ван Хейзен күлмәкләре бик килешә.—Ул Тоглар алдына дүрт күлмәк китереп салды—Болар сезнең костюмнарыгызга килешер дип уйлыйм,—диде.

Тоглар артык карап та, уйлап та тормады:

—Алам,—диде.

Галстуклар белән дә эшне тиз тоттылар—кыз бик югары зәвыклы булып чыкты. Тогларның кибеттән болай гына чыгып китәсе килми,

кыз аны магниттай үзенә тартып тора, ир кешенең мондый хисне күптән кичергәне юк иде инде.

Үзе дә көтмәгәндә, Тоглар кинәт кенә сорап куйды:

—Сер булмаса, әйтегез әле, бу хатын-кыз күлмәкләренең кайсысы сезгә ныграк ошый?

Кыз, бу бай кеше хатынына яки кызына бүләк алу өчен киңәшергә тели, дип уйлады бугай, Тоглар күрсәткән бүлемгә килеп, элгечтән чия төсендәге, үкчәләргә хәтле төшеп торырдай кечкенә күлмәкне сайлап алды:

—Бу Ив Сен-Лоранныкы, кулдан эшләнгән, бердәнбер модель, булса да, моның дөньяда бер-ике варианты гына булырга мөмкин,— диде. Аннары:—мөмкинлегем булса, мин нәкъ шушыны алыр идем, юкса үзегез күрәсез, бездә иң югары зәвыкларга да җавап бирерлек һәм сайлап алырлык матур күлмәкләр бик күп...—дип өстәде.

—Күпме тора инде бу күлмәк?—дип тыныч кына сорады Тоглар.

—У-у-у, дөнья бәясе—ике мең биш йөз доллар!

—Сезгә бик ошагач, мин аны бүләк иттем дип санагыз,—дип, Тоглар әле генә сатып алган портмонесын кесәсеннән чыгарды.

—Юк-юк, сез нишлисез? Мин мондый кыйммәтле бүләкне кабул итә алмыйм,—дип, каушап-югалып калды кыз, чәчләренә чал керә башлаган бу сәер ир кешенең шаяртмаганын аңлагач, аптырап өстәде:

—Мин сезгә яхшылык белән җавап өчен бүләк тә бирә алмыйм...

Спорт костюмлы ир кеше кыз алдына йөз долларлык бер төргәк акча ташлады да ишеккә юнәлде. Ишекнең авыр бакыр тоткасына тотынгач кына ул, кинәт кенә туктап борылды:

—Үзегез яраткан шушы күлмәктән булсагыз, мин сезнең белән бергәләп кичке ашны ашарга шатланып ризалашыр идем... Мин «Редиссон» кунакханәсендә яшим, теләгегез һәм кәефегез булса, рәхим итеп, кичке алтыдан да соңга калмый шылтыратыгыз...—диде һәм, телефон номерын әйткәч, үзе дә малайлар шикелле унайсызланып, урамга атылды.

Тоглар кунакханәгә күтәренке күңел белән кайтып керде, бөтенесе дә әлегә бик әйбәт килеп чыга, ул үз тормышындагы күңелсез кара сәхифәнең ябылуына бик тә ышанырга тели иде. Ул астагы ресторанда ашап алырга булды, аны Ростовтагы иң яхшы ресторан дип сөйлиләр. Бер унайдан кичкелеккә унайлы өстәл дә сайлап куярга мөмкин. Аның «Астория»дәге таныш түгел кыз белән бер өстәл янында кәеф-сафа корып бик тә утырасы килә иде—и-и-и, хатын-кызларны ресторанга чакырмаганына да ни гомер бит инде! Кич турында уйлагач, ул матур итеп киенергә карар кылды, официантлар һәм метродотель хәтерләренә салсын, кичке утыру югары дәрәҗәдә үтәргә тиеш, ни генә әйтсәң дә, Тоглар бит үзенең коллыктан котылуын бәйрәм итәчәк, әле, барып чыкса, янында шундый гүзәл кыз да булачак. Ул аксыл костюмын һәм елан тиресеннән тегелгән туфлиен алып куйды, аларга килешле кәеш белән галстук сайлады, биек якалы һәм яка очлары тырпаеп тормасын өчен алтын кыстыргычлы яңа күлмәген алды, аннары ашыкмый гына әйбәтләп киенде.

Зал ягындагы зур көзге каршысына килеп баскач, ул кинәт үзенә таныш та, таныш түгел дә кебек кешене күрде. Яшеренергә,төс-кыяфәт алмаштырырга яхшы ук өйрәнгән һәм ул хакта белүчеләрдән байтак дәресләр алган Тоглар мондый кискен үзгәреш буласын, әлбәттә, белә иде, әмма болай ук булыр дип... Ул көзгедә бераз арыган, зыялы, нәзакәтле, хәтта әйтергә мөмкин, өф-төф итеп кенә яшәүче урта яшьләрдәге ир кешене күрде. Чигә чәчләренең чалара башлаган булуы да аңа аерым бер сөйкемлелек биреп тора иде. Бәлки, тумышыннан табигый шундый булуы сәбәбеннәндер, бәлки, яшьлегендә спорт белән шактый мавыгуы нәтиҗәседер,—хәер, ул спорт залларына йөрүен соңрак та ташламаган иде,—аның корсагы бөтенләй беленми дә, сыгылмалы гәүдәсеннән көч, сәламәтлек ташып тора иде. Ул һәрвакыт үз яшеннән яшьрәк сыман күренә, мөгаен, тәмәке тартмавы һәм эчкәләсә дә, бик аз эчүе, хәтта төрмәдә дә авыр физик эшләр эшләмәвеннән генә түгелдер, бу—

табигатьнең ана тумыштан биргән бер бүләгедер. Утыз биш яшендә дә ул бер ун яшькә яшьрәк күренә һәм беренче курс кызлары белән йөри иде. Быел кыш, декабрь аенда аңа илле тулырга тиеш—ирләр өчен беренче житди юбилей,—әмма «Редиссон» кунакханәсендәге көзгедән елмаеп карап торган ир-атка кырык яшьтән дә артыкны биреп булмый иде әле. «Мөгаен, тормыштагы барлык уңышсызлыкларым өчен миңа Ходай Тәгаләнең бер мәрхәмәтедер бу»,—дип үзалдына шаяртып куйды Тоглар һәм аска—ресторанга төшеп китте.

Ул озаклап ашады, җентекләп ризыклар исемлеге—менюны, эчемлекләр исемлеген өйрәнде—аны хәзер, Көнбатыштагы шикелле, аерым бирәләр икән. Тоглар бу гамәлен кичне күз алдында тотып эшләде, оркестр белән дә кызыксынды. Уңайлы, аулак өстәл дә чамалап куйды, андый өстәлләр дә байтак икән—залны бик отышлы итеп ясаганнар, беркем дә үзен игътибарсыз калдырганнар дип әйтерлек түгел. Кыскасы, Тогларга биредә барысы да ошый иде, зәңгәрсу шәмәхә күлмәкле таныш булмаган кыз гына шылтыратсын инде. Ашап бетергәч, ул Ростовта кибетләр генә түгел, рестораннарның да яхшы якка үзгәргәнлекләрен искәреп алды, гомумән, тирә-якта тормыш искиткеч тизлек белән алмашына бара икән. Аның ирексездән тоткынлыкта үткәргән өч елында югалтканнарын бише белән кайтарасы килә, әмма сак булырга, көтелмәгән мәгънәсез хәлләргә юлыкмаска кирәк иде.

Әбәттән соң Тоглар бераз йөреп керергә жыенды—көн бик матур, кояшлы иде, ләкин теге кызның шылтыратырга мөмкин икәнлеген исенә төшереп, бер кочак газет-журналлар сатып алды да үз номерына ашыкты. Газет-журналларның кайберләрен ул беренче тапкыр күрә иде. Күн кәнәфигә жайлап утыргач, ул телефонны якынрак тартып куйды һәм газетларга төртелде. Шулай да вакыт-вакыт сәгатенә күз төшереп ала, көн тизлек белән кичкә авышып бара, ә телефон шылтырамый да шылтырамый иде. Ул инде үзенең юләрлегеннән көлеп, телефон саклап утыруын калдырып, йөреп керергә жыенган гына иде, нәкъ сәгать алтыда озак көттергән телефон шылтырады. Хәзер инде йөзләрчә тавышлар арасыннан да Тоглар танып алырдай ягымлы кызлар тавышы ишетелде:

—Хәерле кич, Наталья мин. Сез мине ресторанга чакыру уеннан кире кайтмадыгызмы?

Фешин шаяртыбрак жавап бирергә уйлаган иде, әмма барып чыкмады, көтә-көтә көтек булып беткәндер, күрәсең:

—Мин әйткән сүземнән бервакытта да кире кайтмыйм...—диде.

—Бик яхшы, мин сезне шундый кеше дип уйлаган да идем. Житди мистер Икс, сезгә кем дип эндәшим соң? Үзегезне тотышыгыз белән шуңа тартсагыз да, гарәп шәехенә охшамагансыз...

—Минем исемем Константин, Костя...

—Бик күңелле, сәгать ничәләрдә очрашабыз инде?

—Уңайлы булса, сигездә. Бәлки, сезне кереп алырга кирәктер?

—Рәхмәт. Мин ерак тормыйм, сигездә ишек төбендә булырмын, каршы алыгыз, яме...

Шунда сөйләшү өзелде.

Әле берничә минут кына элек үзен үртәштереп торган Константин Николаевич хәзер канәгать елмая иде. Төрле ырым-шырымнарга ышанучан иде ул, ирекккә чыкканнан соңгы беренче уңышларын да күктән ингән яхшы гамәлгә юрады, ә Наталья исә, бәлки, ана язмыш бүләгедер. Билгеләнгән күрешү вакыты житеп килә иде һәм ул түбәнгә төшеп китте. Көндез кием-салымнар күтәреп кайтканда, кунакханәгә якын гына чәчәк кибете абайлаган иде, хәзер шунда ашыкты. Ачык йөзле сатучы хатын аңа бик матур ике букет сайлап бирде: берсе озын саплы, чәчәк бөреләре тыгыз сары розалар, икенчесе аңа таныш булмаган жете ак голланд чәчәкләре—алары күл төнбоекларын хәтерләтә иде. Ул номерына менеп тормады, кочагындагы чәчәкләрен күтәреп ресторанга керде дә әбәт вакытында үзе сайлап куйган өстәл янына килде. Өстәл дивар

буендагы иң кырый рәттә иде, бирәдән бөтен зал бик яхшы күренеп тора. Ак чәчәкләрне Константин Николаевичның күз алдында ук бәллүр вазага утыртып куйдылар, өстәл сый-нигъмәтләрсез дә шунда ук күркәмләнеп-ямьләнеп китте. Официант белән кабымлыклар, үлән-сәлән, кайнар аш, эчемлек һәм десертка җиләк-җимеш турында бәйнә-бәйнә сөйләшкәч, ул очрашуга әзерләнер өчен номерына ашыкты. Кем белә, бу яна танышлык аңа ни-нәрсәләр вәгъдә итәдер...

## 7

Билгеләнгән вакытка ун минутлар кала Фешин кунакханәнең алгы ишек төбенә чыгып баскан иде инде. Күз алдыннан була торган куе эңгер-меңгергә карамастан, отель алдындагы мәйдан яхшы абайлана, аннары матурлап борынгы рәвешле эшләнгән электр фонарьлары да менә-менә кабынырга тора иде. Әйбәтләп төрелгән сары розаларын артына яшереп, кызны соңгы мизгелдә генә шатландырмакчы булды Фешин, үз исәбенчә, гүзәл кыз килеп чыгарга тиешле аллеядан күзен алмый карап тора башлады. Ләкин аллеяда бер җан әсәре дә күренмәде, артында кинәт кенә таныш тавыш ишетелгәч, ул сискәнеп китте:

—Шулай бик игътибар белән кемне сагалап торасыз икән сез? Мин тагын мине генә көтәсездер дип уйлаган идем...

Фешин, ничектер уңайсыз борылып, бераз гына баш иде дә кызга сүзсез генә чәчәкләрен сузды...

Әгәр дә кибеттә көндез күргән чия төсендәге күлмәкне кимәгән булса, ул хәзер «Астория»дәге сатучы кызны танымаган да булыр иде: җилкәләренә таратып салган куе чәчләрен кыз хәзер җыеп баш түбәсенә өеп куйган, шунлыктан аның энҗе муенсалы аккошныкыдай озын муены күзгә ташланып тора иде. Аның йөз кыяфәте дә танымаслык үзгәргән! Чигәләре тирәсенә таба шомартып тарап куйган чәчләре кызның чиста маңгаена һәм күзләренә аерым бер матурлык биреп тора, гомумән, кечкенә прическасы аны танымаслык иткән иде—әйтерсең лә, ул гасыр башыннан яки хәтта музейларда гына булган Рокотов һәм Брюллов гравюраларыннан төшкән иде... Боларның һәммәсен дә Тоглар житез күз карашы белән тотып алды һәм мизгел эчендә бәяләде дә...

—Ах, нинди гүзәл розалар! Тынычландым да инде, сезнең бары тик мине генә көтеп торганыгызга ышандым,—дип, кыланчыкланмыйча гына, шатланып елмайды Наталья.

Константин Николаевич кызның шаяртырга яратучан, иплe табигатьле булганын чамалады, кыланчыкланса да, аны килешле генә башкарганын искәртеп, күңеленнән генә куанып куйды. Дорфалыкны яратмый иде ул, шундый тупас-дорфа кызга юлыгырга да теләми иде.

Җомга киче, зур шәһәрләрдә нәкъ кәеф-сафа корып, типтерә торган кич иде—бу җәһәттән Ростов та башкалардан калышмый—алар залга барып кергәндә ресторан эченең өчтән дүрт өлеше халык белән тулган, күпчелек өстәлләр, Фешинныкы кебек үк, алдан ук алып куелган, буш күренгәннәренең дә байтагында «Алынган» дигән язулар тора иде.

Наталья үз өстәлләренә матур итеп корылган табынны күреп, бер мизгелгә телдән калды, аннары соклануын яшерә алмыйча:

—Ив Сен-Лоран күлмәге белән Версаче костюмын шушылай юарга да ярыйдыр, мөгаен,—диде.—Безнең танышлыкны да тиешенчә билгеләп үтү фарыздыр, ләкин яшермичә әйтегез әле: туган көнегезме, әллә булмаса, берәр бай банкны бар булганы белән үз кулыгызга төшердегезме ә, бәлки, шәехләр үрнәгендә, нефть чыганагы сатып алгансыздыр?

Тоглар кызның зиһенле үткенлеген чамалады, аны утыртканда беләзеге тирәсеннән кулын үбеп:

—Сездән бернәрсә дә яшерергә исәбем юк. Әлбәттә, сез сизенгән өченче сәбәп тә бар, ләкин ул хакта соңрак әйтермен...—диде. Боз ватып тутырган кечкенә көмеш чиләктән француз шампан шәрабен алды һәм

күбекләнеп торган алтынсу төстәге эчемлекне биек бокалларга тутырды...

Ярты сәгатьтән соң залдагы авыр бәллүр люстраларның утлары сүнде, бары тик сәхнә өсте генә яктыртылып калды, өстәлләрдә исә борынгыча итеп эшләнгән озынча-матур лампалар эчендә шәмнәр кабынды, үсеп утырган зур-зур гөлләр арасындагы торшерларда да аллы-гөлле утлар балкыды. Оркестр уйнап җибәрде, түземсезрәкләр һәм гашыйк парлар биергә чыктылар, әмма биюләрнең иң кызган чагы алда иде әле. Тоглар, мондый урыннарда электән еш булганлыктан, моның чиген бик үткен тоя иде. Ул рестораннарга йөрергә бик ярата, аларның башкалар хисабына үз күнеленне менә дигән итеп күтәрердәй бердәнбер урын икәнен дә белә, кәефе булмаган кешеләр гадәттә бер ялгызлары өйдә эчәләр бит, иң юк дигәндә барларда яки буфетта аяк өсте генә салып чыгалар. Ул исә һәрвакыт зиннәтле, зур рестораннарда, иң яхшы оркестрлар музыкасын тынлап, кәеф-сафа кора торган иде. Сонрак аның бу күзәтүләрен бер психолог та раслады: гомуми шатлык-күтәренкелек ясалма оештырылган һәм эчемлекләр белән дә куәтләндерелгән булса да, аның тәэсире теләсә нинди күнел төшенкелеген бетерә ала икән.

Чибәр кыз белән янәшә утыру бик рәхәт, бик күнелле иде, ике арадагы мөнәсәбәтләр дә бернинди киеренкелексез тиз урнашты. Француз шампаны «Канард-Дюшене»ны алар вакыт-вакыт йомшак грек коньягы «Метакса» белән аралаштыргалап утырдылар, кабымлыклар сайлаганда да Тоглар ялгышмаган, Наталья да, аның үзе шикелле үк, семга, елансыман минога, өстенә дерелдәвек-койкы коеп әзерләнгән севрюга—укборын балыкларын һәм дингез кысласы—краблар салып ясалган тәмле салатны да ярата икән. Дингез азыкларыннан эшләнгән ризыклар исертмәскә дә ярдәм итә—монысын да Тоглар яхшы белә иде.

Ниндидер күптән таныш монлы музыка уйный башлады, Наталья:

—Биибезме?—дип тәкъдим ясады.

Оркестр уйнап бетергәч, Константин, башкалар белән кушылып музыкантларга кул чаба гына башлаган иде, кемдер көчле кулларын аның җилкәсенә салды, Фешин борылып карады. Бик купшы костюмлы, ак чуар күбәләк галстуклы, кыска итеп калдырылган чәчле, ярты битен каплап тора торган төтен сыман соргылт күзлекле таза гына ир-ат аңа текәлеп сорады:

—Тоглар?

## Күктүбәдәге казино

### 1

Кичкә таба, әлсерәткеч август эссесе бераз басыла төшкәч, Күктүбә култыгын уратып алган тәбәнәк калкулыклардан йомшак кына җил исә башлады, яр буена сибелеп-чәчелеп утырган санаторий һәм турбазаларда ял итүчеләр янадан комлыкларга юл тоттылар, менә шул чакта Язучыларның иҗат йорты урнашкан яр буе урамында ике яшь егет күренде. Аларга, мөгаен, беркем дә игътибар итмәгәндер, бары тик дингезгә ашыгучы берничә кыз гына карангалап алдылар һәм егетләрнең икесенә ике төрле тегелгән искиткеч ак костюмнарын, киемнәренә төсе туры килгән матур штиблетларын, егетләрнең төз-зифа гәүдәсенә ул кием-салымнарның бик ятышып торганын искәрделәр. Кызларның күз карашларыннан егетләрнең үз дәрәҗәләрен белеп, шул фырт-купшы киемнәре белән эре генә атлап барулары да читтә калмады. Әлбәттә, соңгы елларда Күктүбәдә нәзакатьле-матур киенеп йөрүчеләр шактый күренә башлаган иде, шулай да тәкәнекедәй көчле кыска муеннарына авыр алтын чылбырлар таккан, таушалып беткән спорт костюмы һәм пычрак кроссовкалар кигән егетләр ешрак очрый—бәлки, шуна кызлар бу егетләргә игътибар иткәннәрдер дә әле.

Яр буе урамын аста сызылып яткан комлыктан аерып-бүлеп торучы

парапет-таш койма буена рәссамнар үз эшләрен чыгарып та тезгәннәр—аларның эш көне әле хәзер генә башлана. Рәссамнарның күзе, әлбәттә, гади кешеләрнекеннән үткенрәк—алар да яр буена килеп чыккан әлеге егетләрне искәреп алды, әмма артык кызыксынып тормадылар, тәҗрибәләре буенча беләләр: кавказлылар рәсем-картиналарны сирәк сатып ала, шуннан башкасына буяу осталарының исе дә китми, җәй бик кыска, ә тормыш бик тә кадерле бит...

Теге егетләр, аста җәйрәп яткан култыктан башка беркемгә дә карамыйча, кулларын болгый-болгый, кайнарланып, бер-берләренә үз телләрендә нәрсәдер сөйли иделәр. Егетләр яшьтәшләр, икесе дә бер үк фамилияне йөртә һәм кай яклары beләндер бер-берсенә охшашлар да, шунлыктан еш кына аларны игезәкләр дип тә кабул итәләр иде. Гаҗәп тә түгел, алар бит туганнан туганнар. Бер ишегалдында үстеләр, бервакытта да аерылышмадылар диярлек, хәтта армиядә бер үк ротада хезмәт иттеләр, сонрак Мәскәү Дәүләт университетында бергә укыдылар, дөрес, анда төрле факультетларда булдылар. Хәтта, өйләнгәндә дә апалы-сеңелле ике гүзәл кызга өйләнеп, икесенә бер туй үткәрделәр—Кавказда туганлык җепләре шулай нык була шул, тагын шунысын да әйтергә кирәк, йорт-җирләрендә егетләр атаклы бер ырудан иделәр.

Парапет-таш койма буенда ук, рәссамнар һәм һәртөрле вак-төяк хатын-кыз бизәнү әйберләре, ярым кыйммәтле ташлардан ясалган муенсалар-брошкадыр, балчыктан катырган уенчыктыр сатучы кырык тартмачылардан арырак мангаллар төтенли, утынга туралган карт чия ботакларының тәмле исе вакыт-вакыт Язучылар йорты ашханәсе алдындагы мәйданчыкка да тарала, ә анда исә шау-шулы халык төркеме минут саен ишәя тора иде.

Күктүбәне күптән инде үзләренеке итеп санаган бик тәкәббер дамалар сирәк токымлы этләрен йөрергә алып чыкканнар. Иркә дог һәм доберман, боксер һәм спаниель, болонка һәм пикенеслар сатарга куелган рәсемнәрне, балчык уенчыкларны бер тартынусыз иснәштерә, аяк астында чуала, ләкин аларга беркем дә үртәләп карамый—чөнки бу этләр Язучылар союзының элекке биләмәләре белән Максимиллиан Волошин йорты арасындагы мәйданчыкта экзотик манзараның аерылгысыз бер өлеше. Ә Максимиллиан Волошин йорты исә ожмах почмагы булган Күктүбәнен иң күренекле-атаклы тарихи урыны иде.

Ләкин җәйге ак костюмлы ике егет тирә-юньдәге шау-шуны да, минут саен геометрик прогрессия белән артып торган сатучы һәм сатып алучыларны да искәрмиләр кебек. Алар һаман кызып-кызып сөйләшә бирәләр.

Төтенләүдән туктаган мангаллар ягыннан тимер таяк-шампурларга кадап кыздырылган яшь сарык итенең хуш исе таралды. Шәрекъ тәмтөмнәре муллан кушып пешерелгән шашлык исе диңгез яры буендагы казармада үткәргән флот көннәрен искә ала-ала сөйләшеп килүче элекке диңгез десантчыларының да борыннарын кытыклады. Егетләр сүзсез генә бер-берләренә карашып алдылар, сатучыларны һәм алар тирәсендә кайнашкан халык төркемен ашыкмый гына урап үтеп, пластик түбәле шашлычный янына тезелеп өлгергән чират ягына юл тоттылар. Шашлык хуҗасы, мөгаен, Ташкенттан күчеп кайткан Кырым татарыдыр, чөнки хәрчәүнәсе өстендә «Чиланзар» дигән язу күзгә бәрелеп тора иде. Ул егетләрне шунда ук абайлап алды, чиратта авыз суларын корытып торучыларга игътибар итмәстән, кытыршыланып беткән тәлинкәне төтенләпчыклап торган шашлык белән түбәләмә өеп, тиз генә егетләргә сузды, аңа ярдәм итеп торучы хатын бер миске салат та куйды әле. Кавказ шашлыклары шәрекънекеләрдән зурлыклары белән генә түгел, тәмнәре белән дә аерылып тора, яшь сарык итенең рәтен белгән егетләр, кара тут йөзле татарның осталыгын бәяләп, тагын бер өлеш шашлык алдылар. Ашап китеп барганда, аларның берсе, рәхмәт әйтеп, пешекченең куртка кесәсенә бөгәрләп йөз долларлык акча тыгып куйды. Хуҗа аны кесәсеннән

алып карады һәм, гаҗәпләнеп, егетләрнен артларыннан: «Ә сдачасы?»— дип кычкырып калды. Егетләр исә әйләнеп тә карамады, халык арасына кереп югалды.

Җәйге көн ел кебек озын тоелса да, егетләр әле яктыда ук байтак нәрсәләрне, барыннан да алда «элекке СССР Язучылар союзы милке булган» биләмәләрне карап чыгарга ниятләгән иделәр. Волошин биләмәләренә язучыларның гаҗәеп матур бакчасы терәлеп тора, аны хәзерге Күктүбәгә нигез салган кеше утырткан булган. Әнә шул бакчага яр буеннан керә торган үзәк капкадан ерак та түгел бер урында егетләр көтмәгәндә җирле алсу шадра таштан эшләнгән Ленин бюстына килеп юлыктылар. Көчле кыска муенга утыртылган Ленин башы яхшы шомартылган биек гранит постаментка куелган, шунлыктан булса кирәк, бу скульптур композиция заманча күренә, тирә-як манзараны бизәп тормаса да, аны бозмый—ямьсезләми иде. Үтеп-сүтеп йөрүче ял итүчеләр каһәрләнгән юлбашчыны күрмиләр дә, тора икән—торсын, диләрдер инде.

Кавказ кунаклары, алдыннан-артыннан берничә тапкыр әйләнеп, һәйкәлне игътибар белән карап чыктылар. Егетләрнең өлкәнрәк күренгән Алихан исемлесе туганына дәште:

—Аслан, бу җирләрне Ленины белән бергә сатып алырбыз, әйбәт эш бит... профессионаллар эше,—диде.

Тегесе уйлап тормый җавап бирде:

—Ризамын. Дөрес, аңа башка урын табарга кирәк булачак. Ә бәлки, казино холлына куярбыз...

Икесе дә рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

Күктүбә култыгы Кырымның корылыклы өлешендә, аңа нигез салучы әйтмешли, «кимерий даласында» урнашкан, шуңа күрә язучылар бакчасы поселоктагы иң зур яшеллек, бер мәрҗән бөртеге шикелле, халык ярата торган оазис булып тора. Бу паркка, ландшафт архитектурасының бөтен шартын китереп, гасыр башында ук нигез салынган һәм ул вакытлар үтү белән тагын да кыйммәтле байлыкка әверелгән. Кайчандыр искиткеч гүзәл фонтанга төрле яктан килеп чыга торган кипарис аллеяләре хәтта Кырым өчен дә сирәк булган агач-куакларны бożралатып урап алганнар. Дөрес, ял итүчеләрне куандырып, әле күптән түгел генә йөзләрчә төрле чәчәк атып утырган бай кактус плантацияләре, соңгы елларда карап-тәрбияләп тормаганлыктан, бик бетәшкәннәр, зәгыйфьләнеп калганнар.

Бакчаның котырып үскән яшеллеге теләсә ничек тәртипсез салынган коттедж һәм әле НЭП чорында ук, аннан соң сугыш алдыннан утызынчы елларда хезмәтчеләр һәм ял итүчеләр өчен төзелгән барак тибындагы биналарның хәерчелеген яшереп-каплап тора иде.

Яшь егетләр, үз фикерләренчә, бернинди кыйммәте булмаган ул бина-корылмаларга үтешли генә күз ташлап, ышанычлы итеп:

—Сүтеп ыргытырбыз... Монысын да... Монысын шулай ук...—дип сөйләнеп уздылар.

Аслан исенә килеп, дулкынланып әйтеп куйды:

—Кара әле, язучыларның истәлеге бит алар! Биредә шундый күренекле шәхесләр булган бит!

—Әйе, беләм,—диде уйчан гына Алихан.—Мин бу хакта бер генә уйланмадым инде. Әгәр дә без бу тарихи урыннарга хуҗа булып алсак, бүгенгене үткәннәр белән бәйләргә тиешбез, юкса безне беркем дә аңламаячак, вәхшиләр яки кыргыйлар дип исәпләячәкләр. Күз алдыңа китер: зур бер гранит тактага, иерусалимдагы Елау Диварындагы шикелле итеп, Күктүбәдә булып киткән барлык күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләренең исемнәрен бронзадан коеп язып куячакбыз. Биредә язучылардан башкалар да ял итәргә яраткан иң. Әлбәттә, тарихка кереп калган ул исемнәрне саф алтыннан да коярга булыр иде, ләкин озак тотмаслар... Сыпыртырлар. Һичшиксез сыпыртырлар.

—Ә бәлки, үзебез биредә төзеячәк ресторан, казино диварларына, кунакханә холлына махсус ефәк обойлар ябыштырып чыгарбыз да атаклы

кешеләрнен портретларын шунда урнаштырырбыз, ә? Хәзер бу бит проблема түгел.

—Тукта, туган, нигә интегәбез сон әле? Идея-фикер бар, ә калганын дизайнерлар эшләп бетерер.

Туганнар тыгыз тупка очкан унайга шап-шоп суккан тавышлар ишеттеләр—күрәсен, борылыштан сон, артыш куаклары артында теннис мәйданчыгы бар иде. Резин-битум түшәлгән зур мәйданчыкта хәтта турнирлар да үткәрергә булыр иде.

—Күктүбә өчен бер генә мәйданчык азрак шикелле,—диде Алихан мәйданчыкны күз карашы белән инләп алгач:

—Аны унга да, сулга да кинәйтергә була бит,—дип йомгаклап куйды Аслан.

Алар үзләре теннис уенына битараф иделәр, әмма анын бәһасен һәм мавыктыргыч икәнлеген беләләр, бу бигрәк тә хәзер, бөтен президент чирүе дәүләт эшләренә караганда тенниска күбрәк игътибар биргән заманда шулай иде. Юан корсаклы кайбер уенчыларнын, «Вильсон», «Данлоп», «Хед», «Адидас» фирмалары теккән кием-салым киеп, кыйммәтле ракеткалар тотып уйнап маташканнарын күргәч, аларны тамаша кылучыларнын күнеленә: «Сыерга ияр килешкәндәй...»—дигән мыскыллы уй килә торгандыр, мөгаен. Тормыш-көнкүреш үрнәкләрен шул югарыдагы түрәләр күрсәтә бит, ә гади халык аларнын мавыгуларына, хәтта ул таракан чабышлары булса да сокланып карарга һәм хупларга күнеккән. Халык үзе әйтмешли: мулласы нинди, мәхәлләсе шундый.

Теннис мәйданчыгыннан эчкә таба гаҗәп матур имәннәр аллеясе сузыла икән, туганнар, сөйләшеп тә тормастан, шуннан атлап киттеләр. Юлны аркылы кисеп үткән беренче сукмактан ук сул якта,—бакчанын эчендәрәк, әкияти сарай-замокка охшаш бер бина күрделәр, ул очлы шпильле түгәрәк манара итеп салынган, сигез басмалы биек таш болдыры да бар икән. Замокнын түгәрәк тар тәрәзәләре киереп ачып куелган, тәрәзә уемнарыннан кергән жиләс жил алсу пәрдәләрне тибрәтеп ала. Калын кызыл кирпеч диварлар ниндидер ышанычлы, жылы һәм матур бер тойгы уята, жилдә кыштырдап-кыштырдап куйган калын ефәк пәрдәләр аша, күнелне кытыклап, талгын гына музыка ишетелә иде. Ишек янында гына жинел пластик өстәл-урындыклар куелган чатыр сыман ак бөркәүле өч ярыны да бар. Халыкнын әле кичке дингезгә—комлыкка ашыккан чагы булганлыктан, бу бөркәүле чатырлар буш иде. Сарай-замокнын ишеге өстендә «Чәйханә, фитобар» дигән язуны күреп, егетләр эченә дә кереп карарга булдылар.

Зал ачык төстәге чия агачыннан буямый-нитми генә матур челтәрләп ясалган бүлем белән икегә бүленгән икән, анын иркенлеге һәм кötelмәгәнчә рәхәт салкынлык биреп торуы егетләрне гажәпләндерде ихтимал, таш диварлар кальга-крепостьларныкы шикелле калын булганга шулайдыр инде. Залнын зур ягындагы бер почмакта утка чыдам кирпечтән эшләнгән каминнын карангы-кызыл авызы шәйләнә, аны, күрәсен, күптән якмыйлар булса кирәк. Әмма мич эченә тутырып куелган кипкән коры утыннар гүя юеш-салкын көннәрне генә көтеп ята иде. Дингездә тәүлекләр буе давыл котырганда, бөтен тирә-юнь юеш томан, янгырлар белән чолганып алынган шыксыз көзге көннәрдә шушы камин янында рәхәтләнеп жылынып утыруның ожмахка тин икәнлеген тоя иде егетләр. Бозга каткан култыкка ишелеп-ишелеп кар яуганда һәм ярларын югалткан дингез дала булып күренгәндә, кар-бураннар арасыннан, кынгырауларын чынлатып, менә-менә мичәүләп жигелгән атлар килеп чыгардай бер мәлдәге озын кышкы кичләрдә бу рәхәтлек бермә-бер артадыр, мөгаен.

Дивар буенда камин белән янәшә торган «Бехштейн» маркалы иске концерт рояле комлыкларда кызыну сезоны беткәнне көтеп моңая, каминнын рәшәткәләре артында ут биегәндә бирелә башка тормыш башланачак, кешеләр шушы тын чәйханәдә ашыкмый гына кичләрен үткәрәчәкләр.

Егетләр диварларга эленгән рәсем-картиналарны карап йөрделәр.

Ул рәсемнәр Күктүбәне күптән инде рухи бер урын итеп яшәүче рәссамнарның бүләгедер, мөгаен. Шулвакыт арттагы бүлмәдән чәйханәнең хуҗабикәсе күренде, егетләрнең болай иртә килеп кергәннәренә гаҗәпләнде булса кирәк.

—Нинди рәхәт, күнелле сездә! Көтмәгән идек,—дип сәламләп, соклануларын белдерде иртәләгән кунаклар.

Фитобарның хуҗабикәсе урта яшьләрдәге ягымлы гына хатын иде, башында—илленче еллар буфетчылары кия торган биек ак калфак-кокошник, ул, мондый мактауларга күнеккән булса да, егетләрнең сүзләренә куанып, өйдәгечә кунакчыллык белән:

—Без кунакларга һәрвакыт шат. Рәхим итегез, бар булганы белән сыйларбыз...—дип, буфетына чыгарып тезгән, конфеттыр-мармеладтыр, печенье-пирожныйдыр ише тәм-төмнәр тутырылган вазаларына ишарәләде.

Ләкин кунакларның күзенә башта буфетның түрендә кайнап утыручы ялык-елык килеп торган, өч чиләк су сыешлы галәмәт зур жиз самовар ташланды.

Күрсәтелгән тәэсиреннән тәм табып, хуҗабикә тәкъдим ясады:

—Сезгә нинди чәй бирим: яшеленме, карасынмы? Һиндстанныкынмы, цейлонныкынмы, краснодарныкынмы? Бөтнек беләнме, мәтрүшкә беләнме, карлыган беләнме, андыз беләнме?..—дип тезеп китте ул.

—Бирегезбез, бирегезбез...—дип ялварып кул күтәргән булды егетләр.—Ике чәйнек, берсе кара, икенчесе яшел чәй белән... Калганнарын үзегез белеп өстәгез инде...

Алар ишек ягы яхшы күренеп торган өстәлгә-камин янына барып утырдылар.

Ике чәйнекне туганнар бик тиз бушатты—Кавказда да чәйне Англиядәгедән ким яратмый иделәр. Егетләр, бу юлы бары тик Кырым үләннәре төнәтеп ясалганы булсын дип, тагын ике чәйнек чәй китерттеләр.

Аларга янадан чәй бирүгә, залга кыска калдырып алдырган чәчле, гадәттә ял иткәндә кия торган спорт костюмыннан таза гына бер егет килеп керде. Ул ашыкмый гына буфет эченә үтте, хуҗабикә кечке кунакларны каршы алырга җыенып маташкан аргы бүлмәгә башын тыгып карады. Туганнар, аның чыгып киткәндә киштәдән кыйммәтле конфет тартмасын эләктергәнен дә күргәч, хуҗабикәнең улы яки берәр туганыдыр дип уйладылар. Алар, чәйханәнең зәвыклы җиһазларына кызыксынып карыйкарый, чәй эчүләрендә булдылар. Өстәлләрдәге икебаналар гына да ни тора бит! Әгәр дә язучыларның бу оҗмах почмагын үз кулларына төшерсәләр, чәйханәне хуҗабикәсе-ние белән, һичшиксез, үз урынында калдырырга карар кылдылар. Чисталыгы, зәвык белән җыештырылган булуы, өйдәгечә унайлылыгы белән хуҗабикәгә бурычлы булуы сизелеп тора иде.

Ләкин ярты сәгатьләп вакыт үтеп, хуҗабикә бушап калган чәйнекчынаякларны алырга алар өстәле янына килгәч, егетләр аның төс-кыяфәте үзгәргәнен күреп таң калдылар: хуҗабикә әзәрлекләнгән-куркынган бер кыяфәттә иде.

—Нәрсә булды сезгә?—дип сорады туганнарның берсе.

Хатын, чарасыз-гаҗиз булып, кулын гына селтәп куйды, куркынган килеш ишеккә ымлап:

—Рэкет,—диде.—Каһәр суккан бандитлар тынгы бирми. Ни теләсәләр, шуны кыланалар, бер тыючы юк үзләрен,—диде.

—Ә милиция ни карый?—дип кызыксынган булды Алихан, җавапның нинди булачагын алдан ук белсә дә, куркынган хуҗабикәне сүзгә тартасы килә иде аның.

—Сон, алар шул ук бер банда инде. Әллә бу үгез Ионның поселок халкы тамагына сөяк булып кадалганын милиция белми, дисезме? Алар белән бүлешмичә, бер капчык бәрәнге дә сата алмыйсың.

—Яр буенда шашлык пешереп сатучы татарлар да Ионга ясак түләп торамы?—дип, Аслан да сүзгә кушылды.

—Яр буендагылармы?.. Аларның әле тагын причалда да берничә

нокталары бар—алар, әлбәттә, түләми. Алар—биш бертуган, әле пеләмәнникләре дә бер футбол командасы чаклы, шулар булыша, хатыннары ягыннан да таза, гайрәтле ир-атлар житәрлек. Ләкин иң мөһиме шул, аларның Осман исемлесе бик гаярь, башкисәр егет, эшендә кул астында һәрвакыт берәр метрлы тимер таягы булыр, уйлап та тормыйча, теләсә кемнең башын сугып ярыр. Аларга да бәйләнеп карадылар каравын, узган ел ике-өч мәртәбә бик каты сугыштылар. Яр буенда да, базарда да. Ләкин Бессарабның ишегалдына,—Ионның каракларча кушаматы инде ул Бессараб,—иң якын кулдашы, Кувалда кушаматлы Ткачукның киселгән башын ыргытып киткәч, шашлыкчыларны әйләнеп уза башладылар—озакка булырмы, әйтә алмыйм. Ә менә калган халык, кибетләр тирәсендә яки урам чатларында берәр чиләк чия-фәләндер, үзе пешергән бөккән-фәләндер яки көнбагыштыр сатып утырса, комлыкларга пешкән кукуруз илтә-нитә калса... Түлиләр инде, түлиләр! Сату итеп тапкан тиеннәреннән түлиләр. Бигрәк тә базарда сатучылар жык күрә. Юньлегә түгел инде... ахыры юньле булып бетмәс моның...

—Ә хакимият? Соң, монда нинди дә булса хакимият бардыр бит?

—Ә нәрсә хакимият, ул Мәскәүдә дә, Киевта да, Симферопольдә дә бер инде. Аларга жинаятьчелек кулай гына: һәрвакыт халыкны куркытып тотарга була...

—Сездән күпме таләп итәләр соң?—дип сорады гамьсезлеген жуйган Алихан. Ул хужабикәнең гажиз көчсезлектән кычкырып елап жибәрергә әзер торганын сизенде.

—Әйтергә дә куркыныч хәтта. Сезонга мең доллар сорыйлар, ничек кенә бәргәләнсәң дә, бу минем жәй буе эшләп тапканым була. Курорт сезоны бездә бит күп дигәндә, дүрт-биш ай гына, калган вакытта күпләр эшсез, бер ярдәм алмыйча утыра. Ә кызым Симферопольдә мединститутта укый, киявем дә студент, арытабан ничек яшәргә дә белмим инде,—дип авыр сулап куйды хәсрәткә баткан хатын. Мин бит чәйханәдә гомерем буе эшлим, мондый чиксез әшәкелек юк иде.—Ул тавышын түбәнәйтеп, өметсез генә әйтеп куйды:—Өч йөз доллар жыйган идем, Бессарабка узган атнада гына шуны бирдем. Ә ул кабахәт бүген янә килгән, калганын түләүне таләп итә. Бернинди аңлатуларымны да тыңларга теләми, кешедән әжәткә алып түлә—юкса ут төртәбез, ди.

Өстәл янында бер мизгелдә авыр тынлык урнашты, әмма Алихан күңелләнеп кинәт кенә әйтеп куйды:

—Кайгырмагыз, без сезгә ярдәм итәрбез, чәйханәгез күңелләребезгә бик хуш килде, мондый тәмле чәйне дә гомеребездә беренче тапкыр эчтек,—диде. Эчке күкрәк кесәсеннән шәп кенә ялтырап торган алтын монограммалы күн портмоне чыгарып, шуннан йөзәр долларлык өч акча алды да теләнә калган хужабикәгә сузып елмайды:—Бирегез үзенә, тыныч кына эшләгез. Ә монысы чәегез өчен һәм бездән истәлек булсын,—дип тагын бер йөзлек долларны өстәде.

Аптырап калган хатынның әле тиз генә аңына килә алмаячагын чамалап, егетләр сүзсез баш иделәр дә залдан чыгып киттеләр.

Таныш имәннәр аллеясына кайтып кергәч, Аслан, бер утыргыч күреп:

—Әйдә, утырыйк әле, бу әкәмәт хәл турында сөйләшеп алыйк,—диде.—Менә сиңа тыныч, аулак урын! Шулай ук хакимлекне шул шпана белән бүлешергә туры килерме икән?

—Юк инде. Безгә икенче Лас-Вегас яки Монте-Карло кирәк—жинаятьчелекне тамырыннан корытмый булмас, бөтен Кырымында шулай эшләү мәслихәттер. Үзең беләсең бит, байлар куркыныч-хәвефле урыннарга йөрергә яратмый. Тагын, күп булса, бер-ике ел дигәндә барысы да яңа хужалар кулына керер. Кырымның бу почмагы исә безнеке булыр, моның өчен акчабыз житәрлек...

—Әйе шул, Тогларның акча станогы тәүлек буе эшләп тора,—дип ризалык белдерде Аслан.

Алар сүзсез калдылар. Илдәге вәзгыятьне энәсеннән жебенә кадәр

ничәмә-ничә кат сүтеп карадылар бит инде. Акыллы кешеләр үзгәртеп кору чорының башында ук илнең хуҗасы юклыкны аңлап алды. Менә шул чакта тау халыклары егетләре Мәскәүдә чын-чынлап беренче тапкыр күренделәр, башкала бу яна хуҗаларның каты кулын шундук тоя башлады. Икенче елда Мәскәү караклары Япончик, Монгол, Захар, Слива, Расписной, Отариклар Мәскәүне тыныч юл белән гадел итеп бүлү өчен кавказлы абрекларны сходкага чакырдылар, чеченнарга үзләре теләгән өлешне алу хокукы тәкъдим ителде, ә калганы славян, грузин, әрмән һәм башка клан-төркемнәргә булачак иде.

Ләкин Хоза, Лечи, Азамат, Бриллиант, «тәхет башлыгы»—Солтан Даудов һәм Алиханның өлкән абыйсы Гелисхан тегеләрнең вәкил булып килгән кешеләренә әйттеләр: без каракларзаконын танымыйбыз, Мәскәү безнеке, без аны беркем белән дә бүлешергә җыенмыйбыз, үзебез кирәк дип тапкан һәрнәрсәне һәрвакыт алып торачакбыз, диделәр.

—Кырымда да шулай эшләрбез,—дип йомгак ясады Алихан.—Кемнәргәдер ярымутраудан китеп барырга кушарбыз, кемнәргәдер ярамаган эш-гамәлләрен ташларга киңәш итәрбез, ә инде безнең ихтыярга буйсынмаган, безнең законнарга риза булмаганнарын һәрчак һәм һәркайда юк итәчәкбез—бер-ике көн эчендә.

Аслан ирексездән куырылып куйды, тегесе көлемсерәп аның җилкәсенә сугып алды:

—Курыкма, үзебез кул буямабыз, кирәк кадәр киллерларны Мәскәүдән китерербез, берьюлы түләрбез, Тогларның станогы аны гына күтәрерлек әле... Ә халык тыныч кына эшләп яшәргә тели, хәзер генә үзен ишеттен бит. Без кешеләргә озак көтелгән тынычлык-иминлекне тәэмин итәрбез, урамнарда йөрү дә куркыныч булмас. Ә халык турыдан-туры яки тегеләйме-болаймы, безнең империягә эшләр, кешеләр биредә никадәр рәхәт-мул тормышта яши башласа, безнең биләмәләргә акча капчыклары—байлар да шулкадәр тизрәк теләп килерләр.

—Егет син, Бора!—дип сокланып, туганына беренче тапкыр кушаматы белән эндәште Аслан.—Син һәммәсен дә дөрес уйлагансың-исәпләгәнсен.

## 2

Әсселек бөтенләй бетте, комлыклардагы халык та әкренләп таралыша башлады, Күктүбәгә кич инде. Җинел зәнгәрсу-шәмәхә энгер-менгер Карадаг өстеннән агып төшә шикелле, ул култык буйлап сузылып утырган поселокны сихри-серле пәрдә белән каплый. Куерып үскән бакчада ачык урыннардагыдан караңгырак: элегрәк бу сәгатьләрдә бакчада күпсанлы утлар кабына, бигрәк тә төнлә диңгез ягыннан, әрлебирле йөреп торган катерлардан караганда, бакча гөлт итеп балкып тора иде, ләкин хәзер Украинада энергетик ачлык хөкем сөрә, шунлыктан хәтта яр буе урамындагы фонарьлар да һәрвакыт янмый.

Егетләрнең биредә булу программасы бик кысан-кысынкы иде, шулай да алар кирәсе килгән кирәкле урыннарны карап өлгерделәр, көннен беренче яртысында хәтта «Зәңгәр култык» санаторие, «Диңгез буе» турбазасы житәкчеләре һәм Язучылар Иҗат йорты директоры белән сөйләшеп тә алдылар, поселок хакимияте башлыгында да булдылар—диңгез буендагы барлык предприятиеләр дә ел башыннан бирле «картотекада» утыра, алар инде күптән банкротлар, бары тик беркемнен дә аларны «банкрот» дип игълан итү җаваплылыгын үз өстенә аласылары килми икән. Дөресен әйткәндә, Күктүбә белән шөгыльләнергә Украинаның кулы җитми иде.

Кырымга килер алдыннан туганнар, кирәге чыга-китә калса дип, Күктүбәдәге бер адресны да алган иделәр, ярдәм-киңәш яки транспорт сорап, һәрвакыт шул адрес белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин иде. Адрес хуҗасы—кайчандыр лагерьда утырганда Алиханның абыйсы Гелисханга тормышы белән бурычлы кеше, ана ышанырга була—төрмә туганлыгы.

Кыйммәт тора ул. Гелисханның камерадашы кәсәбәчелеккә һәвәс кеше икән, кооперативлар чәчәк ата башлаган чорда ук дингез яры буенда «Аксак шайтанда» дигән ресторан ачып, шуннан бик тиз тернәкләнеп киткән. Егетләр шул ресторанга барып кичлекне ашап алырга һәм бер унайдан читтән генә хуҗасын да күзәтергә җыендылар. Беренче очраган кешедән ресторанга ничек барырга кирәклеген сораштылар, ул кеше телчән булып чыкты, сүз арасында әле ике генә атна элек кемнәрдер төнлә ресторанны шартлатмакчы булган да, әмма шау-шу гына кузгаткан икәнлекләрен хәбәр итте.

—Шулай булгач,—диде Алихан,—безгә анда барырга кирәк тә кирәк, барыйк-күрик һәм башка нәрсәләр шунда...

Ресторан дигәннәре яр буе кырыена ук сыенган икән, ул бар күренеше белән җәйгегә охшаган, бары тик буфеты белән кухня өлеше генә каплаулы, ә кунаклар залы ачык һавада. Боларны күздән кичергәч, Аслан:

—Моңа «Кимерия йолдызлары астында» дигән исем кулайрак булыр иде,—дип куйды.

Бу корылманы рестораннан битәр «хәрчәүнә» яки «кабак» дип атасаң да ярап торыр иде. Тирәсендә пешекчеләр һәм официантлар кайнашкан мичне яңа гына салып куйганнар, ул күптән түгел төнлә булган шартлауны искәртеп тора. Киртәләп тотып алынган зал кебегендә буш урыннар җитеп ашкан, бары өч-дүрт пар гына ашап-эчеп утыра иде. Туганнар яр буеның бер өлеше һәм керү юлы күренеп торырлык урынны сайлап утырыштылар.

Официант озак көттермәде. Ризыклар исемлеге-меню сорагач, ул кызганган кыяфәттә кулларын җәеп җибәрде һәм елмаеп:

—Тотмыйбыз,—диде. Аның шулай дию ни өчендер кунакларга ошап куйды. Официант ул арада үз итеп кенә тезеп китте.—Бүген генә Азов дингезеннән тотылган мәрсин балыгы китерделәр, тере иде әле. Баш итеннән пешерелгән балык шулпасы, тимер таяк-шампурда кыздырылган мәрсин ите, шуның ук дерелдәвек-койкыда катырылганы, анысы русларча кабымлыкка, шуңа ияртеп яңа тозланган уылдыгы, тагын калай табада кыздырылган балыкны да өстәргә була. Мондый табыш безгә еш эләкми—рыбнадзор белән милиция котырына, сезнен бәхет басты дип исәпләгез.

Кунаклар бу тәкъдимнәргә рәхәтләнеп риза булдылар, ләкин шәраб яки шампаннан кискен баш тартып, сүзчән егетнең кәефен әйтеп бетермәслек боздылар.

Туганнар ашап бетереп киләләр иде инде, Алихан кинәт сискәнеп китте: «Аксак шайтан»га кереп килгән Бессарабны ул беренче күреп алды. Ион үзе генә түгел иде, аңа мулдан буялган-бизәнгән сары чәчле кыз да ияргән, авызында—ментоллы озын сигарет, култык астына кыйммәтле конфет тартмасы кыстырган—ул Бессараб чәйханәдән сыптырткан теге тартма; арттарак тагын Ионның әзмәвердәй ике яраны да бар, аларның өсләрендә атаманнарыныкы кебек үк, кытайларның ялган «Адидас» спорт костюмы иде. Бу вакытта ресторан халык белән тулган иде инде. Кавказ егетләренең артындагы ерак почмакта—эскәтерсез-нисез икесе янәшә терәтеп куелган өстәлләр генә калган икән. Теге өер гөр килеп шаулашып, официант белән ниндидер сүзләр алыша-алыша, шул якка юнәлде—күрәсең, болар биредә еш булалар, үз кеше булып беткәннәр. Алихан аларның кайда утырасыларын чамалап, тиз генә икенче урындыкка күчеп утырды һәм тегеләрнең, тартынусыз-килешсез кыланып, өстәлләр тирәсенә урнашуларын күзәтә башлады.

Официант шактый өлгер егет булып чыкты, йөгереп кенә йөри, «Аксак шайтан»да булдыксызларны тотмыйлар, күрәсең, пешекче дә юкка гына акча алып ятмыйдыр. Туганнарның ашап бетереп утырганнарын чамалап, официант үз белдеге белән аларга ысланып беткән зур бакыр чәйнектә кофе китерде.

—Менә, Тын култыктагы кайнар комда пешерәбез, күбекләнеп

тора,—дип аңлатты ул, чынаякларга парлары бөркеп торган хуш исле кофены сала-сала.

Ләкин Алихан аны күрмәде дә, ишетмәде дә, аның уйлары ни өчендер Бессараб өере тирәсендә бөтерелә иде. Үзләре генә калгач, ул туганына үз телендә:

—Аслан, аппаратыңны ал әле, минем ни өчендер Бессарабларның ни-нәрсә сөйләнеп утырганнарын ишетәсем килә,—диде.

—Нигә?—дип җилкәсен җыерды Аслан.

—Беләсеңме, күңелем нәрсәдер сизенә, аларга игътибар итик әле, Бессарабтан яманлык аңкып тора. Мин үз сиземләвемә ышанам, ал әле.

—Мистика,—дип көлемсерәде Аслан.—Безгә теше үтмәячәк аның, хәтта кул сугышында да...—Шулай да ул көндезләрен сул кулы беләгенә киеп йөри торган кечкенә күн янчыгыннан наушниклы плейерга охшаш бер нәрсә тартып чыгарды. Кырым комлыкларында һәр икенче кеше шундый нәрсә тыңлап ята...

Алихан, наушникны колакларына элеп, «плейер»ның бер ягыннан кечкенә генә, әмма бик сизгер микрофонны тартып алды да аны буянган кыз белән утыручы җирле рэкетирлар ягына таба юнәлтте. Кирәкле сөйләшүне тотарга теләптер, күрәсең, ул, өстәл өстендәге савытка салынган приборны бер кулы белән боргалап, икенче кулына кофелы чынаягын күтәрде. Якында утыручылардан беркем дә аның җитди-куркыныч эш белән мәшгуль икәнен сизә алмас иде.

Үзенә кирәклесен табып тоткач, Алихан наушникларын төзәтеп куйды, аннары урындык артына сөялде, алып ашкан музыка сөюче меломан шикелле, бармаклары белән ишетелер-ишетелмәс кенә бәргәләп-суккалап утыра башлады. Аслан Борзның тиешле әңгәмәне тотып алганын аңлады. Алихан кулындагы чынаяк кинәт кенә туктап калды, ул аны тизрәк өстәлгә куярга ашыкты. Аслан туганының йөзе үзгәреп киткәнен күрде, ә бит юкса Алихан һәрвакыт салкын канлылыгы, түземлеге белән аерылып тора, шуңа күрә аның кушаматы да Борз—Бүре иде.

—Ни булды, Борз?—дип борчылып, үз телендә сорады Аслан, ләкин тегесе, ымлап, сөйләшми торырга кушты.

Бер өч минуттан инде тынычланган Алихан тиз генә наушнигын салды, суынып беткән кофесына үрелде. Туганың ни-нәрсә агарынырга мәҗбүр иткәнен бик беләсе килсә дә, Аслан аны ашыктырмады.

Чынаягындагы кофесын эчеп бетергәч, Алихан, кулын ишарәләп, официантны чакырып алды, шашлык пешерүчегә биргән шикелле үк, мона да йөз доллар сузды, официант сдача бирү турында уйлап та карамады, хәер, рәхмәт йөзеннән, сыгылып баш иде һәм егетләрне ишеккә хәтле озата килде.

Егетләр караңгы яр буена килеп чыгуга, Алихан:

—Киттек моннан тизрәк, юкса минем кереп тегеләрне атып үтерәсем килә башлады,—диде.

—Тынычлан, Борз,—диде Аслан, туганын җилкәсеннән кочып алып.—Аңлат әле, нәрсә булды соң?

—Ул күселәр шундый кабахәтлек эшләргә җыеналар, әгәр дә без аркылы төшмәсәк, өстебезгә зур гөнаһ алырбыз. Бессараб үз бандитларына бернечә сәгать эчендә искиткеч баеп китәрлек гениаль план уйлап табуы турында сөйләде. Ул инде көнен дә билгеләп куйган—августның соңгы шимбәсен. Шул көнне таң атып килгәндә, Ялтадан өч йөз чакрымлап ераклыкта, далада, ул тиз йөрешле «Кырым» поездын юлдан тәгәрәтеп төшермәкче була. Төгәл урынын әле әйтмәде.

—Ни өчен?—дип самими генә гаҗәпләнеп куйды Аслан.—Шуны эшләсә, кем соң аңа күп акча түләячәк? Аны зур срок төрмә көтәдер—ни әйтсән дә, диверсия ясау бит...

—Бессарабның уйлаганы беркемнең дә башына килмәс иде... Ул әйтә: валюта белән генә эш итә торган «Ялта» кунакханәсе биналарына һәм башка абруй-дәрәҗәле санаторийларга иң бай кешеләр бары тик

бәрхет сезоны ачылгач, август ахырларында гына килеп тулалар, ди. Ешрак «Кырым» экспрессы белән, ди. Ул дөрес сөйли, нәкъ шулай булачак. Ул үзе билгеләгән җирдә тимер юлның ялганган урыннарын нығытып тора торган атлама бикләрне сүтеп алмакчы була, рельслар өзек-өзек булып кала. Поезд юлның күтәрелә төшеп борылган җиренә зур тизлектә килеп керә дә...—үзең беләсең, кырым далаларында андый борылышлар җитеп ашкан,—тизлеген киметә алмыйча, юлдан аска тәгәрәп төшә... Менә шунда бу күселәр качып яткан җирләреннән атылып чыга да купе һәм йокы вагоннарын талый башлый, тапкан-алганнарын машиналарга төйиләр дә—әллүк! Анда ялга дип шыплап тутырылган чемоданнар йөзләгән булыр дип ышана Бессараб. Алардагы яшел долларлар, кыйммәтле кием-салым, кинокамера-фотоаппаратлар, алтын-көмеш бизәнү әйберләре миллионнарча сумга тартачак. Ә син кем түләр, дисең... Оятын-намусын җуйган ул күселәрнең бизнесы шундый хәзер.—Алихан әшәке итеп русчалап сүгенеп куйды, моны ул бик сирәк эшли торган иде.—Кабахәт! Ул һәммәсен дә алдан уйлап-исәпләп куйган: безнең ашыкмас-пошмас хакимият вәкилләре һәлакәт булган урынга килеп җиткәнче, болар инде бар байлыкны аулак җирләргә таратып, яшереп бетергән булачаклар. Йөзләрчә кешеләрнең һәлак булуына төкерә генә алар! Шыплап тутырылган чемоданнары гына булсын. Бандитлар бу планны хуплап каршы алды, әле кул да сугыштылар, ә теге кәнтәй маржалары үзе дә катнашырга теләк белдерде, иң зиннәтле бизәнү әйберләре һәм затлы кием-салым миңа булыр дип, шарт та куйды әле.

—Ах, сасы күселәр...—дип Аслан да сүгенеп алды.—Син хаклы, хәзер без дә күнелебезгә гөнаһ алачакбыз, әгәр без боларны тыеп кала алмасак, Ходай Тәгалә безне гафу итмәс.

—Ә мин нәрсә сөйлим?—дип кабынып китте Борз.—Әйдә, Бессарабны бүген төнлә үк каравыллап торыйк та...—ул кулы белән кискен хәрәкәт ясады.—Поселок халкы да иркен сулыш алыр, бер гаепсез йөзләрчә кешеләрне дә газаплы үлемнән коткарырбыз.

—Дөрес сөйлисең син, ул ерткычны исән калдыру егетләрчә булмас. Аның уй-ниятләрен Гелисхан белә калса, «западло» дияр иде. Ләкин безнең үз бурычыбыз бар, син бит беләсең... безгә җинаятьчел эшләргә катнашмаска каты боерык бирелгән—аның өчен башка кешеләр бар.

—Нишләргә соң?—дип аптырап сорады Алихан, туганының нәрсә әйтергә теләгәнен бик яхшы аңлый иде ул. Үзе дә кул астындагыларыннан һәр боерыкны төгәл үтәүне катгый таләп итә иде. Хәер, кушканны җиренә җиткереп үтәү һәм мәҗбүрилек—алар халкын башка күпләрдән аерып тора торган сыйфат ул.

Алар Язучылар йорты каршындагы яр буе мәйданчыгына килеп чыктылар, бередә ял итеп йөрүчеләр шактый ишәйгән иде, Аслан яңадан үз туган теленә күчте:

—Син, кирәк булса, Кырымга киллерларны Мәскәүдән чакыртып алырбыз, дигән идең. Аны иртәгә үк эшләргә кирәк. Симферополь аэропортыннан башкаладагы үзебезнең кешеләргә шылтыратырбыз, элек МВДда яки КГБда хезмәт итүчеләр арасыннан тиз генә бер-икесен җибәрсеннәр—ул бүреләр эшләрен оста башкара, кызганусыз ахырына җиткерә. Бессарабның аерым билгеләрен сурәтләп бирү кыен түгел, аны эзләп табу тагын да җиңелрәк, ә иң югары бәядән түләүләрне үз өстебезгә алырбыз. Шулай эшләү иң яхшысы булмасмы әллә? Күселәр билгеләгән шимбәгә кадәр әле бит ун көн вакыт бар.

—Син бу юлы да акыллырак булып чыктың, туган. Ходай Тәгалә ярлыкарлык эшне башкалар өстенә йөкләү, ничектер, ирләрчә үк булмаса да, мин синең белән килешәм—артык кайнарланырга ярамас...

—Менә бик әйбәт,—дип шатланды Аслан.—Безнең әле тагын бер эшебез калды—Кукчтүбәдәге атаклы казинога кереп, анда, ким дигәндә, ун-егерме мең оттырып чыгасыбыз бар. Безнең даһи әсиребез Тоглар әйтмешли, «күгәрченнәр» очыртырга кирәк—Кырымда да очып йөрсеннәр

әле. Дөрес, бай халык анда ярты төн уртасында гына жыелып бетә, шуннан соң гына чын уен башлана, дип сөйләделәр сөйләвен.

—Бәлки, безгә дә казинога зур акчалар салып уйнаучылар белән бер вакытта барып керергәдер,—монысы Борзның әллә соравы, әллә киңәше булды.

—Билгеле шулай, вакытыннан элек үзебезне күрсәтеп йөрү һич кирәкмәс. Нәкъ төн уртасында, курантлар сукканда барып керербез, «Пики дамасы»ндагы Герман шикелле. Ә хәзер, әгәр син каршы килмәсәң, әйдә пирска кадәр барыйк—ул нәкъ төнге клуб белән казино каршысында. Ачык диңгезгә чыгып, ике сәгать йөреп, ял итеп керербез. Ишетәсеңме, радиодан бүгенге соңгы теплоходның кузгалырга жыенуын хәбәр итәләр. Диңгез һавасы суларбыз, без инде аның исен дә онытканбыздыр, көндез комлыкта да иркәләнеп ятып булмады...

Туганнар чылбыр булып тезелгән якты утларга—причалга таба ашыга-ашыга төшеп киттеләр.

## 3

Поселок өстендә балкыган реклама утлары диңгездән караганда тагын да күркәмрәк, бәйрәмчәрәк, аллы-гөллерәк күренә икән. Якыннан алар берниндн зәвыксыз ярминкә балаганнары—кәмит корылмалары уты төсле генә иде. Бер метрлы неон утлар белән язылган «Казино» сүзенең «К» хәрефе сүнгән дә, ул әллә ничек килешсез укыла. Элекке «Эллада» ресторанының беренче катын төнге клуб «Серж» алып тора, аны хужасы хөрмәтенә шулай атаганнардыр инде. Монда биш кенә өстәлле кечкенә ресторан кисәге дә бар, жәйгә Харьковтан чакыртып алынган квинтет джаз уйнап тора.

Туганнарны бик яхшы дип тәкъдим ителгән оркестр да, браконьерлар тотып китергән севрюгалы ресторан да кызыксындырмады, алар туп-туры икенче катка—теге «казино»га менеп киттеләр.

Күренеп тора, комарлы уенчылар күптән инде үзләренең яраткан урыннарына утырышканнар.

Бер башында бары-буфеты булган галәмәт зур залда рулетка уйнау өчен ике зур өстәл куелган, алар залны берничә бүлмәгә бүлеп тора шикелле.

Кайдадыр кондиционерның йомшак кына тавышы ишетелеп, саф һава суыртучы вентиляция эшләп торса да, залны куе тәмәке төтене баскан иде. Тәмәке тартмый торган туганнар, борыннарын жыерып, бер-берләренә карашып алды, ләкин башка чара калмаганлыктан, алар, ашыкмый гына күзәтә-күзәтә, залны әйләнеп чыктылар.

Бер өстәлдә инде зур-зур суммалар белән уйный иделәр, туганнар беренче бушаган урыннарга утырды. Банк тотучының гажәпләнүенә каршы, алар инде болай да югары булган ставкаларны тагын да күтәрделәр, тагын да гажәбрәге, Борз рәттән сигез мәртәбә отты, ә Аслан—дүртне. Бер сәгать уйнагач, алар, үзләре өчен отышлы өстәлне калдырып, бар-буфет янына килделәр. Залда: «зур отыш... зур отыш...» дигән сүзләр дулкын булып узды. Шул мизгелдән алып казинодан чыгып киткәнчегә кадәр кавказлылар администрация, уенчылар һәм гади тамашачыларның күз унында булды. Бар янында да егетләр озак юанмады: берәр чынаяк кофе-капуччино белән берәр бокал «Алушта» минераль суы гына эчтеләр, барменның кәефен жибәреп, экзотик коктейльдән дә, сирәк була торган вискидан да, француз шампаныннан да баш тарттылар.

Банк тотучы отып алган фишкалар өемен казинонының матур тартмасына тутырды да, Алиханның үтенече буенча, рулеткада уйнаучылар өстәленен берсенә, уенның барышын күзәтүче крупье янәшәсенә китереп куйды. Кыйммәтле фишкалар белән шыплап тутырылган тартма уенчыларның игътибарын үзенә тарта, алар да, крупье да, бу өстәлгә кавказлылар килеп уйный башлагач, уенның тагын да кызып, эредән китәчәген аңлый иде.

Уен залына килүчеләр арасында бу йортның беркем белмәгән яшерен хуҗалары да бар иде. Алар тирә-яктагы барлык хәлләрне үткен карашлары белән күзәтеп тора, бүгенге төннең казино файдасына булмаячагын да чамалый, әле житмәсә рулеткада ставкаларның тагын да югарырак күтәрелүе көтелә иде. Шуңа күрә, туганнар ашыкмый гына кофе йоткалап торган арада, директор кабинетына жыелган хуҗалар, кинәш-унаш иткәннән соң, уенның барышын күзәтеп торучы иң яхшы крупьега, ашыга-кабалана, тиешле күрсәтмәләрне бирә башладылар. Чынлап та, кавказлы егетләр яшел постау белән капланган өстәл янына килеп, янәшә басып торучылардан фишка тутырылган тартманы үзләренә бирүне үтенүгә, крупьены алыштырдылар да. Ләкин моны берәү дә сизми калды, чөнки уен, кызганнан-кыза барып, киеренкелекнен соң чигенә житкән, ә ставкалар—уенга куелган акчалар суммасы арттырылганнан арттырыла бара иде.

Өстәл тирәсендә туганнарга утырырга буш урыннар юк иде, алар хәтта янәшә дә баса алмады, өстәл аша бер-берсенә каршы гына бастылар. Бу унайсызлык, зиһенеңне-акылыңны туплап өлгерә алмау, бер-берең белән берәр авыз сүз алышып кинәшү мөмкинлеге юклыгы, чыккан саннарны һәм аларның төсләрен язып алып анализлау жае да чыкмау уенга үз төсмерен өстәде—туганнарга бу бик кыйммәткә төште. Бер сәгатьтән соң, аларның тартмалары төбендә нибары бер дистәләп кенә фишка-шакмак тәгәрәшеп ята иде инде. Бая отып алган бөтен зур табыш та, шуна өстәп тагын үзләренең биш мең долларлары да жилгә очкан иде.

Ләкин нәкъ шул мизгелдә янәшә ике урын бушады, якында торучылардан беркем дә аларга дәгъва белдермәде, крупье, кавказлыларга күз карашы белән генә ишарәләп, утырырга тәкъдим итте...

Бу вакытта инде крупье тәмам тынычланган иде һәм ул шартлы ым белән генә үзен алыштыруларын сорады. Күнелләре күтәрелеп киткән казино хуҗалары ризалык бирделәр, чөнки аларны башка өстәлләр һәм башка уенчылар кызыксындыра иде инде—алар бүген купшы ак костюмлы егетләрнең кул арты киткәненә тәмам ышанган иделәр.

Әмма ярты сәгать үттеме-юкмы икән, хуҗаларның берсе өстәл яныннан узып барышлый, кавказлыларның һәр икесенең дә тартмалары фишка-шакмаклар белән тулганлыгын күреп алды—бу фишкаларның күпме суммага тартачагын белә дә белә иде инде ул. Хуҗа шундук беренче каттагы «Серж» төнге клубына ташланды. Казинонын иң тәжрибәле теге крупьесы шунда хәл алырга төшеп киткән иде.

Юк шул, крупьены янадан алыштыру да ярдәм итмәде: Күктүбәнең булачак хуҗаларына бу төндә бәхет елмайды. Бары тик бик күзәтүчән, игътибарлы кеше генә көтелмәгән зур отышлардан егетләрнең йөзләрендә артык куаныч та, аз гына булса да шатлык чаткылары да күрмәс иде—егетләрнең максатлары башка: ун-егерме мең долларны оттырып, Тогларның «күгәрченнәрен» Кырымда «очырып жибәрү» иде.

Крупье егетләрнең саллы суммаларын, муенындагы алтын чылбыры жилкәсенә таба шуышкан тиз әсәрләнүчән ханым алдына этеп жибәргәч, Борз, яшел өстәл өстеннән башын күтәреп, өстәл тирәсенә өелешкән кызыксынып күзәтүчеләрне күздән кичерде. Анын иң беренче күргәне Ион-Бессараб булды.

Тегесе урындыклар артына өелешкән кешеләр арасында, кайдадыр икенче-өченче рәтләрдә, кәнтәй маржасыннан башка гына, яраннары белән басып тора, кавказлыларның күзенә күренмәскә тырышканы сизелә иде. Ләкин залдагы акча исе, комарлык, бигрәк тә бу өстәл тирәсе аны калаклап куйган, диярсен һәм ул кергәннән артыграк тоткарланды. Алиханга шул мизгелләр житте: «Кырым» исемле «Мәскәү-Симферополь» экспрессы күселәр өчен әлегә икенче планга күчкән, хәзер алар башка үлем уены уйнарга тырышачаклар, уенга көтмәгәндә Алихан белән Асланның гомере куелган булырга тиеш. Үзенең бу сизенүен Борз туганына

шундук әйтмәде, ә элеккечә тыныч кына уйнавында булды, башы исә, үзләре казинодан чыгып киткәч, якындагы ярты сәгатьтә Бессараб күселәренең ни гамәл кыласыларын уйлый иде. Бу минутларда Алихан фишкаларын, уйлап-нитеп тормастан, учлап-учлап сибә, ләкин ни хикмәт—крупьеның сандал агачыннан эшләнгән көрәкчеге чирек сәгать үтәр-үтмәстә аларның әлегә кадәр оттырганнарын кайтарып бетерде.

Фишкаларның бер өлешен Аслан тартмасына тутырганда, Борз туганына үз телендә әйтте:

—Чыкканда безне теге ресторандагы танышларыбыз көтеп торачак,—диде.

Туганы, башын күтәрмичә, тыныч кына итеп җавап кайтарды:

—Димәк, Ходай Тәгалә безнең үз гамәлләребезне башкалар җилкәсенә йөкләвебезне теләми...—Аннары бераздан «җөп» һәм «кызыл» бүлемнәренә зур сумма салды да өстәп куйды:—Бер ярты сәгатьтән дә соңга калмыйча чыгып китәрбез, бу бәхетле өстәлне шулай тиз ташлар болар дип уйламый да алар...

Бу мизгелдә аларның берсе дә уен көткәннән тизрәк тәмамланыр дип башларына да китермәде. Ниндидер күренмәс һәм аңлашылмас сизенү калган уенчыларга да кич буена казинода үзләре артыннан башкаларны ияртеп уен алып барган кавказлыларның китәргә җыенуларын искәртте шикелле. Шунлыктан ставкалар күтәрелгәннән күтәрелә барды. Җитмәсә, уенга соңлаган тагын берничә кеше акылга сыймаслык ярышка кушылып китте. Хәзер рулетканы һәр әйләндереп җибәрү алдыннан яшел өстәл өсте төрле төстәге фишкалар белән тула башлады—гадәттә мондый хәл кич буена бер-ике булса була, ә монда ул гел кабатланып торды.

Соңгы шундый минутларның берсендә, барлык уенчылар да үз ставкаларын куеп бетереп, крупьеның соңгы кисәтүе яңгырагач, Алихан кинәт кенә фишкалар тулы өч тартмасын алды да, «зеро»га куйды—аның түземе төкәнгән, урамда үзләрен көтеп торучы бандитлар белән тизрәк йөзгә-йөз очрашасы килә иде. Зал тынып калды, зал кавказлыларның шундый зур отыштан шулай җиңел генә баш тартуларын аңлаудан гаҗиз иде: «зеро»га кую—ул бит бар отышыңны югалтуга тиң—син теләгән «ноль» саны кайвакытларда атналар буе да чыкмый ич! Крупье, шарчыкны тәгәрәтеп җибәрер алдыннан, сораулы кыяфәт белән хуҗаларына борылып карап алды—һәр фишканың бәясе йөз доллар торганда, әле күптән түгел эшли башлаган казино өчен бу артык югары ставка иде, ләкин хуҗалар баш кагып ризалык бирделәр.

Төтенгә чумган зал бер мизгелдән шатлыклы үкерү һәм өметсез илерүләрдән шартлап ярылды сыман—Алиханга «зеро» чыкты.

Хуҗалардан кайсысыдыр шундук залның ябылуын игълан итте һәм исәп-хисап ясау өчен бәхетле кавказлыларны директор кабинетына чакырды.

Бер егерме минуттан шул мәгълүм булды: хуҗаларның йөз илле мең долларлык отыштан яртысын гына түләрлек хәлләре бар икән, калган сумманы кайчан түләү турында йә сөйләшеп килешергә кирәк яки казиноны ябарга туры киләчәк. Туганнар бу хәбәрне тыныч кына кабул иттеләр.

—Түләп бетерергә сезгә күпме вакыт кирәк?—дип, тагын да тынычрак тавыш белән сорады Алихан. Ул үзе дә, хуҗалар шикелле үк, Күктүбәдәге казиноның ябылуын бер дә теләми иде.

Бераз уйланып торгач, хуҗаларның берсе:

—Ике атна...—диде, аннары ашыгып өстәп куйды:

—Без калган сумманы сезнең адресыгызга илтеп тапшырырга әзербез.

—Рәхмәт,—дип башын чайкады Алихан.—Үзегезне алай борчып тору кирәкмәстер. Акчаны «Аксак шайтанда» ресторан хуҗасына илтерсез, ә ул кемгә тапшырырга кирәген үзе белер,—шул сүзләрдән соң Борз саубуллашыр өчен урыныннан күтәрелде.

—Сезгә машина кирәкмиме яки иминлегегезне саклап озата баручылар? Мондый зур акча Кырымда кайберәүләрнең кайнар башларын әйләндерергә дә мөмкин,—диде күләгәдәрәк утырган җитәкчеләрнең берсе.

—Анысы өчен дә рәхмәт, без җәяү генә китәрбез...—Туганнар, саубуллашырга сузылган кулларны кысып, чыгып китү ягын карадылар.

Ишек төбе яхшы яктыртылганлыктан, биек болдырга чыгып баскан туганнар да ачык күренеп торгандыр, мөгаен. Аслан үзенен «плейер»ын алып, ашыкмый гына наушникларын киде һәм шундук якындагы куаклар арасына яшеренгән кешеләрнең тавышын ишетте:

—Чыкты теге лох-мокытлар, әле җитмәсә музыка белән...

Икенче тавыш өстәде:

—Хет шунда гармун белән булсыннар, димәк, бернәрсә дә сизенмиләр... чәйнекләр.

Ә өченче калын тавыш, ихтимал, Бессарабныкыдыр, нәтиҗә ясады:

—Музыка булгач, бик әйбәт, димәк, сакчыларсыз, машинасыз. Алай булса, утын ватарга туры килер иде. Минем юл уна торган... Сөйләшкәнчә, пычаклар белән генә манчыйбыз. Ә хәзер—алга! Артларыннан барсак, «койрык» барын сизәргә мөмкиннәр... Төзелеш янында засада ясарбыз, үткәнендәге кебек, шунда күмеп тә калдырырбыз... Борылып кереп китәр урыннары юк, юл бер генә...—сүзләре өзелде, тиз-тиз китеп барган аяк тавышлары гына ишетелеп калды.

—Программа ачыкмы?—Аслан туганына борылып карады, «плейер»ын кесәсенә тыгып, үзләрен кайда көтеп торачакларын аңлатып бирде.

Ишегалдыннан чыгуга, икесе дә берьюлы иелде дә модалы киң чалбар балаклары астыннан тубык сөягенә җайлап беркетеп куелган коралларын тартып алды: Алиханның кулында унбиш патронлы итальян пистолеты «бернанделли». Асланда—унҗиде патронлы голланд «глок»ы, икесе дә тавышсыз ата торган җайланмалы иде. Бүгенге көндә, «калашников»тан кала, болар илдәге киллерлар һәм аларның корбаннары—банкирлар, бизнесменнар, сәүдәгәрләрнең иң яраткан «уенчыклары» иде.

Бессараб ачыктан-ачык: «манчыйбыз» диде, аларга каберләрен дә билгеләп куйды... Егетләрнең кулларында тиз ата торган тавышсыз корал, димәк, беренче булып ату хокукы да аларныкы...

—Ашыкма, адымыңны киметә төш,—диде Аслан туганына,—күзләр караңгыга ияләшсен әле. Бу юлы өстенлек безнең якта. Һәммәсе бик уңай бара дип уйламыйсыңмы? Мина ошап бетми бу, ничектер, намуссызлык шикелле.

—Аларныкы бик намуслы инде...—дип үртәлеп куйды Алихан һәм усал итеп өстәде:—Бессарабның яраннарын гына атабыз, аның үзенә бер-ике сүз әйтергә телим мин, ул җинел үлемгә лаек түгел...

Бер биш минуттан күзләр караңгылыкка ияләште, дөм караңгы булса да, юл якыннан шәйләнә иде. Төзелеш котлованына кадәр ике йөз метрлап ара калгач, Аслан әкрен генә үтенде:

—Син мина хәзер кычкырып-кычкырып рус телендә берәр мәзәк сөйлә, яна булуы хәерле. Аларның да көтү киеренкелеген киметергә кирәк—кешеләр яхшы кәеф белән кайтып килә бит, зур отыш белән... Корбан чалынасы аңгыра бәрәннәр... «Чәйнекләр», диде бит әле ул...

Берничә минуттан, ясалма көлешә-көлешә котлованга якынлашканда, Алиханның сизгер борынына сигарет төтене исе килеп керде, кичтән маймыллы бер фотограф рәсемгә төшереп торган бердәнбер имән ябалдашы астында сигарет уты да ялтырап китте.

—Без бу карт имәнне үтеп китүгә, алар арттан ташланачак, калак сөяге астына бер кадауда эшне бетермәкчеләр, әзерлән...

Көлешә-көлешә, алар каһәрле урынга—имән астына таба якынлашканнан-якынлаша иделәр. Дөрес, һөҗүм итүчеләрнең җинел генә үз аркаларына сикерү мөмкинлеген киметер өчен, сиздерми генә имәннән бераз унгарак, дингез ягына, юл читенәрәк каера бардылар.

Туганнар имән турысын үтәр-үтмәстән, артларында җинелчә кыштырдау ишетеп, кискен борылдылар—кулларына пычаклар күтәргән ике әзмәвер бер сикерүдә аларны «манчырга» омтыла, ә ерактарак торган өченчесе—күрәсен, Бессарабтыр—ярдәмгә йөгерә иде. Берьюлы диярлек

ишетелер-ишетелмәс ату тавышлары икесе бергә кушылды да шундук сүнде. Бессараб үз яраннарының, кинәт кенә таеп-сөрлегеп киткәндәй, ни өчен асфальтка шапылдап барып төшкәннәрен аңышмый да калды, шундук аның үзен дә бик оста алым белән сугып ектылар. Тешләрен сындыра-сындыра, авызына салкын озын пистолет көпшәсен китереп тыккач кына Бессарабның аңына барып житте: менә нәрсәдән «таеп» егылган икән аның әзмәверләре, менә нинди «чәйнекләргә» тап булганнар икән алар...

Шундый ук тын гына ату тавышын көткәндә, Бессараб, ни өчендер кинәт кенә, бервакыт иртә белән үзенең ишегалдына якын ярдәмчесе Кувалданың кисеп ыргытылган башын күз алдына китерде.

Ләкин ату тавышы ишетелмәде, кулына пистолет тоткан кеше әкрен, әмма ачык итеп әйтте:

—Бессараб, син безне үтереп, пычрак котлованга исемсез этләрне күмгән шикелле күмеп калдырырга теләгәнең өчен үлмисең—анысы өчен яраннарың үз гомерләре белән түләделәр инде. Син—күсе, олысынкечесен талап, западло булып яшисең, шуның өчен үләчәксең дә. Без сине кичтән үк, син поездны тәгәрәтеп төшерергә ниятләгәннән соң ук үлемгә хөкем иттек. Син йөзләрчә кешеләрне үтерергә, гарип калдырырга теләдең... Байлык өчен...

Мөгаен, бу мизгелләрдә Бессарабның чәчләре күзгә күренеп агара башлаган булгандыр, чөнки иртән үзен табып алганда, аның чегәннәрнекедәй тузгып торган куе-калын чәчләре арасында бер генә кара бөртек тә калмаган була инде. Ул, бәлки, чынлап та, Ходай Тәгаләнең җәзалаучы кулы тотып алган мине дип уйлагандыр. Юкса, бу чечен егетләре үзләрен үтереп, котлованга күмеп калдырырга ниятләгәнен кайдан белгәннәр?.. «Кырым» экспрессын тәгәрәтеп төшереп, һәлакәт ясау уен каян ишеткәннәр?... Ничек?... Кайдан?...

—Сиңа пычак та, пуля да әрәм. Син долларлар теләгән идең, син хәзер аларны алырсың да...—Бессарабның канга баткан иреннәре арасыннан пистолет көпшәсен суырып чыгаргач, Алихан, кинәт котырынып, аның авызына дыңгычлап төргәк-төргәк долларлар тутыра башлады...

Туганы янында басып торган Аслан да үз кулыннан тагын бер төргәк өстәде...

Авызы долларлар белән тәелгән Бессараб бер биш минуттан тынып, жансыз калган иде инде...

## Аргентинлының пасьянсы

### I

Өстенә капчыкланыбрак торган ак смокинг пинжәк кигән, ярты йөзен зур күзлек каплаган нык-таза озын буйлы ир кеше кистереп сорады:

—Тоглар?

Фешин таныш түгел бу адәмнең кулын җилкәсеннән алып ташлап, ике төрле аңлардайрак итеп әйтте:

—Сез ялгыштыгыз. Мин ростовлы түгел, кунакханәдә өстә яшим,— дип, Натальяны култыклап, өстәлләре янына алып китте.

Ә музыканы мавыгып тыңлап торган кыз тегеләрнең тиз генә берике сүз алышуларын ишетмәде дә бугай.

Эшләре гөрләп бара торган банкир яки бизнесменнарга бик нык охшаган бу көяз джентельменны Тоглар шундук танып алды: бу бик күп отучан Мәскәү каталасы, ә төгәлрәге, кәрт уены шулеры—кәрт уенын үзенең төп һөнәре итеп сайлаган Аркадий Городецкий, күбрәк Аргентинлы кушаматы белән танылган адәм иде. Кушаматны аңа яшьрәк чакта танго

биюе белән мавыгуы һәм көньяк американнарча кара тут йөзле, кара бөдрә чәчле булганы өчен такканнар. Китеп барышлый, Тоглар ана шартлы ым ясады, анлаган кеше моны чама белән шулай анларга тиеш иде: сине хәзер үк тану минем ихтыярымда түгел.

Жинаятьчел ым-ишарәләр белән бик сирәк кешеләр генә анлаша ала, алар гадәттә караклар канунына буйсынып яшәүчеләр була, яки, Тоглар шикелле үк, ул законнарны хөрмәт итүчеләр. Бу гыйлем жиде йозак астындагы сердәй саклап тотыла, чөнки аны саклау—яшәвен иминлеге дигән сүз. Аны кемгәдер чишкән, фаш иткән кешене үлем жәзасы көтә, шунлыктан ул ым-ишарәләр коды хәтта профессионал жинаятьчеләрнен дә һәрберсенә мәгълүм түгел. Ләкин Аргентинлы һушлы мужик, төрмәдә дә берничә мәртәбә утырып чыккан, дөрес, озаклап түгел-түгелен, ә инде профессионал уенчы буларак, караклар арасында жинаятьчел дөньянын өстен-элита катламында санала, шуна күрә дә ул Тогларнын ымын анлады. Кеше күнелләрен шулай нечкә белүче тирән психолог ялгышырга мөмкин идеме сон? Фешин бит ана ике мәртәбә документлар әмәлләп бирде, ә Аргентинлынын үтенече буенча анын дусларына ничә мәртәбә ярдәм итте—санап бетергесез!

Тоглар белән Наталья рестораннан иртә чыгып китте. «Астория» кибетенен сатучы кызын озатып, кунакханәгә кайтып кергәндә сәгать төнге икенче киткән иде инде. Кешесез калган холлны аркылы кисеп, үз катына менү өчен кин баскычка таба атлаганда Константин Николаевич карангы почмактагы диванда ялгызы бөкшәеп утырган берәүне күреп алды. Фешин баскычнын бер буен да менеп өлгермәде, сулуы капкан яшь егет аны куып житеп, бер сүз дәшмичә, кулына язу кисәге төртте һәм шулай ук сүзсез төшеп тә югалды. Аргентинлы, күрәсен, аны Ростовтагы танышларына да ачарга теләми иде. Номерына кергәч, Тоглар матур хәрефләр белән язылган берничә юлны укыды, моны яхшы белемле кеше язганы сизелеп тора иде. Кайбер бәхетлеләр кебек, Городецкий күлмәкчән тумаган, ә кулына уен кәрте тотып туган, дип юкка гына сөйләмәгәннәрдер шул...

Язу болай иде: «Иртәгә иртәнге унда синен белән бергә баш төзәтеп, ашап-эчеп утырырбыз дип ышанам. Баш төзәтергә мина хәзер бары тик «Хольстен» сырасы гына кирәк. Синен братанын А. Г.»

Тоглар көлеп жибәрде һәм саклык йөзеннән әлеге язуны ерткалап ташлады. Аргентинлынын язганыннан төрмә исе килә иде шикелле. «Братан» дигәне дә шуннан.

Тогларнын Аргентинлыга булган беренче тәэсире тискәре иде, ул: «Менә, иректә иске дусларыннан, тамырдаш-корешларыннан котылып, бер көн дә ял итә алмыйсын, чибәр кыз белән кич үткәрергә дә бирмиләр»,—дип уйланды. Әмма сонрак, тынычлана төшкәч, башкача фикер йөртте. Наталья белән танышлыгын яхшыга юраган шикелле, Городецкий белән очраклы очрашуын да унышка санады. Ирекә чыгуга ук ул кулына дөрес компас ала ич. Кавказда әсирлектә үткән өч елдан сон, ана карангалап кына йөрмәскә, ә ышанычлы мәгълүмат та алырга, тормышны шуна карап көйләргә кирәк. Ә мондый белекле кеше, Мәскәүнен эчке вә тышкы дөньясын биш бармагы кебек белүче Аргентинлы булмый, тагын кем булсын!

Иртән ул, күпьеллык гадәте буенча иртә уянды. Душта коенганда, Аргентинлынын төнге хәбәре кылт итеп исенә төште, ашыга башлады, кул арты жинел каталаны жиренә житкереп каршы аласы килә иде. Икәүләп ашап-эчеп утыру күнелләрәк тә булыр, бигрәк тә Городецкий шикелле күпне белә торган кеше белән.

Ресторанга телефоннан заказ биргәндә, ул «Хольстен» сырасын да онытмады, шешәлесе булсын дип, аерым басым ясап әйтте, чөнки банкалы сыраны күрә алмый иде. Сәгать уннар якынлашып килгәнлектән, Константин Николаевич аска газетлар алырга да төшеп тормады, белә иде: Аргентинлы бервакытта да көттерми. Алар халкы вәгъдәсезлек,

төгәлсезлек, эленке-салынкылыкка хурлык итеп карый, андый кеше, гомумән, абруйлы була алмый. Димәк, төгәллек—корольләр өчен генә әдәплелек билгесе түгел.

Нәкъ сәгать унда ишек шакыган тавыш ишетелде. Тоглар официант иртәнге ашны китергәндер дип уйлаган иде, ләкин бусагада елмаеп Городецкий басып тора икән, өстендә—ачык төстәге спорт костюмы, ялан аягында—өйдә киеп йөри торган артсыз чүәк! Иске тамырдаш-корешының йөзендә гаҗәпләнү күргәч, кунак көлемсерәп әйтеп куйды:

—Мин синнән өстә генә, гранд-люкста яшим.

Алар каты итеп кочаклаштылар.

Залга килеп кергәч, Городецкий, үз күзләренә үзе ышанмагандай, бераз арткарак чигенеп, Фешинны тагын бер мәртәбә күздән кичерде.

—Ә без бит сине, Тоглар, инде өч ел элек җирләгән идек. Туры килгәндә искә алабыз, менә нинди оста бар иде бит, дибез, алтынкул! Бигрәк тә бик мөһим кәгазьләр юнәтергә-ясап бирергә кирәк булганда, еш искә ала идек. Син, мөгаен, күз алдына да китерә алмыйсыңдыр хәзер нинди кәгазьләр заманы икәнен! Менә газетлар «яңа руслар» акчаны һавадан ясыйлар дип язалар. Бер дә һавадан түгел лә! Төрле кәгазьләрне тегендә-монда куып йөртәләр дә, ә аннары кайдагыдыр ниндидер бер банктан капчыклап акча төяп чыгалар. Юк, мин ялган авизоларны күз алдында тотмыйм, алары инде аның пычак-пистолетсыз талый белүнең классик үрнәге...—Ул, ярты сүздән бүленеп, кинәт икенче сүзгә күчте.—Сине исән-сау килеш күрүемә бик шатмын.—Тогларның номерын күздән кичергәч:—Күреп торам: кичәге көяз киемнәрең, янында гүзәл кыз да булу тормышыңда барысы да тәртиптә дигәнне сөйли. Ничәмә еллар кайларда йөрдең соң син шулай? Ни өчен шулай озакка яшерендең? Синең алай артык зур гөнаһларың да булмады бугай, юкса, мин белгән булыр идем...

Шулвакыт ишекне янадан шакыдылар, Фешин ачарга ашыкты. Официант сый-нигъмәт тезелгән арбачыгын номерга тәгәрәтеп кертте дә оста-житез генә итеп диван янындагы кечкенә өстәлгә урнаштыра башлады.

—Менә, синең яраткан «Хольстен»ың да килеп житте,—диде күнелләнеп Тоглар, официант чыгып киткәннән соң һәм Городецкийны өстәл янына чакырды.

—Рәхмәт. Шешәлесен соратуың яхшы булган, хәер, «Хольстен» һәрвакыт әйбәт ул. Әмма ике шешә француз шампаны «Де Кастеллани»ны күреп алгач:

—Очрашуыбыз хөрмәтенә сыра көчсезрәк булыр, мөгаен. Син хаклы, әйдә, ач шампаныңны—очрашуыбыз анлык кынамы соң?—дип өстәде Городецкий.

Шампаннарны Фешин, алай-болай Наташа килеп керсә, дип кенә алдырган иде юкса.

Ике йөз долларлык шампан шешәсен ачып, Тоглар тыйнак кына әйтеп куйды:

—Очрашу хөрмәтенә!

Күтәрделәр. Аргентинлы шундук сыра да ачты, күрәсең, кичтән ул арттырыбрак җибәргән булгандыр һәм махмыры турында шаяртып кына әйтмәгәндер. Салганын эчә-эчә, ул күз карашы белән ымлап Фешинның үзе турында сөйләвен ашыктырды.

Тоглар сүзнеерактанрак башлады...

—Ин әвәл сина рәхмәт. Кичәге түземлегең, мине залда да, язу белән җибәргән егеткә дә ачмаганың өчен, дим. Ул егетнең сүзсез торуына һәм язуына караганда, син минем кемлегемне аңлатып маташмагансың.

—Син мине кемгә саныйсың?!—дип үпкәле тавыш белән җавап бирде Городецкий, ул инде исерә башлаган иде.

—Мин беләм,—диде Тоглар,—шулай кирәк дип тапкан кешеләр, моннан өч ел элек мине автомобиль һәлакәтендә үлде, дип хәбәр таратты. Яхшы сүз белән искә алып торганыгыз өчен рәхмәт, хәер, ул хакта да

мина сүзләр ишетелеп-килеп торды. Син хаклы, мин үзем яшеренеп ятмадым—братва алдында гөнаһларым юк,—мине урладылар.

—Урладылар?!—Көтелмәгән хәбәрдән Городецкий шешәнен авызыннан гына капкалап утырган сырасын кулыннан төшереп жибәрде, идән буйлап тәгәрәп китксн шешәгә игътибар да итмичә, айный төшеп, пышылдап сорады:

—Ментлармы? КГБмы?

—Юк ла! «Чехлар»...

—Ә синең чехларга ни кирәген чыкты? Аларның үзләренен синен эше осталары юк микәнни? Яннарында гына поляклар. Син аларча сөйләшә дә белмисең бугай ич,—дип жинеләеп көлеп жибәрде Аргентинлы.

—Сина аңламадың. Мине чеченнар урлады. Мин аларны иске хәтерем белән шулай атап йөртәм. Хәзер бик азлар гына хәтерли булыр—«чехлар»...

—Юк, исемә төште. Хак сүз, аларны әле Алма-Атада ук «чехлар» дип йөртәләр иде. Кәрт сугарга бик ярата торган халык түгел. Менә кореецлар, казакълар—алары булдыра... Сон шуннан, ул «чехлар»га ни пычагыма кирәк булдың инде син?

—Сина нәрсәгә кирәк булсам, аларга да шуның өчен... Үзен әйтәсен бит: хәзер кәгазь заманы, дисең...

—Аңладым. Димәк, син аларга биш елга житәрлек итеп кирәкле кәгазь-мәгазьләрен әмәлләп биргәнсен дә алар сине исән-имин генә чыгарып жибәргәннәр, бик юмарт түләгәннәр дә шикелле әле.

—Әйе, юмарт түләделәр. Ләкин алар мине жибәрмәде, мин качтым. Һәм хәзер, бәлки, мине бөтен ил буйлап эзлиләрдер.

—Әйе, күз алдыма китерәм, син аларга анда нинди кәгазьләр химичит иткәненне, дим. Аларга, күрәсең, Россияне бер елда алты триллион сумга тәгәрәтү генә аз тоелгандыр—ялган авизолары белән, дим. Хәзер инде көнбатышны талкырга тотынганнардыр, валютага! Алла ярдәм бирсен «чехлар»ына, капиталистларны яратмыйм мин...

Тоглар сүзне артык тирәнәйтеп тормады:

—Төрле кәгазьләр «пешерергә» туры килде,—дип кенә куйды.

—Да, туган, каты капкансың син,—диде, хәлнен, ниһаять, төбенә төшенгән Аргентинлы.—Әйдә әле, тагын шампан жибәрик, ошап китте. Бер дә мондыйны эчкәнем юк иде.

Янә берәр бокал «Де Кастеллани»ны эчеп куйдылар.

—Шуна күрә дә мин әле, хәзерге тормышны анлап-ачыклап бетермичә торып, ачылыргамы-юкмы дип икеләнәм. Әгәр дә Тоглар исән икән диган хәбәр таралса, ирекгә озак яшәтмәсләр мине—йә үтереп ташларлар, йә тагын урларлар, өченче юл юк. Мин, чынлап та, күпне беләм, әмма кызыксынучан-төпченүчән булуымнан гына түгел, ләкин бу мәсьәләнен асылын үзгәртми, кулыма Корьән тотып, «телемне тешләрмен» дип ант бирсәм дә, котылып булмаячак.—Тоглар авыр көрсенеп куйды.

Городецкий озак уйланып утырды, аннары кинәт йөзе ачылып талпынып куйды:

—Синен кайчан да булса башка кушаматың бар идеме?

—Бар иде...—дип сүлпән генә жавап бирде номер хужасы. Бөтенесен дә белеп торучы Аргентинлының сүзне кая борырга теләгәнен аңламады ул.—Сон, син үзен дә хәтерләргә тиеш: бервакыт «Пекин» ресторанында утырганда, мин карандаш белән генә сезнең рәсемнәрне сызгалаган идем, шунда Шакро карт мине Модельяни дип атады. Әмма ул кушамат, никтер, мина ябышмады, юкса үземә ошый иде—Модельяни...

—Иске кушаматың табылу бик әйбәт. Мин Мәскәүгә синнән бер өч көнгә алланрак кайтырмын, булдыра алган һәр жирдә синен хакта гәп куертырмын. Без бит син югалып торган арада шулай ук үзгәреп беттек, милли фатирларга таралыштык: славян төркемнәре, әрмәннәр, әзербәйжаннар, билгеле инде—«чехлар», алар карак гореф-гадәтләрен танымый, читтәрәк аерылып тора. Бер Солтан Даудовлары гына безнең законнар буенча яши, безнекеләр чеченнәргә аның аша гына чыга ала.

Димәк, без синең белән славян оешмасында. Ә хәзерге өч ел, братан, элекке унбиш елынны орып бирә—элекке төрмә исәбе белән бер елы бишкә баса. Сине картлар хәтерли. Без бит яшьтәшләр бугай—юбилейга таба тәгәрибез. Мин үзем «Метрополь»дә үткәрергә уйлыйм. Чаян мин, димәк, ноябрьдә сине дә чакырам...

—Ә минем илле тиенем декабрьда. Кайда үткәрермен, белмим әле, юбилейларга хәтле яшәрмен дип һич тә уйлаганым булмады,—диде Тоглар.

—Сина иллене биреп булмый әле, мин, мөгаен, синен өлкән абыең булып күренәмдер,—дип көлеп җибәрде Городецкий. Аннары сүзен дәвам итте:—Шулай да сине онытa да төштеләр, аргамак көннәр, әйткәнемчә, бер ел эчендә бишне чабып уздылар, ләкин бу очракта шулай булуы сиңа яхшыга гына. Элекке алтын заманнарда Мәскәү тулысынча безнеке—славяннарныкы иде. Әлбәттә, элек тә Кавказ, Урта Азиядән килгән братаннар бар иде, ләкин хәзерге кебек бригадалап булмады. Ә хәзер аларның бөтен братвасы—эте-бетеннән алып тузларына кадәр Мәскәүгә ябырылды. Күпертеп сөйләмим, үзең күрерсең әле—үз җирләрендә ни урлар, ни талар нәрсәләре калмады бит: ачлык, хәерчелек, җан өшеткеч фәкыйрь тормыш...

Шулай, братан, алдашу-урлашу, талау-үтерү хәзер бары тик Россиядә генә файдалы—Дәүләт Думасында да братваның үз кешеләре утыра, безгә каршы булган бер генә законны да үткәрмиләр. Депутатларның ярдәмчеләре һәммәсе—законлы караклар. Чукынып әйтәм: президент администрациясе башлыгының биш ярдәмчесе дә безнең кешеләр, кайбер журналистлар хәтта братва фоторәсемнәре ябыштырылган таныклыклар йөртә. Шундый ксивасы булган кешене, хет «Калашников» асып йөрсә дә, кем соң тоткарларга җөрьәт итсен! Ярдәмчеләре нәрсә, Пудель үзе, син аны беләсең, Приморьедан, ул хәзер халыкара оешмаларда Россиянең вәкиле булып йөри, Россия мандаты белән БМОсына да майга кергән пычак кебек кенә үтеп керә, «Аргументы и факты» атналык газетына интервьюлар бирә. Ә Отарик хәтта үз партиясен оештырырга җыена. Син һушыңнан гына язма: шуңа күрә дә хәзер безнең Мәскәүдә кытайлар да, кореецлар да, монголлар да, вьетнамлылар да, хәтта африканнар да үз кәсебен таба—тулы интернационал Мәскәүне дә, бөтен Россия-матушканы да кисәкләргә өзгәләп чәйниләр.

—Карап-тыңлап торам да, син үзең дә Думага үрмәләргә чамалыйсың, ахрысы, чын сәясәтче булып беткәнсең, Ватан өчен жаныңны бирергә әзер!—дип ихластан көлеп җибәрде Тоглар.

—Гафу ит, кайвакыт шулай салулап киткәлим инде мин, сөйләнергә-тел чайкарга яратам, минем эш коралым оста кул бармакларым гына түгел бит, телем дә. Минем гранд-люкска төрле халык җыела. Кичә, мәсәлән, элекке партия түрәләре белән уйнадым—алар Ростовта хәзер барысы да эшмәкәр-фәлән—капиталист, банкир булып беткәннәр. Һәркайсысы Ватан өчен кайгыра, үз юлбашчылары белән бергә илне таркатып ташладылар да, хәзер елаган булалар. Соң, мин дә алар җырын җырлаган кыланам инде, алайса алар, идеологик мәнфәгатьләрен саклап, минем белән уйнамаячаклар, ә мина кемне төп башына утыртып уйнарга кала соң? Сине түгел бит инде. Ярар, әйдә, Модельянига кайтыйк әле... Яхшы рәссам иде, типтерергә дә яратты, кәрт уйнауны да чит итмәде, авыр туфрагы җиңел булсын. Кызганыч, син шагыйрьләрнең рәсемнәрен ясамадың, бәлки, танылып киткән булыр идең, Мәскәүдә шагыйрьләр мыжгып тора бит,—дип чәнчеп алды Аргентинлы.

Тоглар шундук җавап тапты:

—Ул вакытта син Ялтада мин әтмәлләп биргән ксива белән Охлопков Сергей Александрович булып ике ел яши алмаган да булыр идең. Мин саф рәсем сәнгатенә күчсәм, дим...

Икесе дә чын күңелдән көлеп җибәрде.

—«Король үлде, яшәсен король!» дигән атаклы сүзләрне бераз үзгәртеп әйтим әле,—диде Городецкий.—Тоглар үлде, яшәсен Модельяни!

Хәер, аңлыйм: сиңа легендар Тоглар исеменнән аерылу жинел түгел, әмма нишлисең—тормыш даннан кадерлерәк. Син борчылма, эшсезлек сина янамый, элекке клиентларына хезмәт итәрлек көч һәм сәламәтлек бирсен Ходай үзенә! Безнең кореш-тамырдашларның кайсысын гына алма—Сапер кушаматлы Вася Головачевнымы, днепропетровскийлы Олег Лозовскойнымы—анысының кушаматы Дантес—кыскасы, һәммәсе хәзер төрле компания, фирма, ассоциация, фонд, концерн, финанс һәм траст группалары һәм тагын, шайтаным белсен, нәрсә хужалары гына булып бетмәде. Алар сине көнгә берничә мәртәбә телгә алып тора. Дантес бервакыт үз кабинетында мина бер кәгазь күрсәтте... Ул үзе «Метрополь»нең бишенче катында тулы бер канатны алып яши, берәр кайнар башлы клиент туры килгәндә, мин анардан кайвакыт ачкыч алгалыйм. Дантес үзе дә кәрт сугарга ярата, фирма эшенә бик исе китми, анда жаваплы кешеләре житәрлек... Әйе-е-е, менә шул әйтә: «Тоглар исән булса, ди, мина адресланган бер кәгазьгә имза ясап бирер иде дә, мин үз компаньонымны бер илле миллионга яндырыр идем, ди, баксларда!» «Ә аннары?—дип сорадым.—Компаньоның ул имзадан баш тартачак бит». Дантес көлә генә: «Син, ди, Тогларның ничек оста эшләгәнен оныткансың. Имза хужасы үзе дә аерып ала алмаслык итә бит ул. Ярар, шикләнеп, судка бирсен, ди. Теләсә-кайсы судья аның элек мина жибәргән бер егермеләп хатын ала да алдына таратып сала, һәр ике якта—шаһитлар. Судья фирма бланкларына язылган текстларны каплый, тегенә әйтә: «Тап, кайсы имза ялган? Тапсаң—син хаклы, юк икән—Дантеска, сезнең тәкъдимегезнең финанс ягы белән кызыксынуы беткән өчен, шул ук сумманы түлисез, рәнжеткән өчен әле штрафы да булыр»,—ди. Аңладыңмы инде, Модельяни, хәзер акчаның фомка-кастетларсыз гына ничек эшләнгәнен?

—Әйе, каты, бер сүз әйтеп булмый... Әгәр дә үз компаньонын берьюлы илле лимон бакска тәгәрәтә ала икән, ул Дантес нинди зур акчалар белән эш итә соң хәзер?—дип, аптырашта калып сорады Константин Николаевич. Өч ел элек Лозовскойны бөтенләй башка кеше итеп белә иде бит.

—Кавказ әсире булып яту сиңа, туганкай, иректә балаларның әбәк-әбәк уены гына булып күренер әле. Бу елларда Россиядә, бигрәк тә Мәскәүдә шундый хәлләр булып узды, аларны тиз генә аңлап та, бәяләп тә бетерешле түгел. Кичәге фарцовщиклар, кече фәнни хезмәткәрләр—кефехеләр (к. ф. х.), марксизм-ленинизм укытучылары—һәммәсе дә депутатлар, хөкүмәт әгъзалары, банкирлар булып бетте. Алар миллион һәм миллиардлык байлык туплады, билгеле инде «яшел» акча белән. Бер унайдан, әйтеп куйыйм әле: Мәскәүдә оятка кала күрмә—хәзер барлык бәяләр дә долларлар белән исәпләнә. Бу мөмкинлекләрне син, Тоглар, чечен әсирлегендә ятып, ычкындырдың шул инде, хәзер жинел генә байлык авәләү шактый катлаулы, әмма шулай да мөмкин әле. Шыттыра бу дип уйлама, ышандыру өчен мин сина Кутузов проспектындагы фатирымны күрсәтермен, мин аны кәрт уйнап отып алдым. Ул фатирны бизәү-жиһазлау өчен хужасы Италиядән һәм Франциядән бик атаклы дизайнерларны чакыртып алган булган, ә ремонт эшләрен финнар башкарган.

Үзенең бу кайнар нотыгыннан соң Городецкий дулкынлана ук башлады, ләкин үзен Тогларның бик игътибар белән тыңлап утыруын күргәч, тиз генә тагын бер шешә сыраны бушатып куйды.

Аргентинлы үзенә хас булмаган остазлык миссиясе һәм легендар Тогларга файдасы тию мөмкинлеге белән шул кадәр мавыгып китте ки, хәтта ашау турында бөтенләй онытты, бары тик сырадан бушаган шешәләрен генә идәнгә тәгәрәтә торды һәм сирәк кенә шампан шешәсенә дә караштыргалап алгалады. «Де Кастеллани» аның күнеленә хуш килгән иде шул.

Кунакчыл хужа буларак, Константин Николаевич спиртовканың әкрен утында утырган ялтыравык хромлы савытның капкачын ачып

җибәрде, эченә кара җимеш тутырып тәмләп кыздырылган яшь күркә итенен хуш исе карт тамырдаш-корешларны тәлинкәләргә үрелергә мәҗбүр итте.

Ләкин Городецкий үз сөйләгәннәреннән үзе һаман да суынып җитә алмый иде әле, аны берничек тә туктатып булмас шикелле иде. Бәлки, ул ниндидер сәбәпләр белән Фешинның Мәскәү һәм Россия хәлләреннән хәбәрдар булып калуын гына теләмидер, бәлки, күңеленнән ташып чыкканнарын әйтеп бетерергә, тирә-яктагы тәртипсезлек-әшәкелеккә үзенең мөнәсәбәтен белдерергә телидер. Карт каталанның күңеле нык кайнаган булган шул, бик нык кайнаган булган...

—Менә шулай, братан, күреп торасың, ике-өч ел эчендә җинаятьчеләрнең яна төрләре үсеп чыкты һәм бу вакыт синең Чечнядагы «курортың» чорына туры килде,—диде ул, яшь күркә итенә таза тешләрен батырып.

—Ярыйсы курорт,—дип көлемсерәде Тоглар.

Городецкий кинәт кенә урыныннан кузгалды:

—Синең рөхсәтең белән, бер адәмгә шылтыратып алыйм әле... Бүген төштән соң зур уен көтә, кызыксынсаң, мен минем люкска, сине танылган рәссам дип таныштырырмын...

—Рәхмәт. Төштән соң минем дә эшләрем бар,—дип шундук баш тартты Константин Николаевич, кичкә ул Наталья белән очрашу билгеләгән иде.

Кунак көзге каршында торган телефонга килеп, тиешле номерын җыйды да, нибары бер-ике минут сөйләшеп алды, шуннан артык түгел. Аннары, кулларын шатланып уа-уа, өстәл янына кайтты. Уен булачак һәм карт төлкегә зур калҗа-табыш эләгәчәге сизелеп тора иде.

—Менә шундый хәлләр, Тоглар дус. Әле нокта куелмаган...—Аргентинлының йөзе һаман әле сүрелмәгән, күрәсең, ул төштән соң буласы уен ләззәтен инде хәзер үк кичерә башлаган иде.

—Әйе-е, мина да, мөгаен, бу үзгәрешләргә күнегергә туры килер, ахрысы,—дип нәтиҗә ясады Фешин.

—Менә-менә... Күнегергә дә, як-ягына карангалап тормыйча, үзгәрергә дә кирәк, юкса башынны югалтуың бар... Ярар, сиең өчен рәхмәт, башны да әйбәт төзәттек.—Аргентинлы җитез генә торды, үзенә күзгедән караштырып, сүзен төгәлләргә ашыкты:—Синең исән-сау булуыңа шатмын, без картлар азайганнан-азая барабыз бит. Ә яңалар хәзер утызга да җитә алмыйлар, без аларга, мөгаен, динозаврлар булып күренәбездер инде. Кеше гомеренең бәясе бетте. Мәскәүдә бүген өч йөз бакска да үтерергә ризалар... Кызганыч, аз сөйләшеп утырдык әле...

Фешин үзалдына елмаеп куйды: ярыйсы аз! Гел генә Городецкий такылдап утырды бит, ә Тоглар, тәртипле укучы бала кебек, тыңлап, баш кагып кына торды. Әмма Аргентинлы моны сизмәде дә, әллә сизмәмешкә генә салындымы?

—Тиздән әбәт җитә, аннары иртәнгә кадәр уеным бар, ә иртәгә Мәскәүгә очам—эшләр,—диде Городецкий.—Ә, карале, әйдә, әбәтне бергәләп ашыйк, бу юлы мин сыйлармын, ресторан пешекчесен элекке заманнардан ук беләм. Донда, Аллага шөкер, әле яхшы балыкларның беткәне юк: мәрсине дисеңме, кырпысы-чөгәсеме—тулып ята. Мин балык ассортие-солянкасын, шулай ук төрле балыклар өстенә дердери-койкы коеп пешерелгәнен сорармын, калганнары да иң тәмле балык кисәкләреннән булыр. Ризалаш, андый сый-нигъмәтне тиз генә оныта алмассын. Ә иң мөһиме—сөйләшеп утырасы килә, сүзләр бетмәде бит әле, сине тизрәк яна тормышка кертеп җибәрергә кирәк.

Константин Николаевич сәгатенә карап алды—аның әле вакыты җитәрлек иде. Аннары балык ашлары да ымсындыра иде—чеченнәр аны ашамый диярлек—шуңлыктан, әсирлек елларында Тоглар балык азыкларын бик тансыклаган иде. Әмма сыйланудан да мөһимрәге, сүзчән Аргентинлының сүзләренә караганда, тормыш бик нык-кискен үзгәрә һәм миналанган кырга охшап бара, ә Городецкий, матурлап әйткәндә, нәкъ шул

мина кыры картасын сызып бирә. Җае чыккач, форсаттан файдаланып, Аргентинлы белән якыная төшү дә комачауламас. Тогларга әле Мәскәүдә озак вакытлар юл күрсәтүче кирәк булачак. Шуна күрә, Константин Николаевич иске тамырдаш-корешынын кунакчыл-ихлас тәкъдимен кабул итте.

## 2

Ике сәгатьтән сон, Фешин залга килеп кергәч, метрдотель аны иске дусты кебек итеп каршылады һәм, күрәсен, кисәтеп куелган булгандыр, кичәге өстәл янына алып китте, анда инде Городецкий елмаеп утыра иде. Өстәлдәге яссы вазада таныш чәчәк букеты да тора.

—Ошыймы?—дип сорады Аргентинлы һәм көлеп өстәп куйды:—Мин аларга, дустым өстәлдә шундый гүзәл чәчәкләр булса гына килергә ризалашты, дидем, аларга синен үз букетынны директор кабинетыннан алып чыгып куярга туры килде.

Икесе дә рәхәтләнеп көлештеләр.

Өстәл бай, бик тә бай һәм зәвыклы иде. Фешин моны күрми кала алмады һәм карт шулернын бу гамәлен бәяләп тә өлгерде, шунын белән бергә, үзенен иртән сөйләшеп утыргандагы сизенүләренен дөреслегенә раслау да тапты: әгәр дә ул кемгә булса кирәк икән, димәк, братва өчен генә кирәк.

Тәҗрибәле Аргентинлы Тогларнын эчке халәтен сүзсез дә анлады һәм чын күнелennнән әйтте:

—Моны синен хөрмәтенә банкет дип кабул ит! Без бит хәзерге яна бүреләр түгел, бездә, братан—бу изге эш! Шулай булгач, безне хакимият тә, яна пешеп чыкканнар да җинә алмаячак, безнен идеологиябез үзгәртеп коруларга буйсынмый, акча да безнен өчен берни дә тормый, акча—пычрак ул. Сине иректә беренче булып үзем очратуыма шатмын. Әйдә, синен саулыкка, братан!

Ул өстәл читендәге бозлы чиләктәге таныш булмаган шампан шешәсен муеныннан эләктереп алды. Фешиннын кызыксынулы карашын тотып, Городецкий елмайды:

—Син мине бүген искиткеч шампан белән сыйлаган идек, мин дә менә сине шатландырырга булдым. Ресторанnan түгел бу, валюта кибетеннән китерделәр—моны гомергә бер генә эчәргә була...

—Ни өчен алай гомергә бер генә?—дип бүлдерде аны Тоглар.

Городецкий шатланып кулларын чәбәкләп алды:

—Әһә! Син дә каптын! «Тайттингер»нын бөтен дөньяга таралган рекламасы бу. Сүзгә-сүз тәрҗемәләсән: «Гомерегездә бер генә мәртәбә»... килеп чыга. Мин бит үз вакытымда инязны кызыл диплом белән бетердем, инглиз һәм француз телләрен беләм,—дип горурланып әйтте Аргентинлы.—Йә, әйдә, очрашу хөрмәтенә күтәрик, тормышыбызда мондый шампаннар һәрвакыт булып торсын!

Алар бокалларын күтәрделәр.

Эчеп, һәртөрле кабымлыктан авыз иткәч, алар тегесен-монысын гына сөйләшкәләп утыра иде, Аргентинлы кинәт көтелмәгән сорау бирде:

—Син бит чирек гасыр инде братва белән, әйт әле, белгәнемчә, син һаман да шул кәгазьләр маташтырудан башка эш белән шөгыльләнмәден бугай, ә?

Тоглар, Городецкийнын тагын нинди дә булса кызыклы тарих сөйләргә әзер булуын, анын сөйләгәненнән янә нинди дер файдалы фикер алу мөмкинлеген сизенеп, баш кына кагып ризалашты.

—Алайса әйт әле мина, элекке заманнарда син документлар ясап биргән берәр адәм, ул-бу килеп чыкмагае дип, үзенне теге дөньяга җибәрергә әзер булыр идеме?

—Нигә хаҗәт ди андый гамәл ана? Тормыш—куласа, бер әйләнә—бер баса, дигәндәй, минем бит ана тагын кирәгем чыгуы бар. Безнен

заманда ксивасыз кая бара аласың, син аны бәладән коткарасың, ә ул... Юк, андый кабахәтлек «западло» саналыр иде. Төрле психларга төрле кәгазьләр эшләп биргәнем булды, әмма син әйткән нәрсә башыма да кереп карамады.—Фешин ихлас сөйли иде, Аргентинлы аны аңлады.

—Йә, алайса тыңла, мин сиңа тагын бер тарих сөйләргә тиеш тә тиеш, хәзер бит башка клиентлар китте, бөтенләй башка, колагыңны үрә торгызып яшәргә кала. Мондый хикәятне минем дә, синең дә ишеткәнең һәм иң мавыктыргыч куркыныч фильмнарда да күргәнебез булмады. Безнең заман героеның да мажараларын экранлаштыру мөмкинлеген тапса, Голливуд, мөгаен, бик зур акчалар чыгарып салыр иде.

—Йәле, йә, агарт мине, бәлки, кайчан да булса бер кирәге чыгар,— дип Аргентинлыны үсендерде Тоглар.

—Кайбер вакыйгаларын элегрәк төрле чыганаклардан ишеткән булсам да, бу тарихны тулысы белән бер кеше авызыннан бер ай элек кенә ишеттем, берәүнең өй туенда сөйләде ул аны. Президентыбыз дәваланырга яки кирәк чагында ялгызы кәеф-сафа корырга яраткан Барвиха санаториеннан ерак түгел бер җирдә бер братаныбыз өй туе үткәрде. Ышанам, без әле синең белән икәү аңарда бер генә кунак булмабыз, мин сине аның белән, һичшиксез, таныштырырга тиеш, ул бездән яшьрәк булса да, синең хакта ишеткәне бардыр. Ул үзенә шундый сарай салган—әкиятләрдә сөйләп, китапларда язып та бетерерлек түгел: өч каты күккә үрләгән, тагын бер каты җир астына сеңгән... Нефть магнатлары Шаманның ул хазасын күрсә, көнләшүләреннән шартлар иделәр, валлаһи! Ул Төмәнне үз кулында тота, кушаматы да шуннан—Шаман... Өй туена үз кешеләре генә җыелган иде, күп түгел—илледән артык булмастыр. Төнгә таба, кунаклар төркемнәргә бүленеп, кайсылары бүлмәләргә, кайсылары бакчага таралгач, кемнәрдер бильярд суга, кемнәрдер саунада парлана, кемнәрдер бассейнда коена башлагач, икенче каттагы каминлы залларның берсендә хуҗа белән бергә ун-унике кеше торып калды. Шунда гади генә киемле бер кунак,—ә үзе ул болай зур дәрәҗәле ментлардан,—зур шау-шу кубарып, «Матросская тишина» төрмәсеннән берәүнең качу тарихын сөйләде. Ул хакта аз-маз гына газетлар да язып чыкты, телевидение дә телгә алып узган иде. Шунысы гына аңлашылып бетмәде: бу мент моны әллә үзе тирәсендә бөтерелүче яшь дамалар алдында әтәч булып күренәсе килепме, әллә үз бәясен күтәрергә теләпме, әллә булмаса кемгәдер ым-ишарә итепме сөйләде. Анда «текә егетләр» җитәрлек иде, ә бәлки, башка максаты булгандыр, ментларны без бервакытта да аңлый алмабыздыр. Әмма шунысы хак: ул безгә гаҗәп тә кызыклы хәлләрне бәян итте, ә синең өчен киләчәктә гыйбрәт алырлык, кирәге чыгарлык булуы да мөмкин. Мин бит сиңа кәгазь-мәгазьләрең турында сорауны юкка гына бирмәдем...

—Кәгазь белән кәгазьнең дә аермасы бар,—дип сүз кыстырды Фешин, тәлинкәсендә чәнечкесе белән чокчына-чокчына.—Кайбер кәгазь кеше гомере тора, үзең беләсең.

—Беләм,—дип ризалашты Аргентинлы.—Сине рәнҗетү өчен әйтмәгән идем. Бу тарихны, мөгаен, азагыннан, сиңа күп еллар таныш СИЗО-I дән башларга кирәктер. Ул СИЗО турында мең тугыз йөз туксан беренче елның августында бар халык белде инде, теге ГКЧП башлыкларының һәммәсен дә шунда ябып тоттылар бит. Ә янадан СИЗО турында сөйләнергә элекке милиционер, бик яңгыравык Македонский кушаматлы утыз биш яшьлек Александр Солоник мәҗбүр итте. Кушаматны ана телгә үткен журналистлар сылады булса кирәк. Беләсеңме, шундый алым бар—берьюлы ике кулдагы пистолеттан ату, шул алым «македонча ату» дип йөртелә, әлеге егетебезгә бу алымда тиңнәр юк икән.

Дөрес, «Матросская тишина» төрмәсе белән ул шактый элегрәк танышкан, аның беренче утыруы турында кире кайтып сөйләрмен әле... Төрмәнең бөтен тарихында аннан бер генә качу очрагы да булмаган.

Син әйт, Македонский ничек анда барып эләккән, диген? Төрмәгә

эләгергә ике ай кала, ментлар теле белән әйткәндә, «ул тикшерү ачыклый алмаган бер зат белән» башкаланың Петровско-Разумовский базарына барып чыккан. Безнең братва сүзләренә караганда, кемнеңдер заказы белән килгән: кемдер кемгәдер түләргә тиеме икән—бу шуны ачыклап, төбенә төшәргә тиеш. Бик тә пижоннарча киенгән булган, кыскасы, базарча түгел. Күрәсең, килергә тиешле кеше очрашуга соңга калган, хәзер бит һәр базар тулы ментлар, әрле-бирле йөреп торгач, бу да һаман милиционерлар күз алдында бит инде. Иптәше белән Солоникны, документларын тикшерергә дип, милиция бүлмәсенә үтәргә кушалар. Соң, чакыргач, бара инде болар. Ишектән кергәндә, Солоник әдәпле генә итеп хуҗаларны алдан үткәреп җибәрә дә, үзе кереп, ишекне ябып куя. Македонскийның бер кулы беләгенә ачык төстәге җәйге плащ эленгән, плащ астында күп патронлы голланд пистолеты «глок» икән, ул шундук үзенең элекке хезмәттәшләренә ата да башлаган. Икесен шундук үтергән, икесен авыр яралаган. Милиция бүлмәсеннән атылып чыгып, икесе ике якка сыпырткан болар. Македонский артыннан «Бумеранг» фирмасының ике сакчысы ташланган, аны әле тагын юлында очраклы очраган милиционер да туктатып карамакчы булган, ләкин Солоник аны да атып еккан. Шулай да сакчылар Македонскийны эләктереп алганнар.

Безнең геройның берсе яраланган булган, ул тамызгыч система астында яткан арада, җәтмәгә гади балык кына түгел, алтын балык эләккәне мәгълүм булган. Бу балыкны илнең бөтен милициясе аулаган, барлык махсус хезмәт оешмалары; аны братва да, яшь бүреләр дә эзләгән, һәр пост милиционерының кесәсендә аның фоторәсеме булган, ул 1988 елдан бирле качкынлыкта саналган икән...

Ә хәзер сүзебезнең башына кайтып төшәргә дә булыр. Ләкин аңа кадәр без синең белән берәр бокал гүзәл шампан шәрабен күтәреп куйыйк та, аның артыннан дердериле тәмле чөгә балыгы капкалап алыйк. Аннары безгә шул ук чөгә шулпасын бирерләр, биредә аны аерым рецепт белән кырпы баш миен салып пешерәләр. Аракыны стаканлап чөмерсәң дә, шундый уха ашап куйсаң—бервакытта да исермәссең. Моны исеңдә тот.

Бокалларын уныш өчен күтәрделәр—тәвәккәллек сорый торган бу тормышта фарт-бәхет дигәнең бик кирәк нәрсә ул. Әмма Аргентинлының, күрәсең, теге тарихны тизрәк сөйләп бетерәсе килә иде...

—Димәк,—дип башлады ул янәдән сүзен,—Россиянең беренче гангстеры, безнең газетлар ачыклаганча, 1960 елда Курган шәһәрендә туган, атаклы хирург-травматолог Елизаров эшләгән шәһәрдә, ишеткәнең бар идеме?

Фешин, аны кем белмәсен, дигәндәй, ризалык белән баш какты.

—Ул армиягә кадәр дә шәһәрдә танылган егет булган: чибәр, төз-зифа буйлы, матур киенә, һәрвакыт пөхтә, музыкага үлеп гашыйк, бик әйбәт бии. Классик көрәш буенча югары спорт разряды бар, самбо һәм дзюдо белән мавыга, кул сугышы алымнарын яхшы белә. Армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң, ул милициягә эшкә керә, ату буенча инструктор була. Әмма, Горький югары милиция мәктәбендә читтән торып укыса да, ментлар арасында карьера ясый алмый ул. Ә бит хезмәттәшләреннән бер башка өстен күренә—акыллы, дан сөючән, хәйләкәр, беркем алдында да баш иярга, бил бөгәргә яратмый. Әлбәттә, мондый сыйфатлар мент өчен түгел, анда ул очраклы гына барып эләккән, ә бәлки, инде шул чакта ук, яшьтән ул системаны эчтән өйрәнергә уйлаган булгандыр. Аның шәхси тормышы да берничек тә мундирлы кеше образына тәңгәл килми: купшы-көяз, кукраеп-һаваланып йөрергә ярата, шәһәрдә танылган донжуан. Аны әнә шундый бер мәхәббәт тарихы төрмәгә китереп тыга да инде, мин уйлыйм, шул гаделсезлектән ул бөтен дөньясына үч-ачу тота башлагандыр да: ул үзенә лаек тормышны ни иректә, ни төрмәдә таба алмаган, шуңа күрә сындырылган язмышы өчен һәркемнән үч ала башлаган. Шәһәрдә бик абруй-йогынтылы бер партократның кызы белән гыйшык-мыйшык уйный башлаган чагында, ул инде өйләнгән булган.

Кыз Македонскийга шашар дәрәҗәдә гашыйк икән, шуңа өйләнсә, бәлки, милициядә генерал погоннарына кадәр үскән булыр иде, ул бит гадәттән тыш сәләтле кеше. Яна мәгъшукасы аның, хатынын аерып, үзенә өйләнүен таләп иткән, юкса төрмәгә илтеп тыгам мин сине, дигән. Акылсыз кыз, болай әйтмәскә, житмәсә янамаска тиеш иде, әлбәттә. Бәлки, әле аралары ничек тә җайланган булыр иде, ә Солоник бала чагыннан ирексезләүне, мәҗбүр итүне күтәрә алмый, шунлыктан кыз белән арасын бөтенләй өзә. Шуннан соң ана каршы тиз генә эш кузгаталар, кызны көчләүдә гаепләләр һәм ул беренче мәртәбә төрмәгә эләгә, аңа әлеге статья буенча җәзаның иң югарысын диярлек чәпиләр—егетне кызганып тормыйлар.

Үзең беләсең бит, Тоглар, көчләү өчен утыртылган бәндәнең төрмәдәге тормышын, житмәсә мент та бит әле. Кешене бетте дип исәплә инде. Андыйларны теге... «төшерәләр», параша яныннан гына урын бирәләр, хәтта муенына элмәк салу дәрәҗәсенә китереп житкерәләр. Без синең белән дистәләрчә шундый язмышларны беләбез. Ләкин Солоник боларның берсен дә кичерми—үзен бәйсез тота, камерада булсын, төрмә башлыклары алдында булсын—беркемгә дә баш бирми. Усал, гайяр, рәхимсез була, үлгәнче сугышса сугыша һәм тәки үз урынын яулап ала. Братва, аның көчле-тәвәккәл шәхес икәнен сизенеп, үзенә якынайтырга тырышып карый, әмма ул беркемгә дә хезмәт итәргә теләми, ялгыз бүре булып кала шулай. Төрмәгә ияләшкәч-күнеккәч, кача ул. Төрмәнең зонадан шактый ерак барып чыга торган тар канализация торбасы аша ычкына. Бер чакрымнан артык озынлыктагы жир асты торбасыннан үрмәләүче кешене күз алдына китерә аласыңмы? Ул бит тере килеш кабергә керү белән бер, ә торба берәр жирдә шартлаган, ишелеп күмелгән булса... Мондый тәвәккәллекне бары тик бик ирек сөючән, көчле һәм нык ихтыярлы кеше генә булдыра ала. Төрмәгә ул романтик пижон булып барып керсә, аннан бүре, супермен булып чыга. Юк, кино-театрлардагыча түгел, ә безнең братның һәм зур байларның котын ала торган супермен.

Качкынлыкта булса да, һәркайда аның аерым билгеләре игълан ителеп, эзләнүләр дәвам ителсә дә, Солоник төпкә төшеп ятмый, илне аркылыга-буйга инләп йөри бирә. Кайда гына булмасын, һәр иртәсен ун чакрым араны йөгереп узарга тырыша, көрәш һәм авырлыклар күтәрү белән мавыгып, шактый вакытын спорт залларында уздыра—кыскасы, һәрвакыт менә дигән физик әзерлекле була. Ул бервакытта да тартмаган һәм эчмәгән, башың ачык зиһенле, тәнең үзенә буйсынучан сыгылмалы һәм бик түзем булырга тиеш дип санаган. Әмма ул дөнья рәхәтеннән ваз кичкән тәкъва да түгел, нинди дә булса башка сыймаслык саташулы идеяләр колы да булмаган. Кайбер журналистлар аны бер баш бирмәс бунтарь, җәмгыятьнең санитары, җинаятьчелеккә каршы көрәшче, үтерүчеләрне үтерүче, гаепләләргә үзе җәза бирүче кебек атамалар белән «бизәп» күрсәтмәкче булдылар. Ләкин мин аның ни теләсә шуны кыланып йөрүчене, яки берәр «күсе»не, яисә «западло»ны атып үтергәне турында ишеткәнем юк әле. Ул бары тик заказ буенча гына һәм бик зур акчага гына үтерә. Үзенә-үзе уйлап чыгарган тормышындагы героен ул Френсис Скотт Фицджеральд геройларыннан күчереп алган шикелле, әмма ләкин монысы исә даими һәм бертөзлексез акча, акча, акча таләп итә торган тормыш. Мөгаен, качып-яшеренеп яшәү, тәүлекләр буе үзеннең иминлегенне тәэмин итәрлек сакчылар тоту шулай ук зур чыгымнар сорый торгандыр—аның янадан төрмәгә һич кенә дә барып керәсе килми бит. Әкияти бай тормышның түбән татып, шундый биеклекләргә күтәрелгәч, аның инде кабат канатларын сындырасы килми, дүрт диварлы бүлмә кысаларында ул тончыгып үләр иде, чөнки ана хәзер бөтен дөньясы да тар-кысан булып күренә башлаган бит.

—Фамилиясе бик сәер, милләте белән кем соң ул?—дип кызыксынды Тоглар.

—Шикләнмә, рус ул, чыкылдап торган рус. Андый бөркетне бары тик безнең жир генә тудыра ала.

Солоник һәрвакыт ялгызы гына эш йөртә, озын-озакка сузылган контракт-килешүләр ясамый, нинди генә отышлы булса да, андыйлардан баш тарта. Төп шөгыле—заказ буенча үтерү. Аның кемнәрне кайчан үтерү чираты берничә айга алдан язып куелган дип сөйлиләр: көндәшен, элекке компаньонын, бурычын түләмәүчеләрен үтерергә теләүчеләр шулкадәр күп икән. Тагын шулай да сөйлиләр: имеш, ике-өч көн арасында ул шундый заказ ала, әйтик К. ана Н. ны юк итәргә куша, шул ук көнне Н. исә К. ны чәнчелдер, ди. Шуннан соң, аның үз корбаннары һәм заказчылары турында нәрсә уйлаганын җинел анларга буладыр шикелле.

Дөрес, кайвакытларда ул үзенә кулдашлар да яллый икән дип тә ишеткәләдем, кемнәрдер киллерлар бригадасы оештырган дип тә ышандырмакчы була. Бәлки, шулайдыр да—безнең Бабон кушаматлы братаныбыз Владислав Виннерны үтергәндә, машинасына төрле яктан атып, чәрдәкләп бетергәннәр ич. Заказлы үтерүләрдән бушаган арада—ә ул үз «эше» өчен йөз меңнән дә ким алмаган—Солоник безнең братва белән яңа бандитлар, яшь бүреләр арасындагы низагларны-бәхәсләрне хәл итү юлы белән акча эшли, ә соңгы вакытларда бер банк белән икенче банк арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала яисә банкның теге яки бу финансчылар белән араларын көйли яки киресенчә эш йөртә.

Син, Тоглар, күз алдына китерә аласынмы, безнең братваны, элекке булса да, мент араласын яки акчаларыбызны сыгып алсын әле? Ул бит безнең кануннар буенча яшәми дә.

—Юк. Күз алдына китерә алмыйм. Андый хәлнең булуы мөмкин түгел. Ул әллә Ходай Тәгаләме соң?

—Кызганыч ки, нәкъ шулай. Әлбәттә, ул Ходай Тәгаләнең үзе үк түгел түгелен. Арытабан тыңла... Тагын кабатлап әйтәм: иректә һәммәсе дә үзгәрде. Хәзер сиңа, тирәндә су астында эшләгән водолаз шикелле, кессон аппараты эчендә утырып торырга туры киләчәк, юкса һәлак булачаксың. Македонскийның безнең братва белән ниләр кыланганына тагын бер мисал сөйлим.

Сиңа билгеле булган бер законлы карак—Мәскәүнеке, ничектер, кемнәр арасындадыр Македонскийның сәләтләре турында көлебрәк сөйләнә: янәсе, әкият болар барысы да, халык авыз иҗаты, аңардан зыян күрүчеләр куркуларыннан һәм хурлыкларын яшерү өчен аны шулай югары күтәрәләр, имеш. Ничектер бу сүзләр Солоникның үзенә барып ирешә бит. Ул бик үпкәчел, әлеге бәндәне бик усал итеп акылга утырта. Сиңа таныш ул пахан Киев вокзалы янында яши, табигый ки, хәзер һәркемдәге кебек, броня ишек, балконсыз бишенче кат—безнең брат хәзер үз иминлеге өчен океан арты президентыннан ким кайгыртмый.

Шулай итеп, утыра бу пахан бер яңгырлы кичтә үз өендә, унайлы күн кәнәфидә, видиктан ниндидер бер бик «майлы» фильм карап, янындагы журнал өстәле өстендә пистолеты ята. Теге сөйләнгән сүзләрен ул, әлбәттә, күптән оныткан инде, үз мәшәкатьләре дә муеннан. Бер генә минутка кухняга чыгып китә бу, үзе яраткан цейлон чәе «Эрл Грей»ны, ягъни мәсәлән, «соры кардинал»ны кайнатырга, кире бүлмәсенә килеп керсә, аның кәнәфиендә аягын-аякка куеп бер пижон утыра, моның кольтын бармагында әйләндереп уйната икән.

Безнең егет тә куркаклардан түгел, син аны беләсең, нервылары тәртиптә, ә шулай да кулындагы чәйнекле подносын идәнгә төшереп җибәрә. Сорый бу: «Син кем? Ничек килеп кердең?» Ә Солоник җавап бирә: «Македонский мин, форточканы ябып йөрергә кирәк, ни-нәрсә килеп чыкмас?»—Аннары идәнгә төшеп ватылган чәйнек-чынаякларга карап көрсенеп куя:—Кызганыч, синең белән берәр чынаяк чәй эчмәкче идем, язмаган икән,—ди. Пистолетын кайтарып биргәндә әйтә: «Пушкаң алама синең, моның белән саклана алмассың»,—ди дә тыныч кына атлап ишеккә таба китеп бара, бусагада бик тәкәллефле генә итеп баш ия—сезне күрү шәрәфенә ирешүем өчен шатмын, янәсе. Артист бит ул, үз тормышы белән дә, кеше тормышы белән дә мәче-тычкан уены уйнарга

ярата. Әгәр дә йорт хуҗасы бер минут кына алдан килеп керсә дә, аны шул алама кольтыннан да тәрәзәгә кунаклаган хәлендә атып үтергән булыр иде.

Соңгы тотылуына кадәр Солоникның ни чын, ни ялган фамилияләрен беркем дә белми диярлек, ә инде үзен күреп-танып белү турында сүз дә юк. Төс-кыяфәтен үзгәртергә бик маһир була ул—хәзер бу эш катлаулы түгел бит: яхшы визажистлар, сыйфатлы париклар, менә дигән грим-буяулар буа буарлык. Хәлбуки, ментларны да яманлап булмый, алар аның койрыгында даими утыра, аның турындагы мәгълүматлары һәрвакыт дөрес була. Ләкин Македонский үзен эзәрлекләүчеләрдән һәр чагында ычкынып өлгерә, туп-туры әйткәндә, борын төпләреннән чыгып шыла.

Бервакыт ул, ишеген ватып ментлар килеп кергәндә, жиденче кат балконыннан кача. Соңгы мәртәбә, күрәсең, үз хезмәткәрләренә дә ышанып бетмәгән ментлар, аның төгәл кайсы йортта яшеренеп ятканын белеп, йортны ике кат боҗра белән чолгап алалар, бәреп керсәләр, суынып та житмәгән урын-жирен генә табалар—ул һәрвакыттагыча юкка чыга, жир йоткан диярсең үзен. Солоник көтмәгәндә пәйда булып, көтмәгәндә юкка чыгуда гайре табигый сәләткә ия, шуңа күрә аны кайчандыр бездә Патрис Лумумба университетында белем алган Шакал кушаматлы халыкара террорчы Карлос белән чагыштырып йөртә башлыйлар. Македонскийны аулап йөри торгач, Мәскәү угрозыскысы яшерен корал складын таба, мөгаен алар да махсус аның өчен әзерләнгән булгандыр. Ул складларда төрле-төрле иң яхшы кораллар житмештән артык була. Бу яшерен пакгаузлар өчен берничә эре «авторитет»ларга карата жинаять эше кузгаталар, ләкин аларның берсе дә тикшерү барышында Солоникка каршы ләм-мим бер сүз дә әйтми, әллә куркалар, әллә шулкадәр коралның кем өчен сакланганын юньләп белмиләр шунда.

Солоник Россия буйлап бик еш сәяхәткә чыга, илне аркылыга-буйга инләп йөри, бигрәк тә ул Санкт-Петербургка барып чыгарга ярата. Ялган документлары гына булып, үзен озак еллар эзләүләренә карамастан, ул кулына чит ил паспорты да төшерә, шуның белән ярты дөньяны гизә. Испания, Португалия, Франция, Италия, Германия, Англиядә була, Якын Көнчыгыш, Гонконг, Сингапур кояшларында кызына. Ихтимал, ул андый илләргә ял итеп, көяз киенеп кайту яки Парижның атаклы «Максим»ында кәеф-сафа корып утыру өчен генә йөрмәгәндер—бәлки, юл уңаенда гына бер-әрсен үтереп тә ташлагандыр, ә бәлки, Шакалның үзе белән яисә шуның ишеләр белән очрашкалагандыр да, үтерүчеләрнең халыкара синдикаты бар дип, Көнбатыш күптәннән сөйләнеп килә бит инде. Шулай да мин Македонскийның чит илләргә сәфәр кылуларын ФСБ (Федераль иминлек хезмәте), ФПС (Федераль чик сакчылары хезмәте), МВД (Эчке эшләр министрлыгы), хәтта армиядә утыручы бик югары дәрәҗәле түрәләр оештырадыр дип уйлыйм. Ярар, милиционерлар мокыт та булсын ди, кулларында җентекле күрсәтмәләр була торып та, биш ел буена тота алмасыннар да ди, ләкин илдән чыкканда-кергәндә паспорт контроле бар, ышанып әйтә алам, анда бик яхшы белгечләр утыра. Македонский, дөньялар гизеп, һаман-һаман Мәскәүгә яки Санкт-Петербургка әйләнеп кайтырга тәвәккәлләр идеме икән? Әгәр дә аны кемдер каплап-яклап тормаса, дим. Юк, минем иманым камил, бик югарыда утыручы берәр түрә аны каршы ала һәм озатып җибәрә тора. Мәскәүдә булсын, Санкт-Петербургта булсын, ул байлык-муллыкта яши, иң кыйммәтле рестораннарда, төнге клубларда, яшерен притоннарда була, ат чабышларында уйный—болар бит барысы да милиция һәм махсус органнарның аерым күзәтүендә тотыла торган урыннар—ә ана ике дөнья, бер моржа!

Македонский машиналарны да бик ярата, аның тулы бер машиналар паркы була: берничә «БМВ», «Мерседес», «Форд-бранко», итальян «Мазерати»ы, анысын ул барысыннан да артык күрә. Үзенең бер сөяркәсенә

«джип-гранд-чероки» бүләк итә. Болар барысы да аның көчле-куәтле махсус органнар канаты астында утыруы турындагы фаразымны гына раслый, ул бит ГАИ хезмәткәрләренең чит ил маркалы машиналарны кирәксә-кирәкмәсә дә туктатып торуларын бик яхшы белә, мөгаен, һәр пост милиционерында аның фотографиясе дә һәм тәфсилле күрсәтмәләр дә бардыр. Аэропортларда һәм чикне кичкәндә хәвеф-хәтәрләр аша үтүе житмәгән, тагын көн саен юлларда да энә өстендә утырган кебек йөрү нигә кирәк, ди, ана? Юк, аны махсус органнарның саклап йөрүе көн кебек ачык. Петровско-Разумовский базарында тотканнан соң, анын фатирында дөнья чаклы корал тапканнар, хәтта кул гранатометы да булган.

Минем фаразларымны тагын шунысы да раслый, атарга хөкем ителерлек жинаятьләре булуга карамастан, ул сорау алу вакытларында үзен бик тыныч, ышанычлы тоткан, хәтта әле шаярткалап та утырган—югарыдагы дәрәжәле яклаучыларының аны Россиядә теләсә нинди элмәктән коткарып калачакларын белгән ул. Менә шулар аны «Матросская тишина» төрмәсеннән йолып алганнар да инде.

Соң, үзең уйлап кара...

СИЗО-I—махсус төрмә, ул секторларга, зоналарга, блокларга бүлгәләнеп беткән, бер бүлектән икенчесенә күчү конвойсыз һәм көн саен алышынып тора торган махсус парольләрсез мөмкин дә түгел. Аннары ул Россиядә эчке яктан—ишегалдыннан гына түгел, ә төрмәнең тышкы диварлары ягыннан да илле метрга кадәр телекамералар белән күзәтелеп тора торган бердәнбер төрмә диярлек. Анда әле тагын әллә нинди яшерен хикмәтле нәмәрсәләр бар: электрон кодлар, санлы-цифрлы йозаклар—панельләр, төрле яшерен ут сакчылары—алар аша үткәндә тревога сигналы үзеннән-үзе автомат рәвештә улый башлый. Кыскасы, безнең братка, тыштан һәм сине саклаучылардан ярдәм булмаса, качу мөмкинлеге юк, шуңа күрә дә «Матросская тишина»ның бөтен данлы тарихында аннан берәү дә кача алмаган. Моны бары тик безнең героебыз Македонский гына булдыра алган. Ә ул бит яраланганнан соң бик хәлсез булган, реанимациядә озак яткан, аннары госпитальдә, бары тик качар алдыннан гына лазареттан ялгыз камерага күчерелгән. Ул, әлбәттә, төрмә баландасын ашап та карамаган, ана ашарга якындагы рестораннан ташыганнар, ләкин бит көч жыяр, хәл алыр өчен дә вакыт кирәк.

Хакыйкать өчен шунысын да әйтик, Солоникның төрмәдән качуы күп кенә жинаятьчел төркемнәр өчен дә хажәт булган. Ул бит, түләүле үтерүчеләренең байтагы турында сөйләп бирсә дә, бер генә заказчысының да исемен әйтмәгән. Шуңа күрә мафия шулкадәр күп белгән кешенең тизрәк ирекккә чыгуын һәм хокук саклау органнарының күзеннән ераграк ычкынуын теләгән. Мәскәүдә һәм Санкт-Петербургта Македонскийны коткару фонды да оештырылган, һәм тиешле кешеләр бик тиз генә бер лимон сумманы жыеп та биргәннәр дип ишеттем. Ярлы илдә миллион доллар—зур акча ул, бәлки куркыныч бу киллерга төрмәдән качарга шул ярдәм иткәндер дә һәм мин югары дәрәжәле түрәләр белән махсус оешма хезмәткәрләрен юкка гына гаеплимдер. Хәер, шәхсән минем өчен аның качуы да һәм бөтен тормышы да сер булып кала бирә.

—Шулкадәр күпне яки бөтенесен дә диярлек белгән синең өчен дәме хәтта?—дип көлемсерәп куйды Тоглар.

—Тукта, тукта,—дип дулкынлана башлады Аргентинлы,—мин Барвихада Шаманның өй туенда теге сатлык генералның ни өчен бу хакта сөйләп утырганын, ниһаять, аңладым шикелле. Ул бит йорт хужасын куркыту яки аны кисәтү өчен сөйләгән моны, бик артык кәперәймәсен, түмән нефтеннән килгән табышларын гадел бүлешсен өчен сөйләгән. Соң, әлбәттә, шулай, ничек бу минем башыма шундук килмәгән. Вәт мент, ул һәммәсен дә дөрес исәпләгән! Шаман, калтыранъ ыбрак яшә—Македонский ирекккә, кирәк булса, без аны синең жаныңны кыярга да жибәрә алабыз, без тиктомалдан гына берәүне дә ирекккә чыгармыйбыз, дип искәрткән ул аны.

—Ә син үз фараз кылуларында бик артык мавыгып китмисеңме?—дип сак кына кызыксынды Тоглар.

—Бәлки, шулайдыр да, ә бәлки, юктыр, ләкин болай фикер йөртүләремнең нигезе булырга тиеш, әгәр дә кинәт кенә тиздән Шаманны теге дөньяга озатсалар, мин үземнең усал сизенүләремә раслау алам дигән сүз. Хәлбуки, алга таба тыңла әле...

Солоникны лазареттан ялгыз камерага күчергән көнне үк «Матросская тишина» төрмәсендә күптән түгел генә армиядән кайткан яшь бер егет, кече сержант Сергей Меньшиков пәйда була, яна надзор инспекторы, имеш. Нәкъ менә ул да Македонский белән бер үк көндә эзсез югала. Безнең матбугат беравыздан мескен сержантны Македонскийга качу оештырган бердәнбер төп гаепле кеше дип язып чыгарга ашыкты. Әйе, кечәге солдат кисәге, бәлки, ул качуга ничектер ярдәм дә иткәндер, әмма ул Солоникның иректәге яклаучылары белән атаклы тоткын арасында арадашчы гына булгандыр. Мин хәтта аның бурычы бер генә—Македонскийны егылып имгәнүдән саклап калу гына булгандыр дип уйлыйм. Алар бит текә диварга алдан кемнәрдер кагып куйган тимер ыргакларга баса-баса төшкәннәр, әле житмәсә караңгыда, аннары бер түбә аша үтеп, янә биш катлы бина диварыннан аска шылганнар. Бөеренә операция ясаганнан соң, хәлсезләнеп калган киллер, әлбәттә, ярдәмгә мохтаж булган—аны коткаручылар аны хәвеф-хәтәрдән саклаганнар.

—Хәзер ул киллер кайдадыр дип уйлыйсың инде? Син сөйләмәсәң, ышанмас та идем, берәр язучының әкияте генәдер, дияр идем, алар хыялга бай бит,—Тоглар Аргентинлының рус гангстеры турында шулай озак итеп баш әйләндерерлек тарих сөйләвенең сәбәбен аңламады шикелле.

—Кайда да булса Фиджи яки Таити утрауларының берсендә хәл жыеп ятадыр. Анда һәрвакыт кояш, иркә диңгез дулкыннары, яраларын юып-ялап, көч жыярга, һушына килергә дә кирәк бит әле. Ләкин ныгып, аягына баскач, Парижда мы яки Берлиндамы берәр жирдә пластик операция ясатыр, үз кешеләреннән яңа документлар алыр да янә Россиягә кайтып төшәр. Заказчылары кимемәгәндер, бер атып үтерүнең бәясе бик нык арткандыр—куркыныч шөгыль-һөнәр бит. Ул барыбер туган иленә, Россиягә кайтачак, мин андый кешеләрне беләм: тәвәккәл-куркыныч тормыштан башка яши алмый алар, тыныч тормыш алар өчен зарарлы гына. Бу тарихны ни өчен сөйләгәнемне аңлагансыңдыр дип ышанам, братан?

Тоглар баш какты—һәммәсе дә аңлашыла, янәсе.

Сәгатенә карап алгач, Аргентинлы гажәпләнеп сызгырып куйды:

—Бәй, күңелле итеп, жылы-унайлы жирдә тәмләп сөйләшеп утырганда вакыт бигрәк тиз үтә. Ярар соң, кофе эчеп алыйк та йөгерик. Ярты сәгатьтән минем партнерларым килергә тиеш—алар бикле ишек төбендә көтеп торырга яратмый,—ул, зал ягына борылып, озын буйлы егетне күзләре белән эзләп тапты да әсәренеп кычкырды:—Официант!

## 3

Городецкийдан аерылып киткәч, Тоглар үз номерына күтәрелеп тормады—шәһәр, көннең матурлыгы, әле юньләп иняләшеп житмәгән ирек аны урамга, кешеләр арасына тарта иде. Кайда телисең, шунда барасың, кайда телисең, шунда керәсең, күңелең ничек тели, шулай утырасың—ничек рәхәт бит болар! Әйе, ирегең югалткан, яки аның нинәрсә икәнен бөтенләй белмәгән, яисә яңа гына иреккә чыккан кеше генә аның чын-чынлап кадерен белә. Ирекнең беренче сәгатьләре, көннәре шундый да татлы!

Август азаклары, сентябрь башы Ростовта, мөгаен елның иң матур вакытыдыр—күпсанлы бакча-скверлардагы агачлар әле көз тарафыннан куырылмаганнар, алар купшы-көяз булып, матурланып утыра, үзәк урамнар буйлап гасыр башында ук утыртылган йөзъяшәр имәннәр һәм карамалар да бик мәһабәт.

Яна кибетләр, кибетчекләр, сәүдә нокталары, аларның ачык төстәге чакырулы рекламалары, зәвык белән, ә кайбер җирләрдә артык кычкырып тора торган итеп эшләнгән игъланнар, урамда аллы-гөлле чатырлар астындагы кечкенә кафеларның җинел өстәлләре, күп кенә тарихи биналарның париждагыча бай итеп яңартылган алгы яклары искиткеч— аларга кызыл агачны да, шомартылган мәрмәрне дә бронзаны да кызганмаганнар, болар барысы да күнелне куандыра, күзгә рәхәтлек бирә. Шәһәрдәге бу сокланггыч үзгәрешләрне Тоглар да күрде. Бүген ул Ростовка аеруча үз итеп, яратып карый иде. Бәлки, нәкъ менә шушында хәзер генә иркенләп ирек һавасы сулаганлыктандыр, ә бәлки, менә Наталья сәбәпчедер—гашыйклар бит тормышка ягымлырак һәм матуррак итеп карый, тирә-яктагы гүзәллекне күбрәк күрә—кеше заты гомер-гомердән шулай яратылган инде ул. Ләкин ирекле булуы аны никадәр генә исертмәсен, күзгә керергә җыенучы шәһәр ничек кенә соклandырмасын, Наталья белән алда торган очрашуы йөрәген никадәр генә дулкынландырмасын, Константин Николаевич ирексездән Городецкий белән номерында һәм ресторанда сөйләшүләренә әйләнеп кайта иде. Ул Аргентинлы белән көтелмәгән очрашуы өчен язмышына рәхмәтле иде, башкаладагы җинаятьчел тормышны шулай тулы итеп теләсә кем алдында ачып салмыйлар, аннары аны һәркем дә белеп тә бетерә алмый. Хәер, ни ул үзе, ни Городецкий, җинаятьчел дөньяда саллы гына урын тотсалар да, талау-үтерүләргә, караклык-рэкетларга аларның һичбер катнашы юк. Юкка гына Тогларны чистакул дип йөртмиләр! Аның шөгыле—кәгазьләр, ксива-паспортлар. Ә Городецкийныкы—кәрт уены.

Һәм кирәк бит, илле яшенә җитеп, братва арасында әвәрә килүенең егерме биш еллыгын үткәреп, Городецкий бик дөрес билгеләп үткәнчә, менә кадәрле әле кайдан да булса банктан яки берәр оешмадан үзеннән-үзе акча суыра торган бер генә кәгазь-мәгазь, ялган документ та ясаганы беркайчан да булмады. Ул моны ант итеп әйтә ала. Гомумән, элек тормыш бөтенләй башкача иде бит, теләсә кайсы оешманың банктагы исәбендә булган миллионлаган «безналичка» акчалары бер тиенгә дә тормый иде. Аларга ваклап та, товар базаларыннан да бернәрсә дә алып булмый иде. Шуна күрә дә, «ак якалылар», кәгазь җинаятьчелеге, ялган авизолар да булмады. Элекке ул тормышта күмер, нефть, металл, алтын, бриллиантлар урлауның кирәге дә юк—беркем дә илнең табигый байлыклары хисабына шәхсән үзе байый алмый иде. Ә инде Швейцария банкында шәхси счет ачу берәр акылсызның төшенә генә керсә кергәндер—иртәгә үк ул аферист, хәтта министр булса да, Лубянка подвалларында утырыр иде. Һәрнәрсә ышанычлы саклана, шунлыктан ялган лицензияләр, таможня декларацияләре, чит илдән нәрсә булса да керту яки чит илгә чыгару өчен рөхсәт алуларның мәгънәсе юк, хәтта андый очраклар бер вакытта да булмады.

Тоглар төсле ксерокс һәм компьютер графикасының өстенлекләрен башкалардан күп элек белде, ул аларны Чечнядәге үз «акча сараенда» бик киң файдаланды, аның кул астында һәрвакыт иң камил техника булды. Аның ярдәмчеләре булып эшләгән компьютерчылар үз эшләренең осталары иде. Ләкин һәрвакыт шундый мизгел килеп җитә, үзеннән-үзе кеше катнашуы кирәк була, бигрәк тә шәхси имзаларны ясаганда кирәк була ул. Алыйк шул ук долларны... Акчада шундый нечкәлекләр, микрошрифтлар шундый оста хәйлә белән үрелеп эшләнсә дә, аны да ялган долларларда компьютер графикасы белән ясарга мөмкин, ә менә штат казначееның имзасын бернинди техника белән дә алдый алмыйсың, житмәсә, алар бит әле һәр серия акчада үзенә аерым: аны ясап-күчереп була булуын, ләкин ул үле туган бала кебек җансыз килеп чыга, монда инде Тоглар шикелле оста ясаган чиста клише генә кирәк була.

Мөһер сугылган имзаны да бер кәгазьдән икенче кәгазьгә төптөгәл күчерергә мөмкин, әмма тикшереп караганда, компьютер һәм ксерокслар белән мәтәштерелгәнлекләрен җинел аерырга була. Бер генә

компьютер да беркайчан да кеше акылы, аның таланты, чиксез мөмкинлекләре белән ярыша алмый. Тоглар хәтерли әле, Аргентинлы кебек эре катала Алик Тайванлы,—хәзер ул Германиядә яши һәм бөтен Европаны диярлек үз кулында тота,—менә шул бервакыт электроник техникага үлеп гашыйк булган бер акыллыбашка әйткән иде: нинди генә компьютер уйлап тапсалар да, ул бервакытта да, кеше шикелле, бер нәрсәне сөйләп, икенчене күз алдында тота алмаячак.

Тоглар «Метрополь»нең бишенче катыннан тулы бер канатын алып яшәүче Дантесны да яхшы аңлый: зур афералар өчен чын имза һәм чын мөһер булу кирәк.

Ләкин Константин Николаевич хәзер галәмәт зур эшләргә алынырга җыенмый да, моның һич хаҗәте юк, Чечнядан алып кайткан миллион долларлары озакка җитәчәк әле. Аннары декабрь аенда тулачак илле яше дә әллә ничек сиздерми генә килеп җитте—аз гомер түгел бит, кырык яшьлек күренәм әле, көчем-җегәрем дә җитәрлек дип кукрайсаң да—ерак китә алмассың. Үз йортың, гаиләң турында уйларга вакыт, гомер буе ялгызак буйдак булып яшәмәссең. Тыныч кына, тук буржуа тормышы белән яшәсән дә ярыйдыр—илдәге вәзгыять моңа мөмкинлек бирә, акчаң гына булсын. Башкаланың үзәгендә урнашып, концерт, күргәзмәләргә йөр, үзен бөтен дөнья буйлап эзләсәләр дә, һич тоттырмас Македонский шикелле, илләр гиз, Лос-Анджелеска барып, бабаң рәсемнәрен күреп кайт—Тогларны суйган да каплаган бабасы, дип тә әйтәләр бит әле, Америкада калган туганнары белән элемтәгә керү дә начар булмас иде. Моның өчен академик рәссам Фешин эшләренең каталогын яңадан бастырып чыгарырга да була. Тогларның белүенчә, Татарстан сынлы сәнгать музеенда бабасының картина-рәсемнәре булса да, академик Фешинның эшләре Идел буе шәһәрләренең барлык музейларында да саклана, диләр: Самара, Саратов, Уфа, Сыктывкар, Ижау, Саранск, Воткинск музейларында.

Әгәр дә үзенең уй-хыяллары тормышка ашса, ул тук-имин тормышта яши башласа, Тоглар дигән адәм гомерлеккә үләргә тиеш, бу очракта «күпбеләм» Аргентинлы хаклы. Ләкин Константин Николаевичның Модельяни кушаматын да кайтарасы килми, әмма барыбер братвадан тиз генә котыла алмассың, бигрәк тә хәзерге заманда, бөтен ил җинаятьчел законнар буенча гына яши кебек тоелганда. Аннары ул үзе дә караклар яклавыннан мәхрүм калса, бик хәтәр хәлләргә тарырга мөмкин—Россиядә байлык, ни кызганыч, һәрвакыт бәла китереп чыгара. Ә чеченнәр белән булган тарихның дәвамы да килеп чыкса, бу очракта да иске танышларсыз котыла алмассың. Нәкъ мәкальдәгечә: оҗмахка керәсе иде дә, гөнаһлар кертми. Ләкин бер ягы әйбәт, Мәскәүнең дә, Россиянең дә җинаятьчел дөньясы элекке кебек түгел хәзер, ул чигән юрганы кебек чуп-чуар, димәк, югалып торуын да җинелрәк булачак.

Тогларга тагын шунысы да юаныч: ирекә ана хәзер эш шактый кимегән, димәк, кызыксынучылар да азрак, дигән сүз. Заман хәзер аның сирәк һөнәрен тормыштан рәхим-шәфкатьсез кысрыклап чыгарган, шул ук ксерокс һәм компьютерлар аферистлар өчен оҗмахның оҗмахы инде. Теләсә нинди акцияләр һәм вексельләр, облигацияләр һәм больничный бюллетеньнәр,—кыскасы, паспорттан алып шофер таныклыгына кадәр документларны әтмәлләп бирү—өч көнлек эштер.

Үзе турында, тормыш турында, киләчәккә планнары турында уйланып бара-бара, Тоглар яңадан Ростовның үзәк урамына килеп чыкканын сизми дә калган. «Йә Хода, яшәү нинди рәхәт, ирек нинди гүзәл, яраткан ярыңны көтү нинди татлы!»—дип үзалдына елмаеп уйланды ул. Натальяны исенә төшергәч, үзенең затлы «Юлисс Нордан» сәгатенә күз салып алды—кыз белән очрашуга нәкъ бер сәгать калган икән. Натальяның «Астория» кибете якын гына, почмакны гына борыласы, ләкин кыз аның кибеткә кермәвен үтенде. Бүген Париждан аларның патроны, яшь француз Робер Платт килә икән, ул «Астория»не уртак тотучы Кристиан Лакруа сәүдә

йортының мәнфәгатьләрен кайгырта, шуңа күрә дә Ростовта француз модасы киң таралган икән. Тогларны күргәч, иптәш кызлары сораулар биреп интектерерләр, шуның өчен Наташаның бер дә каушыйсы-кызарасы килми иде.

—На-та-а-лья,—дип җыр шикеллерәк сузып, кызның исемен әйтүдән Тоглар үзен тыеп кала алмады, йөрәге кинәттән генә иркә ягымлылык белән тулды, аның мондый хисне әле беркайчан да кичергәне юк иде, дулкынланудан башы әйләнеп китте, сулуы капты. Ул адымнарын әкренәйтте, скверик уртасындагы беренче очраган утыргычка барып утырмый булдыра алмады. Ләкин озак утырмады—кинәт күңелендә тыелгысыз теләк туды: Натальяга нинди дә булса бик бай бүләк алып бирәсе килде, теге көнге шикелле, аның гүзәл йөзендә соклану, куану һәм бер үк вакытта гаҗәпләнү дә чагылганын күрү үзенә дә зур шатлык булыр иде. Шул уе белән ул урыныннан сикереп торды. Кичә, чәчәк кибете эзләп йөргәндә, викториан стилендәге бер борынгы бинаның алгы ягы матур итеп яңартылганын, аскы катында ювелир кибете «Камея» урнашканын күреп узган, узышлый гына зиннәтле бүләкләр куелган тәрәзә витринасына да күз салырга өлгергән иде. Ул тиз-тиз атлап шунда юнәлде.

Ювелир кибете буш иде. Бары тик ике кыз гына, әкрен генә сөйләшә-сөйләшә, витринадагы балдакларны карап тора, күрәсең, аларның берсе туйга әзерләнә иде булса кирәк.

Мөгаен, яңа кибетләрдә кемнән кемлеген алдан ук тоялардыр, Тоглар залга килеп керүгә үк, тирә-юньдәге гүзәллекне үзләре дә тулыландырып торучы ике сатучы кыз, сөйләшкәннәреннән туктады. Кыйммәтле-зиннәтле бизәнү әйберләре куелган витрина янына берсе килеп басты да:

—Нәрсә алырга теләр идегез?—дип, ягымлы елмаеп сорады.

Тоглар, үзенең ярты сәгатьләп кенә вакыты калганын чамалап, эшне тиз тотты:

—Миңа бүләк алырга кирәк иде, нинди дә булса гарнитур: алкалар, йөзек...—диде.

—Бриллиантлыларнымы?

—Әлбәттә, бриллиантлыларны һәм яшькелт зәбәрҗәт кашлылары булу шарт.

—Гафу итегез, сер булмаса, әйтегез әле: кемгә бүләк итәргә уйлыйсыз? Мин яше ничәдә икәнен сорыйм.

—Ул чама белән сезнең белән бер яшьтәрәк булыр,—дип, Константин Николаевич ни өчендер уңайсызланып куйды.

—Алай булса, бездә сайлар әйберләр җитәрлек: Италия, Америка, Израиль бриллиантлары бар, «Картье» эшләнмәләре, Көньяк Африканың «Де Бирс» бриллиантлары белән...

—Юк, алар миңа бармас. Сездә саф русныкы булган нәрсә дә булса бармы?—дип, үзе дә көтмәгәндә киреләнә башлады Константин Николаевич. Ул үзенең долларларының, ялган булсалар да, Көнбатышка чыгып китүләрен теләми, анарда рус каны, ватандарлык хисе уянды.

—Бездә һәммәсе дә бар, Россия бриллиантлары да,—дип, бераз күңеле сүрелә төшеп әйтте сатучы кыз. Күрәсең, чит ил әйберләрен сатудан аңа күбрәк процент тама торгандыр, әмма Фешинның анысына һич исе китмәде.

Аның алдына бик зәвыклы итеп замштан эшләнгән кыйммәтле берничә футляр китереп куйдылар, ул аптырабрак калды: аңа барысы да ошый иде. Шуннан ул бәяләрен сорады.

—Болары—өч мең ярым доллар, ә болары—дүрт мең ике йөз, ә менә монысы—биш мең биш йөз...—дип ваемсыз гына тезеп китте кыз, клиенттан уңмадым, дип уйлады булса кирәк.

—Менә шушы биш мең биш йөзлеген алам,—диде Фешин һәм шул чагында яшь сатучы кызларның артында торган көзгедән ике кавказлы егетне күреп алды.

Бер карауда ук Фешин аларның чеченнәр икәнен абайлады, тәҗрибәсез кешеләргә төньяк Кавказ тау халыклары: осетины, лезгины, дагстанлысы—барысы да бер төсле булып күренә. Әмма болар, һичшиксез, чеченнәр иде. Константин Николаевич хәтта уйлап та куйды: бу егетләрне ул бертуган Цуцаевлар сакчылары итеп берничә мәртәбә күргән дә шикелле иде.

«Нинди мокыт мин! Труссарди костюмы, Ван Хейзен күлмәкләре, зәбәрҗәт кашлы бриллиантлар... Бәхетсез пижон! Иң элек пистолет сатып алырга иде бит, пистолет! Яки шәһәргә чыгып йөргәндә Аргентинлыдан булса да алып торырга иде»,—дип гаҗиз өметсезлек белән уйланды Фешин, ләкин үзенне битәрләү соң иде шул инде...

Күрәсең, аның «алам» дигән чагында көзгедә чечен егетләрен күрүе нииндидер каушавын да сиздергәндер, һәр кыйммәтле кибетләрдә, бигрәк тә ювелир кибетләрендә була торган мона кадәр ерак почмакта, күләгәдәрәк калган камуфляж формалы сакчы, автоматын аркылы тотып, алгарак чыкты һәм витрина янындагы Фешин янына килеп басты да, йөзе белән кавказлы егетләргә таба борылды. Тегеләр дәшми-тынмый гына, үз дәрәҗәләрен саклап кына чыгып киттеләр.

—Аласызмы, әллә шаяртасыз гынамы?—диде сатучы кыз, Фешинның йөзендәге үзгәрешне сизенеп.

—Алам, кызым, алам! Ләкин бер шартым бар, әгәр сезнең арткы ишегегез булса, сез мине шуннан чыгарырсыз,—дип яктырып китте әлегә кадәр югалыбрак калган Фешин.

Кыз зиһенле булып чыкты:

—Аңладым сезне,—диде.—Ишегебез бар һәм сезне Сергей озата чыгар,—дип, янәшәсендә торган сакчыга ишарәләде.

Тоглар бер пачка долларлар чыгарды, тиешле сумманы санап биргәч, янәшәсенә тагын берничә йөзлек куйды да:

—Ә монысы Сергей белән икегезгә зирәклегегез өчен,—дип өстәде.

Кыз акчаларны сейфка яшерде, яшерен кнопкага басты, тимер турникет тавышсыз гына ачылып китте. Сакчы егет ачылган ишек авызына таба беренче булып атлады, Фешин аның артыннан. Коридорлар буйлап борыла-борыла, алар арткы ишеккә барып чыктылар.

—Менә килеп тә җиттек,—диде сакчы.—Мин чыгып карап керим әле.—Ул ишегалдына чыгып китте.

Константин Николаевич ачык ишек аша чүп-чар басып киткән кечкенә ишегалдын күрде—андыйлар еш кына иске йортларныкы була. Фешинга бер егерме метрлап араны йөгереп үтәргә, аннары көймәләп уелган биек таш түбәле капка аша үтеп, кеше күп йөри торган Ленин урамына барып чыгарга кирәк иде. Шунда аны ерак та түгел бер чатта Наталья көтеп торырга тиеш.

Сакчы егет тиз әйләнеп килде.

—Барысы да тыныч шикелле. Хәерең белән!—ул Тогларны җиңелчә генә җилкәсеннән этеп җибәрде. Гадәттә, десантта парашют белән сикергәндә шулай эшлиләр, егет Фешинны да элекке десантчы дип уйлады булса кирәк.

—Рәхмәт, братан,—Тоглар тыныч кына тимер ишекне ачып җибәрде.

*Дәвамы киләсе санда.*

# Şiğriət
# Шигърият



## Илдус Гыйләҗев

### ТУЙКӘ БУЙЛАРЫННАН КОЯШ КАЛКА

#### Аңларга вакыт

«Коры җирнең алтыдан бер өлеше»ндә
Яшәдек без—җитмеш еллап...
«Бездән дә бәхетле халык булмавы»на
Ышандык бит чын-чынлап.
Коры җирнең сигездән бер өлешендә
Яшәп калдык—оя тузгач.
—Без гайрәтле, кодрәт бездә,—диеп һаман
Мактанабыз—ил зур булгач.
Тормыш дигәннәре генә яхшырмый шул,
Күптер дә бит алтын, көмеш.
... Чалбар алыштырып кына кем мантыган,
Кесә төбе... тишек килеш...

#### Еллар шәүләсе

«Кемең бар соң синең читтә?—дисең,—
Назың калмады бер чеметем;
Күз карашың, хәтта, хәлсезләнде,
Йончыдың син, беттең, егетем».
«Дөрес сүзгә җавап булмый»,—диләр,
Дәшми генә күнәм, килешәм.
Төртеп егу, тартып торгызулар
Дәртле чакта гына килешә.
Хәле беткәннәргә мәрхәмәт юк,

---

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ *(1946) —шагыйрь, «Җир китабы», «Серле мәгарә», «Хак сүз» һ. б. китаплар авторы. Азнакай районында яши.*

Арылды шул, түгел җәлләсе.
...Илле яшьне кая куябыз соң??
Арабызда ята шәүләсе...

## Алга карап

Әле бар да алда кебек:
Тауларга менәселәр,
Яннарыңа киләселәр,
Шашынып сөяселәр.
Матур сүзләр сөйлисем бар,
Яраса-ярамаса.
...Картайган гел сизелми ул,
Артыңа карамасаң...

## Юмарт чишмәләр

Җырыгызны ятлап йөрим,
Туган ягым чишмәләре.
Челтер-челтер моңнар белән
Тулды күңел киштәләрем.
Күп чөмердем суыгызны,
Камаштырып тешләремне;
Сезнең аша алдым бугай
Булган барлык көчләремне.

Иң якыны кайсыгыздыр,
Беренчесе, соңгысымы?
Әйтә алмыйм соң минутта
Кайсы суны сорыйсымны...
Барыгыз да якын миңа!
Җырдан үрәм улакларны.
Сезгә охшап, хисләр ургый,
Күңелем бик юмартланды.

## Туйкә таулары

Туйкә тауларында кылган үлән,
Җил искәндә китә дулкынлап.
Шул таулардан илгә күз сирпесәң,
Җаның, тәнең куя сулкылдап.
Туйкә тауларында хәтер йоклый,
Чокырлары—тарих күзләре.
Чокыр-чакыр булып сибелгәннәр
Пугач яуларының эзләре.
Туйкә тауларында мунча ташы,
Катылыгын җыйган хаклыкның.
Көчле рухы яши бу якларда
Ирек, Хөрлек сөйгән халыкның.
Туйкә тауларыннан кояш калка,
Киләчәккә сибә нурларын.
Исәнлеген сорыйм бездән соң да
Шул тауларга карар улларның...

## Кемгә мин кирәк?

Рәис булып элек эшләгәндә,
Сөтләр кимеп, эшләр пешмәгәндә,
Бармак янап, кычкырды түрә:
—Безгә шагыйрь түгел, җитәкче кирәк!
...Төннәр ката язып утырганда,

Дәфтәр арты дәфтәр тутырганда,
Авыр сулап, кисәтте хатын:
—Миңа—шагыйрь түгел, көчле ир—алтын!
Икесе дә дөрес сөйләгәннәр,
Уем читтә... шуны сөймәгәннәр.
Хисләр күп тә, акыл бит кимрәк:
—Язмый түзеп булмый... кемгә мин кирәк?

## Шулар гына калды

Баскынчылар тиеп пычратмаган
Дүрт байлыгым бар сөеп карарлык:
Бала бишеге—эткәй ясаган,
Үзем салган, үзем яккан мунча,
Тау буендагы татар зираты,
Иркәм бәйләп биргән намазлык...

## Төзәтмә кертәм

Ата-анаң сине өйрәткәндер:
—Егетләргә якын барма!
Алар фәлән, алар фәсмәтәннәр,
Якларына күз дә салма.
Якын китермисең шул сәбәпле...
Хупласам да, бар аерма:
Алар сиңа әйтеп бетермәгән—
Якын җибәр, үзең барма...

## Асылы үзгәрми

«Яңа» урыс, «иске» урыс...
Аермасы юктыр аның.
Максат бер бит: алдап-йолдап,
Талап җыю кеше малын...

## Рәсәйдә

Үзеңнән мең кат тинтәк бәндәләр
Түрә була, яный, акыра.
Шулар бүген, әнә, баеп ята—
Туяр микән бу ил акылга?

## Салават күпере

Матур дуга булып каерылды
Аллы-гөлле төсләр сызыгы.
Җирдән күтәрелде, җиргә төште—
Кеше гомеренең сызымы...



## Нурихан Фәттах

# САРМАТ КЫЗЫ СӘРИНӘ

ТАРИХИ ДРАМА

**Катнашалар:**

Сәринә.
Байсар би—сарматларның Сарайгыр ыруы агасы.
Бигәнәй бикә—Байсар бинең хатыны.
Котас би—сарматларның Алас ыруы агасы.
Юлдаш баба—аксакал.
Танай.
Филеб.
Җәликә.
Мамиха.
Бикә—Котас би хатыны.
Карт.
Кортка.
Малай.
Ир сугышчылар, кыз сугышчылар, ирләр, хатын-кызлар.

Вакыйганың урыны—Кара дингез буе далалары, вакыты—безнең эрага кадәр III гасыр, ягъни моннан 2200 еллар элек.

Сарматлар—борынгы күчмә кабиләләр. Баспурлар—Керчь ярым атавында һәм Кара дингезнен көнчыгыш яры буенда урнашкан борынгы Боспор патшалыгы греклары.

Ага—ыру башы (ир кеше), амага—ыру башы (хатын-кыз).

---

Нурихан ФӘТТАХ *(1928)—Татарстанның халык язучысы, прозаик, драматург. «Сезнеңчә ничек?», «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» һ.б. романнар, «Шәҗәрә», «Фест дисбесе» кебек фәнни-тарихи хезмәтләр авторы. Казанда яши.*

## Беренче бүлек

### Беренче күренеш

**Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Таң ата, кояш чыгып килә. Якындагы өйдән Кортка чыга.**

Кортка *(кире борылып, ишек ягына кычкыра).* Синайтәм, тордыңмы?

**Өйдән карт чыга.**

Карт. Ә? Нәрсә?

Кортка. Әнә, кояш чыгып килә. Нинди матур, Илаһым!

Карт *(кояш ягына карап).* Тагын бер көн яшисебез бар икән әле бу якты дөньяда.

Кортка *(тезләнә, адарынып, кулларын югары күтәрә).* Тәңрем-Аллам, изгеленнән ташлама без гөнаһлы бәндәләреңне!

Карт *(тезләнә, адарынып, кулларын югары күтәрә).* Бар ышаныч синдә, Раббым. Илгә иминлек бир, бигә—акыл, үземә көч-куәт бир!

Кортка. Җыясы ризыкларыбыз, эчәсе суларыбыз бетмәсен, Илаһым!

Икесе бергә *(дога кылып).* Амин! Шулай булсын!

**Аягүрә басалар, күтәрелеп килгән кояшка карап, сокланып торалар да, ашыкмыйча гына өйләренә кире кереп китәләр. Җиһанда балкып кояш чыга.**

### Икенче күренеш

**Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Уң якта—Сарайгыр ыруы агасы Байсар би өе. Киез өй итәгендә сурәтләр: чабып баручы боланнар, киек бугазлаучы ерткычлар.**

**Пәрдә ачылып бераз вакыт үткәч, еракта сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы ишетелә. Таяк атка атланып, «атын» чыбык белән кыйный-кыйный, сәхнә аша Малай йөгереп үтә.**

Малай. Кайталар! Киләләр! Сөенче!

**Өй ишеге ачыла, ялт-йолт каранып, Җәликә чыга.**

Җәликә. Кем булды ул?

**Бигәнәй бикә чыга.**

Бигәнәй. Кем бар анда?

Җәликә. Әле генә кемдер кычкырды, бикә.

Бигәнәй. Йөрсен әле ул кызларны борчып. Мин әле аны менә!..

**«Атын» кыйный-кыйный Малай керә.**

Малай. Кайталар! Сөенче!

Бигәнәй *(еракка карый).* Берни күрмим. Йөрисез шунда кычытынып.

Җәликә *(Малайга күрсәтеп).* Менә бу ут күз ич!

Малай. Ут күз түгел, ут колак!

**Тынлык. Еракта сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы ишетелә.**

Җәликә. Әнә!

Малай. Ишеттегезме инде?

Бигәнәй. Ишеттек, балам. Биебез кайта!

Җәликә. Нишләп ул яктан кайтыр икән соң ул, бикә?

Бигәнәй. Кайсы яктан кайтса да барыбер түгелмени синең өчен?

Малай. Сөенче! Би кайта! Сөенче! *(Чыга.)*

**Мамиха керә.**

Мамиха. Бикә! Котас би килә. Әле генә кешесен очраттым.

Бигәнәй. Нинди Котас би?

Мамиха. Алас ыруыннан Котас би килә, бикә.

Бигәнәй. Ник килә, ничек килә?

Мамиха. Кешесе әйтте: кода булып килә диде.

Бигәнәй. Котымны алдың! Ник аны башта ук шулай димисең?

Мамиха. Кешесе әйтте... монда килсеннәрме, шунда туктап калсыннармы?

Бигәнәй. Менә сиңа кирәк булса! Беркем дә өйдә юк чагында...

Мамиха. Урдага аяк басарга рөхсәт юк дип әйтеп әйттеләр дип әйтиммени, бикә?

Җәликә. Бар, бар, шулай дип әйтеп әйтте диген. Йөрмәсен анда юлбасар башына кода булган булып!

Бигәнәй *(Җәликәгә)*. Кирәкмәгән жирдә кысылсаң, менә моннан мин сине! *(Мамихага.)* Изге ният белән... кода булып килгән кешене кире борып жибәрү йоласы юк. Әйт: туктаган жирләрендә өй корсыннар.

Мамиха. Шулай дип әйтермен, бикә. *(Чыга.)*

**Икенче яктан икенче төрлерәк кычкырткан быргы тавышы ишетелә.**

Җәликә. Менә монысы—алар!

Бигәнәй. Алар, балам, алар!

**Малай керә.**

Малай. Кайталар! Кайталар! Сөенче!

Бигәнәй *(Малайга)*. Бар, улым, йөгер каршыларына!

Малай. Сөенче! Байсар би кайта! *(Чыга.)*

**Быргы тавышы якыная. Әкренләп халык җыела. Юлдаш баба керә.**

Юлдаш. Биебез кайта дип ишеттек—дөресме, кем, килен?

Бигәнәй. Дөрес булырга охшый, Юлдаш баба.

**Танай керә. Ул сугышчы киемендә.**

Танай. Исәнме, инәй!

Бигәнәй. Улым, Танай! *(Кочаклашалар.)*

Танай. Исәнме, Юлдаш баба!

Юлдаш. Исәнме, кем, улым Танай.

Бигәнәй. Барыгыз да исәнсаумы? Атаң?

Танай. *(томлыгып)*. Ы-ы-ы... Әтәй дә исән.

Бигәнәй. Атаңа ни булды?

Танай. Әтәй яралы.

Бигәнәй. Һай Аллам!

Танай. Куркыныч түгел... әз генә, нәни генә...

Бигәнәй. Котымны алдың!

**Байсар би керә. Үзенең яралы икәнлеген күрсәтмәскә тырышып әкрен генә атлый. Аның янында кораллы ирләр.**

Байсар. Менә, мин кайттым, бикә.

Бигәнәй. Бием! Атасы! *(Байсар алдында бил бөгә).*

Байсар. Үзегез ни хәлләрдә ятасыз? Иминлекме?

Бигәнәй. Иминлек, атасы. Син киткәннән бирле ут йоттым—ашаганым аш булмады, йокым йокы булмады.

**Күңелле ыгы-зыгы. Өйдән кызлар тире савытлар белән кымыз алып чыгалар. Кымызны алтын кәсәгә салып, иң элек Байсар бигә бирәләр. Бераз эчкәч, Байсар би бикәгә бирә, бикә—Танайга, Танай—Юлдаш бабага бирә. Кымызлы кәсә түгәрәк буенча кулданкулга китә. Җыр, бию, музыка.**

Байсар *(халыкка)*. Исәнме, илкөн! *(Юлдаш бабага.)* Исәнме, Юлдаш баба!

Халык. Амин!

Бик исәнбез, би!

Юлдаш. Үзең ничек йөреп кайттың, би? Юлың уңдымы?

Байсар *(сул кулы белән эчен тоткалый, авыртынып чыраен сыта. Танайга)*. Улым, Танай, әйт әле—кертсеннәр теге сандыкларны.

Танай. Хәзер, әтәй! *(Чыга.)*

Бигәнәй *(Байсарның авыртынуын күреп)*. Әллә өйгә керәбезме, атасы?

**Бер-ике ир белән Танай авыр сандык күтәреп керә.**

Байсар *(халыкка)*. Туганнар, илкөн! Хәзер бүләкләр өләшербез.

Халык. Биебез баеп кайткан.

Биебез чит ил бүләкләре алып кайткан.

**Байсар би авыртынып сандык өстенә утыра. Халык аптырабрак кала. Танай өйдән аркалы урындык—тәхет алып чыга.**

Танай. Әтәй! Каяле, утыр әле менә монда.

Бигәнәй. Бигрәк төсең киткән. Өзлекмәсән ярар иде, атасы.

Байсар *(җайлабрак утыра, сандыкны ачып җибәрә. Әле бер әйберне, әле икенче әйберне алып карый. Эре таш төймәләр тезеп ясалган затлы муенса чыгара. Бигәнәйгә)*. Беренче бүләгем сиңа, бикә.

Бигәнәй *(муенсаны ала)*. Бай бул, бием. Бигрәкләр матур икән!

Байсар. Ерактан, диңгез аръягыннан кайтарылган. Мондый муенсаларны Мисыр патшаларының хатыннары гына тагып йөри. *(Авыртынып эченә тотына).* Танай! Улым Танай!

Танай. Әтәй, ни булды?

Бигәнәй. Бүләкләр өләшүенне хәзергә калдырып торасыңмы әллә?

Байсар. Бетте, бетте. Юлдаш баба, кил әле бирерәк.

Юлдаш. Мине дә исеңдә тоттыңмени, кем, Байсар, улым?

Байсар. Беркайчан исемнән чыкмадың, Юлдаш баба. *(Сандыктан чапан ала).* Менә сиңа—чапан. Баспур осталары теккән.

Юлдаш *(бүләкне ала, караштыра).* Бай бул, кем, улым Байсар. Үземә атап теккән кебек.

Байсар *(сандыктан асылташлар куеп тегелгән затлы мех бүрек ала).* Монысы—Сәринәгә! Кияүгә чыгасы кызыма дип, бөтен калаларының астын өскә китертеп эзләттем. *(Як-ягына карана).* Кызым, Сәринә! Каяле, кил әле монда.

**Тынлык.**

Бигәнәй. Өйдә юк әле ул, атасы.

Байсар. Әйтәм, күренми. Кайда соң ул?

Танай. Ул, әтәй, әйтми-нитми яуга китеп барган.

Байсар. Нинди яу ул тагын?

Бигәнәй *(Танайга).* Кем әйтте, каян ишеттең әле син аны?

Танай. Ишеттем инде. Үзебезнең урдага кайтып житкәнче барысын да сөйләп бирделәр очраган кешеләр.

Байсар. Нишләп миңа берни дә әйтмәдең, улым?

Танай. Сине борчыйсым килмәде, әтәй.

Байсар *(Бигәнәйгә!).* Шулай да ни булды?

Бигәнәй. Кичәгенәк төнлә ниндидер угрылар барымтага килгәннәр.

Танай. Кичә төнлә түгел, инәй— өченче көн таң алдыннан!

Бигәнәй. Кай арада барысын да белеп өлгердең әле син, Танай улым?

Танай. Башбаштак Сәринәне далада белмәгән кеше юк.

Байсар *(сандыкны ябып куя).* Арыдым. Эчем!.. *(Эчен тота).* Бүләкләрне... үзең.... таратырсың...

Танай. Әтәй, әйдәле, ятып тор.

Бигәнәй. Бием, атасы, ниләр булды—ник әйтмисең?

Байсар. Очлы тау янында... төнлә юлбасарлар чыкты. Сугыштык.

Бигәнәй *(Танайга, ирләргә).* Безне өйгә алып керегез. Карагыз аны—иплэп!

Байсар. Кертмәсеннәр. Монда рәхәт. Туган даламны... көтүләремне карап утырыйм әле... шушында гына...

Бигәнәй *(халыкка).* Хәзергә таралып торыгыз, туганнар.

**Халык тарала.**

Байсар *(Танайга).* Бар, улым, син дә ял ит. Ирләр дә ял итсеннәр.

Танай. Ярар, әтәй. *(Чыга.)*

Бигәнәй. Нәрсә булган бу Танайга? Синең алда тыз да быз килә, кирле-мырлы сөйләнә.

Байсар. Сәринәдән көнләшәдер.

Бигәнәй. Башлы-күзле итәргә кирәк аны да. Өйләндерсәк, көнләшмәс.

Байсар. Карарбыз әле.

**Танай керә.**

Танай. Анда кодалар килгән икән—әйттеләрме әле, инәй?

Байсар. Нинди кодалар ул тагын?

Танай. Котас би, әтәй.

Бигәнәй *(Танайга, ачуланып).* Һай, улым! Ниенә кирәк булды әле ул кодалар сиңа? Күрәсең ич, атаның хәле болай да начар.

Байсар. Котас би... Котас би... Ничек оялмаган ул?!

Танай. Уртанчы улы Баракка безнең Сәринәне сорап килгән ди.

Байсар *(ярсып).* Ничек аяк баскан ул минем жиремә?! Кем керткән аны минем урдама?!

Танай. Мин дә шулай димен шул, әтәй.

Бигәнәй. Кызмале, атасы. Илчегә үлем юк. Котас би илче булып, кода булып килгән. *(Танайга, ачуланып).* Нәрсә катып торасың—атаңны өйгә кертергә кирәк!

**Танай кабаланып Байсарга килеп тотына.**

Байсар *(усалланып аягына баса).* Юк! Мин әле, мин... Котас би алдында күтәрәмгә каламмы соң?!

Танай. Әтәй, тынычлан. Әйдәле, әйдә. *(Байсарны бер яктан култыклап ала.)*

Бигәнәй *(Байсарны икенче яктан култыклап).* Күрше хакы—Алла хакы. Күршеләр белән татулыкка ни житә!

Байсар *(Танай белән Бигәнәйдән*

*ычкынып китә, ачуланып йөренә).* Өченче ел бер көтү куйларымны куалап киттеләр, дүрт кешемне үтерделәр. Былтыр илле баш җылкымны алып качтылар. Барысы да Котас би эше!

Бигәнәй. Тотмагач, алай дип тә булмый инде, атасы.

Байсар. Тоткан булсаммы... тоткан булсаммы мин аны! Юлбасар ул яктыдан курка—гел төнлә йөри. Аткан уклары менә монда тиде *(күрсәтә).* Угы агулы булды, ахрысы, бикә.

Бигәнәй *(куркып).* Агулы дисенме?

Байсар *(эчен тота, утыра).* Үзе болай сыдыртып кына китте. Шулай да менә авырта.

Бигәнәй *(каушап-кабаланып).* Нигәләр генә искә төшерден шул ко... ко... кодаларны, улым Танай? Җәликә! Мамиха! Кая олагып беттегез барыгыз да?

**Өйдән Җәликә белән Мамиха чыга.**

Җәликә. Син чакырдыңмы, бикә?

Мамиха. Без монда, бикә.

Бигәнәй. Барыгыз әле тиз генә яна сауган җирән бия сөте алып килегез.

Танай *(ашыгып).* Үзем, инәй! *(Чыга).*

Җәликә, Мамиха. Хәзер, бикә, хәзер. *(Чыгалар).*

Бигәнәй. Яңа сауган җирән бия сөте эчеп җибәрсәң, агуы да чыгар, ярасы да төзәлер, боерса.

Байсар. Укнын агуы чыгар, тик менә йөрәккә кара кан булып укмашкан ачу чыгып бетәр микән?

Бигәнәй *(Байсарны култыклап урыныннан алып китмәкче була).* Анысы да чыгар. Әйдәле, мамык түшәкләргә ятып бер тынычланып йоклап ал. Торуына таш кыздырып мунча әзерләргә кушармын, имчеләр чакыртырбыз.

Байсар *(битараф).* Урданда Котас би булганда мамык түшәкләрдә йоклап яту килешмәс, бикә. Борын төбендәге айгырыңны, куеныңдагы хатыныңны алып кача торган кешеләр алар... Котас биләр, Барак угланнар.

Бигәнәй. Барак углан?

Байсар. Әйе, әйе, Котас биләр, Барак угланнар!

**Ике кулына ике тире савыт тотып Танай керә. Аннан бераз калышып Җәликә белән Мамиха керә.**

Танай. Менә, әтәй, берсе яңа сауган җирән бия сөте, икенчесе яна сауган кара сыер сөте.

Бигәнәй. Яңа сауган кара сыер сөте әлегә кирәкми.

Җәликә. Без дә шулай дидек ана, бикә.

Мамиха. Кеше сүзенә колак та салмый ул, бикә.

Бигәнәй *(Байсарга касә белән сөт бирә).* Менә, эчеп җибәр әле, атасы.

Байсар *(эчә).* Тыннарым озаеп китте!

Бигәнәй. Хәлләнерсен, Алла боерса.

Байсар. Яралангач... ике көнгә Йөкәнәс җәйләвендә тоткарландык.

Танай. Анда да имче карчык яңа сауган җирән бия сөте эчерде, иеме, әтәй.

Байсар *(яратмыйча).* Улым, мин бит сиңа ял ит дигән идем.

Танай. Син авырганда мин ни җаным белән ял итеп ятыйм, әтәй?

Бигәнәй *(Танай белән асрауларны куалап).* Барыгыз әле, бар! Кирәк булгач үзем чакырырмын.

**Танай белән асраулар чыга.**

Байсар. Имче карчык тагын берике көн ятып торырга кушкан иде—йөрәгем түзмәде. Сине, Сәринәмне сагындым.

Бигәнәй. Ул да озаклады. Кодаларга җавап бирәсе дә бар.

Байсар *(кискен).* Кодаларга җавап бер генә: юлбасарга бирә торган кызым юк минем!

Бигәнәй. Тоткан җирдән өзү дөрес булыр микән?

Байсар. Мин әйткәч, булыр!

Бигәнәй. Алай димәле син, атасы. Кызың турында да уйла, Танаеңны да онытырга ярамый.

Байсар. Алар турында баш ватам да инде мин. Кинәт үлеп-нитеп китсәм...

Бигәнәй. Әйттем исә кайттым диген!

Байсар. Беребез дә мәңгегә килмәгән, бикә. Миннән соң Сарайгырда ыру башы булып кем калыр—менә нәрсә борчый мине.

Бигәнәй. Юк белән башыңны катырма әле. Син әле үзен!..

Байсар *(тавышын әкренәйтеп).* Мина агулы ук тигәнен белгәч тә... Бар әле карап кил—тыңлап тормыйлармы?

**Бигәнәй торып як-ягына караштыра, өйгә кереп чыга, янадан үз урынына килеп утыра.**

Бигәнәй. Ул-бу сизелми.

Байсар. Агулы ук тигәнен белгәч тә, безнең улыбыз Танай күз алдында үзгәрде, бикә. Мин хәтта курка башладым.

Бигәнәй. Алай ук түгелдер лә инде, атасы!

Байсар. Алай ук шул, Бигәнәй бикә.

Бигәнәй. Сине кызганыптыр ул.

Байсар. Кеше кызгана торган кеше түгел ул синең Танай улың.

Бигәнәй. Анысы шулай.

Байсар. Мин бер нәрсә уйладым әле, бикә.

Бигәнәй. Нәрсә икән ул?

Байсар. Су төбенә салынган теге серне чишеп... Сәринә белән Танайны кавыштырсак, ничек булыр икән димен.

Бигәнәй. Менә сиңа кирәк булса! Иске авыздан яңа сүз. Үзең әйтеп торасың... кансыз дисен, үзгәрде дисен.

Байсар. Сарайгырны таратмас өчен шулай эшләргә кирәк, бикә.

Бигәнәй. Гомер буена агалы-сеңелле булып йөрсеннәр дә, кинәт кенә ирле-хатынлы булып китсеннәр имеш! Ил-көн алдында ни диярбез дә, күршеләр күзенә ничек күренербез?

Байсар. Кысыр хәсрәт менә шул була инде, бикә.

Бигәнәй. Әйтмәм дигән идем... Болай булгач, әйтмичә булмас, ахрысы.

Байсар *(сагаеп)*. Тыңлыйм, бикә, сүзеңне.

Бигәнәй. Өченче көн, угрыларны куа китәр алдыннан, Сәринә әйтте: мин югында кодалар килсә, борып җибәрмәгез, мин кайтканчы көтеп торыгыз, диде.

Байсар. Кемнән кодалар килсә дигән иде соң ул?

Бигәнәй. Шул инде, шул... теге... ни, Ко... Котас бинең уртанчы улы Бaрактан дигән иде.

Байсар *(тора, йөренә, уртәлеп)*. Башсыз булып чыкты синең ул Сәринә дигән кызың, Бигәнәй бикә. Минем кан дошманым белән, юлбасар белән... Кара син аны!

Бигәнәй. Яратышалардыр, Байсар би. Яратуның түрәсе дә, йоласы да—бер.

Байсар *(тупас)*. Юк, бер түгел!

Бигәнәй. Син, бәлки, үзеңнең дә яшь чакларыңны исенә төшерерсен, Байсар би? Шуңак ыруының бердәнбер мактанычы булган Бигәнәйне өзелеп яраткан өчен... син дә шуңакларне юлбасарларча барып басмадыңмыни?!

Байсар *(караңгы чырай белән)*. Искегә тисәң исең китәр. Искене актарырга булдыңмыни, Бигәнәй бикә?

Бигәнәй. Шуңаклар белән сугышкан чакта син дә Котас биләрдән, Барак угланнардан ким кыланмаган идең.

Байсар *(эченә тотына)*. Тагын шулар!

Бигәнәй. Котас би улы Барак углан да Сәринәне өзелеп яратадыр димәкче генә булам мин сиңа, Байсар би.

Байсар *(утыра, йомшарып)*. Яратадыр, яратадыр. Кил әле янымарак. Сәринәдән бигрәк мин сине сагынып кайттым, Бигәнәем-Бергенәем.

Бигәнәй *(утыра)*. Сәринәне сагынсаң да бер сүзем юк.

Байсар. Шәп идең син яшь чагыңда, Бигәнәй!

Бигәнәй *(балавыз сыгып ала)*. Бар карап торганым шул Сәринә.

Байсар. Минем дә бар карап торганым—Сәринә. Шулай да ин якыны—син. Моңарчы мин сиңа карата тупас булдым бугай. Хәзер менә сине гел мактыйсым килә.

Бигәнәй. Ярар инде...

Байсар. Тегендә—диңгез, таулар. Өйләре гел таштан, балчыктан. Суларга тын җитми анда. Даладагы кебек җил юк, иркенлек юк.

Бигәнәй. Безнең дала оҗмах ул, оҗмах!

Байсар. Анда мин гел сине уйладым. Яратып, сагынып уйладым.

Бигәнәй. Үз илебезгә, үз җиребезгә ни җитә! Утырыйк әле бер иркенләп.

Байсар *(беравык тынып утырганнан соң)*. Угрылар кайсы яктан килделәр икән—белмәдеңме?

Бигәнәй. Төньяктан диделәр.

Байсар. Димәк, Очлы тау ягыннан!

Бигәнәй. Даланың киртәсе юк—кайсы яктан килсә дә ирек.

Байсар *(көрсенеп)*. Бозылды дөньялар. Үз илеңдә, үз җиреңдә тынычлап яшәве елдан-ел авырлаша бара.

Бигәнәй. Шуна күрә дә күршеләр белән тату булырга кирәк безгә.

Байсар. Юлбасарлар мине өченче көн кич караңгы төшәр алдыннан яраладылар. Сугыш ярты сәгать чамасы барды. Без аларны куып җибәрдек.

Бигәнәй. Качтылармы?

Байсар. Качтылар. Шуннан соң алар әнә минем җәйләвемә килеп чыкканнар, көтүемне куып киткәннәр.

Бигәнәй. Син инде андагы юлбасарларны да, мондагы угрыларны да бер үк кешеләр булган димәкче буласыңмы?

Байсар. Шулай димәкче булам. Шуларның берсе, беләсеңме, кем булган?

Бигәнәй *(сизенеп)*. Юк, булмас!

Байсар. Буласы булган инде, Бигәнәем-Бергенәем. Юлбасарларның берсе... атаманы... Котас бинең уртанчы улы Барак углан булган!

Бигәнәй. Ай-һай, ялгышмадыңмикән, Байсар би?

**Танай керә.**

Танай. Кодаларның сине күрәселәре килә, әтәй.

**Байсар белән Бигәнәй сүзсез генә бер-берсенә карашып алалар.**

Байсар. Син, Танай улым, Котас бинең йомышчысына әйләнмәгәнсеңдер ич?

Танай. Ул синнән бераз шурли бугай—минем аша эш йөртмәкче була.

Байсар. Кем аша эш йөртергә кирәклеген белә ул, ата юлбасар.

Танай. Нәрсә дип әйтим соң, әтәй?

Бигәнәй. Байсар бинең хәле юк, арыган, әлегә беркемне күрәсе килми дип әйттеләр диген.

Байсар. Менә монысы инде булмас! Котас би алдында сер сынатаммы соң?! Авызымда кара кан булса да... *(Кискен.)* Әйт, килсеннәр! *(Тора, йөренә, эченә тотына.)* Ах, эчем!

**Кодалар керә. Алар өч кеше. Берсе Котас би. Кодалардан соң Танай белән Юлдаш керә.**

Котас *(түргә уза, Байсар би алдында бил бөгә)*. Илең имин булсын, терлектуарың көр булсын, Байсар би.

Байсар. Амин, шулай булсын.

Котас. Үзенә, бикәнә, иленәкөненә озын гомер, байлык, тазалык бирсен Раббым.

Байсар. Әйткән сүзләрең изгегә юралсын, Котас би.

Бигәнәй. Теләгән теләкләрең үзенә яхшылык булып кайтсын, Котас би.

Байсар. Әйдәгез, утырышыгыз, кодалар.

**Кодаларга урын бирәләр. Алар Байсар би һәм башка сарайгырлар каршысына утыралар.**

Котас. Сарайгырлар белән без—аласлар, күрше генә булсак та үзара йөрешмибез, белешмибез. Моннан соң алай булмасын дип, ике арада дуслык, татулык сукмагы салынсын дип, мин сиңа зур йомыш белән килдем, Байсар би.

Байсар. Мин болай үзем күршеләр белән аралашып яшим. Кеше малына кул сузмыйм. Җирем-суым җитәрлек. Өстем бөтен, тамагым тук дигәндәй... Инде сиңа килгәндә, Котас би...

Котас *(бүлдереп)*. Диңгез буенда, баспурларда сәүдә эше белән йөреп кайткан диләр сине. Дөресме шул, Байсар би?

Байсар. Баспурга сатарга терлек куалап бардым. Эшем уңды, Котас би. Сатир патшада кунакта булдым. Бик күп бүләкләр биреп, далага чаклы озатып куйды.

Котас. Сатир патшаны мәкерле, икейөзле диләр.

Байсар. Сизмәдем. Минем белән эчкерсез булды. Моннан соң да йөрешергә, сату-алу итәргә сүз куештык. Аларның җирләре аз.

Котас. Беләм. Баспурларның күптән безнең калага күзләре кыза.

Байсар. Мал-туарлары бөтенләй диярлек юк. Иген игәләр дә, чүлмәк ясыйлар, балык тоталар.

Котас. Беләм. Көтү-көтү терлектуарың булмаса, ничек җан асрамак кирәк бу дөньяда?

Байсар. Калалары ике кат койма белән әйләндереп алынган.

Котас. Көче, гаскәре күпме Сатир патшаның?

Байсар. Менә анысын сорарга онытканмын, Котас би.

Котас. Сатир патшаны әледәнәле күршеләренә яу чаба диләр.

Байсар. Күршеләренә яу чаба торган юлбасарлар үзебезнең сармат даласында да җитәрлек, Котас би.

Котас. Әйе, далада тәртип бетте. Барысы да үзара талаша, сугыша.

Байсар. Андыйларга мине кыстыра күрмә, Котас би.

Котас. Аннары—йола! Йола харап итә безне, Байсар би. Безнең Алас ыруында шулай: яшь жегет барымтага барып, күршеләреннән бер көтү мал куып кайтмаса, аны иргә дә санамыйлар, аңа кыз да бирмиләр.

Байсар *(тынычсыз)*. Беләм мин сезнең юлбасарлар йоласын.

Бигәнәй. Андый гына йолалар бездә дә бар инде, атасы. Ирләр кебек кулына корал тотып яу чаба алмаган, кимендә бер дошман башы алып кайта алмаган кызга бездә кияүгә чыгу тыела. Шунлыктан менә Сарайгыр кызларының күбесе утырып кала.

Байсар. Безнеке—изге йола!

Котас. Алайса, Байсар би, сез дә күршеләр белән сугышмыйча тора алмыйсыз икән?

Бигәнәй. Әллә хәзергә яу-сугыш турындагы сүзләрне онытып торабызмы?

Байсар. Котас би безгә үзенең йомышын әйтмәде. Тыңлап карыйк аны.

Котас. Мин, Байсар би, Бигәнәй бикә, уртанчы улым Баракка сезнең кызыгыз Сәринәне сорап килдем. Йомышым минем шул.

Байсар. Кызым Сәринә үзе өйдә юк. Аның үзеннән башка мин бер сүз дә әйтә алмыйм, Котас би.

Бигәнәй. Сәринә үзе кайтсын инде. Килешербез, боерса.

Юлдаш. Кем, Байсар би, Бигәнәй бикә, ... Сәринәне кияүгә бирү-бирмәү ул сезнең эшегез генә түгел—бөтен ил-көн эше. Сәринәнең язмышы ул бөтен Сарайгыр язмышы. Шуңа күрә сез мине дә тыңлап карагыз әле, Байсар би, Бигәнәй бикә.

Байсар. Тыңлыйбыз, Юлдаш баба.

**Еракта сузып-сузып кычкырткан бырғы тавышы ишетелә. Барысы да тынып калалар.**

Бигәнәй. Әнә үзе дә кайта!

**Малай керә.**

Малай. Сөенче! Кайталар! Кайталар!

**Жилләнеп Сәринә керә. Аның янында бер-ике кыз сугышчы.**

**Сәринә этисе алдына килә, тезләнә. Исәнме, этием!**

Байсар. Кызым, Сәринәм! *(Кочаклый.)*

Бигәнәй. Кайтты. Сәринәм дә кайтты! *(Кочаклашалар.)*

Сәринә. Кайттым, әнием. Миңа ни булсын—мин жил кебек. Мине сөнге алмый, кылыч чапмый.

Бигәнәй. Тәүбә диген!

Котас *(үз алдына)*. Карап туйгысыз. Ут кебек, жылан кебек!

Танай. Сәринә! Сеңлем!

Сәринә. Абыем! Барыгыз да исән-саулар. Нинди куаныч!

Бигәнәй. Почмагыбыз түгәрәкләнде, кызым.

Сәринә. Арыдым. Үтереп йокы килә.

Байсар. Сөйлә, кызым—кайларда булдың, ниләр күрдең?

Сәринә. Без аларны куып бардык...

Байсар. Кемнәрне, кызым?

Сәринә. Угрыларны. Өченче көн таң алдыннан безнең көтүләрне куып киткәннәр. Коралды кызларымны жыйдым да, киттем артларыннан.

Бигәнәй. Куып життегезме?

Сәринә. Икенче көнне без аларны Очлы тау ягында очраттык.

Байсар. Очлы таудамыни?..

Сәринә. Очлы тауга житәрәк. Күрделәр дә безне, әрәмәләр арасына кереп качмакчы булдылар. *(Тыела алмыйча күләргә тотына. Ул әле Котас бине дә, аның юлдашларын да күрми. Күрмәмешкә салына.)* Өч йөз баш жылкыны куып киткәннәр дә, жинел генә безне алдамакчы булганнар. Өч йөз баш! Берсен дә бирмәдек. Барысын да куып алып кайттык.

Байсар. Менә ул минем батыр кызым!

Котас *(шомланып)*. Тегеләр... угрылар качтылармы?

Сәринә *(көлә-көлә Котас би ягына борыла)*. Юк, берсе дә качып котыла алмады, Котас би. Утызын да кырып салдык. Сарайгырның утыз кызы яудан утыз дошман башы алып кайтты.

Котас *(ыңгырашып)*. Йа, Раббым!

Сәринә. Сарайгырның утыз кызы бүгеннән башлап үзенә кияү сайлый ала.

Байсар. Син дә алып кайттыңмы, кызым?

**Сәринә** *(тыела алмыйча көлә дә көлә. Көлүендә газап сизелә).* Яудан мин бүген өченче баш алып кайттым. *(Сугышчы кызларга.)* Күрсәтегез мин алып кайткан дошман башын!

**Сугышчы кызлар күн капчыктан баш алып күрсәтәләр.**

**Котас** *(якынрак килеп карый, коты алынып кычкырып җибәрә).* Улым! Барак! *(Егыла.)*

**Бигәнәй.** Ай Алла, харап булдык!

**Танай** *(үз алдына).* Менә кызык!

**Өй эчендә ыгы-зыгы башлана. Котас бине кодалар аягына бастыралар.**

**Байсар** *(чыраен сытып, эченә тотына).* Күнелем сизенгән иде аны.

**Сәринә.** Без аларны сиздермичә генә уратып алдык, йоклаганда өсләренә барып бастык.

**Котас** *(кынындан хәнҗәрен тартып чыгара. Сәринәгә ташлана).* Сез йоклап яткан кешеләрне үтергәнсез. Сез үзегез—угрылар!

**Сәринә** *(чигенә, хәнҗәрен чыгара. Арага кораллы кызлар баса, атылып Танай килеп җитә).* Син, Котас би, ялгышасың: үтерер алдыннан без аларны уяттык.

**Котас** *(чигенә).* Улым, балам!

**Бигәнәй.** Бәхетсез бала.

**Котас.** Сонгы сулышында берәр сүз әйттеме ичмасам?

**Сәринә.** Әйтте. Сиңа миннән кодалар килер диде. Мин аны кызгандым. Бар, кач, без бит вәгъдәләшкән кешеләр, безнең туебыз булырга тиеш ләбаса дидем.

**Котас.** Ул ни диде?

**Сәринә.** Син—җинүче. Җинүченең колы буласым килми—үтер мине диде.

**Котас** *(елый).* Улым, балам... Бир ул башны миңа, Сәринә?

**Сәринә.** Юк, Котас би!

**Котас.** Байсар би! Бигәнәй бикә! Сез дә ата кеше, ана кеше...

**Байсар.** Кызым, Сәринә! Синең яудан өченче баш алып кайтуыңны барыбыз да күрдек.

**Юлдаш.** Күрдек, кызым.

**Бигәнәй.** Бир син аны, кызым, бир ана.

**Байсар** *(аягүрә баса).* Котас би! Бигәнәй бикә! Кызым Сәринә! Илкөн! Бу күнелсез хәл безгә мәңге сабак булсын. Элекке дошманлыкны онытып, безгә—сарайгырлар белән аласларга—киләчәктә мәңге дус-тату булырга кирәк.

**Сәринә.** Әтием Байсар би! Әнием Бигәнәй бикә! Ил-көн! Аласлар белән дуслашырга теләгән өчен дә мин үзем теләп Баракка кияүгә чыгарга ризалык биргән идем. Биргән сүзне мин түгел, ул бозды. Шунын өчен менә башы белән җавап бирде.

**Байсар.** Шулай да бир син ул бәхетсез башны анын атасына, кызым.

**Сәринә.** Бу бәхетсез башны мин яраттым, әтием. Бу баш бары минем үз башым белән бергә генә биреләчәк.

**Котас** *(үзгәреп).* Сәринә! Батырларның батыры, гүзәлләрнең гүзәле! Син мине... улым Баракны хур иттең. Син безне—аласларны аяк астына салып таптадың. Аласлар өчен дә бу күнелсез хәл мәңге сабак булыр. Моннан соң алар беркайчан күрше малына кул сузмаслар!

**Кодалар.** Моннан сон аласлар Сарайгыр белән мәңге дус булырлар.

**Байсар.** Амин, шулай булсын.

**Бигәнәй.** Теләгең изге, Котас би.

**Юлдаш.** Татулыкка ни житә, балалар!

**Котас.** Байсар би! Бигәнәй бикә! Сарайгырлар! Уртанчы улым Барак үтерелгән өчен генә мин сезнең белән туганлашудан баш тарта алмыйм. *(Сәринәгә.)* Сәринә! Мин Барак улым кебек тәкәббер түгел. Мин синең колың булырмын. *(Тезләнә.)* Чык миңа кияүгә!

**Тынлык.**

**Сәринә.** Яудан өч дошман башы алып кайткан кыз буларак, мин үзем яраткан теләсә кемгә кияүгә чыга алам. Бу безнең сарайгырларның борынгы йоласы. Кияүгә чыгарга дисен инде син, алайса, Котас би?

**Котас.** Аласта, бөтен далада беренче бикә булырсын, Сәринә.

**Сәринә** *(икеләнеп).* Сиңа... кияүгә...

**Байсар.** Үзең бел, кызым.

**Бигәнәй.** Без каршы түгел, кызым.

**Сәринә.** Юк, Котас би, юк! *(Көлә).* Мин сине түгел, улың Баракны яраттым. Син... бераз гына картрак, бераз гына ямьсезрәк, Котас би. Юк, юк! *(Үкси).*

**Котас** *(ялварып).* Байсар би!

Бигәнәй бикә! Ник якламыйсыз мине?

Байсар *(эченә тотына)*. Мин... кызымның теләгенә каршы... килә алмыйм...

Бигәнәй. Сәринә үзе риза булса, без риза, Котас би.

Юлдаш. Уйлашырга кирәк, балалар.

Котас *(Сәринәгә)*. Икеләнмә, Сәринә!

Байсар *(бик нык авыртынып)*. Кызым... Сәринә...

Сәринә. Әти, сина ни булды?

Бигәнәй. Бием! Атасы!

Танай. Әтәй!

Байсар *(хәлсез)*. Миңа аткан угы... чыннан да... агулы булган... Барак угланнын. Имче карчык әйтте... өч көнгә түзсәң... исән калырсың диде.

Бигәнәй. Түз, атасы, түз.

Байсар *(бик нык авырлык белән)*. Минем урынга... амага булып... син каласың...

Танай *(Байсарның янына ук килеп)*. Кычкырып әйт—кем кала, кем, әтәй?!

Байсар. Сәринә... син каласың...

Танай. Әтәй! Кабатла!

Бигәнәй. Кучте.

Танай *(шашып, Байсар янындагы кешеләргә)*. Сез ишетегезме: ул кем диде?

Юлдаш. «Сәринә» диде, кем, Танай улым.

Танай *(үле Байсарның якасыннан эләктереп ала)*. Карт алдакчы! Тәмуг кисәве!

Сәринә *(Танайны этеп җибәрә)*. Син үзең тәмуг кисәве!

Бигәнәй *(Танайга)*. Нишләвең бу?! Кулың корыр!

Танай. Йола буенча, Сарайгырда ага булып мин калырга тиешмен. Байсар бинең өлкән улы, бердәнбер улы—мин... Танай!

Юлдаш. Кем, Танай улым, ямьсезләнмә. Байсар би үз авызы белән әйтте: Сәринә кала диде.

Танай. Сез барыгыз да бер сүздә, барыгыз да дошман миңа. Чәнчелеп китегез! *(Тузынып чыгып китә.)*

Юлдаш. Әл-лә-лә! Менә нинди икән әле ул безнең Танай улыбыз!

Бигәнәй. Бары да язмыш кулында.

Сәринә. Язмыш кулында гына түгел, әнием.

Бигәнәй. Язмыштан узмыш юк, кызым.

Котас. Язмышны аны сугышып җиңәргә кирәк!. *(Чыга. Кодалар да чыгалар).*

Юлдаш. Менә шулай кеше: кайгыра, даулаша—бар дөньяны яулап алмак була. *(Үле Байсарга күрсәтеп)*. Аңа инде берни кирәкми.

## Өченче күренеш

**Өй эче. Сәринә түрдә. Аның тирәсендә кызлар бөтерелә. Алар аны киендерәләр, төзәндерәләр.**

**Бигәнәй керә.**

Бигәнәй. Кызым, Сәринә! *(Сәринә ишетми)*. Сәринә дим! Тамактан калдың, инде колактан да калдыңмени?

Сәринә. Әү? Әни, синмени?

Бигәнәй. Үлгән артыннан үлеп булмый—шул кадәр бетеренмә.

Сәринә. Мин уйланам, әнием.

Бигәнәй. Бүген менә ил-көн сине Сарайгырның амагасы итеп күтәрәчәк. Каршы килүчеләр булмасмы, үзара тавыш-гауга чыкмасмы?

Сәринә. Борчылма, әнием, берни булмас.

Бигәнәй. Үз-үзеңә артыграк ышанмыйсың микән, кызым?

Сәринә. Үземнән бигрәк мин халкыма, ыруыма ышанам.

Бигәнәй. Җан сердәшең булса, үзенә җиңелрәк булыр иде димен шул.

Сәринә. Иң ышанычлы сердәшем син—әнием... Бигәнәй бикә.

Бигәнәй *(җиңелчә ачуланып)*. Башыңны җүләргә салып утырган булма. Сиңа хәзер үк кияү турында уйларга кирәк.

Сәринә *(таркау)*. Кияү. Кияү алырга, Кияүгә барырга...

Бигәнәй. Шундый яшьлегең белән, шундый чибәрлегең белән... кайгыга сабышып утырырга монда!

Сәринә. Кемгә чыгарга соң, әни?

Бигәнәй. Үзең теләгәнне сайла.

Сәринә. Сайлыйсым килми.

Бигәнәй. Синең урында булсаммы мин!

Сәринә *(көлеп)*. Утыр минем урынга.

Бигәнәй. Яшьлекне алай гына кайтарып булса иде ул, кызым! Минем яшьлек инде узды... күренмичә, сизелмичә узды. Синеке әле башлана гына. Сөекле ирен, итәгең тулы балаларың булсын—миннән теләк шул сиңа.

Сәринә. Кайгым бар, әни.

Бигәнәй. Нинди бетмәгән кайгы инде ул?

Сәринә. Мин үземә ир дә табармын, бәхетле дә булырмын...

Бигәнәй. Бирсен Раббым!

Сәринә. Мин бәхетле булган белән генә Сарайгырның барлык кызлары да бәхетле булыр микән соң?

Бигәнәй. Кайсы кызларны әйтәсең?

Сәринә. Кияүгә чыгарга хокукы булмаган кызларны.

Бигәнәй. Бәрәч! Синең белән бергә аласларны җинеп кайткан егерме тугыз кызның барысы да кияүгә чыгып бетте ләбаса инде. Син генә калдың.

Сәринә. Мин—булачак ыру башы, үзем белән аласларны җинеп кайткан кызлар турында гына түгел, барлык ил-көн турында кайгыртырга тиешмен.

Бигәнәй. Анысы анын ярый инде ул, кызым. Шулай да син Сарайгырның барлык кызлары кияүгә чыгып беткәнче дуадак каз кебек утырырга җыенмыйсыңдыр ич?

Сәринә. Җыенам, әнием.

Бигәнәй. Андый сүзне кешекара ишетә күрмәсен—яман атың бөтен далага таралыр, йөзеңә карап көләрләр.

Сәринә. Үз уемнан мин кире кайтмаячакмын... йөземә карап көлсәләр дә, яман атым бөтен далага таралса да!

Бигәнәй. Карале, шуны әйтим дигән идем... Мәрхүм әтиеңнең бер теләге бар иде. Бүген... кырыгы тулган көнне...

Сәринә. Мин аның теләгеbelән, әнием.

Бигәнәй. Үзең белгәч, бигрәк тә яхшы!

Сәринә. Мәрхүм Байсар бинең теләгеn һәркем белә: үзе урынына ул мине...

Бигәнәй. Белмисең! Сарайгыр таркалмасын өчен, ул сине...

**Юлдаш керә.**

Юлдаш. Исәнме-саумы, кем, кызым Сәринә. Исәнме, килен.

Сәринә. Түрдән уз, Юлдаш баба.

Юлдаш. Ярый әле икегез дә бергә туры килдегез. *(Сәринәгә)*. Минем сиңа әйтәсе бик кирәкле сүзем бар иде, кем, кызым Сәринә.

Сәринә. Әйтеп кара, Юлдаш баба.

Юлдаш. Үзең яшьсең, үзең чибәрсең. Батырлыгың да ярыйсы. Бүген менә үзеңне амага итеп күтәрәчәкбез. Тормышың түгәрәкләнсен дисәң, кызым, сиңа кияүгә чыгарга кирәк.

Бигәнәй. Мин дә шуны сөйләп торам әле, Юлдаш баба.

Сәринә. Бик акыллы киңәш бу, Юлдаш баба. Синең әллә димләр кешең дә бар?

Юлдаш. Менә дигән кешем бар, кызым.

Сәринә. Кем икән соң ул, Юлдаш баба?

Юлдаш *(чыга, шундук Танай белән бергә керә)*. Менә бу чибәр угланны беләсеңдер.

Сәринә *(аңламаган булып)*. Танайны әйтәсеңме, Юлдаш баба?

Бигәнәй *(җиңелчә ачуланып)*. Кыланып утырган булма! Юлдаш бабаң, олы башын кече итеп, синең белән сөйләшә икән, тынлап кына тор.

Юлдаш. Шул инде, шул... бәхете булгыры... абыең Танайны әйтәм.

Сәринә *(көлеп)*. Син мине абыем Танайга димләргә җыенасыңмыни?

Юлдаш. Юк ла, ниткән абыең булсын ул синең! Атаң мәрхүм—урыны оҗмахта булсын!—яудан, шүнәкләрдән алып кайтты аны.

Танай. Мәрхүм әтәй... Сарайгырның элекке агасы Байсар би—яткан җире мамык булсын—моннан бик күп еллар элек шүнәкләргә каршы яу чапкан. Шунда ул мине янган өй янынннан табып алган. Минем ырудашлар... шүнәкләр, арбаларын, өйләрен яндырып, минем кул-аякларны бәйләп... мине шунда утыртып калдырган булганнар. Миңа бары ике-өч яшь булган.

Юлдаш. Әниең Бигәнәй бикәне дә Байсар би шуннан алып кайтты.

Сәринә. Каян алып кайтты?

Юлдаш. Шуннан инде, шуннан—Шунәктән.

Сәринә. Кичә үлгән булсам, бүген ишетмәгән булыр идем! Дөньяда мин белмәгән серләр житәрлек икән әле.

Юлдаш. Кем, кызым, Сәринә, дөньяның син белмәгән серләре күп. Ул серләрне бары берничә кеше генә белә. Хәзер менә син дә белә башларсың.

Сәринә. Белмәгән булсам, нинди яхшы буласы икән!

Юлдаш. Амага кеше чынын да, ялганын да белергә тиеш. Шунәкләрне жинеп кайткач, Байсар би әйтте халыкка: яшь баласы белән яшь хатын алып кайттым диде. Танайны... ырудашын әниең Бигәнәй бикә, жил-янгыр тидермичә, үз баласы кебек карап үстерде.

Сәринә. Нишләп мин берни дә сизмәдем икән соң?

Бигәнәй. Танай улым үзенең ятимлеген белмәсен, күңеле китек булмасын дип тырыштык инде, кызым. Шуңа күрә сиңа берни сиздермәдек.

Сәринә. Ул үзе каян белгән соң?

Танай. Быптыр монда Шунәктән бер теләнче килеп чыкты—шул сөйләде.

Сәринә. Дөрес, Шунәктән бер теләнче булды бездә!

Юлдаш *(бер кулы белән Танайны, икенче кулы белән Сәринәне тотып, икесен дә бер-берсенә якын китермәкче була).* Дөньяның бер сере чишелде. Бәхетле булыгыз, балалар.

Бигәнәй. Бәхетле булсыннар, тигез гомер итсеннәр.

Сәринә *(карышып).* Ләкин мин Танайга чыга алмыйм!

Юлдаш. Нишләп алай?

Сәринә. Мин аны... яратмыйм, Юлдаш баба, әнием Бигәнәй бикә!

Танай. Мин сине... яратам, Сәринә!

Сәринә *(көлеп).* Син мине... яратасың?! Нишләптер моңарчы сизелмәде. Миңа карата син һәрвакыт көнчел, үпкәчел һәм кансыз булдың сыман.

Танай. Моннан соң алай булмас, Сәринә.

Сәринә. Шулай бик тиз үзгәрерсең микәнни, Танай?

Танай. Үзгәрәм! Утка керергә кушсаң, утка керәм, суга керергә кушсаң, суга керәм!

Сәринә *(чит, салкын).* Әгәр мин сине белмәгән булсам, бәлки әле ышанган да булыр идем. Ләкин мин сине биш бармагым кебек беләм. Беркайчан да син мине яратмадың... туганың-сеңлең буларак та, хатын-кыз буларак та. Син бары үзеңне генә яратасың, Танай.

Таңай *(хурланып).* Үзең әллә кем инде!

Сәринә. Юк, яратмыйм мин сине, яратмыйм!

Танай. Карак калдыгы! Исенә төшәр дә, соң булыр! *(Тузынып чыгып китә).*

Сәринә. Менә монысы Танайча!

**Барысы да аптырап Танай артыннан карап калалар.**

Бигәнәй *(Сәринәгә).* Кешенең йөзенә бәреп «яратмыйм» дип әйтергә теге... кем булдың шул кадәр? Син дә күктән төшмәгән!

Юлдаш *(Сәринәгә).* Хәзер инде мине тынлап кара, кызым Сәринә. Ярату кемгә дә кирәк. Яратудан бигрәк, сиңа ир кирәк. Ирең, терәгең булмаса, Сарайгырда сине беркем санламаячак. Үләр алдыннан Байсар би сине ыру башы итеп калдырган икән, димәк, ул барысын да ныклап уйлаган.

Бигәнәй. Уйлады, Юлдаш баба, бик нык уйлады.

Юлдаш. Син, кызым, алай-болай чит ыруга кияүгә чыксаң, Сарайгыр бик кыен хәлдә калыр иде. Синең бирнәң булып, Сарайгыр чит ыруга кушылыр иде. Син чит ыру кешесенә чыкмасын өчен мәрхүм Байсар би сине Танайга бирергә исәпләгән.

Бигәнәй. Исәпләде, Юлдаш баба! Икәү бергәләп исәпләдек.

Юлдаш. Шулай булгач, Сарайгырның байсезлеген саклап калыйм дисәң, сиңа бары Танайга гына чыгарга туры килә, Сәринә кызым.

Сәринә *(көрсенеп).* Нинди авыр икән амага булу!

Юлдаш. Сиңа тагын шуны да әйтим, кызым Сәринә: безнең сүзгә колак салмыйча, киреләнә башласаң, без сине амага итеп күтәрмәячәкбез.

Сәринә. Куркытма, Юлдаш баба! Мәрхүм Байсар биnең ыру башы булырлык баласы бер генә. Ул да булса, мин—Сәринә!

Юлдаш. Син әле берни белмисең икән, кызым—мәрхүм Байсар бинең

ыру башы булырлык ир баласы бер генә. Ул да булса—Танай.

Сәринә *(нәфрәтләнеп)*. Син Юлдаш баба, ни сөйләгәненне белеп сөйлисенме?!

Юлдаш. Бик белеп сөйлим, кызым. Мәрхүм Байсар бинең варисы—Танай.

Сәринә *(тыела алмыйча)*. Бар чыгып кит моннан, ялганчы карт!

Бигәнәй. Кызым, тукта хәзер үк!

Сәринә *(Бигәнәйгә)*. Әллә син дә анын яклы, Бигәнәй бикә?

Бигәнәй. Үлсәм дә, калсам да—бергә. Ил-көн белән, халкым белән.

Юлдаш *(чигенә, ишекне ача. Ишек артында җиңелчә гүелдек ишетелә. Анда—халык)*. Ашыкма, кызым, куарга. Сиңа соңгы сүзем шул: халык алдында мин Танайны яклаячакмын!

Сәринә *(атылып ишек янына килә)*. Син әле шулаймыни?!

Юлдаш. Шулай, кем, кызым Сәринә.

Бигәнәй *(Сәринәгә каршы якка, Юлдаш янына баса)*. Мин дә «шулай», кызым.

Сәринә *(ярсып ары-бире йөренә дә, туктап кала. Дәртсез)*. Мәрхүм әтием Байсар бинең теләген үтәп... Сарайгырның бөйсезлеген саклап калу өчен... мин риза Танайга кияүгә чыгарга.

Юлдаш. Менә монысы акыллы сүз, кызым!

Бигәнәй. Уф! Авызыннан тартып алгандай алдык акыллы сүзне. Тагын бер кабатла әле.

Сәринә *(дәртсез)*. Кабатлыйм: мин Танайга кияүгә чыгарга риза, Бигәнәй бикә, Юлдаш баба. *(Кискен рәвештә башын калкыта)*. Хәзер мине тыңлагыз!

Юлдаш. Тынлыйбыз. Әйтәсе сүзләренне әйтеп бетер, кызым.

Бигәнәй. Тыңламаган кая ул, тыңлыйбыз!

Сәринә. Мин Танайга кияүгә чыксам, мине амага итеп күтәрәчәксез. Булды бер.

Юлдаш. Күтәрәбез.

Бигәнәй. Күтәрәбез, кызым.

Сәринә. Мин амага булгач, илкөн алдында мине якларсыз. Булды ике.

Юлдаш. Яклабыз.

Бигәнәй. Үз кызымны да якламагач, тагын кемне якларга?!

Сәринә. Карагыз аны, әйткән сүзегездән кайтасы булмагыз!

Юлдаш. Әйткән сүздән кайтмабыз.

Бигәнәй. Сүзебездә торырбыз, кызым.

**Тышта тавышлар ишетелә.**

Юлдаш. Халык җыелды. Илкөнгә күренергә вакыт.

Сәринә. Мин әзер. Керсеннәр.

**Бигәнәй бикә ишекне ача, халыкка керергә куша. Халык керә.**

Сәринә *(түргә утырып, халыкка эндәшә)*. Мәрхүм Байсар бинең хатыны... сөекле әнием Бигәнәй бикә мондамы?

Җавап. Монда.

Сәринә. Сарайгырның акыл иясе, атаклы аксакал Юлдаш баба мондамы?

Җавап. Монда.

Сәринә. Минем батыр ир туганнарым мондамы?

Җавап. Монда.

Сәринә. Минем батыр кыз туганнарым мондамы?

Җавап. Монда.

Сәринә *(аягүрә баса)*. Сөекле әнием Бигәнәй бикә! Атаклы аксакал Юлдаш баба! Туганнар! Моннан кырык көн элек Сарайгыр ыруының курку белмәс олуг агасы... әнием Бигәнәй бикәнең яраткан ире... минем сөекле әтием кара җир астына керде.

Халык *(авыр ыңгырашып)*. Кара җир астына керде.

Сәринә. Курку белмәс батыр Байсар бине дошман угы үтермәде—үзара дошманлык, явызлык, кыргыйлык үтерде. Моны беркайчан онытмыйк, сарайгырлар.

Халык *(авыр ыңгырашып)*. Мәңге онытмабыз.

Сәринә. Үләр алдыннан мәрхүм әтием үзенең теләген әйтеп калдырды. Ул мина Сарайгырның амагасы булырга боерды. Син—әнием Бигәнәй бикә! Син—атаклы аксакал Юлдаш баба! Мәрхүм Байсар бинең боерыгын яклыйсызмы?

Бигәнәй. Яклыйбыз, кызым.

Юлдаш. Яклыйбыз, кызым Сәринә.

Сәринә. Сез—минем батыр ир туганнарым, сез минем кыю кыз туганнарым... сез—ырудашлар... мәрхүм Байсар бинең боерыгын яклыйсызмы?

**Бераз вакытка тынлык.**

Тавышлар. Яклыйбыз, Сәринә! Мен яшә, амага!

**Гомуми күтәренкелек, шау-шу. Сәринәне ак киезгә утырталар. Киезнең ике ягыннан ике ир кеше, ике ягыннан ике хатын-кыз тота. Тотучылар арасында Бигәнәй бикә белән Юлдаш баба да бар. Киезне югары күтәреп түбән төшерәләр. Сәринә тәхеткә утыра.**

Сәринә. Рәхмәт сиңа, әнием Бигәнәй бикә! Рәхмәт сиңа Юлдаш баба! Рәхмәт сезгә ырудашлар. Сарматларның Сарайгыр ыруы амагасы Сәринә сөйли. Мине тыңлагыз. Сезнең күбегезнең аталары, ирләре, уллары, кызлары ел саен, көн саен диярлек булып торган төрле яуларда башларын салдылар. Мин белгәндә генә дә Сармат даласында күпме сугыш булды! Күпме хатыннар тол калдылар, күпме балалар ятим калды! Безнең җиребез батыр ирләрнең, гүзәл кызларның кайнар каны белән сугарылган.

Халык *(авыр ыңгырашып)*. Дөрес, Сәринә!

Сәринә. Далада гомер-гомергә килә торган дошманлык, кыргыйлык сезнең ирләрегез, сезнең туганнарыгыз белән бергә... мәрхүм әтием Байсар би белән бергә минем сөйгәнем Барак угланны да гүргә салды. Дөрес, Барак угланны мин үзем үтердем. Безне туктаусыз үзара сугыштыра торган әшәке йола минем акылымны томалаган. Моны мин бик соңлап аңладым. Тагын мин шуны аңладым, сарайгырлар—җирдә беркайчан да толлар, ятимнәр, гариплэр булмасын дисәк, иң элек безгә үзара дошманлыкны бетерергә кирәк. Дошманлыкны бетерү өчен... яман йолаларны юкка чыгарырга кирәк!

**Авыр тынлык.**

Юлдаш *(ачулы, тыелып)*. Йола безгә ата-бабалан калган. Йола безнең какшамас терәгебез!

Тавышлар. Йола—изге! Йоланың яманы юк!

Сәринә. Йоланың яманы да бар, сарайгырлар! Яшь кызларны корал тотып яу чабарга мәҗбүр итә торган йола—яман йола! Хатын-кызны тәңре җирдә нәсел калдыру өчен яраткан.

Хатын-кызлар. Дөрес, Сәринә! Дөрес, амага!

Сәринә. Сарайгырның бик күп яшь кызлары яуда катнаша алмыйлар. Шунлыктан аларның иргә чыгарга хаклары юк. Бу—кансыз йола!

Хатын-кызлар. Кансыз йола! Яман йола!

Сәринә. Бу йола күршеләр белән туктаусыз сугышып торуны таләп итә. Сугыш берәүләргә байлык китерсә, икенче берәүләргә үлем, хурлык китерә. Бүген без җинсәк, иртәгә күршеләр җиңәчәк.

Халык. Дөрес, амага!

Юлдаш. Дөрес түгел, амага!

Сәринә. Ни дөрес түгел, Юлдаш баба?

Юлдаш. Күршеләр белән чагыштырганда, Сарайгырның халкы азрак. Шулай да бик күпләр бездән шүрләп торалар. Ник? Чөнки сарайгырларның ирләре генә түгел, кызлары да яу чаба. Шуңа да Сарайгыр, беркемгә буйсынмыйча, үз көнен үзе күрә. Инде килеп син, кызым Сәринә, әлеге йоланы юкка чыгарасың икән, ул чагында Сарайгыр көчсезләнәчәк.

Аксакаллар.

—Усал күршеләр безне таптап китәчәкләр!

—Сарайгыр юкка чыгачак!

Сәринә. Сарайгыр юкка чыкмаячак!

Юлдаш. Амин, шулай булсын. Шулай да син аңлатып бир. Кызларыбыз корал ташласалар, Сарайгыр гаскәре бермә-бер кимиячәк. Ничек итеп каршы торырбыз соң дошман явы килсә?

Сәринә. Моннан соң беркем Сарайгырга каршы корал күтәрмәячәк, Юлдаш баба!

Юлдаш. Син аны каян беләсең?

Сәринә. Мин үзем башлап беркайчан күршеләргә каршы яу чапмаячакмын.

Юлдаш. Шулай да булсын.

Бигәнәй. Ниятең изге, кызым.

Сәринә. Мин үзем беренче булып корал күтәрмәгәч, башкалар да безгә каршы яу чапмаячаклар.

Юлдаш. Шулай да чабарга теләсәләр?

Сәринә. Мин ничек тә эшне зурга җибәрмәскә тырышачакмын. Мин ничек тә дошманлыкны дуслыкка әйләндерергә тырышачакмын. Мин далада мәңге иминлек урнаштырачакмын!

Юлдаш. Көненне хатын-кызга калдырмасын икән Раббым.

Бигәнәй. Хатын-кызга тел тидермә, Юлдаш баба. Ни күрсәк тә бергә күрербез. Мин кызым яклы.

Хатын-кызлар. Яклыйбыз, амага! Яклыйбыз!

Сәринә *(аксакалларга).* Сез—аксакаллар?

Аксакаллар. Без... үзен беләсен... Уйларга кирәк.

Сәринә. *(Юлдашка).* Син—Юлдаш бабай?

Юлдаш *(төшенке).* Мин инде карт кеше, балалар.

Сәринә. Син, Юлдаш баба, бер дә курыкма. Күршеләр безне көчле дип уйлыйлар. Уйласыннар! Без аларга берни сиздермәбез. Берничә елдан Сарайгыр даласын шат балалар тавышы күмеп китәр. Күршеләр аны-моны сизеп өлгергәнче, ир балалар үсеп житәрләр, әниләре урынына сакка басарлар.

Юлдаш. Теләгең изге, кызым, амага. Тик менә...

Сәринә. Тик менә... Син мина сүз бирден, Юлдаш баба.

Юлдаш *(авырлык белән).* Мин сиңе яклыйм, амага.

Аксакаллар *(җанланып).* Яклыйбыз, амага! Бетсен яман йола!

Сәринә. Шулай итеп, Сарайгырның яшь кызларны корал тотып яуда катнашырга мәҗбүр итә торган йоласын юкка чыкты дип исәплибез.

Аксакаллар. Амин, шулай булсын.

Бигәнәй *(Сәринәгә).* Без синең теләкне үтәдек, инде син безнең теләкне үтә.

Юлдаш. Барысы да ишетсен—әйт кычкырып безнең теләкне.

Сәринә. Сөекле әнием Бигәнәй бикә! Атаклы аксакал Юлдаш баба! Сарайгырлар! Мин—Сарайгырның амагасы Сәринә... моннан унсигез ел элек мәрхүм әтием Байсар би шүнәкләрдән яулап алып кайткан... үз баласы кебек итеп тәрбияләп үстергән Танайга кияүгә чыгарга риза.

Бигәнәй. Атаң мәрхүмне искә алган бу изге көндә... Исән булса, ул да сөенер иде *(күз яшьләрен сөртә).*

Юлдаш. Инде күңелем тыныч—Сарайгыр исән калыр. Ата-баба рухы мәңге онытылмас.

Аксакаллар. Изге эш—яклыйбыз! Сарайгыр таркалмас!

Сәринә *(Танайны эзләп як-ягына карана. Күренмәгәч, халык ягына карап).* Танай, син мондамы?

**Барысы да, Танайны эзләп, якякларына караналар. «Танай кая?» «Танай юк!» дигән тавышлар ишетелә. Сәер тынлык, гомуми аптыраш.**

Бигәнәй *(ашыгып).* Җәликә! Мамиха! Барыгыз тиз генә Танайны эзләп табыгыз. Әйтегез—хәзер үк килеп житсен!

*Пәрдә ябыла.*

## Икенче бүлек

### Беренче күренеш

**Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Бигәнәй бикә ялгыз. Ул еракка карап уйга калган. Еракта күңелле шау-шу, күтәренкелек.**

Бигәнәй. Кемнәр килеп кемнәр китми бу дөньядан... Кичә—бар, бүген—юк.

**Юлдаш керә.**

Юлдаш. Исәнме, кем, килен.

Бигәнәй. Исән әлегә, Юлдаш баба.

Юлдаш. Моңаясыңмы, килен?

Бигәнәй. Моңаям. Менә шушы вакытта, кояш кичкә авышканда моңаям. Никтер мәрхүм Байсарның миңа үпкәсе бардыр кебек. Сезгә, исәннәргә рәхәт, безгә—үлеләргә бик кыен дип әйтәдер кебек.

Юлдаш. Исәннәргә дә бик үк җинел түгел, килен.

Бигәнәй. Түгел, Юлдаш баба. Кайда рәхәттәр—белгән юк.

Юлдаш. Минем дә мәнә тынычлыгым качты. Сарайгырда хәзер көн дә бәйрәм, көн дә туй.

Бигәнәй. Бу арада туйлар күбәеп китте шул.

**Юлдаш белән Бигәнәй, тын калып, еракттагы күңелле шау-шуны тыңлап торалар.**

Юлдаш. Яшьләрнең күңел ачуларын күрдемме, эчем поша башлый.

Бигәнәй. Картаябыз, яшьләрне яратмыйбыз, Юлдаш баба.

Юлдаш. Юк, килен, картлыктан гына түгел—яшьләрнең гамьсезлегенә, аңсызлыгына эчем поша. Бүген күңелле булса, аларга шул җиткән. Гел менә нинди дер бәла-каза булыр кебек.

Бигәнәй. Бәла аяк астында.

Юлдаш. Ниме соң, андыймондый хәбәр юкмы?

Бигәнәй. Танайны әйтәсеңме?

Юлдаш. Шуны инде, шуны.

Бигәнәй. Юкка чыкты безнең Танаебыз. Нәрсә уйларга да белгән юк. Эзләргә җибәргән кешеләребез дә кайтып житмәде.

**Таяк атын кыйный-кыйный Малай керә.**

Малай. Сөенче! Киләләр! Кайталар!

Бигәнәй *(өйгә кереп барган җиреннән туктап кала).* Кем кайта, балам?

Юлдаш. Бу вакытта кем генә булыр икән ул?

Малай. Әнә, тыңлагыз әле.

Тыңлыйлар. Еракта сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы ишетелә.

Юлдаш. Берни ишетмим.

Малай. Ни, шуны да ишетмәгәч!

Бигәнәй. Югалган Танай улым кайтамы соң әллә?

Малай. Кайталар! Киләләр! Сөенче! *(Чыга.)*

**Мамиха керә.**

Мамиха. Бикә! Юлдаш баба! Илчеләр килә!

**Өйдән Сәринә чыга.**

Сәринә *(Мамихага).* Кемнәр килә дисең?

Мамиха. Илчеләр килә, амага.

Сәринә. Белмәденме—каян, кемнән икән?

**Җәликә керә.**

Җәликә. Амага! Сәринә! Баспурдан илчеләр килгән.

Бигәнәй. Сатир патшаданмыни?

Юлдаш. Баспурлардан безгә илчеләр килгәне юк иде—хәерлегә булсын, балалар.

Сәринә *(Җәликә белән Мамихага).* Барыгыз, каршы алыгыз.

**Мамиха белән Җәликә чыга. Сәринә шунда калку урынга утыра. Бераздан Җәликә белән Мамиха һәм Филеб керә. Филеб янында бер-ике баспур кешесе.**

Филеб *(Сәринәгә якынрак килә, бил бөгә).* Баспур патшасы Сатирның өлкән улы Филеб синең алда баш ия, бөек амага.

Сәринә. Исән-имин минем җиремә, урдама килеп житүең белән котлыйм сине, Сатир патшаның өлкән улы Филеб.

Филеб. Илең имин булсын, терлек-туарың күп булсын, халкың бай булсын, бөек амага.

Сәринә. Амин, шулай булсын.

Бигәнәй. Яхшы сүзләрең үзенә изгелек булып кайтсын.

Юлдаш. Шулай булсын, балалар.

Сәринә. Бик ерактан килгәнсең, Сатир пашта улы. Нинди җилләр ташлады сине безнең бу дала якларына?

Филеб. Сармат сарайгырларының бөек агасы Байсар бинең үлеме турындагы күңелсез хәбәр безнең Баспур җирләренә дә барып житте. Байсар бинең үлеме Сатир патшаның күңеленә кара кайгы булып ятты. Үзенең кайгысын белдерү өчен әтием Сатир патша мине сиңа илче итеп җибәрде, бөек амага.

Сәринә. Әтиебез олуг Байсар бинең үлеме безнең үзебезгә дә аяз көнне яшен суккан кебек булды. Сарайгырларның кайгысын уртаклашкан өчен Сатир патшага миннән рәхмәт әйтерсең, илче.

Филеб. Тагын шул, бөек амага: Сатир патша сине Сарайгыр тәхетенә утыруың белән котларга кушты, синең үзенә озын гомер, байлык, көч-куәт теләде.

Сәринә. Сатир патшаның изге теләкләре өчен миннән аңа шулай ук рәхмәт әйтерсең, илче.

Бигәнәй. Рәхмәт инде Сатир

патшага—бигрәк олылаган безне.

Юлдаш. Бай булсын Сатир патша.

Филеб. Байсар би исән чакта без—баспурлар, сарайгырлар үзара дус-тату яшәдек. Сатир патша киләчәктә дә сарайгырлар белән туганнарча дус яшәргә дигән теләк белдерде.

Сәринә. Сарайгырлар да баспурлар белән элеккечә дус-тату яшәргә телиләр.

Бигәнәй. Баспурлар белән барышып-килешеп яшәргә язсын, тәңрем.

Филеб. Мәрхүм Байсар би миңа сау-сәламәт, таза булып күренгән иде. Аның үлеменә без бик аптыраштык.

Сәринә. Баспурдан кайтканда аларга юлбасарлар чыккан. Шунда әтиемә агулы ук тигән.

Филеб. Нинди зур кайгы. Юлбасарлардан беркайда да качып котылып булмый бу дөньяда.

Сәринә *(көлеп)*. Сүзең дөрес, илче. Син миңа бик таныш бер юлбасарны хәтерләттең.

Филеб (куркып битен каплый). О, Зевс! Мин... юлбасарга охшаганмынмы?!

Сәринә. Нәкъ үзе. Суйган да каплаган!

Бигәнәй. Кызым, Сәринә, олы кунакның йөзен ерту килешмәс.

Сәринә. Ул чыннан да мәрхүм Баракка охшаган, әнием.

Бигәнәй. Авыр юлдан соң илчеләрнең ял итәселәре, ашыйсылары-эчәселәре киләдер.

Сәринә. Шулай шул, әнием. Син анда зурлап аш-су әзерләргә куш әле.

Бигәнәй. Ярар, кушармын. *(Кузгала.)*

Юлдаш. Мин дә китим әле.

**Чыгалар.**

Сәринә. Мин синең хәтереңне калдырдым, ахрысы, илче?

Филеб. Хәтер калырга мөмкинме соң сиңа, бөек амага?!

Сәринә. Ялгыш әйтелгән сүздән генә түгел, кырын күз карашыннан да хәтер кала кайчагында.

Филеб. Минем сиңа хәтерем калмады, Сәринә. Минем күзем томаланды! Мин сине болай уктыр дип уйламаган идем.

Сәринә *(көлеп)*. Нишләп әле син минем турыда уйладың, илче?

Филеб. Синең турыда ишеткәннән бирле... гел сине уйладым.

Сәринә. Баспурда мине күргәнбелгән кеше юк. Кем әйтте сиңа минем хакта?

Филеб. Син ул кешене беләсең. Ул миңа үзенең уңышсыз мәхәббәте турында сөйләде.

Сәринә. Танаймыни?!

Филеб. Танай. Без аның белән дуслашып киттек. Байсар бинең үлеме турында да ул әйтте. Шуннан соң минә жыендым да, илче булып синең катыңа килдем.

Сәринә. Сине монда Сатир патша җибәрмәдемени, алайса?

Филеб. Мин теләдем, ул җибәрде. Синең чибәрлегең, батырлыгың турында күбрәк белгән саен, миндә сине күрәсе килү теләге туа барды.

Сәринә. Шулай да син кем: илчеме, Сатир патшаның улы гынамы?

Филеб. Илче дә, гашыйк та.

Сәринә. Син бик кыю күренәсең, Сатир патша улы.

Филеб. Безнең нәселдә кыюсызлар юк, бөек амага. Син әле генә мине үзең белгән ниндидер юлбасарга охшаттың. Син хаклы ахрысы—бик ерак бабаларым минем диңгез юлбасарлары булган.

Сәринә. Син бераз гына мактанчык та бугай, диңгез юлбасары.

Филеб. Бераз гына түгел, бик зур мактанчык мин, Сәринә!

Сәринә *(көлә)*. Нинди күңелле кеше икәнсең син, илче!

Филеб. Ләкин минем башка мактанчыкларга охшамаган бер ягым бар. Башка мактанчыклар бары үзләрен генә мактасалар, мин йә ата-бабамны, йә хатын-кызны мактыйм.

Сәринә. Һөнәрләрең күп икән синең, Мактанчык Филеб. Ата-бабаңны мактап син бер һөнәреңне күрсәттең, башка һөнәреңне әлегә күрмәдек.

Филеб *(кутәренке)*. Тудыручы бөек Ана сиңа Афродита гүзәллеген, Афинаның батырлыгын биргән. Искитмәле күркәмлегең белән безнең кебек ир кешенең зиһенен буташтыру өчен изге Зевс сине алтын тургә утыртып куйган.

Сәринә. Синең чыннан да зиһенең буталган, ахрысы, илче Филеб. Түргә мине баспурлар алласы Зевс утыртмады. Тәңренең боерыгын, мәрхүм әтиемнең теләген үтәп, мине монда ил-көн утыртты.

**Филеб.** Сарайгырның сылу амагасы! Синең урының дәрәҗәле, ләкин, белүемчә, син дә ялгыз.

**Сәринә.** Минеке кебек дәрәҗәле урында ялгыз утыру хәерлерәк, илче Филеб.

**Филеб.** Бөек амага! Мин сиңа моннан да дәрәҗәлерәк урын тәкъдим итмәкче булам.

**Сәринә.** Минем өчен Сарайгыр тәхетеннән дә дәрәҗәлерәк урынның булуы мөмкин түгел.

**Филеб.** Сарайларымны, бүлмә тулы алтын-көмешләремне—барлык байлыгымны таудай итеп синең аяк астына өеп куярга әзермен, Сәринә!

**Сәринә.** Мин—дала кызы. Аяк астының тигез булганын яратам.

**Филеб.** Көннәрдән бер көнне... озакламый Баспур тәхетенә Филеб патша утырачак. Филеб патша Баспур җирләрен Сарайгыр җирләренә кушса, Сәринәнең байлыгына кызыкмаган кеше калмаячак. Ал мине үзенә кияү итеп, Сәринә!

**Сәринә** *(тора, йөренә, тынычсыз).* Синең кебек сораучылар булмады түгел, булды. Ялындылар, янадылар. Синең кебек тау-тау алтыннар, көтү-көтү маллар вәгъдә иттеләр. Берсе ялынмады да, янамады да, байлык та вәгъдә итмәде. Мин аны үзем тарттым. Ләкин ул мине алдамакчы булды! Шуның өчен мин аның... башын чаптым. *(Тәхеткә утыра, кискен.)* Юк, Филеб патша! Син миңа кияү була алмыйсың.

**Филеб.** Ник, Сәринә?

**Сәринә.** Син яшь, чибәр. Ләкин син—чит халыктан. Син—баспур. Мин—сармат, син—су, мин—ут. Минем кендегем Сарайгырга береккән... халкыма, ыруыма. Мине моннан... бу биек урыннан беркем, берни кузгата алмый.

**Филеб.** Бик кызганыч, гүзәл амага.

**Бигәнәй керә.**

**Бигәнәй.** Кызым, олы кунакны ялыктырма. Аш-су житеште.

**Сәринә.** Әни! Күңелле сүз ишетәсең киләме?

**Бигәнәй.** Күңелле сүзләрне безгә сирәк ишетергә туры килә.

**Сәринә.** Танай исән икән бит, әни!

**Бигәнәй.** Танай?! Кайда ул минем Танай улым?

**Сәринә** *(Филебкә).* Илче Филеб, Танайны син кайда, ничек күрдең?

**Филеб.** Байсар би Баспурга терлек алып килгәч, беренче мәртәбә мин аны шунда күрдем, бөек амага.

**Сәринә.** Икенче мәртәбә кайда күрдең?

**Филеб.** Икенче мәртәбә ул Баспурга качып килгәч күрдем. Очрашкач әйтте: Сарайгырдан киттем диде, анда мине яратмыйлар диде.

**Бигәнәй.** И, бала, бала.

**Филеб.** Ул тагын шуны да әйтте: исән чагында Байсар би мине үзенең варисы дип белде, үләр алдыннан баш тартты диде.

**Сәринә.** Монысы дөрес түгел.

**Бигәнәй.** Бигрәкләр хурланган икән шул, балакаем.

**Филеб.** Мин аны кызгандым, кораллы сакчы итеп, үз яныма сарайга алдым.

**Сәринә.** Ул хәзер кайда?

**Филеб.** Ул минем белән килде, бөек амага.

**Бигәнәй.** Бу сөенечле хәбәрне Юлдаш бабаңа да әйтергә иде. Кая булды соң әле ул?

**Юлдаш керә.**

**Сәринә.** Гомере озын булыр әле—менә ул үзе!

**Юлдаш** *(шомлы, каушап-калтыранып).* Кызым, Сәринә! Кем, килен, Бигәнәй бикә!

**Бигәнәй.** Без монда сиңа сөенечле хәбәр әйтмәкче булып торабыз,—синең анда нишләптер төсең качкан әле, Юлдаш баба.

**Сәринә.** Нәрсә булды, Юлдаш баба?

**Юлдаш** *(Сәринәгә, таләпчән).* Кая безнең батыр ирләр, кая безнең сугышчан кызлар, амага?

**Сәринә** *(каушап).* Туктале, сорау алмале син миннән, Юлдаш баба.

**Юлдаш.** Синнән сорау алыр вакыт житте, амага! Котас би көчле, Котас бине син мыскыл иттең.

**Бигәнәй.** Котас бигә нәрсә булган тагын?

**Юлдаш.** Котас бигә берни булмаган. Безгә булыр. Анысы менә көн кебек ачык. Бетте Сарайгыр, бетте, балалар!

**Сәринә.** Кода булып безгә тагын Котас би киләмени, Юлдаш баба?

**Юлдаш.** Кода булып түгел, яу булып килә!

Сәринә. Яу булып?!

Бигәнәй. Башы аягы астына гына килгере икән!

Сәринә *(аяк үрә баса, тәвәккәл).* Бетмәс Сарайгыр, Юлдаш баба! Яуга каршы—яу! Кызларымны коралландырып, барлык ирләремне алып, Котас бигә каршы мин яуга чыгам.

Юлдаш. Күпме генә кызларыңны, ирләреңне жыя алырсың икән, амага?

Бигәнәй. Яшьләр күңел ача. Аларда яу кайгысы юк.

Юлдаш. Котас би Сәринә өчен килә. Безгә хәзер икенең берсен сайларга кала: син, кызым, Сәринә, яхшылык белән Котас бигә кияүгә чыгарга ризалык бирәсең яисә сугышып аны жинәсең.

Сәринә *(Филебкә).* Илче Филеб!

Филеб. Мин сине тыңлыйм, бөек амага.

Сәринә. Үзең белән синең күпме гаскәрең бар?

Филеб. Барлыгы биш йөз.

Сәринә. Сарайгырга каршы Котас би килә. Син кем яклы, Баспур патшасының улы?

Филеб *(уйланып).* Син беләсең: мин монда сугышыр өчен килмәдем, бөек амага. Ләкин мин сине кыен хәлдә калдыра алмыйм. Мин... Сарайгыр яклы.

Бигәнәй *(җиңел сулап).* Йа Аллам! Жыясы ризыкларыбыз, эчәсе суларыбыз бетмәгән икән әле.

Филеб. Ләкин минем сезгә бер үтенечем бар.

Сәринә. Нинди үтенеч?

Филеб. Әгәр мин Котас бигә каршы сугышсам... әгәр без аласларны жинсәм... син миңа кияүгә чыгасың, бөек амага.

Бигәнәй. Баспурга, чит халыкка!

Сәринә. Мин риза.

Бигәнәй. Авызыңнан жил алгыры!

Юлдаш. Син Танайга ярәшелгән! Танайдан башкага чыксаң, сине жир йотачак, амага!

Сәринә. «Талак» әйтеп Танай миннән баш тартса, мине жир йотмаячак, Юлдаш баба.

Юлдаш *(мыскыл белән).* Кая соң ул сиңа «талак» бирәчәк Танай?

Филеб. Танай монда. Керсенме?

Сәринә. Керсен.

Филеб *(уз кешесенә).* Танайны чакыр.

**Филебнең юлдашы чыга һәм бераздан Танай белән керә. Танай баспур сугышчысы киемендә.**

Танай. Исәнмесез, әнием Бигәнәй бикә, Юлдаш баба. Исәнме, Сәринә.

Бигәнәй *(Танайга таба омтылып).* Танай, улым!

Юлдаш *(исе китеп).* Нәрсә соң бу? Өнме, төшме? Танай улым түгелме соң, чынлап та?!

Сәринә. Танай! Илгә яу килә, Котас би килә. Ул үзенә үтерелгән Барагы өчен миннән канлы үч алмакчы була. Сарайгырның киләчәге синең кулда. «Талак» бир миңа, Танай!

Бигәнәй. «Талак» бир, улым.

Юлдаш. Коткар Сарайгырны!

Танай *(тәкәббер).* Сез мине бик нык рәнжеттегез, сез мине читкә тибәрдегез. Үзегезгә кыенлык килгәч, хәзер миннән «талак» сорыйсызмы?

Юлдаш. Элеккеләрне оныт, Танай улым. Илеңне, халкыңны уйла. Баспурлар белән бергәләп Котас бине жинсәк, без сине Сарайгырның агасы итеп китәрәбез.

Бигәнәй. Танай улым ага булыр.

Сәринә. Котас бине жиңгәнне көтәсе дә юк. Ул мине үзеннән азат итсә, без аны хәзер үк ага итеп күтәрәбез, баспурлар белән бергәләп Котас бигә каршы яуга ташланабыз. *(Филебка.)* Син кире уйламадыңмы, Филеб?

Филеб. Мин әйткән сүземнән кире кайтмадым, сөеклем Сәринә.

Танай. Болай булгач, мин каршы түгел Сарайгырның агасы булуга. Тыңлагыз: Сәринәгә миннән талак, талак, талак!

## Икенче күренеш

**Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Бигәнәй бикә ялгыз. Ул еракка карап уйга калган. Каяндыр җиңелчә шау-шу, җыр авазлары ишетелеп китә.**

**Юлдаш керә.**

Юлдаш. Исәнме, кем, килен.

Бигәнәй. Исән әлегә, Юлдаш баба.

Юлдаш. Моңаясыңмы, килен?

Бигәнәй. Моңаям да, уйланам да. Мөнә шушы вакытта, кояш кичкә авышканда моңаям. Шуны әйтәм әле, Юлдаш баба, Байсар бинең күңеле нишләптер гел шул якка тартты. Баспур ягына. Шулар белән аралашып йөргән булды. Әнә, Сарайгырны хәзер баспур каплап алды.

Юлдаш. Каплап алды, килен.

Бигәнәй. Болай булыр дип күз алдына да китермәгәндер, мәрхүм.

Юлдаш. Китермәгәндер, килен.

Бигәнәй. Үзе менә кара җир астында ята.

Юлдаш. Барыбызның да төп йорты—кара җир астында.

Бигәнәй. Шулаен шулай да, кызым Сәринә дә шул якта бит әле, Юлдаш баба.

Юлдаш. Сәринә китте—дала котсызланып калды.

Бигәнәй. Бар терәгем Сәринә булган икән...

Юлдаш. Синең генә түгел, безнең барыбызның да терәге Сәринә булган. Соңлап булса да, менә шуны аңладым мин, килен.

Бигәнәй. Аңлавын аңладык та, аңлаудан ни файда?

Юлдаш. Башта ук безгә барлык баспурларны кире борып, үз илләренә кайтарып җибәрергә кирәк булган.

Бигәңәй. Танай нык торды бит, калдырабыз диде. Котас би янадан яу белән килә-нитә калса, кирәк булырлар диде.

Юлдаш. Шулай диде шул.

Бигәнәй. Без каршы килмәдек. Танайга ышандык.

Юлдаш. Ярар, тыңлале син мине, килен. Мин болайрак уйлыйм: көч сорап шунәкләргә, Котас бигә кешеләр җибәрергә кирәк безгә. Күршеләр ярдәменнән башка без бу хурлыктан котыла алмабыз кебек.

Бигәнәй. Шулай да булсын. Ләкин син әйтмәдең: Сәринәне кая куясың, Юлдаш баба?

Юлдаш. Сәринә кияүдә. Аның эше катлаулы. Сәринәдән бигрәк безгә Сарайгырны, илне-көнне коткарырга кирәк.

Бигәнәй *(ныклык белән)*. Шунәкләр дә, Котас би дә, баспурларны җинсәләр дә, ахырда Сарайгырны үзләренә буйсындырырга тырышачаклар. Сарайгырны Сәринәдән башка беркем килеп коткармаячак, Юлдаш баба!

Юлдаш. Сүзең хак, кем, килен. Болай булгач, иң элек безгә Сәринәне эзләп табарга кирәк. Кайтсын Сарайгырга. Алсын дилбегәне янадан үз кулына!

Бигәнәй. Ул кайтканчы без үзебез дә йоклап ятмабыз.

Юлдаш. Ниткән йоклап яту ди ул?! Халык ачулы. Халыкны кузгату өчен бер сүз җитә хәзер.

Бигәнәй. Синең белән миңа да килмешәккә караган кебек карый башладылар.

Юлдаш. Карамыйча! Авыз йомып, Танайны, баспурларны яклап торгач, карарлар да шул.

Бигәнәй. Моннан соң авыз йомып тораммы соң! Сәринәм генә кайтсын. Утлы табага бастырабыз әле без аларны!

**Танай керә. Аның янында ике баспур сугышчысы.**

Танай. Исәнме, инәй. Исәнме, Юлдаш баба.

Бигәнәй. Исәнлеккә ис киткән, печәнлеккә ут киткән, улым.

Юлдаш. Исәнен исән лә, Танай улым...

Танай. Мин ага булгач та таралып беттегез дип әйтимме, яшеренеп ятасыз дип әйтимме... Кирәк чакта берегезне бер табып булмый.

Бигәнәй. Нишләп без синнән яшеренеп ятарбыз икән соң, улым Танай?

Юлдаш. Әйтсәм әйтим, кем, Танай улым, ага булып алгач та син үзең безне читләштерден.

Бигәнәй. Сиңа хәзер, улым, баспурлар якынрак.

Танай. Баспур патшасы Сатир сиңа кода туры килә, инәй.

Бигәнәй. Кодасын кода инде анысы.

Юлдаш. Сатир патша кода дип монда баспурларны түргә утыртырга сиңа беркем ирек бирмәгән.

Танай *(тәкәббер)*. Мин—ага. Кемне түргә, кемне ишек төбенә утыртырга кирәклеген үзем беләм.

Юлдаш. Белүен беләсеңдер дә... сарайгырлар синнән йөз чөерә шуңа күрә. Өйләрен, мал-туарларын алып, төркем-төркем булып күршеләргә качалар.

Танай. Сез, бәлки, үзегез котыртасыздыр аларны күршеләргә качарга, инәй?

Бигәнәй. Башыма тай типмәгән әлегә.

Юлдаш. Сарайгырның таркала баруын нишләп син бездән күрәсең әле, Танай улым? Сораусыз-нисез ярлыларның мал-туарын кем тартып ала? Син! Кызларга, яшь хатыннарга кем кул суза? Син!

Танай. Мин түгел, баспурлар.

Юлдаш. Алай булгач, кайтарып җибәр баспурларның берсен калдырмыйча үз илләренә!

Танай. Сәринә Филебне безгә ярдәмгә дип җибәргәч, баспурларны колач җәеп сез каршы алдыгыз бит!

Бигәнәй. Ялгыштык, улым, ялгыштык.

Танай. Юк, ялгышмадык, инәй. Филеб—безне коткаручы, баспурлар—минем таянычым.

Юлдаш *(аптырап)*. Алайса, без кем соң сиңа... сарайгырлар кем?

Танай. Бер таянычым—баспурлар, икенче таянычым—сез... инәй, Юлдаш баба.

Юлдаш. Бер дә безгә таянганың сизелми, кем, Танай улым.

Бигәнәй. Без әле кирәкмени сиңа?

Танай. Кирәк. Күршедә генә Котас би булганда, миңа сарайгырлар да, баспурлар да кирәк.

Юлдаш *(килешүчән)*. Сарайгырның... безнең иминлекне кайгыртуың яхшы анысы, кем, Танай улым. Шулай да тынлале син миңе: олы яу узды, Котас би җиңелеп кайтып китте. Котас би безнең баспурлар белән туганлашканны белә—безгә каршы корал күтәрүдән ул хәзер тыелып торачак. Рәхмәт әйтеп, яхшылап озатып җибәрергә кирәк баспурларны.

Бигәнәй. Әйе шул, әллә ничек кенә булды. Филеб киявемне рәтләп кунак та итә алмадым. Берәр атна сыйлыйк та, озатып куйыйк үз илләренә, улым. Алар китсә, үзенә дә тынычрак булыр.

Танай *(ягымлы)*. Мин үзем дә менә шуның өчен киңәшергә дип, сезне эзләп килгән идем, инәй.

Бигәнәй. Киңәшик. Киңәшле ил таркалмас.

Танай. Башта ук шуны әйтим: минем сезгә үпкәм бар, инәй... Юлдаш баба.

Бигәнәй. Әле булса онытып бетермәдеңмени безгә булган үпкәңне, улым?

Юлдаш. Ага булам диден—булдың. Тагын нинди үпкәң калды безгә.

Танай. Баспурлар мине генә түгел, сезне дә Котас бидән коткардылар. Шулай да сез мина да, баспурларга да сыртыгыз белән торасыз. Мин инде бер айдан артык аларны үз исәбемнән ашатам-эчертәм, кунак итәм. Сез ничек тә читтә калырга тырышасыз.

Бигәнәй. Без беркая да китмәдек—үз урыныбызда, үз җиребездә яшәп ятабыз.

Танай. Ләкин Сарайгыр агасы Танай би урдасына килеп тә әйләнмисез, инәй!

Юлдаш. Яхшылап чакырсаң, барырбыз, кем, Танай улым.

Танай. Инәй! Син әле генә Филеб киявемне берәр атна кунак итәр идем диден.

Бигәнәй. Дидем, улым. Үз киявемне бер атна кунак иткәннән генә ярлыланмам, Алла боерса.

Танай. Биш йөз кешелек кунакны сыйларлык кына чамаң бар инде синең, инәй. Менә Юлдаш баба да читтә калмас.

Юлдаш. Биш йөз кешелек кунак! Бөтен бер чирү!

Танай. Булса була инде, Юлдаш баба. Тиешенчә кунак итәрбез дә, җайлап кына озатып куярбыз. Әнә барыр юллары! Баспурлар киткәч, гөрләтеп яшәрбез элеккечә, үзебезчә!

Бигәнәй *(сөенеп)*. Шулай шул, улым. Күршеләргә качкан кешеләребез дә кайтыр алар киткәч. *(Юлдашка.)* Бер атнага гына түзәрбез, Юлдаш

баба. Танай улым шулай дип торганда... Итем-сөтем житәрлек. Үзем сыйлармын. Килсеннәр, Танай улым!

Юлдаш. Кунак сыйлауга мин дә каршы түгел анысы. Ярый ла кунак булгач та кайтып китсәләр!

Танай *(ягымлы)*. Китәрләр, Юлдаш баба, китәрләр. Филеб алдында йөзгә кызыллык китерәсе дә килми бит. Баспур булса да кияү бит ул безнең. Шул кадәр ерак жирдән арып-талып килсеннәр дә, безнең өчен кан койсыннар да, ничек итеп кисәк кенә, барыгыз кайтып китегез! дип әйтәсең аларга!

Юлдаш. Ахыры хәерле булсын, балалар. Чакыр кунакларыңны.

Танай. Миңа сездән шундый сүз генә кирәк тә. *(Чыга.)*

**Тынлык. Бигәнәй бикә белән Юлдаш баба чыга. Бераздан якынлашып килгән нindидер гөрелте ишетелә. Ара-тирә өзек-өзек кычкырган тавышлар ишетелеп китә. Өйдән ашыгып Бигәнәй чыга.**

Бигәнәй. Кем кычкырды ул? Жәликә! Мамиха! Кая олагып беттегез барыгыз да?

**Жәликә керә. Кемнәндер качып ул бикәгә якынлаша. Аның артыннан баспур сугышчысы куып килә.**

Жәликә. Бикә! Коткар! *(Бикәгә сыена. Исерек баспур сугышчысы аны эләктереп ала.)*

Бигәнәй *(баспур сугышчысына)*. Кит моннан, оятсыз!

**Баспур сугышчысы бикәгә ташлана.**

Бигәнәй. Син әле шулаймыни?! *(Билендәге кынындан хәнжәрен ала, баспур сугышчысына кадый, сугышчы егыла.)*

Жәликә. Менә шул кирәк аларга!

Бигәнәй *(тынычлана алмый)*. Минем жиремдә!.. Минем ашымны ашап!... Минем кунагым булып!..

**Мамиха керә.**

Мамиха *(сүзен рәтләп сөйли алмый)*. Бикә! Бикә!

Бигәнәй. Тагын ни булды?

Мамиха *(Бикәнең күкрәгенә каплана)*. Безнең ирләрне, безнең кызларны...

Бигәнәй *(ачуланып)*. Аңлатып сөйлә!

Мамиха. Кунаклар... баспурлар... кияү... Безнең ирләрне, безнең кызларны... *(Жылый.)*

Бигәнәй *(ярсып)*. Жебегән!

Жәликә. Мин дә күрдем, бикә! Исерек баспурлар тиктомалга безнекеләргә бәйләнә башладылар. Анда талаш, ызгыш, бикә!

Бигәнәй. Акылдан шаштыгызмы әллә—ни сөйлисез?!

Жәликә. Юлдаш баба арага кермәкче булган иде—Танай үз кулы белән чәнчеп үтерде.

Бигәнәй. Уф Алла! *(Хәлсезләнеп урынга утыра.)*

**Ерактагы ямьсез тавышлар көчәя төшә.**

Мамиха. Әнә алар!

Жәликә. Монда киләләр, бикә!

**Филеб белән Танай керә. Алар сугышчы киемендә.**

Филеб *(Танайга)*. Котлыйм сине, Танаис. Синең батырлыгың, осталыгың аркасында сарматларның Сарайгыр ыруы тулысынча азат ителде. Синең тырышлыгың турында мин Сатир патшага әйтермен.

Танай *(Филеб алдында баш ия)*. Рәхмәт яусын сиңа, олуг Филеб. Әтием Сатир патшаның яхшылыгын мәңге онытмам.

**Ике баспур сугышчысы керә. Арттан килеп Бигәнәйне тотып алалар, кулларын каералар.**

Филеб *(мыскыл белән)*. О, Зевс! Сөекле Сәринәмнең сөекле әнисе Бигәнәй бикә түгелме соң син?

Бигәнәй *(Филебкә)*. Ашаган ашың тамагыңа таш булып утырсын. Үлгән чагыңда кулың-аягың тартышып, жан бирә алмый азаплан. Тфү! *(Йөзенә төкерә.)*

Танай. Нишләтергә боерасың бу тоткынны, олуг Филеб?

Филеб. Кызы Сәринә янына алып китсеннәр. Өенә ут төртегез.

**Бигәнәйне алып китәләр. Тавыш, шау-шу, жылаш.**

## Өченче күренеш

**Котас би урдасы. Өй эче. Вакыт кич. Уртада учак яна. Котас би белән Бикә ашап утыралар. Ашаучылардан читтә, ишек төбендә—сарайгыр качаклары Карт белән Кортка. Карт белән Кортка үзара сөйләшәләр.**

Кортка. Тышта кеше бар инде әллә?

Карт. Жилдер ул.

Кортка. Жил күптән тынды.

Карт. Алайса, песидер.

Кортка. Песи кеше кебек ыңгырашамыни, карт дивана!

Карт. Песи булмаса, албастыдыр.

Кортка. Бу карангыда ни калган албастыга ишек төбендә?

Карт. Ышанмагач, бар, чыгып кара.

Кортка. Карармын да шул, син чыкканны көтеп утырмам. *(Чыга. Бераздан кире керә.)* Би! Бикә! Анда кемдер бар. Котым алынды—йөрәгем ярыла дип торам.

Карт. Калган синдә ярыла торган йөрәк.

Бикә. Кем дисен?

Кортка. Ишек төбендә ята. Теләнче микән, сарайгыр микән.

Бикә. Бетмәс анда теләнчеләр, сарайгырлар. Куалап жибәр.

Кортка. Куаладым—китми. Хәлсезләнгән.

Бикә. Әйтегез бирәрсенә... өстерәп алып китсеннәр арырак.

Кортка. Үләр ул алай.

Бикә. Үлмәгәе! *(Кычкыра.)* Жәликә! Мамиха!

**Ашыгып-кабаланып Жәликә белән Мамиха керә.**

Жәликә. Бикә, син чакырдыңмы?

Мамиха. Бикә, без монда.

Бикә. Барыгыз әле тышка чыгып карагыз—анда ниндидер теләнче ята ди.

Котас *(сөяк кимерүеннән туктап).* Башта карагыз—кем? Коралы юкмы? Яшьме, картмы... ирме, хатын-кызмы?..

Жәликә, Мамиха. Карарбыз, би.

Кортка. Карадым, би. Үзе яшь, үзе хатын-кыз затыннан.

Бикә *(ачулы).* Илтеп ташлагыз берәр чокырга!

Жәликә, Мамиха. Ташларбыз, бикә.

Котас. Монда алып керегез!

Кортка. Керербез, би.

**Чыгалар. Беркадәр вакыттан барысы да кире керәләр. Жәликә белән Мамиха, ике яктан култыклап, Сәриннәне тотканнар. Сәринә хәлсез, өтәләнгән. Аны танырлык та түгел.**

Кортка. Менә ул, би.

Карт. Аягында көчкә тора. Шулай да йөрәге яхшы тибә.

Кортка. Әнә, карт диванаиың да теле ачылды.

Карт. Үзе яшь, үзе бик чибәр күренә, би.

Бикә *(ашавыннан туктап, Сәринә каршысына килә).* Адәмме, җенме син?

Сәринә. Мин... мин...

Котас *(табакка салып сөяк-санак бирә).* Мәгез, ашасын, эчсен.

**Жәликә белән Мамиха Сәриннәне аерым табын янына утырталар. Карт белән Кортка аңа ашарга-эчәргә китерәләр. Сәринә ашый, эчә.**

Жәликә *(Сәриннәне таный, куркып кычкырып җибәрә).* Әнекәем!

Мамиха *(шулай ук таный, Жәликәнең авызын томалый).* Ш-ш-ш!

Карт *(уз алдына).* Әллә күземә күренә инде?

Кортка. Тфү, тфү! Ул түгелдер.

Бикә *(тынычсыз).* Бием! Йокларга вакыт. Иртәгә торасы да бар.

Котас *(майлы авыз-битләрен сөрткәләп, тук кыяфәт белән беравык кәефләнеп утыра).* Каяле, китерегез әле монда. Инде хәл кергәндер.

**Жәликә белән Мамиха, икесе ике яктан култыклап, Сәриннәне аягына бастыралар һәм Котас би каршысына китерәләр. Икесе дә тавышсыз гына жылыйлар.**

Сәринә. Менә мин... Сәринә...

Котас *(урыныннан сикереп тора).* Сәринә?!

Кортка *(Сәриннәне кочаклый).* Сәринә балакаем!

Карт. Кызым, Сәринә! *(Кочаклый.)*

Бикә. Шул булмыйча, шул! Ташландык! Сөйрәлчек!

Жәликә. Жыгылганны түбәләмиләр, бикә!

**Мамиха** *(Сәринәне Бикәдән гәүдәсе белән каплап).* Бикә! Авыр сүз әйтмә безнең Сәринәгә!

**Бикә** *(тузынып).* Килмешәкләр! Тамагыгыз туйдымени?! телләшә башладыгызмени?! Ат койрыгына тактырам әле мин сезнең барыгызны да!

**Котас** *(Бикәне читкә этәреп).* Бар әле, бар, йокларга ят. Иртәгә торасың да бар.

**Бикә** *(шыңшып).* Йокылар качты болай булгач. *(Чыга.)*

**Җәликә белән Мамиха да, картлар да чыгалар.**

**Сәринә** *(табактагы калдык-постыкларны ашаган арада әкрен генә сөйләнә).* Гажәпләнмә син, Котас би. Сәринә мин. Дүрт тәүлек буена берни капмадым. Төнлә кайттым, көндез качып яттым...

**Котас** *(мыскыл белән).* Син бит җинүче! Мине җиңгән кеше. Нишләп алай минем табакны яларга кайтасы иттең?

**Сәринә** *(тыштан тыныч, гамьсез, эчтән—киеренке).* Синең табакны яларга кайттым, Котас би. Гажәпләнмә син. Кеше булсаң, андый гына нәрсәләргә исең китмәсен.

**Котас**. Таный башладым мин сине, теләнче хатын. Син чыннан да минем Барагымның башын чапкан Сәринә бугай.

**Сәринә**. Шул үзе, Котас би. Син әле аның әнисен дә беләсеңдер. Бигәнәй бикәне.

**Котас**. Белмәгән кая ул!

**Сәринә**. Менә шул Бигәнәй бикә белән Сәринәне Сатир патша төрмәгә яптырды. Бигәнәй бикә акылдан язды, Котас би. Шунда төрмәдә җан бирде.

**Котас** *(авыр сулап).* А-а-а. Яхшы күңелле хатын иде. Урыны оҗмахта булсын.

**Сәринә**. Каравылчыларны алдап... качтым мин, Котас би. Сатир патшадан, баспурлардан качтым.

**Котас**. Шулай да нишләп минем бусагама килеп җыгылдың—шунысы аңлашылмый.

**Сәринә**. Мин далама, халкыма кайттым.

**Котас**. Синең инде далаң да, халкың да юк, сатлык Сәринә!

**Сәринә**. Син миңа теләсә нинди сүз әйтә аласың, тик миңа «сатлык» кына димә, Котас би.

**Котас**. Син даланны, халкыңны ташлап, чит халыкка, дошман халыкка биреләдең. Сатлык булмыйча, кем соң син?!

**Сәринә**. Сатир патшаның улына кияүгә чыгып мин үз халкымны талаудан, хурлыктан коткарам дип белдем, уйладым.

**Котас**. Син аңа бары талау, хурлык кына китердең!

**Сәринә**. Барысы өчен дә җәзасын татыдым инде мин, Котас би.

**Котас**. Миңа качып чыккан сарайгырларны кире алырга җыенмыйсындыр ич син, Сәринә бикә?

**Сәринә**. Бирсәң, каршы килмәм.

**Котас**. Борыным төште дисең инде, ә? Хәтерлисеңме, теге вакытта син бөтенләй икенче төрле сөйләшкән идең?

**Сәринә**. Мин барысын да уйлап, белеп килдем. Син минем кичәге дошманым. Шулай да бөтен далада, бөтен дөньяда синнән якын беркемем юк минем, Котас би.

**Котас**. Якын кешегә бүләк алып киләләр. Син ни алып килдең?

**Сәринә**. Мин сиңа ике башның берсен алып килдем, Котас би.

**Котас**. Каяле, мондамы ул? Күрсәт миңа Барагымның бәхетсез башын!

**Сәринә**. Ул тегендә калды. Аны барып яулап аласы бар.

**Котас** *(үзгәреп, Сәринәгә таба атыла).* Төшендем мин сине, Сәринә! Мин ант итәм... хурланган яшьлегең өчен, тапталган җирең-суың өчен, коллыкка төшкән халкың өчен үч алырга мин ант итәм! *(Сәринәне кочмакчы була.)*

**Сәринә** *(чигенә).* Синнән шундый сүз ишетү—минем өчен зур бәхет, Котас би.

**Ишек артында шау-шу. Артлары белән чигенә-чигенә Җәликә белән Мамиха, Карт белән Кортка керә.**

**Кортка** *(ярым пышылдап).* Шауламагыз, биебез йоклый.

**Котас** *(ишек ягына кычкыра).* Кем бар анда? Мин йокламыйм.

**Җәликә**. Би! Алар күп!

**Котас**. Кем кирәк, нәрсә кирәк аларга?

**Мамиха**. Алар Сәринәне күрмәкче булалар.

**Котас**. Керсеннәр.

**Ашыгып, бер-берсен узышып ирләр, хатын-кызлар керә.**

Т а в ы ш л а р:

—Сәринә кайткан диләр—дөресме шул?

—Сәринәне күрәсебез килә!

—Сәринә белән сөйләшәсе сүзебез бар!

С ә р и н ә *(керүчеләр ягына борыла).* Туганнар! Сарайгырлар!

Т а в ы ш л а р.—Без—шунәкләр!

—Без дә синең туганнарың, Сәринә!

С ә р и н ә. Туганнар! Сарайгырлар, шунәкләр! Мин сезнең янга кайттым. Сез мине кире какмыйсызмы?

Т а в ы ш л а р.

—Син безнеке, Сәринә!

—Син безнең амага, Сәринә!

—Без синең белән, Сәринә!

К о т а с. Сармат даласында Сәринәне белмәгән кеше юк. Баспурга каршы, Танайга каршы син кузгалсаң, бөтен дала сиңа иярәчәк. Бүгеннән башлап мин үзем сиңа буйсынам, Сәринә!

С ә р и н ә. Таш сарайларга каршы, таш төрмәләргә каршы без бөтен Сармат илен аякка бастырырбыз! Сарайгырлар, шунәкләр, аласлар... бергәләп без хыянәтче Танайны, баспурларны юк итәрбез, туган далабызны хурлыклы коллыктан коткарырбыз!

К о т а с *(Сәринәгә якынрак килеп).* Шуннан соң син минеке булырсыңмы, Сәринәм?

С ә р и н ә. Дошманнарны җиңгәч, тегендә калган бәхетсез башны коткаргач... мин синеке булырмын, Котас би. Шуннан соң ике баш та синеке булыр, Котас би!

Т а в ы ш л а р.

—Баспурга—үлем!

—Танайга—үлем!

—Яшә, Сармат!

—Яшә, Сәринә!

**Барысы да Сәринәне күтәреп алалар, югары чөяләр. Гомуми тантана.**

## Соңгы күренеш

**Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Таң ата, кояш чыгып килә. Якындагы өйдән Кортка чыга.**

К о р т к а *(кире борылып, ишек ягына кычкыра).* Синайтәтәм, тордыңмы?

**Өйдән карт чыга.**

К а р т. Ә? Нәрсә?

К о р т к а. Әнә, кояш чыгып килә. Нинди матур, Илаһым!

К а р т *(кояш ягына карап).* Тагын бер көн яшисебез бар икән әле бу якты дөньяда.

К о р т к а *(тезләнеп, адарынып, кулларын югары күтәрә).* Тәңрем-Аллам, изгелегеннән ташлама без гөнаһлы бәндәләреңне!

К а р т *(тезләнә, адарынып, кулларын югары күтәрә).* Бар ышаныч синдә, Раббым. Илгә иминлек бир, бигә—акыл, үземә көч-куәт бир!

К о р т к а. Җыясы, ризыкларыбыз, эчәсе суларыбыз бетмәсен, Илаһым!

И к е с е б е р г ә *(дога кылып).* Амин! Шулай булсын!

**Аягүрә басалар, күтәрелеп килгән кояшка карап, сокланып торалар да ашыкмыйча гына өйләренә кире кереп китәләр. Җиһанда балкып кояш чыга.**

*Пәрдә ябыла.*

Şiğriət
Шигърият



## Госман Садә

### КАРИДЕЛ АРЪЯГЫНДА

Төркиләр—күк уллары...
Күктән килә юллары...

Күлмәкләре—ак канат.
Канат саен каһанат...

Челләдә, бик эсседә
Әнкә-Су—Енисейдә

Юам канат-күлмәгем.
...Искә төшә Күлтәгин.

### Госел

И диндәш кардәшем! Ходайдан син сөел,
Уян да таң белән иң әүвәл кыл госел.

Хак Раббы илчесе безләрне өйрәтте:
«Зиһенгә юл ача тере су кодрәте».

Кыйблаңа йөз борып, йөзеп кер догаңа—
Яңа көн яудырыр бәрәкәт дөньяңа.

---

Госман САДӘ *(1949)—шагыйрь, «Мәхәббәт елы», «Җиләкле тәрәзәләр», «Тайфун күзе» китаплары авторы. Казанда яши.*

~

*«Курск» атом су асты көймәсе фаҗигасеннән соң язылган шигырь*

Батты суга Рәсәй балтасы...
Су төбендә чумды йокыга
Йөз унсигез газиз баласы.

Яшәр чакта гына балкып ла...
Балык кебек, диңгез төбеннән
Чыгалмады алар калкып ла.

Дулкын җыры моңсу—бик таныш...
Рәсәй тагын-тагын алдады:
Алмалардай гомер—аяныч!

Кемгә кирәк соңын аклану...
Балтаң ничек суга төшмәсен—
Бу ничәнче безнең алдану!

Йомык күзләр—гомер төймәсе.
Көтә тагын-тагы кемнәрне
Су төбендә үлем көймәсе?..

Диңгез безгә—кайгы кардәше...
Бардыр җаны... җаны суның да—
Суга тама кайнар күз яше.

~

Кара төндә карый сөзеп
Кара көзнең кара күзе.
Кара ташта кара елан—
Каргыш сыман кала эзе.

Кара елан урын эзли
Көзге төннең карасында
Кара янып йоклар өчен
Кара ташлар арасында.

Йомарланып йомгак сыман,
Күзен йома кара елан.
...Тизрәк теләп котылырга
Кара төннән, караңгыдан—

Уяна таң!
Кара көзнең
Эзе дә юк—ап-ак булган.
Ап-ак кышта ап-ак ташта
Уйнап йөри ап-ак куян.

~

Бәлкем, син йөзек кашыдыр
Фәрештә бармагында...
Ак чатыр кордым сиңа дип
Каридел Аръягында.

Ай юлы килә сузылып
Аргы ярдан бу ярга.
Яр буйлап кил син йөгереп
Елга шавын тыңларга.

Фәрештә үзе күренми...
Кирәкме эзләп йөрү?
Ай, чатыр шаһит: булыр бу
Оҗмахка безнең керү.

Мин керермен янган утка,
Сине аралап,
Ялкын теле алса әгәр
Ялмап-аралап.

Кураләтә утка керү—
Сирәкләр эше.
Утсыз гына гомер кичә
Җирдә күп кеше.

Утлы юллар билгелидер
Гомер агышын.
Янар таулар түбәсенә
Менеп барышым...

Тарта күрмә җиң очымнан
Аска өстерәп.
Йөрәк кенә таулардан да
Яна көчлерәк.

Алар минем йөрәгемнән
Алыр җыр отып.
Янар таулар, янар алар
Безне җылытып.

## Өстенлек кылса бер тел...

Картаялар сүзләр дә,
Теше төшкән атлардай.
Китә тора картлар да
Сүз кадерен саклардай.

Бер телдән икенче тел
Кыла икән өстенлек,
Югала сүзләр эреп,
Комга сеңгән су кебек.

...Аңламыйм күп сүзләрне,
Картаеп алар үлгән.
...Картайсак әгәр без дә...
—Ни калыр туган телдән???

## Кипарис

Урман арты,
Урман аръягында
Үсә, дисә кемдер,—кипарис.
Мин ышанам шушы илаһ сүзгә,
Илаһилык безгә ул фарыз.

Кипарисны, сеңел, сиңа тиңлим:
Сокланасың иртән күргәндә.
Ул үзе дә сиңа карап тора,
Чәчләреңне иртән үргәндә.

Синең көлү килә еллар буйлап,
Яктыдан да якты юл сызып.
Уйда гына иртән каршы алам,
Таң нурыдай балкып-сызылып.

Урман арты, Урман аръягында
Үсә, дисә кемдер,—
Кипарис.
Ышан, сеңлем, шушы гүзәл сүзгә:
Бу урманга үзең сыйган ич!

Язганнарым минем—җыр юлдашы,
Уем ерак яман-ялганнан.
...Бер Кипарис үсә урманымда.
...Җырым өчен сакла, йа Аллам!

## Сөю таҗы кигән таулар гына

Сонет

Мин үтенәм синнән: сөй син мине!
Сине көтәм—айлы кич җитә.
Бу сөюнең җирдә булмас тиңе,
Хис акылны били—исертә.

Учак ягам. Нуры сиңа илтә
Хисләремнең кечке күкрәвен.
Тулган айның йөзен хәтерләтә
Ярым ачык ап-ак күкрәгең.

Кичке шәфәкъ җиргә иңү белән,
Мин туктатып ялгыз биюеңнән,
Чакырырмын сине тауларга.

Ява анда ап-ак карлар гына...
Сөю таҗы кигән таулар гына
Яратылган безне аңларга.

## Дүртъюллыклар

I

Кеше үлгәч, җаны кая китә?
Югаламы эреп бер эссез?
Тере чакта моны кем дә белми,
Үлгәч кенә бары белерсез.

II

Яз җитүгә җирдә гөлләр калка,
Гөлләр белән тула һәр тараф.
Кеше үлгәч, җаны гөлгә күчә...
Булма, берүк, гөлгә битараф.

III

Картайсаң да үзең, җан картаймый.
Бу сүзләрне бик еш ишетәм.
Җаным күккә очар... соңгы тапкыр
Чыккан чакта гәүдәм ишектән.

IV

Бер күбәләк кунган тәрәзәмә...
Иреккәдер тели чыгарга.
Аңлыйм аны: ул да кемдер җаны.
Кеше җаны тиеш очарга!



# Резеда Вәлиева

## Бәхетле булыгыз, дусларым!..

Күңелемә моң тулган, җыр туган чакларда
Ашкынам тик сезнең якларга.
Күкрәгем тарсына, йөрәгем ярсына,
Ярсына сез дуслар каршына.

Җырларым, моңнарым—тик сезнең өчендер,
Тик сезнең өчендер—бу гомер юлларым.
Җырларым көч бирсен, хисләрне үстерсен,
Тибрәтеп күңелнең иң нечкә кылларын...

Тыңлагыз җырымны, тыңлагыз, дусларым,
Яңа җыр—мәхәббәт турында.
Зур булыр бәхетем: сөюем, рәхмәтем
Әйтәлсәм сезгә бу җырымда.

Әйтәлсәм әгәр дә ни диеп көенеп
Типкәнен тынгысыз йөрәгем:
Туганлык һәм дуслык, халкыма тынычлык—
Дөньяда иң олы теләгем...

Кошлардай сайрашып, очрашыйк җырлашып,
Җырларда очрашыйк без тагын.
Гомерләр тиз үтә, аерылыр чак җитә,
Бәхетле булыгыз, дусларым!..

## Әй туган җир

Әй гомеремнең иң бәхетле, иң кадерле чаклары,
Оныта алмадым сезне, мәңге җанымда сакладым.
Тын гына агып яткан чишмә буйларында һаман
Пар чиләкләрем мине зарыгып көтәләрдер сыман.

Сандугачлар да мине сагынып сайрыйдыр кичләрен,
Әй туган җир, сиңадыр иң назлы, иң саф хисләрем.
Сиңадыр җырларымның иң моңлысы, иң дәртлесе,
Сиңадыр сөюемнең иң татлысы, ләззәтлесе...

---

Резеда ВӘЛИЕВА—*шагыйрә, «Якты йолдызым», «Ялгыз аккош», «Китмә, сөю» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Еллар гына булсын әй, тыныч...

Мин бәхетле көннәр кичерәм,
Алма исләреннән исерәм.
Ләззәтләнәм кошлар чыңыннан,
Алтын көзнең татлы тыныннан...

Ә көз авыр-авыр тын ала,
Бер туктый да тагын кузгала.
Көзләр быел килде уңышлы,
Ходай мулдан бирде уңышны...

Кая баксаң, анда мал-мөлкәт,
Кая барсаң, анда мул уңыш.
Бу тарафтан юктыр куркыныч,
Еллар гына булсын әй, тыныч...

## Иделем иртәсендә

Иртән торсам, бар җиһанга кояш тулган,
Бөтен дөнья нурга манган кебек булган.
Тирә-якта шундый да бер рәхәт тынлык,
Бу дөньяның бар мәхшәрен оныттырлык.

Хәйран калам, нинди матур бу дөньялар,
Мондый гүзәллекләр тагын йә кайда бар?
Кайларда бар мондый ләззәт, мондый хозур,
Һәр иртәсе үзе бер моң, үзе бер җыр...

Кошлар тавыш биреп куя чут-чут итеп,
Җилләр шундый йомшак кына үтә исеп,
Әйтерсең лә хак тәгаләм җаным тоя,
Юаткандай, чәчләремнән сыйпап куя...

И табигать, и кодрәтлем, и гүзәлем,
Алларыңда башым иеп тезләнәмен,
Бу дөньяда яшәү биргән, үстергән—син,
Җырларыма илһам өргән, көч биргән—син.

Сабый чактан сине сөйдем, зурладым мин,
Гомерем буе сине яклап җырладым мин.
Яшим һаман илһамланып синең белән,
Синдә янә бер сабый мин: елыйм-көләм.

Синең белән бар рәхәтем, бар бәхетем,
И табигать—мәңге сүнмәс мәхәббәтем...

## Бирче, Тәңрем, бир бер терәк...

Ни күрсәм дә, кимсенсәм дә,
Тугры калдым антыма мин.
Күңелемнән моңнар чәчтем
Газиз туган халкыма мин.

Түздем бик күп әйберләргә,
Кыерсыту, җәберләүгә,
Үз халкымның күңелен тоеп
Җырлау бәхетен өстен куеп...

Ниләр генә булды бүген,
Болыт сарды күңел күгем.
Өмет утым сүнеп калды,
Талмас җаным кинәт арды...

Әй бер Тәңрем, сузчы кулың,
Ач күземне, күрсәт юлың.
Өзелмәсен өметләрем,
Сүрелмәсен күңел җылым.

Кайда кояш, кайда якты,
Күңелемә нур каян табыйм?
Рухым, җаным сүндермәскә
Ут алырга кемгә барыйм?

Уңга да юл, сулга да юл,
Кая карыйм, кая атлыйм?
Бу мәхшәрдә якты рухым
Каралтмыйча ничек саклыйм?..

Якты җырлар тусын өчен
Җанга якты өмет кирәк.
Сүнмәсен лә якты рухым,
Бирче, Тәңрем, бир бер терәк...
Бир бер терәк...

## Тик бер йөрәк әгәр сагынса...

Җан җылымны кушып җырлар язам,
Назлы күңелләргә үтсен дип.
Мәхәббәтем булып үз халкыма
Моң-җырларым барып җитсен дип.

Җырларымда минем үз халкымның
Кайгы-шатлыклары чагыла.
Әле тургай булып кагына алар,
Әле моңнар булып агыла...

Җырлап килдем яшьлек язларыма,
Җырлап яшим әле бүген дә.
Бәхет санар идем тик бер җырым
Калса әгәр халкым күңелендә.

Давылларга тарган бәгырьләргә
Ләйсән яңгыр булып кагылса,
Җырларымда танып җан җылымны,
Тик бер йөрәк әгәр сагынса...

## Рәхмәт сиңа, бәгърем...

Көтмәгәндә берәү очкын атып,
Ут дөрләтсә кинәт җанымда,
Кинәт дөрләгән ут кинәт сүнә,
Син каласың һаман янымда.

Көзләр килгән саен сагайдым мин,
Салкын үтмәсме дип җаныма.
Үтәлмәде һичбер салкыннар да
Син булганга һәрчак янымда.

Яндырмый да артык, көйдерми дә,
Сүндерми дә яшьлек ялкынын,
Син киләсең саклап җан җылысын,
Рәхмәт сиңа, бәгърем, алтыным...

## Исеңә ал бу балаңны...

И лә газиз туган җирем,
Ипи тәмен тойган җирем,
Тик синдәдер тиңсез бәхетем—
Үз телем, үз моңым минем...

Шуңа дадыр җаным эреп,
Җирдәге оҗмахтай күреп
Яшим сине сөеп-зурлап,
Назлар тулы җырлар җырлап.

Җырларымны халкым алса,
Йөрәк түрләренә салса,
Юктыр миннән бәхетлерәк,
Шуннан артык йә, ни кирәк?..

И шәфкатьле халкым минем,
Мин бер нарасыең синең,
Тойган саен сөю-назың,
Нечкәрәдер йөрәк сазым...

Мәхәббәтең җылы бирә,
Җаннарымны назга төрә,
Күңелем сүнсә, ул үстерә,
Мин бәхетле шуңа күрә.

Әйтер сүзем сиңа тагын:
Бер көн килеп сүнсә таңым,
Бөтенләйгә китә алмам,
Синдә калыр минем җаным...

Якты язлар килгән саен
Ал чәчәк булып калкыр ул,
Таңнарыңда, былбыл булып,
Моңлы сайрап уятыр ул...

Шул чагында тәрәзә ачып,
Тып-тын калып тыңла да аны,
Назлы-йомшак сүзләр белән
Исеңә ал бу балаңны...



## Рафаиль Хәким

# КЕМ СИН, ТАТАР?

### I. Бердәмлек

КҮҢЕЛ ТЫНЫЧ түгел...

Татарларга бер өшәке сыйфат хас: төркемнәргә бүленеп бер-берсен ашау. Бу турыда күпләр язып чыкты. Мин дә кеше язмышларының борылышларын күзәтә-күзәтә үз-үземә сорау бирәм: нигә шулай? Татар милләтенең хәле болай да җиңел түгел, ләбаса. Ни өчен өстәмә кыенлыклар китереп чыгарырга?

Казанда гына түгел, татар яшәгән теләсә нинди шәһәрдә, районда, авылда, имеш, мөһим дип саналган мәсьәләләр тирәсендә вак-төяк ыгы-зыгы бара. Мәскәүгә барсаң, татарлар белән очрашу да күңелсез: берәүләр икенчеләренә пычрак ата, гел кемнедер каяндыр бәреп төшерү белән мәшгульләр, синең шуларны хуплавыңны өмет итәләр. Ә нәрсәне хупларга соң? Аңлашылмый. Шәхси амбицияләрнеме, кухня тирәсенә хас вак-төяк проблемаларнымы? Россиянең һәм БДБ илләренең башка шәһәрләрендә дә шулай ук—күпләр үз милләттәшләре белән көрәштә хакыйкать эзләп, яшь түгеп хатлар язалар.

Вак-төяк амбицияләр халык язмышыннан өстен була башлады.

Татарларның бер-берсенә каршы көрәшенә күпме көч китте, гәрчә бар каршылык "тегеләренең" бары тик башка оешмадан яки башка институттан, башка урамнан яки башка йорттан булуыннан гына гыйбарәт иде. "Безнең кеше" дигәндә татар кемне күзаллый икән соң алайса?

"Мирас" журналы Мирфатыйх Зәкиев белән бәхәс кузгатты, аны озак елларга сузып, суд юлларында йөрде. Символик күренеш. Без буыннан-буынга мәдәниятебез мирасын гына түгел, ыгы-зыгыны да күчерәбез, ә ыгы-зыгы, мәгълүм ки, шайтан гамәле.

---

Рафаиль ХӘКИМ *(1947)—Татарстан Президентының сәяси мәсьәләләр буенча дәүләт киңәшчесе, Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры. «Семь осенних вечеров», «Сумерки империи», «История татар и Татарстана» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Россия Федерациясенең Конституция судына Татарстан Конституциясен гаепләгән дәгъваны әллә каян, әллә кем түгел, нәкъ менә үзебездә яшәгән үз татарыбыз—Азнакай районыннан Марсель Сәламов язып җибәрде. Ул үз республикасы һәм үз халкы белән судлашты. Аның татар булуы оят, минем әнием туып-үскән районнан чыгуы оят.

Амбицияләр канәгатьләндерелде. Һәркем үз хакыйкатенә тугры калды. Күпме вакыт әрәм булды. Күпме көч юкка сарыф ителде.

Татарга мондый сыйфат каян килгән? Мин бу сорауга җавап таптым шикелле. Коллык психологиясеннән һәм мескенлектән. Күп гасырлар буе татарны бүлгәләп, берсенә-берсен өстереп идарә иттеләр. Мондый вәзгыятьтә үз көченә ышанмый башлыйсың. Моны, бәлки, башкача да аңлатып буладыр?

Үз вакытында Столыпин татарларның һәрбер этник төркеменнән үз әдәби теле булган аерым халык ясарга тәкъдим иткән һәм шуның белән милләтне юкка чыгарырга ниятләгән.

Большевиклар бу сәясәтне уңышлы дәвам иттеләр. Картада үзбәкләр, кыргызлар барлыкка килде. Ашыгыч рәвештә башкорт теле һәм башка милли "кирәк-яраклар" уйлап табылды. Башкортларның визит карточкасы сыйфатында үзенчәлекле бер бию туды, анда җегетләр төлке койрыгы таккан бүрекләр киеп биилер. Әлеге биюне, уйлап чыгарып, сәхнәгә куючы Фәйзи Гаскәров—60 нчы елларда, Казанда фатир ала алмаганга, Уфага күчеп киткән татар. Бу бию—сәхнә тезелмәсе. Халкы да нәкъ шулай оештырылган, әмма башка сәхнә—сәясәт сәхнәсе өчен.

Большевиклар эшне киң колач белән алып бардылар. Кавказ татарлары әзәрбәйҗаннарга гына түгел, кумыкларга, балкарларга, карачайларга әверелде. Иң мәшһүр шәхесләре—Казан патшабикәсе Сөембикә булган нугайлар мөстәкыйль халыкка әйләнделәр. Ә Сөембикәнең ире Сафа Гәрәй бөтенләй башка халык—кырым татарлары вәкиле булып чыкты. Алайса, Казанда нишләп ятканнар соң алар? Казан татарлары бу "килмешәк"ләрнең хан тәхетендә утыруына ничек чыдап торган? Бу сорауга җавап бик гади: чынлыкта болар барысы да—Алтын Урда чорында оешкан бер халык. Татарлар Казанда, Әстерханда, Себердә, Касыймда, Кырымда, Мишәр җирендә, Нугай, Башкорт далаларында һәм башка җирләрдә яшәгәннәр, шуңа күрә төрлечә аталганнар: казан, әстерхан, себер татарлары, мишәрләр, кырым татарлары, нугайлар һәм башкортлар. Себердә яшәүче урысларны сибиряк дип атыйлар, ләкин алардан аерым халык ясап "себер урыслары" дип атарга берәүнең дә башына килми. Әгәр дә этнографлар һәм сәясәтчеләр бераз тырышсалар, халыкны шулкадәр бутарга мөмкин ки, алар "без урыслар түгел, без—сибиряклар" дип әйтәчәк. Аларга себер милли киемнәре, биюләре, аерым сөйләш уйлап табачаклар. Һәм тагын бер милләт әзер дигән сүз.

Милли сәясәт нигезендә һәрвакыт ялган яткан.

Хәзер РФ Хөкүмәте карары буенча нугайбәкләр аз санлы аерым халык булып санала, дөрес, алар хәзергә татарча сөйләшәләр. Инде берничә ел себер татарларын һәм аларның аерым телен оештырып маташалар, моңа безнең галимнәр дә бик актив булыша. Сәясәтчеләр керәшен дигән мөстәкыйль халык уйлап таптылар. Аларны Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты гына түгел, Милли мәсьәләләр комитеты аркылы Дәүләт Думасы да, Идел буе федераль округы да, хәтта Патриарх үзе дә яклый. Керәшеннәр керәшен телендә түгел, шул ук татар телендә сөйләшә, керәшен җырларын түгел, шул ук татар җырларын җырлый, татарча бии. Керәшеннең тик православный диндә генә булган шул ук татар икәнлеге күзгә бәрелеп торса да, хәзер моны дәлилләү җиңел булмас. Асылда исә керәшеннәр—төп татарлар. Нәкъ менә керәшеннәрдә генә татар культурасының борынгы катламнары сакланган. Ә бит хәзер кемнәрдер керәшеннәрнең мөстәкыйль этнос була алачагына ышана да башлады. Ачык һәм мәгънәле максаты булмаган халык теләсә нинди абсурдны кабул итәчәк. Столыпин сәясәте тантана итә.

Күңелегезне киң тотыгыз—эш әле типтәрләргә, мишәрләргә, әстерхан татарларына да барып җитәчәк. Яңа халыклар барлыгын заказ буенча

игълан итүче активистлар да табарлар. 2002 елда халык санын алу өчен хәзерләнгән милләтләр исемлегендә татарлардан тыш мишәрләр һәм Казан татарлары аерып куелган. Хәзер Казанда яшәп ятучы, әмма нәселендә мишәрләр булган татар үзенең кем икәнлеген билгеләр алдыннан бик каты уйланырга мәҗбүр. Кем ул: татармы, Казан татарымы йәисә мишәрме? Этнология һәм антропология институты халыкларга теләгәнчә ялганлый, ә татарлар, бер сүз дәшмичә, барысына да түзә, ә кайберләре бу кыланышларны ачыктан-ачык хуплый.

Озакламый Минзәлә татарларын Арчаныкылардан аерып куярлар. Һәммәсенең үз теле, үз графикасы, үз әдәбияты, үз геройлары барлыгы ачыкланыр.

Милләтнең көче кая сарыф ителгәнен "болгарчылар" мисалында күп елларга сузылган мәгълүм фарс ачык күрсәтә. Алар "болгар" дигән мөстәкыйль халыкны рәсми рәвештә танытырга тырышып озак азапландылар. Судлар аркылы паспортларына "болгар" дип яздырырга йөрделәр, моның белән горурландылар. Ә хәзер исә Россиянең яңа паспортларында "милләт" графасы бөтенләй бетерелде. "Болгарчылар"ның тормыш мәгънәсенә тиң олы эшләре кирәксез булып чыкты. "Болгарчылар" кемнеңдер заказын үтәделәр һәм бүген аларның татардан башка беркемгә дә кирәкләре юк.

Керәшеннәрне дә, себер татарларын да, башкортларны да шул ук язмыш көтә. Алар—бүгенге зур сәяси уенның тамгалы кәртләре генә. Һәм, асылда, татарлардан башка беркемгә дә кирәк түгелләр!

Колларга хуҗалары кухнясында бер-берсен ашарга язган.

Хикмәт Столыпинда, большевикларда һәм федераль үзәк сәясәтендә генә түгел. Озак еллар буе иң күренекле галимнәр татар теленең диалектларын эзләү белән шөгыльләнделәр, мәдәниятнең иң нечкә үзенчәлекләренә үтеп керүләре белән масайдылар. Алар мишәрләрнең, себер һәм әстерхан татарларының гына түгел, Пермь, Казан арты, Чистай, Сергач, Биектау, Азнакай һәм башка татарларның да бер-берсеннән аерымлыкларын таптылар. Диалектлар үрчетү белән мавыгып, халыкның бердәмлеге турында тәмам оныттылар. Галимнәрне аңлап була: диссертацияләр яклау да мөһим эш. Ләкин алар фикерен халык тыңлый лабаса. Аларга ышана. Сүзләрең һәм гамәлләрең өчен җаваплылык үлчәме булырга тиештер бит инде!

Галимнәрнең зур-зур төркемнәре "Идегәй" дастанының вариантларын тикшерделәр һәм аның казах, нугай, башкорт, татар һәм башка вариантларын бастырып чыгардылар. Авторы да бер үк, теле дә бер үк, дастаны да бер үк иде, югыйсә. Төптәнрәк уйласаң, халкы да бер үк бит.

Бер галимгә мәсьәләнең асылын аңлату өчен, әтием Сибгат Хәким иҗатыннан бер мисал китердем. Сугыш елларында аның сүзләренә язылган "Юксыну" дигән җыр халык җырына әверелгән. Һәм фольклорчылар аның төрле районнарда 34 вариантын тапканнар. Хәтта бер мәзәк хәл дә булган. Бервакыт әти бер мәҗлестә үзенең шушы җырын җырлаганнарын тыңлап утыра икән. Кунаклар арасында бәхәс купкан. Берәү икенчесенә, сүзләрен дөрес җырламыйсың, дип бәйләнә, ә тегесе үз вариантын яклый, ди. Алар җырның өстәл янында моны елмаеп күзәтеп утыручы авторы барлыгын да онытканнар. Бәлки, "Идегәй" дастанының авторы да күкләрдән шулай күзәтеп торадыр? Әмма елмая микән ул? Галимнәребезнең көчәнүләренә карап, күңеле әрнидер аның. Бар көчне автор вариантын торгызу өчен куеп, сәясәтчеләр белдеге белән төрле халыкларга бүлгәләнгән төркиләр арасында "Идегәй"нең нәкъ менә шул бердәнбер вариантын таратасы иде дә бит...

2002 елда халык саны алу алдыннан Мәскәү демографлары татарларны бүлә башлагач, шунысы ачыкланды: безнең галимнәребез генә түгел, иҗтимагый оешмаларыбыз да халыкның бердәмлеге максатында эшләмәгән икән. Ни эш кырганнар соң алар? Татарларның бөтендөнья конгресслары шау-шулы тантана итеп уздырылды. Аннан соң башкарма комитет күпсанлы очрашулар, концертлар, җыелышлар үткәрде һәм ун ел гомер сизелмичә узып та китте. Нәрсәгә ирештек соң? Нугайбәкләр бездән аерылды, керәшен һәм себер татарлары без—мөстәкыйль халык дигән дәгъва белдерде, татар-башкорт мөнәсәбәтләре тәмам буталып

бетте. Өстәвенә, латин графикасына күчүгә Дәүләт Думасы гына түгел, конгрессның икенче съездында шуны яклап тавыш биргән кайбер татарлар да каршы төште.

Милли-мәдәни автономияләр кәгазьдә генә яши. Алар халык тормышында ни сәяси, ни икътисадый, ни мәдәни фактор була алмадылар. Әлеге оешманың мөмкинлекләр киңлегенә карамастан, эшчәнлек нәтиҗәләре бик түбән, һәрхәлдә, федераль дәрәҗәдә бернинди нәтиҗәсе юклыгы анык. Бүген татар сабантуй үткәрүдән гайре зур эшләргә сәләтсезмени?

Безнең эшкуарларыбыз кайда соң? Татарларның күбесе акча эшли белә һәм татар тарихы, мәдәнияте турында сүз куертырга да ярата. Кайберләренең хәтта бу хакта үз фикерләре дә бар. Шул ук вакытта мәдәни үзәкләр мохтаҗлыктан интегә һәм Татарстаннан ярдәм көтә.

Революциягә кадәр татарларның мәгариф системасы тулысы белән эшкуарлар акчасына эшли. Шушы җирлектә Казанда гына түгел, Уфа, Оренбург, Троицк, Петербург һ.б. шәһәрләрдә татарның көчле мәдәният үзәкләре барлыкка килә. Бүген исә татар эшкуары, матбугатка акча биргәнче, иске "мерседес"ын яңага алмаштыруны кулайрак күрә. Иң яхшы татар журналы "Шура"ны һәм иң яхшы татар гәзите "Вакыт" ны үз акчасына чыгарган бертуган Рәмиевлар юк шул инде бүген. Безнең татар эшкуары, акча-фәлән җәлләмичә, бай мәҗлес үткәрә ала. Я булмаса мәчет төзергә акча бирергә мөмкин. Бары тик ахыр чиктә генә, теләр-теләмәс кенә, берәр китап бастырырга ярдәм итәчәк. Революциягә кадәр ак һәм кара эшкуарлар булган. Аклары байлыкларын халык белән бүлешкән, каралары—акчаны җилгә сибеп яшәгән. Ә бүген исә бөтен татар дөньясына мәгълүм меценатлар юк.

Имамнарыбыз, мөфтиләребез ни кылдылар? Алар күп мәчетләр төзеделәр. һәм, мөселманнар бердәмлеген кайгыртучы рухи остазлар буласы урынга, бик яхшы прорабларга әйләнделәр. Курсавины, Мәрҗанины, Муса Бигиевны алар арасыннан бик сирәкләре генә искә ала, ә инде әлеге күренекле теологларны укып караганнары аннан да азрак. Күпсанлы мөфтиләр бер-берсе белән талашып, мәхәллә бүлешеп, зәһәрлекләрен күрсәтеп, ил күләмендә адәм мәсхәрәсенә калдылар. Оят!

Тәлгат Таҗетдин өчен Казан—гомер бишеге. Ул безнең шәһәрдә туып-үскән, укыган. Ә хәзер аның өчен Казан—ваххабичылык оясы. Ә бит Казанда бернинди ваххабичылыкның булуы да, аның берәр каян үтеп керүе дә мөмкин түгел. Таҗетдин хәзрәт моны барысыннан да яхшырак белә. Чөнки татар халкының культура традицияләре бөтенләй башка. Безнең атаклы теологларыбыз теләсә нинди фундаменталистларга каршы торырлык нигез салып калдырганнар. Таҗетдиннең бөтен Россиягә берданбер мөфти булырга омтылышын аңларга буладыр, ләкин рухи лидерга хас намус-вөҗдан кайда? Вакыт узар, үтәгән заказының әһәмияте калмагач, Тәлгат Таҗетдин дә шушы Казанга кайтыр, чөнки ул татардан башка беркемгә дә кирәкми. Ә татарлар аны, Зәки Вәлиди Тоганны кичергән кебек, гафу итәрләр.

Ә безнең язучыларыбыз, шагыйрьләребез, фикер хакимнәребез нишли? Татар халкының киләчәге өчен бар өрнүне, бар идеяләрне мин язучылар тирәлегендә сеңдереп үстем. Олы әдипләрнең бу дөньядан китүен күрәм дә, эчем поша башлый. Язучылар берлеге зурайганнан-зурая. Яңадан-яңа әгъзалары барлыкка килә, тик язучының дәрәҗәсе төшә бара. Совет чорында, татар иҗтимагый фикере эзәрлекләнгән заманда язучылар сынмады-сыгылмады. Алар татарның мәдәниятен, телен һәм традицияләрен саклап калдылар. Аларның халыкка бөек хезмәтләре әнә шул. Бүген татар язучылары халыкны ни рәвешле рухландыра соң? Узганнарны искә ала...

Татар матбугаты... Ныклап карасаң, анда укыр нәрсә юк.

Татар телевидениесе... Анда карар нәрсә юк.

Кайчандыр татарлар бөек халык булган, Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан һәм башка ханлыклар белән идарә иткән. Без бүген үз-үзебез белән дә идарә итә алмыйбыз.

Без Россиядәге, төрки һәм ислам дөньясындагы үз урыныбызны

аңларга, Европага һәм дөнья культурасына мөнәсәбәтебезне билгеләргә тиеш. Милләтне шундый олуг максатлар гына берләштерә, бөек бурычларны аңлау гына вак-төяк ызгышлардан арындыра ала. Быел халык саны алу матавыгы безнең барлык кимчелекләрне яктырту өчен кирәк булган, күрәсең. Борис Ельцинның бер киңәшчесе күп еллар элек миңа: "Халык саны алуның чираттагысында сез күп татарны югалтачаксыз",—диген иде. Ул моны белми әйтмәгән һәм Мәскәү үз бурычларын хәзергә бик яхшы үтәп бара. Татарлар өчен әйбәт сабак. Бәлки көч һәм фикер тупларга кирәклеген, ниһаять, ныграк аңларбыз.

Тарихтан мәгълүм: татарлар һәрвакыт социаль проектларының киң колачы белән аерылып торганнар. Татар фикере тирәнгә керергә бик яратмый, ул гомуми манзарага нигезләнә. Тасвирлы әйтсәк, татар микроскопны өнәми, күбрәк телескоп куллана. Бәлки шуңадыр, татар галимнәре арасында космик киңлекләрне тикшерүчеләр ешрак очрый: Роальд Сәгъдиев, Рәшит Сюняев, Альберт Галиев—исемнәре бар дөньяга мәгълүм галимнәр. Татарлар, бер-берсен ашаудан туктап торган арада, алдынгы фикерләр, искиткеч шәп идеяләр уйлап чыгарырга сәләтле.

Кайвакыт татарлар бар гаепне урысларга һәм Россия империясенә сылтап куярга яраталар. Акланыр өчен җайлы ысул. Әлбәттә, татарларга, хәтта урысларның үзләренә дә алдынгы халык булырга комачау итә торган империя традицияләре бар. Путин империя рухына баш калкыту мөмкинлеге биреп ялгышты. Россия демократия һәм федерализм юлына ныклап басарга да өлгермәде—каршыбызда инде үткән заманнарның шәүләләре чагыла башлады. Империяне кабат торгызуга бөтен көчне туплап каршы торырга кирәк. Татарлар, һичсүзсез, ирек, демократия һәм федерализм ягына басарга тиеш.

Исегезгә төшерегез: безнең халык кайсы заманнарда көчле күтәрелеш чорлары кичергән? Күтәрелешнең беренче дулкыны 1905 елгы революциядән соң, демократик ирекләр барлыкка килгәч башланган. Ул чакта күп газеталар, журналлар чыгарылган, нәшриятләр ачылган, партияләр оешкан. Татар эшкуарларының куәтле катламы барлыкка килгән. Чираттагы көчле күтәрелеш 1917 елгы революциядән соң һәм Татарстан республикасы төзелгәннән соң була. Бездә югары уку йортлары барлыкка килә, татар теле дәүләт теленә әйләнә диярлек, яңа театрлар ачыла, опера сәнгате, симфоник музыка туа һ.б. Өченче дулкын үзгәртеп кору чорына туры килә. Республика ун ел эчендә, билгесезлектән арынып, яңа дөньяга таба тарихи ыргылыш ясады. Татарларның һәм республиканың дәрәҗәсе нык артты.

Авторитарлык һәрвакыт безнең халыкка каршы эшләде, аны исән калу-калмау чигенә җиткерде. Татарлар өчен демократия отышлы!!! Ул безнең социаль активлыкны һәм югары мәгърифәтне тулысынча кулланырга мөмкинлек бирә.

Россия бүген кай тарафка барырга белми. Ул Көнчыгыш белән Көнбатыш, демократия белән империя арасында бәргәләнә. Россия тарих чатында туктап калды. Урысның Солженицын шикелле акыл ияләре Россия җәмгыятен, бөтенләй бутап, ялгыш юлга кертеп җибәрделәр. Ун ел элек Россиядә бар нәрсә тулысынча олигархлар карамагына тапшырылды. Ә олигархларны ил язмышы кызыксындырмый. Бүген сәяси һәм интеллектуаль элита Россиянең хәлен начар күзаллый. Ул шәхсән үзенең, ахыр чиктә, Мәскәү мәнфәгатьләрен кайгырта.

Урысларны сүгәргә кирәкми. Бөек рус культурасы авыр кризис кичерә. Ул дөньяда гына түгел, БДБ илләрендә дә, хәтта үз дәүләтендә дә йогынтысын югалтып килә, чөнки аны көнбатыш китч кысрыклый. Урыслар алдында да татарларныкы кебек үк проблема тора: ничек тә исән калырга. Тик алар үзләре әле моны ахыргача аңлап кына җиткермиләр, әле һаман да бөек үткәннең хатирәләре һәм хәзерге көннең иллюзияләре белән күңелләрен юаталар.

XX гасыр башында күренекле татар идеологлары татар халкының игътибарын Европа гыйлеменә, шул исәптән рус культурасына юнәлдергәннәр. Тукай Пушкинга ияреп язган. Ул, Пушкиннан үрнәк алып, милли шигърият тудырган. Бүген татарлар Европадан өйрәнергә тиешләр. Барлык яңа идеяләр һәм технологияләр анда барлыкка килә. Без урысның үз

кыйбласын тапканын күтеп ята алмыйбыз. Гомумбилгесезлек шартларында безгә, һич икеләнмичә, тулысынча Европага йөз тотарга кирәк. Илдәге иҗтимагый кыйммәтләрне тәгъбир итүдә җаваплылыкның бер өлешен үз җилкәбезгә алу зарур.

Тукай татарларны дөньяның иң алдынгы халыклары белән рәттән күрергә хыялланган. Алдынгылар арасында булыр өчен алар дәрәҗәсенә күтәрелергә кирәк.

Испания Каталониясенең хәле Россиядәге Татарстан хәленә бик охшаш. Төрле илләрдә яшәүче каталонлылар Җир шарына сибелгән татарларны хәтерләтә. Каталонлылар бик борынгы тарихлы, көчле культуралы, дөньяның башка милләтләре белән бер дәрәҗәдә булырга омтылучы халык. Алар моңа испанлыларны сүгеп түгел, ә Европада актив эшчәнлек алып бару юлы белән ирешергә тырышалар. Аларның башкаласы Барселона, халыкара форумнар үткәрелә торган инициативалы шәһәр буларак, һәрвакыт игътибар үзәгендә. Менә шундый халыклардан үрнәк алырга кирәк. Көчле милләт булыр өчен алдыңа башка халыклар һәм илләр игътибар итәрлек зур бурычлар куярга кирәк.

Дөньяда милли культуралар арасында каты конкуренция бара. Бу конкуренция үз эчендәге гаугалардан хәлсезләнгән милләтләргә бернинди шанс калдырмый. Шушы гади хакыйкатькә төшенү үз халкың язмышы өчен ихлас җаваплылык хисе тудыра.

Һәрчак истә тотарга кирәк, без, татарлар—бер халык. Дәрдмәнд әйткәнчә:

> Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
> Кеше үз исмене инкяр итәрме.
> Татарлыктан татар угълы татармын,
> Татар түгел димә—башың ватармын!

Кем син, татар? Уйлан! Үз җаныңны тыңла һәм җавап бир. Син бәхетсез илнең, үз тамырларыннан оялганга, болгар, керәшен, мишәр, нугайбәк, башкорт исемнәре артына качкан бәхетсез гражданымы? Әллә син—үз халкыңның күтәрелүенә инанучы, бөек традицияләр варисымы?

Кем син? Татар-монгол явы турындагы мәкерле уйдырмалардан оялган маңкортмы, әллә төрки даһиның үткән чорлар белән горурланучы токымымы?

Татар, син төрки халыклар гаиләсендәге урыныңны оныткансың, шуңа күрә үзеңнең бу дөньядагы билгеләнешеңне таба алмыйсың. Син кемнеңдер традицияләре койрыгында сөйрәләсең һәм, шулардан ычкынып, үзеңне-үзең дөнья казанышлары дәрәҗәсенә чыгарга мәҗбүр итә алмыйсың. Үткәнеңә карап баксаң—киләчәгеңне күрерсең.

Татар, бер генә мизгелгә туктал да, милләттәш туганыңа явыз һәм нәфрәтле карашыңнан арын. Газиз милләттәшеңә үпкә саклама. Үзара ызгышны туктат. Синең бурыч—көчле булу, димәк, халыкның бердәмлеген саклау. Алай гына да түгел, син үз тирәңә төрки һәм башка халыкларны да тупларга бурычлысың, чөнки, илдә буталыш барганда, кемдер гомуми киләчәгебез өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга тиеш.

Без белемле, бай, акыллы, зирәк, бер-беребезгә һәм башка халыкларга карата түземле булырга тиеш.

Без Татарстан тирәсендә, суверенлыгыбызга бернинди сәяси технолог та кул суза алмаслык итеп, нык оборона боҗрасы ясап бирләшергә тиеш.

Без башкарырга тиеш нәрсәләр, без яулыйсы үрләр иксез-чиксез, алар турында киләсе мәкаләләрдә укырсыз.

## II. Тарих

ҮТКӘНЕҢӘ КАРАСАҢ—киләчәгеңне күрерсең...

Татарлар турында кыргый халык дип мәкерле уйдырма тараттылар. Моңа хәтта кайбер татарлар да ышанды. Кайсыберәүләр, урыс, үзбәк, казах, башкорт булуны кулайрак күреп, үзләренә башка исем таптылар. Икенче

бирәүләр, үз тамырларыннан оялып, тыннарын да чыгармадылар. Рус әдәбиятында да, Европа әдәбиятында да татар һәрвакыт явыз һәм хәйләкәр, мәкерле һәм рәхимсез. Бу образ халыкны кимсетергә нык ярдәм итте.

Чынлыкта исә, үз тарихыңнан оялырлык нигез юк. Безнең тарихыбыз чынлап та бөек. Һәм бу тарих әле тәгәлләнмәгән.

Төркиләр дәүләт төзи һәм аның белән идарә итә белүләре белән дөньяга танылган. Садри Максуди безнең халыкның рухын, булдыклылыгын әнә шулай бәяләгән. Төрки каганат, Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Кырым, Себер һәм башка ханлыклар—шушы гаять зур дәүләтләрне санап кына чыгу да уйланырга мәҗбүр итә. Татарның даһилыгы гасырларга сузылган туктаусыз төзелеш, сугыш, җиңү һәм җиңелүгә сарыф ителеп беткәнме әллә? Татар үз потенциалын кайда, кайсы чорда һәм ни сәбәпле югалткан соң?

Бәлки, Алтын Урданың чиксез киңлекләрен үз иңнәренә салырга көч-куәт җитмәгәндер? Әллә ханлыкларга таркалу, татар белән татар арасына чөй кагып, кирәкмәгән көнчелек тудырганмы? Яки Казанны яулап алуда татар гаскәрләренең дә катнашуы халкыбызның рухи таркалышына китергәнме? Ничек кенә булмасын, татар XVI гасырдан бирле кабат аякка басарга тели, ләкин иң мөһим тарихи үзәген генә таба алмый аптырый. "Идел-Урал" штаты оештыру бу хәлне төзәтер иде, әлбәттә, әмма ул чакларда көч җитмәгән, бердәмлек булмаган. Большевиклар, "Татар-башкорт республикасы" проекты тәкъдим итеп, дилбегәне үз кулларына алганнар. Соңыннан татарлар өстеннән катгый күзәтчелек урнаштырганнар. Мәскәү бүген татар халкының бердәмлегенә юл куймаячак, аны башкортлар һәм башка халыклар белән берләштермәс өчен бар көченә тырышачак. Чөнки болай идарә итү җиңелрәк. Бу—империя традициясе. Тик заманалар алмашынып бара бит.

СССР таркалганнан соң ил үзгәрде. Дәүләтнең биләмәсе кечерәю—сан ягыннан түгел, сыйфат ягыннан үзгәреш ул. Икътисадый һәм демографик мөмкинлекләр күзгә күренеп кимеде. Илнең икътисады чыгымлырак була башлады, көньяк өлеше төшеп калу аркасында конкурентлык сәләте кимеде, ә үзара элемтә проблемалары шул килеш калды. Россия чынлыкта Каспий, Кара һәм Балтыйк диңгезләрендә үз йогынтысын югалтты. "Яңа Россия"дә Петр I казанышларының берсе дә калмады.

Моңарчы Россиядә дәүләт төзелеше мәсьәләсе беркайчан да бу кадәр кискенләшмәгән иде әле. Һәм төп сәбәп аңа каршы корылган мәкерлекләрдә түгел, ә һаман да традицион үзаң, империячелек инстинкты саклануда. Аек акыл бөекдержавачыл сафсата һәм уйдырмалар белән алыштырылды. Илнең бюджеты сизелерлек кечерәеп барган бер мәлдә сәясәтчеләр һаман хыял диңгезендә йөзәләр. Безнең илдә финнарның мобиль телефоннар сатучы "Nokia" компаниясе бюджеты Россия бюджетыннан зуррак. Шул хәлдә держава турында сүз йөртү мөмкинме?! Оптимистлык өчен нигез юк.

СССР җимерелү белән беррәттән "Бөек Россия" дә таркала башлады. Рус шәһәрләренең анасы—Киев чит илдә бүленеп калды. Бәс, шулай булгач, нишләп әле Казан Россия составында калырга тиеш, ди? Дәүләт таркалуны кем һәм нинди чикләрдә туктатып калыр? Россиянең табигый чикләре кайда?

Россияне Киевтан башка күзаллап була, ләкин Казаннан башка—юк. Тарихтан мәгълүм: Россия Казан ханлыгын яулап алганнан соң барлыкка килгән. Аңа кадәр Россия түгел, Московия булган. Бүген Мәскәү белән Казан арасындагы мөнәсәбәт символик мәгънәгә ия—Мәскәүнең урыс булмаган халыклар белән уртак тел таба белүе нәкъ менә шушында күренә.

Россиянең СССР җимерелгән вакытлардан башланган таркалуын Россия тарихын яңадан барлап чыгуга нигезләнгән башкача сәясәт кенә туктата ала.

Россиянең тамырлары—православие дә, ислам да; монда славян башлангычы төрки башлангыч белән бергә үрелгән. Бу—Россиянең генетик коды, аннан качып та, котылып та булмый. Әлеге код илнең киләчәген билгеләячәк. Башкача әйткәндә, Россиянең ике таянычы, ике баганасы бар —Киев Русе һәм Алтын Урда. Россиядә милли идеянең

һәм реаль сәясәтнең буталчыклыгы нәкъ менә шуның белән исәпләшмәүдән, Петр-Екатерина традицияләре йогынтысында татар мирасыннан оялып баш тартудан килеп чыга.

Гомер узар һәм Идел буендагы зур шәһәрләрнең Алтын Урда нигезенә салынганын һәркем ачык күрер. Һәм Бату хан фигурасы кешелек алдына җимерүче түгел, бөек төзүче сыйфатында килеп басар. "Татар ясагы" уртача салым (10%) дип кабул ителер. Алтын Урданың финанс системасы Урта гасырлар чорындагы иң яхшы система дип танылыр. Тарихи документларны җентекләп карасалар, урыслар үзләре дә күрерләр: православиенең чәчәк ату вакыты Алтын Урда чорына туры килә. Чөнки Чыңгыз хан законнары ("Яса") буенча барлык дини оешмалар салым түләүдән азат ителгәннәр. Ә Алтын Урда "изү"еннән котылганнан соң монастырьларның матди хәле бик авырлаша һәм алар ябыла башлый. Россия дәүләтендә почта (ямчылык) хезмәтенең дә башка күп институтлар белән беррәттән татар мирасы буларак әле бик озак вакыт эшләп килгәнлеге дә ачыкланыр.

Россиядә Чыңгыз хан рухы һәрвакыт яши. Россиянең бар тарихы—монгол империясе чикләрендә дәүләт торгызуга омтылыш.

Мәскәү—Алтын Урда тудырган шәһәр, чөнки ул "татар ясагы" җыю аркасында аякка баскан һәм абруй казанган, аннан соң, шушы өстенлектән файдаланып, үз тирәсенә урысның башка кенәзлекләрен туплаган. Дмитрий Донской татарларга каршы сугышырга уйлап та карамаган, ул лояль татарлар белән бергәләшеп, законлы хакимиятне яклап, литвалыларга таянучы узурпатор Мамайга каршы чыккан. Туктамыш хан исә Мәскәүгә Дмитрийны ясак түләргә мәҗбүр итү максаты белән яу чапкан. Заманча әйтсәк, ул Рус олысындагы тәртипне дәүләттә урнаштырылган гомуми тәртипкә тәңгәлләштергән генә.

Бу дәверде татарның ахыргы максаты урыс җирләренә һич бөйле булмаган. Татарлар бөек далалар аркылы Европага ыргылганнар, урманнар зонасына бик кагылмаганнар, чөнки анда атлы гаскәр бар осталыгын күрсәтә алмас иде. Сәяси көчләрнең ул чактагы бүленеше буенча урысларның татар өчен дошман булуы мөмкин түгел. Икътисад күзлегеннән караганда да, аларның татар кызыгырлык әллә ниләре булмаган.

Россияне Петр махмырыннан соң рәхимсез тарихи айну көткән.

Бүген бик күп тарихи әйберләрнең мәгънәләренә кабат төшенү бара. ЮНЕСКО Чыңгыз ханны үткән меңьеллыкның атаклы кешесе дип таныды. Гитлер шикелле явызлыгы белән түгел, ә дөньяви процессларга иң көчле йогынты ясаган бөек шәхес буларак таныды. Эрмитаж оештырган "Алтын Урда сәнгате" дигән күргәзмә зур уңыш белән дөнья буйлап сәяхәт итә. Алтын Урда белән кызыксыну елдан-ел көчәя генә барачак.

Күренекле хирург Ренат Акчурин "Россиядә "татар мәсьәләсе" дигән программ мәкалә язган. Ул анда, сүз җаеннан гына, республиканы "суверенлаштыру шаукым"ында гаепләп узган, үзе татарча аңламаса да, татар теленең латин графикасына күчүе татарлар ихтыярына каршы килә дип белдергән; Бөтендөнья татар конгрессының II съездында кабул ителгән мәгълүм карар аның өчен әһәмиятле түгел икән. Ул татарның ультра милләтчеләрен тапкан һәм хәтта Әнкара "кулы уйнавы" турында да өстәргә онытмаган. Җыеп әйткәндә, безнең республикага каршы "дәлилләр"нең гадәти җыелмасын тәкъдим иткән. Хирург Акчурин, аталарча кайгыртучанлык күрсәтеп, Идел Болгарстанын һәм Алтын Урданы үз чорының иң алдынгы илләре дип санаучы яшь татар историографиясенең "балалар авыруы" барлыгына диагноз да куйган. Аның фикеренчә, бу—"аберрация, ягъни Казанның тарихи карашны бозып күрсәтүе" .

Тарихчы бервакытта да йөрәкне шунтирлауда хирургка киңәш бирергә җөрьәт итмәс иде. Нигә соң хирург, хәтта бөек булса да, тарих фәнен хирургиядән түбәнрәк яки гадирәк дип саный? Тарихта да белгечлек кирәк түгелмени? Алтын Урданы тикшергән галимнәрнең берсе дә әлеге дәүләтнең дөньяви әһәмиятен шик астына алмый бит. Моны белү өчен академик әдәбиятка күз төшерү дә җитәр иде, урыс телендәме, инглиз, венгр яки немец телендәме—бусы мөһим түгел. Чөнки Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда турындагы әлеге фикер гомум кабул

ителгән, биредә беркем дә бәхәс куптарып маташмый. Аберрациянең монда ни катнашы бар?

Күренекле татар сәясәтчеләре арасында иң якты йолдыз—Йосыф Акчура, төркичелек идеясе авторы (Ренат Акчурин терминологиясендә "яңа пантюркизм"). Йосыф Акчура Төркиягә качып китәргә мәҗбүр булган һәм Кемаль Ататөрек аны үзенең киңәшчесе иткән. Төркия республикасын төзүгә ул да зур өлеш кертә. Йосыф Акчура татар дәүләтенең торгызылуын күрергә хыяллана һәм безнең халыкны төрки дөньядан башка күз алдына да китерми. Моның кемгә зыяны бар? Россиягәме? Урысларгамы? Ни өчен славяннар берлеге оешмас борын яхшы да, ә төрки берлек оешмас борын начар икән? Патша чиновникларының татарга каршы чараларын кабатлау нигә кирәк? Без бит цивилизацияле кешеләр!

XX гасыр башында татар фикере күренекле шәхесләрнең тулы бер йолдызлыгын тудырды: Йосыф Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди, Рәшит Арат—алар барысы да Төркиягә китәргә мәҗбүр булганнар, үз дәүләтләренә түгел, башка дәүләтнең чәчәк атуына хезмәт иткәннәр. Муса Бигиев язмышы да шундый, үз иленнән сөрелгәч, ул мөселман дөньясына хезмәт итә. Бу галимнәрнең һәрберсе татар фикере тарихында тирән эз калдырган. Ватанда калган Мулланур Вахитов, Солтангалиев безнең дәүләтчелекне торгызырга тырышып караганнар. Аларның язмышы да фаҗигале. Татарның киләчәге хакына, тарихны гаять тирән аңлаган, ана телен, гарәп, төрки, Европа телләрен бик яхшы белгән нинди зур гыйлем ияләре эшләгән! Аларның фәнни хезмәтләре әле хәзергәчә искерми.

Бүген теләсә кем, хәтта үз телен һәм тарихын белмәгән кеше дә үзен Россиядә "татар мәсьәләсе" турында фикер йөртергә хаклы дип саный. Оят һәм аяныч...

Алтын Урда—данлы мирас, аның өчен Мәскәү Казан белән сугышкан. Казан ханлыгын буйсындыру Иван Грозныйга халыкара документларда үзен патша дип атарга мөмкинлек биргән. Бу исем ул чакта хан дәрәҗәсенә тиңгәл була. Бүген Россия гербында ике башлы бөркет өстендә өч таҗ көязләнеп тора— Казан, Әстерхан һәм Себер ханлыклары символлары. Алар татар ханлыкларын яулап алу хөрмәтенә Алексей Михайлович тарафыннан 1625 елда куелган. Хәер, ике башлы бөркет үз вакытында Җанибәк хан акчаларына сугылган булган. Ул заманда татар мирасыннан баш тартмаганнар. Киресенчә, Казан белән Мәскәү каршылыгына этник һәм дини тәсмерләрдән бигрәк Алтын Урдадан калган киңлекләрдә сәяси йогынты өчен көндәшлек хас булган.

Россия безнең өчен чит биләмә түгел. Татарлар халык буларак шушы зур киңлекләрдә оешканнар һәм бүген дә үзләренең газиз җирләрендә килмешәкләр кебек түгел, хуҗалар булып яшиләр. Шулай булгач, без үзебезне тиешенчә тотарга, ягъни шушы җир язмышы өчен җаваплылыкны аңларга тиеш.

Тарих бервакытта да гади һәм берьяклы гына булмый, гәрчә шулай дип күрсәтергә тырышсалар да. Ә инде татар тарихы һәрвакыт катлаулы борылышларга бай. Безнең халык өчен иң авыр мәсьәлә—татар-монгол явы темасы, татарларны монголларга бәйләп күрсәтүдер, мөгаен.

Татарлар һәм монголлар, әлбәттә, төрле халык. Әмма тарих бит ул телләрне һәм этник үзенчәлекләрне аерган кебек үк җиңел бүгәләнми. Гасырлар буе үзара көрәш һәм үзара йогынты нәтиҗәсендә бик күп нәрсә кушылып беткән. Бу хәл Урта гасырлар башында ук, Азия континенты үзәгендә башланып һәм Европа территориясендә тәмамланган. Ике халык бер бәйләмгә эләккән. Монголлар төркиләрдән күп нәрсә алганнар һәм үзләре дә татарларга шактый йогынты ясаганнар, аеруча хәрби сәнгать һәм дәүләт төзелеше өлкәсендә. Без монгол мирасыннан ваз кичә алмыйбыз. Ахыр чиктә, Казан Кремлендә күмелгән ханнар—Чыңгыз токымыннан. Без аларны үзебезнең борынгы бабаларыбыз буларак олылаячакбыз әле.

Россия дәреслекләрендә, матбугатында, нәфис әдәбиятында, публицистикасында "татарщина", "татарская дань", "татаро-монгольское иго" диган

тезмәләрне әледән-әле кулланып торалар. Куликов кырындагы сугышны урыс тарихының хәлиткеч вакыйгасы дип күкләргә күтәреп күпертеп күрсәтәләр. Гәрчә урысның үз тарихчысы Ключевский күпсанлы әсәрләрендә әлеге вакыйганы "әһәмияте булмау сәбәпле" хәтта телгә дә алмый. Бату хан үзенә уллыкка алган Александр Невский, мәсәлән, рәсми фараз буенча, татарга каршы иң төп көрәшче булган, имеш. Тарихи дөреслекне әнә шулай бозып бетерделәр инде.

Лев Гумилев исә татар-монгол изүе булмаган, киресенчә, татарлар һәм урыслар тевтонлылар һәм литвалылар ябырылуына каршы берләшкәннәр дип раслый. Ихтимал, ул бу вөзгыятьне бераз идеаллаштыргандыр да. Татар-монголлар гуманистлар түгел, ләкин рәхимсезлек буенча ул чордагы Европадан бер нәрсәсе белән дә аерылып тормаганнар. Хәтерләсәгез, ул чакта Европада тәре походларында кан түгелгән, инквизиция еретикларны учакларда яндырып үтергән. Европаны Чыңгыз ханның галәми масштабтагы ниятләре генә куркыткан, күрәсең. Шуңа җавап итеп татарлар турында мәкерле уйдырмалар чыгарганнар.

Татарларның иң беренче бурычы—җәмгатьчелекнең безнең тарихка мөнәсәбәтен үзгәртү. Бу бурыч Татарстанның рәсми структураларына, ТР Фәннәр академиясенә генә түгел, бөтен татар халкына кагыла. Бу— гомуммилләт эше. Россиянең татарларга карашын тиз арада башка юл белән үзгәртеп булмаячак. Мәгълүмат чараларында дөреслекне чыгару өчен бернинди мөмкинлекне дә ычкындырырга ярамый, теләсә нинди форсаттан файдаланырга кирәк. Федерациянең һәрбер субъектында милли-мәдәни автономияләр каршында бу эш белән махсус шөгыльләнүче тарих сөючеләр төркеме оештырылырга тиеш. Бүгенге көндә иң катлаулы сорауларга җавап бирерлек академик әдәбият җитәрлек, ләкин тарих темасына популяр әдәбият бик аз. Әлеге активистлар үз төбәкләренең тарихын тикшерергә, Россия җиренең тарихи катламнарын күрсәтергә тиеш. Безнең өчен ап-ачык: Әстерхан ул— Хаҗитархан, Волгоград—татар тамырлы Сарацин, Саратов Алтын Урданың Укәк шәһәре нигезенә салынган, һ.б. Ә урысларның күпчелеге өчен бу зур яңалык булачак.

Тарих буенча популяр әдәбиятны, аеруча балалар китапларын зур тираж белән басарга кирәк. Моны Татарстанда эшләгәннәрен көтеп ятасы түгел. Белемле һәм инициативалы эшкуарлар моны үз кулларына алып, коммерциячел нигездә куйсыннар иде. Бу фикерне бер үк вакытта өндәмә итеп тә, мөрәҗәгать итеп тә итеп кабул итегез. Чөнки хәзерге вакытта Тарих институтына академик эш йөкләнгән, бирелә "Татарларның борынгы чорлардан тарихы" дигән 7 томлык хезмәт хәзерләнә. Киләсе 3-4 елда башка эшләргә бүленү мөмкинлеге юк. Институт инде моннан башка да үз мөмкинлекләреннән артыграгын башкара. Шул ук вакытта ул татар тарихын язу эшенә республика тарихчыларын гына түгел, Россия һәм халыкара фәнни үзәкләрнең дә иң яхшы галимнәрен тарта.

Казанның якынлашып килүче 1000 еллыгы Россиянең татарларга килмешәкләр һәм урысларны изүчеләр дигән карашын үзгәртергә бик шәп җай чыгара.

Быел Иван Грозный гаскәрләренең Казанны яулап алуына 450 ел тула. Россиянең рәсми хакимияте ханлыкны буйсындыруны прогрессив күренеш дип күрсәтәсе килә. Татарлар моның белән бервакытта да килешмәячәкләр.

Казанны буйсындыру—безнең язмыштагы фаҗигале борылыш. Әлеге дата үткән заманны түгел, киләчәкне уйларга сәбәп булырга тиеш. Аны нәфрәт кабызу өчен түгел, татар һәм урыс тарихына аек караш булдыру максатында файдаланырга кирәк.

Татар аңы тарихны ике өлешкә бүлә: Казанны алганчы һәм Казанны алгач. Моңарчы мәгълүм тарих урысларның татарга каршы, православиенең исламга каршы көрәше итеп күзалланды. Чынлыкта исә тарих катлаулырак. Тарихи вакыйгаларны Куликов сугышы мисалындагы кебек сәясәтләштерү яхшыга илтми. Бу Казанда гына түгел, бөтен Россиядә яшәгән татарлар файдасына булмаска мөмкин. Үзәкнең басымына шундый ук басым белән җавап бирергә ярамый. Зирәгрәк булырга кирәк.

Россия үзенең бөеклеген югалтты. Хәзер Россия җаны үткән

чорлар даны белән бүгенге катастрофик хәле арасында бәргәләнә. Урыс культурасы да үз абруен югалта. Бөек Толстой, Достоевский, Чехов, Бердяев кайда бүген? Алар юк. Бу—ил өчен зур бәла. Россия православиеле рус дәүләте булып кылана, башка халыклар белән исәпләшми диярлек. Хакимият вертикале төзергә, Татарстан һәм башка республикаларның хокукларын чикләргә, чечен мәсьәләсен көч кулланып хәл итәргә маташу үлем ачысына охшап кала.

Империяләр чоры узды. Россиянең киләчәге—бары тик демократик федерация төзүдә генә. Һәм ул федерациядә республикалар, өлкәләр, крайлар декоратив түгел, реаль субъектлар булырга тиеш. Россиянең сәяси элитасы дәүләт һәм халык белән әледән-әле экспериментлар ясап торачак, субъектларны яңа административ берәмлекләргә берләштереп республикаларны юкка чыгарырга тырышачак. Билгесезлек һәм тотрыксызлык сәяси технологларга җәмәгатьчелек фикерен теләгәнчә болгатырга ярдәм итә.

Безнең бурыч—Россиядәге сәяси вәзгыятьне тотрыклы итүгә булышу, ә моның өчен татарларның булган структураларын, иң элек милли-мәдәни автономияләрне ныгыту зарур.

Без бу тиз үзгәрүчән дөньяда үз юлларын таба белгән халыклардан үрнәк алырга тиеш. Кечкенә генә Эстонияне карагыз әнә: ул, һич икеләнмичә, шунда ук Европа традицияләренә таба юнәлде. Бу илнең икътисадый яктан Татарстанныкы кебек мөмкинлекләре юк иде. Эстоннарның саны да бары тик 1 миллион гына. Ләкин алар алга киткән илләрдән өйрәнәләр һәм соңгы ун ел эчендә шактый уңыш казандылар. Иң мөһиме—эстоннарның Европа халыклары арасында үз урыннары, димәк киләчәкләре бар.

Татар тарихы Азия континентына тирән үтеп кергән—һуннар державалары, төрки һәм татар дәүләтләре житлеккән чорларга тоташкан. Тамырларыбыз—шунда. Яңа эра башында һәм шулай ук Идел-Урал төбәгендә бөек күчешләр чорында безнең халыкның үзәге оешкан. Соңрак, язмыш ихтыяры буенча, күп кенә этнослар: болгарлар, кыпчаклар, нугайлар, һ.б. безнең тарихка бөйле көчле процессларга тартып кертелгәннәр. Татарның йөзен, асылын Алтын Урда иҗат иткән. Тел, әдәбият, культура, психология Алтын Урда чорында ук камил чагылыш тапкан. Хәер, XX гасыр да милләтне үзгәртте, аңа заманча, Европа үзенчәлекләре бирде. Безнең халыкның тарихы—туры мәгънәдә дә, күчерелмә мәгънәдә дә—Көнчыгыштан Көнбатышка туктаусыз хәрәкәттә. Кайчандыр алдынгы фикер һәм югары культура Көнчыгышта була. Әмма дөньяви процесслар үзәге әкренләп Көнбатышка күчә. Бүген Европа иң либераль идеяләр үзәге, нәкъ менә Европада халыклар хокукларына зирәк мөнәсәбәт яшәп килә. Фән һәм техникада алдынгы фикер, алга киткән икътисад һәм мәдәният тә Европада. Россия Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасында торырга тырышып нык ялгыша. Безнең бурыч—Көнчыгыштан аерылмыйча гына Европага таба үрләү.

Татарлар тарихта дан-шөһрәт девере дә, кимсетелү заманнары да кичерделәр. Телебезгә, культурабызга, динебезгә карата дүрт ярым гасырга сузылган эзәрлекләүне без лаеклы уздык, ана телебезне һәм абруебызны саклап калдык. Болар барысы да үлеп баручы империянең койрыгында сөйрәлү өчен эшләндемени соң? Юк, без цивилизацияле җәмгыятькә юнәлгән үз юлыбызны Россиягә каршы барып та, аннан чыгып та түгел—Россия белән бергә табарга тиеш.

Татар, син үз тарихың турында дөреслекне белергә тиеш.

Татарлар кыргый халык булган дисәләр дә—ышанма.

Татар-моногол изүе Россиянең һәм башка илләрнең үсешен тоткарлаган дисәләр дә—ышанма.

Без татарлар түгел, без—болгарлар дисәләр дә—ышанма.

Алтын Урданы кимсетеп сөйләсәләр дә—ышанма.

Без—бөек культура варислары, дөньяга безнең потенциал кирәк. Татар телендә, әдәбиятында, әхлакый кыйммәтләрендә олы тарихи тәҗрибә тупланган һәм без—бу традицияләрнең иярләре. Безнең ата-бабалар Евразия киңлекләрен үзләштерә алганнар һәм иң кырыс шартларда яши алырлык дистәләгән дәүләт төзегәннәр. Төрки каганаты, аннан соңгы

Алтын Урда булмаса, Россия бервакытта да барлыкка килә алмас иде.

Тарихта берни дә эзсез югалмый. Безнең бәлабез шунда ки, төрле чорларда тарих чылбырын өзәргә маташтылар, берничә буынны татарлар турында ялган укытып тәрбияләделәр. XXI гасырда кем булачагыбыз хәзер бары тик үзебезгә генә бәйле. Мескенлегебезне җиңеп, тарихи хакыйкатьне кайтару эшенә тотынырга кирәк, шуннан соң, иншалла, вакытның өзелгән чылбыры да ялганып китәр...

## III. Ана теле

СОВЕТ ЧОРЫНДА Габдулла Тукай сүзләренә язылган "Туган тел" җыры татарларның гимны иде. Аны төрле җыелышларда рухланып-дәртләнеп җырлаганнарын хәтерлим. Бу җыр хакимиятнең ассимиляция сәясәтенә каршы протест рәвеше иде.

Без теләгәнебезгә ирештек—татар теле Татарстанда дәүләт теле дип игълан ителде һәм әкренләп бөтен Россия буйлап яңадан гамәлгә керә башлады.

Ләкин күңел барыбер тыныч түгел...

Хәзер татарларны яшьләрнең күпләп-күпләп урыс теленә күчүе борчый. Бу һәр җирдә, хәтта Татарстан шәһәрләрендә дә шулай. Җитди проблема. Әлбәттә, яшәр өчен, эшләр өчен һәм бигрәк тә Россиядә лаеклы урын тотар өчен урыс телен урыстан яхшырак белергә кирәк. Ләкин төп куркыныч—тел тармагының глобальләшүендә. Инглиз теле бөтен дөньяга ургылып тарала, яңадан-яңа илләрне һәм халыкларны билəп бара. Галимнәр исәпләве буенча, 100 елдан соң дөньяда өч тел өстенлек итәчәк: инглиз, испан һәм кытай телләре. Калган телләр язмышы—кухня теле булып калу.

Урыс теленә мондый кысрыклауга каршы тору җиңелрәк, чөнки ул сан ягыннан да, дәүләт ярдәме ягыннан да өстенлеккә ия. Хәер, Россия җәмгыяте үзе дә хәзергә дөньяви процессларга, глобальләштерү куркынычын тоярлык дәрәҗәдә катнаштырылмаган әле. Тик бу озакка бармас. Татарлар әлеге куркынычны кискенрәк тоялар. Чөнки телнең ассимиляцияләшү бәласенә без күптән тардык инде.

Шулай булгач, татар телен торгызу өчен бүген шулкадәр тырышырга кирәк микән соң? Татарстан гражданнары балаларын анык киләчәге булмаган телне өйрәнергә мәҗбүр итеп дөрес эшлибезме соң? Бәлки шул тырышлыкны урыс һәм инглиз телләрен өйрәтүгә юнәлдерергәдер?

Өлкән буын өчен тел—изге нәрсә. Сибгат Хәким болай дип язган иде:

Язмышым, үзең аердың,
Юк өткәм һәм юк әнкәм,
Юк җирдә башка шатлыгым,
Әйтче, мин кемнән, я, ким?
Әнкәмнән мәхрүм итсәң дә,
Телемнән итмә ятим.

Замана яшьләре прагматиклар, үзен саклап кала алмаган һәр нәрсәне тормыш мәйданыннан себереп ташлыйлар. Татар телен ни көтә соң? Без яшьләргә ни әйтергә тиеш?

Тарихи күзлектән караганда, татар телен яклап күп дәлилләр китерергә мөмкин, әмма тарих бүгенгегә аек караш булганда гына киләчәк файдасына эшли. Татарларның дөнья культурасында телнең гамәли кулланылыш зарурлыгын аклый торган үз киштәсе булырга тиеш.

Татарларның хәзерге дөньяда урынын билгеләячәк ике мәдәни фактор бар. Беренчесе—татар теленең төрки телләр төркемендәге төп тел статусы. Икенчесе—исламның иң алга киткән формасы буларак җәдидчелек үзенчәлекләре. Киң мәйданга чыгарлык башка казанышларыбыз юк. Димәк, татарның эшчәнлеге өчен ике мәйдан бар: төрки дөнья һәм ислам дөньясы. Татарның Россиядәге абруен да шушы факторлар билгели.

XX гасыр башында татарлар Европа культурасы белән төркиләр арасында арадашчы ролен үтиләр. Урта Азиядә күп кенә мәктәпләрне, газеталарны, нәшриятләрне татарлар ачкан, үзләре шунда эшләгәннәр дә.

Безнең эшкуарлар ул заманда Россия белән Көнчыгыш арасында да арадашчы булганнар. Әлеге функцияне совет чоры ясалма рәвештә юкка чыгарган. Хәзер безнең алда әлеге функцияне кайтару бурычы тора. Йөз елга кире кайтып, икенче кат омтылыш ясап карарга кирәк. Ләкин бу миссияне бермә-бер кабатларга ярамый. Заманалар да, вәзгыять тә, ихтыяҗлар да үзгәрде. Төрки дөнья милли чикләр белән бүлгәләнгән булып чыкты һәм татарларга элеккеге рольдә теркәлеп калу хәзер катлаулырак.

Иң элек лингвистикага кагылышлы проблемаларны ачыкларга кирәк, алар дөрестән дә шактый җыелган. Менә иң ачык мисал. Башкорт белән татар бер-берсен тәрҗемәчесез аңласа да, мөстәкыйль башкорт, теле күзгә бәрелеп тора. Бер тел белән икенчесе арасында чик кайда дигән сорау туа. Акыллы фәнни дәлилләрләрдән еракларак китеп, тормыш чынбарлыгына күз салсак, бик гади итеп әйтеп була: тел кешеләргә аралашу өчен хезмәт итә. Ул—үзара бәйләныш коралы. Әгәр дә без үзара сөйләшкәндә бер-беребезне аңлыйбыз икән, димәк, телебез бер үк.

Минем кызым телевизордан башкортча спектакльне беренче мәртәбә өч яшендә карады һәм аңа барысы да аңлашылды. Әгәр дә беркайда да укымаган сабый бала башкорт сөйләмен аңлый икән, димәк аның өчен башкорт теленең татар теленнән аермасы юк, бары тик әйтелештә генә үзенчәлекләр очрый. Фәкать шул гына. Тормыш таләбе шушы. Тылмач кирәкми икән, димәк тел бер үк.

Бервакыт гаиләбез белән Кырымга ял итәргә барган идек. Анда минем кызым телевизордан кырым татарлары телендәге тапшыруларны аңлап, мавыгып карый иде. Мин моннан шундый нәтиҗә ясадым: хәтта балаларга да тел киртәсе юк икән, димәк, татарлар һәм кырым татарлары теле дә нигездә бер үк, ә үзенчәлекләре әллә ни әһәмияткә ия түгел.

Төрки тел бик күптән барлыкка килгән. Ул бай гына түгел, үтә чыдам да булып чыккан. Садри Максуди:"1200 ел эчендә безнең тел бик аз үзгәргән",—дип язган иде.

Дистәләгән төрки әдәби тел уйлап чыгару өчен күпме көч сарыф ителгәндер! Теге яки бу авазларның яки кайбер сүзләрнең әйтелеш үзенчәлегенә генә нигезләнеп мөстәкыйль телләр һәм диалектлар барлыгын белдерүче лингвистиканың ни хаҗәте бар? Ул кемгә хезмәт итә? Без бүген шул "фән"нең ачы җимешләрен татыйбыз түгелме?

XIX гасыр ахырында Исмәгыйль Гаспринский гомумтөрки телдә "Тәрҗеман" газетасы чыгара башлый. Ул төрки дөнья алдында торган проблемаларны яхшы аңлаган. Аннан соң безне революцион процессларга тартып кертәннәр. Татарлар революциянең ирек китерәчәгенә ышанганнар. Ә иректән дә кадерлерәк тагын ни бар? Әмма ирек, хөррият урынына төркиләрне совет тулай торагының милли бүлмәләренә таратканнар.

Сталин боерыгы буенча, дистәләгән төрки алфавит төзү эше вәхшиләрчә үткәрелә. Революциягә кадәр татар матбугатын патша Россиясенең барлык төрки халыклары укыган булса, бүген исә бу мөмкин хәл түгел. Без бер-беребезне сөйләм телендә генә аңлыйбыз. Иң аянычы—без әллә ахмаклыктан, әллә гадәт буенча шушы сәясәткә ябышып барабыз.

Соңгы елларда миңа немец телле күп кенә илләрдә булырга туры килде һәм мин шуңа игътибар иттем: австриялеләр, баварлылар, саксонлылар, швейцариялеләр мөстәкыйль телләрдә сөйләшәләр (мин ул чакта шулай дип уйлый идем). Бервакыт Мюнхенда, мэриядәге очрашуда бер баварлы минем белән сөйләшергә теләк белдерде, әмма тәрҗемәченең немец телендә генә сөйләшүен белгәч, кулын селтәп кайтып китте. Мин моңа бик гаҗәпләндем.Безнең югары квалификацияле тәрҗемәчебез бавар диалектында бер сүз дә аңламый икән. Баксаң, немецлар бер-берсенә һич аңлашылмый торган төрле диалектларда сөйләшәләр икән.Әмма ләкин бер үк әдәби телдә укыйлар һәм язалар.

Дәүләт теле немец теле булган Швейцариядә мин тел вәзгыятен махсус тикшердем. Безне Швейцариянең Юстиция министрлыгында кабул иттеләр, без кантоннарда, Берн муниципалитетында булдык. Бар җирдә дә швейцар телендә сөйләштеләр. Люцернда исә парламент Татарстан делегациясен аягүрә басып каршылады. Безне озатып йөрүче швейцарияле

алар сөйләгәнне немец теленә тәрҗемә итте, аннан соң безнең тәрҗемәчебез урыс теленә тәрҗемә ясап барды. Бу хәл миңа нык тәэсир итте. Без башкорт, кумык, балкар, карачай, нугай, кырым татар, казах, уйгур һәм башка телләрне, тәрҗемәчесез аңласак та, мөстәкыйль телләр дип атыйбыз. Ә австриялеләр, баварлылар, швейцарлылар һәм башкалар, бер-берсен аңламасалар да, үз телләрен (ягъни без тел дип күзаллаган) диалект диләр. Һәм боларның берсе дә үз әдәби телен уйлап чыгарырга ашкынмый—анда законнардан башлап гади хатларга кадәр бар нәрсә немец телендә языла, газеталар һәм матур әдәбият тә шул телдә басыла.

Швейцариядә, Фрибургтагы Федерализм институтында кайбер профессорлар әдәби немец теленнән бигрәк инглиз телендә сөйләшүне мөгъкуль күрделәр. Бу—глобализация шаукымы, күрәсең. Мин моңа аптырап калдым һәм сорау бирдем:"Хөкүмәттә һәм парламентта, телевидениедә һәм өйләрегездә кулланылучы камил сөйләм диалектыгыз булгач, ни өчен сез үз әдәби телегезне булдырмыйсыз?" "Моның өчен базар тар",—дип җавап бирделәр. Дөрес, кайбер немец диалектлары үз әдәби телен булдыру юлыннан киткәннәр (мәсәлән, голланд теле), ләкин аларга инглиз теле кысрыклавына каршы тору кыенрак булачак.

Даһи фикер һәрвакыт гади була. Димәк, төрки телләр өчен иң куркынычы—урыс теле дә, империя традицияләре дә, Россиянең хәзерге сәясәте дә түгел, ә БАЗАР галиҗәнапләре икән ләбаса!

Әлеге мисалдан берничә нәтиҗә ясарга мөмкин.

Беренчесе. Гомумән әйткәндә, төрки тел—бер. Шул ук вакытта чыгышлары тарихи дәлилләнгән әдәби телләр бар. Шул ук вакытта ясалма төстә барлыкка китерелгән дистәләгән тел яши. Әгәр дә аерым торучы чуваш һәм якут сөйләм диалектларын читтәрәк калдырсак, үз эченә күпсанлы шивәләр һәм сөйләшләр сыйдырган төп ике диалект бар—"угыз" һәм "кыпчак". Мин бу мәсьәләгә лингвист күзлегеннән түгел, тормышның гади таләпләреннән чыгып карау максаты белән, фәнни классификацияләрдән аңлы рәвештә читкәрәк китәм.

Чыннан да, татарларга төрек, әзәрбайҗан, төрекмән телләрен берниндидиэ өзерлексез аңлау кыен, әлбәттә. Ә менә без, "кыпчак" диалекты эчендәгеләр, бер-беребезне яхшы аңлыйбыз. Үзбәк сөйләм теле фарсы сүзләренә бай, бу хәл аралашуны кыенлаштыра. Әмма нигездә үзбәк, казах һәм кыргыз әдәби телләрен аңларга мөмкин.

Инде башкорт яки мишәр, себер яки әстерхан татарларына килгәндә, аларның сөйләм үзенчәлекләре татар шивәсенең бер сөйләше дигән төшенчәгә туры килә. Фәкать шул гына. Чагыштыру өчен: мәгълүм казакларның сөйләшен беркем дә мөстәкыйль тел дип санамый, гәрчә аларның үзаңы башкортларныкыннан көчлерәк, тарихи тамырлары тирәнрәк булса да.

Әгәр дә башкортлар үзләренчә сөйләшергә тели икән, рәхим итсеннәр. Ләкин безгә, төркиләргә шулкадәр күп әдәби тел, шулкадәр күп алфавит нигә кирәк? Алар бит төрки дөньяны бүлгәләү өчен махсус уйлап чыгарылганнар! Ни өчен без демократия шартларында да сталинчыл "тел белеме" принципларын тотарга тиеш? Һәм ни өчен без телләрнең дөнья мәйданындагы кискен конкуренциясе каршында үз-үзебезне үз телебез белән тарихи тупикка кертергә тиеш? Һич аңлашылмый...

Икенче нәтиҗә түбәндәгедән гыйбарәт. Куәтле немец милләте, киләчәкне уйлап, немец культурасы ареалын саклап калу өчен австриялеләр һәм швейцариялеләр белән берләшә икән, димәк, немецларныкы кебек икътисадый, административ, нәшрият потенциалы булмаган төркиләргә исән калу турында инде күптәннән кайгыртырга кирәк иде. "Кыпчак"лар белән чагыштырганда, "угыз" мәдәни төркеменең үсү өчен мөмкинлекләре зуррак, чөнки ул Төркия, Әзәрбайҗан, Төрекмәнстан дәүләт потенциалына таяна. Үзбәкләргә дә хәзергә исән калу турында уйламаска була—алар бик күп һәм бер җирдә оешып яшиләр. Казахлар белән кыргызлар да вакыты җиткәнче үз дәүләтләренә таяна алалар. Ә менә Россиядәге төрки халыкларның бер-берсеннән аерылган хәлдә исән калу мөмкинлекләре юк. Базар мөнәсәбәтләре тиздән һәммәсен үз урынына утыртачак һәм республикалар глобализациягә каршы торырлык үзенчәлекләребезне административ көч кулланып кына саклап кала алмаячак.

Әлбәттә, Мәскәү төрки халыкларның берләшүенә каршы торачак, безнең бар омтылышыбызны, шул исәптән шушы мәкаләләрне дә, пантюркизм дип атаячак. Ләкин без хәзер һич кичекмәстән икенең берсен сайлап алырга тиеш: йә без Мәскәүнең төче сүзенә алданып өкренләп юкка чыгабыз, йә без исән калу юнәлешендә тарихи ыргылыш ясыйбыз. Ахыр чиктә, безнең төрки халыкларны саклап калырга омтылуыбыз урысларга да, урыс теленә дә каршы килми. Киресенчә, Россиядә төркиләр славяннарны табигый рәвештә тулыландырып тора. Һәрхәлдә, төрки кушылмадан башка Россиягә Евразиядә урын юк.

Өченче нәтиҗә. Урысларны киләчәктә татарлар язмышы көтә, алар хәзергә моны аңламыйлар әле. Киләчәктә урыс, украин һәм белорус телләре (асылда бер теленең төрле шивәләре) мөстәкыйль телләр буларак исән кала алмаячаклар. Аларга славян дөньясын цивилизация буларак үстерү максатында берләшергә туры киләчәк. Европаның күп кенә славян халыклары Германиянең икътисадый һәм мәдәни басымы астына эләкте дә инде. Аларның дөньяга кирәкле телләр һәм культуралар буларак рольләре берничә дистә елдан соң бик көчле сынауга дучар ителәчәк. Совет культурасын ябык чикләр генә коткара иде. Хәзер андый чикләр юк. Бүген табигый конкуренция хакимлек итә.

Татар теленең киләчәге бармы соң? Бөек милләтләр арасында аңа урын табылырмы?

Татар телен төрки дөньяда мәдәни кыйммәтләр алмашуга ярдәм итә торган арадашчылык функциясе генә саклап калачак. Бу—Көнбатыштагы либераль идеяләрнең төрки телдә чагылышы булачак.

Глобализация барча илләргә дә кагылачак. Тик шул ук вакытта гомумдөнья культурасын тулыландырып һәм туендырып торучы локаль культуралар сакланачак. Аерым этник культураларның конкурентлыкка сәләте гомумкешелек хәзинәләрен баету дәлиле булып калачак. Көнбатыштагы кече предприятиеләр, бер-берсе белән ярыша-ярыша автогигантларның төп конвейерына запас детальләр китергән кебек, милли культуралар да дөньяның идея фабрикаларына яңалыклар һәм ачышлар ташыячак.

Төрки культураның бөеклеге һәм әһәмияте, анда татар теленең урыны безнең ихтыярдан һәм булдыклылыктан тора.

Татарстан өчен икътисадый фактор гаять әһәмиятле. Республикага үз тауарларын сатар өчен базар кирәк. Халыкара конкуренцияне һәм тауарларыбызның сыйфатын исәпкә алсак, көнбатыш базарлары безнең өчен ябык икәне аңлашыла. Безнең өчен Көнчыгыш кала. Көнчыгыш өкренләп урыс телен онытачак. Димәк, бер үк вакытта төрки, урыс һәм инглиз телләрен белүче кешеләр кирәк булачак. Шул рәвешчә әлеге функциянең дә кирәге чыгачак. Татар телен саклауга һәм үстерүгә бар өмет тә шунда. Нәкъ менә шул сәбәпле, Татарстанда татар балаларына гына түгел, урыс һәм башка халыклар балаларына татарча өйрәтүнең мәгънәсе бар. Бу безнең гражданнарга Азиядә эшләү өчен өстенлекләр бирәчәк.

Татарларга исән калу өчен бик каты көрәшергә туры киләчәк. Бу юлда иң беренче адым—латин графикасына күчү. Кириллица, гарәп алфавиты кебек үк, татар теле өчен уңайсыз. Бүген күпләр латиница белән баш катырырга кирәк микән дип борчылалар. Күпме чыгым тотарга һәм Мәскәү басымына каршы торырга кирәк булачак. Кириллицага барыбыз да күнеккән идек бит инде.

Минем әтием—Сибгат Хәким, теленең бар нечкәлекләрен дә белгән кеше буларак, теге яки бу графиканың өстенлекләренә тулысынча бәя бирә алырлык шәхес иде. Ул башта мәдрәсәдә гарәп алфавиты, аннан соң яңалиф өйрәнгән, гомер буе кириллицада язган. Ул татарларга иң төгәл графика—латин дип саный иде. Бу—икеләнергә урын калдырмый торган абруйлы фикер. Хикмәт бары тик шунда: латинның кайсы вариантын сайларга һәм аңа күпме вакыт эчендә күчәргә?

Бөтен дөньяның, һәрхәлдә аның дөньви процессларны билгеләүче өлешенең латинга күчүен исегезгә төшерү урынлы дип уйлыйм. Бу процесстан хәтта Япония дә читтә калмады. Хәзерге вакытта кириллицаны кулланган халыкларны алдынгы дип әйтеп булмый. Болар—Россия, Украина, Белоруссия, Болгария, Сербия, Казахстан һәм Кыргызстан. Әлеге исемлеккә әллә ни ис китми шул.

Татарлар өчен совет чоры нәтиҗәләреннән бигрәк, шул чор эчендә

дөньяның бик нык алга китүе куркыныч тудыра. Россия юл читендә утырып калган булып чыкты.

Латин графикасы татар сөйләменең үзенчәлекләрен төгәл чагылдырып кына калмыйча, мәгълүмат системаларында үз урыныбызны табарга да мөмкинлек бирәчәк. Яңа гасырның асылы—мәгълүмати революция. XX гасырның символы Форд уйлап тапкан конвейер булса, яңа гасыр символы—Интернетка тоташтырылган компьютер.

Мәгълүмат системалары—тормышка йогынтысы буенча басма китап барлыкка килүгә тиң революцион күренеш. Интернетка бары тик өстәмә техник җайланма дип кенә карарга ярамый. Ул безгә өр-яңа дөнья ачты, анда чикләр дә, цензура да юк. Интернет теләсә кемгә ачык һәм санаулы минутлар эчендә, беркинди ераклыкларга карамастан, теләсә кем белән тоташтыра ала. Ул фән, икътисад үсеше, мәгълүмат алмашу өчен моңарчы күрелмәгән киң мөмкинлекләр ачты, кешеләрнең яшәү рәвешен үзгәртте.

Заман мәгълүмат системаларында үз урынын тапмаган халык тарихтан төшеп калачак. XX гасыр башында татарларның роле Россиядәге төрки халыклар арасыннан беренчеләрдән булып нәшриятләр ачу, китап, газета таратудан гыйбарәт булган. Алар Көнчыгышка яңа гыйлем китергәннәр. Бүген исә татарларның функциясе—мәгълүмат системалары төзү.

Татарларның латин графикасына күчү юлында ике киртә тора: беренчесе—сәяси—Россия хакимияте структураларының каршылыгы. Икенчесе—инде кабул ителгән алфавитның кимчелекләре.

Мәскәүнең татар латин графикасына кискен каршылыгын юридик яктан шәрехләү мөмкин. Россия Конституциясе һәм халыкара хокук үз теленең үсеш юлларын мөстәкыйль рәвештә билгеләүче халык ягында. Дәүләт Думасы исә латин алфавитына күчү илнең куркынычсызлыгына яный дип белдерде. Бу кыргыйлыкның ачык мисалы. Патша Россиясендә латин гына түгел, гарәп алфавиты да, грузиннарның һәм әрмәннәрнең үз алфавитлары да гасырлар буе гамәлдә булган. Һәм алар Россия өчен беркинди дә куркыныч тудырмаганнар. Федераль үзәк латинга каршы күтәрелеп империячел инстинктын һәм урыс культурасының үз абруен югалтудан куркуын күрсәтте. Татарларга латинга күчүне тыю Россия проблемаларын хәл итү дип уйлау көлке. Шунысы аяныч: шушы пычрак сәяси интригага бер төркем татарлар да катнашкан булып чыкты. Әмма сәясәт—вакытлы нәрсә.

Татарның латин графикасы—эшләнү чорында ук, яңалифкә кайтырга теләүчеләрнең "универсаль" алфавит яклылар белән үзара килешенү ... Нәтиҗәдә төрки телләргә хас, әмма татар теле өчен бик үк уңайлы булмаган хәрефләр барлыкка килде. Хәер, татар алфавитын камилләштерү мөмкинлеге бар әле: "койрыклы" хәрефләрне инглиз аналогларына алыштырыга кирәк. Мәсәлән, ş-**sh**, ç-**ch**, ŋ-**ng**. Бу очракта ул Интернетка җайлаша төшә, компьютер клавиатурасы гадиләшә, димәк, алфавит үзе дә универсаль һәм конкуренциягә сәләтле була. Безнең алфавит төрекләрнекеннән бер адым алгарак атларга тиеш. Төрекләр латинга күчкәндә компьютер челтәре булмаган бит әле. Безнең төрекләрне борылышта узып китү мөмкинлегебез бар. Бу—латинга күчүнең тоткарлануын аклаучы бердәнбер нигезле дәлил.

Татарны төреккә иярүдә гаепләүчеләр әлегә аңлап җиткермиләр: төрки дөньясында "угыз" һәм "кыпчак" диалектлары арасында табигый конкуренция туачак. Һәм биредә төп рольне бер яктан төрекләр, икенче яктан татарлар дәгъвалаячак. Моның да аңлатмасы бар. Әлеге ике халыкның һәрберсе—олы тарих һәм бай культура иясе. Төрекләрнең тамыры—Госман империясе, татарларныкы—Алтын Урда. Төркиянең өстенлеге мәгълүм: халкы күп, Европа һәм НАТО белән бәйле дәүләте көчле һәм бай. Үзбәкләр Урта Азия традицияләренә таянып үз юнәлешләрен аныкларга тырышалар. Ләкин, казахлар шикелле үк, алар үз мәгълүмати тәкъдимнәре белән катнашырга әзер түгелләр. Моны татарлар эшли ала. Ләкин безнең дә артык мактанырлыгыбыз юк. Татарстан Республикасын Төркия белән чагыштырып булмый. Россия татарлардан курка, шуңа күрә безгә ярдәм итми. Татарлар аз, өстәвенә кесә ягы да сай. Татарларның бердәнбер өстенлеге—университетлары булу. Аларда мәгълүмат системаларын камилләштерү мөмкинлеге бар. Моннан тыш, тагын шунысы мөһим: татарлар төрки халыклар арасында яши, аларның традицияләрен, мәдәни

үзенчәлекләрен яхшы белә. Әгәр дә без бүген татарча латин графикасын инглиз теленә якын вариантта эшләсәк, ул Интернет өчен уңайлырак һәм үзенә зуррак игътибар җәлеп итәчәк. Һәм безнең тагын бер өстенлегебез артачак. Хәзерге вакытта яшь буын үзен Интернеттан башка күз алдына да китерми. Моны да истә тотарга кирәк.

Безгә хәзер фикер сөрешендә, телдә һәм культурада революция ясау зарур. Һәм ул татар алфавитының латинга күчүеннән башланачак. Бу— котылгысыз. Әгәр дә латин алфавиты татарларны берләштермәсә, Мәскәү безгә каршы күтәрелмәс һәм кириллицаны ныгыту максатында махсус законнар чыгармас иде. Әлбәттә, Татарстаннан читтә, аеруча Башкортстанда татар телен латин графикасында укытуга юл куелмаячак. Моннан куркырга кирәкми, моңа үзе булырга кирәк. Барча татарны да тиз арада һәм бер үк вакытта латинга күчерүгә исәп тоту кыен. Шуңа күрә, күпмедер вакыт татар дөньясы, серблар шикелле, ике алфавит кулланачак.

Латин графикасына бернинди закон да, рөхсәт тә көтеп ятмыйча, үзебезгә күчә башларга кирәк. Аны өйдә, якшәмбе мәктәпләрендә, махсус курсларда өйрәнүне, Интернетта компьютер программалары таратуны беркем дә тыя алмый. Интернетта ş, ç, ņ (төзәтергә!) хәрефләрен баштан ук инглиз хәрефләренә алыштырырга, ә хәрефен ä дип язарга кирәк. Барысы да үз кулыбызда лабаса.

Ләкин бу гына җитми. Татар Интернеты кирәк. Татар милли-мәдәни автономияләренең Федераль Советы Бердәм татар мәгълүмат базасы булдыру максатында күренекле галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре һәм эшкуарлардан торган махсус орган оештырырга тиеш. Бай татарлар бу программага җәлләмичә генә акча бирергә тиеш, чөнки бу гамәл отышлы: алар үзләре татар дөньясыннан иң хәбәрдар кешеләргә әйләнәчәкләр. Безнең атаклы эшкуарлар революциягә кадәр татар мәгърифәтен үз кулларына алганнар иде. Бүген мондый гамәл балаларыбызга компьютер белеме бирү, татар сайтлары ачу һәм аларны гомуми челтәргә берләштерү өлкәсендә котелә. Татар дөньясындагы мәгълүмати революциянең стратегиясен эшләү зарур.

Язмыш татарларны дөнья буйлап тараткан. Бүгенге көндә барча татар өчен нәтиҗәле эшли алырдай оешмалар төзү авыр. Әмма глобализация аркасында бездә Интернет барлыкка килде. "Татар электрон пәрәвезе" халыкны берләштерергә, аны хәрәкәтчәнрәк итәргә булышачак. Татарларның компьютер аша аралашуына бернинди административ чикләр дә, үзәк һәм җирле хакимият каршылыгы да комачау итә алмаячак. Шуңа күрә, һәрбер татар гаиләсендә кириллица һәм латинда эшләнгән татарча программалы компьютер торырга һәм ул Интернетка тоташтырылган булырга тиеш.

Татарлар борын-борыннан балаларын башта атта йөрергә өйрәткәннәр. Бүген исә аларны иң элек компьютерга өйрәтергә кирәк. Шул очракта гына алар бу дөньяда үз юлларын табарлар.

Озак уйланып һәм үзара талашып торырга вакыт юк. Бар ихтыярны бер йодрыкка җыеп, кайчандыр бабаларыбыз җәдидчелек юлына баскан шикелле, тарихи ыргылыш ясарга кирәк.

Татар, синең телеңнең киләчәге нинди? Бу хакта уйланасыңмы? Синең телеңнең меңьеллык тарихы бар. Дөньякүләм бөек дәүләтләрнең берсе булган Алтын Урдада шушы телдә сөйләшкәннәр. Ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләре, безнең дөньяга карашыбыз шушы телдә тупланган. Аның киләчәге хәзер синең кулда.

Татар, син үз тарихыңның төрки дөньядан аерылгысыз икәнен онытмаска тиеш. Димәк, киләчәкне дә шул дөньядан башка күзаллау мөмкин түгел. Катып калган ялган фикерләр белән башыңны катырма, синең кебек үк мескен хәлдә калган кардәшеңнең сүзенә колак сал. Аңа кулыңны бир—сталинчыл "тел киртәсе" калдыкларын җимереп ташла. Германиядә моны эшли алдылар бит.

Кайчандыр татарга тылмач кирәкми дигәннәр. Бүген алай түгел. Әмма заманалар үзгәрә һәм халкыбызның асыл сыйфатларына кире кайтыр чак җитте. Һәрбер татар урыс теленнән тыш, инглиз яки башка Европа телен белергә тиеш. Ләкин иң элек син үз телеңне белергә бурычлы. Әгәр дә син ана телеңне дә, милли культураңны да белмисең икән, синең бу дөньяда беркемгә дә кирәгең юк.



# Әмир Мәхмүдов

## АК ТӨШЛӘР

### Бу да төшме?

Мәхкәмә карары көчле,
Һәр татар калды өнсез:
Имештер, булырга тиеш
Ил башы аның...
Телсез!

### Бәхетем юлларында

*Дим буйлары буйлап килә*
*Рәйхан гөлнең исләре.*
*Аларның да безнең кебек*
*Өзелә микән эчләре?*
Халык җыры.

Рәйхан гөлләр гашыйк итәр
Димкәем тугаенда.
Рәйханалар үсеп җитәр
Сихри Дим буйларында.

Рәйханалар үсеп җитәр,
Булырбыз туйларында...
Рәйхан гөлләрем исертер
Бәхетем юлларында.

---

Әмир МӘХМҮДОВ *(1947) —шагыйрь, филология фәннәре докторы. «Матурлык тантанасы», «Мәңгелек моң» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Чынга аша икән ак төшләр!—
Каршы алды мине аккошлар.
Үтте, китте салкын ак кышлар.—
Чынга аша икән ак төшләр.
Кышлар аша кайта ак кошлар...
Кай җирләрдә ак, пакь җан кышлар?!

## Бәхет

Ятим бала кебек, Бәхет
Баганага сөялгәндер.
...Хакыйкать бер:
Синнән башка
Беркемне дә сөялмәмдер.

## Шайтан туе

Җиркәемдә—шайтан туе...
Иблисләр әмер итә:
Әфган халкын утка тота
Террорист Америка...

Иблисләр яши Җирдә,—
Террорчы илләр яши...
Бомба булып төшәр сезгә
Ятимнәрнең күз яше!

## Бүре

Капкынга эләккән бүре,
Капкынын сөйрәп бара...
Аучы (илле сум алмакчы!..)
Мылтыгын төзәп бара.
Бүрене куып җитмәкче...
Тик якынаймый ара.

Биек таудан бара бүре,
Капкынын сөйрәп бара.
Ап-ак карда—каны кара,
Аучысы да хәтәр түгел.
Тик сызлый гына яра.

## Кан вакыты

Гасыр—китте. Күптән үтте
Таң вакыты. Йолдыз калыкты.
Татар өчен килеп җитте
Дан вакыты. Кан вакыты.

Каннар сорап килеп җитте
Данлы чагың.
Афәтләрдән котылырга
Бармы сагың?
Яңа мең ел
килеп җитте
Күрсәтәм, дип, куәт, көчен.
Көч-куәтең җитәрме соң

Газиз халкым, ирек өчен?
Яшәрсеңме еллар буе
Башка чит-ят халык өчен?

Кан вакыты...
Таң вакыты—
Үтте инде татарның.
Озак яшәрсеңме, халкым,
Күңелен күреп ятларның?

## Чеченстан

Чеченстан, синең күкләреңдә
Ак болытлар гына йөрмидер.
Ач козгыннар синең тауларыңда
Кара үлемнәрен эзлидер.

## Алдый

Дөньяны һич аңлап булмый,
Дөнья ул—матур алдый.
«Алтын кирәк!»—дип әйтәсең,
Ул әйтә: «Бакыр ал!»—ди.

## Дөнья

Көтмәгәндә ишек ачыла да,
Көтмәгәндә—ишек ябыла.
Яшьрәкләр очып, кереп кала,
Картларга да... «бишек» табыла.



# Сәйдә Зыялы

СӨЮ ДӘВАМЫ

## Шул бер төн

Без кавышкан июнь төне
Төшертмәде пәрдә читен:
Илаһи шул яктылыкка
Утырдык без гел ис китеп.

Июньнең иң кыска төне
Сыйдырды бар хыялларны...
Сөтләрдән ак, сулардан пакь
Итеп күрдек бар дөньяны.

Дөнья шундый ап-ак иде.
Сөенештек шул аклыкка.
Чишмәләрнең җырын алып,
Очтык икәү ак болытка.

...Ерак калган мизгелләрне
Сөйлим инде хәзер кемгә?..
Гомерләргә җитәр бәхет
Сыйган икән шул бер төнгә...

## Бездән кала бары гамәлләр

Бер килгән без җиргә... Бер китәсе...
Табигатьнең каттый кануны:
Үз-үзеңне эзләп табу өчен
Кешеләргә биргән януны.

Бер килгән без җиргә... Бер китәсе...
Һәрбер гомер җирдә санаулы.
Тану өчен яхшы һәм яманны
Кешеләргә биргән сынауны.

Бер килгән без җиргә... Бер китәсе...
Бездән кала бары гамәлләр.
Гамәл арасында Галәмне дә
Юлдан яздырырлык хәрәм бар.

Сәйдә ЗЫЯЛЫ— *шагыйрә. «Айның тулган чагы», «Кайнар сукмаклар» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Бер килгән без җиргә... Бер китәсе...
Алмагач та коя алмасын.
Бездән калган гамәл каршысына
Хәрәм килеп чыга алмасын!

## Дәвам

Яшеннән соң дөнья пакь һавалы,
Ачылыплар китә сулышлар;
Түтәлләрем тулы яран гөле,
Бөреләре тәмам тулышкан.

Дымлы яфракларның сулышыннан
Бөркелә тик сөю хисләре.
Үкенечтән түгел, иркә-наздан
Йөрәккәем әллә нишләде.

Иңнәремә әллә канат үсте,
Әллә инде җаным адашты?
Өнсез калып бактым дөньясына—
Мәхәббәттә гөлләр аңлашты!

Яшьнәп үтте яшен...
Яңгырдан соң
Дымлы ямь тутырды һаваны;
Ачыласы чәчәк бөресендә
Балкып тора сөю дәвамы.

## Анам кыры

И, Әнием! Чыктым әле кырга.
Кыр-басулар инде үзгәрде.
Еллар түгел, гасыр кичәлсә дә
Табармын күк синең эзләрне.

Учма-учма алып урак урдың:
Элек арыш, аннан сабанын...
Бер шешә сөт, ике бәрәңгегә
Риза була иде тамагың.

Кадалса да камыл табаннарга,
Башак уып бергә туендык.
Бу кырларда синең тир таммаган
Тургай төшәрлек тә урын юк.

Чәчкән, урган, чүбен утаганда
Бу кырларны ничә иңләдең?
Ат шикелле эшләп... киярең
Булмады бит алмаш күлмәгең.

И, Әнием! Тагын чыктым кырга.
Мөлдерәмә тагын күңелләр...
Хәтерләтеп синең йөзләреңне
Серкәләнә кырда игеннәр.

## Яз килгән чак

Яшел хәтфә иркен болыннарда,
Табигатьтә сафлык тарала;
Шул мәлләрдә мин дә гел терелэм,
Шул мәлләрдә мин дә яңарам.

Җырчы кошлар матур көен башлый,
Туган якны мактап яңадан;
Шул мәлләрдә мин дә гел терелэм,
Шул мәлләрдә мин дә яңарам.

Табигатьнең әле гашыйк чагы.
Һәр тарафта чәчәк ярала;
Шул мәлләрдә мин дә гел тереләм,
Шул мәлләрдә мин дә яңарам.

Ул чакларда сулкылдамый йөрәк
Язмыш биргән ачы ярадан;
Бар дөньяга ямьнәр сибәр өчен,
Бакчаларда гөлләр яңарган.

Шул ук болын, шул ук бакча юкса,
Әйтерсең лә бар да өр-яңа!
...Ярый әле һәр ел язлар килә—
Матурлыгы белән—дөньяга.

## Тик игелек калды

Әйтелгәндер кайчак саксыз сүзләр...
Акыл йөри арттан. Сүз—әлек.
Аткан уктыр—сүзем.
Әмма нишлим:
Күңелемдә бүген игелек.

Акыл китә ачу килгән чакта.
И, үкенәм хәзер тилмереп...
Ачу күптән китте.
Әмма нишлим:
Күңелемдә бары игелек.

Тән ярасы бетә, төзәлә ул.
Сүз ярасы сызлый илереп.
Җанда һаман яра...
Әмма нишлим:
Күңелемдә бары игелек.

Булмый тормыш гел кояшлы гына,
Тормый якты һаман сибелеп.
Дөньядан гел гыйбрәт ала торгач,
Күңелемә тулды игелек.

## Гыйсъянчы

Өлешемә тигән көмешемме—
Ул кадәрен белим мин каян?
Бер терәлсәм, йөз мәртәбә үләм,
Күз яшемне йотып елмаям.

Мизгелләргә тиңлим гасырларны,
Уйларымда очыш тоям мин;
Ирекле дип йөрим үз-үземне,
Юкса, ирек—бары хыялым.

Лаеклыны һәрчак хөрмәт итәм,
Ышанам мин көчсез көчкә дә;
Кайгыларга башым имәсәм дә,
Шатлык килсә, күңлем нечкәрә.

Газапларны һәрчак яшерсәм дә,
Бәхетләрен тыймыйм мин аның:
Язмышымның колы булсам да, мин—
Гыйсъянчысы әчке дөньямның.

**Нурулла
Гариф**

# СИН ЯШӘСӘҢ, БЕЗ ДӘ ЯШӘРБЕЗ

АВЫЛГА МӘДХИЯ

*И авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямле вә хуш...*

Сәгыйт Рәмиев

БЕЗ БАРЫБЫЗ да авылда туып-үскәннәр. Үзен шәһәр кешесе итеп күрсәтергә теләүчеләрнең нәсел-нәсәбендә казынсаң, аларның да тамырлары берничә буыннан соң барыбер авылга тоташыр. Әмма гел алай булмаган. Үткәнендә—Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында—Идел-Чулман төбәгендә 200 дән артык шәһәр искә алынып, бабаларыбыз ватаны «Гардарика»—шәһәрләр иле дип аталган. Соңрак, Казан ханлыгы яуланганнан соң, меңләгән авылның исән калган 400 гә якынында көн күрергә, яшәү өчен җан асрап, көрәшеп, телен, динен, тарихын саклап, киләчәккә тапшырырга язган бабаларыбызга. Соңгы дүрт-биш гасыр дәвамында татарның тибрәлгән бишек-ватаны, дәүләтенең башкаласы да шул авыл булган. Без дә уку-тәрбия, дөньяны танып белергә өйрәткән тормыш университетлары гыйлемен шунда алдык. Бүген дә шул ук рухи азыктан тукланабыз әле.

Һәр буынның үз укытучылары бар. Безнекеләр әти-әни, таякка таянган әби-бабайлар, барын да белеп торучы күрше-күләннәр иде. Үзебез дә яхшы укучылар, укытучы абый-апаларыбыз сөйләгәннәрне, бар күреп белгәннәрне дәфтәрләребез арасындагы киптергеч кебек, күңелгә сеңдереп баручы ачык авызлы малайлар идек. Соңрак аңышканча, чит җирләргә китеп, дөньяви университетлар бетереп тә, барыбер әниләр чаклы укымышлы булып, әхлакый тәрбия, белемгә ия булырга насыйп булмаган икән безгә. Бүген инде каршыбызда яңа буын баласы—үз кызулларыбыз. Боларның уй фикерләре, белемгә омтылышлары башкача. Укытучы апаның һәр әйткән сүзе дөрес, директорның һәр кушканы канун дип уйлаучы малай-шалайларны да тапмассың хәзер.

Шулай да миңа безнең буын баласы күпкә бәхетлерәк булгандыр кебек тоела. Ул заманда шайтаннары, тегенди-мондый «денди»лары, «теле»—телсез күрсәтеп, көн-төн сөйләп, җырлап торучылары юк иде. Бар да гади, табигый һәм шунысы белән бары да татлы иде. Әниләрне тәмле әйберләр сорап та тинтерәтмәдек. Хәер, аның кибетләрендә шикәрписуктан башка баллы әйбере юк та иде бугай. Шулай да дәреслек хакына әйтергә кирәктер, нигәдер тешләр бик еш авыртып, бәгырьләргә үтеп сызлый иде.

Без, авылдан китүчеләр—аны язмыш кочагына ташлаучылар. Ә шәһәрдә ятимнәр яши, илсез-җирсез калучылар. Шуңа иялэшергә дә һәм шуның белән мактанышырга да була икән бит әле. Дөрес, без үз иркебез белән китмәдек анысы. Шулай ук куып җибәрделәр дип әйтү дә ярамас. Мәҗбүр булгач, зур өмет-хыялларга бирелеп, үзебезне тышаудан ычкынган атлардай тоеп, бер-беребезне узыша-узыша киттек инде. Әнилэрдән еракта безгә барысы да рөхсәт ителер кебек тоелды. Яраганы, ярамаганы да. Киңәш биреп, тыеп торучысы да юк иде. Шунлыктан, таптык та, югалттык та. Тик кайсысы зуррак булгандыр, бу турыда кайта-кайта уйланып, үкенәселәр алда әле. Арабызда сирәк кенә булса да зур урын, байлыкларга тап булучылары да очрады. Һич булмаса, бәлкем, алары тормышларыннан ризадыр. Тик авыз тутырып, алар өчен дә канәгатьлек килгәндер дип әйтә алмыйм. Шикләндерә.

Безнең табышларыбыз, күбесенчә дөнья буйлап таралган, җиңел бирелгән ирек, күңел ачуга омтылышлар булды. Югалтулары исә бәләкәйдән сеңеп, җанга якын булган, әмма тора-бара үзгәреп онытылганнары дин, тел, гореф-гадәтләргә бәйле иде. Белмим, авылның шундый иркенлек-киңлекләрендә җанга мондый тарлык каян сыйгандыр. Элек авылдан рәхәт тормыш, иркенлек эзләп киткән идек без. Инде менә арып-талып, кайчандыр безне ымсындырган шау-шулы тормыштан туйганлыктан, тынычлык эзләп, авылга кайтып бару. Безне әле анда һаман яшьли сөйгән ярлар, уен җирләрендәге гармун-моңнар көтә кебек. Гомер үлчәве дә чик якка таба чайкалган инде. Безләрдә кабат бер язмыш. Бу юлы да «гаеп»—дөньясында. Кабат барын да кирегә борып, үги баласыдай күреп, дулкын кебек читкә кага ул безне. Дөнья яшәеше буенча болай булырга тиеш түгел иде дә бит, тик, бер табигать буйсынуында булса да, кешелек белән кешесезлекнең үз кануннары шул.

Авыл, әти-әниләребезне әби-бабайларга әверелдереп, үзе дә картайган инде. Ә без үскәндәге әби-бабайларны хәзер бар дөньясын бетереп эзләсәң дә тапмассың. Үзебез дә ялгыз түгел. Янәшәбездә—бер үк язмышка тарыган тормыш юлдашы, нилэр күрсәтерлеген уйлап, хәзердән үк куркуга салган бала-чагасы. Шулай да күңел—шайтан түгел, авылда тынычлык, җанга рухи азык табарына өметләнә әле...

Һәр авылның үз йөзе, үз төсе. Үзендә яшәүчеләрдән аермалы буларак, без аның ис-тәмен дә тоябыз шикелле. Һәр авылның үз тормышы, үзгәрмәс сыйфатлары бар. Һәр авылның яшәүчеләре һәм аның үзен яшәтүчеләре бар. Үз игелекләләре, үз имгәкләре дә чыга аннан. Әмма дөньясында берни дә катып калмый. Вакыт узу белән авылның көнкүреш тормышы, яшәгән уңайлык сыйфатлары да үзгәреп тора. Дөньясында булган бар ачы үзгәреш җилләренең авырлыгын үзендә татыган авылларны соңгы чиккә җиткермисе иде дә бит. Шул ук авыл хозурыннан чыккан ил җитәкчеләрнең бу турыда уйланырга вакытлары бармыни?!

Бүгенге көндә дә авылда татар халкы җир җимертеп бушлай эшли. Их, өзрәк акчасын да түләсәләр икән! Кабат төрле буталчыклар чыгарып, элекке чордагыча бер сыер, дүрт сарык белән чикләнеп, алмагач саен салым салмасалар. Рәсәй кулындагы үз байлыгын кире тартып алса икән авыл... Абый-апалар хәзер, соңгы сыерын сатып булса да, баласын укыта. Шул балаларга аз гына, кимендә милли төсмерләрен югалтмаслык кына, дини һәм әхлакый тәрбия дә бирсәләр икән. Юк шул, әлегәчә бары да укмашып, чит халык тегерменендә тартыла.

Дөньясы үзе дә хәрәкәттә булып, бер алдын, бер артын күрсәтә. Әле бер 60-70 ел элек, бер көн эчендә бар байлыгын югалтып, авылдан Себер киткәннәрнең оныклары, бүген кайтып, мирасчы буларак, кабат шул байлыкларга ия була баралар. Аерма да бар. Элеккеләре мәчет-мәдрәсәләр тотып, әзме-күпме авыл, милләт казнасына акча кертсә, бүгенгеләре машиналарда «трай» тибә. Хәер, барысын да караңгы төсләргә буяп, барыннан да юньсезлек кенә күрергә кирәкмидер. Әнә бит, ата-бабалары исемнәрен атап, мактарлыклары да бар. Мәчетне дә яңартканнар, зират та әйле булып, яңа койма белән уралган.

Авыл үзе дә акрынлап элекке «беркатлылыгыннан» чыгып килә инде. Әмма халыкны сәясәт бик кызыксындырмый әле. Гомер буе бил бөктергән түрәләренә дә үпкәсе юк. Ни эшләсен инде. Мәскәүенә үпкәләр идең, әнә район түрәсе түгел, үз авылыңның җитәкче «җинаятьчеләре» дә үзен әллә кемгә куеп, барын да изеп, сытып ташларга әзер. Һәрберсе үзенең баю ягын гына каера. Шулай да кешеләрнең дөньясындагы үзгәрешләрне күреп, уй-фикерләренең үзгәргән чагы. Авыл белән шәһәр арасы күпкә кыскарып, үзара бәйләнешләры да үзгәргән инде. Элекке чорлардагы кебек, барысына да ризалашып утыручыларны бик тапмассың. Аралашулары да күбрәк «син—миңа, мин—сиңа» канунында хәзер. Акрынлап шәһәрнең бар уңайлыкларын үзендә туплый авыл. Әнә, әле кайчан гына безнең ялан аякларның эзе катып калган сазлы урамнарга таш җәйгәннәр. Күп тә үтмәс, асфальт җәелгән бу урамнардан җир җылысын тоеп яланаяк йөрүдән мәхрүм калган яңа буын шак-шок кына «көттә» басып йөрер. Алары да шәһәрнең шайтаннары, кайчандыр авылны язмыш кочагына ташлап китүчеләрнең угыл-оныклары булып калмасмы?

Татарны милләт буларак саклап калучысы да, яшәткәне дә бары бер авыл. Аның тирәсен әйләндереп алган койма капкалары шәһәрнең таш стеналарыннан да ныграк булып чыкты. Үлем белән яшәүнең кыл уртасында калган халык, үз тормыш-яшәешен, дин-әхлагын ныгытып кына сакланып калган. Бу иман ныклыгын Рәсәй тарафыннан дүрт гасыр буе искән хәйлә, мәкер җилләре дә какшата алмаган иде. Инде менә фән-техника заманы җиткәч, авыл киртәсе аша үтә күренмәле теле-радио дулкыннарның кереп, татар әхлагын кимергән мәле. Бу үзгәрешләргә дә авыл авызын ачып карап тормас кебек. Әле интернеты да керсә, авыл өчен шәһәрнең керәге дә шуның чаклы гына булачак. Шәһәрнең үзенең авыл каршына ялынып килер көннәре алда түгелме әле? Дөньясы да гомер буе шәһәр кебек гел сырты белән тормас. Уйларның шөбһәләндергәне дә бар. Шул интернетларга кереп дөнья гизүләре интернатларда яшәгәндәй газаплы булмасмы? Монысы турында кайта-кайта уйланасы, өметләрнең бер киселеп, бер ялганасылары алда әле.

Тагын бер заман үзгәрешен күрсәтеп, урамның як-ягыннан газ торбалары сузылган. Болары авылны иң сөендергәне. Утын әзерләү мәшәкатенә бәйле рәвештә ярты авылны айнытмый торткан пенсионер әбиләрнең әҗәл даруыдай күреп, үлемтек сандыкларында гына саклаучы «шайтан суы» юкка чыкмасмы? «Исерек ир, чи утын» белән җәфалануыннан икегә—ялгыз хатын, буйдак ир-атларга бүленгән ярты авыл халкы, бер-берсенә баш бирмичә яшәвеннән туктап, бәлкем кабат авылның киләчәгенә өмет биреп, бергә кушылыр. Газ керү, бар авылны айнытып, аны олы гөнаһ—аракы эчүдән дә коткарса икән... Аның нәтиҗәләре татар дөньясына гасыр башындагы урыс «революция»сеннән дә зуррак үзгәрешләр китерергә мөмкин. Ул гына түгел, авылны шәһәр алдына тезләндереп торучы башка «баулары» да өзелә. Күпләрнең шәхси трактор, машиналары бар хәзер. Ә аның арадашчысы, авыл халкының җир җимертеп эшләргә теләгән тезгенлектә тотучы колхоз-совхозлар җан-тәслим кылып ята бүген.

Авылның үткәндәгесе белән бүгенгесе арасында аерма зур. Аның карашлары киңәйгән саен дөньясы тарая. Һәр өйдә дөньясының ничек кайнавын, кая баруын күрсәтеп телевизорлар тора. Алардан күренгәнчә, дөньясын су да баса, җир дә тетрәтә. Ахыр заман алдыннан сурәтләнгәнчә, халыклар төркем-төркем булып урам-калкулыкларга җыела. Гыйбрәтләрен күрсәтеп, киләчәкне кисәтүче башка хәбәр-хәтемнәр дә җитәрлек. Тетрәнүләрнең кайберләре татар авылларында да күзәтелә. Алары әлегә чөкердәшкән стакан, авыл «мужиклары» алларында чайкалган аракы дулкыннарыннан гыйбарәт. Аның шаукымы елдан-ел ешаеп, хәвеф-хәтәр, үлем-җитемнәргә дә китерә. Бу тетрәнүләрнең татар халкына табигать бәлаләреннән дә зуррак югалтулар китерүе мөмкин.

Авылда да шәһәрчә яшәп була хәзер. Күбесенең бәдрәфләре дә өйләренә кергән инде. Аларында зәңгәрсу төстәге француз унитазларын да очратырга була. Ә менә эшсез калган татар комганнарын музейга куяр өчен дә эзләп таба алмассың. Алар төсле металл җыючы пунктлар аша узып, күбесе җиз чиркәү кыңгырауларына коелган. Татар халкы

язмышына тарып, күп кенә авылдашларның оныклары кебек, алары да урысча доңгылдый. Бер тамырдаш-туганнарның нәсел-тамырлары кибүе өметләрне күбрәк кисә. Кайда абындык та, кайда сөртендек соң без?!

Элек, без үскәндә, авылның бар яшәеше дә тәгәл үлчәнгән, уйланылган иде. Кияү, кыз табулары да күп очракта тормыш тәҗрибәсен туплаган яучы карчыклар башкарды. «Чиләгенә күрә—капкачы»,—дип үзебезгә дә менә дигән кызлар табып, димләгәннәр иде. Ә юк шул, тыңламадык! Ризалашмыйча, үзебез сайлап алдык. «Күрше авылныкы күркә булып күренү» генә җитмәгән, күрше өлкә, күрше халыкларга чаклы барып җиттек. Үткәннәр, гореф-гадәтләр белән санлашмаган буын без. Шуңа тормыш көн-күрешләребез дә башкача.

Авылны искә төшереп, хәтернең әллә кайсы почмакларына таба тәгәри бу уйлар йомгагы. Тәгәри дә, әллә кайсы гомерләрдән тыныч кына йоклап яткан хатирәләрне уятып, тышка чыгара. Кичкенәдән канга сеңгән авылның җыр-моңнарын миләрдә чыңлата... «Эх дусларым, дусларым, дусларым-дус ишләрем, сез дуслардан аерылсам, ялгыз башым нишләрмен...» Бер учак тирәсендә бәрәңге пешереп, җырлап үскән малайлар идек без. Гомер буе шулай бергә уйнап, иңгә-иң терәшеп, ярдәмләшеп яшәрбез кебек тоелган иде. Тик берникгә дә буйсынмаган вакыт агышы һәммәбезне таратты шул. Сүнгән учакның көл-күмер эзләрен генә түгел, урынын да тапмассың хәзер. Бергә җыелыша алмауның сәбәпләре дә төрлечә... Кемнең хатыны, кем үзе юньсез булды. Кемгәдер аякны аракы, кемгәдер шайтанның башкасы чалды. Кайтыр, җыелыр көн җиткәч кенә кемгәдер акчалы эш тәкъдим иттеләр, кемнеңдер баласының, кемнеңдер баҗасының туган көне җитте... Шунлыктан сабан туе—җыеннарда гына биш минутка очрашып, кемнеңдер мактануларын, кемнеңдер уф-зарларын тыңлап, хәл-әхвәл белешәбез. Бала чакта кичергән тойгылар белән уртаклашып, бүгенге каткан күңелләрне алдап, аз гына булса да шул чорларга кайтып килер вакыт калмый. Хәзер без башка инде, бары авыл гына күңелне нечкәртә... Әллә нигә бер булса да балачакка кайтарып, күңелне яшәртә. Әйе, авылга еш кайтмасаң, оныталар шул, аннан соң дөньясына юкка үпкәләп йөр инде.

Авылның тарихын да, киләчәген дә шәһәрдән аерып булмастыр. Без генә түгел, элегрәк балаларын озатып калган әби-бабаңнарның да кайберләре шәһәрләрдә яши хәзер. Шунда дөнья куйгач, аларны мәңгелеккә авылга кайтаралар. Салкын җир куены кайда да бер булса да, һәркем авылны, ата-бабасы нигез-җирен кулайрак күрә. И кеше, нинди генә кырыс чүл-котыплар, сазлык-таулар булмасын, оҗмахларга алыштырмастай газиз ватаның авыл—кендек каның тамган газиз җир сиңа.

Ни-нәрсәләр генә кичерсә дә, кеше күңеле өметләнмичә яши алмый. Безнең буынны азмы-күпме алдап, яисә куркытып була иде әле. Бүгенге көндәгеләрне башкача уйлатып булмый инде. Соңгы вакытта өметләребезне аклап, яшьләр авылда кала. Бер ара ике дистә чамасы калган бала-чаганың да исәбе, авыл мәктәбен яңадан ачарлык булып, илле-алтмышка җиткән. Тик барысын да үз хәленә кайтарып булырмы? Элекке мәчет урыны—яшьләр күңел ачкан клуб бинасы хәзер. Китапханә нигезендә—яңа мәчет. Ә без үскәндә шау-гөр килгән мәктәп урыны көтүлеккә әйләнгән. Шулай да авылның иманы бөтенләй чыгып бетмәгәндер кебек. Изге йорт урыннарындагы мәдәният йортлары, китапханәләр дә һаман шул ук юнәлеш-кыйблага карап тора әле. Бары үзебез генә бераз юньсезләндек. Бер-беребезгә якынлык, туганлыгыбыз да бары йомыш төшүгә кайтып калды. Эх, бик үзгәрәсе иде дә бит, үзгәрүләре, үзгәртүләре авыр шул...

Киләчәк турында уйланганда һәрчак халыкның тибрәлгән бишеге авыл искә төшә. Аның бүгенге халәтенә бәйле милләтнең киләчәге турында уйланасың. Дөньясының бернинди үзгәрешләренә дә карамастан, иртәге көндә дә тәрбиячебез, матди вә рухи яктан да тукландыручыбыз булып калсаң иде син—Авыл. Нәкъ шигъри юллардагы кебек: «Син яшәсәң, без дә яшәрбез».

# ХӘЛЕҢ НИЧЕК, ТАТАР КИТАБЫ?

## «РУХИЯТ» НӘШРИЯТЫНДА «ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ» СЕРИЯСЕ ЧЫГА БАШЛАУ УҢАЕННАН ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА ӘҢГӘМӘ

*«Казан утлары» журналы, күренекле татар зыялыларын җыеп, түгәрәк өстәл янында әңгәмә үткәрде. Анда журналның баш мөхәррире **Равил Фәйзуллин**, баш мөхәррир урынбасары **Флүс Латыйфи**, бүлек мөхәррирләре **Наис Гамбәр** һәм **Марат Закир**, «Рухият» фонды җитәкчесе **Илсөяр Хәйруллина**, «Идел-Пресс» Дәүләт унитар предприятиесенең генераль директоры **Ислам Әхмәтҗанов**, академик **Миркасыйм Госманов**, Татарстан Дәүләт советы депутаты **Туфан Миңнуллин**, галим **Җәүдәт Миңнуллин**, Г. Камал исемендәге татар Дәүләт академия театры директоры **Шамил Закиров** һәм баш режиссеры **Марсель Сәлимҗанов**, Татарстан үзәк Милли китапханәсе директоры урынбасары **Ирек Һадиев**, Татарстан баш архив идарәсенең бүлек мөдире **Гөлфия Садретдинова** катнашты.*

*Бүгенге көндә татар китабы ни хәлдә, мәдәниятны кайгыртырдай милли җанлы татар байлары бармы, милләт өчен зур эшләр башкарган олуг шәхесләребезнең исемнәре онытылмыймы, зыялыларыбызны ни борчый, нинди гамьнәр били—әңгәмә әнә шул хакта.*



**Равил Фәйзуллин:** Гаҗәеп процесслар бара: дөнья тотучы хаким дәүләтләр, бер яктан берләшү-глобальләштерү сәясәте алып барсалар, икенче яктан, кабатланмас үзгәлекләрен, үзләренең тарихи чишмә башларын, милли тамырларын бик нечкәләп өйрәнәләр, борынгылык рухын яңа буыннарга сеңдерәләр. Ә безгә, бай рухи мираска ия булып та, бүгенге көндә үз дәүләте юк дәрәҗәсендә булган халыкка нишләргә? Әлбәттә, кичектермәс мөһим эшләрнең берсе: әнә шул бай мирасны киләчәк өчен акыллы файдалана белү. Ниһаять, без дә, халык-милләт булып сакланып калу—милләтнең фәкать үз эше, үз бурычы икәнен, читләрдән нидер өмет итү мәгънәсез икәнен аңлый башладык шикелле. Шигырьдә әйтелгәнчә, «Чит шәфкатен көтмә, йөрәгеңә таян! Киләчәккә карап, үткәнеңә таян!» Шөкер, хәзер бездә дә йокымсырап яткан потенциаль көчнең уяну процессы бара. Җитәкче даирәләр арасында милләтпәрвәр җитәкчеләр күренә башлады. Алар җитәкчелек иткән предприятиеләр мәктәпләр, музейлар ача, мәчетләр төзи, фондлар булдырып, халыкның мәгърифәтен үстерү, рухын ныгытуга булышлык итә. Шундыйларның берсе, иң эш күрсәткәне—«Татнефть» акционерлык җәмгыяте. Ул оештырган «Рухият» янарыш фонды биш ел инде милләткә яхшы гына хезмәт итеп килә. Бүгенге сөйләшүдә мин аның нәшрият эшчәнлеген аерып күрсәтер идем. Бу нәшрият кыска гына вакыт эчендә милләтнең рухи үткәнен барлау һәм киләчәк офыгын киңәйтү өчен бик күп эш башкарды. «Рухият» күренекле галимебез Миркасыйм Госманов белән берлектә онытылып барган Олуг Шәхесләребезне халыкка кайтару эшен башлап җибәрде. Бу башлангычның күркәм нәтиҗәсе—инде дөнья күргән җиде затлы китап. Хәер, Миркасыйм ага туплаган, милләт өчен җан атып утка-суга кергән Олуг Шәхесләребезнең исемлеге шактый зур. Бүгенге буын алар хакында бик аз белә. Безнең бу киңәш-табыш, фикер итү мәҗлесендә, татар халкының күренекле зыялылары катнаша. Олуг Шәхесләребез хакында замандашларга ни рәвешле бәян итәргә, милли нәшриятларыбыз, татар китабы ни хәлдә, милләткә хезмәт итәрдәй җитәкчеләребез, меценат-байларыбыз бармы, милли тарихыбызны өйрәнердәй фәнни-гыйльми потенциалыбыз ни кимәлдә—сүз-фикер орчыгы шул тирәдә бөтерелердер.



**Илсөяр Хәйруллина:** Белгәнегезчә, «Татнефть» элек тә әдәбият-сәнгать әһелләренә финанс ярдәме күрсәтә иде. Ләкин «Рухият» фонды оешкач, бу ярдәм эзлекле бер системага салынды. Бу фондка, кемнәрдер уйлаганча, әлләни зур акчалар бирелми. Булган кадәрен максатчан файдалансаң, байтак эшләр эшләп була икән. Китап нәшер итү—бер юнәлеш. Икенче юнәлеш—сәләтле балаларны ачыклау, аларның талантын үстерү өчен һәртөрле бәйге-чаралар, фестивальләр үткәрү. Әле зур сәхнәгә алып чыкканчы да алар урыннарда—үз төбәкләрендә конкурс-сынаулар уза, сәхнә киемнәре тектерелә. Инде ике ел рәттән Камал театрында аның директоры Шамил Зиннурович Закировның эчкерсез ярдәме белән «Сандугач сайрар илем» балалар фестиваленең гала-концертын уздырдык. Нәшрият эшчәнлегенә килгәндә, безнең беренче проектлар «Татнефть» белән бәйләнгән иде. Аларның табигатьне саклыктыруда тырышлыклары «Көмеш чишмәләр җыры» альбомында чагылды. «Акбүз атым—ак канатым» китабы исә ат үрчетү һәм ат спортын янарту турында гына түгел, ул татарның атлы үткәнен искә төшерү дә булды. Россия нефть компанияләре арасында беренче булып, «Татнефть»нең үз тарихын чагылдырган «Ромашкино» китабы дөнья күрде.

Мин үзем, язучылар арасында кайнашкан кеше, гомер буе урыс шагыйрьләренең булмасам да, гомер буе затлы Мәскәү басмаларына бик кызыгып карый идем. «Их, татар шагыйрьләреннән дә шундый затлы бер серия эшләргә иде»—дигән хыял башта озак йөрде. Ниһаять, полиграфия сәнгате өчен дә, милләт өчен дә горурлык булырдай зәвыклы цикл дөньяга килде. «Классик шигърият» сериясе Фәнис Яруллинның «Көзге моң» җыентыгы белән башланды. Бу серияне тора-бара Рәшит Әхмәтҗанов, Сажидә Сөләйманова, Гамил Афзал, Нур Әхмәдиев, Роберт Әхмәтҗанов, Клара Булатова, Флера Гыйззәтуллина, Зөлфәт, Роберт Миннуллин, Мөдәррис Әгъләмов иҗаты бизәде. Хәзер исә анда керү өчен Гәрәй Рәхим, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ һәм башкалар әзерләнә.

Милләт өчен җанын аямаган шәхесләр хакында архивларда, бүтән чыганакларда сакланып калган материалларны эзләтеп, эшкәртеп, китап итеп бастырып чыгару эшенә исә болай керештек. «Рухият» нәшрияты теркәлгән көннәрдә яшь галимнәр Раиф Мәрданов, Рамил Миннуллин, Сөләйман Рәхимов мина XVI гасыр шагыйре Мөхәммәдъяр турында альбом чыгару фикере белән мөрәҗәгать иттеләр. Без аны Беренче Бөтендөнья татар конгрессына өлгерттек. Шуннан соң, әйдәгез әле, Шиһабетдин Мәрҗани турында да китап эшлик,—дип сөйләштек. Мең ярым гына тираж белән нәшер ителгән шул басма җәмәгатьчелектә зур тәэсир тудырды һәм тиз арада таралып та бетте. Икенче басмабыз исә «Ризаэтдин Фәхретдин» булды.



**Наис Гамбәр:** Мина бернечә ел дәвамында «Рухият» нәшрияты белән хезмәттәшлек итәргә туры килде. Һәм, әйтергә кирәк, мин бу эшне ихлас күнелдән, шатланып башкардым. Ни өчен дигәндә (исеменнән үк аңлашылганча), «Рухият» нәшрияты татар халкының рухын саклап калу, үткәндәге рухи хәзинәләребезне бүгенге укучыга китереп җиткерү юнәлешендә бик изге эш башкара. Алай гына да түгел, нәшрият хәзерге заман авторларының әсәрләрен бастырып чыгару буенча да туктаусыз эзләнүләр алып бара. Минем редакторлыкта дөнья күргән Мөдәррис Әгъләмнең «Кан тамырын кистем», Роберт Әхмәтҗановның «Җәяүле күбәләк» дип исемләнгән шигырь китаплары, Нур Әхмәдиевнең 4 томлык «Сайланма әсәрләр»е шуна дәлил булып тора.

Кыскасы, «Рухият»ның рухы нык, карашлары киң, иманы нурлы. Алга таба да шулай бергә-бергә сөенешергә язсын.

**Миркасыйм Госманов:** Татар шәхесләре—үзе бер искитмәле зур дөнья. Әйе, бу китапларны чыгару идеясе (басым ясап әйтергә телим)—шәкертләремнең башлангычы. Бу группаның «Ризаэтдин Фәхретдин» китабындагы мәгълүматлары



инде кинрәк, колачлырак иде, документаль нигезе дә тирәнрәк булып чыккан. Мин боларны хупладым. Бергәләп сөйләшеп утырганда аерым шәхес турында киң мәгълүмат тупланган сериягә кереп баруыбызны таныдык. Шунда ук унлап күренекле милләттәшебезне эченә алган план төзедек. Илсөяр ханым исә аны тагын да киңәйтергә тәкъдим итте. Менә шулай башланып китте бу эш. Әлегә татарда берән-сәрән генә күренгән биографик романнан аермалы буларак, бу серия баштан ук уңышка юлыкты. Бүгенге көнгә алда саналганнарга өстәлеп, «Фатыйх Кәрими», «Газиз Гобәйдуллин» тарихи-библиографик җыентыклары укучыларга барып ирешге. «Бертуган Рәмиев»ләр дә бастыру өчен әзер. Бу калган, теге калган, дия торгач, исемлеккә 80гә якын фамилия теркәлде. Бу бит әдәбият, сәнгать, мәгърифәт әһелләре генә түгел, асыл шәхесләребез исемлеге! Болар—татар тормышына, татар культурасына тәэсир ясаган шәхесләр! Кызык сорау туа: әлеге исемлеккә кергән һәм керәчәк шәхесләрнең чиге кайда? Бәлки милләт күнеленә утырып житкән, аларга карата милләтнең мөнәсәбәте ачыкланган шәхесләрне генә алырга кирәктер? Бездә бит гаҗәп хәл: күренекле шәхесләребездән кем дә берәү вафат булса, жылый-жылый илтеп күмәбез, онытмаска антлар итешәбез, аннары бик сирәк искә алабыз. Хәтта, вакытлар узгач, каберен эзләп табу да кыенлаша. Франциядә менә бик гыйбрәтле бер гадәт яши: пантеонга иң атаклы французларның сөякләрен жыеп урнаштыралар. Ләкин үлгәч тә түгел. Хәтта Де Гольләре дә әле гади кабердә ята, Жак Кусто да гадәти зиратка күмелгән. 20, 50 ел узгач та, бу шәхес җәмәгатьчелек хәтерендә саклanca, аның жәсәден пантеонга күчерәләр. Бу—төпле, акыллы мөнәсәбәт. Бик кирәк дип табылса, хәзерге заман шәхесләренә урынны башка серияләрдән дә бирергә була ләбаса. Ә менә Бубыйлар, Рәмиевләр, Исхакый кебекләр—еллар белән сыналган зур фигуралар. Алар Вакытка бирешмәделәр. Күпме генә кыссалар, таптасалар, изсәләр дә, алар барыбер ил, милләт түрендә үзләренә лаеклы урынны алдылар. XIX—XX гасырда тарихта үз йөзен, үз эзен калдырган күренекле татарлар хакында, 100 дә булмасын, һичьюгы 40-60 китап чыгара алсак та бу бик изге олы эш булыр иде. Моны финанслауда бер «Рухият» фондына гына салынып булмас. Аны хәл итүнең үрнәген дә тарихтан эзләргә була. XIX гасырда һәм XX гасыр башында татар мәдәнияты нигездә хәйриячеләр исәбенә үскән. Кайсы гына гәзит-журналның, яисә театрның эшчәнлеген алма, һәрберсенең терәге—хәйриячеме-ценатлар. Мәктәп-мәдрәсәләрне әйтәсе дә юк. Хәйриячеләр исәбенә меңләгән мәктәп салынган һәм эшләгән. Халыкның йөзен, рухын алар билгеләгән. Татар мәдәниятен алар тудырып калдырган. Димәк, безгә әлеге сериядә ул заман эшкуарлары, байлары, миллионерларыннан иң күренеклеләрен күрсәтергә кирәк булачак. Алар—тарихка тәэсир ясаган бөек, фидакарь затлар. Рәмиевләрне генә алыгыз: 13 ел дәвамында иң абруйлы «Вакыт» гәзитен чыгарып бөтен төрки дөньяга тараталар, иң төпле «Шура» журналын нәшер итәләр. Өстәвенә 7-8 хәйрия жәмгыятендә әгъза булып, шуларга даими матди ярдәм күрсәтеп торганнар. Бүгенге эшмәкәрләребез Рәмиевләр, Хөсәеновлар, Юнысовларның эшен дәвам итә алырмы? Әлегә бу—бик бәхәсле. Чөнки яңа татар байлары әлегә формалашып житмәгән. Бүгенге көндә безнең Рәмиевләр, Акчуриннар, Дебердеевлар, Яушевлар кебек, гомердән-гомергә, нәселдән-нәселгә бер эшне—бу изге гамәлне башкарып килгән хәйриячеләребез юк дип әйтә алабыз. Чөнки нәселдән нәселгә килгән байларыбыз да юк. Кичәге хәерчеләрнең кайберләре бүген кинәт кенә баеп киттеләр анысы... Әмма алар әле байлыкларын кая куярга да, нишләтергә дә белмиләр. Нигезләре дә йомшак, гыйлемнәре бик сай. Түгәрәкләп шуны әйтәм, әгәр без XXI гасырда да милләт булып яшәргә өмет итәбез икән, элекке мәдәни тормышыбызга житәкчелек иткән, матди жирлек тудырган затларыбызга бурычлы. Алар хакында мәгълүмат туплап, китап чыгаруга галим яшьләребезне тартырга иде. Бер китап икенчесенә формасы, стиле белән охшамаска да мөмкин. Чөнки һәр Шәхес—үзенчә, алар хакында тупланган мәгълүмат та төрле күләмдә була. Минемчә, иң мөһиме—Шәхесне мөмкин кадәр төрле яклап, тулырак ачу.

**Илсөяр Хәйруллина:** Бу җәһәттән, Миркасыйм ага, бер вакыйга искә төште. Әле күптән түгел генә «Рухият» житәкчелегенә китап чыгаруда

булышлык сорап бер матбага вәкиле мөрәҗәгать итте. «Әгәр дә акча бирсәгез, Әлмәт ягыннан чыккан күренекле кеше турында китап нәшер итәр идек»— диләр. «Рухият» акчасы унга-сулга таратырлык түгел. Без китапларны булган аз акчага зәвыклы итеп бастырырга тырышабыз. Әле бит ул китапның милләт мәнфәгатьләре күзлегеннән карап әзерләнгән булуы да шарт.

**Миркасыйм Госманов:** Бик әйбәт шарт. Стиль дигәннән, күренекле кеше хакында язганда, аның нәселен, ата-бабасын да онытырга ярамый. Мәсәлән, без «Фатыйх Кәрими» китабында аның әтисенә дә лаеклы игътибар юнәлтергә тырыштык. Бит Гыйльман ахун Фатыйхны тәрбияләп үстергән, ана төпле юнәлеш, акыл биргән кеше дә. Әлегә кадәр галим-голәмә аны «Гыйльман хәзрәт мулла булган»—дип уратып узып китәргә омтыла иде. Бертуган Рәмиевләргә багышланган китапта да Шакир Рәмиевкә аерым игътибар иттек. Моңарчы гел Закирны гына (Дәрдмәндне) телгә алдык, һәм аның Шакиры да булган дип узып китә идек. Ә бит, документлардан күренгәнчә, нәкъ менә Шакир Истанбулда укып яткан энесе Закирга нинди гыйлем алырга, нинди китаплар биреп, кемнәр белән очрашырга-кинәшләшергә дип юнәлеш күрсәтүче хатлар язып торган. Ул энесенең рухи атасы булган диергә тулы хакыбыз бар.



**Туфан Миңнуллин:** Фатыйх Кәрими белән Шакир Рәмиевнең икесе бергә Европага сәяхәт кылулары исегездәме? Алтын шахталары тотучы миллионер Рәмиевләр, хәзерге байларыбыз кебек, чит илгә чыктык әле дип, дингез яры буенда, ресторанда типтереп, вакытларын күңел ачып уздырмыйлар. Музейларда, китапханәләрдә йөриләр, Европаның бөтен тарихи урыннарын урап кайталар. Аларның әнә шулай үз акчасына дөнья буйлап сәяхәттә йөрүе бүгенге эшмәкәрләребезгә сорау бирергә мәҗбүр итә: Ә сез шулай эшли аласызмы?

Янә бер мәсьәлә бар. Шәхесләргә багышланган серияне чыгарганда төп коллектив—даими редколлегия булырга тиеш, минемчә. Шул чакта гына аны әзерләү таләпләре бер, бизәлеш стиле уртак булачак. Чыккан китапны тиешле адресатына җиткерү мәсьәләсе дә бар. Монысын Милли китапханәбез башкара алыр иде. Аның бит әле башка илләр белән дә китап алышу мөмкинлеге бар.

**Равил Фәйзуллин:** Рәхмәт, Миркасыйм ага. Сез инде бик тәфсилләп сөйләдегез, һәм бу бик тә табигый. Чөнки Сез бу мәсьәләләрнең эчендә кайныйсыз, күбебезгә караганда да күбрәк уйланасыз, хезмәтегез дә зур. Йөзләгән шәхесне барлап, исемлек төзү—үзе бер зур гамәл.

**Миркасыйм Госманов:** Бу исемлек әле тулы түгел, йөз илле дә булуы ихтимал. Бергә-бергә тулыландырыйк.

**Равил Фәйзуллин:** Менә шушы затлы, олпат исемнәрнең тормышын китап рәвешенә китереп җиткерердәй кадрларыбыз бармы соң? Аларны ничек туплап була?

**Туфан Миңнуллин:** Афәрин! «Рухият» тарафыннан да, галимнәребез ягыннан да зур эш эшләнгән һәм эшләнә. Шулай да ашыга төшәргә кирәк минемчә.

**Илсөяр Хәйруллина:** Әйе шул. Шәхесләребезне тиз арада барлап, халыкка чыгару янә шуның өчен дә кирәк, дип уйлыйм мин: күренекле затларыбызның кайсысын гына алып карасак та, аларның нәсел дәвамчылары, ни кызганыч, йә урыслашып, йә яһүдләшеп беткән, күбесе, башка милләткә хезмәт итә. Газиз Гобәйдуллин, Бубыйлар, Фатыйх Кәримиләрнең дә нәселләре милли чисталыгын югалткан инде.

**Миркасыйм Госманов:** Рәмиевләр дә шулай ук...

**Илсөяр Хәйруллина:** Татарның бу зур шәхесләренең үзебезнеке булуын тарихка теркәп, ташка басып калдырсак та, эшебез, көчебез юкка сарыф ителмәгән булыр иде. Кадрлар ягына килсәк,—(инде менә никадәр китап чыгардык!)—бу

биниһая зур эшне шул 3-4 егет эшли. Яшь галимнәрне дә җәлеп итеп, берничә төркем төзесәк, эшебез тагын да сыйфатлы булып, тизрәк барыр дип өметләнәбез. Нәшриятлардан «Идел-Пресс»ның да даими ярдәмен тоябыз. Китапларның полиграфик яктан күркәмлелеге аларга бәйле. Әлеге серияне ике-өч мең данә түгел, 10 мең тираж белән дә чыгарырга хыялланабыз без. Берничә елдан ул басмаларны эзләп тә табып булмаячак бит.



**Флүс Латыйфи:** «Рухият», Татарстан китап нәшрияты һәм «Мәгариф» параллель рәвештә бер үк эшне эшләп бармый микән,— дигән шик туды әле миндә. Сезнең исемлеккә Рәшит Рәхмәти Арат та кергән. Әле күптән түгел генә, аның хакында гаҗәп дәрәҗәдә яхшы эшләнгән, саллы нигезле китап дөнья күрде. Анда Арат турында бөтен мәгълүмат та тупланган, аның иҗатыннан өзекләр дә бар. Нәшриятлар үзара киңәш-табыш итеп эшләсә, кабатланудан качарга була.

**Илсөяр Хәйруллина:** Без анысы Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров белән һәрдаим киңәшләшеп-сөйләшеп торабыз.

**Флүс Латыйфи:** Аннан соң мәсьәләнең янә бер ягы бар: исемлеккә кергән Фатих Әмирхан, Мулланур Вахитов, Мәҗит Гафури кебекләрнең тормышын, иҗатын сурәтләгән китапларны бүген үк чыгару кирәкмидер дә. Моннан бер ике-өч ел элек кенә аларның сайланма әсәрләре китап булып чыкты. Алар хакында инде байтак язылды да. Әлегә күзгә күренмәгәнрәкләрне беренче чиратта өскә калкыту мәслихәтрәк булыр кебек. Шулкадәрле дә беләсе килгән кешеләр бар: Йосыф Акчура, Аитовлар, Алкиннар, Апанаевлар... Узган ел журналыбыз коллективы бөтендөнья татар яшьләре көннәре вакытында халыкара «Идел» лагеренда очрашулар үткәрде. Бактың исә, шаккаткыч хәл: Апанаевлар урыслашмаган диярлек, Апанаевларның хәзерге буыныннан Мәскәүдәге татар яшьләре хәрәкәтендә оештырып, катнашып йөрүче егетне очраттык.

**Марат Закир:** Оныкларының оныгы!

**Флүс Латыйфи:** Әйе, оныгының оныгы. Дөрес, татарча белүе чамалырак, әмма җаны-тәне белән татар! Чыраена язылган-аристократ! Кан, нәсел сакланган. Монысы—сүз уңаеннан гына. Җәмәгать, еллар үтә, заманалар үзгәрә. Дөньялар болай барса, бу Апанаевларны тагын берничә елдан чыгарырга рөхсәт итмәүләре дә ихтимал иң.

**Миркасыйм Госманов:** Минем бу исемлектә чират турында сүз бармый бит. Бу—генераль исемлек, шушы эшнең кирәклеген аңлау, аның арка терәген табу җәһәтеннән мөһим ул. Чират мәсьәләсен хәл итү, анысы—сонрак... Анысы—редсовет эше. Киңәш-табышны исә киңәйтелгән редсоветта тотарга була. Монда тагын бер нәрсә бар: кайбер онытылган исемнәрне мин дә бик белергә телим, әмма мәгълүматлар аз, тупланмаган, башыңны ташка орсаң да, бүген-иртәгә генә китап итеп чыгара торган түгел.



**Марсель Сәлимҗанов:** Редсовет булырга тиеш. Чират мәсьәләсе дә дөрес күтәрелә, минемчә. Менә Габдулла Кариев турында китап бар. Мулланур Вахитов турында да күп язылды. Билгесезрәк исемнәрне күтәреп чыгасы иде.

Хәзерге заманда матди ярдәм итүчеләр—алар әле меценат түгел, вакытлы спонсорлар гына. Монда аерма зур. Спонсор сәдака бирә дә, шуның белән бетте-китте. Ә меценат бит ул озак еллар дәвамында өзлексез матди ярдәм күрсәтә. Меценатка исә үз чиратында хөкүмәттән аңлау-ярдәм кирәк. Әгәр дә меценатлык өчен хөкүмәт салым алмаса, бу хәрәкәт үсәр иде. Әмма тагын шунысы кызганыч: татар байлары арасында татар мәдәниятын читләтеп, башка милләтләргә ярдәмләшүне, хезмәт итүне өстен күрәләр. Татар мәдәниятына ярдәм итүчеләргә хөкүмәтебез җирле салымнар мәсьәләсендә генә булса да нинди дер ташламалар ясасын иде.

**Туфан Миңнуллин:** Элек ничек булган икән? Мәсәлән, Морозовлар заманында...

**Марсель Сәлимжанов:** Аларга хөкүмәт зур ташламалар ясаган.

**Миркасыйм Госманов:** Элек законы булган аның. Ә хәзер—юк...

**Илсөяр Хәйруллина:** Элегрәк елларда бу эшчәнлек өчен промышленность предприятиеләре, шул исәптән «Татнефть»нең дә салым ташламалары бар иде. Әмма быелдан анысын да бетерделәр.

**Марсель Сәлимжанов:** Театр өчен кайбер спонсорларның ярдәмен хәер сыманрак диярлек алган чаклар була. Әмма ләкин даими ярдәм юк.

**Миркасыйм Госманов:** Хәйриячелек—изге нияттән, изге эш эшләргә теләүдән килеп чыга торган гамәл ул. Бүгенге вәзгыятьтә исә матди чыганак, нигездә, чиновниклар кулында. Әмма ул аларның да милке түгел, алар—арадашчы гына. Чын хәйриячелек исә хосусый милек булганда гына мөмкин. «Рухият»—хәйриячелекнең яңа формасы, әмма аның да вакытлыча гына булуы ихтимал.

**Марсель Сәлимжанов:** Хәйриячелек белән шөгыльләнүче түрәләребез дә юк түгел.

**Миркасыйм Госманов:** Ләкин андыйлар—йөзгә бер генә.

**Туфан Миңнуллин:** Россия күләмендә, яки байлар күп җирдә, гел байлардан гына торган диярлек милләттә (яһүдләрдә, мәсәлән) хәйриячелек—гадәти, табигый күренеш. Әмма безнең кебек, ярлылыктан чыгу процессы бик акрын барган милләттә, аерым бер байларның акчасына гына ышанып, өметләнеп ятарга ярамый. Беренче чиратта бу эшкә дәүләт катнашырга тиеш. Мәсәлән, Татарстан республикасының быелгы бюджетына Дәүләт Үзәк милли китапханәсенә нәшриятлардан сатып алып бирүне аерым маддә-юл итеп уздыра алдык. Турыдан-туры аерым бер максат белән финанс ярдәме күрсәтү дәүләтнең хәленнән килә әлегә. Мәсәлән, татар язучыларының ПЭН үзәге «Татар акылы» дигән китапны инглиз телендә чыгарырга җыена һәм моның өчен хөкүмәт казнасыннан махсус акча бүлеп бирелде. Без сүз алып бара торган Шәхесләр турындагы китапларны чыгару җәһәтеннән дә дәүләткә мөрәҗәгать итәргә була. Редсовет карап чыкканнан соң, бер ел эчендә басылырга тиешле китапларның исемлеген хөкүмәткә тәкъдим итеп, раслатып, финанс мәсьәләсен дә хәл кылу—татар депутатларының кулыннан килмәслек эш түгел.

**Равил Фәйзуллин:** Бүгенге көнгә Олуг Шәхесләр турында 6-7 китап чыккан инде. Моның өчен дүрт еллап вакыт сарыф ителгән. Киләсе елларда, әйтик, тагын 6-7 китап бастырып чыгару мөмкинме? Бу эшне оештыруда яңа кешеләр катнаша аламы?



**Җәүдәт Миңнуллин:** Минемчә, иң элек редсовет белән редколлегияне оештырып җибәрү зарур. Аннан соң инде эш төркемнәрен дә кинәйтергә була. Тәҗрибәле өлкән буын һәм дәрт-дәрманы ташып торган яшь буын галимнәребез дә җитәрлек. Иң мөһиме—оештыру һәм финанс!

**Миркасыйм Госманов:** Архив хезмәткәрләре дә рәхәтләнеп эшләячәкләр.

**Ислам Әхмәтҗанов:** «Изгелек кыл да, күлгә ташла, халык белмәсә, балык белер»,—дигән әйтем бар бездә. Бүгенге очрашуыбызның, кинәш-табыш итешүебезнең дә төп мәгънәсе-асылы, минемчә, зыялылар арасында туган фикер-уйлануларны журнал аша халыкка җиткерүдән, укучыны да уйландырудан гыйбарәт. Базар сүзе алты килештә төрләндерелә башлагач, рухи яктан фәкыйрьләнәбез, татар китабы үлә, дигән сүзләр еш ишетелә башлады. Бу сүзләрдә хаклык та бар. Һәм бу хаклыкның бер дәлиле булып менә бу сөйләшүебез-очрашуыбыз тора. Чынлап та, бүген китап чыгару гаять түбән дәрәҗәдә башкарыла. Без китапны



нинди хәлдә генә чыгармыйбыз да, аны ничек кенә мәсхәрәләмибез! Ә бит китапны затлы иттереп тә, бөтенесен бер калыпка салып, күзне иркәләрдәй итеп тә, Казанга, Татарстаныбызга килгән шул ук яһүдләрне, йә булмаса, башкаларны да шаккатырырдай шәп итеп тә эшли алабыз. Татарның культурасы аның китабында чагыла. Гаяз Исхакыйның «Сайланма әсәрләр»ен чыгару хакында, хәтерем ялгышмаса, Министрлар Кабинетының махсус карары булды. Өч томлык чыккач кинәт кенә сигезенче томга күчтеләр. Парадокс: ничек өченче томнан сигезенчегә күчәргә, аннан соң исә унбишенче томны чыгарырга мөмкин?

Миркасыйм аганың идеясенә килсәк, әлбәттә, спонсорларга мөрәҗәгать итү әйбәттер дә ул, ләкин моның нинди нәтиҗә китерәчәген алдан ук фаразларга мөмкин: бик күп булса, шул 100-200 мең сум акча җыелыр. Чөнки безнең спонсорлар белән теге Морозовлар арасында—җир белән күк аермасы. Безнең спонсорларны әле тәрбиялисе бар, алар телендә сөйләшергә өйрәнәсе бар. Югыйсә, без нинди генә симпозиумнар җыймыйбыз!? Әмма шушы потенциал спонсорлар белән республика күләмендә бер генә җыелыш та уздырган юк. Әлегә алар белән бүгенге культура хәлен, театр, китап язмышын уртага салып сөйләшә алмадык. Шәхесләр исемлеген хөкүмәт даирәләренә тәкъдим иткәнче, башта бик төпле финансист тарафыннан исәп-хисап ясарга кирәк, китап чыгаруны күпмедер дәрәҗәдә этапка салырга, ягъни беренче, икенче, өченче этап итеп биш-ун ел эчендә нинди китаплар чыгачагын ачыклау зарур. Менә шуннан соң инде Министрлар Кабинеты ишеген дә шакырга буладыр. Бу эшне тиешенчә гамәлгә ашыру өчен хөкүмәт махсус карар да кабул итә ала. Чөнки бу—зур вакыйга, дистә еллар дәвамында сөйләнә торган вакыйга, буыннарга кала торган изге эш. Безнең мәдәнияткә хезмәт итә торган предприятиеләребез бар. Әйтик, әгәр дә «Идел-Пресс», табыштан алына торган дәүләт салымыннан азат ителсә, шул исәпкә елына кимендә 7-8 исемдәге китап чыгара алыр иде. Андый ташламалар «КамАЗ», «Вертолет заводы» кебек эре предприятиеләр өчен гамәлдә булды бит. Ә нигә китапка да ташламалар булмаска тиеш әле?!

**Илсөяр Хәйруллина:** Без нәшер итә торган китапларның бәясе нәшрият, китап кибетләрен үтеп, укучыга килеп җиткәнче 50-70 сумга җитә. Әгәр дә без, халык китап алмый, дип, аны чыгармый да башласак, милләт нинди язмышка дучар ителер—анысы хакында да уйларга кирәк.

**Флүс Латыйфи:** Илсөяр ханым, сезнең сүзгә куәт өстәп, шуны әйтәсем килә: эштән кайтышлый китап кибетенә кердем. Киштәдә бары өч татар китабы ята. Бәяләре—50, 60, 75 сум. «Дөнья әдәбияты классиклары» сериясендә урысча чыккан китапларның бәяләре исә һәркайсының 500, йә 600 сум. Әмма сыйфаты, ягъни чыгарылыш ягыннан аларны бер дә татар китапларыннан яхшырак, дип әйтә алмыйм.

**Туфан Миңнуллин:** Татар китабы 50 сум буламы, 3 сум буламы—халык бит әлегә барыбер егылып алмый аны. Эш, җәмәгать, бәядә генә дә түгелдер. Сүз ничек итеп әдәбиятыбызны, татар китабын саклап калу турында бара. Бердәнбер юл әлегә—китапны китапханәләргә илтеп җиткерү. Заманалар азынып-тузынып да, халык барыбер китапка кайтыр. Хәзер китапханәләрдә укучылар арта, диләр. Һәрбер китапханәгә бер генә китап юллаган очракта да, бүген без кимендә 5 мең данә тираж белән китап чыгара алабыз һәм тиешбез. Китапны дәүләт сатып алып, дәүләт китапханәләренә бушка тарата икән, бу бик яхшы гамәл булачак. Бүгенге түгәрәк өстәл артында сөйләшүнең бер нәтиҗәсе итеп, хөкүмәткә, Президентка, Дәүләт Советына бу мәсьәләнең зарурлыгын, килеп терәлгәнен аңлатып-анализлап бирә алсак, киләсе ел бюджетына бу эш өчен акча алу җиңеләячәк, минемчә.

**Илсөяр Хәйруллина:** Без төрле төбәкләргә, төрле кыйтгаларга таралган татарларыбызга нефть тә, «КамАЗ» машинасы да, икмәк тә бирә алмыйбыз. Әмма китап бирә алабыз!

**Туфан Миңнуллин:** Җәмәгать, байлар дигәннән, сезгә бер хәл сөйлим әле. Беркөнне, Дәүләт Советы сессиясендә Хәйруллинар белән әңгәмәләшеп тордым. Аларны ишетә беләсез. «Эдельвейс» сәүдә-житештерү үзәге белән «Кызыл Шәрык» сыра заводы хужалары алар. Исәнләштек. Ләкин болар мине танымыйлар...

**Илсөяр Хәйруллина:** Туфан ага, парламентта бергә закон чыгарып йөрисез түгелме соң?

**Туфан Миңнуллин:** Сон, нишләтәсең инде, алар бөтенләй икенче тормышта үскәннәр, үзләре унганнар-булганнар... Таныштык. Мин сүз башладым: «Жегетләр,—минәйтәм.—Менә сез—бик байлар, сыра чыгарасыз. Әмма берзаман буш сыра шешәсе белән бергә сезнең исемне дә ыргытачаклар бит. Тарихта калырга телисезме сез?»—дим. Болар мина карап торалар инде: «Бу нинди юләр?»—дип. «Дөньяда акчадан да кыйммәтрәк әйбер бар—исем!—дим.—Борадарән Хәйруллиннар!» Болар мине үзләреннән акча сорарга маташа дип уйладылар, ахры. «Безгә киләләр инде ул сәдака сорап, без бирәбез аларга»—дигән булалар. «Сездән сәдака сорамыйм мин, жегетләр, меценат булыгыз сез!»—дим. Ә меценатның кем икәнлеген белмиләр егетләр. «Савва Морозовны беләсезме?»—дим. Чамалыйлар. Табигый, Третьяковны белмиләр. «Ә менә татарның Хөсәеновлары, Дебердеевлары, Акчуриннары булган»—дип санап киттем боларга. Аларның исеме һаман да халык телендә. Югыйсә, алар заманында да байлар житәрлек булган. Күбесенең исеме тарихта калмаган. Чөнки халыкка хезмәт иткәннәрнең генә исеме онытылмый. «Ә нишләп була соң?»—диләр бу яна татар байлары. «Жегетләр,—минәйтәм,—ачып бирегез бер татар мәктәбе! Шәп урында затлы бина торгызыгыз. Укытучыларын да үзегез тотыгыз! Булсын әле бер борадарән Хәйруллиннар мәктәбе!» Башлары шундук эшкә керепте: «Тәк, анда ничә класс була, ничә катлы бина кирәк?»—санап та чыгардылар. Күп дигәндә, 10 миллион акча житә икән. «Туфан абый, анладык, без бу турыда утырып кинәшләшербез»—дигән карарга килеп кузгалыштылар.

**Марсель Сәлимжанов:** Авылга кайтып, кечкенә генә бер агач мәчет салырлар әле.

**Туфан Миңнуллин:** Юк, алдан әйтеп куйдым боларга: «Зинһар өчен мәчет сала күрмәгез, мәчетне сездән башка да салалар аны. Татарча милли тәрбия бирә торган мәктәп булдырыгыз!—дидем.—Сез татардан башка беркемгә дә кирәкмисез, үзегезне—Хәйруллиннарны саклыйсыгыз килсә, сезне бары тик татар гына саклап кала ала»—дигәчтен, берсе хәтта татарча сөйләшә башлады... Безнең гамьнәрне аңлый торган төпле жегетләр бар, җәмәгать, бар, табарга, жыярга, югалтмаска, үстерергә генә кирәк аларны. Бергә тупларга кирәк, уятырга кирәк.

**Миркасыйм Госманов:** Әле менә алда әйтелгән Шәхесләр турында берничә китап чыккач, мина бер бай гына кеше: «Әгәр Исмәгыйль Гаспралының китабын чыгарсагыз, бөтен чыгымын үз өстемә алыр идем»—диде. Икенчесе болай тәкъдим ясады: «Эшләгез әле Һади Атласиның китабын»—ди. Кайчанга кадәр вәгъдәсендә торыр, әмма шунысы хак: тәкъдимнәр бар! Булачак ул! Хәзерге туып-формалашып килгән яңа байлар белән дә эшли, сөйләшә белергә кирәк инде. Дәүләттән дә алырга кирәк. Дәүләт кулындагы капитал халыкның үз байлыгы лабаса! Тартып алынган байлык... Бик күбесе әрәм ителгән! Туздырылган! Калган өлешеннән Дәүләт Милләткә өлеш чыгарырга тиеш. Әлегә яна байларга бик үк ышанып та булмый. Чын меценатлар интеллектуаль тәрбия алган шәхесләрдән генә чыга ала.

**Равил Фәйзуллин:** Бу сөйләшүләребез эзсез калмасын иде. Шунысы куанычлы: ниһаять, без бу мәсьәләләрне күтәрә, алар хакында уйлана башладык. Әле бу язма басылып чыккач та, фикердәшләребез артыр, дәүләт тирәсендәге хәлле түрәләр һәм мөлкәт туплаган яңа катлам даирәсендә дә фикердәшләребез ишәер.

**Ислам Әхмәтжанов:** Шулай да, Министрлар Кабинетына аерым мөрәжәгать белән чыгу зыян итмәс иде.

**Равил Фәйзуллин:** Бик яхшы фикер!



**Шамил Закиров:** Соңгы 10-15 елда күренекле татар рәссамнарының әсәрләрен Милли-мәдәни үзәккә туплау буенча Розалина Шаһиева зур эш башкарды. Мәскәвенә дә, Себеренә дә барды, акчасын да табышып, оештырып йөрде. «Рухият» белән бергә күренекле татар рәссамнарының альбомнарын чыгаруны эзгә-җайга саласы иде. Чөнки бу нәшриятның альбомнар әзерләүдә тәҗрибәсе зур. Спонсорлар исә, юк дисән дә, бар алар, бар. Әмма алар нигездә эстрада сәнгате тирәсенә тупланганнар. Салаватлар, Зәйнәпләр тирәсенә. Уфада, Чаллыда, Төмәндә, Мәскәүдә яшәүче дистәләгән спонсорны беләбез. Мәгълүм исемнәр. Әмма алар һәртөрле шоу, сәхнәдән ары китә алмыйлар. Китап дигән хәзинәне кулларына алмыйлар, күрәсен...



**Ирек Һадиев:** Татар фәненә, тарихына килүче төпле яшьләребез байтак. Аларны уртак максатка җәлеп итәрдәй кешеләребез дә бар. Китаплар да чыга тора. Әмма акча кытлыгыннан битәр, авторларын канатландырып җибәрә торган, китапка карата җылы, төпле сүз әйткән рецензияләребез матбугатта бер дә күренми. Җылы сүз китапның таралышына да тәэсир итәр иде.

**Гөлфия Садретдинова:** Тарихчылар да, архивчылар да, нәшер итүчеләр дә бер үк изге эшне башкара. Документларны фәнни әйләнешкә кертү җәһәтеннән без—архивчылар да хәл кадәри эш алып барабыз. «Гасырлар авазы» (урысчасы—«Эхо веков») журналын, аңа кушымта рәвешендә ел саен берничә китап та чыгарып киләбез.

Күренекле татар зыялыларына кагылышлы документлар бик күп. Аларны эзләү, туплау, анализлау үзе генә дә күп вакыт таләп итә.

**Җәүдәт Миңнуллин:** Китап, китапханәләргә таратылган очракта да, тираждан һәркайсына 1-2 китап кына эләгә әле. Бу бик аз. Татар факультетлары, группалары булган югары уку йортларына бу китаплар кимендә 15-20 данә кирәк. Аларны иң күп укучы кеше дә—студент. Әгәр әлеге серия спонсорлар акчасына бастырылса, аларны махсус һәм югары уку йортларына бушлай тапшыру җаен табарга иде. Тиражны да зурайтырга кирәк. Әгәр бу сөйләшүгә зурлап күтәрелгәнбез икән, аның нәтиҗәсе сизелерлек булсын. Ягъни, яшь буынга адресланган ул китаплар, китапханәләргә генә түгел, мәктәпләргә дә барып җитсен иде.

**Илсөяр Хәйруллина:** Китап әзерләнгәндә, чыгарылганда иң әүвәле тираж мәсьәләсе ачыклана. Безгә хәзердән үк бу китаплар белән кызыксынучыларны барлый башларга иде. Россиядә бик зур татар диаспорасы бар. Кайда, кемгә, күпме кирәк? Бер өлешен сатуга чыгарып, калганнарын адреслы таратуга биреп була. Сораучы табылса, алга таба, китапларны 2 мең генә түгел, ә бәлки 7-10 мең данәдә дә нәшер итеп булыр иде. Тираж зурайган саен, бер данәнең үзкыйммәте төшә.

Бу сөйләшүдә минемчә, иң кыйммәтлесе, күңелгә якыны—зыялыларыбызның менә шушылай хәлне аңлап, киңәш-табыш итешеп, әйдәгез, эшлибез,—дип торуы.

**Равил Фәйзуллин:** Без, минемчә, бүген бик зур мәсьәлә күтәрдек. Без—фикердәшләр. Сүзебез—бер. Мәсьәләсе дә—берәгәйле итеп күтәрердәй мәсьәлә. Яна чыккан китапка битарафлык турында да әйтелде. «Казан утлары» журналы мөмкин кадәр китапларга мөнәсәбәтен белдереп барырга тырыша. Журналның тышлыгында да китаплар хакында рәсемле мәгълүматлар күренә килә. «Китап күзәтү» сәхифәсендә дә яна китапларга игътибарны һәрдаим юнәлтәбез. Башка матбугат чаралары да бу эшкә битараф карамасыннар иде. Бу изге эшнең зурлыгын халыкка күрсәтү—һәммәбезнең дә бурычы. Милләтне хөрмәтләүнең бер формасы ул.

*Әңгәмәне* **Марат ЗАКИР** *язып алды.*

Сәгыйдулла
Хафизов

# ОЧМЫЙЧА СИН ТҮЗЕП КАРА...

## 1

Башкортстандагы татар шигъриятенең үзен зур әдәби дөньяга чынлап торып танытуы тоталитар режимга каршы көрәшнең кискенләшүе һәм янарыш җилләре исә башлау елларына туры килә. Бу поэзиянең туу, формалашу процессы аның актив бер канаты булган сәяси лириканың көч алуы, ныгуы белән бергә барды. Ул елларда мондагы яшь әдәби тәнкыйть тә, укучылар зәвыгы да шагыйрьләрдән иң элек сәяси пафос көтте, шуны эзләде...

Сез кайларда, татар угланнары,
Калдырасыз мирас кемнәргә?!

Җыр-мотивы белән милләттәшләренең кайнар ихтирамын яулаган Марис Нәзиров бераздан композитор Фәүзә Гасакирова көенә «Очмыйча син түзеп кара» җырын яңгыратып үзен көчле тойгылы шагыйрь итеп раслый алды.

Кыр казлары оча җырлап,
Кайтаваздай тынлык ярып,
Юл алалар еракларга,
Югалалар офыкларга:
Кыйгак... Кыйгак...

Тик, шундук искәртик: күк гөмбәзен ярып җырлап очучы киек казлар әсәрнең «төп геройлары» түгел. Шагыйрь боларга капма-каршы янәшәлек белән йорт казларын тасвирлаган. Зәңгәр күктә илаһи бөеклек тойгылары уятып канат тибрәтүче кыргый туганнарына бага-бага болар да онытылып канат кагыналар, һавага ыргылалар... Тик зур очыш килеп чыкмый шул—алар киртә, кыекларга бәрелеп җиргә егыла:

Төшү белән килеп җиргә,
Каурыйларын чәчеп җилгә,
Ыңгырашып, сыкрап, елап
Ярсып, соңгы көчен җыйнап:
Кыйгак... Кыйгак...

Җырның «Очмыйча син түзеп кара, иннәреңдә канат барда» дип

рефрен булып яңгыраган юллары, әлбәттә, идея-эстетик аныксызлыкка юл калдырмый. Очышның, биеклеккә күтәрелүнең ничаклы зур рухи ихтыяж, бәхет икәнен көчле канатлы киек кошларга карап түгел, ә очыштан бизгән, бүксә баскан йорт казлары янәшәсендә ныграк кичерәсең. Әйе, иннәрендә рухи канатлар, күңелендә җыр-дәрт барда кешегә дә «очарга» кирәк!

Хәер, бу—җырның идеясенә кагылышлы бердәнбер версия түгел. Тернәкләнеп килүче яшь татар шигъриятен җентекләп күзәткән әдәбиятчылар, гадәттәгечә, әсәрдә сәяси мотив күрергә теләделәр. Әйтик, Рәиф Әмировның «Заман—Башкортостан» газитендә басылган «Иңнәреңдә канат барда» исемле язмасында укыйбыз: «Киек казлар дөньясы—күкләр, җырлар, киңлек һәм горур тынычлык. Йорт казларының мохите—җир, чикләре—йорт-кура, моңнары—ярсу-үксү, аһ-зар... Килеп бәрелгәне—туган өй кыегы, килеп төшкән урыны—туган җир...» Җырдан шундый символик, хәтта тирән социаль мәгънәләр табып, Р. Әмиров йорт казлары образында Башкортстандагы татар шагыйренең үз тойгы-кичерешләре, драматизмы яшерелгән дигән нәтиҗәгә килә.

Тәнкыйтьченең фикерләренә ныграк төшенү өчен, Марисның әлеге әсәрне ике вариантта язуын һәм әүвәлгесен «Йорт казлары» дип атавын искә тотарга кирәк.

Казлар, казлар, аңлыйм сезне,
Мин кушылам сезнең зарга.
Очмыйча син түзеп кара,
Иннәреңдә канат барда,—

дигән юллар, чынлап та, тәнкыйтьче искәрткәнчә, «лирик геройның күңеле... романтик омтылулар яныннан үтеп, йорт казларына таба юл ала» икәнен раслыйлар. Безгә йорт казлары фаҗигасен «яшь шагыйрь үз язмышы, үз көнкүреше аша үткәргән хәл-әхвәл...» дип кабул итәргә һәм ахыр чиктә, Марис Нәзировның «туган халкына, туган җиргә тугрылык» саклавын, Р. Әмиров әйткәнчә, батырлык дип танырга мөмкинлек тә бар кебек. Тик тәнкыйтьченең шәрехләү фаразы бик гамәли, әхлакый нәрсәләргә килеп терәлгәч, үзалдыңа, ялгыз калып уйланып та куясың. Ярар, «шәхси һәм иҗади язмышын Башкортстан белән бәйләргә карар иткән Марис Нәзиров» батыр булсын, ди. Ә киек казлар—ягъни Казанга киткән татар әдипләре—кемнәр булып чыгалар соң? Куркакларммы, халыкка һәм туган җиргә хыянәт итүчеләрме?.. Ә. Еники, Н. Фәттах, Х. Сарьян, Ә. Баянов, И. Юзеев, З. Насибуллин, Р. Миңнуллин һәм тагын башка дистәләрчә «киек» әдипләр, минемчә, мондый бәягә лаек түгел.

Һәм, ниһаять, Марис Нәзиров үзе, аның каләмдәшләре «йорт казлары» дәрәҗәсендәге шагыйрьләр булырга ризалашырмы? Зур очыштан, дәртле җырдан мәхрүм йорт казлары язмышына ризалашырлармы соң иннәрендә канат тойган яшь татар шагыйрьләре?

Марисның «Йорт казлары» шигырен үзгәртеп «Очмыйча син түзеп кара» җырын язуы үзе үк аның сәяси версиягә омтылмавын күрсәтә. Шагыйрь йорт казларына теләктәшлек тойгысын белдергән «казлар, казлар, аңлыйм сезне, мин кушылам сезнең зарга» юлларыннан баш тарта һәм «очмыйча син түзеп кара, иннәреңдә канат барда» мотивын кабарта, көчәйтә.

Мин ышанам:
Тәнем гүргә кергәндә дә
Салә җаным очар галәм инләп,—

дип җырлаган шагыйрьнен лирик герое, әлбәттә, ихата каршылыклары, киртә-куралар әсирлегендә кала алмый—Марис рухы очышны сайлый!

Хәер, аллегорик фикерләү, поэтик символлар логикасыннан чыгып карасаң, Марис кына түгел, ә аның социаль-психологик каршылыкларны үтеп, иҗади биеклекләргә юнәлүче ишле каләмдәшләре дә очышта булып тоела. Болар иркен, зәңгәр күккә күтәрелеп, үз моңнарын кангылдап, үзләренчә һава яручы аккошлар ласа!

Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабаев, Марат Кәримов, Азат Магазов сыман олы әдәбиятчыларыбыз белән беррәттән, шигърият

остасы Нажар Нәжми дә Башкортстан жирлегендәге татар поэзиясенә унай йогынты ясады, ныгырга булышты. Халык шагыйре шигъриятне гөл бакчасы итеп кенә карамады, анда халык, тормыш мәнфәгатьләренен тирән чагылыш табуын, гражданлык тойгылары көчле булуын теләде. Һәм яшь каләмдәшләреннән дә шуны таләп итте. Ләкин анын аерым фатиха-мәкаләләрендә, матбугат чыгышларында «су асты агымын» табу азарты да үзен сиздергәләде. Мәсәлән, «Шагыйрь гомере» дип исемләнгән матбугат язмасында ул Халисә Мөдәррисованы эчке каршылыклар белән тулы шагыйрә итеп күрсәтә һәм аны бөек Лермонтов, сталинизм тоткыны Хәсән Туфан белән янәшә үк куя... Язма авторы Башкортстанда каурый ярган талантнын көчен барлаганда унтугыз яшьлек кызнын: «Түзәр хәлләрем калмады—бирегез сөйгәнемне» дигән әрнүле тавышын искә төшерә һәм аннары «Алтын балдак» шигыренә туктала. Бу, чынлап та, дикъкатьне бик җәлеп итә торган әсәр. Алтын балдак безнең акылга туй символы, яшәрү билгесе булып урнашкан. Һәм алтын балдак—ир белән хатынны бергә бәйләүче гомерлек зынжыр, чылбыр да ул. Әмма Хәлисә Мөдәррисованың хөр рухлы лирик герое бармагындагы алтын балдак һич тә мондый гадәт-кануннар символы түгел. Ул—бары ядкарь, сөю истәлеге. Менә шуна: «Калсаң да син жиде-ятларга, күнелкәем синең якларда» дип, шигырь герое сары күзле алтын балдакны бармагыннан бер дә салмый йөртә.

Тик шунысы сәер, шагыйрә үзе алтын балдакка карата: «Син түгелсен ирек зынжыры... Алтын кыршау—никах чылбыры түгел...» дип кабатлап, искәртеп тора, әмма мәкалә авторы шуна карамастан, үз мантыйгын корып болай ди: «Никах чылбыры... Күрәсез, алтын балдак ирексездән ирексезлек образына әйләнә. Алтын ирексезлек... Кыйммәтле ирексезлек... Бай ирексезлек... Күрәсез, ул күпме ассоциатив фикерләүләргә алып килә. Ә бит матур, бай, кыйммәтле ирексезлектән дә яманрак бәхетсезлек бар микән дөньяда?»

Әмма Халисә Мөдәррисованың әлеге шигырендә мондый авыр уйтойгыларга нигез юк бит. Киресенчә, лирик герой кулындагы алтын балдак үз иясенә яктылык, юаныч сирпеп тора. Нигә кирәк шундый буталчык шәрехләү? Халисәнең талантын ап-ачык, туп-туры расларлык әсәрләр, образдетальләр азмыни?! Күрәмсең, Марис Нәзировны йорт казы белән янәшә кую теләге булган кебек, Халисә Мөдәррисованың лирик героен да укучылар каршында нииндидер каршылыклар, ирексезлек халәтенә бәйләп күрсәтү, аны авыр уйларга төрү омтылышы өстенрәк булып чыккан.

Татар телендә язучы яшь шагыйрьләргә мөнәсәбәттә «Туган жирнең үги балалары» темасы чын, дөрес хәл буларак та, шулай ук төрле фаразлар белән күпертелеп тә сәяси актуальлек алды һәм вакыт-вакыт матбугат битләрендә шау-шу да кузгатты ул...

## 2

Гомумән, әдәби тәнкыйтьтә мондый катлауландыру хаҗәте бар иде микән? Демократизм, плюрализм принципларыннан файдаланып биредәге татар поэзиясе сәяси мотивларны «ачык текст» белән дә муллан гәүдәләндерде бит. Моңа ышану өчен татар шигърияте «бишеген тирбәтүче» шагыйрьләр Йосыф Гәрәй, Фәрит Габдрәхим, Рәшит Гатауллин, Рим Идиятуллин, Марис Нәзиров, Мариус Максутов әсәрләренә күз салу да житә. Алар шовинистик, империячел Мәскәү Кремле сәясәтен Башкортстан шартларында дәвам иткән шакировчылык мәзһәбенә кыю каршы чыктылар. Анын халыкларны манкортлаштыруга юнәлтелгән мәкерле сәясәтен фаш иттеләр һәм үз әсәрләре аша милләттәшләренең тел, мәгариф, басмачылык өлкәләренә караган теләкомтылышларын жәмәгатьчелеккә ирештерергә теләделәр. Бу елларда көчле сәяси пафосы һәм үткен, яңгырашлы метафоралары белән аеруча Фәрит Габдрәхим ижаты популярлашты. Партия-совет кланы Башкортстан белән Татарстан арасында «дуслык күпере» сузган иде. Әмма шагыйрь «Сәхнәдәге рәсми үбешүләр фәкать ерагайтты араларны»,—дип бу хәлне үзенчә раслап, Башкортстан татарын «туйдан» мәхрүм халык рәвешендә күрде.

Өфе—Казан рәсми «Әпипә»гә,
Рәсми «Карабай»га бии, күрче!
Башкортстан татарының гүя
Бәгырендә бии ике күрше.

«Кайнар еллар»ның сәяси лексиконында еш кабатланган «эш аты» гыйбарәсе дә Фәрит Габдрәхим табышы иде. Эш атының тәкъдире шундый инде: ул хуҗасына карышусыз, тугрылыклы хезмәт итә, әмма сый-хөрмәт һәм наз көр чаптарга эләгә.

«Туган телем!»—дисен,
Их син—Башкортстан татары!
Ни пычагыма сиңа тел?!
Син бит эш аты бары.

Шагыйрь эш аты—Башкортстан татарының да—мәдәни-рухи таләпләре һәм омтылышларына хөрмәт белән карарга чакырды.

Сәяси лирикадагы аерым табышлар шундук башкалар тарафыннан эләктереп алынды, үстерелде, көчәйтелде. Мәсәлән, шул ук «эш аты» метафорасын М. Закировның лирик герое үз-үзенә нисбәтләп болай ди:

Йөк аты мин, мөмкинме соң
Башка белән бутавы.
Эшләгәндә—авызлыклы,
Кешнәгәндә—тышаулы.

«Эш аты»на бәйле «тышау» төшенчәсен кеше затына күчереп, Рим Идиятуллин метафораның яңа эчке формасын ачты. Лирик геройның «хисләкләре тышауланган, өметләре өркеп качкан, ә тышаулы зат ерак китмәс»...

Үзенең гражданлык поэзиясенә өлеш булып кергән бер моңсу, сагышлы шигырендә Мариус Максутов:

Үз илеңдә ятим булу бәхете
Бездән башка кемгә эләксен...—

юлларын язган иде. Тора-бара бу мотив «ятим бала», «үги ул», «ирекле тоткын», «качак» сыман анык образлылык алып, дистәләрчә шагыйрьләрдә сурәтләнде. Мәсәлән, Туган җиренә төбәп, Халисә Мөдәррисова болай язды:

Сөйкемле зат булалмадым синдә
Ни кылсам да күнел кителде,
Үз өендә үги ана белән
Үсеп килгән бала шикелле.

Татар поэзиясендәге «китек күнел» проблемасы Салават Рәхмәтулла, Мөхәммәт Закиров, Марат Кәбиров, Фатыйх Сәйфран кебек яңа буын шагыйрьләрендә дә дәвам итте һәм сәнгатьчә табышлар белән ачылды.

Сүз ирегє ачылган тәүге елларда Фәрит Габдрәхим: «Ошбу илдә эзләп табалмассың ичмасам бер татар шагыйрен» дип оран салган иде. Әмма җөмһүрияттәге демократик үзгәрешләр шигъри мөхиттә үз җиренә, үз халкына береккән яңа типтагы шагыйрьләр төркемен тудырды. Кендек киселгән нигез, тәпи баскан җир, ата-ана хакы турында уйланып, бу шагыйрьләр мөһаҗирлыкны инкяр иттеләр.

Китә алмам туган җирне ташлап,
Китә алмыйм кайтмас сәфәргә.
Һәм исәннәр һәм үлгәннәр белән
Язган миңа монда яшәргә,—

дип каләмдәшләренең уртак тойгыларын чагылдырды Рим Идиятуллин. Боларда хәтта китүчеләрне өнәмәү хисе көчле булды. «Шигъри даннарга күмелгән Казанга киткән халык»,—ди, әйтик, сарказм катыш Салават Рәхмәтулла.

Әмма үзенчә жор тел белән шуны да өстәп куя: «Рифмаларны коеп куям, юк алмаш ыштаным да!»

Сугыштан соңгы елларда татарстан Язучылар берлегенең яртысын Башкортстаннан килгән язучылар тәшкил итә, дигән ныклы фикер яшәп килде. Ләкин үзгәртеп кору елларында мөһажирлек күзгә күренеп кими. Татарстан Язучылар берлегенең ул вакыттагы рәисе Ренат Мөхәммәдиевнын 1999 елгы корылтайдагы хисап докладында моны раслаучы сүзләр бар: «Әле кайчан гына бетмәс-төкәнмәс талант чишмәләре булып аккан Башкортстаннан да килүчеләр сирәгәйде». («Казан утлары», 1999 ел, 9 сан.) Ә инде Чаллы шәһәрендә чыккан «Аргамак» журналының 2000 елгы, 1 санында бу хакта тагын да катгыйрак фикер әйтелә: «Башкортстаннан татар әдәбиятына яшь язучылар, шагыйрьләрнең килүе тукталды».

Үз жиренә береккән шигърият җегәрен, шунын шытымын без татар телендәге поэзия, аерым алганда, сәяси лирика активлыгында күрдек. Тоталитар режим тарафыннан рухи кысылган халыкнын тавышын ишеттерер өчен бу әдәбият, рус демократы А. И. Герцен әйтмешли, югары трибуна булып торды.

Сәяси лириканың яңгыраган вакытта тормыш белән бәйләнеше нык, халыктагы аһәңе көчле кебек тоелса да, чынында ул—бик кыска гомерле. Ил-көндәге вакыйгалар бик тиз алмашына, карашлар үзгәрә һәм шулар белән бергә шагыйрьнең идея-эстетик ачышлары да җуела, тоныклана башлый. Поэзияне фәлсәфи лирика, табигать лирикасы, социаль мотивлар һәм сөю-мәхәббәт шигырьләре яшәтә. Болар аны универсаль рухи-әхлаки кыйммәтләр, поэтик ачышлар һәм хис-тойгылар байлыгы белән сугаралар, гомерле итәләр. Ләкин лириканың әйтелгән төрләре, үз чиратында, шагыйрьләр алдына зуррак иҗат таләпләре куя һәм поэзиядәге сурәт-тасвир чараларынын да төрлеләнүе, камилләшә төшүе зарур шарт була. Бер сүз белән әйткәндә, милли шигъриятнең ныгу этабы шагыйрьләрнең үз «мин»нәре, ягъни шәхсиятләрен ныграк ачу һәм стиль аныклыгын көчәйтү хасиятләре белән бәйле.

Башкортстанда үзенең каләм үзенчәлекләрен ачкан дистәгә якын татар язучысы бар. Боларны, тәнкыйтьче әйткәнчә, «үз шигъри дөньясын, үз юлын, үз тавышын тапкан шагыйрь»ләр дип атарга була.

Басылган шигырьләре, чыгарган китаплар саны белән күзгә нык бәрелеп тормаса да, поэзия тәнкыйтьчеләре Рим Идиятуллин иҗатын ешрак хуплап телгә алалар. Шигъри үсмерлек чорында ук язганнарына карап, Хәсән Туфан: «Яхшы бу!.. Молодец!» дип аңа фатиха биргән булган. Н. Нәжми, Г. Садә, Р. Миңнуллин, А. Магазов, К. Дәүләтшин, М. Вафиннар да Рим поэзиясенә багышлап әтрафлы чыгышлар ясадылар. Тәнкыйть бу шагыйрьне «татар, башкортта алтмышынчы еллар уртасында формалашып, шигъри эчтәлек һәм формага кызыклы яңалыклар китергән буынның үзенчәлекле вәкиле», дип дөрес күрсәтә. Нечкә җылы тойгыларга, рәссам осталыгына бай булган кебек, фәлсәфәгә дә юмарт аның шигърияте. Шул ук вакытта әрнүле моңсулык та хас бу шагыйрьгә:

Сагышларым!—
Хас та инде утлы күмер;
Җаннарымда җөй калдырып,
Эчләремне гел яндырып
Торган сагыш—минем гомер.

Бездә яхшы шагыйрьне иң элек метафоралар остасы итеп тәкъдир итәргә омтылалар. Әлбәттә, каберне—газапланып кара гүрдән күтәрелүче мәетнең аркасы итеп күргән, йә булмаса тоталитар заман әдибе белән «ташлы ярга башын бәрә, бәйдә торган бер көймә» арасында ассоциатив охшашлык тапкан шагыйрьне метафоралар коруга сәләтсез димәссең. Ләкин, күзәтүебезчә, Римнын иң яхшы әсәрләре вакыт һәм урын сурәтләрен тудырып, киң даирәле, иркен сулышлы хәят күренешләре барлыкка китерәләр. Бу—дүрт яклы, саф һәм гөнаһлы дөньяның бишенче тарафын эзләп йөрүче мөсафир шагыйрь, хәзергесе белән хисапсыз «элек»ләрне тыгыз үреп, бердәм

вакыт буразнасына өмет-орлыклар салучы игелекле-шәфкатьле шагыйрь. Юкка гына аның шигырьләрендә «Әнә», «Әнә кара», «Әнә күр!», «Күрәсеңме?», «Чакыр әле», «Сәлам сезгә!», «Хуш бул!», «Хәерле көн!»^ «Хәлегез ничек?» кебек юл-хәрәкәт сүзләре даими кабатланмый. Шагыйрь герое «мәж килеп йөрим һаман түм-түгәрәк җир өстендә»,—ди. Ул бишектәге сабыйның да, таңны уяткан гашыйкларның да, солдат анасы белән тол хатынның да, хәтта түшәктә үлем көткән әбинең дә иминлеген сораша. «Хәлегез ничек? Хәлегез ничек?» «Хәлең ничек?» дигәндә кеше үз гамьнәрен ачмый түзә алмый. Шагыйрь үз фаразы, тоемы белән дә күп серләргә, төрле-төрле гыйбрәтләргә ия була, зиһене үсә, акылы тармаклана. Шуңа күрә шагыйрь сүзләреннән һәрчак мәгънә, фәлсәфә табасың...

Урын һәм вакыт образларын тыгыз үреп әсәр композициясендә файдалануны галимнәр «хронотоп күренеше» диләр. Поэтика мәсьәләләрендә зур белгеч М. Бахтин моны әдәбиятның таралган сурәтләү алымы дип раслап, әйтә: «Язучы һәм аның геройлары фәлсәфәгә бик маһир булмасалар да, әсәрдәге хронотоп принцибы киң, төрле хәят, яшәү күренешләре тудырып көчле фәлсәфәлек катламын хасыйл итә».

Фәлсәфи лирика белән бергә, Рим иҗатында социальлек тә актив. Милли тормыш, бигрәк тә сугыштан соңгы кырыс еллар, лирик герой дөньясына күптөрле кеше-персонажлар белән уелып, катлаулы хисләр тезмәсен тудырган.

Римнең үзенә дәгъва белдерергәме, яисә әдәбияткамы—шагыйрь иҗатында милли тоем житенкерәми.

И әнкәем, табутың!—
Сабый чагымда тирбәлгән
Бишегем кадәр генә...

Табутны бишеккә тиңләү бәлки шагыйрьгә образлы фикерләү маһирлыгы, фәлсәфилек тә бирәдер, әмма, дөресен әйтергә кирәк: Сибгат Хәкимнең яисә Хәсән Туфанның лирик герое әнкәсен табутка куеп җырламас иде...

Татар шагыйренең «О, Русия!», яисә «О, могжиза!..» дип чит шивәнең фонетик кануннарына ияреп язуы, шулай ук сәер тоела...

Ил-көндәге шагыйрьләребез арасында Салават Рәхмәтулла стилен дә бик тиз таныйсың, хәтта аның «бу—мин!» дип ерактан кычкырып торган үз строфикасы бар. Сүзләрне, аеруча фигыльләрне янәшә куеп, көчәйтеп бирергә ярата ул: «Әнкәй, түз бер, түз ике»; «Яумаса... миннән торамы, торамы синнән генә?!»; «Әнкәсе, чәй куй, куй, аш!»; «Бәлеш итеп пешереп бир, пәрәмәч итеп пешер, төеп пешер, пешер ярып»; «Давылларны кочтым, җилләрне, кочтым әллә ниләр, әллә кемнәрне..»

Бу шигъри стилистика үзенчәлеге мәхәббәт шигыренә дә бик ятышып, аны бизәп тора.

Үзең генә белгән юллар белән
Төшләремә килеп керәсең...
Сиңа гына сөйләр сүзләрем бар,—
Бар әле, бар сине күрәсем.

Тәнкыйть Салаватның каләмен фәлсәфилек, фикер тыгызлыгы, гади, аңлаешлы тел-сурәт һәм җорлылык сыйфатлары белән барлый. Тик менә аны Такташ-Атнабайга охшатып «бунтарь поэзия» вәкиле итеп санаулары белән генә килешәсе килми. Дөрес, Рәхмәтулланың әлеге шагыйрьләрне үзенә остаз итеп алуын һәм алар стиленә охшатып байтак кына шигырьләр дә язуын танымыйча булмый. Ләкин шагыйрь иҗатындагы бу катламны Салават казанышы дип атау кыен. Ул—үзенә бер талант. Ә талант исә гадәт-нормаларга сукыр иярүне, утырган зәвык һәм карашларга баш июне белми. Галәттә, иҗади каләмнең өлгерүен традиция һәм новаторлыкның тыгыз оеткысында күрәләр. Ягъни шагыйрь мирастан нәрсәдер ала һәм нәрсәнедер үзе дә шыттырып, үстереп бирә. Салаватның шигырьгә керүе исә күбрәк «үзем генә белгән юл белән» бара. Әйтик, шагыйрьләрнең бик күбесе

кавышу, кияү-кәләш кичерешләрен язгы ямь, чәчәкләр һәм кошлар симфониясе белән бәйлиләр. Дөньяны шигъри кабул итүнен утырган символлары бар бит... Ә менә Рәхмәтулланың «Күзгә бакча»сында кияү кәтү халәте күз фасылына корылган. Яфраклар—сары келәм, ә түтәлләр кабартылып куелган мендәрләргә охшап калганнар. Чыршылар исә ишек бавы көткән малайлар сыман.

Менә тиздән, ап-ак юрган тотып,
Бу бакчага керер кыш-кунак...
Монсу каен тора, йокларга, дип
Толымнарын сүткән кыз сымак.

Монда бар сурәт классик традицияләр белән каршылыкка керә. Анын каравы, «Күзгә бакча»—безнең хәят, халык поэтикасына аваздаш. Күз бездә—кыз бирү, кияү каршылау, туйлар чоры түгелмени?!

Салават күбрәк тормыштан, үз язмыш-табигатеннән, хәтта, әйтер идем, укытучылыгыннан килә. Сүздән: Рәхмәтулланың мөгаллим дөньясын ачкан байтак уңышлы шигырьләре бар. «Зур булсам да үзем, ир булсам да, мина ошый алар дөньясы», дип балаларга булган мәхәббәтен белдерә. Рәхмәтулла, «Тиешлесен әйтеп беттем микән?» дип шөбһәләнгән укытучы сыман, шигырь дөньясында да фикерләү башлангычын алга сөрә. Ул чынлап та интеллектуаль акыл, зиһен иясе һәм үзенең сөенечле «Эврика!»сы белән күңелләрдә туктаусыз мәгънәви, әхлаки ачышлар ясаучы шагыйрь.

Зәңгәр галәм!
Анла, мин туганмын
Серләренне чишеп бетәргә!

Чынлап та, жирнең тарту көчен ничек белергә була? «Тарту көчен Жирнең белү өчен аерылып туган якларыңнан, еракларда яшәп кара син!». Ә озатышканда кеше ник сагышлы? Кабаланып, ашыгып киткәндә нәрсәдер кала: «Балачак калган болдырда аягын салындырып, яшьлек калган... Сөйгән яр да ятларга торып калган...» Һәм тагын да зуррагы «Эх, туган-үскән жир кала, йөрәкне авырттырып». Нигә йорттагы күгәрченнәр жаен-кышын гел «гөлдер-гөлдер» килеп яшиләр? «Гөлдер-гөлдер яшәгән жир, Ул туган-үскән жирдер, Ул—туган-үскән илдер...» Без дөньяны дүрт тарафлы дип яшибез. Ә ана кешенең үз исәбе бар:

Дөнья дүрт яклы түгел ул,
Бу—хата бит, бу—хата!
Дөнья, балам, алты яклы
Алты бала үстердем бит,
Алтысы алты якта...

Хәят, заман, яшәү кебек олы төшенчәләрдә С. Рәхмәтулла безгә туктаусыз серләр ача, рухи бай, мәгънәле, мәхәббәтле яшәү әмәлләрен уртаклаша.

Салават Рәхмәтулланың лирик герое ихлас, укучысы белән бик дустанә, ләкин кайчагында ул бөтенлеген югалта, таркала, хәтта капма-каршы сыйфатларга да ия була. Әйтик, «Уяну» китабын кулына алган укучы лирик геройның: «Йөрәгемне көрәшләргә аттым! Көрәшләргә жилде жыр-атым!..» кебек югары пафослы омтылышларын хәтеренә сала. Тик янәшә шигырьләрнең берсендә шул ук зат: «Яшел елан» куенында узган елларымның әллә ничәсе», дип укучысы каршында бөтенләй үзгәреп тә китә. Ана дуслар кул селтәгән, сөйгән яр ят белән киткән. Һәм жырларының да әллә ничәсе житлекмичә туган икән?.. Кайсына ышанырга соң? Лирик герой үзенең социаль аныксызлыгы, принципсызлыгы белән еш кына укучыны шулай аптырашта да калдыра.

Тормыш булгач, төрлесен күрәсең, төрлесен кичерәсең, диярләр... Тик сәнгать кануннары образны анык идея, ачык максат белән сурәтләүне таләп итә шул! Зур шагыйрьләрнең лирик геройлары үзләренең кабатланмас холык-фигыльләре, бәя-карашлары һәм ныклы принциплары белән сокландыра.

Лирик геройның тормыш ваклыкларыннан арынган һәм шагыйрь идеалын гәүдәләндергән сәнгать төшенчәсе икәнен дә онытмыйсы иде!

Тәнкыйтьтә татар шигъриятенең күренекле вәкилләре Рим Идиятуллин, Салават Рәхмәтулла, Марис Нәзиров, Халисә Мөдәрисова, Дилә Булгакова, Фәндидә Харрасова, Марат Кәбиров, Мөнир Вафин иҗатларына карата житди генә фикерләр әйтелсә дә, Мөхәммәт Закировка төбәп анык кына сүз кузгатучы булмады әле. Монда аның шигырьләреннән бигрәк, үз шәхесе сәбәпче түгел микән? Мөхәммәт бернichә шигырьләр циклы бастыргач та, «Мин—шагыйрь, даһи!» дип сөрән салучылардан түгел бугай. Шагыйрьлек, анынча, бик авыр вазифа. («Әдәбият—имандыр, үзгәреп торган дөньяны иманына инандыр».) Икенчедән, әдип—зур язмышлы, олпат, әхлаки өлгергән шәхес ул. («Шигырь язып була, ә шигърият язмышлардан башка буламы соң?».) Юкка гына борынгы гарәпләр әдәп, әдип, әдәбият төшенчәләрен «әдәп» сүз-тамыры белән беркетмәгәннәр бит...

Ихлас тойгыларга, табигый янәшәлекләргә корылган антитезаларны Мөхәммәт гажәп мул куллана. «Ут аларның гомерләрен киссә, гомерләре кисте ут юлын»,—ди шагыйрь Чернобыль геройлары хакында. «Минме сыенам Жиргә? Әллә үзе сыенамы бүген миңа Жир?» антитезисында кеше белән Жир-ана арасында рухи якынаю ачылып китә. «Монда кайгыларым якты, шатлыкларым ямансу»,—ди шагыйрь туган жирендә.

Байтак мәгънәви ачышлар ясаган шагыйрь—Мөхәммәт Закиров, әлбәттә, укучы игътибарыннан читтә кала алмый. Аның каравы, бездәге тәнкыйть сандалында Рамил Чурагул рәхимсез чүкелә. «Мәкаль-әйтемнәргә су кушып жыр мәтәштерә»... «Шигырьләрендә—арзанлы фикер»... «Ярлы поэтика, зәвыксыз»... кебек гаепләр табып, каләмдәше Марат Кәбиров әйтмешли, аны туктаусыз «тукмап» торалар. Әмма, дип фикерен дәвам итә М. Кәбиров, Рамилның бүген радио-телевидениедән, сәхнәдән йөздән артык жыры янгырый. Нинди жыр күңеленә ошый, шул Рамилныкы булып чыга... Эх, мин дә шулай яза алыр идем бит, дип уйлап куясың хәтта. Әйе, күпләр яза алыр иде. Әмма беркем дә язмаган бит... Тәү карашка гади генә тоелган нәрсәләрне дә күңелләрне тибрәндерер жырга әйләндерү жиңел түгел шул.

Халык, чынлап та, Чурагулның жырларын үз итә. Әйтик, авылын, туган төягеН сагынып кайткан кеше үз хатирәләре, истәлекләрнең образлы кыяфәткә кереп: «Авыл урамнары буйлап йөгерә балачагым» янгырашын хупламый түзә алмый. Ә инде элекке авылны тапмыйча, анда кырыс үзгәрешләр, бушлык күрсә, кунакның: «Әйт, авылым, кайда соң мон? Мон кайда соң, әйт урам!» дип ихлас өзгәләнүләре дә бик табигый. «Әйтмә син авыр сүз, әйтмә түз!» дип сабырлыкка, күркәм мөгаләмәгә чакыруны гашыйклар гына түгел, барыбыз да үз итә, йөрәгенә ала. Шулай итеп, Рамил Чурагул халык күңелендә интим булып яшәгән теләкләрне кыю рәвештә ачык дөньяга чыгара, жыр итеп янгырата. Ә инде шул максатта мәкаль-әйтемнәрне, халыкчан гыйбарәләрне мул файдалана икән, моның нәрсәсе начар соң?!

Без кайчак жыр жанрының холкын, табигатен аңлап житмибез бугай. Һәрхәлдә лирикага булган таләпләрне турыдан-туры жырга күчерү омтылышлары сизелә. Әмма аннан катлаулы метафоралар, драматизм эзләү урынлы булмас. Жыр—сүз-бизәкләр гармониясе, ассоциацияләр муллыгы, ритм, рифма төгәллеге ул. Рамил Чурагул иҗатын гына түгел, танылган жырчы шагыйрьләр рәтенә кереп килгән Радик Хәкимжан, Әзһәр Кәшфуллин эшчәнлеген дә жыр сәнгатенең үз таләпләре яктылыгыннан чыгып бәяләргә кирәк.

Рамил иҗаты уңаеннан, жырда, шигырьдә яна сүз куллануга бәйле бер фикер дә кузгатасы килә. «Туганнарның кадерен бел!» жырында әлеге шагыйрь «зиһай ят» дигән бик янгыравыклы сүз кулланган иде. Тәнкыйтьче шул унай белән болай язды: «Зиһай ятлар сүзен гади халык түгел, хәтта филологлар да аңламый. Мин бик күпләрдән «ул нәрсәне аңлата соң?»—дип сораганым булды. Белмиләр. Жырны сүзлек белән тыңламыйлар. Аның сүзләре аңлаешлы, ачык булырга тиеш».

Шулай итеп, шагыйрьнең оппоненты яна сүз куллануга каршы кеше икәнен белдерде. Ләкин язучыны яна сүз, бизәк эзләүдән мәхрүм итү дөрес

хәлме? Шул унайдан халык әдибе Гомәр Бәшировның фикерен тыңлап үтәсе килә: «Мин әдәби телебез барыннан да элек һәм беренче нәүбәттә халыкның үз сөйләм теленнән кергән сүзләр исәбенә баерга тиеш дигән караштa торам. Әгәр кайда да булса бер шивәдә—мишәрдәме, Казан артындамы яки керәшен дип йөртүчеләрдәнме,—монарчы әдәби телдә булмаган кирәкле бер төшенчәне аңлатырга сәләтле сүз килеп чыга икән, нигә аны әйләнешкә кертеп җибәрмәскә?» («Мәгариф», 2001, 3 сан, 11 бит).

Зиһай ят—җиде ят мәгънәсен аңлаткан диалекталь сүз. Олы әдибебез әйткәнчә, ул әдәби телгә кереп, яшәп китә икән, безнең сөйләшебезне баетачак кына. Башкортстан төбәгендәге татарлар сөйләше үзенчәлекле лексик катламга гаҗәп бай һәм мондагы каләм осталарының тырышлыгы, зирәклегеннән әдәбиятның тел-сурәт байлыгы билгеләнә.

4

Поэзия тулпарын элек-электән дәртле ирләр иярләп килә. Сүз һәм хисләр дөньясында телбизәкләр, нәкышләр уеп, ритм, рифмалар корып, вакыт һәм чор киртәләрен үтеп шулар җилдерә. Башкортстандагы татар поэзиясе, әлбәттә, кызлар лирикасыннан да мәхрүм түгел. Хәер, иҗатчыларны җенесләргә бүлү дөрес микән? Гоманымча, эпос, драма төрләренә карата бу, чынлап та, шикле гамәл булса да, лирикага фарыздыр. Чөнки бу төрдәге әсәрләрдә тормышка, кешеләргә карата мөнәсәбәт белдерү, бәя бирү алга чыга һәм, гомумән, дөньяны күрү, эмоциональ кабул итү рәвешләре үзәктә тора. Без ир-ат дөньясы, хатын-кыз дөньясы дип сөйлибез икән, лирика боларның реаль гәүдәләнешләрен чагылдырырга һәм әлеге ике мохитне бер-берсенә ачарга, якынайтырга бурычлы. Кызганычка каршы, ир белән хатын-кыз җенесен һәрьяктан бертигез итеп танып, рухи дөньяларын төссезләндергән совет заманы, әдәбияты кызлар лирикасына мөстәкыйльлек бирә алмады. Шундый әдәби шартларда Халисә Мөдәррисованың «Мин— хатын-кыз, бары яратыгыз, минем вакыт кыска таң кебек» юлларын шигъри декларация дип кабул итми мөмкин түгел. Чынлап та, бу шагыйрә лирик героен үтә интим тойгыларда һәм хатын-кызга гына хас кичерешләрдә сурәтләүне алга сөрә.

Кояш димә, йолдыз димә,
Алтын да, көмеш димә.
Ничек бармын, шулай ярат,
Бары шул килеш кенә.

Мәхәббәт, Халисә фаразынча, утлы тойгы. Аның лирик герое сөю хисләрендә үзен давыл кошы кебек табигый хис итә: «Яшеннәр алтын нур иде, бер бәйрәм иде давыл...»

Кайнар тойгыларны, драматик кичерешләрне сурәтләүдә Халисә, берьяктан, самими яшьлек хыялларыннан, китаптан, аеруча рус поэзиясеннән килә. С. Есенин, А. Ахматова, А. Блок, М. Цветаева иҗатларындагы аерым мотивлар табигый булып татар шагыйрәсе сурәтләгән тойгыларга килеп кушыла:

Син минем кара кайгым да,
Кояшлы ахагым да,
Тыңлаучым да, аклаучым да,
Хагым да, нахагым да.

Интим кичерешләрне тасвирлауда шагыйрә тоткан икенче юнәлешне түбәндәге строфа ачыклый сыман:

Пәйгамбәр яры яшендә—
Хисләрне тыймас чагым.
Кадеренне белеп сөяр,
Сөелеп туймас чагым.

Ислам мәзһәбендәге хатын-кызның күңел драмасын аеруча көчле, тәэсирле итеп аның «Баланнар» әсәре гәүдәләндерде. «Мәк гөледәй кызыл балан—яшь кызның күңел төсе». Тындырмаслар, каерып өзәрләр... Әмма ана авызыннан татар хатынының рухы үзе җавап бирә:

Өлгергән инде балан,
Өзәргә кирәк, балам.
Авыр чаклар бик күп булыр—
Түзәргә кирәк, балам.

Мондый әсәрләре белән Халисә кызлар лирикасының рухына, поэтик сурәтләү алымнарына таянып үсү мөмкинлекләрен барлый.

Татар телле шигърияттә кызлар лирикасын үстерүдә Дилә Булгакова да үз өлешен кертә. Ләкин ул интим кичерешләрне, сөю, мәхәббәт хисләрен бирүдә Халисә кебек анык социаль персонажлар тасвирлау һәм сәбәпле мотивлаштыру алымнарын кулланмый, ә ишарәле шигърият чараларыннан бик иркен файдалана. Шул яктан ул табигать лирикасын һәм андагы символлар байлыгына, халык иҗаты казанышларына иркен таяна. Һәм нәтиҗәдә шагыйрә мәхәббәткә кагылышлы тойгыларны турыдан-туры үз исемнәре белән атамаса да, лирик героенын кайнар мәхәббәтен яисә сагышларын, омтылышларын ышандырырлык итеп ачуга ирешә.

Син—имәнем,
Мин—бер миләш.
Җил-давылдан
торасың бит
мине саклап.
Салкыннарда
сынармындыр
Синсез шартлап...

Менә мондый тасвир—Дилә Булгакованың типик стиле.

«Синең өчен таш өстендә чәчкә аттым...!» «Мин бит синсез елак болыт...» «Нур-йолдызың булыйм микән, йә күктә тулы аең?..» «Миңа юллар урау-урау, арымасмы атларын»... кебек тезмәләр лирик геройның мәхәббәт дөньясын кызыклы, шигъриятле итәләр. Бу дөньяның язлары, җәйләре, якты таңнары булган кебек, көзләре, җил-давыллары, яшеннәре дә бар. Монда «яфракларын ачып, җир җиләге бит алмасын буйый кызылга... Талпынып чакыра сыерчык үз парын».. Алка таккан арышлар да яшертен генә сөрмә тарта...

Һәм билгеле инде әлеге шигъриятле хәят тә шомлы хәлләрдән азат түгел.

Болыт кызы толымнарын
тарады таугa басып.
Таш кыяда нур балкытты
Төсләр күперен ачып.

Әмма тормыштагы яманатлы, гауғалы «мәхәббәт өчпочмагы» табигатьтә дә үзен сиздерә:

Җил егете көнләшүнең
Чиге-чамасын үтте;
Болыткайны алып китеп,
Үргән чәчләрен сүтте.

Кыз-болытны кызганып, җил тарафларына чатнатып яшен атты һәм «горур тау да елый икән—ташлардан яшьләр акты», дип «тау мәхәббәте»н сурәтли нечкә хисле шагыйрә.

Күрәбез, поэзия чаралары белән Дилә Булгакова каләме шактый иркен эш итә һәм, әйтергә кирәк: кызлар лирикасын үстерүдә ишарәле шигъриятнен зур мөмкинлекләре бар.

Шагыйрәләр арасында үзенчәлекле тавышын Фәндидә Харрасова да

сиздерә. «Казан утлары» (1997, 11 сан) үз авторы хакында бик анык сүзләр язды: «Аның лирик герое шигырь «сәхнәсендә» чын-чыннан яши, ышандыра. Бу шагыйрәгә динамика һәм сурәтләү осталыгы хас, хисләре бик киеренке, хәтта ниндидер фаҗигалек төсмерләре дә бар...»

Фәндиданең лирик герое «шаһинәләр рухы тибә тамырларда», дип нәсел-нәсәбен һәм дәрәҗәсен белеп, горур яшәмәкче. Ләкин кырыс тормыш адым саен аның каршына сынаулар куя, авырлыклар тезә. Менә «ишегенне биклим, капкан ябам, кичерәлсән кичер, нигез, хуш!» дип ул туган йорты белән саубуллаша. Ә нигез гаме чын ирләрдә генә була торган кичерешләр дулкыны кузгата:

Шушы җирдә нәсел-тамырларым,
Шуннан ингән иман-кодрәтем.
Ил таркала нигез какшаганга,
Йөзен җуя милләт, әй, Раббым...

Бу «шаһинә» тормыш сандалында чүкелсә дә, «кояшлы һәм җырлы бер кыйбла» булып балкый, аның дөньяга, шулай ук, үз карашы, фәлсәфәсе бар:

Гөнаһы да, савабы да бер җилкәмә—
Дөнья күтәм, дөньялыкны җир күтәрә.

Кызлар лирикасының тагын бер вәкиле Кәүсәрия Шафикова иҗатын күздә тотып Фәрит Габдрәхим: «Тел шартлатып сокланырлык метафораларга корылмаса да, шигырьләрендә дулкынландыру көче зур»,—дип язды. Мәкалә авторы әйткәнчә, шагыйрә иҗатында милли җирлек нык: «Аның таллары да татарча сөйләшә, чишмәләре дә татарча челтери, кызлары да татарча уйла».

... Башкортстандагы татар телле шигърияттә каләм көчен күрсәткән, стиль үзенчәлеген ачкан талантлар белән танышуны тагын да дәвам итү мөмкинлеге бар иде әле. Ләкин безнең алда бер хакыйкать инде ачык булса кирәк: туган мөхиттә һәм милли телдә замандашларның катлаулы рухи дөньясын, күңел кичерешләрен, омтылышларын сәнгатьчә көч белән ачкан поэтик тәҗрибә өлгереп килә. Халыкның үз шигъри чишмәләреннән тибеп чыккан моңнары, берләшеп җырлыйсы җырлары бар. Тик бу иҗат башкорт әдәбиятының татарча укылышы түгел, шулай ук Казанда чыккан әсәрләрнең кайтавазы, иярчене дә түгел. Ул—Башкортстан татарларының үз, кабатланмас рухын гәүдәләндергән әдәбият. Ә әдәбияты булган халык, Тукай әйткәнчә, тарихта әсәрле, эзле була ул!

**Гомәр Сабирҗанов,**

*Татар энциклопедиясе институты директоры урынбасары*

# ӘХМӘТҺАДИ МАКСУДИНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Моннан нәкъ 75 ел элек, ягъни 1927 елда Казандагы «Татарстан» типо-литографиясе мәдәниятебез тарихында беренче мәртәбә фәнни-универсаль белешмә чыгара башлый. Аның тышлыгына гарәп хәрефләре белән «Фәнни камус», ә кәгазь тышлыгына кирилл алфавитында «А.-Г. Максудов. Энциклопедический словарь *(На татарском языке).* Издание А.-Г. Максудова. Казань. 1927 г.» дип язылган. Китап гарәп алфавитында басылган.

Бу хезмәтнең авторы—инде XX гасыр башында ук бөтен төрки-татар дөньясына танылып өлгергән журналист, нашир һәм иҗтимагый-сәяси эшлекле Әхмәтһади Максуди (1868-1941).

«Камус»ның кереш өлешендә ул аның максатын болай дип бәян итә: «Матбугат вә әдәбиятка катнашкан фәнни истилах *(сүзләр)* вә атамаларны аңлату өчен мәдәни милләтләр берничә җилдле *(томлы)* фәнни камуслар тәртип кылырга мәҗбүр булганнар. Хәзер бу мәҗбүрият тәрәкъкый юлына баскан безнең милләттә һәм башка төрек милләтләрендә дә хис кылына *(ителә)* башлады. Шул бабта бер башлангычка нигез салу уе белән мин ун мең кадәр фәнни, әдәби вә сыйнфый *(икътисади)* атамалардан гыйбарәт шушы камусны тәртип кылдым». Ә. Максуди фикеренчә, «Фәнни камус» дүрт томда чыгарылырга тиеш булган, ләкин 1927—1928 елларда аның беренче томы гына, дүрт өлешкә бүленеп, аерым брошюралар итеп бастырылган. Шуларның беренчесендә—48 бит (409 сүз); икенчесендә—64 бит (383 сүз); өченчесендә—55 бит (594 сүз); дүртенчесендә—159 бит (913 сүз); барлыгы 326 бит (2299 сүз) бар.

Хезмәтенең төзелеше турында автор: «Гадәттә камуслар әлифба тәртибе белән тәэлиф кылынсалар да, бу китапта төп атамаларны башка сүзләр белән янәшә итеп язарга тырыштым. Моннан максатым һәр сүзне үзенә мөнәсәбәтле берничә сүзгә бәйләүдер.

Мәгълүмдер ки, камуслардан бер сүзне караганда, кешеләр шул сүз янындагы башка сүзләргә дә күз салмый калмыйлар. Ул сүзләр төбәп караган сүзгә мөнәсәбәтле булганда, укучыларның күңелләрендә һәрберсе бергә бәйләнеп калып, онытылмаганнары онытылганнарын искә төшерәләр». Шулай итеп укучы: «...аз бер заман эчендә күп фәннең мөһим истилахларыннан хәбәрдар булып китәчәк».


«Фәнни камус»та барлык төшенчәләр, атамалар 126 параграфта 21 төркемгә берләштереп бирелергә тиеш булган. Хезмәтенең беренче чыгарылышында ук Ә. Максуди шушы параграфларның эчтәлеген китерә һәм бит саннарын да күрсәтә.

Беренче томда барлыгы 56 параграф; беренче брошюраның башлангыч параграфында «Гыйлем вә фәннәрнең гомуми исемнәре» санап кителә, алар 15: (Фәлсәфә фәннәре; Математика фәннәре; Физика бүлекләре; Химия фәннәре бүлекләре; Мифологиягә мөнәсәбәтле фәннәр; Нәбатат *(үсемлекләр)* фәннәре; Хәйванәт фәннәре; Антропологиягә мөнәсәбәтле фәннәр; Медицина фәннәре; Иҗтимагый фәннәр; Тел вә әдәбият фәннәре; Тәрбия вә тәгълим фәннәре; Космографиягә мөнәсәбәтле фәннәр; Тарихи фәннәр; Дини фәннәр *(теология фәннәре)*.

Һәр параграфта теге яки бу тармакка караган төшенчәләр, атамалар хакында кыскача гына аңлатмалар да биреп барылган. Мәсәлән, «Тарих фәннәре» дигән параграфта 18 атама теркәлгән: историка, историография, историясофия, философия истории, археология, палеология, археография *(полеография)*, эпитаграфика, дипломатика, нумизматика, хронология логография, генеалогия, геральдика, синология, египтология, семитология, тюркология, славистика.

22 нче параграфта философема, космос, натура *(природа)*, натуральный, макрокосм, микрокосм, ноумен, феномен, корпус *(тело)*, материя, масса, форма, объем, молекула, атом *(49—50 б.б)*, шул рәттән хаос, пространство, время, атараксия, эманация, эоны *(52—53 б.б)* һ. б. төшенчәләр бирелә.

Әйткәнебезчә, сүзлек гарәп хәрефләре белән басылган, «кара сүзләр»—атамалар—кириллицада русча, янәшәсендә шул ук сүзләр гарәп хәрефләре белән бирелгән. Аларның шактый өлеше татарчага да тәрҗемә ителгән. Күп кенә атамаларның кайсы телдән алынуы (лат., фр., рус, инглиз һ. б.) җәяләр эчендә күрсәтелгән, кайбер сүзләрнең этимологиясе турында белешмә китерелгән. Мәсәлән, 128 биттә: «Комильфотность»—төшенчәсе турында: «(фр)—әдәп; мәҗлес әдәпләрен кыла белү, үзен һәр мәҗлестә кирәгенчә килешле рәвештә тота белү. Бу сүз французча ком ил фу—ничек тиеш шулай, дигән сүздән ясалган».



«Камус»ның титул бите

Татар телендә фәнни терминологияне системага салуда зур хезмәт куйган Татар энциклопедиясе институты галимнәре билгеләп үткәнчә, Ә. Максуди сүзлегендәге живопись-рәссамлык; сюжет-мәүзугъ; сплав-эрүле катнашма; математика өлкәсеннән: дуга—җәя; гипербола-кысынкы җәя һәм күп кенә башка атамаларны бүген дә кулланып булыр иде.

Шул ук вакытта сөйләм телендә һәм язма телдә кулланылган яки шулардан файдаланып ясалган интернациональ терминнарның синонимнары күрсәтелмәгән. Мәсәлән, поэзия, культура, филология, философия һ. б. сүзләр татарчага тәрҗемә ителмичә генә алынган. Авторның андый алынмаларны татар теле лексикасының бер өлеше булырга тиеш дип уйлавы ихтимал.

Беренче томга кергән дүртенче китапчык тышлыгында биология, анатомия, физиология, медицина, хокук һәм сәясәткә караган атамаларны эченә алган икенче томның тиз арада чыгачагы хәбәр ителә.

Кызганычка каршы, «Фәнни камус» 1 томга кергән дүрт брошюрадан калган өлеше басылмаган булса кирәк. Хәзер безнең кулда барлыгы әнә шул дүрт юка китапчык кына.

Сүзлекнең аңлатма мәкаләләре турында берничә сүз.

Атамалар һәм төшенчәләрнең аңлатмалары асылда гадәти лексикографик сүзлекләрдәгедән аерылмый диярлек. Мәсәлән, глиптика сүзе бик кыска итеп аңлатылган: «...таш йә металлга сызып-казып язу, рәсем һәм бизәкләр төшерү». Хирургия терминына бирелгән аңлатма: «авыруның

әгъзаларын басып, тартып, кисеп, тегеп, ялгап тергезү ысуллары турындагы фән». Шундый кыска-кыска гына, гомуми, төшенчәләрнең эчтәлеген өстән-өстән генә ачыклаган аңлатмалар «Фәнни камус»ны белешмә сүзлек дип бәяләргә дә нигез бирә. Дөрес, күп очракларда аңлатма-төшенчәләргә (мәсәлән, агностизм, критицизм, рационализм, эволюционизм, философия истории, дипломатика һ. б. сүзләргә) шактый киң, эчтәлекле һәм адекват аңлатмалар бирелә. Шул ук вакытта кайбер терминнарны артык гадиләштереп, примитив аңлату очраклары да күзгә ташлана. «Мышление» («Фикерләү») терминына бирелгән мәкалә моның ачык мисалы: «...уйлау, тәфәккер; бер фикердән икенче фикергә күчү. Ишек каккан тавышны ишеткән кеше колагы белән ишеткән тавышны тоюдан башта һавада бер тавыш хасил булганын белә. Бу беренче уй була. Ул кеше бу уйдан аның сәбәбенә күчә: бу тавыш ишектән хасил булды, ул ишек янында бер кеше булырга кирәк, ул кеше минем ишекне бер максуд *(максат)* өчен каккандыр, ул мине күреп сөйләшүне тели торгандыр, дип уйлана. Әнә шул тәфәккер була. Уйлау күбесенчә яңа хасил булган бер төптән башланып китә, хәтердәге хыялларны берсенең күңелгә килүендә башлана, йокламаган сау кеше һич бер уй вә уйланусыз тора алмый, уйлануның бетүе һуш китүдән гыйбарәт бер ауру була» (123 б.). Янсә: «Актуальный». Беренчедән, ни өчен автор бу сыйфат сүзен төшенчәләр рәтенә кертергә кирәк дип тапкан. Икенчедән ник шундый садә аңлатма белән чикләнгән: «фигълый, әсәре мәйданга чыгып тора торган сыйфатлар; бер нәрсәне эретеп торган җылылык шикелле» (66 б.).

...Ә. Максуди сүзлегенең эчтәлеген, үзенчәлеген тел белгечләре һ. б. галимнәр махсус өйрәнеп тирән анализ ясарлар әле. Кыска гына бу язманың максаты—нинди дер сәбәпләр аркасында милләтебезнең рухи тормышы һәм мәдәниятебез тарихының олы юлыннан читтә, онытылып яткан хезмәткә белгечләрнең игътибарын юнәлтү. Башта мин бу мәкаләгә «Онытылган китап» дип исем бирмәкче идем, ләкин эзләнү барышында ул уемнан кире кайтырга туры килде.

Язмамның беренче вариантын бетереп барганда (2001 елның ахырында), Татарстан китап нәшрияты, билгеле язучы һәм библиограф Исмәгыйль Габдулла улы Рәмиевнең (1895—1969) «Әдәби сүзлек»[1] исемле хезмәтен бастырып чыгарды. Анда Ә. Максуди турында кыскача биографик белешмә бирелгән: «1927—1928 елларда аның русча-гарәпчә-татарча терминнар сүзлеге (ассызыклау безнеке—Г. С.)—500 битлек «Фәнни камус» нәшер ителгән» диелә. Соңрак тел белгече Ф. Фасеевнең «Татар телендә терминология» (Казан, 1969) дигән монографиясенең әдәбият исемлегендә «Фәнни камус»та искә алына, аның дүрт кисәктән торуы, 1927—1928 елларда басылып чыгуы әйтелә (197 б.). Дөрес, монографиядә бу китап турында бер сүз дә юк.

Өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең (1978—1981) авторлары да беренче томда бирелгән «Сүз башы»нда К. Насыйриның 1896 елда чыккан «Ләһҗәи татари», Җ. Вәлидинең 1927, 1929 елларда дөнья күргән һәм берничә хәрефкә төзелгән «Татар теленең тулы сүзлеге» белән файдаланулары турында әйтәләр, Ә. Максудиның терминологик сүзлеге искә алынмый.

Соңгы вакытта, бертуган Садри һәм аның абыйсы Әхмәтһади Максудилар турында еш искә алынган заманда конференцияләрдә укылган докладларда[2], алар хакында вакытлы матбугатта басылган язмаларда[3],

---

[1]Рәмиев И. Г., Даутов Р. Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәләр).—Казан, 2000.

[2]Гаффарова Ф. Ю. Бертуган Максудилар.—Заказанье: Проблемы истории и культуры. Материалы конференции.—Казань, 1995.

[3]Әхмәтҗанов М. И. Мәгърифәтчебез кабызган «Йолдыз».—«Шәһри Казан» газетасы, 1993, 14 сентябрь; Нуруллина Р. М. Беренчеләрнең берсе (Һади Максудиның тууына 125 ел тулу белән).—«Ватаным Татарстан» газетасы.—1993, 1 октябрь; «Я ближе всех связан с И. Гаспринским. «Гасырлар авазы—»Эхо веков» журналы, 1995, май. 174-195 б. б.

китапларда[1] Ә. Максудиның «Фәнни камус»ы тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калган. Югарыда күрсәтелгән очрактан тыш, аның башка беркайда да искә алынмавы сәер, әлбәттә.

Бу онытылган басма авторы турында 1999 елда нәшер ителгән «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә (русча басмасы) Ә. Максуди турында кыска гына мәгълүмат бирелә, әмма анда да «Фәнни камус» хакында бер сүз дә әйтелми.

Билгеле бу хәлнең төп сәбәбе—Ә. Максудиның тормыш юлы һәм иҗат мирасы хәзергә кадәр бик аз өйрәнелүдә. 1996 елның май аенда махсус чыгарылган «Гасырлар авазы»—«Эхо веков» журналында «Тикшеренүчеләр Ә. Максуди исемен теге яки бу очрак уңае белән яки академик басмалардагы искәрмәләрдә һәм анда да әле идеологик штамплардан файдаланып кына искә алалар», дип, бик хаклы билгеләп үтелә *(117—178 б. б.)*. Тагын шуны да әйтергә кирәк, Ә. Максуди XX гасыр башында ук инде татар иҗтимагый һәм милли хәрәкәтендә шөһрәт казанган шәхесләрнең берсе буларак, 1930 елларда НКВД органнары тарафыннан контрреволюцион эш алып баручылар исемлегенә кертелгән була. Алай гына да түгел, НКВДның махсус бүлек вәкиленең 1936 елның 27 сентябрендәге йомгаклау сүзендә әйтелгәнчә: «1928 елдан кулга алынган көнгә кадәр... Совет хакимиятен корал куллану юлы белән бәреп төшерүне максат итеп куйган, Татреспубликада к-р (контрреволюцион) «Бөтенсоюз социалистик фашистлар партиясе» исемендәге баш күтәрүче милли-социалистлар оешмасын да җитәкләгән», имеш *(шунда ук, 186 б.)*.

Россиядә төрки халыклар арасында исеме киң танылган, Казанда 1906 елда ачылган, мөселман әдәбияты тупланган беренче китапханә—«Көтепханәи исламия»не оештыручы, 1906—1918 елларда «Йолдыз» газетасы нашире һәм мөхәррире, мәктәп һәм мәдрәсәләр өчен уку әсбаплары төзүче шәхесне шундый мәгънәсез гаепләүләр нәтиҗәсендә 1932 елның декабрендә кулга алалар, 1933 елның маенда Киров шәһәренә сөргенгә озаталар. Хәзер «Фәнни камус» хакында бер кайда да искә алынмауның төп сәбәбе—Ә. Максудиның тормышындагы шул фаҗигале хәл булуын ачыктан-ачык әйтергә була.

1950 еллар ахырында Төркиядә нәшер ителгән «Ике бертуган Максудилар» исемле китап авторы Г. Г. Баттал-Таймас (аның хакында да «Татар энциклопедик сүзлеге»нең 64 битендә кыска гына мәгълүмат бирелә) Ә. Максудига багышлап язган очеркында аның берничә әсәрен күрсәтсә дә, безне кызыксындырган «Фәнни камус» искә алынмаган; әлбәттә, 1921 елдан эмиграциядә яшәгәнлектән, аның бу хакта белмәве дә гаҗәп түгел. Ә. Максудиның дүртенче буын оныгы Г. Г. Зәбировның «Максуд баба һәм Максудилар» *(Казан, 2000)* исемле китабыннан да кирәкле мәгълүматлар табылмады.

Шулай итеп, Ә. Максуди сүзлеге тел һәм мәдәният тарихы сәхнәсенең артында калган. Моның беренче төп сәбәбе турында әйтелгән иде инде. Ләкин бу хәлнең тагын бер мөһим сәбәбе бар, ул—халкыбызның алфавиты алышынуда. Нәкъ менә «Фәнни камус» дөнья күргән 1927 елда гарәп графикасындагы татар әлифбасын «Яңалиф»кә күчерү турында карар кабул ителә. Латинга күчү мәдәни үсеш юлында алгарыш булып саналса, гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган һәрнәрсәгә дини-милләтчелек күренеше дип кырын карау хөкем сөргән.

Әйткәнебезчә, Ә. Максудиның беренче хезмәт җимеше—«Фәнни камус» төгәлләнмәгән хәлдә калган. Шуңа бәйле бәхәссез бер фактны искәртеп үтәсем килә: Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889)[2], Каюм

---

[1]Айда Адиля. Садри Максуди Арсал.—М., 1996; Баттал-Таймас Г. Г. Два брата Максуди. Жизнь, творчество и труды.—Казан, 1999; Забиров Г. Г. Максуд баба һәм Максудилар.—Казан, 2000.

[2]Ш. Мәрҗани. Вафиятел-әслаф вә тәхийятел-әхлаф -Элгәрләрнең некрологлары һәм аларның киләчәк буыннарга бүләге // VII-XIX гасырларда яшәгән күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре турында мәгълүматларны эченә ала; 7 томлык кулъязма Казан университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана. Ш. Мәрҗани. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар—Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр. Ике китаптан тора, беренчесе - 1885, 1895 елларда, икенчесе—1890 елда, 1989 елда (кыскартылып) Казанда, 1998 елда Төркиядә басыла.

Насыйри (1825—1902)[1] һәм Ризаэтдин Фәхретдин (1859—1936)[2] h. б. татар галимнәренең эшчәнлеге инде XIX гасыр ахырларында ук энциклопедик хезмәтләр иҗат итүгә юнәлтелгән. Моның шулай икәнлеге югарыда искә алынган И. Рәмиев төзегән «Әдәби сүзлек» мисалында да ачык күренә. Соңыннан ул хезмәт милләтебезнең тарихын, мәдәниятен тирәнтен белүче Рәис Нәүширван улы Даутовның иҗади тырышлыгы нәтиҗәсендә беренче мәртәбә 1992—1994 елларда «Татарстан» журналында басылды, 2001 елда аерым китап буларак дөнья күрде.

Галимнәрнең һәм мәдәният эшлеклеләренең һәр буынында татар энциклопедиясен төзү эшенә омтылучылар булган. Шулар арасыннан Казан педагогия институты профессоры Рифкат Шакирҗан улы Таһиров (1903—1978) исемен хәтергә төшереп үтәргә кирәк[3]. Ул энциклопедик хезмәт язар өчен бик зур көч куйган, күп материал туплап системага салып барган. Шул материалларның беренчесе папкасы тышына «Энциклопедический словарь «Татарстан» (в 11-и томах)», дип язып куйган. Кызганычка каршы, ул да үзенең күпьеллык хезмәтен тәмамлап гамәлгә ашырырга өлгерми.

Шунысын да искәртик: заманча эшләнә торган универсаль энциклопедияләр төзү бер яисә берничә кеше тырышлыгы белән генә башкарыла торган эш түгел. Шулай да Ә. Максуди һәм алда әйтелгән галимнәрнең омтылышлары, хезмәтләре бүгенге фундаменталь фәнни белешмәләр төзү юлының мөһим бер баскычы, нигез ташы дип санарга кирәк.

Югарыда сөйләгәннәрдән безнең алга тагын бер зур һәм актуаль проблема—мәдәни мирасыбызга караш проблемасы килеп баса. Әйтергә кирәк, узган елларда гасырлар буена тупланган мәдәни мирасыбызны барлау һәм өйрәнү өлкәсендә шактый эш эшләнде кебек. Диссертацияләр яклана тора, махсус тикшеренүләр нәшер ителә, әмма 1917 елларга кадәр 1920 еллардан алып 1990 елларга кадәр—шул өлкәдә башкарылган эшләрне җитди тәнкыйть күзлегеннән яңадан карап чыгасы бар. Мисал өчен 1979 елда басылып чыккан «Татарстан китаплары. Библиографик күрсәткеч» *(1 том.—1917 ноябрь.—1929)* дигән китапны күрсәтергә була. Анда Ә. Максудиның да ике хезмәте—1918 елда басылган грамматика дәреслеге һәм руслар өчен «Татарстан. Самоучитель татарского языка» (нәшер ителү елы күрсәтелмәгән), искә алына. Ләкин әлеге «Фәнни камус»ның дөньяга чыгуы турында ләм-мим әйтелми. Шушы китап өстендә эшләгәннәрнең берсе әйтүенчә, ул чорда Облит вәкилләре «Библиографик күрсәткеч» төзүчеләргә сәяси дәрәҗәсе һәм абруена шикләнеп карау хөкеменә эләккән авторларның хезмәтләрен теркәүне «тәкъдим итмәгәннәр». Гыйлемлек мәҗбурияте һәм тормыш бездән Татарстанда гына түгел, бәлки татарлар күпләп яшәгән өлкәләрдәге, шулай ук Мәскәү, С.-Петербург кебек билгеле фәнни һәм мәдәни үзәкләрдә дә дөнья күргән татар китапларының библиографик күрсәткечләрен яңадан төзү эшенә керешүебезне таләп итә.

---

[1]К. Насыйри. «Ләһҗәи татари», 2 томда, 1895-1896.

[2]Р. Фәхретдин. Тарихчы, дин белгече, журналист. Тарих, мөселман фәлсәфи, әхлак нигезләре, педагогик хезмәтләр авторы.

[3]Г. Сабирҗанов, И. Кадыйров. «У истоков татарской энциклопедии», «Республика Татарстан», 1998, 10 ноябрь.

**Фатих Урманче**

# МЕҢ ЯРЫМ ЕЛ ЭЛЕК

## ЕВРОПА ХАЛЫКЛАРЫ ЭПОСЫНДА ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫНДА АТИЛЛА ОБРАЗЫ

Бу бөек тарихи шәхеснең исеме төрки-татар телләрендә **Атилла**, Европа телләрендә һәм төрле энциклопедияләрдә **Аттила** дип язылa. Атилла (?—453)—һуннарнын хөкемдары, ханы, Евразиядә яшәүче күп санлы герман һәм төрки-татар халыклары эпосынын һәм язма әдәбиятынын катлаулы, каршылыклы, нык кына мификлаштырылган серле-сихерле каһарманы. Монын конкрет сәбәбе Атилла чорындагы һәм анын турыдан-туры катнашы белән оештырылган, дөньякүләм әһәмияткә ия булган тарихи процесслар белән анлатыла: сүз IV—V гасырлардагы «халыкларнын бөек күчеше»нен дәвамы хакында бара. Әнә шундый зур тарихи вакыйгалар да, аларда турыдан-туры катнашкан зур тарихи шәхесләр дә, гадәттә, соныннан килгән буыннар тарафыннан үтә каршылыклы бәя ала. Ә инде 434—453 елларда Атилла идарә иткән Көнбатыш Һуннар дәүләтенең әһәмияте турында әлеге мәсьәләне махсус өйрәнгән профессор Ә. Мөхәммәди үзенең «Һуннар һәм Туран язмалары» *(Казан, 2000)* дигән хезмәтендә түбәндәгечә яза: «Кытай чикләреннән башлап Урта Азиягә кадәр җәелгән борынгы Һун дәүләте кебек үк, көнбатыштагы Һуннар дәүләте көнчыгыш, көнбатыш һәм башка өлкәләргә бүленгән. Һуннарның үз чорлары өчен югары дәрәҗәдәге үсешкә ирешкән, үзенчәлекле мәдәнияткә ия булулары мәгълүм. Алар дәүләт эшләрендә кытай йә латин алфавитыннан түгел, ә үз әлифбаларыннан файдаланганнар, ягъни язма цивилизацияле халык булганнар».

Хәрби, икътисади һәм мәдәни яктан югары дәрәҗәдә торып, Евразиянең төп территорияләрен биләгән Көнчыгыш, соңрак Көнбатыш һун дәүләте Европа халыклары язмышында, бигрәк тә Атилла чорында, дөньякүләм, глобаль үзгәрешләргә китерә. Аларнын барысы да бу процессларда катнашырга мәҗбүр булган барлык халыклар өчен дә һичшиксез унай күренеш булган дип раслау дөреслеккә туры килеп бетмәс иде. Чөнки әлеге процесслар дәвамында берничә йөз мең кеше катнашындагы ифрат та зур, куркыныч сугыш-орышлар була, шактый күп халык кырыла. Ике дистә ел буена әнә шул вакыйгаларнын үзәгендә Атилла тора, хәтта аларнын төп өлешен ул үзе оештыра. Кем өчендер әлеге сугышлар унай нәтиҗәләр бирсә, икенче бераүләр зур югалтуларга дучар була. Шунын белән бәйле рәвештә тарихи Атилланы бәяләү дә капма-каршы юнәлешләрдә бара: ике мең ел буена Көнчыгышны Көнбатышка каршы кую дәвам итеп килә. Ягъни, утрак тормышта яшәгән Европа илләре, янәсе, алдынгы цивилизацияле дәүләтләр; күчмәчелектә гомер кичергән Азия халыклары исә—артта калган, хәтта кыргый варварлар. Дөнья тарихында зур роль уйнаган һуннарны һәм аларнын данлыклы юлбашчысы Атилланы бәяләүдә дә әлеге примитив тенденция беренче планга чыга. Цивилизациягә шактый соң ирешкән, дөресрәге—кешелек дөньясынын барлык матди һәм рухи казанышларын Борынгы Шәрекътән алган Европа үзен өйрәтүчеләрдән, остазларыннан үч алырга тырыша һәм дөньякүләм мәгълүм «индоевропеистика», «европоцентризм» дип аталган ясалма, Җиһан, Кешелек тарихынын күптән ачыкланган мәгълүматларына турыдан-туры каршы торган теорияләр уйлап чыгара. Һун дәүләтләренә һәм тарихи Атиллага бәя бирергә алынганда, мәсьәләнең әнә шул ягын да истән чыгарырга ярамый.

Ф. А. Брокгауз һәм И. А. Ефрон энциклопедиясендә Мундцук (Ә.

Мөхәммәди китабында—Менчук) улы дип аңлатылган Атилла агасы Ругилас үлгәч, 433 елда абыйсы Бледа (Белит) белән бергә һуннарның иң югары хөкемдары (ханы, хаканы?) дигән исемгә лаек булалар. VI гасыр тарихчысы Иорданның «О происхождении и деяниях гетов» дигән китабында язылганча, Атилла 445 елда Бледаны үтереп, хакимиятне тулысынча үз кулына ала. Иорданның гот, герман халыклары идеологиясенә нигезләнгән бу китабы—бик тә тенденциоз әсәр: ул тулысынча европоцентризм таләпләренә җавап бирә. Шуңа күрә менә шушы юнәлештә фикер йөрткән галимнәр Иордан сүзләренең һәркайсын объектив дип кабул итәләр. Нәтиҗәдә, Атилла үзенең туган абыйсын үтереп, тәхеткә күтәрелә дигән сүзләр рәсми тарихта, төрле энциклопедияләрдә урын ала: чөнки әлеге адым Атилланы һич тә бизәми, ә европоцентризм вәкилләренә шул гына кирәк тә! Тик шундый хакыйкатьне дә онытырга ярамый: кешелек тарихыннан бер дә гөнаһсыз бөек шәхесләрне гомумән табып буламы икән? Өстәвенә әлеге мәсьәләне фәндә бөтенләй башкача аңлату да бар: профессор Ә. Мөхәммәди югарыда күрсәтелгән китабында түбәндәгечә яза: Белит (Бледа) үтерелгән елларда «инде күптән бу чорда хакимият тулысынча Атилла кулында булганга күрә, Белит нинди дә булса җитди көндәшлек хасил итә алмаган».

Әмма ничек кенә булмасын, хакимиятне тулысынча үз кулына алгач, Атилла болай да зур дәүләтнең чикләрен тагын да киңәйтү чараларына керешә һәм бу эшләрне зур уныш белән алып бара. Моның сәбәпләре, барыннан да элек тарих кануннары белән аңлатылса (колбиләүчелекнең һәм шуңа нигезләнгән Изге Рим империясенең байлыктан череп таркалуы), икенчедән, ул сәбәпләр Атилланың шәхси сыйфатлары белән дә нык бәйләнгән була. Атилланың тышкы кыяфәте бик тә үзенчәлекле, бары тик хәрби кешеләргә генә хас сыйфатларга ия булган. Бу хакта Атиллага килгән Византия илчелеге әгъзаларыннан берсе Приск Панияле һәм, аңа таянып, Иордан язып калдырган. Әнә шул чыганаклар нигезендә булса кирәк, танылган, татар тарихчысы Г. Гобәйдуллин да (1887—1938) үз фикерләрен бәян кыла. «Тарихи сәхифәләр ачылганда» *(Казан, 1989)* дип аталган китабында урын алган мәкаләләрнең берсендә ул Атилла турында болай яза: «Һуннар Атилла исемле ханнары заманасында бик куәтләнеп китеп, ул заманның иң куәтле булган Европадагы империяләрне дер селкеткәннәр. Хәзерге Франция, Германия, Италиянең эчләрендә һун атларының тоякларыннан күтәрелгән тузан бик еш күренәдер иде. Истанбул, Рума кебек зур шәһәрләрдә торган императорлар Атилладан мәрхәмәт сорап ялварганнар, әллә никадәр акча, бүләк биреп кенә үзләренең җирләрен һуннардан котылдырып торганнар».

Тарихчы тарафыннан Атилланың тышкы кыяфәте ничек сурәтләнүе аерым бер игътибарга лаек: «Атилла кыска буйлы, киң җилкәле, зур башлы, сирәк сакаллы, кечкенә, эчкә батып торган кыек, үткен күзле бер кеше булган. Аның күз карашы кешене куркыта, үзенә буйсындыра, иң гайрәтле батыр кешеләр дә аның күз каравыннан чыдый алмыйлар; аның сүзе, һәрбер хәрәкәте кешегә зур тәэсир бирә вә куркыта, ул үзе ачуы килгән кешеләренә бик мәрхәмәтсез, яраткан һәм илгә хезмәте тигән кешеләргә бик күп яхшылык кыладыр иде». Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтик: галимнең бу сүзләре гарәп тарихчысы ибне Гарәпшаһ тарафыннан Идегәйгә карата әйтелгән сүзләргә бик якыннар. Ашау-эчү һәм кием ягыннан, гомумән, көндәлек тормышта Атилла бик тә тыйнак була. Үзе күчмә тормышны яратса да, читтән килгән дәрәҗәле кунакларны ул Венгриядәге башкаласында агачтан төзелгән махсус зиннәтле сарайда каршы ала торган була.

Европада аның турында: «Ул—кыргый бер азиат»,—дигән хәбәр таратырга тырышсалар да, Атилла белән якыннанрак танышкач, бөтенләй башка тәэсир кала торган булган: ул һәрвакыт үз-үзен бик тә горур тота белгән; үзенең ил-халкы алдындагы сәяси дәрәҗәсен, җинелмәс, көч-куәткә ия илнең хөкемдары булуын аңлап эш иткән. Барысын да таң калдырганы—ул үз халкы вәкилләренә генә түгел, хәтта явыз дошманнарына карата да һәрвакыт гаделлек күрсәткән. Нәкъ әнә шуңа күрә Европа илләренең бик күп халыклары Атиллага үз ирекләре белән буйсынганнар. Хәер, бу очракта сүз аның шәхси сыйфатлары турында гына бара дип булмый. Европа халыклары аны, беренчедән, үзләрен Рим империясе коллыгыннан азат итүче дип санасалар, икенчедән һәм, моның капма-каршысы буларак, аларның—европалыларның сансыз күп гөнаһлары өчен үз аллалары

(Господь Бог) тарафыннан җибәрелгән җәза, бәла-каза дип кабул иткәннәр. Әнә шуларның барысы бергә Атиллага искиткеч зур дәүләт төзү мөмкинлеген бирә. Ул төзегән дәүләт-илне еш кына **Халыклар союзы** дип атыйлар. Әлеге дәүләт составына түбәндәге халыклар керә: төньяк готлар (герман халыклары), гепидлар, тюринглылар, геруллар, хәзәрләр һ. б. Атилла дәүләтенең башкаласы хәзерге Венгриянең төньяк-көнчыгышында, Токай шәһәреннән ерак булмаган бер җирдә урнаша. Европадагы сәясәтенең башлангыч чорында Атилла Көнчыгыш Рим империясен һәрвакыт зур хәвеф астында тота. Дунайдан көньяктагы территорияләрнең барысы да Атиллага буйсындырылгач, Рим императоры ана даими рәвештә зур ясак түләп торырга мәҗбүр була. Атилла гаскәре Мизия, Фракия, Иллирия илләрен айкап чыга. 440 елда Атилла Көнбатыш Рим империясе императоры Валентиниан III дән сеңлесе Гонорияне ана хатынлыкка бирүен үтенә. Император риза булмый. Җитмәсә римлылар көнчыгыш готлар императоры Теодорих белән үзара килешү дә төзегәннәр икән. Әнә шул хәлләр Атилланың ачуын чыгара. Нәтиҗәдә, ул 500000 кешедән торган гаскәре белән көнбатышка юнәлә, ут һәм кылыч белән Германия аркылы Рейн елгасына кадәр үтә; Неккара кушылдыгы тамагы янында Рейнны кичеп чыга, Трир, Мец, Аррас кебек күп калаларны утка тота. Атилла гаскәре Орлеан шәһәрен камап алгач, шәһәргә ярдәмгә Валентинианның яубашы Аэций белән көнчыгыш готлар патшасы Теодорих килеп җитә. Нәтиҗәдә, Атилла Орлеан каласын камап торудан баш тарта һәм үзенең гаскәрен Труа шәһәреннән ерак булмаган Каталаун тигезлегенә җыя. Нәкъ әнә шул Каталаун кырында 451 елның 15 июнендә әлегә кадәр һичкайда күренмәгән халыклар сугышы була. Башта һун гаскәренә каршы Теодорих, ул һәлак булгач аның улы Торизмунд сугыша. Атилла үзенең ныгытылган кальгасы Вагенбургка чигенергә мәҗбүр була. Моннан соң инде Аэций дә һуннарга каршы сугышны дәвам итүдән баш тарта. 200000 артык гаскәр яу кырында ятып кала. Сугышта катнашучы якларның бер-берсенә каршы ачуы шул дәрәҗәгә җитә ки, легендалар буенча, имештер, әлеге кырда һәлак булган гаскәрләрнең рухы, орыш туктатылгач та, һавада сугышуларын дәвам итәләр. Рәсми тарих Каталаун кырында Атилла гаскәре тар-мар ителә, дип язмакчы була. Һәрхәлдә, «Советская историческая энциклопедия» әнә шундый фикер уздыра *(Т. 4.—М., 1963, 890 багана)*. Чынлыкта исә мәсьәлә бөтенләй башкача тора. Җиңелгән гаскәр, гадәттә, тәмам юкка чыкмаса да, сугышны дәвам итә алмый. Каталаун кырындагы сугышның нәтиҗәләре Атилла гаскәренең җиңелмәве турында сөйли: әгәр җиңелгән яубаш булса, ул үз яуларын алга таба да дәвам итә алмаган булыр иде. Ә Атилла башкача хәрәкәт итә: яңадан Германиягә кайта. 452 елда ул яңа яу оештыра, көнчыгыш Альплар аркылы Италиягә бәреп керә, нык кальгаларның берсе булган Аквилеяны, Альтинум, Падуя, Милан һ. б. күп шәһәрләрне яулап ала. Рим, гомумән Италия һуннарның корбаны булу куркынычы алдында кала. 452 елда Атилла үзенең гаскәре белән Рим капкасы алдына килеп туктый. Бу «мәңгелек шәһәр»не җимерелүдән коткарып калу өчен, Атилла каршына рәсми, бик тә бай киемнәрдән һәм Римнең иң югары дәрәҗәле руханилары белән бергә папа Лев I чыга һәм Атилладан шәһәрне җимермәвен үтенә. Атилла Рим папасы үтенече белән килешә, шәһәргә кагылмый, тик алтын акчадан салым ала. Шул рәвешчә, ул дәверләрдәге Европаның мәдәният һәм сәнгать үзәге булган Рим һун явыннан котылып кала.

Иделнең түбән агымы һәм Җаек буйларыннан чыгып, ун ел дәвамында бөтен Европаны айкап, Көнбатыш Рим империясе һәм Көнчыгыш Рим империясе кебек зур һәм һәръяктан кодрәтле илләрне тетрәндереп узган Атилланың тормыш юлы һәм кылган эшләре никадәр катлаулы, каршылыклы, мифологик бер зат башкарган сыман серле булган кебек, аның бу дөньядан китүе дә шулай ук бик серле. Соңыннан бу үлем турында төрле риваять-легендалар, хәтта тулы мифологик-эпик сюжетлар барлыкка килә, (бигрәк тә Европа, хәтта Скандинавия һәм Исландия халыклары эпосында) «Атилла үзенең соңгы туенда никах түшәгендә бургунд кызы Ильдико (яки Ильдихо) кулыннан һәлак булмадымы икән?» дигән фараз бар. Кайбер гоман кылулар буенча, Ильдико, үз халкы күргән җәбер-михнәтләр өчен Атилладан үч алам дип, аңа кул сала.

Венгриядә таралган кайбер легендалар буенча, Атилланың гәүдәсен берсе эченә берсен салып, алтын, көмеш һәм тимер табутларга куялар. Гадәт буенча,

табут хәзерләгән әсирләрнең барысы да үтерелә. Тисса елгасының бер төшен вакытлыча судан арындыралар да, табутларны елга төбендәге жиргә күмәләр аннан елга суын янадан үз урынына кайтаралар: Атилланың гәүдәсен, шулай итеп, су астына—елга төбендәге жиргә күмәләр. Аның кабере кайда икәнлеген әлегә кадәр беркем дә белми һәм беркайчан да белмәячәк.

Атилла бу дөньядан киткәч аның тарафыннан төзелгән һәм Евразиянең төп өлешен биләп торган дәүләт акрынлап таркала. Атилланың улы Эллак чорында Паннониядәге Нетада елгасы буендагы сугышта герман һәм скиф кабиләләре мөстәкыйльлеккә ирешәләр. Әмма Атилла төзегән дөньякүләм ил («мировое государство») юкка чыкса да, атаклы полководецның мификлаштырылган образы Европа һәм Азия халыклары аңына гаять тирән үтеп керә һәм төрле риваять-легендаларда, сагаларда, дастаннарда мең ярым ел буена сакланып, безнең көннәргә кадәр килеп житә.

## Тарихи Атилладан—Атли

Атли—Скандинавия халыклары мифологиясе һәм эпосы каһарманы. Килеп чыгышы ягыннан Атилла образы белән турыдан-туры бәйләнгән бу исем исланд сагаларында һәм ирланд эпосында шактый еш очрый. Беренче карашка, әлеге әсәрләрдәге Атлиларның тарихи Атиллага бернинди дә катнашы юк кебек. Чыннан да, тарихи Атилла бу дөньядан китеп, Европадагы һун дәүләте таркалганнан соң әлеге сагалар барлыкка килгәнче инде 5-7 гасыр вакыт узган. Исландия халыклары һуннарның тарихи варислары булган төрки-татар дөньясыннан меннәрчә чакырым ераклыкта гомер кичерәләр. Шуна да карамастан, тарихи Атилла истәлеге анда төрки-татар халыкларына караганда яхшырак сакланган. Эш нәрсәдә соң, мондый хәлне ничек аңлатырга? Билгеле булганча, Европа һун дәүләтенең башкаласы хәзерге Венгриянең төньяк-көнчыгышында, ягъни Европаның үзәгендә була. V гасырның 40—50 елларында Атилла кул астындагы һunnнарның төп хәрби хәрәкәтләре Европа жирләрендә башкарыла. Бу хәрби хәрәкәтләрнең, орыш-сугышларның барысы да Атилланың һәм һуннарның жиңүе белән тәмамлана. Ул елларда Европада булган хәрби, сәяси һәм икътисади вакыйгаларның барысында Атилла һәм һун гаскәрләре хәлиткеч роль уйнамаса да, турыдан-туры катнаша. Мәсьәләнең тагы бер ягын искә алырга кирәк: Атилла үзе дә, аның яубашлары да Европа илләре хөкемдарлары-корольләре кызларына өйләнергә тырышалар. Ягъни, Атилла һәм аның житәкчелегендәге һуннар Европа халыкларының көндәлек тормышына да тирән үтеп керергә омтылалар: Атилланың сәясәте шуны таләп итә. Күрсәтелгән вакыйгалар һәм хәлләр нәтижәсендә Атилла һәм һуннар барлык Европа илләрендә, хәтта Ирландия белән Исландиядә тәмам «үз кеше» булып китәләр. Тора-бара Европа халыклары әлеге вакыйгаларда катнашкан кабиләләрнең һәм Атилланың һун булуын да оныталар, аларны үз кабиләләре һәм халыклары дип кабул итә башлыйлар. V гасырның 40—50 елларында киң таралган: «Атилла һәм һуннар—Европаны яулап алучы кыргый азиатлар-варварлар» дигән караш бөтенләй онытыла. Скандинавия, Ирландия һәм Исландия халыклары традицияләрендә Атилла исеме Атли формасындагы гадәти исемгә әйләнә һәм әлеге илләр әдәбиятында киң тарала.

Биредә, кыскача гына булса да, Атилла-Атли исеме белән бәйле вакыйгалар чагылыш тапкан әсәрләрнең кайберләренә махсус тукталып үтү таләп ителә. Чөнки бу катлаулы мәсьәләнең күрсәтелгән аспекты әлегә кадәр бөтенләй өйрәнелмәгән. Шундый әсәрләрнең берсе—«Ньяла турында сага» («Сага о Ньяле»). Аны төньяк халыклары әдәбияты һәм рухи мәдәнияте хакында житди фәнни хезмәтләр язып калдырган профессор М. И. Стеблин-Каменский: «скандинавлылар тормышын яктырткан сагаларның иң зур күләмлесе, дөнья прозаик әдәбиятының иң бөекләреннән берсе» дип билгеләгән иде. «Ньяла турындагы сага»дә сүз X гасырда Норвегиядә булган вакыйгалар турында бара. Әнә шул вакыйгаларның кайберләрендә Атли дә катнаша. Бу очракта сүз чыннан да тарихи Атилла хакында бара икән дип булмый, билгеле. Сагадагы Атли ил башында торган хөкемдар-король дә түгел. Шулай да Атлиның характерына, үз-үзен тотышына кагылышлы кайбер күренешләргә тукталып үтү кызыклы нәтижәләр бирергә

мөмкин. Атли биредә исланд яугире Аривилнын улы дип тәкъдим ителә. Ул сугышырга бик ярата. Конунг (король) Харальд Серый Плащ (якынча 960-965 елларда хакимлек итә) Атлины һәм аның гаиләсен яратмый. Күрәсен, ул чорлардагы Европа хөкемдарларынын берсе дә Атилланы яратмагандыр. Атлига әлеге корольнын дружиннигы Хрут һәм анын гаскәрләре белән сугышырга туры килә. Орыш вакытында дошманнарның берсе Атлига таш белән ата. Атлинын кылычы кулыннан ычкына. Хрут шул кылычны эләктереп, Атлинын бер аягын чабып өзә һәм ана үлем ярасы ясый. Шул рәвешчә, сагага гомумэпик бер мотив килеп керә: Атли үз кылычыннан һәлак була... Шул ук әсәрдә тагын бер Атли турында сөйләнә. Әгәр югарыда күзәтелгән өзектә Көньяк гаутланды дигән җирдән чыккан Атли турында сөйләнсә, бусында инде сүз Көньяк Фьордлары ягыннан килгән Атли турында бара. Бу очракта да һичкемнән курыкмый торган сугышчы, кыю, көчле һәм горур бер яугир хакында бәян ителә. Ачык яуда Атли дошманыннан җинелмәгән булыр иде, әмма ул кызу эш белән мавыккан мизгелдә, дошманы Брюньольв, сиздермичә генә килеп, анын башына айбалта (секира) белән сугып, хыянәтчеләрчә үтерә... Атли исеме шул ук әсәрдә тагы берничә тапкыр телгә алына. Бер тапкыр ул Атли Сильный дип тә атала.

«Буннлауг Елан Тел турында сага» («Сага о буннлауга Змеином Языке») дип аталган әсәрдә ниндидер Атли телгә алына (әсәр 1280 елларда язылган). Моннан аермалы буларак, 1220 елда барлыкка килгән шактый зур күләмле «Эгиль турындагы сага» («Сага об Эгиле») дип аталган әсәрдә Атли исемле зат турында кинрәк мәгълүмат бирелә. Әсәрдә сүз Норвегия конунгы-короле Харальд Прекрасноволосый (якынча 860-940 еллар) чорында булган вакыйгалар, яна җирләр яки байлык өчен данлыклы, бай һәм көчле ырулар, шуларнын житәкчеләре арасындагы үзара көрәш, еш кына хәрби бәрелеш-сугышлар турында бара. Эгиль— әнә шундый зур байлыкка дәгъва кылучы көчле, кыю һәм батыр яугирләрнен берсе. Әсәрнен башыннан ахырына кадәр ул эпик каһарман рухында сурәтләнә. Безне кызыксындырган каһарман биредә Атли Короткий исеме белән мәгълүм. Ул—әсәрнен баш каһарманы Эгиль белән бер дәрәҗәдә торган зат. Алар арасында күптән байлык, төгәлрәге—җир өчен көрәш бара. Әлеге байлыкны Атлига король үзе биргән. Эгиль аны көч белән тартып алмакчы була. Менә алар көрәш мәйданында—Тингта очрашалар. Атли бергә-бер чыгып сугышырга тәкъдим итә. Аларнын үзара орышы турында әсәрдә тәфсилләп сөйләнелә. Башта алар кылыч белән сугышалар. Күпме генә тырышса да, Эгильнен кылычы Атли гәүдәсенә үтми. Атли дошманынын коралын бернәрсәгә дә үтмәслек итә белә икән. Ягъни, бу очракта Атли ниндидер маг, сихерче осталыгына да ия. Кылычтан берниндн мәгънә булмагач, алар икесе дә коралсыз гына сугышалар: Эгиль көчлерәк булып чыга. Атлине егып, өстенә ята һәм бугазын тешләп өзә. Атли әнә шулай һәлак була. Күренүенчә, скандинав сагаларында Атли—кыска буйлы, бик көчле, кыю, батыр сугышчы. Ул беркайчан да алдауга, ниндидер хәйләгә, бигрәк тә хыянәткә бармый. Әмма кыскача күзәтелгән әсәрләрнен һәркайсында ул батырларча сугышта һәм котылгысыз рәвештә билгеле бер хыянәт нәтиҗәсендә генә һәлак була. Европа илләре әдәбиятында Атилланы да, исеме шул яугирнекенә якын булган Атлины да башкача сурәтләү мөмкин дә булмагандыр.

Әмма Атли образын сурәтләгән әсәрләрнен саны монын белән чикләнми. Атли турында тагын «Вельсунглар турында сага» («Сага о Вельсунгах») (Исландия) һәм «Тидрек турында сага» («Сага о Тидреке») (Норвегия) дип аталган эпик әсәрләрдә сөйләнә. Биредә инде Атли—явыз һәм комсыз хөкемдар. Ул хәйлә белән Гьюкунглар ыруыннан булган бургунд короле Гуннарны һәм анын энесе Хегнины тозакка эләктерә; аларнын алтын хәзинәсен кулга төшерә, ә үзләрен коточкыч җәзага тартып һәлак итә. Атлинын хатыны, Гуннар белән Хегнинын сенлесе үзенен иреннән үч алам дип, Атлины үз кулы белән үтерә. Сонгы эпизод мәгълүм тарихи риваятьләр нигезендә барлыкка килгән: аларда сөйләнгәнчә, Атилла үзенен сонгы хатыны булырга тиешле герман әсирәсе Ильдиго (башка кайбер чыганакларда Ильдихо, Ильдико) тарафыннан никах түшәгендә агулап үтерелә. «Тидрек турында сага» да Атлинын һәлак булуы башкача сурәтләнә: Хегнинын хатыны үлем дәрәҗәсендә яраланган иреннән балага уза. Ул бала Атли сараенда үсә һәм Атлины, алдап, алтын хәзинә яшерелгән тау мәгарәсенә алып керә.Шунда бикләнгән һун короле әлеге алтын хәзинә янында ачлыктан

интегеп һәлак була. Кайбер легендаларда Атлига ниндидер шайтани сыйфатлар да хас дип әйтелә. (Янәсе, ул эттән туган икән—Иордан, Ф. Дан һ.б.ларның китапларында чагылыш тапкан мотив.)

Моннан кала, Атли образы нигездә Исландиядә XIII гасырның икенче яртысында барлыкка килгән «Өлкән Эдда» («Старшая Эдда»)да киң генә чагылыш таба. Китапка бирелгән мондый атаманың мәгънәсе әлегә кадәр ачыкланмаган. Аны гадәттә аллалар һәм батырлар турындагы жырлар жыентыгы дип аңлаталар. Әнә шул жырларның икесе Атлига багышланган. Беренчесе—«Атли турында гренлдан жыры» («Гренлданская песнь об Атли») («гренландская») дигән билгеләмә биредә ялгыш бирелгән: әлеге жырның Гренландиягә бернинди катнашы юк). Жыр шактый борынгы чорларга карый булса кирәк. Атли үзенең хатыны Гудрунның абыйлары—Гуннар белән Хегнины һәлак итә. Кайбер мәгълүматлар буенча, биредә сүз жинаятьчел үтерү түгел, ә бәлки ритуаль үлем, ир кешеләрне корбанга китерү хакында бара. Шуның өчен Гудрун үзенең ире Атлидан үч алмакчы була. Бу күренешнең нигезендә ыруглык жәмгыяте таләпләре ята: Гудрун өчен туган абыйлары иреннән күпкә якынрак. Шуңа күрә ул ире Атлины коточкыч жәзага тарта: үзенең Атлидан туган ике баласын үтереп, итләрен кыздырып, иренә ашата (бик борынгыдан килгән натуралистик гомумэпик мотив!). Соңрак Гудрун сырадан исергән Атлиның үзен дә суеп үтерә һәм өйләрен яндыра. Жырда әйтелгәнчә, бер хатын-кызның (Гудрунның) хыянәтчел эшләре аркасында өч конунг һәлак була. Беренче карашка, әлеге сюжетның тарихи Атиллага бернинди дә катнашы юк кебек. Чынлыкта исә мәсьәлә башкача хәл ителә. Моны тәгәл ачыклау өчен, Гудрун исеменең этимологиясенә игътибар итәргә кирәк. 453 елда үзенең ире Атилланы һәлак иткән хатын-кызның исеме Ильдиго-Хильд исеменең кечерәйтелеп-иркәләп әйтү формасы. Шул ук Хильд исеме алманча Кримхильдадан алынган. Немец эпосындагы Кримхильда исланд эпик традицияләрендә Гудрун дип алыштырыла. Ягъни, тарихи Атилланың үлеме белән бәйле вакыйга шактый озын юл узып, XIII гасырга бөтенләй башка формада—исем трансформациясе аша килеп житә.

«Өлкән Эдда» («Старшая Эдда»)ның тагын бер жыры «Гренландские речи Атли» дип атала. Аның сюжеты әле генә күзәтелгән жырныкыннан аерылмый; персонажлар да шул ук, вакыйгаларга да шулар. Тик бу жырның күләме зуррак: аңа кайбер яңа күренешләр кертелгән, каһарманнарның монологлары һәм диалоглары кинәйтелгән. Беренче жырдагы кайбер натуралистик күренешләр реалистик хикәяләү белән алыштырылган. Әмма бу жырның да тарихи нигезе шул ук—Атилланың Ильдиго кулыннан һәлак булуы!

Скандинавия халыкларының Атли исеме белән бәйле әдәби әсәрләрен күзәтү мөһим нәтижәләр ясарга мөмкинлек бирә. Барыннан да элек, шуны әйтик: Атли исемле каһарман да булган әсәрләрнең барысы да—«Өлкән Эдда»ның күзәтелгән бүлекләре дә, аерым сагалар да, һичшиксез, тарихи Атилланың шәхси тормышы һәм аның тарихи-хәрби эшчәнлеген яктыртуга нигезләнә. Тик ул үзенең этник табигатен нык кына үзгәртә: төрки һуннарның данлыклы яугире булган Атилла Скандинав халыкларының тулы хокуклы вәкиленә әверелә һәм, әлбәттә, үзенең дәрәжәсе тулысынча саклап кала. Ул һәрвакыт диярлек конунг-король яки аның якын туганы, һичьюгы—көчле, батыр яугир буларак сурәтләнә. Аның хатыны да—хөкемдарлар нәселеннән. Шуның белән бергә, түбәндәге фактларга да игътибар итми мөмкин түгел: скандинавларда «Сагалар гасыры» дигән билгеләмә Исландия жирләрен үзләштергән IX-X гасырларда ыруглык жәмгыятенә хас кануннар хөкем сөрә: анда барысы да тик көч белән генә хәл ителә. Шуңа күрә дошманыңны хыянәт юлы белән юк итү, бер-береңне алдау, дошманыңнан үч алу өчен аны рәхимсез үтерү кебек коточкыч хәлләр ул чорда гадәти бер күренеш булган. Аларның барысы да монда күзәтелгән әсәрләрдә шактый киң чагылыш таба. Еш кына алар Атилла—Атли исеме белән бәйләнештә бирелә. Европа һәм Скандинавия халыкларының ижтимагый аңына тирән үтеп кергән төп күренеш—Атилланы хыянәт юлы белән үтерү. Бу хыянәтне Европа халыклары күп гасырлар буена онытa алмаганнар.Без карап үткән әсәрләрдән бик күбесенең үзәгендә әнә шул вакыйга ята.

## Шул ук Атилладан—Этцель, Эцель

Күньяк герман дастан-поэмасы «Нибелунглар турында жыр» («Песнь о нибелунгах»)ның баш каһарманнарыннан берсе әнә шундый исем йөртә. Поэмада без скандинав эддаларыннан таныш булган каһарманнар белән очрашабыз: Зигфрид (Сигурд), Кримхильда (тарихи Ильдиго-Ильдихо, Гудрун), Брюнхильда, Гунтер (Гуннар), Этцель (тарихи—Атилла, исланча—Атли), Хаген (Хегни). Бу тарихи шәхесләрнең кылган эшләре һәм шигъри образлары гасырлар буена скандинав һәм немец халыкларының күнелен борчып килгән. Дөрес, аларның тарихи гамәлләрен һәм образларын кабул итү шактый зур үзгәрешләр кичергән. Исланд, скандинав һәм герман халыкларының эпик традицияләре нигезен һун яулары нәтижәсендә 437 елда Бургунд корольлегенең юкка чыгарылуы һәм 453 елда һун ханы (короле) Атилланың һәлак булуы кебек зур тарихи вакыйгалар тәшкил итә. Тик тарихи вакыйгаларны кабул итү һәм әдәби әсәрдә чагылдыру ягыннан исланд һәм немец эпосы әсәрләре нык кына аерылып торалар. Хәлбуки, әсәрдә тарих вакыйгаларының барышы ничек кенә үзгәртелсә дә, немец халкы әлеге поэманы чын тарихның реаль гәүдәләнеше дип кабул иткән. Поэманың төп мәгънәсе дә әнә шунда. Әсәрдә төрле дәүләтләр язмышы аерым хөкемдарлар кичергән хәлләр-фажигаләр аша чагыла: король Гунтерның энеләре белән бергә үтерелүе—Бургунд корольлегенең юкка чыгуы дигән сүз. Европа һун державасының язмышы исә тулысынча Атилла (Этцель) образында гәүдәләнә. Һәм бу—урта гасырлар эпосының уртак сыйфаты. Әсәрне махсус тикшергән галимнәр фикеренчә, әсәр 1200 еллар тирәсендә Дунай буйларында барлыкка килгән. Анда Этцель дәүләтенең үзәге хәзерге Венгриядә булуы да әйтеп үтелә. Күләм ягыннан поэма шактый зур—9316 шигъри юл тәшкил итә. Шуның баш өлешендәге 1568 елда һуннар һәм аларның юлбашчысы Этцель хакында бер сүз дә юк. Икенче төрле әйткәндә, «Нибелунглар турында жыр»да ике мөстәкыйль сюжет (ә бәлки борынгырак чорларда ике мөстәкыйль әсәр) берләштерелгән: аларның беренчесендә сүз Зигфридның үлеме турында барса, икенчесендә бургунд династиясенең һәлак булуы тасвирлана. Сүзне әсәрнең идея эчтәлегенә күчергәнче, «нибелунг» атамасының мәгънәсен ачыклап китү зарур. Әсәрнең беренче өлешендә нибелунглар—төньяктагы хәзинәләрне саклаучы әкияти затлар һәм Зигфрид кул астындагы батырлар; икенчесендә—бургундлар. Сүз аңлаешлырак булсын өчен, әлеге бүлекләрнең эчтәлегенә дә тукталып үтәргә кирәк: бургундларның король сараена данлыклы нидерланд батыры Зигфрид килеп төшә һәм корольләрнең сеңлесе Кримхильдага гашыйк була. Король Гунтер үзе исланд королевасы Брюхильдага өйләнмәкче икән. Зигфрид аңа ярдәм итәргә әзерләнә. Әмма бу ярдәм турыдан-туры алдауга нигезләнә: әлеге никах уңышлы булсын өчен, Гунтер ниндидер батырлык күрсәтергә тиеш. Тик бу батырлыкны Гунтер урынына, кешегә күрсәтми торган плащ киеп, Зигфрид башкарып чыга. Брюнхильда Зигфридның батырлыкларын игътибарсыз калдырмаска тырыша. Тик аны бу фикереннән кире кайтырга үгетлиләр: янәсе: Зигфрид үзе бит Гунтерның вассалы гына! Менә шул нәрсә Брюнхильданың йөрәгенә тия: ничек инде аның сеңлесе—король кызы Кримхильда—король улына түгел, бары тик аның вассалына гына кияүгә чыккан? Шулай итеп, еллар уза. Брюнхильданың тәкъдиме буенча Гунтер Зигфрид белән Кримхильданы башкалага—Вормс шәһәренә кунакка чакыра. Нәкъ әнә шунда инде Гунтерның туенда булган алдау ачыла да: туй вакытында кешегә күрсәтми торган плащ ярдәмендә пәһлеван кыз Брюнхильданы жиңгән Зигфрид сиздермичә генә яшь киленнең йөзеген һәм билбауын алган икән. Нигәдер саксызлык күрсәтеп, ул әлеге кыйммәтле, билгеле бер дәрәжәдә тылсымлы әйберләрне үзенең хатыны Кримхильдага бүләк иткән. Еллар узып, әлеге хатыннар яңадан Вормс шәһәрендә очрашкач, алар арасында талаш кузгала: кемнең ире көчлерәк, кыюрак, гомумән—өстенрәк. Ачуы купкан Кримхилда үзенең апасына анардан Зигфрид алган йөзек белән билбауны күрсәтә: шуның белән көч-куәт ягыннан Зигфридның король Гунтердан өстен торуы ачыклана. Хәзер инде Брюнхильда кайчандыр аны—жиңелмәс пәһлеван кызны үзенә буйсындырып, Гунтерга бүләк иткән Зигфридтан үч алмакчы була. Гунтерның вассалы—коточкыч зур көчкә ия булган Хаген—ау вакытында, алдап, Зигфридны үтерә. Шуның белән дастанның зур булмаган беренче өлеше тәмамлана. Әнә шуннан соң инде

сүз һуннар һәм Атилла-Этцель урдасына күчә. Әле сөйләнгән вакыйгалардан соң унөч ел вакыт узган. Өзелеп яраткан гүзәл хатыны Хельха бу дөньядан китеп, Этцель тол калган. Ул янадан өйләнергә дип үзенә иш эзли. Шушы уңайдан биредә Атилла-Этцельнең немец эпосында ничек сурәтләнүен гомуми планда ачыклап үтәргә кирәк. Чөнки бу жырда аны сурәтләү Европа халыкларының башка әсәрләрендәге сурәтләүдән тамырдан аерылып тора. Барыннан да элек махсус шуны әйтеп үтик: «Нибелунглар турында жыр»дагы Этцель Европадагы иң зур державаның хужасы. Аның кул астында—12 корольлек. Анда мәжүсиләр дә, христианнар да, урыс, грек, валах, поляк, бәжәнәк һ. б. халыклар да яши. Шуңа карамастан, ә бәлки нәкъ шуңа күрәдер, герман-немец халкының зур күләмле жырында Этцель баштан ахырга хәтле тик уңай герой буларак кына күрсәтелә. Аның хакында поэмада бер генә тискәре сүз дә юк. Күрше илләрдәге, бигрәк тә бургундларның корольләре һәм аларның вассаллары арасындагы туктаусыз ызгыш-талаш, шактый югары социаль баскычта торган якын туганнарның бер-берсен алдавы, бер-берсенә хыянәт кылуы, үч алуы, хәтта ерткычларча үтерешүгә кадәр барып житүе фонында Этцель илендәге тәртип, тынычлык, бер-береңне ихтирам итү, һәрвакыт гаделлекне саклау әхлакый-мораль яктан һун жәмгыятенең бургунд корольлегеннән күп өстен торуын раслый. Һун жәмгыятенең тагын бер уңай ягы—анда ил башында торган Этцельдән өстен бер генә кеше дә юк; анда Этцель хакимияте, абруе һәм сүзе һичкем тарафыннан кире кагыла алмый. Шуңа күрә Һуннар һәм Этцель биләгән илләрдә нинди дер жәнжал, ызгыш-талаш, үзара көрәш юк һәм була да алмый. Моны Этцельнең кыюлыгы, батырлыгы, һәр мәсьәләне гадел хәл итүе, бер сүз белән әйткәндә—чиксез абруе «рөхсәт итми». Бу хакта поэмада кат-кат һәм ассызыклап әйтелә. Поэма авторын Этцельнең бургунд корольләреннән һәряклап күп өстен торуы һич тә борчымый. Моны ул табигый күренеш дип саный: әсәрдә Этцель йөзендә идеаль, һәр яктан булган хөкемдар образы гәүдәләнә. Бу хәл—поэманың сюжетында, анда сурәтләнгән вакыйгаларда аеруча ачык күренә: үзенә иш эзләгән Этцельгә Бургунд илендә, танылган батыр Зигфрид хыянәтчел төстә үтерелгәч, тол калган искиткеч гүзәл, акыллы, чиксез бай Кримхильданың булуы турында хәбәр итәләр. Шушы уңайдан әсәрдә бургундларның гаять бай булуы, һуннарны һәм аларның хөкемдары Этцельне күптән белүләре, тирән ихтирам итүләре турында махсус әйтеп кителә. Башта Кримхильдага өйләнергә риза булса да, Этцельнең күңелен бер нәрсә борчый: христиан динендәге Кримхильда аңа—мәжүси Этцельгә кияүгә чыгарга риза булырмы? Поэмада Кримхильда күңелендә дә шундый ук шик туу турында да әйтелә. Тик шулай да Этцель якыннарының киңәшен тотып, Вормс шәһәрендә яшәүче Кримхильдага махсус кодалар илчелеге жибәрә. Кримхильда башта шактый кискен каршылык күрсәтә: беренчедән, аның кайчандыр өзелеп яраткан ире Зигфрид истәлегенә хыянәт кыласы килмәсә, икенчедән—аны булачак ир белән хатынның ике диндә торуы борчый. Шулай да Кримхильданы, Этцельнең бик тә кыю, батыр, куркусыз яугир булуын, һун иленә күчкәч, аның хакимият һәм байлык иясе—һичшиксез, бәхетле хатын булачагын әйтеп, күндерәләр. Әмма ләкин булачак ир белән хатынның максатлары бөтенләй капма-каршы. Әгәр Этцель киләчәктә матур гаилә кору өчен өйләнергә жыенса, Кримхильданың төп максаты—Этцельгә кияүгә чыгып, аның жинелү белмәгән яугирләре ярдәмендә үз туганнарыннан, беренче чиратта кайчандыр аның ире Зигфридне үтергән Хагеннан үч алу, аны юк итү. Шул рәвешчә, әсәрдә ике жәмгыять бер-берсенә кискен каршы куела: Этцельдә һәм һуннарда—киләчәктә матур гаилә кору кебек изге теләк; Кримхильдада—якын туганнарыннан үч алу. Гомумән, «Нибелунглар турында жыр»да үч алу, хыянәт кылу, күзгә карап алдау кебек мотивлар шактый зур урын били. Тик һәр очракта да алар Һун жәмгыятенә түгел, ә бургундларга карый. Әмма нинди генә каршылыклар булса да, Этцель Кримхильдага өйләнә. Һәм әлегә кадәр бәхетсез булган бу хатын чыннан да зур бәхеткә ирешә һәм үзен ожмахтагыдай хис итә башлый. Алар бер-берсен чын күңелдән яраталар. Этцель хатынының бер генә теләгенә дә каршы килми: аның өчен иң мөһиме—Кримхильданы ул үзенең беренче хатыны Хельханы яраткан кебек үк ярата. Ә бит элегрәк Этцель Хельха кебек акыллы һәм гүзәл хатынны беркем дә алмаштыра алмас дип борчылган була. Кримхильда да үзен янадан тугандай хис итә башлый. Житмәсә, ул Этцельнең дәүләт эшләрендә дә турыдан-туры катнаша. Борыңгы Шәрекъ илләреннән килгән традицияләрне дәвам итеп, алар ил эшләрен бергәләп хәл итәләр. Икенче төрле

әйткәндә, Этцель Европа илләренә Борынгы Шәрекънең гүзәл традицияләрен дә алып килә. Шул рәвешчә, Этцель белән Кримхильда, бәхетле гаилә корып, искиткеч матур һәм бай илдә 13 ел бергә яшиләр. Һәм бу матур тормыш шулай ук дәвам итә алган да булыр иде. Искәртелгәнчә, Этцельгә кияүгә чыккач, Кримхильда ифрат зур көчкә һәм хакимияткә ия була. Күпме еллар узса да, ул үзенең баштагы ниятен һәм максатын һич онытмый: менә хәзер ул инде үзенең туганнарыннан һәм Хагеннан үч алырга тиеш!.. Әмма ачык яу кырында түгел, ә бәлки алдау, хыянәт юлы белән. Күзәтелә торган бу жырның төп максатларыннан берсе— һуннар һәм бургундлар җәмгыятен бер-берсенә кискен каршы кую. Һәм һәр очракта да һуннарны чиксез мактап, бургундларны фаш итү... Әлеге мәкерле ниятен тормышка ашыру өчен Кримхильда 13 елдан соң үзенең ин якын туганнарын кунакка чакырмакчы була һәм Этцельдән рөхсәт сорый. Этцель каршы килми, әлбәттә, ничек инде ул үз хатынының туганнарын кунакка чакыру кебек изге теләгенә каршы килә алсын?! Ул бит Кримхильданың мәкерен белми. Шушы унайдан жырда Этцельнең бик тә гади, бер катлы кеше булуы, хәйлә һәм мәкерне күз алдына да китерә алмавы, гомумән, аның гаделлек һәм яхшылык гәүдәләнеше булуы турында кат-кат әйтеп үтелә. Әсәрдәге вакыйгалар барышы да шуны раслый. Бургундлар да Кримхильданың кунакка чакыруын яхшы кабул итәләр: алар да бу хатынның явыз максатын аңламыйлар. Бары тик үзе дә мәкер капчыгы булган Хаген гына Кримхильданың чын ниятен шунда ук аңлап ала һәм кунакка баруга кискен каршы чыга. Ләкин аны беркем дә тыңламый. Хаген туганнары белән юлга җыена: әмма туй-тантанага түгел, ә сугышка!.. Чөнки хәзер Кримхильда яшәгән һун илендә чын мәгънәсендәге канкойгыч сугыш буласын ул бик яхшы аңлый. Тик беркатлы һәм киң күнелле Этцель генә бу хакта берни белми, әгәр белсә, жырда әйтелгәнчә, бөтен Европаны калтыратып торган Этцель әлеге сугыш-бәрелешләрне туктаткан булыр иде. Этцельнең бу җәнҗалларга бернинди мөнәсәбәте юк: ул алардан күп өстен тора! Әлеге вакыйгаларга ул катнашмый да! Биредә әсәрдә чагылыш тапкан кайбер саф мифологик мотивлар турында да берничә сүз әйтеп үтәргә кирәк. Юлда ике әкияти изге кош-кызлар Хагенны һуннар илендә һәлак булачаклары турында кисәтәләр. Икенчедән, поэмада нибелунгларның (әсәрнең икенче өлешендә бургундлар шулай атала) Дунайны нинди зур авырлыклар, югалтулар белән кичүе турында тәфсилләп сөйләнә. Борынгы мифологик күзаллауларда билгеле булганча, су, елга—бу һәм теге дөньялар чиге. Елганы кичеп чыгу—димәк, икенче бер дөньяга күчү. Көч-хәл белән Дунайны кичкән нибелунглар язмышы шулай булып чыга да: һун илендә, Кримхильда тарафыннан оештырылган каты сугыш нәтиҗәсендә аларның барысы да һәлак була. Һәм гаять тә мөһиме—әлеге сугыш-орышларда һуннарның барысы Кримхильданы яклыйлар, ана берсүзсез буйсыналар. Чөнки ул—аларның хөкемдары Этцельнең хатыны. Бәлки Этцель бәрелеш-орышлар беткәнче аларда катнашмаган да булыр иде. Тик нибелунглар сугыш дәвамында Этцельнең абыйсы Бледельне (тарихи Бледа) һәм, иң кызганычы, корольнең бердәнбер варисы—улы Ортлибны үтерәләр. Бу явызлыкны да Хаген башкара. Әнә шуннан соң инде сугышка Этцель үзе дә катнашып китә. Күргәнебезчә, моның берничә җитди сәбәбе бар: беренчедән, ул яраткан хатыны Кримхильданы яклый; икенчедән, туган абыйсы Бледельнең ерткычларча үтерелүе һәм, өченчедән, бердәнбер варисы, сөекле улы Ортлиб өчен нибелунглардан үч алу. Хәзер, орышка инде Этцель үзе дә катнаша башлагач, нибелунгларның һәлак булачагы көн кебек ачык. Тик төп йөкне әле һаман да Кримхильда күтәреп бара: Һуннар белән Хаген аның кулына эләгәләр. Ул үзенең туган абыйсы Һуннарның башын кисәргә боера; Хагенны исә үз кулы белән үтерә. Әмма король Дитрих Бернскийның дружиннигы Кримхильданы да һәлак итә. Шулай итеп, бургунд-нибелунгларның барысы да һәлак була. Димәк, чын тарихта 437 елда булган конкрет вакыйгалар поэмада тулы һәм төгәл чагылыш таба. Тик «Нибелунглар турындагы жыр»ның тагын бер мөһим үзенчәлегенә игътибар итми мөмкин түгел: шул ук чор вакыйгаларына багышланган башка күп санлы әсәрләрдә ахырда Атли-Атилла да һәлак була. Биредә исә ул, өзелеп яраткан хатыны Кримхильда, бердәнбер улы Ортлиб, көрәштәше һәм абыйсы Бледель үтерелү нәтиҗәсендә бетмәс кайгыга батса да, үзе исән кала. Димәк, Этцель үзе дә, һуннар иле дә яшәвендә дәвам итә!

*Ахыры киләсе санда.*



Qərʹən tatar telendə
Коръән татар телендә

# 27—НӘМЕЛ (КЫРМЫСКА) СҮРӘСЕ

**Нәмел сүрәсе 93 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Нәмел—кырмыска дигән сүз. 18 нче аятьтә кырмыскалар турында сөйләнгәнгә күрә, сүрәгә шушы исем бирелгән.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Та. Син. Болар Коръәннең, *(яхшы белән яманны)* ап-ачык аерып бирүче Китапның аятьләредер. **(2)** Мөэминнәр өчен тугры юл күрсәтүче һәм сөенеч хәбәре китерүчедер.

**3.** Намазны дөрес укыганнар, зәкят бирүчеләр—чын мөселмандыр. Алар—Ахирәт көненә дә чын күңелдән инанган кешеләр. **(4)** Ахирәт көненә ышанмаганнарның яман эшләрен Без яхшы итеп күрсәттек *(алар яхшы эш кылабыз, дип уйлыйлар)*. Ләкин аларның күңел күзләре сукыр килеш кала. **(5)** Алар шундый кешеләрдер ки, алар хәтәр җәзага мәхкүм. Алар—Ахирәттә дә иң күп зыянга дучар ителгән кешеләрдер. **(6)** Шик юк ки, Коръән сиңа һәрнәрсәнең асылын белүче, бердәнбер, хикмәт иясе тарафыннан бирелде.

**7.** Исегездәме, ничек итеп Муса гаиләсенә:

—Мин ут күрдем. Анда барып юл сораштырыйм яки утлы кисәү алып килим, җылынырсыз,—диде. **(8)** Анда баргач, бер аваз ишетелде:

—Ут янындагы *(Муса)*, әйләнә-тирәдәге *(фәрештә)*ләр мөбарәк кылынды *(аларга бәрәкәт бирелде)*.—Галәмнәрнең Раббысы Аллаһ *(камил)* һич кимчелексез. **(9)**—Әй, Муса, Хакыйкать—Мин ул, һәрвакыт җиңүче, бердәнбер хөкем вә хикмәт иясе Аллаһ. **(10)**

—Карышкыңны ташла!—диде Аллаһ. *(Муса таягын ташлады)* ул шундук еланга әверелде, аны күреп *(Муса)* артына борылып карамыйча, кача башлады.

—Әй, Муса, курыкма. Мин монда гына. Мин булганда пәйгамбәр берничдән дә курыкмас,—дигән тавыш ишетелде.

**11.** Әгәр дә берәрсе яманлык кылганнан соң (тәүбә итеп) игелек кылса, һичшиксез, Мин аны ярлыкармын һәм ана чиксез мәрхәмәтле булырмын.

**12.** Кулыңны куеныңа тык та, Фиргәвенгә вә токымына тугыз могҗизаның берсен күрсәт: *(кулың)* һич зыян күрмичә, *(күз явын алырдай)* ап-ак булып *(нур чәчеп)* күренер. Шик юк ки, алар азгын халык булып чыкты.

**13.** Аятьләребез ап-ачык булып килгәч, алар:

—Бу, һичшиксез, бер күз буу-сихер генә,—диделәр.

**14.** Гәрчә алар эчтән генә аятьләрнең дөрес икәненә ышансалар да, тәкәбберлекләре һәм кирелекләре аркасында, телләре белән инкарь иттеләр. Бакчы, бозыклык таратучыларның ахыры ни белән бетте!

**15.** Хактыр ки, без Даутка һәм *(аның улы)* Сөләйманга гыйлем бирдек. Алар әйтте:

—Безне мөэмин колларының күбесеннән өстен кылган Аллаһка мактаулар булсын,—диделәр.

**16.** Сөләйман Даутның варисы булды. Әйтте:

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде

—Әй, кешеләр, безгә кошлар теле өйрәтелде. Безгә бар нәрсәдән дә өлеш чыгарылды. Шик юк ки, бу Аллаһ Тәгаләнең безгә булган аеруча мәрхәмәте һәм юмартлыгы,—диде.

**17.** Сөләйман янында җеннәрдән, кешеләрдән, кошлардан торган гаскәр тупланды. Боларның барысы да *(аның тарафыннан)* идарә ителә иде. **(18)** Кырмыскалар күп булган үзәнгә килеп чыккач, бер кырмыска әйтте:

—Әй, кырмыскалар, оягызга кереп качыгыз. Сак булыгыз, Сөләйман гаскәрләре, үзләре дә белмәстән, сезне таптап-сытып китмәсен,—диде.

*(«Нужно отметить, что выражение вади-л-намл нельзя перевести как «долина муравьев», ибо «Намл»—это имя собственное; согласно Т(см. корень вади), долина Намл расположено между Джибрином и Аскаланом. Намлах—это название племени...»*
Мөхәммәд Али тәфсиреннән.)

**19.** *(Кырмыска әйткәннәрне ишеткәч)* Сөләйман гаҗәпсенде һәм елмайды да әйтте:

—Йа, Раббым,—диде.—Үземә һәм атам-анама биргән нигъмәтләреңә шөкер итәргә һәм Синең ризалыгыңны алырдай игелекләр кылырга миңа форсат бир. Рәхмәтең илә миңа да *(җәннәттә)* башка тугры колларың белән рәттән урын бир,—диде.

**20.** Ул *(Сөләйман)* кошларны күздән кичергәч:

—Ни өчендер һөдһөдне күрмимен. Әллә ул югалып калдымы?—диде. **(21)**—Һәрхәлдә мин аңа каты җәза бирәчәкмен яки аның башын чаптырачакмын, әгәр дә ул ни өчен килмәгәнен акларлык ачык дәлил китермәсә.

**22.** Озак та узмастан, һөдһөд килеп житте һәм әйтте:

—Мин син белмәгән нәрсәне беләмен,—диде.—Сәбәдән мин сиңа бик тә мөһим бер хәбәр китердем; **(23)** хактыр ки, мин анда патшалык итә торган бер хатынны очраттым. Аның бөтен нәрсәсе бар. Ул бик зур тәхеткә ия; **(24)** алар Аллаһ урынына Кояшка табына торган халык. Яман гамәлләрен матур күрсәтеп, шайтан аларны юлданяздырган. Шунлыктан алар тугры юлны тапмый; **(25)** күкләрдә һәм Җирдәге ачык һәм яшерен нәрсәләрнең бөтенесен белеп торучы Аллаһка алар сәҗдә итми; **(26)** бөек Гарешнең хуҗасы, Үзеннән башка һичбер тиңе булмаган Аллаһ—бердәнбер Илаһ *(дип танымый)*.

**27.** Сөләйман әйтте:

—Карап карыйк, син дөресен сөйләдеңме, әллә ялганладыңмы?—диде. **(28)**—Син шушы хатны алып кит, аларга тапшыр. Бераз вакыт җавап көт. Ничек җавап бирерләр икән?

**29.** *(Хатны алгач, патшабикә якыннарына)* әйтте:

—Әй, яраннарым, хактыр ки, миңа бик тә әһәмиятле бер хат килеп төште; **(30)** ул хат Сөләйманнан һәм ул рәхимле, мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән: бисмилләһир-рахмәнир-рахим, дип башлана: **(31)** «Миңа каршы баш калкытмагыз. Баш орып, яныма килегез,» диелгән. **(32)** Патшабикә:

—Әй, киңәшчеләрем,—диде.—Фикерләрегезне миңа җиткерегез. Сездән башка бу мәсьәләне үземә генә чишүе бик кыен булыр.

**33.** Әйттеләр:

—Без—көч-куәт иясе, каты сугыш өчен яралтылган. Әмер—синнәндер, үтәү—бездәндер. *(Нинди әмер бирү Синең ихтыярыңда.)*—диделәр.

**34.**—Хактыр ки, патшалар берәр илгә басып керсә, шул илне туздырып ташлый. Шул халыкның абруйлы адәмнәрен хур итеп, мәсхәрәгә калдыралар. Болар да безне шулай итәчәк; **(35)** мин аларга берәр бүләк юллыймын, илчеләрем нинди җавап алып кайтыр, карап багыйк.

**36.** Илче килеп җиткәч, Сөләйман әйтте:

—Сез мал биреп миннән котылмак буласызмыни? Аллаһның миңа биргән нигъмәтләре, сезгә Аллаһ биргән ул бүләгегездән хәерлерәк. Сез шул бүләкләрегез белән горурланасызмы? **(37)** Кире кайт*(ып әйт)*, һичшиксез, җиңелмәс гаскәрем белән мин сезгә яу чабам, аларны хур итеп, пыран-заран китереп кайтып китәчәкмен. **(38)** Һәм тагын әйтте:

—Әй, олуг киңәшчеләрем, алар миңа баш орып килгәнгә чаклы, кайсыгыз шул тәхетне миңа алып кайта ала?—диде.

**39.** Җеннәр арасындагы бер гыйфрит шикеллесе:

—Син урыныңнан калыкканчы ук, мин аны сиңа алып кайтырмын. Бу эшне башкарырга куәтем җитәрлек,—диде.

**40.** Китап укып белем алган берәү:

—Күз ачып йомганчы мин *(ул тәхетне)* сиңа алып кайтырмын,—диде. Һәм ул *(Сөләйман)* аны *(тәхетне)* алдында күрде дә әйтте:

—Бу Раббымның мине сынап каравыдыр, мөгаен: шөкер итәчәкме мин, әллә шөкер итүдән баш тартачакмынмы, дип.

Шөкер итү кешенең үз файдасына булыр. Кем шөкер итми, *(үзенә зыян)*, хактыр ки, Аллаһ аның шөкеренә мохтаҗ түгел. Чөнки Аллаһ Үзе байлыкка хуҗа.

**41.** Әйтте:

—Бу тәхетне ул танымаслык итеп үзгәртегез,—диде.—Күрербез, ул аны танырмы, юкмы? Дөрес юлдамы бу патшабикә, әллә кыек юлдамы? **(42)** Ханым килгәч, сорадылар:

—Бу синең тәхетеңме?—диделәр. Хатын әйтте:

—Әйе, шул бугай,—диде. *(Сөләйман әйтте):*

—Моннан элек безгә *(Аллаһ)* белем бирде һәм без мөселман булдык.

**43.** Аллаһны инкарь итеп, табына торганнары *(Кояш)* Исламны кабул итәргә комачаулык иткән. Чөнки ул хатын кяферләр токымыннан иде.

**44.** Аңа *(патшабикәгә)* әйттеләр:

—Сарайга кер,—диделәр. *(Астына су җибәрелгән бәллүр-пыяла идәнгә басар алдыннан)* тирән суга керәм дип, патшабикә итәген күтәрә төште, аның матур балтырлары күренде. *(Сөләйман)* әйтте:

—Бу бәллүрдән түшәп салынган идәндер,—диде. Бикә әйтте:

—Йа, Раббым, чыннан да, мин оятлы булдым, гөнаһ кылган хатын булып чыктым түгелме? Галәмнәрнең Раббысы булган бер Аллаһка Сөләйман белән бергә иман китереп, мөселман булдым,—диде.

*(«Кояшка табына торган бу гүзәл патшабикәнең исеме Бәлкыйс иде. Аның балтырлары төк белән капланган, дигән хәбәр таралган була. Имеш, ул йонлы аякларын кешеләрдән генә түгел, Кояштан да яшерә икән. Шушы гайбәтнең дөресме, түгелме икәнен беләсе килепме, күрсәтергә харам аякны күреп кенә Кояшның Бәлкыйскә һичбер тәэсире булмаячагын исбат итәргә теләпме, Сөләйман падиша ачык түбәле, утә күренмәле, бәллүр идәнле сарай кордырып, бәллүр астына су тутырта, балыклар җибәрә. Бәлкыйс алдана, затлы киемен чылатмас өчен, ул итәген күтәрә төшә: аның тәне һәм Кояшка, һәм Сөләйманга күренә. Әмма шунысы ачыклана ки, патшабикәнең балтырлары йонлы түгел, гаҗәеп матур икән. Күргәнегезчә, патшабикә Аллаһка иман китерә».*

Хәсән Чантай белән Шәех Ногмани тәфсиреннән.)

**45.** Хактыр ки, Без Салихны үз халкы Сәмудка күндердек:

—Аллаһка гыйбадәт кылыгыз,—дип кардәшләрен өндәсен өчен. Ләкин алар ике фиркага аерылып, талашып беттеләр.

*(«Бер фирка Аллаһка иман китерде. Икенчесе кяфер булып кала бирде. Аларның һәр икесе дә: безнең дин—хак дин, ди».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**46.** Салих аларга әйтте:

—Әй, кардәшләрем, ни өчен сез игелек кыласы урында яманлык кылырга ашкынасыз? Аллаһтан ярлыкау сорасагыз яхшырак булмасмы икән? Бәлки, ул сезгә мәрхәмәтле булыр,—диде.

**47.** Алар әйтте:

—Синең аркаңда һәм сиңа ияргәннәр аркасында өстебезгә афәт (ачлык) килде,—диделәр. Салих:

—Сезнең гамәлләрегез Аллаһтан яшерен түгел. Бәлки, сез сынауга дучар ителгән нәселдер,—диде.

**48.** Бу шәһәрдә тугыз ир кеше *(тугыз явыз төркем)* бар иде. Болар тирә-якка бозыклык таратучы *(башлыкларның балалары)* иде. Алар игелек кылу турында уйлап та карамадылар.

**49.** Алар үзара Аллаһ исеме белән ант иттеләр:

—Ана *(Салихка)* вә якыннарына төнлә һөҗүм итәбез *(кырып чыгабыз)*. Аннан соң кан үчен алучыларга әйтербез:

—Валлаһи, дөресен сөйлибез, без аның гаиләсенең һәлакәтен күрмәдек, белмибез,—диярбез.

**50.** Шулай итеп, алар тозак корды. Без дә сиздерми генә алар уйлаганның астын өскә китереп ташладык. **(51)** Әнә кара, алар корган тозакның нәтиҗәсе ничек булганын. Без аларны *(таш яудырып)* нәселләре белән һәлак иттек. **(52)** Менә, гаделсез золымнары аркасында аларның йортыннан хәрабәләр генә калды. Хактыр ки, аңлаган халыклар өчен монда гыйбрәт бар. **(53)** Иман китереп, *(гөнаһлардан)* сакланганнарны Без коткарабыз.

**54.** Лутка да *(пәйгамбәрлек)* бирдек. Ул халкына әйтте:

—Сез белгән көе, яманлык кыласызмы *(егетләрне хатын сыйфатында кулланасызмы)*?—диде. **(55)** Хатыннарыгызны *(нәүмиз)* калдырып, шәһвәти ихтыяҗларыгыз өчен ирләр янына йөрисез. Хәер, сез ни кылганыгызны белмичә, бозыклыкның аргы ягына чыккан кавем. **(56)** Халыкның җавабы шул булды:

—Лут токымын ватаныгыздан куып җибәрегез. Чөнки алар—сафлыкларын сакларга тырышучы нәсел,—диделәр.

**57.** Шуннан соң Без аның үзен дә, нәселен дә коткардык, фәкать алдан ук һәлакәткә дучар ителгән хатынынннан башка. **(58)** Аларның өстенә шундый бер *(утлы күкертләр, ташлар катнашкан)* яңгыр яудырдык. Үгетләп тә, гыйбрәт алмаганнар өчен бик тә хәтәр иде ул яңгыр.

**59.** Әйт:

—Аллаһка булсын мактаулар. Аның якын иткән бәндәләренә *(нәбиләргә, рәсүлләргә)* сәламнәр булсын. Илаһ булыр өчен Аллаһ хәерлерәкме, әллә аларның Ана тиңләштергән нәмәстәләреме?—диген. **(60)**—Әллә күкләрне вә Җирне яраткан, Күктән сезнең өчен яңгырлар яудырган хәерлерәкме? Шул су белән сугарып, Без агачларын корытмыйча, нинди гүзәл бакчаларда үсемлек-җимешләр яраттык. Аллаһка тиң башка берәр илаһ бармы әллә? Юк, әлбәттә, алар кыек юлдан киткән халыктыр.

**61.** Әллә Җирне тотрыклы итеп яраткан, араларыннан елгалар агызган, биек таулар корган, ике диңгез арасына пәрдә куйган хәерлерәкме? Аллаһка тиң башка берәр илаһ бармы әллә? Юк! Ләкин аларның күбесе *(Хакны)* белми.

**62.** Кыен вакытында Үзенә дога кылган кешегә ярдәм итүчеме яисә афәтләрне кире кайтарган, сезне Җир өстендә хаким кылган хәерлерәкме? Аллаһка тиң башка берәр илаһ бармы әллә? Сез бик аз уйлый торган кавем.

**63.** Яки коры җирдә һәм диңгезләрдә караңгы төннәрдә сезгә юл күрсәткән, юмартлыгы *(яңгыр)* алдыннан сөенеч китерүче җилләрне истергән хәерлерәкме? Аллаһка тиң башка бер илаһ бармы әллә? Алар табынганнардан Аллаһ чиксез бөек һәм пакьтер. **(64)** Әллә башта яралтып та, соңыннан юкка чыгарганмы, сезне Күктән һәм Җирдән ризыкландырганмы хәерлерәк? Аллаһтан башка Ана тиң берәү бармы? Әйт син:

—Әгәр сез хаклы икән, сүзегезгә исбат китерегез,—диген.

**65.** Әйт:

—Күкләрдә һәм Җирдә яшерелгән серләрне Аллаһтан башка кем белер? *(Фәрештәләр дә, кешеләр дә, пәйгамбәрләр дә белми.)* Алар да Кыямәтнең *(яңадан терелүнең)* кайчан булачагын белмәс,—диген.

**66.** Юк, аларның белеме Ахирәтне ачыклый алмый, алар бу турыда шик-шөбһә кичерәдер. Юк! Аларның күңел күзе сукыр. **(67)** Инкарь итеп, кяфер булганнар әйтте:

—Без дә, вафат булган аталарыбыз да туфрак булгачтын, чынлап та, *(яңадан терелеп, каберләрдән)* чыгарылачакбызмы? *(Без моңа ышанмыйбыз!)*; **(68)** хактыр ки, бу турыда моннан алда аталарыбызга да сөйләгәннәр иде инде. Бу борынгылар уйлап чыгарган әкияттән башка нәрсә түгел.

**69.** Әйт:

—Дөнья буйлап сәяхәт итегез, гөнаһкярларның ахыры ни белән беткәнен күрерсез,—диген. **(70)** *(Ий, Мөхәммәд)* син алар *(иман китермәгәннәр, сиңа иярмәгәннәр)* өчен кайгырма. Алар корган мәкерләр өчен дә борчылма. **(71)** Алар:

—Бу вәгъдә ителгән газаплар кайчан килер? Әгәр сез дөрес сөйлисез икән *(әйтегез)*,—диләр. **(72)** Әйт:

—Сез тиз килсен дип теләгән җәзаның бер өлеше озакламый киләчәк,—диген.

**73.** Шик юк ки, чыннан да, синең Раббың кешеләргә бик тә миһербанлы. Ләкин аларның күбесе шөкер итми. **(74)** Синең Раббың аларның күңелләренә яшерелгән серләрне дә, ачык гамәлләрен дә тулысы белән белеп торучы. **(75)** Җирдә һәм Күктә яшерелгән серләрнең барысы да ачык рәвештә китапка *(Ләүхел Махфүзгә)* язылган. **(76)** Шик юк ки, бу Коръән—Исраил угылларына бәхәс-гауга куптарган нәрсәләрнең күбесен аңлатып бирә торган Китап. **(77)** Хакыйкатән, ул тугры юлга өндәүче һәм мөэминнәр өчен бер рәхмәттер.

**78.** Хактыр ки, синең Раббың алар арасындагы бәхәсне тугры хөкемгә китерәчәктер. Ул—һәрчак җиңүче, дөресен белүче.

**79.** Бәс, син Аллаһка инанып сыен. Чөнки син ап-ачык бер Хакыйкать янындасың. **(80)** Чыннан да, син *(күңелләре)* үлеләргә *(вәгазьләреңне)* ишеттерә алмассың, арка тарафка борылып, колаклары ишетмәс дәрәҗәдә саңгырау булып, качып баручыларны да иманга чакыра алмассың. **(81)** Һәм син *(күңел күзләре)* сукырларны да адашкан юлларыннан аерып, тугры юлга күндерә алмассың. Син аятьләребезгә иман китерәчәк кешеләргә генә сүз тыңлата алачаксың. Менә шулар инде чын мөселман булыр. **(82)** Вәгъдә ителгән Көн килгәч, *(Кыяматтә)*, алар өстенә җир астыннан бер Даббәне *(дип аталган куркыныч затны)* чыгарачакмын. Ул кешеләрнең аятьләребезгә чын күңелдән инанмаганнары турында сөйләр.

**83.** Ул Көнне һәр өммәтнең аятьләребезне ялганга чыгаручыларын бергә җыйнарбыз. Һәм алар *(җәза өчен)* кулга алыначаклар.

**84.** Ниһаять, алар *(хисап җиренә)* килеп житкәч, *(Аллаһ)* боерыр:

—Минем аятьләремне, аларның яхшымы, яхшы түгелме икәнен уйлап тормастан, ялганга чыгаручылар сезме? Ни кылганыгызны аңлатып бирегезче.

**85.** Гаделсез җәберләр кылганнары аркасында Сүз гамәлгә кергәч, *(аларга үзләре казанган җәзага әмер бирелгәч)* алар телдән калыр.

**86.** Истирахәт кылыр өчен төнне, яктылык өчен көнне Без яралтканны күрмәделәрме? Монда иман китергәннәр өчен, әлбәттә, гыйбрәтләр бар.

**87.** Сурга өрелгән Көнне, Аллаһның Үзе теләгәннәрдән башкасы, күкләрдә вә Җирдә булганнарның барысы да гарасатка дучар ителер. Аларның барысы да түбәнчелек белән баш иеп, Аның хозурына килеп басачаклар.

**88.** Син тауларның үз урыннарында торганнарын күрермен дип уйлыйсыңмы? Алар болыт күчкән кеби күчеп китәр. Бу бар нәрсәне тәртип белән яралткан Аллаһның әмере белән эшләнер. Шик юк ки, Ул сезнең ни кылганыгызның барысын да белеп торучы.

*(«Бу аять Җир шарындагы бар нәрсәнең дә хәрәкәттә булганына ишарә итә, хәтта таулар да күрер күзгә генә мәңгелек кебек күренсә дә, ахырда алар да—хәрәкәттә, үзәннәр—хәрәкәттә. Тора-бара Җирдәге таулар урынында—үзәннәр, иңкүлекләр урынында таулар хасил булачак».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.)

**89.** Игелекләре белән килгән кешегә игелек бирелер. Андыйлар куркынычтан котылыр. **(90)** Яман кылмышлары белән килгән кешеләр йөзтүбән җәһәннәмгә атылыр. Аларга:

—Әй, кылмышларыгызга күрә сезгә бирелгән җәзалар артык гаделсез түгелме бу? Гаделсез җәза түгелдер бит?—дип әйтелер.

**91.** Әйт:

—Мин бары тик гөнаһ эшләүне харам кылган бу шәһәрнең Раббысына гыйбадәт итәргә күндерелдем. Бөтен нәрсәгә Аллаһ хуҗа; һәм мин мөселман булырга боерылдым,—диген. **(92)**—Мина Коръән уку әмер ителде,—диген.—Кем тугры юлдан барса, үз файдасына.

Кем адашса, әйт:

—Мин бары тик *(гөнаһ кылмагыз)* дип кисәтүче генә,—диген. **(93)** Тагын әйт:

—Аллаһка мактаулар булсын,—диген.—Ул әле сезгә әмерләрен житкерәчәк һәм сез дә алар белән танышачаксыз. Раббы сез кылганнарны белми түгел.

*Үткен мәсьәлә*



# Гомәр Саттаров

## И ГАЗИЗ ТЕЛЕМ!

Туган тел—дөньяны танып белү, өйрәнү-төшенү өчен тылсымлы алтын ачкыч, могҗизалы асыл корал—үзара аралашу-аңлашу коралы ул. Туган тел—милләтне милләт иткән, саклаган, яклаган, алгарышка алып барган иң мөһим иҗтимагый фактор, милләт яшәешенең мөкатдәс һәм асыл нигезе. Арабыздан вакытсыз китеп барган мөхтәрәм милләтпәрвәр академигыбыз Әбрар Кәримуллин үзенең «Тел—милләтнең сакчысы» дигән китабында *(Казан, 1997)* бик хаклы язганча: «Кеше һава суламыйча яши алмаган кебек, милләт телсез яши алмый. Телнең зәгыйфьләнә баруы—ул милләтнең юкка чыга баруының күрсәткече. Милләт—ул теле булган халык». Мин, соңгы җөмләне беркадәр аныклый, тулыландыра төшеп, милләт ул—туган теле булган халык, дияр идем. Туган тел—алтын багана, барыбыз өчен дә гомуми һәм уртак милли хәзинә, милләт булып яшәүдә ныклы терәк-таяныч, өмет-ышаныч. Бай-мул җәүһәр-якутлардан гыйбарәт милли хәзинәбез—татар әдәби теле ярдәмендә без—татарлар—үзара аралашабыз, сөйләшәбез, аңлашабыз. Без укыйязабыз, башлангыч, урта, беркадәребез югары белем дә алабыз, әдәпәхлакка, тәрбиягә өйрәнәбез, сәнгатебезне, әдәбиятыбызны, матбугатыбызны, фәнебезне, икътисадыбызны үстерәбез, тәрәккыят итәбез.

Туган телебез татар теле—борынгы һәм һәрьяклап үсеш алган төрки телләрнең берсе. Ул—мул сүзлек хәзинәсенә, чал тарихлы һәм даимән тулыланып-үсеп баручы бай һәм күп жанрлы милли әдәбиятка, фольклорга, мәдәнияткә, сәнгатькә, мәгърифәткә, матбугатка, дәүләтчелек теле булуга ия. Ул шулай ук илчелек-дипломатия теле вазыйфаларын башкаруга, фән теле булуга, күп тармаклы терминологиягә, әдәби телебезне даими баету-тулыландыру өчен мөһим эчке потенциаль чыганак булган катлаулы лексик-грамматик, диалекталь һәм ономастик системаларга ия. Татар теле—һәр әтрафтан гаять бай мираска ия булган тел. Аның үз эчке закончалыклары нигезендә, алга таба үсү-камилләшүе өчен зур потенциаль мөмкинлекләре һәм бай традицияләре бар. Мәгълүм ки, татар теле—ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөньяда халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе, җир йөзендәге 30 дан артык хәзерге төрки телләрдән мондый югары бәягә, күркәм дәрәҗә-мәртәбәгә ия булганнарыннан берддәнбере. Бу исә туган телебез татар теле белән

Гомәр САТТАРОВ *(1932)—филология фәннәре докторы, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, күпсанлы гыйльми китаплар авторы. Казанда яши.*

горурланырлык мөһим фактор, мактанырлык күрсәткеч. Шул телнең күкрәп яшәргә, гөрләп үсәргә, дәүләт теле булырга, туган халкына бар куәт-егәрлегендә хезмәт итәргә хакы-хокукы юкмыни?! Бар, әлбәттә!

Хәзерге вакытта татар халкының, татар теленең, Татарстанда яшәүче барлык башка халыкларның матди һәм рухи тәрәккыятенең нигезендә моннан унике ел элек, 1990 елның 30 августында, Татарстан Республикасының суверенлыгы турында Декларация кабул итү һәм 1994 елның 15 февралендә Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында дәүләтара Килешү-Шартнамә төзелү ята. 1992 елның июлендә «Татарстан халыкларының телләре турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. 1994 елның июлендә бу законны гамәлгә ашыру өчен «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт Программасы» һәм Татарстан халыкларының телләренә караган башка указ-карарларга кул куелды. Республикабызда татар теленә дәүләт теле статусы биреп, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә җиткерү-үстерүдә болар—һичшиксез, гаять мөһим тарихи документлар.

Дәүләт Программасының төп өлешен татар теленең сакланышы һәм үсеше, аны һәрьяклап өйрәнү һәм камилләштерү мәсьәләләре алып тора. Анда татар телендә укыту системасын булдыру, фәнни һәм педагогик кадрлар әзерләү, әдәбият, фән һәм сәнгать, радио һәм телевидение тапшырулары үсешен, татар телендә китаплар, газета-журналлар бастыру, сүзлекләр, дәреслекләр һәм укыту-методик әдәбият чыгаруны тәэмин итүнең конкрет җаваплы оешмалары һәм финанслау чыганаклары билгеләнгән. «Татарстан халыклары телләре турында дәүләт законына һәм программасына нигезләнеп, без, әлбәттә, ана телебезне үстерү өчен барча мөмкинлекләрдән файдаланачакбыз»,—дигән иде мөхтәрәм Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев «Мирас» журналындагы әңгәмәсендә *(«Мирас», № 7-8, 1994, 11 бит)*. Һәрберебезнең күңеленә хуш килерлек сүзләр. Амин, шулай булсачы, дияргә генә кала.

Татарстан халыкларының телләре турында дәүләт Законын һәм Программасын тормышка ашыруда беркадәр уңышларыбыз бар, әлбәттә. Башкалабыз Казанда һәм республикабызның башка шәһәрләрендә татар урта мәктәпләре, гимназияләр, лицейлар, көллиятләр, Казанда Татар гуманитар институтын ачу, татарча газета-журналларның, фәнни һәм әдәби китапларның, мәктәп һәм вуз дәреслекләренең саны ишәю, Татарстан югары уку йортларында факультатив характерда булса да татар теле укытылу, кайбер табигать һәм төгәл фәннәр буенча дәреслек һәм кулланмалар чыгару, студентларга татарча лекцияләр укый башлау, татар телен фән һәм югары уку йортлары теле итәргә омтылыш һ. б. әнә шундыйлардан.

Хәлбуки, бу өлкәләрдә уйланырлык нәрсәләр, хәл итәсе мәсьәләләр күп әле. Шулардан, минем карашымча, иң мөһимнәре: мәктәп-гимназияләрдә татар телен һәм әдәбиятын укытуның сыйфатын күтәрү, татар теле һәм әдәбияты буенча урта мәктәп программаларын укучыларның төпле белем һәм күнекмәләр алуларына ирешеп гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

Аяныч ки, республикабызның төрле төбәкләреннән татар яки татар-рус, рус-татар мәктәпләрен, гимназияләрен, лицейларын, көллиятләрен һ.б. бетереп, КДУ ның татар факультетына укырга кергән студентларның байтагы татар сүзләрен дөрес әйтә һәм яза белмиләр. Мәсәлән: шәхәр, Тагир яки Тахир, Фәгыймә, хәм, әхәмиятле... дип сөйлиләр һәм язалар. Алар: сурәт, дикъкать, канәгать, гаярь, хакимият, икътисад, мөхәррир, Гомәр, Гыйләҗев һ. б. кебек сүзләрне дөрес язмыйлар. Татар әдәбиятыннан, мисал өчен, Татарстан халык язучылары, шагыйрьләре кемнәр булуын белмиләр. Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Г. Исхакый, Г. Бәширов, Ә. Еники һ. б. кебек классик әдипләребезнең төп әсәрләрен әйтеп бирә алмыйлар. Студентларның башка гуманитар фәннәрдән дә (тарих, география һ. б.) белем дәрәҗәләре шактый түбән. Димәк, хәзерге вакытта татар урта мәктәп һәм гимназияләрендә белемнең төпле сыйфатлы, тирән булуын тәэмин итү, укытуны камилләштерү ифрат зарур көнүзәк мәсьәлә булып тора.

Урта мәктәп-гимназияләр, лицейларыбызны максатчан юнәлешле итү (әйтик, математик мәктәп-гимназия яки лицей, экологик мәктәп-гимназия яки лицей, лингвистик мәктәп-гимназиясе яки лицее һ. б.) халык хуҗалыгы

һәм тормыш таләпләренә ныграк җавап бирер иде. Шушы уңайдан бергәләп уйлашу өчен бер мисал рәвешендә туган авылым мәктәбе—Яшел Үзән районы Мулла Иле урта мәктәбе турында беркадәр киңәебрәк язып китмәкче булам.

2001 елның 17 февралендә Мулла Иле авылында татар-рус мәктәбе ачылуга 100 ел тулуга багышланган тантана зур юбилей-бәйрәм итеп үткәрелде. Республика күләмендә билгеләп үтелде дисәм дә, ялгыш булмас. Анда Татарстан Президенты аппарат җитәкчесе, биология фәннәре докторы Ә. С. Гобәйдуллин, Татарстан Мәгариф министры, педагогика фәннәре докторы Ф. Ф. Харисов, Яшел Үзән шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы Р. Г. Зиннәтуллин һ. б. мөхтәрәм кунаклар катнаштылар, тантаналы кичәдә чыгыш ясадылар, мәктәпкә истәлеккә зур бүләкләр тапшырдылар. Бу тантанада Мулла Иле җидееллык мәктәбендә 1940—1947 елларда «бик яхшы» билгеләренә укып тәмамлаучы буларак, мин фәкыйрегез дә катнаштым. Мине, телче галим буларак, бер нәрсә сөендерде: авылым урта мәктәбе укучыларының татар телен, әдәбиятын, тарихын яхшы белүләре, бу фәннәрне яратулары! Утыз елдан артык мәктәп директоры һәм татар теле, әдәбияты укытучысы булып эшләгән, Татарстанның атказанган укытучысы, шагыйрь һәм прозаик, сүз остасы Равил Гарафетдин улы Сәйфетдинов үрнәге-йогынтысында аның укучыларының 5-6 сыйныфларда ук әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлаулары һәм, әйтергә кирәк, шактый уңышларга ирешүләре.

Менә конкрет бер мисал. VII сыйныф укучысы Майорова Рәмилә Фәһим кызы, 12 яшендә генә булуга карамастан—әдәби китап авторы да инде. Аның, Татарстан Республикасы Президенты аппараты җитәкчесе Ә. С. Гобәйдуллин булышлыгы белән басылып чыккан «Өмет бар туар көннәремдә» *(«Арт-кафе» нәшрият үзәге, 2001)* дип аталган бу китабы шигырь, драма һәм проза әсәрләре тупламыннан гыйбарәт.

Аның шигырь, пьеса һәм хикәяләрендә самимилек, кечкенә генә уңышка, яхшылыкка ихлас сөенү, уңышсызлыкка, начар нәрсәләргә борчылу-көенү, дөньяга балачак күзеннән карау, матурлыкны ярату, гүзәллеккә соклану, киләчәккә ышаныч-өмет белән карау чагылыш ала.

Яхшылык, яктылык көтәм
Һәр туар көннәремнән,
Фәрештәләр сыйпап үтә
Кечкенә иңнәремнән.

Еллар караңгы булса да,
Өметләрем ак минем;
Тормышлар ярлы булса да,
Күңелләрем шат минем...

Минем килер бәхетемне
Саклый күктә Ходаем,
Яхшылык, яктылык көтәм
Бу дөньядан көн саен.

Мулла Иле урта мәктәбен телләрне тирәнтен өйрәнә, үзләштерә торган лингвистик гимназия итү өчен бөтен шартлар да бар. Бу урта мәктәпне татар теле, рус теле, инглиз теле, гарәп теле һәм төрек телләрен тирәнтен өйрәнү-үзләштерү максат ителгән тел гимназиясе ясау заманча зарур һәм урынлы булыр иде. Әлеге телләрне укыту өчен тәҗрибәле белгеч-укытучы кадрлар белән мәктәп тиешенчә тәэмин ителгән. Мулла Иле урта мәктәбе тел гимназиясе итеп үзгәртелсә, мин аңа шеф-консультант булырга риза булуымны мәктәпнең йөзьеллыгына багышланган тантаналы кичәдә ясаган чыгышымда мөхтәрәм авылдашларыма, укытучыларга, укучыларга һәм чакырылган кунакларга рәсми рәвештә белдердем.

Мулла Иле авылының тел гимназиясе Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы факультеты һәм Шәрык институты өчен база мәктәп-гимназия функциясен башкара алыр иде. Безнең студентлар Мулла Иле тел мәктәп-гимназиясенә кайтып практика үтәрләр, бу мәктәп-гимназияне уңышлы тәмамлаган унберенче сыйныф укучылары КДУның әлеге факультет һәм институтының абитуриентлары, студентлары булырлар иде. Мулла Иле авылының Волгоград-Казан тимер юлындагы Албаба станциясенә якын урнашкан булуы, Албаба станциясе белән Казан арасында электр поездлары йөрүе дә шушы теләк-максатларны гамәлгә ашыру өчен зур уңайлык тудыра.

Инде оптимистик нотадан күңелсезенә күчәргә туры килә. «Балык

башыннан бозыла»,—ди халык. Әйе, чыннан да шулай. Татарстан Җөмһүриятендә татар һәм рус телләренең тигез хокуклы дәүләт телләре булу статусын закон-кануннар чыгара торган иң югары дәүләт органыбыз—Дәүләт Советы үзе сакламый, үзе боза: Татарстанның дәүләт телләреннән берсенә генә, рус теленә генә, өстенлек бирә. Татпарламент үткән унбер ел дәвамында сессия утырышларында русча сөйләште һәм һаман русча сөйләшә.

Дөньядагы барлык дәүләтләрнең парламентлары (парламент иҗтимагый-сәяси терминының килеп чыгышы—француз телендәге parler [парлер]—«сөйләшү» сүзеннән) да диярлек үз иленең рәсми кабул ителгән дәүләт телендә сөйләшә. Англия парламенты һәм АКШ конгрессы утырышлары—инглиз телендә, Швеция риксдагы швед телендә, Норвегия стортингы норвег телендә, Польша сеймы поляк телендә, Литва сеймы литва телендә, Италия парламенты итальян телендә, Төркия Милли Мәҗлесе төрек телендә, Казакъстан Дәүләт Җыелышы утырышлары казакъ телендә алып барыла. Ни өчен Татарстан республикасы һәм дәүләтенә исем биргән титуллы халык—татар халкының туган телендә алып барылмый?! Кайчанга чаклы туган телебез—татар теле—законнар чыгара торган иң югары дәүләт органыбызда үги бала хәлендә кимсетеләчәк, исәпкә бар, санга, гамәлгә юк булачак?!

Әйе, хәзерге вакытта татар телен дәүләт теле итеп гамәлгә кертү, аның статусын, абруен үстерү, чынлап дәүләт теле вазыйфасын башкарту үрнәген республикабызның иң югары дәүләт органы булган Дәүләт Советы күрсәтергә тиеш. Якын киләчәктә Татарстан Дәүләт Советына депутат булып сайлану өчен теркәлергә теләгән һәр кандидатның ике дәүләт телен белүе мәҗбүри булуы күрсәтелгән аерым маддәне Конституциябезгә кертү катгый зарур. Татарстан Дәүләт Советы депутаты буласың килсә—татармы син, русмы, чувашмы, маримы, армы, яһүдме—ике дәүләт телен дә бел! Татарстанның титуллы телен белмәүче, татар телен өйрәнмәүче депутат, йомшак итеп әйткәндә, Татарстан Республикасын, аның югары дәүләт органнарын, Президентын, хөкүмәтен, халкын санга сукмаучы, үзен һәркемнән, һәрнәрсәдән өстен тотучы, төзәлмәс иң яман чир—бюрократизм чире белән авыручы бюрократ бәндә була. Татарстан Дәүләт Советында татарча белмәүче яки белергә дә теләмәүче депутатлар күп булганга, парламентыбыз татарча сөйләшми, Татарстанда татар теле, рус теле белән тигез хокуклы дәүләт теле булуга карамастан, сессия утырышларын татар телендә алып бара алмый. Димәк, Татарстанда татар теленең дәүләт теле булу статусын Татарстан парламенты үзе тиешенчә гамәлгә кую-тәэмин итүдән, сессия утырышларында татарча сөйләү-эшләү үрнәген бирә-күрсәтә алудан мәхрүм. Ә бу инде сәяси трагедия, милли дәүләти фаҗига, афәт, әлбәттә.

Алай гына да түгел: «Татарстан халыкларының телләре турында Закон» һәм Программаны кабул иткән һәм боларны тиешенчә тормышка ашыруны даими контрольдә тотарга тиешле, татар телен дәүләт теле буларак саклау, яклау, укыту, фәнни өйрәнү һәм үстерү өчен иң беренче чиратта төп җаваплы дәүләт органы—Татарстан Республикасы Дәүләт Советы—үзе аерым сүзатамаларыбызның татарча традицион әдәби дөрес әйтелеш һәм язылыш нормаларын бозуга, алардан тайпылуга юл куя, гамәли мөмкинлек бирә.

Моннан биш ел элек Татарстан Дәүләт Советы бер түрәнең, депутат әфәнденең кәефен бозмас өчен, аның фәнни нигезләнмәгән тәкъдимен хуплап, татарча әдәби традицион әйтелештә һәм язылышта Норлат булып йөргән шәһәр һәм район исемен, русча әйтелеш һәм язылыштагыча Нурлат итәргә фатихасын бирде. Милли әдәби телебез нормаларына, тарихи географик-топонимик мирасыбызга хилафлык китереп, татарча хата әйтелеш һәм язылышка юл ачты. Законлылык, канун-тәртип саклау үрнәге булырга тиешле Дәүләт Советыбыз ялгышты, хата юлга басты. Аның карары нигезендә хәзер барлык татар газета һәм журналлары «Нурлат» дип яза, Татарстан радиосы һәм телевидениесе дикторлары татарча әйтелештә дә «Нурлат» дип сөйли. Менә шулай итеп Норлат шәһәре һәм районы атамасы, Нурлыат-Нурлат булып куйды. Хәлбуки, ат һәм башка хайваннар гына түгел, адәм баласы үзе дә фәрештәләр кебек нурдан яратылмаган.

Шулай итеп, татарча «Норлат» әйтелеш һәм язылышы да русча әйтелеш һәм язылыш белән тәңгәлләште, бердәй «Нурлат» шәкеленә керде. Бары тик Татарстан телевидениесенең Татарстанда һава торышын хәбәр

иткәндә файдалана торган татарча картада гына Норлат булып калды.

Табигый ки, берничә гасыр дәвамында атамалары татарча «Норлат» рәвешле әйтелеп һәм язылып йөргән торак пунктларның (авыллар, шәһәр, станция, районнар) татарча язмаларда һәркайда һәм һәркайчан «Норлат» булуы яхшы аңлашыла. Тарихи чыганакларда, рәсми белешмә-сүзлекләрдә, 1999 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты тарафыннан чыгарылган «Татарский энциклопедический словарь»да (баш редакторы академик М. Х. Хәсәнов) татарча «Норлат» рәвешле, ягъни дөрес язылган.

Милли тарихи-топонимик мирасыбызны тәшкил иткән географик атамаларның татарча нормалашкан әйтелеш һәм язылышын үзгәртергә беркемнең дә, бернинди дәүләт органының да хакы юк! Аларның милли дөрес әйтелеше һәм язылышы махсус законнар белән саклана. Чөнки милли географик исем-атамалар—тел, тарих, археология, тарихи география, экология җәүһәрләре-ядкарьләре алар. Биредә шушы фикеребезне раслау өчен, күренекле әдибебез Миргазиян Юнысның «Кәрәзле телефон» кәрәзлеме?» дип аталган публицистик әсәреннән (*«Казан утлары», № 4, 2001*) түбәндәге өзекне китерү урынлы булыр:

«Америка Кушма Штатларының аборигеннары-индианнар бары тик резервацияләрдә генә сакланып калганнар, ә америкалылар шул кырылып беткән халык биргән тау, елга, күл һәм башка табигать исемнәрен үзгәртмичә саклап торалар: Кентукки, Арканзас, Огайо штатлары, Аппалач таулары... Энемнең дусты булган Америка язучысына мин шушы сорауны бирдем:

—Индианнар кушкан исемнәрне сез нигә үзгәртмичә саклыйсыз?

Ул миңа ничек җавап бирде:

—Алар бит шул исемне йөрткән җирләрнең җанына тиң. Гомумән, тарихи исемнәрне үзгәртү—искиткеч зур варварлык ул! Тарихка тияргә ярамый! Исем ул—шул ук археология! Казымыйча алырлык археология байлыгы» (126-127 битләр). Нинди зирәк, акыллы һәм гыйбрәтле сүзләр!

Соңгы елларда русча Набережные Челны шәһәре атамасын татарчага, туры калька итеп тәрҗемәләп, Яр Чаллы дип йөртү модага керде. Әмма тәгаен туры калька «Яр буендагы Чаллы» булыр иде. Чаллы шәһәре—борынгы болгар бабаларыбыз тарафыннан XI йөзләрдә үк нигезләнгән торак пункт. Болгар телендә чал сүзе «таш», «чаллы» сүзе «ташлы» мәгънәсен белдергән. Чулманга (Камага) коючы Чаллы («Ташлы») елгасының ташлы ярлардан гыйбарәт тамагына утырудан, Чаллы («Ташлы») елгасы исеменнән алып, аңа Чаллы дигән исем кушканнар. Татарстанда берничә Чаллы елгасы һәм атамалары составында чаллы («ташлы») сүзе булган ике дистәдән артык татар авыллары бар.

Набережные Челны атамасын, татарчага хата рәвештә калькалаштырып, Яр Чаллы дип йөртү татар әйтелеше, татарча сүз тәртибе законнарына бөтенләй туры килми. Татарлар бу атама составында яр («берег») сүзен күрсәтергә килсә, Чаллыяр (ягъни «Ташлыяр» рәвешле) әйтерләр иде. Чөнки татар телендә яр «берег» сүзе, Ташлыяр (ташлы+яр), Кызылъяр (кызыл+яр), Акъяр, Караяр, Сарыяр һ. б. кебек «сыйфат+исем» конструкцияле кушма төзелешле географик атамалар составында икенче урында, икенче компонент булып килә. Мәсәлән, Кызылъяр—Татарстанның Арча, Түбән Кама, Баулы районнарындагы; Иске Кызылъяр, Яңа Кызылъяр—Әгерҗе районындагы татар авыллары; Ташлыяр—Мөслим районындагы татар, Теләче районындагы рус авылы атамасы; Акъяр—Төмән өлкәсе Төмән районындагы татар авылы исеме; Караяр—Зөя елгасының кара балчыклы яры һәм аның янындагы болын атамасы һ. б. Күрәбез, татарлар Яр Кызыл, Яр Ташлы, Яр Кара, Яр Ак, Яр Сары дип сөйләмиләр һәм язмыйлар. Димәк, «Яр Чаллы» дип әйтү һәм язу да татар милли әдәби теле нормаларына туры килми, аны вата, җимерә, боза.

Без Чаллы шәһәре исемен татарча бер генә сүз белән «Чаллы» дип әйтеп һәм язып йөрергә тиеш булабыз. Хәтта русча да «Набережные Челны» дип ике сүз белән әйткәнче, «Чаллы» дип кенә атап йөртсәк, беренчедән, әйтелеш һәм язылышта кыскалык, димәк, экономия пәйда була, икенчедән, тарихи дөреслек, атаманың болгари беренчелеге, борынчылык торгызыла, өченчедән, руслар да Чална, Челна, Челны тибындагы Чаллы сүзен (атамасын) дөрес итеп әйтә һәм яза алачаклар. Чагыштырыгыз: татарча да,

русча да—Актаныш, Мамадыш, татарча—Алабуга, русча—Елабуга һ. б.

Атамалар турында сүз чыккач, башкалабыз Казанның үзәк урамнары, мәйданнарының исемнәре хакында да, галим ономаст-топонимист буларак фикеребезне әйтү урынлы булыр. Бу мәсьәлә чал тарихлы Казаныбызның меңьеллыгын 2005 елның 30 августында бөтендөнья күләмендә тантаналы итеп үткәрү—махсус бәйрәм итү—уңаеннан тагын да актуальләшә.

Соңгы ун ел дәвамында матбугатта күпме язып, радио һәм телевидение тапшыруларында күпме сөйләп, Казанның Ленин урамы исемен Кремль урамы, Куйбышев мәйданы исемен генә бөек шагыйребез хөрмәтенә Тукай мәйданы дип үзгәртеп атата алдык. Казанның калган үзәк урамнарының исемнәре искечә, совет заманындагыча: Бауман урамы, Карл Маркс урамы, Дзержинский урамы, Профсоюз урамы, Киров урамы һ. б. булып кала бирде. Казанның меңьеллыгын үткәрер алдыннан, шәһәргә нигез салынуның меңьеллыгын билгеләп үтүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча шәһәрнең комплекслы программасы әзерләнү уңаеннан, башкалабызның үзәк урамнарына милли төс, милли йөз-рух бирүне күздә тотып, аларны татар халкы тарихындагы күренекле олуг шәхесләребезнең исемнәре, тарихи этнонимнар, тарихи даталар белән атау, һичшиксез, мөһим һәм зарур. Бауман урамын моннан бер мең ел элек Казанга нигез салган баһадир болгар бабаларыбыз хөрмәтенә Болгар урамы дип; Киров урамын болгарларның ишле һәм куәтле кабиләсе—Татарстан Республикасы туграсы (гербы) итеп алар табынган тотем—көчле һәм житез җанвар канатлы ак барс—рәсеме алынган барс (барсил) кабиләсе этнонимы белән Барс яки Ак барс урамы дип; Дзержинский урамын легендар милли тарихи шәхесебез Сөембикә ханбикә хөрмәтенә Сөембикә урамы дип; Профсоюз урамын татар халкының милли азатлыгы, иреге, бәхете өчен каһарманнарча көрәшкән классик әдибебез Гаяз Исхакый хөрмәтенә Гаяз Исхакый урамы дип; Карл Маркс урамын Казанның тарихи, истәлекле датасы—меңьеллыгы уңаеннан Казанның меңьеллыгы урамы дип исемнәрен алмаштыру урынлы һәм дөрес гамәл булачак. Бу исемнәр Казанның мөхтәрәм кунаклары алдында йөзебезне кызартмаслар, башкалабызга милли тарихи рух, йөз һәм төс бирерләр иде. Казан топонимиясенә милли йөз бирү, урамнарыбызның исемнәрен татарча атау—заман таләбе, Казанның меңьеллык тарихи датасы таләбе, Республикабызга исем биргән титуллы татар халкының таләбе. Казанның Татарстан башкаласы, бөтендөньяга сибелгән татар халкының рухи кыйбласы, мәркәзе булуын исебездән чыгармыйк!

Башкалабыз Казанда хәзер 1785 урам һәм тыкрык бар (карагыз: *Казан шәһәре урамнарының исемнәре. Белешмәлек (проект).—Казан шәһәре хакимияте. Ноябрь—2000, 8-15 битләр)*. Хәлбуки, «Татарстан башкаласында татар исемен йөрткән урамнар саны урыснкыннан алты тапкыр диярлек кимрәк» (карагыз: *Әбрар Кәримуллин. Күрсәтелгән хезмәт.—Казан, 1997, 166 бит)*. Димәк, башкалабыз топонимиясендә хәзергә хәлләр татар теле файдасына түгел. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максат-бурычларыннан чыгып караганда да нисбәт һәм хәлләр үтә мөшкел.

Татар теленең республикабызда дәүләт теле буларак статусын тәэмин итү, күтәрү өчен татар милли мәгариф системасын камилләштерү, аның эзлекле башлангыч-урта-югары белем бирү алка-циклын тиешенчә тормышка ашыру гаять зарур. Хәзерге вакытта татар милли мәгариф системасының башлангыч һәм урта белем бирү буыннары заман таләпләренә туры килә, аларны канәгатьләндерә диярлек. Әмма милли мәгариф системабызның яшьләребезгә татар телендә югары белем һәм тәрбия бирү буыны бик нык аксый әле. Чөнки милли мәгариф системабызда яшьләргә татарча югары белем һәм тәрбия бирә торган бүлек, факультет һәм махсус югары уку йортлары бик аз. Менә шуңа милли мәгарифебезнең замани ихтыяҗлары тиешенчә канәгатьләндерелә алмый. Менә шуңа гуманитар, табигать һәм төгәл фәннәр буенча татарча югары белем бирә торган махсус дәүләти милли югары уку йортын—Татар дәүләт милли университетын кичектермичә ачу ифрат зарур. Аны ачу турында Татарстан Дәүләт Советында, Татарстан Президенты даирәләрендә, матбугатта, фәнни конференцияләрдә, җыелышҗыеннарда сүз күп булды инде. Сүздән гамәлгә күчәр сәгать җитте. Татар

дәүләт милли университетын ачу—һәрьяклап өлгергән мәсьәлә, заман, бүгенге тормыш, татар дөньясы, аның киләчәге, милли мәгарифе таләбе.

Татар дәүләт милли университеты структурасында башта дүрт факультет булыр дип уйланыла: 1. Татар филологиясе, тарих һәм педагогика-психология факультеты; 2. Хокук һәм идарә факультеты; 3. Икътисад һәм халыкара мөнәсәбәтләр факультеты; 4. Төгәл фәннәр факультеты. Әлеге факультетларда студентларга татарча югары белем һәм тәрбия бирү өчен әзерлекле һәм тәҗрибәле өлкән буын галим-профессорларыбыз, академикларыбыз бар. Алар көчендә чагында, алар исән чагында ашыгырга, Татар дәүләт милли университетын (ТДМУны) ачып, милли зыялы кадрлар әзерләү эшен юлга салып калырга, кичекмәстән башлап җибәрергә кирәк. Эш шунда ки: урта буын галим-голәмәбез сан ягыннан шактый аз, байтагы, заманы шулай туры килгәнгә (бу аларның гаебе түгел), татарча иркен сөйләшә, фикер йөртә алмый. Шулай булгач, студентларны татарча укыта да алмаячаклар.

Илбашыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев узган унбер ел эчендә Татарстан халык хуҗалыгын, сәнәгатен, икътисадын, авыл хуҗалыгын, мәдәниятен, мәгарифен, матбугатын, сәнгатен тотрыклы итүдә, үстерүдә, халыкның тормыш хәлен яхшыртуда, Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын булдыру һәм ныгытуда, халыкара багланышлар тудыруда бәяләп бетергесез зур өлеш кертте, күпкырлы нәтиҗәле эшчәнлек күрсәтте. Боларның барысы өчен дә зур рәхмәт аңа.

2001 елның 25 мартында өченче срокка (2001—2006 елларга) Татарстан Республикасы Президенты итеп сайланган хөрмәтле Илбашыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең әлегә кадәр тормышка ашмаган, халкыбызның телен, мәгарифен, мәдәниятен, фәнен үстерүдә, матур, якты киләчәген тәэмин итүдә ифрат зур тарихи өлеш кертәчәк Татар дәүләт милли университетын ачу турындагы Указга кул куюын, озакка сузмастан махсус Указ чыгаруын сайлаучы һәм татар галиме буларак сорыйм. Татар дәүләт милли университетын ачу мәсьәләсе, аның үзенчәлекләре белән Президентыбыз яхшы таныш. Әмма милләтебез өчен бу көнүзәк җитди мәсьәлә, ни өчендер, уңай хәл ителмичә, һаман сузылып килә.

«Безнең сүзебез эшебездән аерылмый»,—диде Минтимер Шәрипович 12 апрельдә С. Сайдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасын башкарырга керешү уңаеннан Татарстан Дәүләт Советы сессиясендә ясаган чыгышында *(«ВТ». 13. 04. 2001 ел, 2 бит)*. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты, барыбызга да яхшы мәгълүм акыллы сәясәтче Фәндәс Сафиуллин 2001 елның 23 мартында «Дулкын» радиосы аша чыгышында тавышларны Минтимер Шәриповичка бирергә чакырып: Минтимер Шәрипович үзе дә хуплаган Татар дәүләт милли университетын ачу турындагы Указга яңа срокка сайлану белән кул куюына ышанам һәм бөтен күңелем белән шуны телим»,—диде. Мин дә моңа ихлас ышанам һәм бу изге гамәлнең мөмкин кадәр тизрәк тормышка ашуын теләп калам. Амин!

Татар дәүләт милли университетын ачу татар халкы өчен, аның теле, милли тәрәккыяте, киләчәге өчен, фәне, мәдәнияте, матбугаты, әдәбияты, сәнгате, мәгарифе, халыкара сәясәте үсеше, гомумән, абруе арту өчен ифрат зур һәм мөһим роль уйнаячак.

Барысы да чагыштыру аша танып белenә. Татар дәүләт милли университетының халкыбыз өчен шундый зур һәм мөһим роль уйнавын дәлилләү өчен, Казан дәүләт университетында дәһшәтле Бөек Ватан сугышы барган вакытта—1944 елда ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлеге һәм 1989 елда шул бүлек базасында барлыкка килгән татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты укытып-тәрбияләп чыгарган 2500 дән артык милли кадрларның халык хуҗалыгының төрле тармакларында җиң сызганып эшләве, милләтебез мәнфәгатьләренә хезмәт итүе мисалында шактый ачык итеп күрсәтеп булыр иде.

Кайда гына, кем булып кына эшләми КДУ ның татар бүлеген яки факультетын бетергән белгеч-кадрлар?! КДУның татар бүлеге чит илләр, мәсәлән, Румыния өчен дә, югары белемле белгеч-филологлар әзерләде. Фән докторлары Мәхмүт Әнвәр, Али Хәлил Нәдрәт, фәнни хезмәткәр Вуап

Җәүдәт Шухран татар бүлеген 1958 һәм 1960 елларда тәмамлаган студентлар.

Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеге һәм факультетының төп вазыйфасы—урта мәктәп, гимназия, лицейлар, көллият-училищелар өчен татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләү, әлбәттә. Бу бүлек һәм факультет XX гасырның икенче яртысында алар өчен белгеч филологлар—татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләп чыгаруда төп терәк-база функциясен башкарды һәм башкара. Әлеге бүлек һәм факультетны тәмамлаучыларның күбесе Татарстан мәктәпләрендә һәм башка республика, өлкәләрнең башлыча татар мәктәпләре, гимназияләрендә татар теле-әдәбияты, тарих, көнчыгыш телләре (гарәп, төрек һ. б.) укытучылары булып эшлиләр.

Казан университетының татбүлек һәм татфагын тәмамлаучылар арасында журналистлар шактый күп. Татарстан Язучылар берлеге әгъзаларының яртысыннан артыгы КДУның татбүлеген яки татфагын тәмамлаган, йә булмаса хәзер дә татфакта укучы мөхтәрәм затлар. Шуларның өчесе (Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах) «Татарстан Республикасының халык язучысы, икесе (Р. Фәйзуллин, Ф. Яруллин) «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Моннан 60 ел элек Казан дәүләт университетының татар бүлеген, 12 ел элек татар факультетын тәмамлап чыккан иптәшләрнең исем-фамилияләрен санап чыгу өчен генә дә 100 битлек китапчык язу кирәк булыр иде. Без алдыбызга андый максат куймадык. Бу мәкаләмдә исем-фамилияләрен очратмаган затлар мине гафу итсеннәр! Төп максат-бурыч исә бер—Казан дәүләт университетының татар бүлеге һәм татар факультетының халкыбызның күпьяклы тормыш-яшәеш ихтыяҗларын канәгатьләндерү, халыкка хезмәт итү өчен никадәр югары белемле фидакарь белгеч, милләтпәрвәр зыялылар әзерләвен бәян итү. Шушы күркәм үрнәктә Татар дәүләт милли университетын кичекмәстән ачуның зарурлыгын нигезле итеп дәлилләү-раслау иде.

Бередә татар филологиясе фәнен үстерүдә соңгы 5-6 ел дәвамында (1995—2001 елларда) Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты каршында һәм Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ТӘСИ) карамагында филология фәненнән кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау Советларының уңышлы эшләвен билгеләп-бәяләп китү урынлы булыр. Киләчәктә Татар дәүләт милли университеты каршында татар теле һәм әдәбияты буенча аспирантура һәм докторантура булдырып, яклау Советы ачуның татар теле гыйлеме һәм татар әдәбияты белеме фәннәрен алтабан тагын да уңышлы үстерү өчен зур өлеш кертәчәген махсус ассызыклап әйтәсе килә.

1995—2000 елларда татар теле һәм әдәбияты буенча филология фәннәре кандидаты һәм докторы гыйльми дәрәҗәсен алу өчен 50 дән артык диссертация якланды. Докторлык диссертацияләренең күп яклануы бигрәк тә куандыра. Чөнки һәр докторлык диссертациясе ул—филология фәненә, аның үсешенә, бу очракта татар филологиясе фәненә (татар теле гыйлеменә һәм татар әдәбияты белеменә) саллы өлеш кертү дигән сүз.

Татар филологиясе буенча соңгы елларда 24 фән докторы барлыкка килү—сөенечле, шатлыклы күренеш, әлбәттә. Әмма моның көенечле ягы да бар. Бу елларда докторлык диссертациясе яклаган иптәшләрнең күбесенең яше—пенсия яшендә: 60 белән 75 яшь арасында. Эш шунда ки, мондый олы яшьтә инде аларның күбесе аспирантлар алып, аларны тиешенчә фәнни җитәкләп, үзләренең гыйльми юнәлешләрен, фәнни мәктәпләрен тудыра, үз шәкертләрен булдыра алмыйлар.

Татар теле буенча 30 лап филология фәннәре докторыбыздан күбесе, остаз булып, фән кандидатлары һәм докторлары әзерләү бәхетеннән мәхрүм. Күп санлы филология фәннәре кандидатлары һәм докторлары әзерләп, үзләренең фәнни лингвистик мәктәпләрен тудырган остаз галимнәрдән Л. Җ. Җәләйне (10 фән кандидаты, 4 фән докторы остазы), М. З. Зәкиевне (30 фән кандидаты, 7 фән докторы остазы), Д. Г. Тумашеваны (25 фән кандидаты, 1 фән докторы остазы), В. Х. Хаковны (8 фән кандидаты, 1 фән докторы остазы) күрсәтә алабыз. Минем үземнең дә 37 фән кандидаты (алар арасында татарлардан тыш, казакълар, үзбәкләр, тывалылар һәм шор), 7 фән докторы бар.

Остаз булмаган җирдә—осталык юк. Осталыкка, һәр рухи, фәнни яисә

матди-сәнәгати юнәлешкә юл күрсәтүче, өйрәтүче, чишмә башында торучы, үсешен кайгыртучы, шәкертләр тәрбияләүче, аларны җитәкләүче, белем, үгет-нәсихәт, һөнәри үрнәк күрсәтүче рухи, гыйльми яисә һөнәри ата яки ана, иң күркәм сыйфатларны һәм традицияләрне туплаган олуг зат—ул остаз. Менә шуңа «һәр эшнең остасы бар, һәр останың остазы бар» ди татар халык мәкале. Корьәндә остаз ата-анага тиңләштерелә. Галим өчен аерым фәнни юнәлеш тудырып, күпләгән шәкертләрне берләштергән фәнни мәктәп барлыкка китерүдән дә зуррак мәртәбә, күркәм дәрәҗә, хөрмәтле абруй—сан һәм дан юк, әлбәттә. Үзенең фәнни мәктәбен тудырып, күпсанлы шәкертләр тәрбияли алган галим-остаз—халык һәм ил тарихында үзен мәңгеләштерүче, үзе исән чагында ук үз-үзенә җимерелмәс мәрмәр һәйкәл коючы бөек асыл зат ул.

Татар дәүләт милли университеты чал тарихлы халкыбыз ихтыяҗларын югары зәвык белән заманча канәгатьләндерү өчен белгеч-зыялылар әзерли торган даны еракларга таралачак, абруйлы милли югары уку йорты булыр иде. Татар халкының чал тарихында мондый мәртәбәле милли югары уку йортының булганы юк иде әле. Булыр ул, булмый калмас! Чөнки милли университет—татар халкының гасырлар дәвамында өлгергән зарури рухи ихтыяҗы.

Милли университет—
Халкым өчен терәк багана!
Булыр ул, булмый калмас!
Чөнки милләт бөркетләре—
Батыр егет, сылу кызлары
Бөек хыялларга
Очар өчен,
Милли чынбарлыкны
Кочар өчен канат кагына.

Литвада В. Капсукас исемендәге Вильнюс дәүләт милли университеты моннан 4 гасырдан артык элек, 1579 елда ачылган. Бу милли югары уку йортының сан ягыннан ике миллионнан артмаган литва халкын, аның телен саклап калуда, фәнен, мәгарифен, мәдәниятен тудыруда һәм үстерүдә керткән өлеше бәяләп бетергесез зур, олпат һәм мәһабәт.

XVI гасыр азагында литва язуына нигез салучы Микалоюс Даукша бик хаклы һәм дөрес язганча: «Не урожайностью земли, не разнообразием нравов, не красотой края, не крепостью замков и городов жив народ. Он силен прежде всего своим языком, который сохранил и на котором говорит, который возвеличивает и поддерживает общество, мир в нем и братскую любовь. Он—мать единства, отец гражданственности, страж государственности... Уничтожь язык, и не останется мира, согласия, единства и других добродетелей! Уничтожь язык, и угаснет солнце в небе, не останется порядка в мире, не станет жизни!» (цитата, чыганактагыча русча китерелде).

Әйе, теле барның—юлы бар. Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр! Газиз туган телебез—татар телен кадерлик, яклыйк, саклыйк, чарлыйк, сөеп үстерик, мөхтәрәм милләттәшләр!

Туган тел—алтын багана,
Туган тел—яшел бишек!
Туган тел—гомер итүдә,
Фани дөньяны көтүдә,
Буыннарны беркетүдә,
Татарны татар итүдә,
Милләтне алга илтүдә
Могҗизалы, серле ишек!

Туган теле барның—милли юлы бар, милли йөзе бар, шәхес буларак үзе бар, кеше буларак абруе бар, кадере-бәясе, хөрмәте бар!

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

*Хөрмәтле галимебез Гомәр ага Саттаровны олы бәйрәме—70 яшь тулу уңае белән кайнар котлыйбыз һәм аңа ныклы сәламәтлек, яңа иҗади-фәнни уңышлар телибез!*

*Мәдәниятебез тарихына*

**Рифә Рахман**

# ТӨРЕК-ТАТАР ӘДӘБИ БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕНЕҢ КАЙБЕР СӘХИФӘЛӘРЕ

Озын һәм бай тарихлы төрек-татар әдәби бәйләнешләрен ике гасыр чигендә формалашкан җәдидчелек хәрәкәте юламаннарыннан саналырлык Исмәгыйль Гаспралыдан һәм аның «Тәржеман» газетасыннан башка күз алдына китереп булмый. Төрки халыкларны бөтендөнья әдәбиятлары эченә алып керүдә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасында күпер салуда аларның хезмәте бәяләп бетермәслек зур.

Исмәгыйль Гаспралы эшчәнлегенә кагылышлы материаллар цензура архивларында байтак. Шулар арасында иң игътибарга лаеклысы—Вакытлы матбугат буенча Баш идарәнең 71 санлы эше буларак теркәлгән «Мөселман матбугаты һәм мөселманнар арасында мәдәният таралу» язмасы. Аның «Татар матбугатында яңа агымнар» исемле бүлегендә Одесса гимназиясен тәмамлап бетермәгән Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспралының, Парижга барып, яшь төрекләр белән танышуы һәм Абазы әфәнде матбугат башында торганда (ә Лорис-Мәликов Тышкы эшләр министрлыгын җитәкләгән вакытта) Бакчасарайда, тәрҗемәсен бирү шарты белән, газета оештыруы бәян ителә. Цензор аның берничә елдан Төп тикшерүче күзәтүеннән чыгуы, русча һәм татарча вариантлар арасында аерма булу, оештыручының хәйләкәр сәясәте хакында хәбәр итә.

Исәп-хисап тотучы, фикерле татарлар Гаспралының максаты, халык милләт буларак урыслар арасында эрегәнче, милли узаннарын уятырга теләү икәнлеген аңладылар, ди. Аның аваз методы белән укыту өчен тырышуларын, ана тарафдар кешеләрнең әхлаксыз муллаларны, искелек тарафдарларын тәнкыйтьләп язуларын әйтә, тәрәккыятьчеләрнең беллетристик формада, проза әсәрләренә яшереп, яңа идеяләр пропагандалавын күрсәтә һәм мисалга Р. Фәхретдиновның «Сәлимә яки гыйффәт» әсәрен китерә.

Риза Фәхретдинов хезмәтләрендә дә цензорның хаклыгын раслаучы юлларны еш очратырга мөмкин. Мәсәлән, үзе язган тәрҗемәи хәлдә, кызының истәлекләрендә беллетристик юнәлешне сайлау һәм тәхәллүс астына качуның сәбәпләре хакында сөйли *(алда телгә алынган китап—36, 48 битләр).*

Хисапта тәрәккыятьчеләрнең халыкны алга җибәрәчәк биш юлны күрсәтүләре хакында да фикерләр бар. Алар Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә саналган юлларга өлешчә туры килә:

1) сәүдәне үстерү;
2) сәнәгатьне алга җибәрү;
3) балаларга һөнәр бирү;
4) көнчыгыш һәм көнбатыш телләрен өйрәтүче мәктәпләр ачу;
5) рус телен белү.

Цензор карашынча, яңалык та, искелек тә—милләтне саклауны максат иткәнлектән—бердәй куркыныч!

Р. Фәхретдинов үзенең дөньяга күзе ачылуда «Тәрҗеман» газетасын шулай ук бик югары бәяли. Беренче тапкыр әлеге басма кулына килеп кергәч, ул Фәрид исемле иптәше белән идарәгә хат яза һәм шул көннән башлап аның бер генә санын да калдырмыйча укып бара *(«Тәрҗемәи хәлем», 20 бит).*

Газетаның татарлар тормышында мөһим роль уйнавы хакында хатлар идарәгә гел килеп тора. Кайвакыт газета аларны үз битләрендә дә урнаштыра. 1898 елның 18 санында Оренбург өлкәсендәге Иманкол авылы кешесе А.

Мортазин «Тәржеман» газетасы тәэсирендә мәктәпкә янача уку керүен һәм аның көткәннән дә зуррак унышлар китерүен хәбәр итә.

Цензураның әлеге хисабыннан Гаспралы дәреслеге тәэсирендә дистәләгән китаплар язылуы хакында да беләбез. Ул пропагандалаган «ысулы җәдид» мәктәпләре өчен татарлар эшләгән мөгаммә үзенен унай нәтиҗәләрен бирә. Аны төзүчеләр хәтта китапханәдә булырга тиешле китаплар исемлеген дә язалар. Алар арасында Г. Исхакыйның «Инкыйраз»ы, Ф. Кәриминен «Шәкерт илә студент»ы, Рәшит Ибраһимовның дөнья шаулаткан рисаләләре, «Тәгълимати шәйтания»—кыскасы, татар иҗтимагый-мәдәни тормышында мөһим роль уйнаган әсәрләрнен күбесе бар *(Дәүләт Надир. Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905—1917).—Казан: Милли китап, 1998.—62-64 битләр).*

«Тәржеман» газетасының ике телдә чыгуы рус-татар, төрек-татар әдәби бәйләнешләренен көчәюенә китерә. Аны тулаем, махсус һәм җентекле өйрәнү безнен бу юнәлештәге белемнәребезне әле тагын да тирәнәйтә алачак.

Газетаның даими авторлары да була. Шулар арасыннан ташкентлы Мулла Габбас әсәрләре, әдәби бәйләнешләр ноктасыннан караганда, аеруча игътибарга лаек. Чит әдәбиятларны яхшы белгән, «Француз хатлары» белән танылган әдипнен ләкабе дә аерым фикерләргә этәрә һәм бик үзенчәлекле.

И. Гаспралы төрки халыкларны дөнья әдәбияты үрнәкләре белән таныгуга зур өлеш кертә. Даниэль Дефо «Робинзон»ының камилрәк 1904 елгы басмасын да ул хәзерли. С. Максуди кебек яшьләрнен милли карашлары формалашуда, чит илләргә китеп, югары белемнәр алуында аның роле зур була. Татар язучыларының күбесе аны остаз, үз милләтләренен ин бөек каһарманы саныйлар. «Тәржеман» бабаның үлеменә мөнәсәбәтле мәкаләсендә С. Максуди түбәндәгеләрне яза: «Хакыйкатән уйлап карагыз, Исмәгыйль бәктән бөек безнен күпсанлы татарның кеме бар? (...) Гаспринскийның мәйданга чыгуы, аның мөнбәр тәгълиме булган «Тәржеман»ның һозуры—Русия мөселманнарында яна хәятның башыдыр. Беренче буларак, мәгънәсез хәятыбызга бер мәгънә биргән, максатсыз яшәешебезгә иҗади әмәлләр иткән, шатлыксыз тормышыбызда өмидләр тудырган кешебез Исмәгыйль бәк булды». *(Максуди С. Әмәлләр остазы // Йолдыз, 1911.—22 сентябрь.)*

Сонрак милли хәрәкәтнен төрле төркемнәренә керсәләр дә, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров кебек мөхәррирләрнен вакытлы һәм гомумән матбугатка бәйле карашлары да Исмәгыйль Бәк, аның газетасы үрнәгендә, йогынтысында формалаша.

1903 елны Кырымга ясаган сәяхәтен тасвирлаган юлъязмасында Ф. Кәрими, «Тәржеман» газетасының төп хезмәте итеп, аның «милләт—кәнденен хаста идекен, дәвага мохтаҗ булдыгын, каранғылыкта идекен—зыяга мохтаҗ булдыгын игътираф итмәгә (танырга) башлау»ны күрсәтә. *(Кәрими Ф. Кырымга сәяхәт // Морза кызы Фатыйма.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1996.—371 бит.)*

«Тәржеман»ны укып рухланган, фикерләнгән Гаяз Исхакыйның да бөтен әдәби эшчәнлегенен шул юнәлештә булуын һәм аеруча «Ике йөз елдан сон инкыйраз»да әдипнен милләт хасталыгын һәрьяклы аңлатуын беләбез.

И. Гаспралы чыгарган газетаның егерме еллыгына бөтен дөньядан җыелалар һәм котлау телеграммалары килә. Мәҗлестәге чыгышлар аның татар мөхәррирләрен үстерүдәге өлешен ачык күрсәтә.

Төрек-татар әдәби бәйләнешләрен тикшергәндә, икенче бер мөһим затны—Нәмык Камалны да онытырга ярамый. Ул галимнәр тарафыннан остазы Ибраһим Шинаси беренчеләрдән булып әсәрләренә керткән европачалык идеяләрен дәвам итүче, Көнбатыш тәэсиренә аннан да ныграк бирелүче буларак бәяләнә. *(Akyüz Kenan, Batı Tesirinde Türk Şiiri Antolojisi.—Ankara, 1970.—S. 54-56.)*

Мүйҗән Җунбур әдипнен бөеклеген төрки халыклар арасында эшләгән эшләренен зурлыгында дип саный. Аның, халыкның хиссиятен аңлап, тыштан кергән фикерне эчтәге белән яраштырып, иҗатына уздырганлыгын әйтә.

Нәмык Кәмал бөтен гомерен вакытлы матбугатны демократизацияләү һәм сәяси карашларны уздыру чарасы итүгә, яшь төрекләр хәрәкәтенә, аларның идеяләрен әсәрләре аша пропагандалауга багышлый.

«Төрек энциклопедиясе»ндә Яна заман әдәбиятын төзүчеләр хакында шушындый юллар бар: «Романда—Әхмәт Мидхәт исә Нәмык Кәмал, шигырьдә янә—Нәмык Кәмал илә Әкрәм вә Хәмид, әдәби тәнкыйтьтә Кәмал вә Әкрәм, театр турында исә бонларның һәммәсе бердән бу әдәбиятның корылмасында». *(Türk ansiklopedissi, Çilt XXXII.—Ankara, Milli tcitim başimaavi, 1983.—S. 512.)*

Нәмык Кәмалны драматург итеп «Зәвалль чуҗык» таныта. Пьеса тиз

арада бөтен төрки дөньяга тарала. Аныкына охшаш эчтәлектәге әсәрләрнең күпчелеге пьесаның тәэсирен тойган яисә аңа ияреп язылган була.

Сәхнә өчен иҗат ителүенә карамастан, ул прозабызга да үзенең эзен сала. Драматургиябезгә тәэсире исә озак елларга сузыла. Октябрь инкыйлабы алдыннан язылган «Галиябану»дагы (М. Фәйзи) соңгы күренеш «Кызганыч бала»дагы Шәффыйканың Ата (Гата) белән хушлашуын хәтерләтә. Анда да өлешчә әтисе мәнфәгатьләре хакына корбанга китерелгән кыз язмышы сурәтләнә.

«Кызганыч бала» драмасы тәүге тапкыр 1901 елда—Бахчасарайда, 1904 тә—Казанда, 1909 елны Әзәрбайҗан театрында куела. Нәкъ менә татар каләм ияләренең иң беренчеләрдән булып, пьесаны тәрҗемә итүе һәм аның белән милли театрыбыз ачылу көнен билгеләве күп нәрсә турында сөйли. Г. Камал татарча варианттагы китапның титул битенә, әдипкә мөнәсәбәтен белдереп, «прогрессив төрек язучысыныкы» булуын әйтә.

Нәмык Кәмал бу пьесаны Дюма Баласы әсәрләре тәэсирендә яза. Шулай итеп, татар әдәбияты инде яңа жанр формалары аша дөнья мәдәниятләре белән бәйләнешкә керә.

Нәмык Кәмалның башлангыч чор иҗатына озын монологлар, артык купшылык, ясалмалылык хас. Галиәсгар Камал да «Кызганыч бала»ның теленә, исемнәрнең татарча яңгырашын һәм кайбер башка нәрсәләрне исәпләмәгәндә, зур үзгәрешләр кертми, шунлыктан анда «Зәваллы чужык»ка хас бөтен кимчелекләр чагыла.

«Кызганыч бала» тәэсирендә язылган әсәрләргә чит әдәбиятлардан да мисал китереп булыр иде. Мәсәлән, А. Ахвердовның «Бәхетсез үсмер»е һәм Нәмык Кәмал пьесасы арасында идея-эчтәлек охшашлыклары ярылып ята, әмма ни өчендер совет чорында язылган әзәрбайҗан әдәбияты тарихы буенча мөһим хезмәтләрдә бу күрсәтелми. Әйтергә кирәк, хәтта ике милләт арасындагы бәйләнешләргә бөтенләй игътибар бирелми, ике гасыр чигендәге әдәбиятта үзәккә М. Ахундов исеме куела һәм аның иҗаты да руслар йогынтысында гына формалашкан кебегрәк фикергә урын калдырыла.

Реалистик әдәбиятның туу, үсү баскычларын күрсәткән «Азербайджанский реализм» (Ариф Гаджиев, Баку: Язычы, 1984), «Этапы азербайджанского реализма» (Яшар Караев, Баку: Язычы, 1983) хезмәтләрендә дә төрек каләм ияләре ирешкән уңышларның әзәрбайҗанлыларга тәэсире турында өстән генә, гомуми планда гына әйтелеп кителә. Шул ук «Бәхетсез үсмер» әсәре дә бары тик рус әдәбияты тәэсирендә генә туган кебек аңлашыла.

А. Ахвердов пьесасында да мәгърифәтчеләргә хас үзәк фикерләр бар: иске гореф-гадәтләргә таянып яшәү адәм баласын бәхетсез итә, белем, аң биреп кенә, аны рухи томаналыктан алып чыгып була. Дөрес, «Бәхетсез үсмер»нең төп геройларыннан булган Фәрхад русча укыган, Рәсәйдә табиб һөнәрен үзләштергән, әмма бу фактлар гына әле драманың төрек йогынтысыннан азатлыгы хакында нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирми. Аның басылып чыгу вакыты да (1990), бездә «Зәваллы чужык» пьесасына ияреп иҗат ителгән «Кызганыч бала»ныкы белән бер үк.

Нәмык Кәмал 1873 елны «Ватан яки Силистрә» драмасын да язган була. Урыс-төрек сугышы хакындагы сюжетны нигез иткән бу пьеса татар әдәбиятына ватандарлык идеяләрен пропагандалауны алып килә. Нәмык Кәмалның икенче бер кечкенә күләмле проза әсәрендә («Ватан») әлеге идеяләр бергә туплап бирелә.

Фатыйх Сәйфи-Казанлының «Ике татар классигы турында» китабында Галиәсгар Камалның әдәби мирасы турында мәгълүмат бар. Андагы төрек һәм рустан тәрҗемәләр арасында без Нәмык Кәмалдан алынган «Ватан»ны, «Кызганыч бала»ны, Әхмәт Мидхәтнең «Саран»ын, «Шкабионның хәйләсе»н, Әхмәт Пашаның «Хәстә»сен күрәбез. Алар исә—үз чиратында, Көнбатыштан фикер алып, Көнбатыш мираска ияреп яисә турыдан-туры төрекчәләштерү юлы белән язылган әсәрләр. Шулардан нәкъ менә Нәмык Кәмал каләменнән чыккан «Ватан» гына үзәккә ватанпәрвәрлек идеяләрен куя.

Меһмет Каплан: «Ватан яхуд Силистрә» пьесасы сәхнә әсәре буларак эшләнеш ноктасыннан тәнкыйтьләнә ала, әмма төрек тупламы хаятына тәэсир иткән, аны яшәткән фундаменталь кыйммәте—халыкка аңлаешлы телдә, аны хисләндерерлек вә сәнгатьчә өслүб белән аңлату ноктасыннан бәяләп бетермәслек бер әсәрдер»,—ди. *(Kaplan Mehmet. «Vatan yahut Silistre» // Hareket, 1980.—№ 14.—S. 30.)*

Нәмык Кәмалнын публицистик китапларыннан иң кызыклысы—«Төш» тер (Рөя»). Анын элгәресе Зыя Пашанын да мәгърифәтчелек карашларын уздыручы һәм шул исемдәге сатирик проза үрнәге була. Нәмык Кәмал фикердә остазыннан да югарырак күтәрелә, үз ватанынын якты киләчәген сурәтли. Ул вәхшилек юкка чыккан, яхшылык һәм мәгърифәт җингән, социаль гаделлеккә нигезләнгән ил булачак, имеш. Әлеге публицистик үрнәкнең татар язучыларына тәэсире шик тудырмый. Гаяз Исхакый кебек милләтпәрвәрләр иҗатыннан да бу китапка реминисценцияләр күрсәтеп була *(«Ике йөз елдан соң инкыйраз»)*. «Рөя» бераз сонрак, 1909 елда, Айдаров исемле кеше тарафыннан татарча да чыгарыла.

Нәмык Кәмалнын тарих, әдәбият теориясе буенча мәшһүр хезмәтләре бихисап. Аларда шул чорнын алдынгы карашлары, алгарыш, дөньяви фәннәр, дин, милләт, ватанга мөнәсәбәтле, әдәбият, чит ил әдәбиятлары турында һәм башка фикерләре тупланган. Ул кайсы әдәби жанрда ни өчен хезмәт иткәнлегенә кадәр анлата, мисаллар белән раслый. Әхлакны төзәтүдә театрга йөкләнгән дәрәҗәле эшне бер генә әдәби жанр да башкара алмый дигән фикердә тора.

XVIII гасырда төрекләрдә Расин идеяләренең популяр булуын беләбез. Ә. Мидхәт тә классицизм вәкилләренең иҗатыннан шактый нәрсә өйрәнә. Алар—шул ук Расин, Корнель—театрны әхлак төзәтүче төп чара дип карыйлар. Беренчесе кешенең эчке дөньясын игътибарга алса һәм сәхнә әсәрләрендә психологизмны үстерсә, икенчесе әхлаклылыкны гражданлык хисләре белән дә бәйли.

Төрле философларга мөнәсәбәте ачыктан-ачык чагылган «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә Ф. Кәрими Корнель, Расин исемнәрен дә атый. Дөрес, ул аларны шагыйрь буларак телгә ала, ә бит мәгърифәтчелек чорында каләм ияләренен күбесе төрле жанрларда язганнар һәм, теге яисә бу әдипләрне үзләренә үрнәккә куйганда, беренче чиратта, нинди төрдә иҗат итүеннән бигрәк, фикеренә игътибар иткәннәр.

Шушы заманда татарлар арасында таралыш тапкан карашлар әле Беренче рус революциясеннән соң да шифалы тәэсирен киметмәгән була. Г. Тукайнын 1907 елда язган «Театр» шигыре—әйтерсең лә, Нәмык Кәмал язганнарнын поэзиядәге кайтавазы.

Үткен телле Тукайнын төрек милләтпәрвәре эшчәнлеге белән танышлыгы күренеп тора. Ул, башында Нәмык Кәмал, анын каләмдәшләре торган Яшь госманлылар хәрәкәтенең үз принципларыннан ваз кичүе өчен борчылып, «Бөраларәнә насихәт» шигырен иҗат итә. Нәмык Кәмалнын үзенә багышланган эпиграммасы да бар. Гомумиләштереп әйткәндә, төрек язучысы әдәбиятыбызга Тукайлар буынын да үстерешә.

Нәмык Кәмалнын «Таралган битләр яисә яфраклар» («Эвраки перишан») китабында ислам галимнәренен портретлары сурәтләнә, аларнын биографияләре бирелә. Бераз сонрак бездә дә бу эш җанлана. Риза Фәхретдиновнын теологлар, төрле философлар турындагы китаплары туура Нәмык Кәмал язганнарнын да йогынтысы булырга тиеш.

Унтугызынчы гасырда яшәгән, төрки халыклар мәдәният үсешендә билгеле бер эз калдырган шәхесләр арасында Тәуфикъ бәй Әбуззия дә бар. Аны төрек әдәбият фәнендә, беренче чиратта, күренекле тәнкыйтьче буларак бәялиләр. Ул мәдәни мираснын иҗтимагый мәгънәсен анлату, төрек әдәби үрнәкләрен, сайлап, китап итеп бастыру эше белән шөгыльләнә. Халыкка белем бирү, аны агарту максатыннан, күп еллар дәвамында дивари календарьлар чыгара. Белгәнебезчә, бездә шушы ук эшне Каюм Насыйри башкара.

«Тәрҗеман» газетасынын редакторы Исмәгыйль Гаспринский аннан, Мәкәрҗә ярминкәсендә сату өчен, зур күләмдә календарь бастыруны үтенгән була. Үз илендә ун-унике мен күләмендә генә тарала алган әлеге хезмәт бездә алтмыш мен данәдә сатыла. *(Гордлевский В. А. Очерки по новой османской литературе // Избранное. В 4-х томах. Т. II.—М.: Изд-во Восточной литературы, 1961.—С. 376.)* Төрек әдәбияты, халык авыз иҗаты, фикере әнә шундый юллар белән дә гади халыкка да барып ирешә.

Шулай да Тәуфикъ бей Әбуззияне урыс ориенталистларына һәм татар мәгърифәтчеләренә иң таныткан әсәре—«Госманлы әдәбиятынын үрнәкләре» («Нәмүнәи әдәбияты Османия») китабы. Үз илендә әллә ни популярлык казанмаган бу китап, нигездә, шулай ук Рәсәйдә сатыла. Гордлевский һәм Смирнов кебек ориенталистлар, төрек әдәбияты хакында мәкаләләр, язганда шуна таянып, яна заман төрек әдәбияты хакында фикер йөртәләр.

1895—1905 еллар прозасындагы тәрҗемәләрне тулаем караганда, аларның иң күбесе Әхмәт Мидхәттән икәнлек күренә. Бу исә, үз чиратында, аның иҗатының Яңа заман әдәбиятыбызның чишмә башында торуына ишарәли.

Кем соң ул Әхмәт Мидхәт һәм татар мәгърифәтчеләре ни өчен аның иҗаты, иҗтимагый эшчәнлеге белән кызыксынганнар дигән сорауга киңрәк тукталасы килә.

Ә. Мидхәт Төркиянең Стамбул шәһәрендә һөнәрче гаиләсендә туган, Болгариядә француз лицеен тәмамлаган. Яшьтән үк ата-анасыннан һөнәрчелеккә өйрәнгән һәм 1869 елда Багдадта типография ачкан. Шул елларда ул үзенең иҗади эшчәнлеген дә башлаган.

1871 елда Ә. Мидхәт тагын бер типография ача, шулай итеп, Төркия матбугатын үстерүдә зур эш башкара. Иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге, Нәмык Кәмал белән бәйләнешләре өчен аны сөргенгә сөрәләр, әмма ул анда да язучылык эшен туктатмый.

Ә. Мидхәт әдәби әсәрләр язу өстенә, фәлсәфә белән дә шөгыльләнә. Ул кешенең аның данлаган, иҗтимагый алгарышны хуплаган, Ислам белән фән бер-берсенә каршы килми дип уйлап, аларны берләштерергә омтылган. Аның фәлсәфәсе татарларны, мөгаен, шундый юнәлешле булуы белән дә тарткандыр.

Хезмәтебезнең алгырак өлешендә без татар мәгърифәтчеләре арасында да андый карашларның булуы хакында язган идек инде. Әхмәт Мидхәт төрекчәләштергән мәсәлләрнең авторы Жан де Лафонтенны искә төшерик. Аның «тормышы һәм иҗаты—Аллага табыну белән хөр фикернең пародокс дәрәҗәсендәге берлеге», дияргә мөмкин. *(Строев А. Жан де Лафонтен // Французская литературная сказка XVII—XVIII веков.—М.: Худ. лит., 1990—С. 668.)*

XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башында яшәгән Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, Ф. Кәримиләрнең иҗтимагый эшчәнлеге, әдәбиятка, дөньяви фәннәргә, икътисади алгарышка, дингә карата фикерләренең, хәтта әдип буларак эволюцияләренең Ә. Мидхәтнең иҗтимагый эшчәнлеге, карашлары һәм иҗатының үсеш-үзгәрешләренә аваздаш икәнлеген күрербез. Гаяз Исхакый да аның яшәү, көрәш рәвешен үзенә үрнәк итеп алган.

1905 елда Харитонов матбагасында авторы күрсәтелмичә басылган «Ике баһадир» рисаләсендә төрек әдибенең инглиз җәмәгать эшлеклесе Джон Вольтер белән янәшә куелуы һәм аның милләтпәрвәрлектә үрнәк итеп күрсәтелүе дә Ә. Мидхәт исеменең татарлар арасында популярлыгы хакында сөйли.

Бу рисаләне И. Гаспринский газетасындагы мәкаләдән алып нәшер иткәннәр. Анда Әхмәт Мидхәт хәтта сөргендә дә милләт мәнфәгатьләрен күздә тотучы, аңар мәгърифәт нуры үткәрүче, халык бәхете өчен көрәшүне иректән дә артыграк күрүче итеп гәүдәләндерелә.

Бу елларда халыкта кемнең популяр булуы әдәби әсәрләрдән дә күренә. Герой алдынгы карашлы булса, һичшиксез, милләткә файдалы китаплар укыган. Әйтик, Закир Һадиның мәгълүм шәкертенең кулында да Исмәгыйль бәкнең «Ике баһадир» атлы рисаләсе бар.

Төрки халыклар, аларның күренекле идеологы И. Гаспринский үзе дә Вольтерның биографиясе белән Әхмәт Мидхәтнең «Вольтер егерме яшендә яхуд элк мушакасы (беренче мәхәббәте)» язмасы аша танышалар. 1883 елда ул китап булып та басыла. Ә. Мидхәт аны француз әдибенең Мадмуазель де Новерьега юллаган гыйшык хатларына тәфсир рәвешендә яза.

Ни өчен Ә. Мидхәт нәкъ менә Вольтер идеяләрен пропагандалау, аның әсәрләрен тәрҗемә итү белән шөгыльләнә? Әлбәттә, эш, беренче чиратта, максатлар уртаклыгында.

Ә. Мидхәт төрле сәяси карашлы мәгърифәтчеләрнең язганнары белән таныша һәм һәрберсеннән шул чорда Төркия өчен мөһим дип саналган унай сыйфатларны ала. Әйтик, Руссо халыкның иң демократик катламнары тормышын яхшыртуны күздә тотса, Вольтер һәм Монтескье урталык сәясәтендәге мәгърифәтчеләр санала.

Вольтер янача уйлаучы тулы бер яшь буынны тәрбияли, аны мәгърифәтчеләрнең «укытучысы» дип саныйлар, хәтта шул ук Руссо да Вольтер язган бер генә нәрсәнең дә игътибардан читтә калмавын әйтә.

Алда Ф. Кәримидән китерелгән өзекләрдә без аның да әлеге ике философны башкалардан аерып алганын күргән идек. Бу исә, үз чиратында,

ике тугандаш халыкта да үзгәрешләр чорында бер үк акыл ияләренең укылуын, өйрәнелүен күрсәтә.

Әхмәт Мидхәт белән шәхси дус булган һәм аның «Тәрҗемани хакыйкать» газетасына охшаш вакытлы матбугат органы чыгарган И. Гаспринский төрек әдибен тугандаш халыкларга якынайтуда зур эш башкара. Ф. Кәрими, Р. Фәхретдинов кебек татар укымышлылыры да Ә. Мидхәтне якыннан беләләр һәм аларның иҗади ярдәмләшүе турындагы фактлар төрек-татар әдәби бәйләнешләренең берьяклы гына булмавын сөйли.

Р. Фәхретдиновның татар-төрек әдәби бәйләнешләрен тасвирлаган «Әхмәт Мидхәт» брошюрасы—аеруча кыйммәтле документлардан. Каләм әһлебез, төрек әдәби бәйләнешләрнең ерак тарихын күздән кичергәннән соң, түбәндәге сүзләрне яза: «Төркиядә булган соңгы галимнәрдән Русия мөселманнары арасында зур шөһрәт табучылар Әхмәт Мидхәт әфәнде илә Шәмсетдин Сами булса кирәк. Моннарның өченче барлыгы мәгълүм түгел. Әбүл Зыя Тәүфикъ, мөгаллим Нажи Кәбиләр исеме икенче вә өченче дәрәҗәдә булырга тиешле». *(Фәхретдинов Р. Әхмәт Мидхәт.—Оренбург: Вакыт, 1913.—120 бит.)*

Р. Фәхретдинов беренче ике әдипне янәшә куйса да, хәтта Ш. Сами эшчәнлегенең дә Ә. Мидхәтнекеннән түбәнрәктә торуын әйтә. Бу хезмәттә ул Фатих Кәрими белән Әхмәт Мидхәт арасында барган хат алышу, Ф. Кәриминең, Әхмәт Мидхәтне таныштыру өчен махсус рәвештә, төрекчәгә әсәрләр тәрҗемә итүен яза. Аларны барлау да төрек-татар әдәби бәйләнешләрынын икеяклылыгын күрсәтүдә зур бер эш булыр иде. Ә. Мидхәт белән башка татар укымышлылары да бәйләнештә торган. Бертуган Рәмиевләр ул чыгарган «Тәрҗеман әл-хакыйкать» газетасын алдырганнар.

Бездә Ә. Мидхәткә кагылышлы шактый гына әдәби-тарихи материаллар сакланып калган. Мәскәү һәм Санкт-Петербург китапханәләрендә аның теләсә кайсы әсәрен диярлек табарга мөмкин. Белгәнебезчә, аларның шактые Казаннан күчерелгән.

Р. Фәхретдинов Ә. Мидхәтнең ни өчен шул дәрәҗәдә популяр булуы, күпчелекнең карашларын кыйбла итүе турында уйлана һәм аның сәбәпләре—халыкның барлык катламнары өчен язуда, «Бөтен әдәбиятлары дин бәхәсләреннән читкә чыга алган Руссия мөселманнары өчен олуг бер галим булуында» *(Фәхретдинов Р. Әхмәт Мидхәт.—Оренбург: Вакыт, 1913, 1913.—120 бит.)* дигән нәтиҗәгә килә. Болардан Ә. Мидхәтнең, беренче чиратта, мәгърифәтче язучы буларак танылуы аңлашыла. Руханилар катламыннан чыккан бу каләм әһленең әдәбиятка мөнәсәбәтле фикерләре, аңа бәяләмәсе үзенчәлекле булуы, кыюлыгы белән шаккаттыра.

Күп кенә язучыларның әдәби мирасы Ә. Мидхәт язганнарны уку тәэсирендә туганлыкны Риза Фәхретдиновның «Моның әсәрләре яшьлек вакытымызның ядкарьләре булдыгыннан, катымызда аерым хөрмәтләре вә күнелемезнең ин тирән йирендә махсус урыннар бар» *(Шунда ук.—45 бит.)* сүзләре дә раслый.

Төрек әдәбиятында барган әдәби процессны дөрес күзәллаган Р. Фәхретдинов Ә. Мидхәтнең үз халкына кылган хезмәтен Толстойның рус дөньясына эшләгәннәре белән чагыштыра. Рус классигы кебек үк, иҗаты белән халыкка хезмәт итүне күз алдында тоткан төрек язучысы күп язуда, тиз язуда, милләтпәрвәрлектә аннан да алда тора иде дигән фикергә килә.

«... ихтимал ки, Ә. Мидхәт әфәнде, әсәрләренең кыйммәте, игътибары илә түбән булса булыр», «Толстойны Толстой итүче вә шөһрәтене дә читләргә җибәрүче нәрсә: Толстойдан бигрәк, мохит, мәмләкәт, әмсал вә әкрам, вә кавем, вә кабиләдер»,—ди ул. *(Шунда ук.—45 бит.)*

Р. Фәхретдинов әлеге сүзләре белән Көнбатыш әдәбиятына ияреп язуның максаты—осталыкта ярышу булмыйча, ә үз халкына тәэсир итүдә икәнлекне күрсәтә. Икенче төрле әйткәндә, ул Ә. Мидхәтнең Көнбатыш әдәбиятлардан, беренче чиратта, тема, фикер алганлыгына игътибар итә.

Әхмәт Мидхәтнең үлеме уңаеннан «Йолдыз» газетасының 23 декабрьдә чыккан мәкаләдән түбәндәге юлларны китереп узасы килә: «Бу галим әфәнде беренче галим улмаклыгы илә бәрабәр төрекләрнең беренче әдибе вә мөселманнарның беренче философы иде. Төркиядә иң элек әхлакый вә милли роман язучы бу иде. Аурупа телләреннән фәнни вә фәлсәфи әсәрләрне тәрҗемә кылуда да бу беренче иде. Бу затның тәэлиф (ияреп язылган) вә тәрҗемә тарихына тәртип иткән әсәрләре йөздән зыядәдер (артыктыр)».

Шушы ук газетаның 1912 ел 25 декабрь санында Тәкый Бәдигъ Русиядә Әхмәт Мидхәт исемен ишетмәгән кешенен азлыгын, үз вакытында зур шөһрәт тапкан «Җәллад» романын укыганнарның да барлыгын әйтә. Аны шулай ук Толстой белән чагыштыра. Анын христианнар арасында тоткан урынын Ә. Мидхәтнен ислам галәмендә билгәненә тин күрә һәм рус әдибенә зур игътибар күрсәткән татар матбугаты үз кешесенә тагын да кин күнеллерәк булыр дип өметләнә. Зыялы кешеләрнен күпчелегенә анын йогынтысы бар дип саный.

Әхмәт Мидхәт 1912 елның 15 декабрендә Истанбулда үлә. Аның белән бөтен төрки халыклар хушлаша. Татар зыялылары исеменнән Г. Камал барып житкәнче, аны иң мәртәбәле урынга жирләгән булалар инде *(«Йолдыз», 912 ел, 23 декабрь).* Шулай да жирләү вакытында күбесенчә шәкертләр катнашканны, олы затларның нибары егерме-егерме бишкә генә жыйналуын күргән әдибебез бу хакта «Мәрхүм Әхмәт Мидхәт әфәнде» мәкаләсендә бик үкенеч белән түбәндәге юлларны бастыра: «Әгәр Мидхәт әфәнде шикелле бөек бер зат вафат итсә, башка милләтләр дөньяны кубарырлар, женазасына ничә вә ничә мен халык жыелыр иде. Төрекләрнен бундый иң газизә бер кешеләренә бу рәвешчә илтифатсыз кыйланулары шаян тәәссефтер (кызганurга лаектыр)».

Г. Камал мондый хәлләрнен төрки дөнья өчен гадәтилеген әйтә һәм, күптән түгел генә вафат булган, гыйлемлелегенә Төркиядә тиңнәр булмаган иң зур мөгаллим Монастырлы Исмәгыйль Хаккый күмелгәндә дә, бары тик якыннары гына катнашуны әйтә.

Без алдагы сәхифәләрдә китергән мисаллардан тыш та, татар әдәбиятында Әхмәт Мидхәттән тәржемәләр бар. Болар: С. Максуди башкарган «Яшьлек—җүләрлек» (1897) һәм татарчалаштыручысы аталмыйча, Садыйк ибн Габдрахман дип редакторы гына күрсәтелгән «Яшь егетләр өчен гаять файдалы бер кинәш» (1902) һ. б. 1904 елда Харитовнов матбагасы тәкъдим иткән китаплар арасында гына да анын 5 әсәре аталган: «Әпипә ханым», «Хыял вә хакыйкать», «Дәрдәнә ханым», «Кыйссадан хисса», «Папастагы әсрар».

В. А. Гордлевскийның әйтүенә караганда, тумышы белән черкес булган Әхмәт Мидхәт ижатында безнең өчен ятрак сюжетлар да бар, әлбәттә. Ул инде анын әсәр исемнәрендә үк чагыла. Кайвакыт французча киенгән, зыялы тормыш кичергән геройлары да һәрвакыт татар кешесенә якын тоелмыйдыр, әмма ул уздырган фикерләр, ул ижат иткән тел—гасыр башы укучысы өчен аңлаешлы, якын, кирәк.

Р. Фәхретдинов, бик хаклы рәвештә, Ә. Мидхәтнең татар әдәбиятына тәэсире кыска жөмләләр, ачык тел белән, гыйбрәтле, укырга күнелле итеп язуда дип билгели. Чыннан да, анын санап кителгән тәржемәләренә нәкъ шундый сыйфатлар хас.

Сәяхәтнамә жанры Әхмәт Мидхәт ижатын да читләп үтми. Татар укучысына анын «Аурупага бер сәяхәт» китабы таныш була. XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында үз язучыларыбыз да сәяхәтнамә жанрында актив эшлиләр. Ф. Кәрими, Р. Фәхретдинов һәм төрекләрнен көчле әдәби тәэсирен тойган Заһир Бигиевләр мирасында моңа мисаллар бар. Ф. Кәримнең шул жанрдагы язмасы хәтта исеме белән дә Ә. Мидхәтнекенә аваздаш: «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902).

Х. Кәмилев «Хәзерге төрек прозасының чишмә башында» («У истоков современной турецкой прозы») китабында Ә. Мидхәтнен публицистик әсәрләрендә дә, нәфис әдәбиятында да көнбатыш мәдәниятне пропагандалавын, халыкнын культура дәрәжәсен күтәрергә омтылуын яза.

«Ул феодал искелеккә каршы көрәште, калимчеләрне көлкегә калдырды. Хатын-кызны, анын гаиләдәге һәм жәмгыятьтәге феодал искелек калдыклары зынжырыннан коткаруны яклап чыгышлар ясады. Хатын-кызларны Ә. Мидхәт һәрвакыт зур теләктәшлек белән, аларнын фажигале язмышына игътибар жәлеп итәргә тырышып сурәтләде»—ди. *(Кямилев Х. У истоков современной турецкой прозы.—М.: Наука, 1967.—С. 106.)*

Ә. Мидхәт ижатына хас әлеге сыйфатлар ике гасыр чигендә әдәбият мәйданын тоткан татар каләм ияләрендә дә күренә. Р. Фәхретдиновның «Әсма яки гамәл вә жәза» әсәрен укыганда да, без героиняны көчле кызгану тойгылары кичерәбез.

Әхмәт Мидхәт ижат иткән геройлар еш кына француз телендә яхшы сөйләшә, төрле философлар язганнардан хәбәрдар. Ф. Кәрими ижатында да геройны шул рәвешчә ижат итүгә юлыгабыз. «Салих бабайнын өйләнүе» (1897)

хикәясендә челем тартып, бакча каравыллап утыручы гына булган Салих бабай француз язучыларының әсәрләре, фикерләре белән таныш. «Нуретдин хәлфә»сендә (1900) янача укытуның искечәдән нәрсә белән аерылганлыгын да аңлый алмаган хәлфә төрле фәлсәфи терминнар белән эш итә, танылган философларның карашларына үз мөнәсәбәтен белдерә.

Ә. Мидхәт карашларын кабул итмәгән, әмма иҗатына кагылышлы трактат чыгарган Шопенһауэрның исемен дә юлыгабыз без «Нуретдин хәлфә»дә. Әлеге философ һәр теләк, өмет газап алып килә, аларның үтәлүе исә яңадан-яңа өметләр, шулай булгач, газаплар чыганагы тудыра дип санаган. Аның этикасының нигезендә антропологик пессимизм яткан. Ул хәрәкәтсезлеккә, нирванага чакырган.

Инде «Нуретдин хәлфә»дән аерым юлларны укыйк: «Дөнья—өмид дөньясыдыр. Бу кадәр авыр мәшәкатьләргә вә мөмкин зәхмәтләргә адәмнен түзеп торуы ялгыз өмид саясендәдер. Өмид вә тәхәййил иткән бер нәрсәсенә житешер өчен, бичара инсан нә кадәр зәхмәтләргә тәхәммел итәдер.

«Дөнья—бер жәһәннәмдер, гакыйл (лы—Р. Х.) өчен анда яшәмәк лаек түгелдер»,—дигән Шопенһауэр кеби философлар бар исә дә, бәрәкәт бирсен ки, бонлар бәк аздыр. Инсаннарның күбесе дөньяда яшәмәк вә мөмкин мәртәбәдә чук яшәмәк тарафындадыр.» *(Кәрими Ф. Морза кызы Фатыйма.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1996.—78 бит.)*

Әсәр башында Шопенһауэрның әйткәннәрен кабул итеп тә, тормыш бәхетеннән, димәк, газапларыннан да ваз кичәргә теләмәгән Нуретдин финалда, бер теләгенә дә ирешмәгәч, аның хаклыгын танырга мәжбүр була. Язучы, шулай итеп, геройның фикердә тотрыксызлыгын күрсәтә. Иҗатында хәрәкәт кешеләрен тасвирлаучы Ф. Кәриминең үзе өчен дә Шопенһауэр фәлсәфәсе таяныч була алмый.

Китапларны теләгәнчә бастырырга мөмкинлекләр аз, дөньяви фәннәргә нигез генә салынып килгән бу унъеллыкта һәрбер әсәрне публицистик максатларда кулланып калырга омтылу төрек һәм татар язучыларның күпчелегенә хас була.

Күргәнебезчә, Ә. Мидхәт исеме татар-төрек бәйләнешләре тарихында төп урынны алып тора. Әлбәттә, XIX гасырның икенче яртысы төрек әдәбиятын татар укучысы аның иҗаты аркылы гына күзаллаган, дисәк тә, хата булыр. Ана Мехмет Рәүф, Т. Фикрәт, Х. З. Ушаклыгөл һәм башкаларның иҗаты да яхшы таныш булган.

Х. З. Ушаклыгөл төрек әдәбиятында атаклы новеллачы буларак үз урынын алган. Сами Паша, Әхмәт Мидхәт башлаган традицияләрне дәвам итеп, ул бу жанрны идея-сәнгати яктан тагын бер баскычка югарырак күтәрә.

Х. З. Ушаклыгөлнең кечкенә күләмле әсәрләре үзәгендә, гадәттә, нинди дә булса бер сәбәп аркасында сөеклесенә бәйле хыяллары чынга ашмаган герой тора. Аларда эротика белән хыялланган яшь егетне дә (шунда ук Гаяз Исхакыйның аерым әсәрләре искә төшә) мәхәббәттә үзе теләгәнгә ирешмәгән яисә күңел кичерешләренә артык бирелгән, хисләре яшь булып аккан сентименталь гашыйкны да очратасың.

Ике гасыр чигендәге унъеллыкта иҗат ителгән әсәрләр арасында Ф. Кәриминең «Каенана» хикәясе бар. Ул, хатлар формасында язылуы, бай һәм байбичәләрнең икейөзлелеген, гаиләдә, каенана аркасында төрле авырлыкларга төшкән килен образын ачуы белән, Х. З. Ушаклыгөлнең «Язылып бетмәгән дәфтәрдән»енә охшаш.

Язучы урнаштырган керештән үк әсәрнең сентименталь рухы, иҗтимагый тормышта зур әһәмияткә ия булмаганлыгы аңлашыла. Чынлыкта да, хикәянең башы, уртасы үтә хисчән, тойгылы җөмләләрдән генә тора диярлек.

Х. З. Ушаклыгөлдән китерелгән мисалда киленнең рухи тормышын каенана бозарга тиеш түгеллек, кешенең үзен гаиләдә иркен итеп тоярга хокукы барлык ассызыклана. Ата-ананың табаны астында яшәүче ир тормышта мөстәкыйльлеккә, димәк, бәхеткә дә ия булмый дигән фикер уздырыла. Вакыйгалар каенана алып барган көндәлек рәвешендә бирелә.

Ф. Кәриминең әсәре исә Зөһрә һәм аның ире арасында барган хатлар буларак оеша, һәм аны татар әдәбиятында эпистоляр жанр формалашуга нигез биргән хикәя дип тә санап була. Реформалар заманы төрек әдәбиятында да эпистоляр жанрдагы әсәрләр шактый була. Алар арасында героиняның тирән кичерешләре күрсәтелгән «Хатын-кыз фәлсәфәсе» бар. Аның авторы булган Ә. Мидхәт шулай ук гаиләдәге хокуксызлыкка, рәнҗетелүләргә каршы чыга.

Бу әдәби үрнәкләр гаилә бәхетенең күпчелек очракта хатын-кызның үзенә, аның холкына бәйлеген күрсәтәләр, алар тирән психологизм белән язылганнар. Төрек әдәбиятына тәкълид рәвешендәге Ф. Кәрими хикәясендә каенана-килен конфликты бик гади юл белән хәл ителә.

Х. З. Ушаклыгәл әсәрләрендә финал укучы көтмәгәнчә була. Әйтик, «Алданган» хикәясе. Хатыны ял итәргә киткән җирдән хәбәр алган ир, хатны ачып та тормастан, аның эчтәлеген фаразларга керешә. Авыру хатыны үлгәндер дип уйлап, яшь, чибәр кәләш алу турында хыяллана башлый. Төрле планнар корып бетергәч кенә, хатны ачып укыса, аптырашта кала: хатыны сәламәтләнгән һәм кайтырга тора икән.

Гаяз Исхакыйның «Көтелгән бикәч»е дә әлеге әсәргә күп ягы белән тартым, шулай да без сүз алып бара торган чорыбыздан Ф. Кәриминең 1900 елда язган «Нуретдин хәлфә»сен искә төшерик. Героеннан үтергеч көлү алымы белән, ул югарыда сөйләнгән хикәягә аеруча аваздаш.

Нуретдин хәлфә, Гайнетдинов исемле кешеләрнең бик тә чибәр кызлары белән башкорт ягына ял итәргә киләчәкләрен алдагы елда ук белешкәннән соң, кызның атасын үз ягына—кадимчелеккә аударырга, инде булмаса, өйләнү һәм баю бәрабәренә үзе җәдидчелеккә күчәргә уйлап, шулай ук «кымызга бара».

Зур хыяллар белән йөргән хәлфәне яшен суккандай була: ни гомерләр ана хатын булыр дип исәпләгән кыз тарантастан ире белән төшә. Наданлыгына да карамастан, мәгърифәт, галим-голәмә, танылган китаплар турында зур фикерләр йөртеп яшәгән Нуретдин хәлфәнең бушкуыклыгы гади бер тормыш вакыйгасы аша күренә.

Ф. Кәрими иҗатында новелла жанрындагы әсәр булуга бары тик төрек яисә француз әдәбияты гына йогынты ясамаган, билгеле. Хикәянең буеннан-буена Гогольгә хас шаярту, кечкенә кеше хисләре белән уйнау күренеп тора. Гомумән, бу чорда иҗат ителгән оригинал әсәрләрнең кайсысын гына алып тикшерсәң дә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш йогынтыларының һәр икесен сизәсең. Аерым бер китапны шушы тәэсир нәтиҗәсендә туган дип кистереп әйтү дә кыен. Җитмәсә, рус, төрек әдәбиятларының үзләренең дә таянган нокталары—бер.

Гадәттә, каләм ияләре табигатьтән килгән талантларын ачарлык үрнәк иҗатларны өйрәнәләр, әсәрләрнең үз зәвыкларына туры килерлекләрен сайлыйлар. Бер үк ихтыяҗларны төрле мәдәниятләр аркылы канәгатьләндерә алу да язучыга берьюлы төрле әдәбият йогынтысы булуга китерә. Ф. Кәриминең «Европа сәяхәтнамәсе»н уку гына да бу чорда галим-голәмәнең (алар ук—язучы да!) бөтен дөнья фәннәреннән, фәлсәфәләреннән, тарихлардан, шәхеслә̣рдән һәм башка бик күп нәрсәләрдән искиткеч, хәтта ки бүгенге көн кешесе кызыгып карарлык хәбәрдар булуларын раслый.

Бу унъеллыкта язылган әсәрләрне укып кына да, рус һәм төрек әдәбиятларының үзләрендә дә охшаш процесслар баруын күрә алабыз. Әйтик, ике әдәбиятта да чит ил, аеруча инглиз, француз эстетик һәм фәлсәфи фикерен өйрәнү көчәя. Шулардан Жан-Жак Руссо, Шатобриан, В. Гюго, Шекспир, Мольер, Дарвин, Вольтер, Карнель, Расинга игътибар бигрәк тә зур. Төрекләрдә дә, русларда да болар хакында дистәләгән китаплар басыла. Ул исемнәр әледән-әле, берәмтекләп яисә күпләп безнең әсәрләребездә дә күренә.

Татарлар арасында төрле фәлсәфә агымнары формалашуда үз язучыларыбызның хикәя, романнары һәм педагогик, иҗтимагый, дини эчтәлекле трактатлары ныклап тарала башлау да зур роль уйный. Әмма 1905 елга кадәр басылган татарча әсәрләрдә дә, мәкаләләрдә дә нинди дә булса концепцияләрне бөтен тулылыгы белән чагылдыру күренми әле. Милләт өчен максатчан, үз юлы белән эшләүчеләр арасында бу чорда Рәшит казый аерылып тора, ул хәтта рус хөкүмәтен куркуга салырлык хезмәтләр дә бастыра.

Төрек-татар әдәби бәйләнешләре әдәбиятыбызга алып килгән сыйфат үзгәрешләрен тикшерүдән чыгып, бу бәйләнешләр берьяклы гына икән дип нәтиҗә ясау хата булыр. Татар зыялылары үзләре дә төрекләрне рус әдәбияты белән таныштыруга зур көч куйганнар. Казан шәһәр башлыгының хатыны О. С. Лебедева (Гөлнар ханым) татарча яхшы гына аралаша, һәм ул, Стокгольм ориенталистлар конгрессына баргач, Ә. Мидхәт белән таныша, ана русчадан тәрҗемәләр вәгъдә итә. Аның тырышлыгы аркасында, төрек-татар телендә Пушкин,

Лермонтов, Толстой әсәрләре дөнья күрә. Гөлнар ханым төрекләр өчен рус әдәбиятының кыскача махсус тарихын да төзи. Соңрак төрекләрне рус әдәбияты белән таныштыру эшен татар-кавказ эмиграциясе вәкилләре дәвам итә.

Русларны төрек әдәбияты белән таныштыруда татарларның да билгеле бер өлеше бар. «Төрек җыентыгы. Якын Көнчыгыштагы хәлләргә» (1909) дигән китапта кайбер әсәрләр Казан татарлары тарафыннан тәрҗемә ителгән.

1905 елдан соң да төрек әдәбиятыннан күп кенә әсәрләр татарчалаштырыла. Беренчедән, матбугат иреге алу да мөмкинлекне зурайта, икенчедән, революциядән соң да үз китапларыбызның азлыгы аны башка әдәбиятлар хисабына баету зарурлыгын тудыра (ә төрек әдәбиятыннан тәрҗемә итү кыен булмый) өченчедән, мәгърифәтчелек реализмыннан үзгә алым белән язылган әсәрләргә күчү процессы билгеле бер вакыт таләп итә.

Ә без күзәтә торган чорда Ә. Мидхәт иҗатына күбрәк игътибар биреп, революциядән соң аны арткырак планга күчерү, сәнгати осталык ягыннан югарырак торган, импрессионистик алымнарга бай, субъектив-психологик сурәтләрне еш кулланган Х. З. Ушаклыгөл, И. Шинаси, Т. Фикрәт әсәрләренә күбрәк мөрәҗәгать итү белән аңлашыла.

Төрек әдәбиятының шифалы йогынтысы татар әдәбиятында новелла жанрын тагын да бер баскычка күтәргән Шәриф Камал иҗатында аеруча нык күренә. Шәриф Камал новеллаларының чишмә башында Ф. Кәриминең «Нуретдин хәлфә»се тора дисәк тә, һич тә ялгышмабыз.

Төрекләрдә дөнья күргән әсәрләрнекенә охшаш исемнәр белән бу уңъеллыкта бер-бер артлы татарча китаплар чыккан. Аларның күп вакыт идея эчтәлеге дә якын янсә бердәй икәнлекне дә әйтеп узарга кирәктер. Мисалга Н. Назыйминың «Бәхетсез кыз»ы (1886) белән Х. З. Ушаклыгөлнең «Бәхетсез» 1893) әсәрләренә охшаш Фатих Халидиның һәм Закир Һадиның мәгълүм повестьларын китереп булыр иде.

Гаяз Исхакый да үзенең автобиографик повестена Х. З. Ушаклыгөлнең «Тормышмы бу?» әсәренең атамасын куя. Х. Гюрпынарның 1897 елда «Гыйффәт» исемле китабы чыкса, Р. Фәхретдинов 1899 елда «Сәлимә яки гыйффәт»не бастыра. Мондый мисаллар байтак.

Аннан соңгы елларда да бу күренеш дәвам итә, татар китапларында төрек әдәбияты үрнәкләренең исемнәре кабатлану еш очрый: «... Мәрхүмнең дәфтәреннән» (Г. Ибраһимов)—«Бер үленең дәфтәре» (Х. З. Ушаклыгөл), «Хыял вә хакыйкать» (Ә. Мидхәт)—«Хыялмы, хакыйкатьме?» (Ф. Кәрими), «Уяну» *(Н. Кәмал һәм Ш. Камал)*.

Төрек-татар әдәби бәйләнешләре турында сүз йөрткәндә, боларны да искә алмый булмый, чөнки, әйткәнебезчә, тәрҗемә әсәрләр беренче тәэсирдән соңрак барлыкка килә һәм шул тәэсирне тагын да көчәйтә.

Р. К. Ганиева төрек әдәбиятының Г. Ибраһимов, Н. Думави һәм башкаларга да зур йогынты ясавын яза. *(Ганиева Р. К. Көнчыгыш традицияләрен үстереп // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т. 3. (Баш ред.: Юзиев Н. Г.).—Казан: тат. Кит. Нәшр., 1986.—523-538 бит.)*

Төрек әсәрләре, тәрҗемәләре, аларга урнаштырылган кереш сүзләр аша әдәбият теориясеннән дә шактый мәгълүмат кергәнлеген онытырга ярамый. Бу, үз чиратында, әдәбиятны һәм ана хезмәт итүче фәннәрне үстерергә булыша.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: 1895—1905 елларда да төрек-татар бәйләнешләре нык була, танылган татар әдипләре әле һаман төрек әдәбиятын башка төрки халыкларныкыннан һәм моңа кадәр үрнәк иткән фарсы-гарәп телендәге мирастан шактый өстен саныйлар, аның аша көнбатыш мәдәниятқә якынаю мөмкинлеген аңлыйлар.

*Юмор һәм сатира*

## Тәлгат Нәҗмиев

# ХИКМӘТЛЕ ХӘЛЛӘР

### Урындыклы конферансье

Икенче класста укыганда Дәрҗия Аппакованың «Туган тел» китабындагы «Минем атым» дигән шигырен смотрда сөйләп, район сәхнәсенә үттем. Анда Мактау грамотасы һәм китап белән бүләкләнеп, сабый күңелем күтәрелеп-дәртләнеп китте...

—Юмористик шигырьләр кулай икән сиңа,—диделәр тәүге укытучым Дания апа Фәләхова белән өлкән пионервожатый Саимә апа.

Менә шуннан соң бәйрәм саен сәхнәгә менә башладым, мәзәкләр дә сөйләштергәлим. Авыл мәдәният йорты директоры, нәфис сүз остасы Мөдәррис абый Фәсхетдинов белән (ул озын гәүдәле иде) парлы конферансье ясап, хәйран тамашачыларны таң калдырдык. Кукмара, Вятские Поляны, Красные Поляны, Сосновка, Можга кебек җирләрдә концертлар бирдек. Красные Полянудан кайткач, бер сәбәпсез көн буе еладым да әле. Күз тигән, диделәр.

Өлкән классларда концерт белән үзебез аерым йөри башладык, район күләмендәге нәфис сүз осталары смотрларыннан да калдырмадылар. Ә инде сигезенче классны тәмамлагач, танылган баянчы Илдар Нургалиев гастрольләргә алып чыгып китте. «Профессиональ әртис» буларак, 1967 елда Саба районы авылларында кәмит күрсәтеп йөрдек. Кәмит, дип шуңа әйтәм, арабызда караим милләтеннән (бәлки, халык төркемедер) булган Михаил Романович Пармет дигән житмеш яшьлек фокусчы бар иде. Без, дүрт кеше, беренче бүлектә концерт куябыз, ул тәнәфестән соң сәгать ярым могҗизалар күрсәтә, авызыннан ут чыгара. Берүзе генә түгел инде анысы. Михаил дәдәй халыкны алдаганда Илдар баянда уйнап тора, мин фокус күрсәтә торган яшерен әйберләрен чыгарып-алып кереп торам. Үзе сәхнәдә вакытта серле җирләрен тикшерәм.

Бабайның «багажы» җиде кисәк сумка-чемоданнан тора иде. Бүлешеп күтәреп йөрибез. Миңа, кечкенә булгач, читлек белән тере күгәрченнәр тоттырдылар. Икенче кулымда—үземнең «чумадан», аркадагы рюкзакта фокусчының чүпрәк-чапраклары... Менә шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов язганча, бик түбәннән күтәрелдек инде без...

1 сентябрь килеп терәлгәч, яшьли бозылам, аттестатсыз да калам, ахыры, дип тирәнтен акыл белән уйлап, авылыбызның IX классында укуны дәвам итәргә булдым. Әле парта алган көнне дә Иштуганда соңгы концертны бирдек.

... Чир китә, гадәт китми, диләр бит. Мәктәптә оештырган концерт бригадасы белән тимер юл буйлап гастрольләргә йөри башладык. Шәмәрдән промкомбинаты «Кызыл почмагы»нда концерт беткәч, ул вакыттагы клуб мөдире, искиткеч талант иясе (рәссам, баянчы, җырчы, скетчларны үзе

язып сәхнәгә куючы, шаян биюләр башкаручы) Виль Гарипов яныма килеп: «Безнең бик көчле коллектив бар. Әйбәт конферансье кирәк. Шимбәякшәмбегә килеп алырмын авылыңнан, әйдә, безнең концертларны алып бар әле»,—диде бу. Ризалаштым, бушка түгел бит! Бушка сызлавык кына чыга.

Кыш көне йөреп тордым да, җәй көне Виль үзе урынына клуб мөдире итеп урнаштырды. Аннары Саба, Арча, Балтач, Кукмара районнарына инләп-буйлап йөри башладык. Концертка халык су кебек агыла иде.

—Хәзер сәхнәгә иң яшь, иң кечкенә җырчыбыз Эльбрус Сибгатуллин чыга,—дип игълан итәм. Мәһабәт гәүдәле, Әлмәндәр карт әйтмешли, гүәрдин кебек кеше күренгәч, тамашачы иләсләнеп кул чаба башлый. Җырның исемен әйтү өчен янына барып басам Эльбрус абыйның (исеме дә туры килеп тора бит). Теге миңа таба бөгелми. Ә мин—аның нәкъ пиджак кесәсе белән тигез.

Иптәш Сибгатуллин алга карап, шундый горур итеп басып тора. Мин нишлим инде? Сәхнә артына кереп китәм дә, урындык алып чыгып, җырчы янәшәсенә куям. Менеп баскач, тигезләнә язабыз тагын. Шуннан соң ул җырның исемен әйтә, мин, үз чиратымда, тамашачыга җиткерәм:

—«Солдатлар». Роберт Әхмәтҗанов сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы...

Шуннан җайлап кына төшеп, урындыгым белән кереп китәм. Шәп җырлый иде Эльбрус Һидиятович. Гәүдә дә, моң да, чибәрлек тә бар. Раббым җыеп биргән.

Җыр бетәр-бетмәс алкышлар яңгырый башлый. Сәхнә читеннән урындык өстерәгән конферансье янә күренә. Алкышлар тагын да көчәя. Кемгә ул? Җырчыгамы? Әллә азапланып йөргән минамы?

Өч-дүрт җыр башкарганнан соң, халык ишетерлек итеп:

—Шушысын җырла да кер! Мин һаман урындык күтәреп йөрмәм,—дип тә җибәрәм. Бер очтан колагына җиде бабасын искә төшереп сүгенгәндәй итеп авыз кыймылдаткан булам... Тагын алкышлар...

* * *

Без Арча районының Сеже авылында чыгыш ясаганда булачак җәмәгатем Лемара Фатыйхова, укучы бала буларак, концертыбызны укытучылардан кача-поса мич арасыннан караган. Урындыкта басып торучы шушы «сәхнә йолдызы» белән гомер итәсе булыр, дип башына да китермәгәндер ул вакытта.

Нишләмәк кирәк, язмышны, күрәчәге шулай булгандыр инде...

## Кыз-әбиләр

2001 ел башында Татарстан Матбугат министрлыгы, «Татарстан хатын-кызлары» һәм «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясе бергәләп «Кыз-әбиләр» дигән китап чыгардылар. Китап танылган журналистлар Исмәгыйль Шәрәфиев һәм Риман Гыйлемханов мөхәррирлегендә дөнья күрде. Ул сугыш китергән авырлыкларга чыдап-түзеп, ил-көн өчен сәламәтлекләрен, яшьлекләрен, бәхетләрен корбан итеп, бер дә кияүгә чыкмый калган газиз җаннар—кыз-әбиләргә багышланды.

Шул китапларга мәгълүматлар туплаган көннәрдә «Татарстан яшьләре» газетасы хезмәткәрләре, үзләре әйтмешли, «көтүләре» белән Сабага килделәр, хезмәт коллективларында, мәктәптә, район китапханәсендә, редакциядә булдылар. Саба урман хуҗалыгыннан бер күмәк хуҗалыкка килдек тә:

—Риман кайда?—дип сорашабыз.

—Кыз-әбидән интервью ала,—диде хуҗалык рәисе.—Шулай, Тәлгат абый, бу заманда кыз-әби табу җиңел түгел ул,—дип, бик зур эш кыргандай, мактанып куйды.

Минә Риман кайтып төште.

—Шундый матур итеп сәгатьтән артык сөйләшеп утырган идек. Ни кызганыч, саубуллашыр алдыннан гына әбием: «Улым, мин бер атна гына кияүдә булган идем шул», дип әйтеп куймасынмы...—диде ул күңелендәге үкенү хисләрен басарга теләп.

Кыскасы, китап бик матур нәшер ителде. Шушы изге эш гамәлгә ашып, бераз вакыт узганнан соң, «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясенә—Риман янына сугылган идем.

—Китап та чыкты, кушамат та тагылды,—диде ул.

—Нинди?—дип сорадым.

—Әйтмим. Язасың,—диде Риман, матур итеп елмаеп. Аннары түзмәде, барыбер әйтте:—«Гинеколог»...

## Могҗиза

Дөньяның әчесен-төчесен, рәхәт мизгелләрен күреп, бакыйлыкка күчкән шәхесләр байтак туган ягыбызда. Шуларның берсе Олыяз авылыннан Гыйльман ага Гайнетдинов, үзен чын хезмәт белән таныта. 1933 елда аны—гади ат карауччыны, колхозчы-ударникларның I Бөтенроссия съездына җибәрәләр. Ворошилов, Буденный кебек командармнар белән фотосурәткә төшеп кайткан делегатны, башта «Правда» колхозы рәисе итеп, курсларда да укып кайткач, Саба районының җир бүлеге (райзо) начальнигы итеп куялар. 72 колхоз белән турыдан-туры җитәкчелек итә башлый. Кирәк булса, хуҗалык җитәкчеләрен алыштыра, ялкынлы чыгышлар ясый, юморны ярата, сүзгә үтә тапкыр була.

Туган авылына Кызыл Мишәнең сарык фермасы мөдирен—Хәсән исемле кешене рәис итеп алып килеп, халык алдына бастыра бу.

—Сезгә—яңа прсидатель. Фермада бик яхшы эшләде,—дип башлый ул.—Әле менә бүген дә без авылны чыкканда колхоз сарыклары барысы берьюлы: «Хәсән кит-мә-ә, Хәсәәән киитмәәә!»—дип кычкырып калдылар.

Сугышка да алмыйлар Гыйльман абзыйны. «Бронь» белән калып тора. Әмма 1942 елның караңгы төнендә ишек шакыйлар аңа. Ватанга каршы корткычлык эшләүдә—атларга корчаңгы йоктыруда, үлемгә юл куюда, чәчүлекләрне чүп үләнгә бастыруда гаепләнә ул. «Халык дошманы»на үлем җәзасы яный. Җиде кешедән торган ишле гаиләсе өйләреннән ташландык мунчага куып чыгарыла. Ярый әле партия райкомының беренче секретаре Сабир ага Шакиров (1938—1947 елларда эшли) ярдәм кулын суза—Плəтән төрмәсеннән судка кайтарылгач азат ителә Гыйльман ага.

Персональ пенсионер Гыйльман ага сиксән яшендә якты дөнья белән бәхилләшә. Әмма гомеренең соңгы көннәренә чаклы юмор хисен югалтмый.

КПСС райкомының беренче секретаре Үзбәк ага Закиров бер килүендә амбарга сугыла һәм шунда Гыйльман аганы очрата.

—Сезне, ударник-колхозчыларның I съезды делегатларын тагын бер җыеп, хөрмәтләргә уйлыйлар,—дия-дия күрешә ул могътәбәр ветеран белән.

—Булыр, булыр,—ди Гыйльман ага.—Теге вакытта да иптәш Сталин Татарстан делегациясен үзенә кунакка чакырды. Карчыгы коймак пешереп ашатты...

Икенче вакытта шул амбар тирәсендә җыелган халыкны авызына каратып, Гыйльман ага болай дип сөйли икән:

—Әле менә Казанга баргач, мясокомбинатка кергән идем. Андагы могҗизаны күрсәгез: сарыклар бер яктан йөгереп кереп китәләр дә икенче яктан колбаса булып чыгалар...

Шыпырт кына оратор-трибун артына килеп баскан колхоз рәисе Абелгаз Дәминов һич көтмәгәндә сүзгә кушыла:

—Гыйльман ага, син бит күреп бетермәгәнсең. Әгәр дә әйбәтләп караган булсаң, аның икенче башыннан колбасаны кертеп җибәрәләр дә башыннан сарыклар йөгереп чыга,—дип әңгәмәне тагын да куертып җибәргән.

## Үзебезнең Әчтерхан

«Бәкер» курортында ләм белән дәвалап та күрсәтәләр инде.

Табигать хәзинәсенең иң олысы—сазлы-торфлы җирдән алынган тиңсез күкертле-водородлы ләм, әлбәттә. Аның белән төреп тә яткыралар, электр белән дә дәвалыйлар, тампон да куялар. Соңгысы простатитка ярдәм итә, диләр. Шуңа күрә көнгә ике тапкыр чират дилбегә буе була.

«Бәкер» курортына простатиттан дәваланырга дип тәүге тапкыр килгән берәү, үгез кебек илле-алтмыш ир-атның шприц белән ләм алырга чират торганын күрде дә, салмак кына итеп:

—Элек «артлары» кычыткан кешеләр Әчтерханга барган, ә хәзер «Бәкер»гә киләләр икән—... дип куйды.

## Кычыткан...

Кычыткан белән бәйле бер кызык хәлне искә төшерик әле. «Матбугат йорты» нәшриятының баш редакторы Азат Низамиев коеп куйган мөхәррир дә, программист-компьютерчы да, сәхнәдә конферансье-пародияче дә, оста итеп скетчлар уйнаучы да, мәҗлестә авызына каратып тора торган тамада да. Кунаклар бераз кәгеп алгач, Азат юри буталган була һәм, Габделфәт Сафинның «Кычыткан чыпчыгы» дигән җырын истә тотып:

—Әйдәгез әле, Габделфәтнең «Чыпчыгы кычыткан»ны җырлыйк әле,—ди икән.

## Алданмыйм, дисәң дә...

Без күрмәгән аз калды, Бохарада таз калды, дип әйтергә ярата иде бер танышым. Читтән торып укып йөргәндә, үзебезнең ничек алданганны да сүз уңаеннан язып китим әле.

Июнь ае. Казан. Матур якшәмбе иртәсе. Сабакташым Газиз Кашапов белән әдәбият галиме—филология фәннәре кандидаты, укытучыбыз Шәйхелислам абый Садретдиновка (1936—1996) керер чыгарга кирәк иде. Бу дөньядан бик иртә киткән—үтә дә тыйнак һәм гади әлеге шәхесне без бик хөрмәт итә идек.

Нигә, дисәгез, Чиләбе шәһәрендә хезмәт итүче кадровый офицер Газиз Кашапов университетка укырга керү тәртипләрен сорап хат яза. Җавапны Шәйхи абый бирә һәм балачактан әдәбият сөйгән кырык бер яшьлек Газизне имтиханга чакыра. Шул көннән бирле алар бер-берсенә бик тә ихтирамлы булдылар.

—Бер нәрсә алып керик инде,—дим.—Буш кул белән керү уңайсыз.

Эзләп киттек. Кибетләрдә фәкать «Каберне» дигән кызыл гына бар. Чын аракының сәгатьләп кенә сатыла торган чагы.

Борынгы Кекин йортына урнашкан гастрономда пәхтә генә киенгән бер ир-ат минем янга килде дә:

—Бырат, зинһар өчен, егерме тиен акча бир әле. Монда минем күрше эшли. Аста ак бар, дүрт сум егерме тиен тора. Менә дүрт сумы,—дип акчасын да күрсәтте бу.

Сөенечемнән ни эшләргә дә белмичә:

—Бирәм, бирәм, дүрт сум кырык тиен итеп бирәм. Миңа да бер ярты ал, дим.

Бик тиз ризалашты бу. Икенче ишектән чыгып таймасын дип, ерактан гына күзәткән кебек итәм үзем. Без дә җүләр түгел бит, читтән торып булса да укып йөрибез әле... Кибетче янына барып басты бу. Теге яңа «дус» нәрсәдер алды...

Шуннан урамга чыктык. Газиз мине читтәрәк көтеп тора иде. Танышым портфеленнән «ак баш»ны минем дипломатка тиз генә шудырды. Олылап рәхмәт әйттем.

... Киттек Шәйхи абыйларга. Ишек төбендә җәмагате Люция апа каршы алды:

—Аракыгыз булса, кермисез, бетте-китте! Кичә дә кунакта булдык. Житте...

Шәйхи абый әкрен генә:

—Юктыр. Якшәмбе көнне каян тапсыннар аны. Булса—бик шәп булыр иде әле,—дип куйды.

Ничек кирәк алай кердек. Газиз белән Люция апа залга чыгып, телевизор куштылар. Без Шәйхи абый белән сөенә-сөенә шешәне ачып, ике рюмкага салдык. Бер-беребезгә елмаеп, ипле генә итеп чәкештердек һәм эчә дә башладык.

Әмма... тәмсезлегенә һәм исенә чыдый алмыйча, ул—миңа, мин аңа сәерсенеп карадык та, туктап калдык.

—Уксус!—диде Шәйхи абый.

Шешәне әйләндерә-әйләндерә карыйбыз. Этикеткасы «Столичная водка»ныкы, ә бөкесе, дөрестән дә, уксусныкы!

Шул аракы язуын уксус шешәсенә ябыштырган икән теге дуңгыз тәре! Сволочь! Авыздан ризык киселде. Шәйхи абый үрдәк түшкәсе кадәр йодрыгын йомарлады да:

—Кайсы кибеттән алдыгыз. Әйдәгез, тагын килер ул. Барып манчыйбыз,—диде...

## Яңа сүзгә—иске җавап

Үз җилкәләрендә күп тәҗрибәләр кичергән булсалар да байтак терлекчеләр яңа сүзләргә башта ияләнә алмадылар. Шуңа күрә кызык хәлләр дә булгалады. «Премикс» дигән сүзне бутап: «Миңа дигән климаксны ник алдың? Үтерәм бит, зараза!»,—дип озын куллы хезмәттәшен сәнәк белән куып йөргән ди бер сыер савучы Тимершык фермасында.

Яңа Мичәндә ике терлекченең мондыйрак әңгәмәсе колакка чалынды.

—И, малай, безнең терлекчеләр йортындагы япон уҗымын (гидропон—автор искәрмәсе) Казаннан килгән бер галим, кайчы белән кисеп, шәһәрдәге мәчесенә алып кайтып киткән. Председателебез Фәрит үзе күргән...

—Әйтмә дә генә инде, малай. Бу колхозга килгән кеше, файдалы дисәләр, җонынны кыркып алып китәргә дә күп сорамас!

Ә инде район шифаханәсеннән ерак булмаган «Урта Саба» ярдәмче хуҗалыгы фермасыннан табибка күренергә кергән сыер савучыдан:

—Иреңнең резусы нинди?,—дип сорагач, шул «фермент», «гидропон», «премикс», соя сөте кебек сүзләр белән буталган хатын әллә нәрсә турында уйлый-уйлый:

—Әй тутырык бала, айныр-айнымас ир, көйсез бием, бер абзар мал... Аны үлчәргә вакытым бармы соң минем?..—дип, табибәне шаккатырган.

## Өч укытучы, бер танкист

Безнең район хакимиятендә белемнәре буенча педагог булган кадрлар байтактан бирле һәм нәтиҗәле эшлиләр. Мәсәлән, башлыкның беренче урынбасары Таһир Шәрәфиев—филолог, халык депутатларының район Советы рәисе урынбасары Нурислам Насыйбуллин белән хакимиятнең аппараты житәкчесе Расих Сабиров—физик-математиклар. Берара районның элеккеге хәрби комиссары Альфред Габдрахманов башлыкның төзелеш, коммуналь-торак хуҗалыгы, транспорт һәм элемтә буенча урынбасары булып эшләп алды.

Рәхимҗан Сабитович хакимият башлыгы итеп билгеләнеп, Арчага ялга кайткач, аппаратта кадрлар белән хәлләр ничегрәк соң, дип сораштыралар икән. Ул күп уйлап тормаган:

—Әллә нәрсә түгел. Өч укытучы да бер танкист анда,—дигән.

## Тагын уку...

Элек номенклатурада торган хезмәткәрләрне югары партия мәктәпләренә җибәреп, белем өстәтеп кайтара торган әйбәт гадәт бар иде. Казанда бер айлык, өч атналык курслар өчен бирелгән «диплом»нарның саны юк, анысы. Ә ераккарак китсәң, бертөрле тормыштан әзрәк аерылып торасың. Минем шәхсән үземә Горький, Саратов һәм Ленинград югары партия мәктәпләрен күрергә туры килде. 1982 елда—без укыганда академик Андрей Сахаров та Горький шәһәрендә иде әле. Саратовта Гагарин космостан төшкән җиргә дә алып бардылар. Ленинградта укыганда, Пушкин шәһәрендәге Петродворецта, хәтта Разливтагы Ленин шалашында булдык.

1989 елда Саратовка кабат барырга кушканнар иде. Житди сәбәп табып, үзем киреләндем. Әллә аяк тартмады, әллә шагыйребез Зөфәр Шәйхетдиновның шаярып язган шигыре сәбәпче булды...

... Укыйбыз да укыйбыз,
Барысын кушып бутыйбыз.
Көннәр буе борын белән
Дәфтәр битен чукыйбыз.
Баш мәтәлә алга да,
Баш мәтәлә артка да.
Тәмле төшләр күрә-күрә,
Кемдер йоклый аркада.
Ак чәчләр төшкән күзгә,
Сакаллар житкән тезгә.
Картаеплар беткәчтеннән
И... уку тагын безгә.

Яшь вакытта (өйләнгәч, улым Нияз тугач инде) Ленинград югары партия мәктәбенә көндезге бүлеккә барырга чынлап торып димләгәннәр иде. Икенче диплом алу модага кергән заман иде бит. Идеология секретаре Марсель Степанович Васильев чакырды да (үзе журналист кеше) житди кыяфәт белән:

—Сезгә район партия комитеты, олы ышаныч күрсәтеп, Ленинградка укырга барырга тәкъдим итә,—диде дә үзеңне анда ничек тоту турында мораль дә укый башлады мәрхүм. —Салсаң, хатын-кыз белән тәртипсез йөрсәң, коммунист исеменә тап төшерсәң, шунда бетәсең, монда кире кайту юк,—дип куркыта ук башлады.

Хатын-кыз мәсьәләсендә алай начар исемем чыкканы булмаса да, бушка булганда төшерә торган гадәт бар иде ул вакытта. Шуна күрә коммунизм төзүченең Мораль кодексын озаклап тыңлыйсым килмәде. Житмәсә, үч иткәндәй, күз алдыма Карл Марксның кирпеч калынлыгы «Капитал»ы килеп басты.

—Марсель Степанович, минем белем житкән инде. Акыл кирәк. Шуны өләшә торган җиргә җибәрегез әле,—дип ялваргандай әйттем.

Башта бик сәерсенеп, ямьсез итеп карап торды ул, әмма әйтер сүз тапмады ахыры, уйлап бетерербез, диде дә бүлмәсеннән чыгарып үк җибәрде һәм... бүтән чакырып, олы ышаныч күрсәтүчесе дә булмады.

# BER RƏSEM TARİXI

«Qazan utları»nıņ 2001 yılğı ikençe sanında «Cəlilneņ bilgesez rəseme» isemle məqələ bastırğan idem (185-186 bitlər). Məqələdə Musa Cəlilneņ Başqortstanda 1930 yılnıņ cəyendə təşkən rəseme turında süz barğan ide. Fotoğa dürtəw təşkənnər: urtada yəş Musa Cəlil basıp tora, anıņ uņ yağında nindider bilgesez ike qız, sul yağında ber yeget utırğan. Alar kemnər? Bəlki, jurnal uquçılar arasında rəsemdəge keşelərne belüçelər tabılır? Məqələ şulay təmamlana ide.

Küp tə ütməde, Ufadan, yazuçı həm ədəbiat belgeçe Sufian Safuanovtan xat kilep təşte. Ul bu rəsemneņ tarixın açıqlap, bolay dip yaza. Rəsem şağirneņ Ufa yaqlarına berençe kilüe, Dim buyında qımız eçep yal itüe belən bəyle. 1930 yılnıņ cəyendə Məskəw dəwlət universitetı studentı Musa Cəlil kanikul waqıtında başta Qazanğa kilə, monda ber atna çaması torğannan soņ, yəşlek dustı Təxfət Çenəkəy belən bergələp alar paroxodta Ufağa baralar. Monnan Musa Məğərif eşçelərе profsoyuzınıņ Çişmə stansiəsennən yıraq bulmağan, Dim buyında utırğan Qara Yaqup awılındağı yal yortına urnaşa.

«Yal yortı digəç tə, xəzerge məğnədəge yal yortı tügel ide ul,—dip yaza ataqlı başqort yazuçısı Əkrəm Wəli.—Anıņ ber-ike awıl əyen quşıp salğan aşxanəsennən başqa qaraltısı da yuq ide. Yal itüçelər məktəp binasında həm awıl xalqınıņ əylərendə toralar ide. Şulay da küņelle ide bu yal yortında. Anıņ təzeleşe tügel, ə yal itüçe keşelərе həm Dim buyınıņ ğəcəyep tabiğəte küņelle ide.»



Musa kendəleklərendə bu çor turında bolay yaza: «Andağı ber ay bik küņelle ütte. Anda da səyü-səyelülər bulmadı tügel. Kərrə digən başqort qızı mine betenləy sixerləde. Ləkin min aņardan tiz aynıdım».

S. Safuanov açıqlawı buyınça, rəsemdəge qızlarnıņ berse Musanıņ başın əyləndergən «başqort qızı Kərrə» (ul suldan berençe). Kərrə Kaçkina— Başqortstannıņ İglin rayonındağı Tübəndəge Ləməz awılı qızı. Soņraq ul jurnalist Ğarif İşmayevqa kiəwgə çıga. Ğ. İşmayev ğomereneņ azağına qədər «Qızıl taņ» gəzite redaksiəsendə xezmət itə. Ə Kərrə Başqortstan ASSR Yuğarı Sovetı Prezidiumı apparatında eşli, ike ul üsterə. Xəzer ul mərxümə inde.

Rəsemdəge ikençe qız—Lələ Jdanova (suldan ikençe). Lələ rəsemneņ tarixı turında istəlek yazıp qaldırğan. Ul «Sovet Başqortstanı» gazetınıņ 1966 yıl 15 fevralendə basılğan. «...Bez bergələp iyül' betkənçe yal ittek, annan bergələp Ufağa qayttıq. Tağın ber kiçtə bergələp cıyılışıp, cırlaşıp utırdıq həm

fotoğa təştek»,—dip yaza L. Jdanova «Qarayaqup istəlege» isemle yazmasında. Altmışınçı yılarnı ul uqıtuçı bulıp eşli. Aldağı yazmışı bilgesez.

Rəsemdəge əçençe keşe—Qadıyr Bakirov (unnan berençe). Q. Bakirov ğəmere buyı sənğət' əlkəsendə eşli. Ul Başqort dəwlət akademiə teatrında həm respublikanın başqa drama teatrlarında, Başqort dəwlət filarmoniəsendə rejissyor bulıp ozaq yıllar buyı eşli, orden-medal'lər belən büləklənə.

S. Safuanov bik dəres kürsətkənçə, Musa Cəlilnen künelen Başqortstan, biredəge dusları, teləktəşləre, qələmdəşləre hərwaqıt üzenə tartıp tora. 1930 yıldan son da Musa berniçə mərtəbə bu yaqlarğa kilə. Ufada, Yomataw şifaxanəsendə, Tuymazıda bula, başqort yazuçıları belən aralaşa, yəmle Dim buylarına soqlanıp matur-matur şiğerlər yaza.

**Rafael' MOSTAFİN.**

---

## *Uquçı süze*

. . .

İsənmesez, xörmətle «Qazan utları». Təmən əlkəse, Yalutor rayonı, İsət urta məktəbe uqıtuçısı Qadırova Asia yaza. Min matematika uqıtuçısı həm 8 nçe klassta klass citəkçese bulıp eşlim.

Menə küptən tügel min «Qazan utları» jurnalının 2001 yılnın 3 nçe sanında Mədinə Malikovanın «Marat abıy» digən oçerkın uqıdım. Həm bik şatlandım, çənki Marat abıy Məlekov beznen İsət məktəbendə uqığan, monda belem alğan. Anın turında məktəp muzeyında stend bar. Biredə anın üz qulı belən bülək itelgən kitapları. Elek ul tuğan yaqlarına qaytsa, hərwaqıt beznen məktəpkə kerep uqıtular, tormış belən qızıqsınıp kitə ide. Bez anı onıtmadıq, muzeyğa kergən hər keşegə anın turında səyləp torabız.

Awılıbız zur bulmasa da, ər-yana ike qatlı məktəp açıldı. Yana uram təzelep kilə həm şul uramğa bez məktəp kollektivı belən «Marat Məlekov uramı» dip isem birergə materiallar cıyabız. Bez anın belən ğorurlanırğa tieşbez, uquçılarıbızğa həm awıl xalqına ul zur ürnək.

Mədinə Malikovağa oçerkı əçen zur rəxmət, əgər Marat abıy turında tağın materiallarığız bulsa, alarnı beznen məktəpkə cibərsəgez ide.

**Asia QADIROVA,**
*Təmən əlkəse, Yar awılı.*

. . .

«Qazan utları» jurnalı xezmətkərlərе-qərdəşlər-tuğannar! Minem sezgə şundıyraq üteneçem bar. Eş şunda, jurnalığıznı küptənnən aldırsam da, yıl buyına bəten nomerların da alıp bulmıy. Yılnın berençe yartısına yazsalar, poçtada inde, ikençe yartısına yazmıylar. Küp waqıt «podpiska yuq»,—dip aqçanı kire qaytarıp birələr. 2001 yılnın ikençe yartısına şulay buldı, ə 2002 yılğa bətenləy yazmadılar. Min sezdən şunı sorar idem, əgər ütkən yılnın ikençe yartısı (2001) jurnalları artıp qalsa, şularnı cibərə almassızmı? Tağın, 2002 yılğa jurnalnı seznen aşa alıp bulmasmı? Sonğı waqıtta elek alğan jurnallarnı uqıp waqıt ütkərdem, ikeşər-əçər mərtəbə uqıp çıqtım inde. Jurnalnın eçtəlegenə minem üpkə-sapqam yuq. Qayber avtorlarnın əzrək citeşməgən cirlərе bulsa, «aşlıq kibəksez bulmas» dim.

Sorağan jurnallarnı bulsa, poçta aşa salığız ələ. Min xaqın cibərer idem. Yənə kilep, jurnalğa podpiskanı, xaqın arttırıbraq bulsa da, ber yılğa yazdırırğa ide.

**Nail ĞİZETDİNOV,**
*Başqortstan, Aqberdino posyologı.*

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ КОРЫЛТАЕ

Шушы елның 31 маенда К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Татарстан язучыларының XIV корылтае булды. Аны кереш сүз белән яшь ягыннан иң өлкән аксакал язучы Сафа Сабиров ачты.

Корылтайда катнашучыларны Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев котлады. «Язучыларның зур җыелышы—Татарстан өчен гаять әһәмиятле вакыйга,—диде ул үзенең чыгышында.—Безнең республикабыз халкы, гомумән, татар халкы әдәбиятны ярата... Күп гасырлар буена әдәбият үзенә күрә мәктәп, тәрбия һәм җан азыгы булып хезмәт итте, алдынгы идеяләрне алга сөреп, тормышның катлаулы сорауларына җаваплар бирә килде».

Президент бертөркем каләм әһелләренә—Кави Латыйп белән Разим Вәлиуллинга Татарстан Республикасының Мактау грамотасын, ә Азат Вергазов белән Вахит Имамовка «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнең диплом һәм билгеләрен, шулай ук Язучылар берлегенә яңа микроавтобус ачкычын тапшырды.

Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турындагы хисап доклады белән идарә рәисе Фоат Галимуллин чыкты. Ревизия комиссиясе хисабын Лирон Хәмидуллин ясады. Әдәби жанрлар буенча Резеда Әхтәмова (шигърият), Факил Сафин (проза һәм публицистика), Рафис Корбан (балалар әдәбияты), Дания Гыймранова (драматургия), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Флера Сафиуллина (әдәби тел мәсьәләләре) өстәмә докладлар ясады.

Докладлар буенча фикер алышуда Гөлшат Зәйнашева, Гәрәй Рәхим, Вахит Имамов, Разим Вәлиуллин, Зиннур Мансуров, Мәдинә Маликова, Рабит Батулла, Фәүзия Бәйрәмова, Җәүдәт Дәрзаман, Лена Шагыйрьҗан, Зәки Зәйнуллин, Айдар Хәлим, Владимир Лавришко, Илсур Хәснетдинов һ. б. чыгыш ясады.

Корылтайда альтернатив нигездә күпчелек тавыш белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп Фоат Галимуллин сайланды. Берлек идарәсенә түбәндәге язучылар үтте: Харрас Әюпов, Фәүзия Бәйрәмова, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Разим Вәлиуллин, Лилия Газизова, Галимҗан Гыйльман, Җәүдәт Дәрзаман, Вахит Имамов, Рәфкать Кәрами, Зиннур Мансуров, Хатип Миңнегулов, Газинур Морат, Шәһинур Мостафин, Рашат Низами, Гәрәй Рәхим, Данил Салихов, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Зиннур Хөснияр, Солтан Шәмси.

Язучылар корылтаенда шулай ук ревизия комиссиясе сайланды.

Шушы елның октябрь аенда Русиядә үткәрелә торган халык санын алу уңаеннан съездда катнашучылар татар халкына мөрәҗәгать кабул иттеләр.

Татарстан язучылары корылтае эшендә Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин, мәдәният министры Илдус Тарханов, Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов һ. б. рәсми кешеләр катнашты.

### ИДЕЛ-УРАЛ ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ

Татарстан республикасы белән Свердловск өлкәсе арасында икътисад һәм мәдәният килешүенең 5 еллыгы уңаеннан Свердловск өлкәсендә Татарстан көннәре булып узды. Анда Президент Минтимер Шәймиев җитәкчелегендә республика хөкүмәте әгъзаларыннан, Югары Совет, милли автономия, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты вәкилләреннән, эре предприятиеләр җитәкчеләреннән торган рәсми делегация катнашты.

Ике арадагы хөкүмәтара килешүгә 5 ел тулу күп вакыт түгел, әмма ул һәр якның да икътисади һәм мәдәни үсешенә зур этәргеч ясады. 1999 елда ук Татарстанның Свердловск өлкәсе белән товар әйләнеше 2,4 тапкыр артты. Безнең республика Урал төбәгенә авыр йөк машиналары, җиңел автомобильләр, шин, мазут, азык-төлек, синтетик-каучук, эчемлекләр, куллану әйберләре җибәрә. Татарстан аннан кара һәм төсле металл, корыч торбалар, экскаваторлар, төзү материалы, бизәнү әйберләре ала.

Бу төбәктә 240 мең татар яши. Өлкә губернаторы Эдуард Россель аларның эшчән

халык булуы белән горурлана. Татарлар күп районнарда зур-зур авыллар булып тупланган. «Уралтрансмаш» предприятиесендә, оешмаларда булган очрашуларда милләттәшләребез Минтимер Шәймиев белән рәхәтләнеп татарча сөйләштеләр. Якынлык һәм ихтирам хисләре сәүдәгәр Агафуров йортында «Татарстан—Яңа гасыр» телеканалын һәм «Татарстан» журналының Свердловск өлкәсенә багышлап чыгарылган санын тәкъдим итүдә дә сизелеп торды.

Минтимер Шәймиев һәм Эдуард Россель Татарстан һәм Свердловск өлкәсе Россиянен иң көчле икътисади төбәкләре икәнен искәртеп, алар нык булганда гына Россиянең көчле булачагын әйтеп үттеләр.

Свердловск өлкәсендә Татарстан көннәре барышында Минтимер Шәймиев һәм Эдуард Россель 5 ел элек төзелгән килешүгә өстәмә рәвештә 2002—2003 елларга сәүдә-икътисади хезмәттәшлек турында беркетмәгә һәм үзара аңлашу меморандумына кул куйдылар.

**ФЕСТИВАЛЬЛӘР, ФЕСТИВАЛЬЛӘР...**

* * *

Май аенда Казан төрле иҗат фестивальләренең үзгә бер «Мәккә»се булып торды, башкалада халыкара дәрәҗәдәге берничә фестиваль-тамаша узды. 20-26 май көннәрендә төрки халыкларның VII «Нәүрүз» театр фестивале үткәрелде. Анда 14 театр—Анталия дәүләт театры (Төркия), Дәүләт яшь тамашачы театры (Әзәрбайҗан), «УЧУР» яшьләр телетеатры (Кыргызстан), Г. Мусрепов исемендәге Казакъ дәүләт балалар һәм яшүсмерләр академия театры, Кырым татарлары музыкаль-драма театры, Саха республикасы дәүләт юмор һәм сатира театры, Хакасия милли театры, В. Кок-ола исемендәге Тува музыкаль-драма театры, М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры, «Нур» Уфа татар дәүләт театры, К. В. Иванов исемендәге Чуаш дәүләт академия драма театры, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, М. Фәйзи исемендәге Оренбург Татар дәүләт драма театры катнашты.

«Нәүрүз» фестивале ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан Россия Мәдәният министрлыгы, Россия театр әһелләре берлеге, төрки мәдәниятен һәм сәнгатен бердәм үстерү халыкара оешмасы «ТЮРКСОЙ» катнашында үткәрелде.

Фестивальне ачу тантанасында Татарстан Президенты М. Шәймиев катнашты һәм чыгыш ясады.

* * *

22 май көнне Муса Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет театры бинасында Рудольф Нуриев исемендәге XVI халыкара классик балет фестивале ачылды. Ул композитор Л. Любовскийның шагыйрь Р. Харис либреттосына язылган «Йосыф кыйссасы» балеты белән башланып китте. 31 майга кадәр дәвам иткән бу фестивальдә П. Чайковский, Ф. Яруллин, А. Адам һ. б. композиторларның әсәрләре башкарылды.

* * *

Шул ук театр бинасында нефть төбәге сәләтле балаларының «Сандугач сайрар илем» дип исемләнгән сәнгать фестиваленең йомгаклау концерты булып үтте. Анда Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарыннан килгән 400ләп яшь башкаручы катнашты. Фестивальне «Татнефть» ААҖнең «Рухият» фонды оештырган.

**КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ БҮЛӘК АЛА**

«Бәллүр каләм» республика журналистлар конкурсына йомгак ясалды. «Журналистикада исем» номинациясендә «Бәллүр каләм» призы А. Юнысова, Й. Шәрәпова, Р. Вафин, И. Шиһапов, Р. Щербакова, Л. Толчинский, Н. Кәримова, Н. Гыйматдинова, Э. Хамматова, Т. Нәҗмиевкә бирелде. Шушы ук номинациядә ТР прокуратурасының матбугат үзәге житәкчесе Р. Хажиевны (үлгәннән соң) билгеләп үтәргә карар кылынды. (Искәртеп үтик, бүләкләнүчеләрнең өчесе—Татарстан язучылар берлеге әгъзалары: А. Юнысова, Т. Нәҗмиев, Н. Кәримова—безнең журналның да авторлары.)

«Ел дебюты» номинациясендә «Бәллүр каләм» бүләкләре А. Цыганов белән Л. Хәйруллинага тапшырылды. «Журналистлар белән аралашуда ачыклык өчен» дигән призга Әлмәт шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы Р. Әбүбәкеров лаек булды.

**ЯҢА РӘИС**

Татарстан Президенты М. Шәймиевнең 2002 елның 5 июнендә чыккан Указы белән Мортазин Ирек Минзәки улы «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе рәисе итеп билгеләнде. И. Мортазин моңарчы соңгы өч елда Татарстан Республикасы Президентының матбугат үзәге житәкчесе булып эшләгән иде.

**МУЗЕЙЛАР ДА ЯРЫША**

Мәдәният министрлыгы коллегиясе карары белән елның иң яхшы ике музее билгеләнә. Музейларның былтыргы эшчәнлекләренә йомгак ясап, җиңүчеләр дип Г. Тукайның казандагы әдәби музее һәм Лаешның төбәкне өйрәнүче тарих музее табылды. 16 май көнне мәдәният министрының беренче урынбасары Рафаэль Вәлиев Г. Тукай музеена килеп, музей эшчәнлегенә зур бәя бирде, андагы хезмәткәрләрне Халыкара музейлар көне белән котлады. Эмиль Җәлалетдинов, Зөһрә Сәхәбиеваның Тукай сүзләренә язган җырларны башкарулары тамашачылар

күнеленә бик тә хуш килде.

Музей директоры Мөҗип Низамиев килгән кунакларга, бүләк иясләренә бик зур рәхмәт әйтеп, музейның кешеләрне, бигрәк тә яшьләрне тәрбияләү өлкәсендә әһәмияте зур икәнен искәртеп үтте.

### КИРӘКЛЕ СӨЙЛӘШҮ

Башкалада «Республика мәктәпләрендә һәм көллиятләрендә татар телен латин графикасы нигезендә укыту буенча эксперимент эше» дигән темага семинар-киңәшмә үткәрелде. Татарстан Мәгариф министрлыгы һәм Укытучылар белемен күтәрү институты тарафыннан үткәрелгән әлеге семинар-киңәшмәдә татар телен латин графикасында укыта башлау турында эшлекле сөйләшү алып барылды һәм тәкъдимнәр кертелде.

### МУСА ҖӘЛИЛ ФОНДЫ ОЕШТЫ

Оренбург өлкәсенең Шарлык районы Мостафа авылында Муса Җәлил исемен мәңгеләштерүче төбәкара иҗтимагый фонд оешты.

Фонд хезмәткәрләре шагыйрьнең туган авылында мемориаль музей комплексын төзү башлангычы белән чыкты, шагыйрьнең тормышына һәм иҗатына бәйләнешле булган төбәкләргә—Оренбург өлкәсе, Татарстан, Башкортстан республикалары дәүләт структураларына ярдәм күрсәтү үтенече белән мөрәҗәгать итте. Мемориалны ачу татар халкының бөек улы, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулган көннәрдә, ягъни 2006 елда планлаштырыла.

### ҖАНГА ЯКЫН ӘДИПЛӘР ЯГЫНДА

Язучы Фәүзия Бәйрәмова Мордова Республикасында булып кайтты. Ул татарлар күпләп яшәгән Белозерье авылында, Шәриф Камалның туган авылы Татар Пешләсендә, Ләмбрәдә, Һади Такташның туган авылы Сыркыдыда, Гафур Колахмәтов җирләнгән Юнә авылында, Габдрахман Әпсәләмовның туган авылы Аллаголда, шулай ук Рузаевка һәм Саранск шәһәрләрендә булды, мәчетләрдә, мәктәп, китапханәләрдә халык белән очрашулар үткәрде.

### АЛЬБАТРОС ЯЗМЫШЫ

Май аенда күренекле прозаик, публицист Миргазиян Юныйска 75 яшь тулды. Ул—«Тозлы җил», «Теләп алган давыл», «Энҗе эзләүчеләр», «Биеклектә калу», «Табу һәм югалту» кебек халык арасында ихтирам казанган әсәрләр авторы. Юбилей алдыннан аның тагын бер китабы—«Альбатрос язмышы» исемлесе дөнья күрде. Шул китапны тәкъдир итү кичәсе Казанның Халыкара дуслыгы йортында үтте.

### СӨЛӘЙМАНОВ УКУЛАРЫ

Түмән шәһәренең Д. Менделеев исемендәге фәнни китапханәсендә 2002 елгы Сөләйманов укулары узды. Монда ике көн дәвамында Себердә туып үскән күренекле татар шагыйре, җәмәгать эшлеклесе Булат Сөләйманов рухы хәтердә яңартылды.

Ул «Көнбатыш Себер татарлары: башка халыклар белән этно-мәдәни мөнәсәбәтләр» дигән темага узды. Эшлекле әңгәмәләр барышында милләттәшләребезнең мәдәниятен, мәгарифен, матбугатын, тарихын, әдәбиятын, сәламәтлеген саклау һәм үстерү хакында ихлас чыгышлар ясалды.

### ЮБИЛЕЙ УҢАЕННАН

Язучы Әбрар Шәминнең тууына 90 ел тулу уңаеннан 6 июньдә аның туган төбәге Кайбыч районы үзәгендә Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая музеенда китап укучылар конференциясе үткәрелде. Анда әдипнең якташлары, музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина, Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев, балалар шагыйре Рафис Корбан, шулай ук мәдәният министрлыгы вәкилләре һәм язучының туганнары катнашты. Ә. Шәмин туып-үскән урамга аның исеме бирелде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбияты өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аппаратының баш референты Тарханова Флера Габдрахман кызы Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Ямьле җәй»—*Ә. Бикмөхәммәтова фотоэтюды.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрә Фирая Зыятдинова.

# ЯҢА КИТАПЛАР

ДАУТОВ Рәис. **Балачак әдипләре**: Био-библиографик белешмәлек. Беренче китап.—Казан: «Мәгариф» нәшр.—2002.—224 б. Тиражы—3000 данә.





«Мәгариф» нәшрияты «Балачак әдипләре» дигән сериядән күренекле татар язучылары турында биографияләре, портретлары белән татар һәм рус телләрендә белешмәлек-китаплар бастырып чыгара башлады.

Әлеге сериядән беренче китапка мәктәп программаларына исемнәре кергән һәм төрле сыйныфларда иҗат биографияләре өйрәнелгән хәзерге заман татар язучылары (Алар китапта утыздан артык: Г. Афзал, И. Юзеев, А. Гыйләҗев, Р. Фәйзуллин, Ф. Яруллин, Ш. Галиев, Т. Миннуллин, М. Юныс, Роб. Әхмәтҗанов, Р. Миңнуллин, Ә. Баянов, Р. Харис, Р. Батулла һ. б. Белешмәлек Татарстан Республикасының Балалар китапханәсе тәкъдим иткән исемлеккә таянып эшләнгән) хакында мәгълүматлар бирелә. Китапка кереш сүзне шагыйрь Роберт Миңнуллин язган. Белешмәлек—мәктәп укучылары, укытучылар, балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр һәм, гомумән, әдәбият белән кызыксынучылар өчен файдалы әсбап.

Китапның редакторы—Л. Гыйззәтуллина, рәссамы һәм бизәлеш редакторы—Л. Золондинова.

ЛАТЫЙФИ Флүс. **Ишелеп төшкән бәхет:** Роман.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.—416 б. Тиражы—3000 данә.




Күренекле язучы Флүс Латыйфи (үткән ел аның 3 томлык «Сайланма әсәрләре» дөнья күрде) мәхәббәт, дуслык-иптәшлек, вәгъдә һәм әманәткә тугрылык, хыянәт кебек тирән психологик кичерешләрне сурәтләү остасы санала. Ф. Латыйфиның бу яңа китабы да шуны раслый.

Әсәрдә егерменче гасыр дәвамында татар халкына карата үткәрелгән яшерен геноцид сәясәтенең кешеләр язмышын ботарлап ташлавы, хәтта киләчәк буыннарга аянычлы тәэсире җете буяулар белән ышандырырлык итеп сурәтләнә. Чит илләргә чыгып китәргә мәҗбүр һәм Ватанда яшәгән милләттәшләр, аларның үзара мөнәсәбәтләре, яшьләрнең күңел сафлыгы, рухи чисталыгы хакындагы мавыктыргыч вакыйгалар беркемне дә битараф калдырмый.

Китап ике имляда—ягъни, латин һәм кириллица графикаларында басылган. Редакторы—Н. Вәлитова, рәссамы—Ю. Щетинкина.

Индекс 73210



Фирая Зыятдинова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)